ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ

ШӘЕХЗАДӘ
БАБИЧ

Зәңгәр җырлар

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ

Зәңгәр җырлар

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ

ЗӘҢГӘР ҖЫРЛАР

ШИГЫРЬЛӘР, ПОЭМАЛАР, ЭПИГРАММАЛАР, МӘКАЛӘЛӘР, ХАТЛАР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1990

ШАЙХЗАДЕ БАБИЧ

ГОЛУБЫЕ ПЕСНИ

СТИХИ, ПОЭМЫ, ЭПИГРАММЫ,
СТАТЬИ, ПИСЬМА

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
1990

ББК 84(2Р-Тат)-45
Б12

Җыентыкның төзүче-редакторы, текст һәм фәнни аппаратны хәзерләүче, кереш сүз авторы

ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНОВ

Бабич Ш.

Б12 Зәңгәр җырлар: Шигырьләр, поэмалар, эпиграммалар, мәкаләләр, хатлар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.— 544 бит.
ISBN 5—298—00445—8

Күренекле татар-башкорт шагыйре Шәехзадә Бабичның яңа җыентыгына шигъри әсәрләр, поэмалар, эпиграммалар, мәкаләләр, көндәлек язмалары һәм хатлар тупланды.

Китап киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Б $\frac{4702510000—066}{М132(03)—90}$ 135—90 ББК 84(2Р-Тат)-45

ISBN 5—298—00445—8 © Галимҗан Гыйльманов, төзү, искәрмә һәм аңлатмалар, 1990

ТӨЗҮЧЕДӘН

Күренекле татар-башкорт шагыйре Шәехзадә Бабичның яңа «Сайланма»сы — моңа кадәр дөнья күргән җыентыкларның иң тулысы. 1917—1918 елларда иҗат ителгән берничә әсәрне исәпкә алмаганда, аңа шагыйрьнең барлык билгеле әсәрләре дә кертелде. Шулай ук Ш. Бабичныкы булуы ихтимал кайбер әсәрләр дә тәкъдим ителде. Бу — Бабич иҗатын ачыклау, җыю мәсьәләсен тагын бер мәртәбә көн тәртибенә кую максатыннан эшләнде.

Җыентыкка шулай ук шагыйрьнең публицистикасы, халык иҗатына бәйле язмалары, көндәлек дәфтәрләреннән өзекләр, хатлары урнаштырылды. Бабич иҗатының моңа кадәр аз өйрәнелгән якларына укучы игътибарын юнәлтү, әдипнең иҗат юлын, әдәби мирасын мөмкин кадәр тулырак күзаллау өчен бу бик мөһим иде.

Җыентык шагыйрьнең 1910 елда иҗат ителгән шигырьләре белән ачыла. Төзүче фикеренчә, шагыйрьнең беренче чор иҗаты нәкъ менә 1910—1913 елларны үз эченә ала. Өйрәнчек шигъри язмалар исә (1907—1909) аерым бүлек рәвешендә поэтик әсәрләрнең ахырында бирелде.

Төзү процессында текстлар чыганак буенча, ягъни оригиналдагыча алынды. Шуңа күрә аерым әсәрләрдә тел төрлелеге күзәтелә. Бу, беренчедән, шагыйрь салган поэтик ритмны төгәл саклау өчен кирәк була, икенчедән, аның әдәби мирасын фәнни нигездә кабул итү өчен кирәк. Чөнки тәкъдим ителгән җыентык бер үк вакытта киң катлам әдәбият сөючеләргә дә, әдәбият галимнәренә, укытучыларга, студентларга да атап чыгарыла.

Әсәрләр мөмкин кадәр хронологик тәртиптә китерелде. Аларның язылу датасы, автор билгеләгәнчә яисә матбугатта

басылып чыгуына карап, һәр текстның алдында бирелде. Язылу һәм басылу датасы иске стильдә калдырылды.

Хәзерге әдәби телдә булмаган аерым сүз һәм гыйбарәләр төшермәләрдә аңлатылды. Йолдызчык (*) белән күрсәтелгән очраклар автор тарафыннан бирелгән текст асты аңлатмаларына ишарә булып торалар.

Текстларга караган төп чыганаклар, аңлатма-искәрмәләр җыентыкның ахырында әсәр урнаштырылган бит күрсәтмәләре белән бирелде.

Алынма сүзләрне мөмкин кадәр үз традицион язылыш һәм әйтелешләренә якын итеп бирү максат ителде. Калган очракларда хәзерге орфография кагыйдәләре күздә тотылды. Тик кайбер шигъри әсәрләрдәге ритм һәм рифма үзенчәлекләрен саклау йөзеннән аерым чыгарма-чигенешләр ясалды (мәсәлән, «ы, е» төшеп калуы, «в, у» күчешләре — күңлем, аулым һ. б.; сүзләрнең кушылуы — аныңчөн, сабриталмас һ. б.).

Кайбер кыскартулар җәяләр эчендә нокталар (...) белән билгеләнде.

КОЯШЛЫ ШИГЪРИЯТ

Бабичлар — Башкортстан җирендә элек-электән билгеле нәселләрнең берсе. Аларның туган илләре — матур Агыйдел буена урнашкан, куе урманнар белән уратып алынган Кыйгазытамак авылы.

Нәсел атасы — Мохтар баба — Казан тирәсеннән күчеп килгән кеше. Анда ул ниндидер бер фабрика яисә мастерской тотып, бөлепме, сәүдә эшләре беләнме, хәзерге Башкортстан җирләренә килеп чыккан һәм Агыйдел буйларында төпләнеп калган. Шул да билгеле — Мохтар үзенә хатынлыкка тирә-якта чибәрлеге белән дан тоткан бер башкорт кызын алган. Аларның бер-бер артлы биш уллары туа — Илекәй, Ишкилде, Ишбулды, Ишалды һәм Гайнулла.

Мохтар баба хәлле генә кешеләрдән була. Ул үз улларына кечкенәдән төпле белем, һөнәр бирү ягын карый. Аның биш малае да тирә-якта билгеле кешеләр булып җитешәләр.

Мәсәлән, Илекәйнең 1812 елгы Ватан сугышында катнашуы билгеле. Буыннан-буынга күчеп килүче шәҗәрә язмаларында аның бу сугышта зур батырлыклар күрсәтүе, орден белән бүләкләнүе һәм полковник чины алуы хакында әйтелгән. Җитмәсә, сугышта аеруча танылган гаскәр башлыкларына патша хөкүмәте Уралдан, Себердән уңдырышлы җирләр өләшә. Илекәй исә үз хезмәтләренә күрә туган ягы Агыйдел буйларыннан җир сорый. Күп тә үтми, ул Кыйгазытамак тирәсендәге авылларга контон башлыгы итеп билгеләнә.

Илекәй тиз арада үз тирәсенә энеләрен җыеп ала. Алар — биш бертуган баһадир — иңгә-иң терәп тормыш итә башлыйлар. Ишкилде Кыйгазытамак тирәсендәге бер авылда указлы мулла булып тора, Ишалды өлкән абыйсы контонында старшина хезмәтен башкара, ә Гайнулла хакында берниндн мәгълүмат та сакланмаган.

Ишбулды исә, Ишкилде абыйсы артыннан ук Указ алып, Кыйгазытамакка мулла итеп куела. Шагыйрь Шәехзадә Бабичның нәсел җебе нәкъ менә шушы Мохтар, Ишбулды бабаларыннан башланып киткән. Бу нәсел кешеләре элек-электән руханилык белән шөгыльләнгәннәр. Ишбулдының дүртенче малае Гыйльван Шады авылында мулла булып торса, Гыйльванның Мөхәммәтзакир исемле улы да язмышын мәчет-мәдрәсә белән бәйли.

Закир ата-анасыннан сигез яшендә ятим кала. Малайны әнисе ягыннан бабасы — Әхмәт бабай (аны тирә-якта «Аксакал», «Ак бабай», «Ширин бабай» дип тә йөрткәннәр) тәрбияләп үстерә. Ул оныгын Өсән авылы мәдрәсәсенә укырга илтеп бирә һәм үзе дә шунда торып кала.

Закир Әсәннең икенче мәхәллә мәдрәсәсендә иң алдынгы шәкертләреннән санала. Озакламый мәдрәсә программасын алданрак һәм уңышлы тәмамлаган егетне хәлфә итеп куялар. Соңрак ул икенче мәхәлләнең мулласы, мөдәррисе һәм имамы итеп тә билгеләнә. Нәкъ ул укыткан чорда Әсәннең җәдитчелек рухындагы мәдрәсәсе үсеш чоры кичерә; анда «Иж-Буби» мәдрәсәсеннән, Казаннан, Уфадан килгән хәлфәләр белем бирә.

Мөхәммәтзакир мулла үз гомерендә өч тапкыр өйләнә (беренче һәм икенче хатыны авырып дөнья куя); аның унҗиде баласы була. Шуның унбере генә исән үсә. Шәехзадә — өченче хатыны Бибисаҗидәбануның баш баласы.

Мөхәммәтзакир мулла тирә-якта гаделлеге, туры сүзле булуы, ярлыларны кыерсыткан кешеләргә катылыгы белән аерылып тора. Әсән авылның беренче кадим мәдрәсәсе муллалары белән судлашуга кадәр барып җитә. Суд кадимчеләрнең указларын алу белән тәгәлләнә. Мөхәммәтзакир зур китапханә оештыра, бакчачылык, сабын кайнату эшләре белән шөгыльләнә, ул чорда чыгып килгән барлык газета-журналларны да диярлек алдырып тора, җыеннарда дөнья хәлләрен аңлатучы буларак та таныла. 1905 елгы Рус-япон сугышы хакындагы шундый бер чыгышы өчен ул төрмәгә дә эләгә, Указын алдырта. Авыл халкының кат-кат язып соравыннан соң гына хәзрәт азат ителә һәм элекке эшенә куела [1].

Бибисаҗидәбану абыстай беренче кадим мәхәлләдә мулла булып торган бер татар кешесенең кызы. Ул — артык тыйнак, авыр сабырлы, уку-язуга бик һәвәс түгел, аның каравы, чигү-тегү эшенә бик оста, җыр-моң яратучан, йомшак күңелле хатын була.

Замандашларының истәлекләренә караганда, Ш. Бабич үзенә әтисенен гаделлеген, туры сүзлелеген, белемгә һәвәслеген, зирәклеген алса, әнисенең җыр-моңга мәхәббәтен, нечкә күңелен кабул иткән. Бу характер сыйфатлары соңрак аның бөтен тынгысыз тормышында, ярсу иҗатында чагылыш таба.

2

Шәехзадә Бабич 1895 елның 15(2) январенда Башкортстанның Дүртөйле районы (элеккеге Уфа губернасы, Бөре өязе) Әсән авылында безгә таныш Мөхәммәтзакир мулла гаиләсендә туган. Йорттагы төп хуҗалык эшләрен кызлары белән хәзрәт үзе алып барганлыктан, Шәехзадә кечкенәдән иркенлектә, кыенлык күрмичә үскән. Аның бөтен шөгыле — җыр-бәет чыгару, бакчаларындагы иң биек өянкегә эленгән бишектә такмак сөйләп, җырлап яту, кәмит күрсәтү, «театр» уйнау. Уку яшенә житкәч, малай әтисенең җәдит мәдрәсәсендә укый башлый. Шунда ул Бабичларның зур китапханәсен ачып керә, шунда чын шигърият белән очраша, аеруча Г. Тукай иҗатын яратып күңеленә сала.

1908 елда абыйсы Фәтхелкадиргә ияртеп, Мөхәммәтзакир мулла Шәехзадәне Кыйгазытамак авылы мәдрәсәсенә мөгаллим-хәлфә итеп җибәрә. Шунда бер ел укытып кайтканнан соң, үсмер егетнең карары үзгәрә — аның күңеле ераграк офыкларга омтыла, ә хыяллары киңрәк дөнья таләп итә. 1910 елның җәй айларында Бабич казакъ далаларында хәлфәлек итеп йөри. Шәйх-мүлдәкә көндәлекләреннән

---

[1] Кара: БАССРның Үзәк дәүләт архивы. Фонд 11. Тасвирлама 2, саклау берәмлеге 73, 3—119 битләр.

шул билгеле: беренче баруында булачак шагыйрь Кустанай өлкәсенең Тургай тирәсендәге Дүсәнбай авылында балалар укыта. Казакъ балаларына «мүлдәкәлек» итәргә Бабич тагын 1913 елның җәй айларында чыга. Шәехзадә бу сәяхәтеннән яңа бер шигъри дөнья алып кайта. Ул — Абай иҗаты. «Мин Кунканбайның өләңендә фәсахәт, матурлык вә ләззәт табып, аны татарның Тукае, гарәпнең Имрелкайсе дәрәҗәсенә мендердем»,— дип яза ул соңрак [1]. Тукай, Абай иҗатлары аша булачак шагыйрьгә рус әдәбиятына да тәрәзә ачыла. Ул Лермонтов әсәрләрен аеруча яратып укый, ятлап йөри.

1911 елда Ш. Бабич, Уфага килеп, төрки дөньясында билгеле «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Беренче сыйныфта укыганда ук үзенең беренче шигырьләр җыентыгын әзерли, аңа «Әйтеп узыйм» дигән сүз башы яза. Әмма, билгесез сәбәпләр аркасында, бу китап чыкмый кала.

1912—1913 елларда Бабич халык иҗаты белән кызыксынып китә, Тукайның «Халык әдәбияты»н тырышып өйрәнә. Ул хәтта 1913 елда Троицкида чыгып килә торган «Акмулла» журналының берничә санында «Мәкальләр фәлсәфәсе» исеме астында мәкаләләр циклы да бастырырга өлгерә. «Галия» шәкерте бу «фәнни» тикшеренүләрен мәкальләрнең «мәгънәләрен, тәрбияләрен, фәлсәфәләрен» ироник ачыклауга багышлый [2]. Шул ук чорда ул мавыгып татар, башкорт халык көйләренең тарихын яза [3].

1913 елларда Бабичның исеме «Шура» (Оренбург) журналында күренә башлый. Ләкин ул монда фольклорчы булып түгел, шагыйрь булып чыгыш ясый.

Шәехзадә бик тиз арада «Галия»дә иң билгеле шәкертләрнең берсенә әверелә. Бабич бу елларда мәдрәсәдәге «Парлак» исемле кульязма әдәби журналның мөхәррире вазифасын башкара (үзе киткәч, шагыйрь журналны Г. Нигъмәти кулына тапшыра), «Милли көй, сәхнә вә әдәбият» түгәрәге җитәкчеләренең берсе була, үзе дә яшерен әдәби түгәрәк оештыра (Х. Туфан беренче иҗат адымнарын шунда ясый), мәдрәсәнең зур кыллы оркестрында беренче мандолиначы булып таныла. Җитмәсә, ул мондагы әдәби-музыкаль кичәләрне оештыручыларның, мәдрәсә идарәсенә җибәрелә торган делегация әгъзаларының иң активына, башлыгына әверелә.

Озакламый Бабичның эшчәнлеге мәдрәсә күләменә генә сыймый башлый. «Дворяннар сарае»нда һәм башка культура учакларында уздырыла торган кичәләрнең барысында да диярлек, 1914 елның көзеннән алып, Ш. Бабич даими катнашып бара. Ул анда үзенең шигырьләрен укый, конферансье вазифасын үти, хәтта спектакльләрдә рольләр дә башкара. Мәсәлән, аның 1916 елда Уфага килгән Г. Кариев белән берлектә берничә спектакль куюы билгеле. Соңрак Бабич үз концертларын җырчы Газиз Әлмөхәммәдов белән бергә оештыра башлый. Аларның шундый бер концерт программасы белән Мәскәүгә барырга җыенулары хакында да истәлекләр бар.

Татар, башкорт сәхнә сәнгатен үстерүдә Бабичның роле зур. Ул, төрки дөньясында беренче булып, концерт алып баручылар, артистлар өчен, төрле авторларның әсәрләрен төзеп, «Көлке капчыгы» исемендә җыентык чыгара. Бу китабында Бабич сатираны киңрәк җәмәгатьчелеккә җиткерергә омтылды, аның үтемлерәк чараларын эзләде. «Көлке,— диде ул,— кешене рәхәтләндерә, күңелне ача, эч пошуны баса,

---

[1] Бабич Ш. Сайланма әсәрләр (Х. Госман сүз башы).— Казан, 1958, 8 бит.
[2] Акмулла, 1913, № 30.
[3] Кара: Бабич Ш. Шигырьләр мәҗмугасы.— Казан, 1922.

җитди нәрсәләрне тыңларга бөек бер иҗтиһаэ бирә (теләк уята.— *Г. Г.*), ялыккан кешеләрне җиңеләйтеп җибәрә»[1].

«Галия»дә уку чорында (1911—1916) Ш. Бабич XX йөз башында милли культуралар үсешендә азмы-күпме роль уйнаган барлык татар, башкорт һәм өлешчә казакъ әдипләре, музыкантлары, телчеләре белән дә диярлек аралашып яши.

Бу чорда Уфадагы әдәби хәрәкәт М. Гафури тирәсенә тупланып бара. Бабич та аңа тартыла. Алар шулкадәр дуслашып китәләр ки, «Галия» шәкерте» «Шәрекъ матбагасы»нда М. Гафури урынында берничә тапкыр эшкә дә кала, анда корректор булып эшли.

1914 елның март аенда Уфага С. Рәмиев килгәч, яшь шагыйрь аның белән танышу юлларын эзли башлый. Күп тә үтми, алар арасында дусларча мөнәсәбәт урнаша. Шушындый талантлы әдипләр белән аралашып яшәү яшь шагыйрьнең поэтик осталыгын арттырырга ярдәм итә, дөньяда акны карадан аерырга өйрәтә.

Шулай да, «Галия» шәкерте Шәехзадә Бабич тормышына, иҗатына төп юнәлеш биргән кеше — Г. Ибраһимов. 1915 елда Уфага кайткан әдипне шәкертләр таләбе буенча «Галия» идарәсе татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп чакыра. Г. Ибраһимов татар-башкорт дөньясына таныла башлаган Бабичны, аның киләчәген бик тиз күреп ала һәм, шагыйрьнең талантын тулырак балкыту өчен, кулыннан килгәннең барысын да эшләргә тырыша. «Мин Бабичны байтактан бирле беләм,— дип яза ул 1922 елда.— Беренче очрашуым Уфада «Галия»дә әдәбият дәресләре укыткан чагымда булды. Ул тәкърир (сочинение.— *Г. Г.*) өчен бирелгән маузуг (темаларны да, күрсәткән планны да ... файдаланып, шундый кыйммәтле чаткылар чәчрәтә иде ки, әдәби зәвыклылар өчен аның сыйныф тәхрирләреннән ялтыраган истигъдады (сәләтлеге.— *Г. Г.*) белән сихерләнмәскә мөмкин түгел иде. Һәм шул вакытта мин аңа үзендәге табигый талантның үсүенә ярдәм бирер дип уйлаган чараларны кылырга тырыштым»[2].

Кызганычка каршы, безгә бу «кыйммәтле чаткылар» килеп җитмәгән. Алар хакында кайбер истәлекләрдән генә белә алабыз. «Шәехзадә Бабич «Чыңгыз хан» исемле бер әсәр язган иде,— дип искә ала З. Бикмурзин.— Бу әсәр Галимҗан Ибраһимов тарафыннан рецензияләнеп, бастырып чыгарырга ярарлык дип табылган иде, ни өчендер, ул басылмый калды»[3].

Шагыйрь Зариф Бәшири «Галия»не яңа тәмамлап чыккан Бабичның Г. Ибраһимов турында болай дип сөйләвен искә ала: «Ул укыта башлагач та, мин үземдә кискен борылыш башланганын сиздем. Аңа чаклы миндә дә матур әдәбиятта, бигрәк тә шигырьдә гарәп-фарсы сүзләрен куллану кирәк дигән бер караш бар иде. Шул уңай белән бервакыт Галимҗан агай миннән сорый: «Син киләчәкнең яктыга таба баруында нәрсәгә таянасың?» — ди. «Билгеле, мин әйтәм,— халкыма»,— дим. «Шулай булгач,— ди Галимҗан агай әйтә,— синең әдәби телең дә үз халкыңның теле булырга тиеш түгелме?» — ди. Шуннан соң, халык телен актарып, аның җәүһәрләрен эзләргә керештем»[4].

«Галия» мәдрәсәсен алты ел урынына биш елда уңышлы тәмамлап чыккан Бабич, 1916 елның җәен күренекле телче Вәли Хангилдин белән бер фатирда уздыра, балалар укыта (ул хәтта «Галия»

---

[1] Бабич Ш. Көлке капчыгы. Уфа, 1916, 2 бит.

[2] Бабич Ш. Шигырьләр мәҗмугасы.— Казан, 1922, 15 бит.

[3] Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр.— Казан, 1966, 81 бит.

[4] Бәшири Зариф. Замандашларым белән очрашулар.— Казан, 1968, 281 бит.

мөдире Зыя Камали улына да дәресләр бирә), «Аң» (Казан), «Шура» (Оренбург), «Кармак» (Оренбург), «Сүз» (Мәскәү), «Тормыш» (Уфа) газета-журналларында актив язышa, Агыйдел елгасында салчылар житәкчесе булып эшли[1].

1916 елның көзендә Бабич Троицк шәһәрснә укытучы булып китә. Февраль революциясен дә шатланып шунда каршылый. Ул чорда шагыйрь белән якыннан аралашып яшәүче Сәрвәр Әдһәмова болай дип яза: «1917 елда патшаны төшергән көннәрдә аның иксез-чиксез шатланып йөрүләре һәм демонстрация вакытында кулына кызыл байрак тоткан хәлдә җил-җил атлап барулары әле дә күз алдында»[2].

Революция тәэсирендә Бабич ныклап журналистлык эшенә тартыла, хәтта Әхмәт Таҗетдин Рахманкулов дигән журналист белән «Хөр милләт» исеме астында газета да чыгарып йөри. Газетаның беренче санында ук шагыйрьнең «Яшәсен эшчеләр!» шигырe басылып чыга. Шушы көннәрдә Бабич С. Кудашның, Җ. Юмаевның шигырьләре һәм үзенең «Тәмсил кисәге», «Хөррият бүләге» дигән әсәрләре кергән җыентык төзеп бастыра[3].

«Галия»дәге әдәбият укытучысы белән даими хат алышып торган шагыйрь, Ибраһимовның берничә чакыру хатыннан соң, 1917 елның июнь ахырларында Уфага кайтып төшә һәм остазы кул астында чыга торган «Ирек» газетасында язышa башлый.

«Ирек» үзе бу хакта: «Яшь шагыйрьләремездән Шәехзадә Бабич Троицкидан шәһәремезгә кайтты»,— дип хәбәр итә[4]. Бабичның бу чор эшчәнлеге хакында Г. Ибраһимов болай дип искә алган иде: «...Уфада (Бабич)» социалистлар белән бергә эшли, әдәбият кичәләрендә татар буржуазиясенең җанын җәһәннәмгә җибәрәчәк ачы көлкеләрен укый, безнең «Ирек»тә байларны каһәрләп шигырьләр яза, кайчандыр «танчы», «уралчы» булган булып, реакция вакытында янадан буржуазиягә сатылып, эшче-крестьяннан ваз кичкән мөртәт «социалистларны» сүгә... эшчеләрне киң колач белән каршы ала... революция каһарманнарына афариннар укый...»[5].

Әмма Бабич Уфада озак тормый. Аны, 150 сум эш хакы вәгъдә итеп, М. Гәләү «Кармак» журналына эшкә чакыра. Материаль хәле мактанырлык булмаган шагыйрь бу шартларга риза була. Җитмәсә, «Кармак» белән аның бәйләнеше күп еллар буе дәвам итеп килә.

Август аенда Оренбургка барып урнашкан Бабич җаны-тәне белән эшкә чума. Өстәвенә, ул шәһәрдә концертлар бирә, кичәләр уздыра, әдәби түгәрәкләр оештыра. Шунда аның күптәнге хыялы тормышка аша — шагыйрь Т. Ченәкәй аны Дәрдмәнд белән таныштыра[6]. Әмма Бабич бу чорда үзен чолгап алган иҗтимагый вакыйгаларга катлаулы мөнәсәбәттә тора. Социалистик революция алдыннан ук:

Һич тотар хәл юк кирәклене тезгенен,
Һич белер хәл юк фикернең төзлеген,—

дип икеләнә башлаган шагыйрь, 1917 ел ахырларында башкорт милли хәрәкәтенә барып кушыла. Бабичның ярсу, ашкынулы йөрәге эз-

---

[1] Совет әдәбияты, 1959, № 5, 105 бит.
[2] Әдһәмова Сәрвәр. Безнең Бабич.— Совет әдәбияты, 1965, № 1.
[3] Хөррият бүләге.— Троицк, «Энергия» типографиясе, 1917.
[4] Ирек, 1917, 25 июнь, № 24.
[5] Бабич Ш. Шигырьләр мәҗмугасы.— Казан, 1922, 18 бит.
[6] Ченәкәй Төхвәт. Тәүге һәм һуңгы осрашыуҙар.— Әҙәби Башкортостан, Өфө, 1960, № 6, 68—76 битләр.

ләгән «иҗтимагый хакыйкатьне» милли лозунглардан, матур вәгъдәләрдән табарга омтыла. Һәм шулай шомлы, «тезгенсез» вакыйгалар дулкынында бер ел чайкалганнан соң гына шагыйрь күңеленә «төз фикер» килә. Аның чын халык улы булуы шушы критик моментта күренде дә инде: Бабич бара-тора эшнең нәрсәдә икәнен, хакыйкатьнең кем ягында булуын, үзенең һәм үзе кебекләрнең нинди хәлтә әләгүен акрынлап төшенә башлады. Ниһаять, 1919 елның февраль аенда шагыйрь кызыллар ягына чыкты һәм бу хакта халыкка да игълан итте («Башкорт халкына көйле хитаб» әсәре күздә тотыла). Озакламый ул Башкорт республикасы Вакытлы хәрби-революцион комитетының 1919 ел 25 февраль боерыгы белән Башревком карамагындагы башкорт матбугатының сотрудниги итеп билгеләнә. Әмма, шундый якты юлга чыккач кына, шагыйрьнең тормышы кинәт киселә — ул 1919 елның 28 мартында революция дошманнары тарафыннан җәзалап үтерелә. Бу вакытта аңа 24 яшь кенә иде әле.

3

Ш. Бабич иҗатында кояшка карап бакмаган, йолдызларны күреп хозурланмаган, ай нурлары астында уйланмаган шигырьне күрүе кыен. Шагыйрь хыялының җитез, омтылышлы булуы әнә шул күк җисеменә бәйле рәвештә язылган шигырьләрдә чагылган. Бабич лирик героеның үсеш эволюциясе дә шушы поэтик образларга мөнәсәбәттә аңлатыла. Менә аның 1910—1911 еллар арасында язган шигырьләреннән юллар: «Белмәсәң, минем кояшым илдәге мәктәп иде» («Зарлану»), «Шат кояшның шат нурында ялтырый сүнгән Уфа» («Яз тәэсире»), «Дөньяда бик аз булыр чын, зур шагыйрь Габдулладай; ул караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай» («Габдулла әфәнде Тукаев»). Шагыйрь үз Кояшын, Аен нидә күрә соң? — мәгърифәттә, табигать матурлыгында, камил иҗатта. Яшь шагыйрьнең бөтен омтылганы менә шулар. Тора-бара лирик геройның хыял дөньясы киңәя, карашлары катлаулана, күккә, Кояшка төбәлгән күзләре җиргә дә карый, җир халкына да игътибарлы. Ул хәтта үзенең барлык сәләтен, кирәк икән, «яшь чагын, алтын чагын» да «халык алдында биргән таза анты өчен» корбан итәргә әзер («Халкым өчен», 1914).

Әйе, Ш Бабичның лирик герое җирдән калкыбрак, өстәрәк яшәүче герой; шуңа күрә ул ярсу, тынгысыз, хәтта бунтарь герой («Айга мендем», «Теләк», «Дөньяга», «Мин — даһи»). Әмма ул бу ярсуында, омтылышларында халкыннан һич аерылып китми, һәрвакыт аның белән уртаклык эзли һәм аны иҗтимагый хакыйкатькә ирешү юлында табарга омтыла. Ул да «гамь чигә», «тормыш тигезсезлекләрен уйлап яна», чөнки «күзләре алдыннан сгълап, ярлы мескеннәр үтә», аның күңелен «ярлыларны кызгану әрнетә» («Бай һәм ярлы», 1914).

Бабич герое, кайгы килсә дә, шатлык хисләре кичергәндә дә һаман шулай ярсу, тынгысыз булып кала. Аның күңелендә хәтта алла белән иблис көрәше чагыла кебек:

Берсе «Дин!» дип, берсе «Мин!» дип тарткалай,
Белмимен,
Әллә алла, әллә иблис алдалай.
(«Әллә алла, әллә иблис», 1916)

Ләкин аның хыялларын күкнең, диннең буш идеаллары да, җир нәфесе дә үзенә йолып ала алмый, аның шәхесе ирекле иҗат әһеле,

матурлык, дөреслек эзләүче зат булып калырга тели. Бу омтылышыннан аның хыяллары чиксез, теләкләре керсез:

Айга мендем, ай нуры белән коендым, уйнадым,
Күп сөендем, сөенеч белән туендым, туймадым.
Туймадым, айдан узып, менден кояшка ашкынып,
Юк, шулай да булмады ташкын нуцелне бастырып...

(«Айга мендем», 1914)

Шагыйрь алла тәхете каршына менсә дә, туган халкын онытмый, аның эзләнүләре дә шушы халкы өчен икән:

Айга үрләп, нурда уйнап,
Күкрәгемне нурладым.
«Ит гафу, әй ай,— дидем,—
Мин нурларыңны урладым.»

«Һич зарар юк, ал,— диде ай,—
Ал да, чәч нур халкыңа;
Мин дә бит төн хакына
Алдым кояшның нурларын.»

(«Кем өчен?», 1916)

Дөрес, вакыт-вакыт лирик герой үз Кояшын, үз Нурларын күздән югалта һәм моны бик авыр кичерә. Бу вакытта ул тулысынча ялгызлык кочагында. Ул дөньяның ике чигенә ташланып карый. Бер караганда ул җир өстендә барган канкоюлы сугышны «күк йөзендә тын гына йөзгән йолдыз, кояш, айга каршы куя («Сугыш»), күңелен «Күккә оч, күктә тыныч, Монда — сугыш, монда — кылыч» («Әйдә, күңелем») дип тынычландырырга тырыша. Икенче караганда, «Җир хәсрәте» кочагында калып, Кояшына бара алмавына ачына:

Якты эзләп күккә бактым — якты нурлар инмәде.
Җиргә бактым — җир караңгы, күз чәчәкләр күрмәде.
Шунда минпәи көлде йолдыз, көлде ай күктән карап,
Ник газаплыйлар мине? Ансыз да җан күптән кәба.

(«Караңгылыкта», 1916)

Шундый авыр минутларда да герой Кояшы белән очрашудан өметен өзми. Ә аныңча, Кояш — киләчәк матур тормыш, азат тормыш хыялы...

Ямь күрәлмәм, гамьле хәлләр китмичә, яшь кипмичә,
Күз яшемне киптерерлек якты кояш чыкмыйча.

(«Ямь күрәлмәм», 1916)

Җир белән күк арасында Кояш Нурларын сагынып сыктаган Бабич герое үз Кояшын табып сөенә:

Зәңгәр күк — таҗым, чуар җир — тәхтем,
Үзем — азат хан, ак кояш — бәхтем...
Гөлләр елмайган, кырлар нурланган,
Бөтен җир-күге нурга чорналган.

(«Бәхетем», 1916)

Февраль революциясе шавы ишетелә башлаган 1916 елларда Бабич чын мәгънәсендә зур иҗади үсеш кичерә. Нәкъ шушы елны аның аллага, дингә, кануннарга баш күтәреп чыккан Газазил хакында поэма-балладасы дөнья күрә. Бу әсәрендә шагыйрь өр-яңа романтик поэма үрнәге бирде. Берәүләр тарихи легендаларда урта гасырчылыкны идеаллаштырган (Н. Думави, «Шәрекъ дәһие»), икенчеләр дини легенданы шигырьгә салып, тормышта кара көчләр хакимлеге нәтиҗәсендә туган газапларга түземле булу, явызлыкка көч белән каршы тормау, тормыш ләззәтләреннән ваз кичү кебек нәрсәләрне гәүдәләндергән (Г. Сөнгати, «Хозыр»), өченчеләр легенданың үз эчендә уңай һәм тискәре көчләр каршылыгын күрсәтергә омтылган (Г. Шәрифи, «Нәккәҗан») бер заманда, Бабич дини легенданы пародиягә әйләндереп, аның эчтәлеген үтергеч көлү хөкеменә тотты [1].

Шушы ук елда ул үзенең «Җандала» балладасын һәм «Җитабеннас фи-хаккылхавас» * дигән эпиграммалар циклын иҗат итте, халыкка көчле сатирик буларак танылып өлгерде. Бу уңайдан шуны да әйтергә кирәк: Г. Тукай сатирасы ачык социаль тәнкыйть, фашлау тәшкил итсә, Бабич сатирасы һәрвакыт нечкә юмор, көлке белән өретелеп бирелә. Анда, романтик әдәбият кануннары белән эш иткәнгә күрә, тәнкыйть фикере бик тирәнгә яшерелгән була.

Менә шушы көлке, юмор Бабич лирик героендагы көр рухны бетмәс-төкәнмәс итеп саклап калды, аны ялгызлык, аһ-зар кочагына җибәрмәде. Аның йөрәгендә халык өчен хәсрәтләнү һәм халык өчен шатлану берьюлы яши. Бу очракта ул, Г. Ибраһимов әйткәнчә, «күз яше үтәли көлә...».

Шагыйрь үзенең шатлыгы белән дә, кайгысы белән дә Февраль революциясен кабул итәргә әзер иде. Чыннан да, революция булгач та, ул үз Кояшын табып шатланды:

Исте җил, сүнде бер ялган шәм,
Таралды һәм болыт, һәм томан.
Калыкты чын кояш, кипте яшь...
Капланды «кара көч» йөзтүбән.

(«Хөррият буләге», 1917)

Ләкин «кара көч» әле тулысынча бетерелмәгән, якты кояш чытып өлгермәгән иде. Моны аңлап җитмәгән шагыйрь урау юлларга кереп китте, бары тик 1919 ел башында гына Советларга дан җырлый алды. «Колчак, Дутов ялчыларына» нәфрәтен белдерде. Әмма нинди генә авыр хәлләрдә калса да, аның лирик герое үз иманына тугры булды. Бу иман — Кояш белән Җир тормышы арасында гармония, матурлык эзләү, аны табып, туган халкына җиткерү. Халык үз шагыйрендә ялгышмады. Бабич халык алдында биргән «таза анты»на тугры калды.

Галимҗан Гыйльманов

---

[1] Бабич Ш. Сайланма әсәрләр (Х. Госман сүз башы).— Казан, 1958, 14 бит.

* «Атаклы кешеләр турында китап».

ШИГЫРЬЛӘР, БАЛЛАДАЛАР, ПОЭМАЛАР

1910

И КИТАБ!

Ап-ачык тор һәрвакытта, и китаб! Баксам сиңа,
Чын, асыл нигезле җирдән күп белемнәр бир миңа!

И китаб! Мин аңгыраны төз юлга күндерсәнә!
Мине баскан «җәһел» утын су сибеп сүндерсәнә!

Син — җуаткыч, син — уяткыч, син миңа чын-чын атам;
Булмасаң син, мин сине сагнып кына чирләп ятам.

И китабым, и китаб! Миңа кыл син хитаб!
Син генә башымдагы чуп-чарны алырсың утап.

Җәһел — наданлык.
Хитаб — эндәшү, сүз, мөрәҗәгать.

1910

БӘХЕТСЕЗ МИН

Татлы өметтән башым буп-буш булып калган хәзер,
Күкрәгемә үрмәкүч оясы чормалган хәзер.

Кайда барсам, кайда торсам да бәхетсез гәүдә мин,
Шул бәхетсез зинданына мин дә тоткын, ауда мин.

Көн саен миндә бәхетсезлек кенә арта бара,
Җайсыз, унайсыз, кырыйсыз юлына тарта бара.

Мин, шулай уйлана торгач, татлы уйларга күчәм,
Төрле хыялларга батып, гарше әгъләгә очам.

Гарше әгъла — биек урын.

1910

ОХОТНИК

Ап-аяз бер яз көнендә кырда йөрдем көн буе,
Калмады йөрелмәенчә сахра, урман, күл буе.

Мин берүзем йөрмәдем: бер бик матур эт — Моська бар,
Һәм дә ау аулап йөрүче бер охотник дус та бар.

Чәй эчеп иртүк, җиңел мылтык алып, шылдык икәү,
Авылыбыздан күз ачып йомганчы юк булдык икәү.

Эй барабыз, эй барабыз, туктамый, тып-тын гына,
Җил чыга да, безне каплый тик тузан, чүп, ком гына.

Күл дә юк, кош-корт та юк, дип, иптәшем хәсрәтләнә,
Күктә үрдәкләр күренгәч, хәлләнә дус, рәтләнә.

Ялтырап бер күл күренде, инде дуска баксана,
«Вәт менә килде бит бәхтем, энем»,— дип шатлана.

Тагы да шатлык арта аңа, артадыр шул бермә-бер:
Күлдә күп үрдәк йөзә һәм күктә оча пыр да пыр.

«Атканым буш китмәсә иде минем»,— дип торды да
Бер сулап куркынды һәм бер шатланып сызгырды да:

«Кал шушында, ят сузыл да, шауламый тын гына ят!» —
Диде. Мин дидем аңа: «Каушамый, ашыкмый ат!»

Өс-башын салды да китте җиргә ятып юлдашым,
Нәкъ еландай бара шуып, калкытып кына башын.

Мин карап тордым ятып, башымны аз-маз калкытып,
Күкрәк изелде минем, кыймылдамый ятып-ятып.

Дус сөйрәлеп бара-бара күлгә бик якынлады,
Мылтык атты, күккә чыкты тик төтен, ялкыннары.

Кычкырам: «Ни чаклы үрдәккә тиде?» — дип мин аңа,
Кычкыра: «Ярдәм әрәм китте бит, иптәш!» — дип миңа.

Иптәшем янына килдем йөгреп, ыргып, сикеренеп,
Бер генә үрдәк ята тыпырчынып һәм селкенеп.

Шул бер үрдәкне алып киттек авылга туп-туры,
Вәт охотниклар! (Бүтән һич нәрсә юк, кул коп-коры.)

Юлда (кайтканда авылга) чаукалыктан нагяһан
Чыкты да китте кинәттән ялт итеп бер ак куян.

Диде охотник миңа: «Мин бу куянны да атам,
Үрдәк белән куян итен бергә пешерәм, болгатам».

Күңлемә минем дә бик ошады шушы фикер:
«Ит хәзер бик күп була,— дидем,— әй, аллага шөкер!»

Корды мылтыкны охотник, куйды да һәм пистонын,
Диде: «Мин атам куянны, салдырам газиз тунын!

Син чишен, мин мылтык аткач, бар да тот, куянны суй!
Читкә чапса, син аны ку!..» — дип миңа ул бирде уй.

«Тотмасак без, суймасак без, куркак ул, бик тиз үләр»,—
Дип уйладым да чишендем (мин дә бит беркат, юләр).

Тезләнеп турылады охотник куянга мылтыгын,
Һәм куянга атты да аксатты ул арт култыгын.

Җан кадерле шул! Куянга да кадерле үз җаны,
Йөгрәсе килә аның да, акса да актык каны.

Бу куянның бер дә бездән тоттырасы килмәде,
Чапты да китте, сикерде, аксадым дип тормады.

Мин күземне кып-кызыл иттем дә, җирне тырмалап,
Чаптым артыннан куянның «вау да вау» дип өргәләп.

Әй чаба ул, мин куамын, әй чаба ул, мин куам...
Купты йөрәк, шиңде колак — шүрләде мескен куян.

Күп куа торгач, куян арды, баралмый, туктала,
Мин җитеп, таш-кәс белән оргач, чабарга уктала.

Нагяһан — кинәт.

Мык итеп җиргә егылгач, селтәнеп бар көч белән,
Дуска кычкырдым: «Қил әле тиз генә! Үлде куян!»

Бик кинәт сикреп торып яткан җиреннән, иптәшем
Қилде йөгреп һәм куянны суйды да тотты башын.

«Бу йөрүдә унды юлым»,— дип охотник шатлана,
Һәм үзе ыргый-сикерә, мактана, тинтәкләнә.

«Их кызык булды: куянны син кудың да соң»,— диеп,
Минем күзгә карап, ул көлде бик нык кычкырып.

«Йә, нигә без тик торабыз, әйдә,— ди,— кузгалаек,
Қичкә калдык, кеше ятмас борын өйгә бараек.»

Қиттек, ычкындык авылга, юл түгел, бер эз дә юк,
Қап-караңгы төн, вә күктә ай да юк, йолдыз да юк.

Қөчкә җиттек өйгә кайтып, әлсерәнеп, эт кебек,
Булса да салкын, җиләс төн, кыздырылдык ит кебек.

1910

И ДУСЛАРЫМ

Дусларым, торган җирегез — туган авыл, киң авыл,
Барча кайгы, моңнарыңны җуйган авыл, тын авыл.

Иң сөекле киң авыл һәм тын авылны мин генә
Ташладым; ник ташламыйм, башка тулгач ком гына!

1910

ИКЕ ШӘКЕРТ

Бер бүлмәдә ике шәкерт дус кына торган була,
Эчләре пошканда җырлап, уйнаган-көлгән була.

Керсә алларына кыз, дуслыклары чиктән аша:
«Кызны мин кочам элек»,— дип, дөп тә дөп йодрыклаша.

1910

ЯҢГЫР ТЕЛӘГЕ

Яу, яу, янгыр, яу, янгыр,
Безгә килеп ау, яңгыр,
Имчәкләрең сау, яңгыр,
Яу, яу, янгыр, яу, яңгыр!
Яңгыр, безне ямьләндер,
Сусадык, суга кандыр,
Һәр җирдән тамчы тамдыр,
Яу, яу, яңгыр, яу, яңгыр!
Син безне ризыкландыр,
Ризыгыбыз — икмәк-нандыр,
Катык, сөт, май һәм балдыр,
Яу, яу, яңгыр, яу, яңгыр!
Хайванны ризыкландыр,
Ризыклары — үләндер,
Үләннәрне чыландыр,
Яу, яу, янгыр, яу, яңгыр!
Хайваннарны көрләндер,
Үләннәрне төрләндер,
Дөнья йөзен нурландыр,
Яу, яу, яңгыр, яу, янгыр!
Игеннәрне дә үндыр:
Безнең терәк — игендер,
Тулсын игенгә ындыр,
Яу, яу, яңгыр, яу, яңгыр!
Күрмисеңме, әй, янгыр:
Үләннәр бик коргандыр.
Иген кипкән-шиңгәндер,
Яусаңчы бер, яу, янгыр!
Шаулап торган урманнар
Ямьсезләнгән, корганнар,
Җансызланган, үлгәннәр,
Яу, яу, димен, яу, янгыр!

Нан — ашамлык.

Бар әйберләр кызгандыр,
Дөнья тулган тузандыр,
Бу хәлләрне кызган бер,
Сип суыңны, сип, яңгыр!
  Яумасаң, эш ямандыр,
  Хәзер явар замандыр,
  Кояш, дәрьяны яндыр,—
  Күтәрелсен пар, яңгыр!
Яшәрсен сахра һәм кыр,
Кошлар очсын пыр да пыр,
Без шатланып җырлыйк җыр,
Бул тизерәк, яу, яңгыр!

1910

СИН АЛДАМА

Сүзләреңнең барысы ялган, бересе чын сүз түгел,
Синдә юк чын сүз белән ап-ачык йөз, төз күңел.

Алдасаң да күп кешене, булмады бит файдасы,
Таусия итәм сине мин: «Инде чып-чын сүзле бул!»

Алма ат, «алдакчы» дип, кәкрене турыла, алдама!
Тиз таерсың, алдасаң, алдау юлы бик бозлы юл.

Ал исем, «чын сүзле» дип, бер дә куркма, чынны әйт,
Чем-кара, ап-акны аерырга туры сүз — күзге ул.

Калсын исмең мәңгегә, чын сүз белән ал атак!
Кыскасы: гайрәтле бул, чын сүзле бул! Бу — изге юл.

Таусия итәм — киңәш итеп әйтәм.
Ат (ак) — исем.

1910

БЕЗНЕҢ БАКЧА

Безнең, иптәш, бакчабыз бар, иллә әйбәт, шәп тә соң,
Төрле буяу белән сырлаттык матур рәшәткәсен.

Ак, кызыл, зәңгәрле чәчкә бакчабызның гөлләре,
Ялтырап, сузылып ята сукмаклары һәм юллары.

Бакчабызда бар: чия, алма, шомырт агачлары,
Кып-кызыл булып тора салынып миләш тәлгәшләре.

Һәм усак агачлары шулай да җилгә калтырый,
Бакчабызның сакчысы ул: туктамыйча шылтырый.

Чыршы, наратлар тагы да бакчаны ямьләндерә,
Уртасында ике наратның ясалган сәндерә.

Ул үләннәр тип-тигез, тик бер карыш һәм теп-текә,
Йомшак искән җил үләнне акрын-акрын селкетә.

Чут та юк, бик күп җиләк, күп, минсинайтим, төрледән,
Дөньяда беткел түгел ул карлыган һәм бөрлегән.

Ул яшелчә — барчасы бар, кишер, карбыз, кабак,
Көн саен торсаң алып, бетмәс, кыярны йөз табак.

Тар гына тонык, агым бер су буенда бакчабыз,
Кер чайкарга кап-кара кашларга таяр басмабыз.

Иң сылу кызлар йөри үтеп безнең бакча аша,
Бакчабыз, үткәндә кызлар, хуш исен күпләп чәчә.

Гел килә бакча эченнән кер чайкарга Әсма кыз,
Килми ул килгәндә чәчкәп һәм дә калфак-тасмасыз.

Кыш үтеп, яз айлары килсә, керәм шул бакчага,
Чыкмаем, шунда ятам мин, капланам да чәчкәгә.

1910

ОЛАКТЫРЫЛГАН ПЕСИ

(«Зиләйлук» көенә)

Йөргән чакта җырлап, тауны буйлап,
Төште күзем, тауның астында
Күккә карап, бакрып, елап яткан
Олактырылган песи мескенгә.

Тау башыннан бераз карап тордым,
Мәхлуккәйне аяп, кызганып.
Күргәч койрык селкеп рәнҗегәнен,
Төште эчкә суык, сызлавык.

Шунда әрнеп мин дә яшьне түктем,
Кем, дип, олактырган песине?
Инсан, явыз, нахак олактыра
Песине, дип, тиргим кешене.

Тау башыннан төшеп, якынлашып,
«Пескәй, пес-пес!» — дидем, кул болгап.
Песи торып миңа карады да
Бик шатланды, мескен, мыр-мырлап.

Арыкланган, кипкән, хәле киткән,
Нәҗес-пычрак каткан мортына.
Киләм диеп, миңа укталса да,
Килалмый шул — егыла, сөртенә.

Бардым йөгереп, песи килмәгәч,
Алдым кулга сыпырып аркасын.
Шунда песи әйткән төсле булды:
«Ничек мине күңлең тарта соң?»

Инсан — кеше.
Морт — мыек (*Ш. Бабич искәрмәсе*).

1910

ГАШЫЙК ДУСТЫМА

(Чит илдә гармун уйнаган вакытта)

Котлы булсын тартканың, шул чын юаныч гармуның,
Гармун уйнап, ит тәхәттер мәгъшукаңның альбомын.

Син беләмсең, сине сагнып ифтирагътан мәгъшукаң,
Күз яшен түгеп, кул иткәндер, мөгаен, балконын!

Син сагынсаң да фәрештәңнең матурлап көлгәнен,
Кайда инде кул тотышып, мәгъсуманә йөргәнең!

Тик боларның белмәдең кадрен, дустым, чыктың сәфәр,
Бу лаекмы, айрылып аннан еракта торганың?

Белсәң иде син аның ак күңленең йомшаклыгын,
Бер күрер өчен бу көннәрдә сиңа гашшаклыгын.

Һәм үзеңнең таш күңелле булганыңны расласаң,
Аңлар идең читтә йөрүнең бары нахаклыгын.

Зарлы көйгә сал да, дустым, тарт, чикылдат гармуның,
Әрчелеп шик-шөбһәсеннән күңлең, таралсын бар моңың!

«Үлмәсәм, тәңрем кавыштырыр»,— диген дә көл дә тор!
Күз яшен сөрт, ярсыма, уйла йөрәгең ярылуын.

Тәхәттер иту — хәтергә төшерү.
Мәгъсумана — әчкерсез.
Ифтирагъ — аерылышу.
Гашшак — үтә гашыйклык.

1910

КУРКАК

Бер авыл мәктәбендә ватылды тәрәзә «шырт» итеп,
«Шырт» кына түгел шул, ул бит кыйрый «чылтырт» итеп.

Ватты кем? Кыйратты кем? Бу сүз күбәйде — шау да шау,
Ул талашу, бәйләнешү, үзара җәнҗал да дау.

Чыкты хәлфә бүлмәдән, кычкырды селтәп камчысын:
«Кем генә ватса, аңа мин күрсәтәм кан тамчысын!»

Хәлфә утыртты шәкертләрне тезеп, тезләндереп,
Һәм шәкертләрне карап торды бераз күз яндырып.

Соңнан әйтте: «Кайда киткән? Монда юк бит таз Йосып!»
Мәдрәсәне тентесәләр — таз Йосып калган посып.

Белделәр, бу тәрәзне шул таз Йосып ваткан икән.
Ул шуңа мендәр арасында посып яткан икән.

Җилтерәтеп, тәрткәләп тазны алып килгәч бире,
Диде хәлфә: «Әй, ходай аткан! Чишен, ят, таз пәри!»

Шыр ялангачланды таз, калды бары ыштан гына,
Таз күгәрде, качты кан, җаны юк, калды тән генә.

Хәлфә әйтте: «Камчыламасмын, сөальгә бир җавап:
Кайсы көндә киссәң тырнакны була бик күп савап?»

Куркуыннан аңламыйча хәлфәнең сүзен малай,
Диде: «Тәрәзә ватмадым мин, ипикәй, билләй-валлай!»

Булса да хәлфә ачулы, көлде моңа «шырк» итеп,
Таз йөрәге торды биш көн нык сугып, дерт-дерт итеп.

Сөаль — сорау.

1910

МИҢА ЮНЬ, ИЧМАСАМ

Мин халыкка аптырыймын: нигә алар көн саный?
Ник тарыгалар? Аларга дөнья бит бик киң сарай!

Нәрсәгә ашкына алар, әйтчәле, бу юньмени?
Аптырыймын, бит алар хөр, соң алар, ә минмени?

Көн санасам һәм ашыксам, ул миңа юнь, ичмасам,
Бер дә ашыкмас идем мин, читкә чыгып китмәсәм.

1910

ЗАРЛАНУ

Ятсына миннән хәзер бу дөньяның бар әйбере,
Дусларың моны күреп, җәлләр, дисең син, кайбере.

Кайда югалды языксыз ак чагым, моңсыз чагым?
Үтте гомремнең хәзер бер йөз дә туксан айлары.

Буйга җиткәч тә югалттым мин кояшымны кинәт,
Тик бу көннәрдә түбәмдә тапка чумган ай йөри.

Белмәсәң, минем кояшым илдәге мәктәп иде,
Һәр кызык анда иде, бу туң күңел майдай иде.

Ә хәзер күңлем минем боздай туңып, таштай ката,
Чөнки йөргән җирләрем тик кап-кара Тургай җире.

Мин начар булдым илемдә, шунда да шәкерт идем,
Ә наданнарның хәзер мин иң шәбе, иң айгыры!

1911

ҚӘҖӘ БЕЛӘН ДУҢГЫЗ

Қәҗә дуңгызга сөйли бервакытта:
«Беләсеңме, кояш бар бит,— ди,— күктә?
Кояш көндез янып уттай йөри һәм
Китә кич булса,— ди,— тауга батып та».

Ди дуңгыз: «Әй, синең ялган сүзең бу,
«Кояш» дип, алдыйсыңмы дуңгызны?
Ышанмыйм: юк кояш, ата-бабадан
Ишетмәдем кояшың-йолдызыңны!»

Қәҗә әйтә: «Түгел ялган, кояш бар,
Ышанмасаң, бүтән белән сөйләш, бар!»
«Ата-бабам сөйләмәгән,— ди чучка,—
Ничек килсен синең сүзең дөрескә?
Үзем дә күрмәдем кояш дигәнне,
Көне-төне казынсам да тирестә!»

Қәҗә ди: «Син кояшны күрмисең шул,
Югары, өскә карый алмыйсың шул;
Әгәр дә сиңа бер-бер нәрсә әйтсәң,
Хәзер зык кубасың, ышанмыйсың шул».

Ди дуңгыз: «Кем булып киттең, кәҗә карт,
Безнең ата-бабаларны мәзахлап?
Кафер син, дәһри син, бидгать чыгардың,
Төбенә кит дозахның, бар, газап тарт!»

«Бу дуңгызга төшендереп булмый
Икән»,— дип, тып-тыныч кәҗә юнәлде.
Барып дусларына дуңгыз, сөенеп:
«Қәҗә мәлгуньне җиңдем»,— дип сөйләнде.

Мәзахлап — көлеп, мыскыллап.
Кафер — ислам динен тотмаучы.
Дәһри — алласыз.
Бидгать — изгәләр кылмаган эш.
Дозах — җәһәннәм, тәмуг.

1911

НӘСИХӘТ

(Үземә)

— Әй, Шәйх! Уян! — димен,— уян!— димен,
Күзеңне, уянмасаң, уям, димен.

Күшегеп, тавык кебек, күп моңайма,
Шөкер ит саулыгыңа, уйлан, димен.

Үзеңне бер ходайга тапшыр да гуй,
Шуннан соң үз-үзеңә сөен, димен.

Шайтаның арлы-бирле тарткаласа,—
Бер карыш чыкма юлдан,— сөям, димен.

Курыкма! Эт өрсә дә, җырың җырла,
Этләрдән курка торган — куян, димен.

Уйланып, дәфтәреңә җырлар яз да,
Шуларны укып-укып юан, димен.

Җырларың аркасында китеп калыр
Бервакыт күңлеңдәге чобан, димен.

Бүген дә надан булып калсаң да гуй,
Ходайга киселмәсен тубаң *, димен.

Сиңа да якты заман килеп җитәр,
Әгәр дә ярлыкаса ходаң, димен.

«Фәдгуни, истәҗибләкем» дигән
Һәрвакыт теләгеңне телән, димен.

Түбәңнән, ходай кушса, күтәрелер
Каплаган йолдызыңны томан, димен.

---

* *Туба* — шөкер, казакъ истигъмалы (шулай ук «тапшыр да», …лгаң кал» дигәннән соңгы «гуй»ләр да казакъ истигъмаллары) (*Ш. Бабич искәрмәсе*).

«Фәдгуни, истәҗибләкем» — «Сез сорагыз, мин җавап бирермен».

1911

ЧЕП-ЧИ НАДАН

Бер адәм: «Русча беләмсең син?» — дип
Сорады; мин әйттем: «Беләмен мин»,— дип.

«Йә, сөйләп кара!» — дигәч ул, мин дидем:
«Знакум, я бит ничауа иезнаем!»

«Шәп икәнсең русчага: Шәйкулзадәм,
Кем өйрәтте, әйтче?» — диде ул адәм.

Мин бу сүзгә аптырам тордым, ләкин
Аңладым тиз: ул икән чеп-чи надан!

1911

ТИК ТОРУ АРТЫК

Һәркайчан тик тор, берәр ахмак адәм сүз сөйләсә,
Бел, аңа сүз кайтарудан тик тору артык ласа.

1911

КҮҢЕЛ

Күңел сызлый, сызлый, сызлавык бар
Кара көчләр мине тотканга,
Җегәрләгән бераз орчыгымны
Кара көчләр килеп сүткәнгә.

Күңел яна, көя ут эчендә,
Яшь вакытлар әрәм үткәнгә;
Укып яткан җирдән, туган илдән
Аерылып ерак киткәнгә.

Күңел әрни, әрни, бозлы салкын,
Буранлы җил мине сукканга;
Җил очырып мине якты җирдән
Караңгыга илтеп тыкканга.

Күңел ауру, тәмам аптырашта,
Һөнәрсезлек башка үткәнгә;
Бер эш эшләп булмый, кулдан килми,
Эшсез генә үлем көткәнгә.

Күңел газапланмый, тыныч тора,
Вөҗдан аны каты сүккәндә;
Нурлы булсын диеп киләчәгем,
Бер ходайдан өмет иткәндә.

1911

ГАБДУЛЛА ЭФӘНДЕ ТУКАЕВ

Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь Габдулладай;
Ул — караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай.

Ул бөек уй, нечкә хис, тәгъризләргә бик бай, димен,
Бар урыннардан аның урынын кадерле, дәү, димен.

Бакыр эчендә көмешләр ялтырап яткан кебек,
Ап-ачык, ап-ак булып, тик ак күбек аккан кебек,

Күп китапларның арасында аның китаплары —
Ап-ачык нурлар чәчеп, күренеп тора һәр яклары.

Алса, укыса халык шигырен аның — истә кала,
Һәм аның шигыре халыкның күңленә зур хис сала.

Гали зат Габдулланың хәзер Казанда мәскәне,
Ул уяткыч, ул юаткыч, ул терелткеч хәстәне.

Билгеле, безнең мабиһел-ифтихар ул мөхтәрәм,
Зур шагыйрь, мәшһүр шагыйрь бар бездә дә, дип
шатланам.

Тәсбих вә тәһлил әйтеп җырлап йөримен җырларын,
Җырлаганда нечкәрә күңлем, эри һәр җирләрем.

Тәгъриз — читләтеп әйтү.
Мәскән — торган урын.
Хәстә — авыру.
Мабиһел-ифтихар — мактана, горурлана торган.
Мөхтәрәм — хөрмәтле.
Тәсбих вә тәһлил әйтеп — мактап, олылап.

1911

МОҢЛАНАМ

Белмим инде, нигәдер гел моңланам,
. . . .
Кайгы-хәсрәт, моң вә зарлыклар белән,
Юк тынычлык, тулганам да тулганам.

Күрмәсәм дә тарлык, хурлык, кимчелек,
Куркыныч уйлар эчендә уйланам.
Мин түгел катыйль, залим, мескен, зәгыйфь,
Нигә соң мин гарьләнәм дә моңланам?

Ихласым юк, басмый аяк, йөрми кул;
Әллә нидән шикләнәм һәм шомланам.
Ялтырап өмет кояшы нур чәчмәсә,
Мин бу хәл, бу зар белән булмам адәм.

Китмәсә баштан бу болганчык томан,—
Аһ, дус-ишләр, мин булмам адәм.

* Бу юл шагыйрьнең кульязмасында нокталардан гына тора.

1912

САБАНТУЙ ҺӘМ МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР

Язга каршы көн батырлангач, кышның мартлары,
Банкрот байдай, бетергәч күп карын, март «шартлады».

Кар йокарды, инде күр син безнең апрель башларын:
«Аһ, харап булдык»,— дип кыш түкте күздән яшьләрен.

Сипте апрель күз яшенең өстенә яңгырларын,
Сулады кырны, аяк астын, халык ындырларын.

Акты сулар, кайда уй бар — шунда сулар тулдылар,
Артылып аккан сулар зур елгага кушылдылар.

Китте кызлар, төрле сүзләр сөйләшеп, «гөл-гөл» диеп,
Җырлашып, «ак гөлгә кунып сайрады былбыл», диеп.

Чыкты маллар һәммәсе ташлап караңгы абзарын,
Күп тели торгач, алар да күрде инде язларын.

Кыт-кыт кыткылдый тавыклар, казлары каңгылдаша,
Кичкә табан әллә кайда бакалар бакылдаша.

Яшь-яшел кырлар яшәрде, ярды яфрак бар агач,
Килде көньяк кошлары: аккош, сыерчык, карлыгач.

Имтихан тотты шәкертләр, җитте апрель уртасы.
Әйтә һәркем: «Башлана сабантуй, апрель иртәсе...»

Күп малай, иртә торып, кычкырды: «Карга, карга...» —
дип,
Өй саен йөренә малайлар: «Бир, апай, ит-ярма?» — дип

Бер бүлек малай, егетләр, бер бүлек — кыз, корткасы,
Тау башына менделәр пешерергә «карга боткасы».

Дәртләнеп, җырлап егетләр тарттылар гармуннарын,
Кайсысы кызлар белән уйнап таратты моңнарын.

Іоилек үткәч, ботка беткәч, кыз-егетләр кайттылар,
Иртәгә күкәй җыябыз, дип, йокларга яттылар.

Иртән иртүк йөрде малайлар берәр токсай элеп,
Өйдән-өйгә йөгереп, бу көнне тансык белеп.

Көн күтәрелгәч, балалар өйләренә кайттылар,
Инде чыкты атлылар һәм анда-монда чаптылар.

Җенләнеп, гаскәр кебек акрып йөри бу атлылар,
Чыкма урамга җәяү, чыксаң әгәр, таптарлар.

Соңыннан, тәгәрмәчләнеп бер җирдә торгач, атлылар
Барсына кәнфит, керәндил һәм күкәй тараттылар.

Бу да үтте, инде иртән ат чабыш мәйдан була,
Анда сөлгедән, керәндилдән, түбәтәйдән була.

Үткәч апрель, ямьле, матур май килер, майдай эреп,
Май аенда моңлы кошлар моңланып сайрар эреп.

Басуга китәр халык, сука, сабан дыңгырдатып,
Җир сөрерләр анда атлар тирләтеп, дөпелдәтеп.

Май халыкны басуга куар һәм сыердай безләтер,
Көннәрен бушка җибәртми, көн дә, көн дә эшләтер.

Майны үткәргәч халыклар, эш беләи июнь җитәр,
Милли бәйрәмнәр килерләр, бик хозур җыен җитәр.

Пар атын чуклап, тагын куш кыңгырау пыр туздырып,
Өй килер кунак җыенга, килер кызләр кыздырып.

Бер көтү малай барып ачар басуның капкасын,
Ыргытыр кунак аларга, күчтәнәч, дип, акчасын.

Кырга чыгарлар халыклар һәм кунаклар барчасы,
Һәм килер Г... авылының вак-төяк тауарчысы.

Бер урынга сәүдәгәрләр торпыша корып торыр,
Арлы-бирле болганып, шунда халык йөреп торыр.

Кыңгырау һәм дә тарантас таушына дөнья тулар,
Бер ягыннан җенләнеп, исрек агайлар шәп узар.

Күп төялгәннән аларның арбасы сыгылып төшәр,
Кайсы салыныр арбадан һәм кайсысы егылып төшәр.

Күп булыр бутылка болгап, җирне ертып җырлаган,
Ул бутылкалар сугылган, чылтыраган, кыйраган.

Анда, мәйданда көрәшә һәр талапкар, көчлеләр,
Хәйләкәрләр, йөрәклеләр һәм юан, киң түшлеләр.

Җыйды мәйдан башлыгы яулык вә акча, тастымал,
Барсы булды илле яулык, байтак акча, башка мал.

Чыкты да яланга бер озын таякны какты ул,
Башына җыйганнарын җилбердәтеп такты ул.

Агылып-агылып килде мәйданга читтән күп адәм,
Кыз-хатын бер җиргә җыелган, яшел, күк ситсадан.

Һәр авылның да була киң ат чабыш мәйданнары,
Яшәсен безнең халыкның милли бу бәйрәмнәре!

Иллә шәп булды көрәшләр, килде атлар дүрт эрәт,
Бик тә әйбәт үтте мәйдан, булмады тик рәтлерәк.

Әллә ничә ат җигелер, атка яулык бәйләнер
Дә егетләр, дәртлеләр, бик шәп җыенны әйләнер.

Елмаер, муйнын борыр һәм яңгыратып сызгырыр,
Боргылатып сызгычын, сызып күңелне өздерер.

Бер тарантаска утырыр скрипкачы егет,
Ду килер атлар, җыенны әйләнер пыр туздырып.

Яшь-яшел күрекле гармунын ялтыратып тарткалар,
Һәр кешегә дәртле йөз белән көлеп бик шат карар.

Төш авышкач, сахрадан кайтыр халык, җыен бетәр,
Төйнәлеп яткан халык күңлендәге төен бетәр.

Чүмәлә чәллә мөәзиннәр, габделкарилар, муллалар
Өй саен ашка йөрер, бер тин вә барнау алгалар.

Көн дә ун өйдә сыйланыр муллалар дүрт көнгәчә,
Мулланы йөретер халык баштарак көрсенмичә.

Дүрт булып, бишенче көн үтәр, кунак кайтып китәр.
Шундый ук як-якта җыеннар булып, июнь үтәр.

1912

КЫЗГАНА

Таң ата да җир йөзенә акрынлап күз сала,
Күрә: Туран угълы ята, башкалары кузгала.

Чын күңелдән кызгана да тели ул уятмага,
Шул сәбәпле куша кояшка музыка уйнатмага.

Ул чыгарган көйләр илә нечкә йөрәкне өзә,
Дөньяда йөзләгән адәм егъламый ничек түзә.

Ләкин ул һич тәэсир итми бу Туран угълынына,
Сулга яткан да, әйләнми, ичмасам, уң ягына.

Әмма башкаларга бу хәл бик каты тәэсир итә,
Кисә киеп бер җиңене, ажгырып эшкә китә.

Бу хәятны мәрхәмәтле таң күрә дә кызгана,
Уятуга билне баглап, беләкне дә сызгана.

Шул сәбәпле, тегендә итенеп килеп китә,
Өмет өзми һич вакытта,— уянганнарын көтә.

1912

ШАКҠАТЫРА

Мишәр, башкорт, казакъ, татар,
Башкагыз да тулып ятар.
Сезнең мәртдә ятуыгызга
Бөтен мәхлукат шаккатар.
Чөнки төп атагыз Туран,
Янә дә абзагыз туган;
Хәтта төн йокыларында
Якынга килмә дип куган.

Шулай алар нык кырышкан,
Шуңа максатка ирешкән;
«Еламасаң, ими булмас»,—
Дигән сүзләр бик килешкән.
Ә сез һәнүз тик ятасыз,
Үзара суган сатасыз;
И, ходаем, үзең бир, дип,
Як-яктан башны ватасыз.

Мәхлукат — җан ияләре.

Туран — иранлылар тарафыннан төрки халыклар яшәгән урынарга бирелгән исем.

Һәнүз — әле дә; һаман да.

1912

ВӨҖДАН ҺӘМ НӘФЕС

«Вау» белән «Нон» бергә туган, җоп чыгар,
Бу икәүсез дөньяда һич юк чыгыр.
Эш вә мәсләк юллары бер булмагач,
«Вау» белән «Нон» һәрвакыт орышып чыгар.
«Вау» төзек ул, «Нон» бозык, соң тискәре,
«Вау» тәүәссет, «Нон» — озынлы-кыскалы.
Сакчысы «Вау»ның — фәрештә гаскәре,
Тискәре «Нон» гаскәре — иблисләре.
«Нон» да шайтан гаскәре тыгылып тора,
Гаскәре аз «Вау» тора җиңелеп кенә.
«Вау» ягында булмагач көч, ни эшлим,
«Нон» юлында мин йөрим яңлыш кына.
Күп саен ак күкрәгем керләр бирә,
Һәр шәятин әүсафы ягылып кына.
Тискәре «Нон» гаскәре гел этләшә,
Билгеле, «Нон» үзе дә эт ләбаса.
Чын да мин әүлия булмасмы идем,
«Вау» мәлаик гаскәре бик шәп дәһа!

Мәсләк — дөньяга караш, тоткан юл.
Тәүәссет — уртача.
Шәятин әүсафы — шайтан сыйфатлары.
Мәлаик гаскәре — фәрештәләр гаскәре.

1912

ИМЕШ

Беләсеңме? Ямь-яшелдән киң генә чапан киеп,
Чалма чорнаса казандай, әһле тәкъвадай, имеш.

Һәм сакалны үстерү белән, сач-мыекларын кырып,
Кәҗәдәй булып йөриләр әһле ислам, дин, имеш.

Ничә тәсбигъларга тартып, ашарына калмаса,
Кайгыдан дивана була әһле хәяттан, имеш...

1912

«ГАЛИЯ» ҖЫРЛАРЫ

Кара бәрән тиресе дә
Кама булыр дисеңме?
Сикереп төшеп биегәннән
Язык булыр дисеңме?

«Галия»нең ятагында
Ике катлы карават,
Киләчәкне кайгыртыйк без,
Үткән эшкә салават!..

Әһле тәкъва — дин кушканны гына эшләүчеләр, диндар кешеләр.
Әһле ислам — мөселманнар.
Әһле хәят — тереклек ияләре.

1913

ТУКАЙ ҮЛГӘЧ

Абау алла, уф алла, үлде шагыйрь Габдулла,
Үлде, әмма сайрап үлде якты, матур, ак юлда.

Әй, хөрмәтле Габдулла, ярлыкасын сине алла,
Шигърең белән рухландырып, салдың безне ак юлга.

Сөйде милләт бу шагыйрен, белде кадерен-хөрмәтен,
Үз юлында армый-талмый итте, мескен, хезмәтен.

Тик үзен изгән түбән дөньяны сансынмады,
Китте милли дөньядан, калдырды үксез милләтен.

Тәсбих вә тәһлил кебек, җырларга калды җырлары,
Моңланып исһәргә калды тәмле исле гөлләре.

«Мәрхаба!» — дип каршы алсын бу татарның былбылын
Мәңге оҗмахта ходайның хурлары, былбыллары.

Әй, хөрмәтле Габдулла, ярлыкасын сине алла,
Шигърең белән рухландырып, салдың безне ак юлга.

Тәсбих — көйләнеп санала торган дисбе.
Тәһлил — гарәпчә «бер алладан башка алла юк» дигән җөмлән әйтү.
Мәрхаба! — Хуш килдегез, килүегезгә шат!

1913

ҖЫРЧЫНЫ КӨТКӘНДӘ

Тир-ра-ра-ра, ри-ри, ра-ра-ри-ри...
Тизрәк җырчы килсә ярар иде;
Җырчының җырлаганын тыңлап торсам,—
Күңелдә кайгы-хәсрәт тарар иде;
Кайгыга аралашып кайнар яшем
Мөлдерәп, икс күздән агар иде.

Мөмкинме кызык җырга кызыкмаска,
Моңланып моңлы көйгә, боекмаска?
Таш колак, үлгән йөрәк, туңган башлар
Моңлыга моңаймас та, боекмас та:
Адәмне төрле хәлгә салган җырлар
Наданны кыздырмас та, суытмас та.

1913

КЫЙТГА

И ходаем, мал-милек — барысы синең
милкеңдәдер;
Бар хәер эш-яхшылык «кодрәт» дигән
илкеңдәдер;
Бай булу, хурлык күрү, абруй китү,
шөһрәт табу,—
Барчасы синнән, илаһы, һәммә эш
иркеңдәдер.

1913

* * *

Рәхмәт, апай, җибәргәнсең дүрт бәрәңге,
Тәрбияләп үстерә күр дүрт баланы;
Батыр уллар, матур кызлар үсеп җиткәч,
Таң калдырсын тирә-якны, күп адәмне!..

1913

КҮҢЕЛСЕЗ ЧАКТА

Юкка чыккан, юкка икмәкне череткән бәндә мин,
Бер зәгыйфь, көчсез, һөнәрсез, буйга беткән бәндә мин,
Чәчкә төсле күкрәп үскән, иң кадерле чакларым,
Бер дә юкка алданып, тик исраф иткән бәндә мин.

1913

КҮҢЕЛЛЕ ЧАКТА

Пакь туып, вөждан белән, пакьлектә үскән бәндә мин.
Бәндәләргә «бәндә» булганнар эчендә алла мин.
Саф иман тапланмаса, тәкъдир аяктан салмаса,
Нурлы йолдызлардан да нурлы ялтырармын алда мин.

1913

ҺАТИФ ВӘ ТАТАР

Һатиф: Күз салып торсам, кызык соң сез татарның дөньясы,
Уртагыздан шаулап акмакта наданлык дәрьясы.
Сез утыз миллионга җиткән бер халыкны актарып
Эзли башласаң, килеп чыкмас утызлап мулласы.

Татар: Юкны сөйлисең, фәрештә, бездә бик күп муллалар,
Һәр авыл саен кимендә өч указный мулла бар.

Һатиф: Юк, алар мулла түгел, алар «татарның каргасы»,
Тик аерма шул: яшел бишмәт, түбәлдәй чалмасы.
Андый гайбәт капчыгың һәм андый каргаң — унга бер,
Ә Зыяң һәм Акчураң, Мусаң, Ризаң миллионга бер.

Татар: Син беләсең «Ишми»емне, бит аны кем дә белә,
Дөнья тетрәткән ишан ул, берүзе меңгә тора.
Ничә йөз асрап мөрид, милләт вә динне саклый ул,
Бер бакыр тәртсәң аңа, таудай каралны аклый ул.

Һатиф: И татар, һич белмисең, Ишми ишан — чын дошманың,
Ул — динеңнең тамрыны кыркырга торган тычканың.
Мәдрәсәңне яптыра, төрле доносларяздыра,

Бик анык бел! Ул — монафыйк, иң беренче
шайтаның.
Кушмый шайтан — «Дөньяга мишәйт»
журналының әгъзасы,
Ул — идабәр, ул — шикайәт, ул — явызлык
казнасы.

* * *

Шул вакыт мескен татар һич эндәшми тик
тора,
«Иттифак!!.» дип бер тавыш килгәч, бетә
тын, җил өрә.

Монафыйк — икейөзле, әчкерле.
Идабәр — бәхетсезлек, уңышсызлык.
Шикайәт — зар, сукрану, жалоба, донос.

1913

КАДИМ МУЛЛАНЫҢ СҮЗЕ

«Надан калмыйк, тырышыйк, беләек,
Вә белгәч, белмәгәнгә белдерәек.
Үзебезне үзебез кимсетәбез,
Белик тә, рәхәтләнеп тораек.
Әгәр белсәк, булыр мулла бар адәм,
Мәзин, мулла чыгар безнең арадан.
Чыгар әдип, мөхәррир һәм мөһәндис,
Чыгар барлык татар таптан-карадан».
Менә шулай диләр зиндыйк җәдидләр,
Сәләфләргә, борынгыларга зыйддләр,
Кадер калмас, бетәр пачут вә хутлар.
Әгәр бар да укыса, мулла булса,
Бетәр яхшы, җуан башлы гощерләр,
Тимәс тәңкә, әгәр бер кортка үлсә.
Авылга салмагыз мәктәп, и байлар!
Бетәр булса мең баллар вә майлар,
Ижек, Әбҗәд, Кисекбашлар да артык,—
Укымасын авылдагы малайлар.
Салып мәктәп, укучылар күбәйсә,
Китәр кадре гыйлемлекнең, агайлар!
Борынгы чаклар үтте бит, и туганнар!
Борынгылар тик аз-маз укыганнар,
Күбесе укымый дөнья куйганнар,
Җеп ишкәннәр, чабата тукыганнар.
Хәзер минем хәлем җайсыз, егетләр,
Кучәремә катып беткән дегетләр.
Укытып күп адәмне, мулла ясап,
Дегетләде мине мәлгунь җәдидләр.

Кадим — иске, борынгы.
Мөһәндис — инженер, җир үлчәүче.
Сәләфләр — нәселләр.
Зыйдд — каршы, дошман.

1913

* * *

Агыйделдән саллар ага,
Сал өстендә мал ага.
Эшең төшмәсен дөньяда
Мулла белән аллага.

1913

КЫЙТГА

Белмәгән белән бәрабәрме белә торган кеше?
Тиң булырмы күрмәгән белән күрә торган кеше?
Берме, үз-үзен наданлык каберенә күмгән белән
Чын гыйлемнән кальбенә рух-җан бирә торган кеше?

Кальбенә — күңеленә.

1914

ХАЛКЫМ ӨЧЕН

Аппак алтын җырларымны
Җырламыйм данлык өчен,
Җырлаем алтын илемчән,
Үз туган халкым өчен.

Саф көмештик җырларымны
Җырламыйм алтын өчен;
Җырлаем тик саф көмештик
Саф йөрәк халкым өчен.

Чәчкә төсле җырларымны
Җырламыйм зәукым өчен,
Җырлаем тик чәчкәдәй
Кызларга бай халкым өчен.

Дәртле кайнар җырларымны
Җырламыйм дәртем өчен,
Җырлаем тик мәңге шат,
Дәртле, көләч халкым өчен.

Егъламыйм мин көннәрем
Сыргак, суык, салкын өчен,
Егълыем тик ярлы, мескен,
Кызганыч халкым өчен.

Яшь чагым, алтын чагым,
Ялкын чагым булсын фида,
Халкым алдында минем
Биргән таза антым өчен.

Илемчән — илем өчен.

1914

БАЙ ҺӘМ ЯРЛЫ

Син сабыр итсәң сабыр ит, башкасы сабритмәсен,
— Юк, түзалмыйм — сабриталмыйм, акчасы
жәбритмәсен.

Эч яна, тормыш тигезсезлекләрен уйлап яна,
Моңлы мескен бәндәләрнең моңнарын сөйләп яна.

Мин чыгып бактым урамга, моңлы күзләр аркылы
Күзгә чыкты, яшь булып, күкрәктә янган ялкыны.

Сабритмәсен, жәбритмәсен — сабыр итмәсен, җәбер итмәсен.

1914

БЕР МИНУТ

Бер минутта ташты күңлем, бер минутта булды ут,
Бер дә янды, бер дә тынды — бары да булды бер минут.

Бер минут — бар дөньясын каргап кабынды утларым,
Янды, көйде, парча-парча булды мескен күкрәгем.

Әйе, янды күкрәгем... Тик юк, ләкин мескен түгел,
Бу йөрәк — утлы йөрәк, үткен күңел, кискен күңел.

Ул яна, тик кайгырып янмый, яна шатлык белән!
Ул яна, бу дөньяны күрмәк булып аклык белән!

Ул яна... чү, сипмәгез су, әйе, ул янсын әле!..
Янган утлар күзләремнән яшь булып тамсын әле!..

Там, минем күз яшьләрем, там, там, тамып тор мәңгегә,
Ян, минем ак күкрәгем, ян, ян, янып тор мәңгегә.

1914

АЙГА МЕНДЕМ

Айга мендем, ай нуры белән коендым, уйнадым,
Күп сөендем, сөенеч белән туендым, туймадым.

Туймадым, айдан узып мендем кояшка ашкынып,
Юк, шулай да булмады ташкын күңелне бастырып.

Шул барыштан барышыма киттем ходайның гарьшенә,
Унсигез мең галәме артымда калды барысы да.

Ни өчендер тапмады күңелем карар гарьшендә дә,
Көрсине күрсәм дә хәтта, тынмадым анысында да!..

1914

ЯРСЫНМАСА КҮКРӘК

Ярсынмаса күкрәк яшьнәп, күкрәп,
Телләрендә ялкын яналмый,
Аһ ормасаң сыкрап, тетрәп-тетрәп,
Кулларыңнан алтын тамалмый.

1914

КЫЙТГА

Нәфес — шайтан, бик явыз ул, һәр адәмне аздыра,
Аздыра торгач, наданнарны юлыннан яздыра.

Әмма аннан да явыз бер нәрсә бар: ул — эчкелек,
Ул халыкны йорт-җиреннән һәм диненнән яздыра.

1914

МАНДОЛИН

И үзәк өзгеч тавышлы, моңлы, зарлы мандолин,
Җилче, моңланчы өзеп бер, мин дә тыңлап моңланыйм.

Син минем җан сердәшем, җан моңдашымсың, мандолин!
Сергә беткән, моңга беткән зарлы тавышың җанга им.

Шул синең тавышың гына тик дәртемә дәрман бирә,
Шул бирә һәр нәрсәне: шул җан бирә, шул ямь бирә,

Шул миңә уй, шул миңә хис, шул миңәргә аң бирә.
Шул миңә сер чишмәсеннән ләэлөэ вә мәрҗан бирә,

И минем күңелемне сафлаучы мөкатдәс мандолин,
Сине тыңлап, күзләрем саф яшькә манчып алгалыйм.

Сине тыңлап, һәммә таптан, һәммә кердән сафланам,
Сафланам да, пакьләнәм дә — алла, алла, алла! дим.

И сихерле, серле, илһамлы, гаҗәеп мандолин!..
Әйдә сыздыр, әйдә өздер, сафланыйм, иманланыйм!

Ләэләэ — энҗе.

1914

ЯРКАНАТ

Нигә көндез очмадың син, әй акылсыз ярканат,
Хәл җыяр, йоклар вакытта син йөрисең очкалап.
Барча кош көндез йөри, көндез генә җилпи канат,
Төн буе йоклыйлар алар, чөнки төн — йоклар сәгать.
Син исә төнлә очасың, ни кызык? үткәч вакыт;
Көндез очканда кошлар, син карап калдың ятып?
Син оча дип төн агармас һәм кояш кайтмас кире,
Уңмаган син, әйләнәңне каплаган гафләт чире.

* * *

И туган, минем, хәлемне ярканатка кыл кыяс?
Калка гаклым башыма тик үткәч эш, баткач кояш.

1914

* * *

Ризабыз, кыйсмәтең безгә бүлемле:
Наданнар маллы, әмма без белемле;
Бетә тиз дөнья малы, мәңге тормый,
Белем бетми, юылмый һәм дә черми.

Гафләт — гамьсезлек, ваемсызлык.
Кыяс — охшату.
Кыйсмәт — өлеш.

1914

БӘГЪЗЕ СТУДЕНТЛАРЫБЫЗ

Яхшы кылдым: яшьлегемдә русча укый башладым,
Слава бох, күптән шәкерт дигән исемне ташладым.
Мин хәзер бит абразуынный, пакрайнимир, шәп җегет,
Эндәшә һәркем миңәргә: здрастуй, студент!
Өстә дә шәп, башта картуз, билдә бик шәп киң каеш,
Шәп брюка, ул аякта яхшы шиблит һәм калуш.
Җиз төймәләр пальтода ялт-йолт итеп балкып тора,
Ну бәхетле студент син! — дип гүя әйтеп тора.
Ул минем чәчләр кая киткән, һаман майлап торам;
Маржалар алдында мин былбыл кебек сайрап торам.
Һәр вакытта мин сүземә русча кыстырып сөйлим,
Патамушты наш язык неприятны дип уйлыйм.
Мин татарча милли кичәләргә һич тә бармаем,
Рус театр дөньясына бер дә бармый калмаем.
Анда мин кызлар белән тик кулга-кул ялгашып,
Ха-ха...лар илән көлеп тансы итәм тып-тып басып.
Мин татарча җырлый белмим, җырламыйм һәм җырламам,
Тик фәкать рус җырларын җырлап юанам, моңланам.

1914

БЕР МУЛЛАГА

Анда барып кычкырасың: «Эчмәгез, эчке харам,
Эчтеңисәң — беттең, харап булдың,— дисең,—
малың әрәм!»

Монда килеп: «Кем бара,— дисең,— калага иртәгә?
Бер чирек алчы!» — дисең, әйтсәң әгәр дә: «Мин барам».

«Эчмәгез!» — дигән буласың, әй, аракы мичкәсе!
Дин әрәм һәм мал әрәм булгач, үзең дә эчмәче!

«Эчтеңисәң — беттең!..» имеш, соң үзең ник эчәсең?
Әй, кеше кайрап йөри торган кара кайрак ташы!

1914

САМАД ӨСЛҮБЕ

(«Тормыш» мөхәррирләреннән)

Күр әнә — «тау» башка тау, зур тау, гаҗәп зур тау әнә,
Шундый тау, мәгърур танаулардан да мәдһиш тау әнә.

Ат ялы, ат койрыгы төсле үләннәр анда юк,
Анда аксыргак, әрекмән, типтәрен калган да юк.

Анда, әйтәм бит, үләннең исме дә, җисме дә юк,
Хәтта ки имгә дә юк, исме дә, төсе дә юк.

Андагы тау балчыгын без күрмәгән һәм белмәгән,
Андагы туфрак тагын һич, һич тә төшкә кермәгән.

Туфрагы кызыл түгел, кара түгел һәм ак түгел,
Башлары өйдәй, ләкин бармак башыдай түгел.

Бездәге кебек анда кыздырмый кояшның чаткысы,
Тик бары ул көйдерә,— вот шунда шул гаҗәп төше.

Искитәргеч, шаккатыргыч андагы тынлык тагын,
Ямьле, нурлы, серле күркәм андагы моңлык тагы.

Сайрый кошлар, каргалар; черки-чебеннәр бызлыйлар,
Һәм сыерлар мөңриләр, тынлыкны һич тә бозмыйлар.

Шул чебеннәр бызлавы китте йөрәкне яндырып,
Каргалар каркылдыйлар, аһ, үтерәләр моңландырып...

Әллә ничи серле моннарны күңелгә алдыра,
Ул мәһабәт нурлы тауда, әйтсәм әйтим, ул — Хира.

Күп чокырлар анда тынлыкны тагын да серләндерә.
Шул чокырларның берсендә бер адәм тик утыра.

Күзләрен текләгән дә ул, уйлый да уйлый әллә ни,
Әллә кайларга текләп уйлый,— бәхетсез бәндәмени?

Күкрәге киң, кап-кара чәче, тешләре бодай кебек,
Йөзләрендә балкый нурлар, балкый тулган ай кебек.

Шул мәгарәдән ерак түгел биек тау өстенә
Утырып уйларга талган, кул куеп баш өстенә.

Ул халыкның тормышын яхшыртырга бер ачкыч көтә,
Күпме көннәрдән бирле ул шунда бер, бер эш көтә.

Йөзләрендә, күзләрендә, җитдият балкый аның,
Ул иренмичә иркенләп уйлыйдыр халкы хәлен.

Юк маниг҃ъ йөртергә фикрен берүзе әллә ялгызы,
Шул фикер бәгъзрендә йөзмәктә үтә кич-көндезе.

Ул теләгәнчә фикер йөртә, теләгәнчә тора,
Уйларын уйлап, фикер йөртеп, фикердә утыра.

Ошбу көн ныграк чумып киткән фикер дөньясына,
Нидидер бер җитдият кергән бөтен әгъзасына.

Бервакыт ул күзләрен тутырып карый да алдына,
Әллә кайдан бер кеше килде дә чыкты алдына.

Калтырап китте аның, тетрәп мөбарәк тәннәре,
Әгъзасы катып, оеп, калды кымырҗып йәннәре.

Чем-кара, ап-ак кием кигән теге килгән кеше,
«Син укы!» дигәч, аның хәлләр бетә, тәннәр өши.

Әгъзасын бизгәк тота, дер-дер киләдер, калтырый,
Калтырый, ни эшләргә белми куркына һәм аптырый.

Өушына килгәч тә, айныгач та ул кайтып китә,
Нәрсәләр күргәнен барын да әһленә сөйләп бирә.

Ошбу көннән башлап ул илче була ул ошбу көн,
Ошбу көннән башлап ул рәсүл буладыр ошбу көн.

Бәндәләргә якты капкалар ачыла ошбу көн,
Ошбу көн йөрәкле рәсүл арыганча эш, бик, бик читен.

Ошбу айда туды зур, өлкән, бөек иблисебез,
Туды зур хәлфә, бөек остаз, олы юлбашчыбыз.

Бәс бүген без сакланабыз, акланабыз ошбу көн,
Пакьләнәбез, хакланабыз, шатланабыз ошбу көн.

Тәмле ашлар капкалыйбыз, кафкали бу ошбу көн,
Эчтәге серләр[не] һич тә сакламыйлар ошбу көн.

Нурланабыз, җырлашабыз, шәпләнәбез ошбу көн,
Типтерәбез, уйныйбыз, рәхәтләнәбез ошбу көн.

1914

ТАРКАУ УЙЛАР

Уйларым таркау, томан кайный — җәһәннәм, авырый баш,
Урыла утлы төтен, атылып чыгадыр утлы таш.

Бу вәһемнәр илә ысланган хыялым ләүхәсе,
Юк ничек күңелемдә илһам анда ингикас.

Ох бу башымны, и ходаем, бу минем чын баш түгел,
Ах... залим баш — синдә мәхкүм калды мәзлүм яшь
күңел...

Белмисен, баш, син минем дәрьям төбендә ни барын,
Барыбер сизсәң дә булмый, чөнки син гаувас түгел.

Зир-зәбәр уйлар, газаплар берлә тик сызлый бу баш,
Урыла, кайный төтен, кайный томан, гөжли бу баш!

Вәһемнәр — уйлар.
Ләүхә — такта.
Ингикас итсен — күренсен, чагылсын.
Мәхкүм калды — тоткын булып калды.
Гаувас — диңгез төбенә чумып җәүһәр эзләүче-табучы кеше.
Зир-зәбәр — асты өскә (килү).

1915

ӘЙДӘ, МИЛЛӘТ!

Йөк авыр, юл болгавыр булса да, милләт, әйдәле,
Алда рәхәт кадрене белмәккә михнәт файдалы;
Якты, нурлы көннәрең алдында — бу хак вәгъдәсе,
Әнә күренә кыйбла яклап бик матур ак шәүләсе...

1915

МӨТӘШАГЫЙРЬ ЗАРЫ

Һәркайчан кыздырса көн дингез йөзен кайнарлатып,
«Бу» булып күккә оча да «су» булып җиргә төшә.

«Бер шигырь яз!» — дип мине кыздырса дәрт, ул күп вак:
«Уй» булып искә төшә дә «сүз» булып җилгә оча...

Уй күгемнән мәгънәләр эзләп очам,— табалмыймын,
Эзләнеп тә тапмагач, аһ, рух төшә, кайгым үсә...

Мәгънә бар, ләкин ерак шул, көч кирәк, баралмыймын
Берсе булса, берсе булмый, эч поша да эч поша...

Мөтәшагыйрь — шигырь язып маташучы.

1915

СКРИПКА

И минем сызгычлы нәрсәм, и матур кәкре муен!
И күңелнең назлы урыныннан урын тоткан уен!

Сандугач күк сыздырып, сайрап җибәрче бер генә!
Сайра, җырла, тик мине дәртләндерүче син генә!

Син генә иң нечкә хисләр, нечкә моңнар чишмәсе,
Син тавышлар казыйсы һәм син уеннар патшасы.

Син — бу дөньяның түгел, оҗмахта хурлар сазы син,
Саф, матур, моңлы авазларның бөек остазы син.

Таң калам мин таушыңа, нинди тылсымлы тавыш?
Нинди моң баскан тирән серле вә әфсүнле тавыш...

Нинди һәм ялкынлы ул — салкын йөрәкне кыздыра!
Бер җылап, бер моңланып, бер сызгырып җан өздерә.

Нинди нәрсә бар соң анда: зарлана, зар-зар елый,
Зары зар, елаучы кем соң: әллә җен, әллә пәри?

Кем генә соң кул очыннан кыл эченә моң чәчә?
Кем чәчә моң, кем сибә? Кемнәр елый, кем ыңгыраша?

Мин гашыйк булдым сиңа, и скрипка, әйдә сыз!
Әле дә син бар, юкса дөньям мәгънәсез һәм файдасыз.

Әфсүн — сихер.

1915

КЫЙТГА

— Фәлсәфәдән туйдык инде, сатма, ташла фәлсәфәң
Фәлсәфә чәйнәр заман узган, хәзер эшләр заман...

— Сез туйгач та, туймаганнар ач көйгә торырмыни?
«Фәлсәфә сатма...» дигән сүз фәлсәфә түгелмени?..

1915

КЫЙТГА

Куй нәфесне иркенә, тән төрмәсендә ятмасын,
Тик аны вөждан җебе белән тышаула, качмасын!

1915

* * *

Әйдә, күңлем, монда торма, күккә, күккә, күккә оч!
Күккә оч, күктә тыныч... Монда — сугыш, монда —
кылыч!

Әйдә күккә, монда ямь юк, күктә ямь бар, анда нур,
Монда нәрсә? — Ямьле сыннар... Анда хур бар, анда хур

Әйдә, гомрем, әйдә, бәхтем, әйдә, күңлем, бергәләп,
Монда булса күбәләкләр, андадыр барлык мәләк.

Мәләк — фәрештә.

1915

КӨРӘШЕП ҮТКӘР ҚЫСКА ГОМЕРЕҢНЕ!

Ник сызлыйсың, күңлем? Ник юк өчен
Агулыйсың минем канымны?
Көйдереп син эчтән, һич вакытсыз
Чыгарасың, ахры, җанымны.

Үзеңне син изеп янган белән,
Уйлама син вакыт үтәр дип,
Кара төндә кара болыт булып,
Җирне баскан золмәт китәр дип.

Сине бәйләп тоткан нык богауны
Бик тиз генә өзә алмассың,
Аяк астың тулы тирән чокыр,
Бик тиз йөгреп китә алмассың.

Төкер дөньясына, бул түземле,
Агулама юкка тамырыңны,
Чын ирекле алгы көннәр өчен
Көрәшеп үткәр кыска гомреңне!

Сөю, вөждан, иман, хаклык кебек
Матур сүзләр — искән җил генә;
Алар — сәмави сүз, күктә алар,
Аларны тик сөйли тел генә.

Каргалган җир үзенең тамугында
Әле бик күп еллар яначак,
Рия, нифак, вәхшәт сазлыгында
Бик күп еллар батып ятачак.

Золмәт — караңгылык.
Сәмави сүз — күк сүзе, изге сүз.
Нифак — әчкерлелек.

1915

ГӨНАҺ — ҖӘЗА!

Таянып иягкә,
Күз текеп еракка,
Утырам уйланып,
Берүзем бер якта.

Уйланам, уйланам...
Уй белән югалам...
Бервакыт кинәттән
Сискәнеп уянам.

Уянам, ни күрәм?..
Әйләнә һәр тирәм,
Уй тирән һәм томан...
Шаккатып тик торам!..

1915

АПТЫРАГАН МИНУТЛАРДА

Мең төрле уй, катты баш...
Нишләргә дә аптыраш!..
Яртым яна, яртым туңа,
Җаным үлде яртылаш...

Какты дулкын, акты яшь...
Сүздә «ләгънәт», күздә хәсрәт,
Эчтә дәһшәт, калтыраш...
(Булмый шул эш буталгач...
...Мәсҗет — таш... мулла — юкагач!..)

Юл баткак, ваһ лайла,
Кул-аяк богауда;
Кыймылдап булмай ла!..
Ва!!! Хәсрәт ва вәй ла!!!

Ут йөри үзәктә,
Эч яна дозахта;
Ургылып ялкыннар
Тоташты йөрәккә...

Йолдызым өметсез,
Күз егълый өзлексез...
Кадалсын дөньясы,—
Күңелгә кызыксыз!..

Ян, бичара җан!
Там, кап-кара кан!
Көлсен бөтен җиһан
«Шәехзадә» бичарадан!..

Дозах — җәһәннәм, тәмуг.

1915

АПТЫРАШ!

(Вариант)

Мең төрле уй, катты баш,
Нишләргә дә аптыраш!..
Яртым яна, яртым туңа,
Җаным үлде яртылаш.

Артым салкын, алдым ялкын,
Какты дулкын, акты яшь;
Сүздә — ләгънәт, күздә — хәсрәт,
Эчтә — дәһшәт, калтыраш...

Уй чуалды, катты баш,
Нишләргә дә аптыраш.
Булмый шул эш буталгач,
«Мәсҗет — таш, мулла — юкагач!..»

1915

ШӘМСЕТДИН СУФЫЙ АВЫЗЫННАН

Бу җиһанда без татардай
Тозсыз улгай, улмагай,
Булса булгай, без шикелле
Эшсез улгай, улмагай.

Башкалар эшли һаман,
Чөнки алар ялкау түгел,
Әмма бездә эшчеләр юк,
Булса — йөзгә тулмагай.

Пыр тузып алга баралар,
Омтылалар башкалар,
Тик ятып безгә бәхетләр
Әллә килгәй, килмәгәй.

Дөньяда тормак теләрсәң,
Форсатыңнан файдалан,
Нагяһан синең гел [ул]
Кулда торгай, тормагай.

Башта хикмәт, башта гайрәт,
Эчтә зиннәт булмаса,
Тышкы купшылык, туганнар,
Зәррә файда бирмәгәй.

* * *

Әй җәмәгать! Шактый ук мин
Фәлсәфә саттым бугай.
Инде хәзер бу укучы
Безгә чыккай, чыкмагай.

Зәррә — бертек.

1915

ӘЙ АДӘМ БАЛАЛАРЫ

Йә әййеһәл башкортын,
Чүплисе бар баш кортын.
Килеп чыгып астыртын,
Татарларны шаштырдын.

Йә әййеһәл нишарәт,
Аңласаң бар ишарәт.
Аңламасаң шишарәт,
Корсагыңны тишәр ат.

Йә әййеһәл типтәрләр,
Аң булмасаң, утарлар.
Алай-болай итәрләр дә
Яман якка селтәрләр.

Йә әййеһәл казачи,
Эшеннең күп казасы.
Казан калса, язасы
Гөрзинең иң тазасы.

Йә әййеһәл татарин!
Вак мылтык атарин.
Медаль алдың ваклыкта,
Тәхсин, тәхсин афәрин.

Йә әййеһәл кыргызлар,
Йондыз баскан кондызлар.
Җирегезне пычрата
Харам авыз дунгызлар.

Йә әййеһәл мөселман!
Эчмиенче исергән.
Бер тин өчен пошынган,
Юк эшләргә кысылган.

. . . .

Эшкә килсә ишелгән,
Сүзгә килсә очынган,
Кичкә керсә кычынган,
Иртән торса шешенгән.
Берсен-берсе макташып,
Гарешләргә очырган,
Туры әйткән кешегә
Мәңге дошман киселгән.

Йә әййеһәл мөслимат!
Тайаватын-сайават.
Бар дөньяңны читкә ат та
Кершән як та сөрмә тарт.
Тышка чыккач суган сат та
Өйгә ингәч йоклап ят.

Мөслимат — хатын-кыз.
Тайаватын-сайават — хатыннар дигән мәгънәдә.

1915

АКТЫК ЗАРЫМ

Валлаһи, син чәнчелеп кит, тончыгып ул, бет, кадал,
Шунда да һичкем дә күрмәс, валлаһи, бер эт кадәр.

Нишлием соң? Әйтче, зинһар! Чәнчелимме? Ни эшлим?
Чәнчелеп, чәчрәп чыгыйммы?.. Нишләсәң дә эш кыен!..

Нишлием соң? Зәгъкумле хәсрәтләр белән күңлем яна,
Нишлием соң?.. Мәлгунь иблисләр төкергән дөньяга...

1915

АВРУЫМ — САУЛЫГЫМ

Сау йөрүдән яхшырак ак юлга керткән авруым;
Чәнчелеп китсен ходайдан йөз чөерткән саулыгым!
И гаҗиз тән, сызла, сыкра, җан газапны аңласын,
Аңласын да алласын, һәр даим теленнән салмасын...

Зәгъкум — ачы, зәһәр.

1915

КИҢӘШЛӘР

Мулла булсаң — гавам халкын майлау яхшы,
(Мужик булсаң — яхшы мулла сайлау яхшы).
Каты бәрелеп гавам халкын өркеткәнче,
Сыйлап-сыйлап барын бергә бәйләү яхшы;
Кинәттән күтәрелеп куркытканчы,
Акрын гына, иплән кенә уйлау яхшы.
Хәлфә булсаң — шәкерткә сер бирмәү яхшы,
(Шәкерт булсаң — этем кебек өрмәү яхшы).
Шәкерткә: «Һи, җүнсез!» — дип кычкырганчы,
Иң элек үз җүнеңне турылау яхшы;
Бай булсаң, бик рәхмәт, байлык яхшы.
(Булмасаң, өмет өзмә, саулык яхшы).
Вә ләкин саулык бар адәмнәргә
«Карунлык»тан шиксез «хатим-эттаилек» яхшы;
Шагыйрь булсаң — ялындырмый җырлау яхшы,
Милләт чирен җырлый-җырлый чирләү яхшы,
Булмасаң, килештереп урлау яхшы,
Вә-л-хасил: тиккә карап тормау яхшы.

Гавам — кара халык.
Вә-л-хасил — кыскасы.

1915

ҖӘЙ КӨНЕ УРАМДА

(Мәхәүр)

Бервакыт чыктым урамга, өстә бишмәт җилбәгәй,
Җилләнеп, ялт-йолт карап һәм селтәнеп барам, агай!
Мин түгел ялгыз гына, янымда бер иптәш тә бар,
Өс-башы бик шәп апың, башында әйбәт фәс тә бар.
Бервакыт иптәш миңа әйтә: «Әнә кызлар килә!..
Тиз җыен, ыспай барыйк, тәнкыйтьче ут күзләр килә...»
— Килсәләр ни; мин килештермәм ләкин ыспай йөреп,
Чөнки мин яшьтән гадәт алдым, туган, шушылай йөреп.
— Юк, туган, иплә барыйк, юкса көләрләр бит алар,
Һәм: «Абау, нинди бара, зәхмәт»,— диярләр бит алар!..
— Көлсәләр көлсен, аларның көлгәнен шул мин телим,
Әйдә көлсеннәр, аларның көлгәненнән мин көлим...
Ул үзе күзлекне иплә, фәсне кыңгыр ташлады,
Житте кызлар, иптәшем тик йөргәләргә башлады.
Һәм тамагын төрле-мырлы кыргаларга башлады...
Елмаеп мыскыллаучы күзләр үттеләр тиз-тиз басып,
Үттеләр дә тәхкиранә, көлделәр шыркылдашып.
Тик алар көлгәч, миңәргә үпкәләп иптәш диде:
«Син әгәр килсәң минем күк һич алар көлмәс иде».
Мин дидем: «Иптәш, алар миннән түгел, синнән көлә,
Күркә төсле кыланышыңнан һәм дә фәсеңнән көлә...»
Уйладым: инде мине иптәш сүгеп ташлый, диеп;
Әле дә рәхмәт, бер тавыш бар (?):
«Көлкенеч фәсле...» диеп.

Мәхәүр — хозур (күңел ачу) урыны.
Тәхкиранә — мыскыллап, кимсетеп.

1915

БЕР ЭЧҮЧЕНЕҢ ЗАРЫ

(Аракы сату тыелгач)

И кая ул көн, ки бездә шәп торулар бар иде,
Ду китереп дөньясын тик әйттерүләр бар иде.

Җыелышып бар дус вә ишләр, рестораннарга тулып,
Бер-бер артлы шешәләр бушап торулар бар иде.

Бик кызып киткәч тә, бердәм кычкырышып, җырлашып,
Рестораннарның эчен дер селкетүләр бар иде.

Аз гына эндәшсә хатын — әйдә, йодрык, берие ман! —
Чәчләреннән йолка-йолка изгәләүләр бар иде.

Бәрәсең бер көзгегә, ул чәчелә дә юк була,
Менә шкаф, әнә әйбер, шалтыр да шолтыр йорт тула.

Ул арада атканыңның берсе лампага куна...
Шул куе корым, төтендә йорт тулулар бар иде.

Анда бер балаң чырылдый, монда берсе зар елый,
Балаларның коты кубып, калтыраулар бар иде.

Нинди гөнаһ шомлыгыннан, кайда китте ул заман?
Ары сөртенеп, бире сугылып, тик йөрүләр бар иде.

Кайда ул кәеф корулар, кайда ул киң ресторан?
Көне-төне типтерүләр, сиптерүләр бар иде.

1915

ХӘЗРӘТЕ СҮНЧӘЛӘЙ РУХЫНА

Чәлләне чалларга чал,
Салманы саннарга сал,
Алманы алма әле,
Алланы алда әле!

Алма, алма, алмакай,
Алдала да, ал да тай.
Алда, анда — бал да май,
Алдалый, җәнҗал Камай!

Зарлау, парлау, ялгаулы,
Қармау, алдау, әрләүле,
Ялкау, аңкау — мылкаулар,
Минрәү белән дүртәүләр.

Ышанмадым, алдадым,
Көчәнмәдем, алмадым,
Җайладым да майладым
Күчәрләрен арбаның.

Балчык-балчык, чуалчык,
Ачык-тишек, буталчык,
Тылсым-тылсым, мәтәлсен,
Булсын-булсын буталчык.

1915

ТИМЕРГӘ

Дога кылам Тимергә:
Бәхтең булсын гомергә,
Бәхтең үсеп, бай булсаң,
Мин баймын дип тилермә.

Дога кылам Тимергә:
Бу дөньяда җиңелмә,
Мәгърифәте тәхсилдән
Һичбер вакыт иренмә.

Сәгадәткә ирешкәч,
Сәфаләткә бирелмә;
Тимер, безнең орлыкны
Тәшәббес кыл җыерга.

Әгәр дога тозсыз чыкса,
Кабагыңны җыерма,
Әгәр инде яхшы чыкса,
Танавыңны киермә.

Мәгърифәте тәхсил — белем алу.
Сәгадәт — бәхет.
Сәфаләт — түбәнлек.
Тәшәббес — керешү, хәстәрен күрү.

1915

БӘНЕМ ФӘРЕШТӘМ

Зәңгәр күзкәйләрен зәңгәрләтеп,
Гүзәл карый минем фәрештәм,
Аһ, шул күзләр миңа җаннан артык,
Бәхет табам карап торыштан.

Ефәк чәчен үргән ефәк тартып,
Фире затлар аны үрешкән!
Җилбезәкләп теккән зәңгәр бәрхет
Зифа буйга бигрәк килешкән.

Сызылып төшкән нәзек тылсым кашка
Ай нурлары явып сырышкан,
Әллә энҗе, якут, әллә башка?.—
Тезелеп төшкән тешләр бер иштән!

Сөенеп-сөенеп яна утлы йөрәк —
Бер сүз катса миңа — сөенечтән,
Тавышлары аның асылырак
Чылтрап аккан көмеш инештән.

Фире затлар кичен айга басып
Назлыкаем белән күрешкән,
Бер-берсенә шунда ялганышып,
Ай нурында сарылып үбешкән.

Шуны күреп, күктә хури затлар
Гыйшык көен җырлап биешкән,
Шуны ишетеп, җирдә күбәләкләр
Гөл-чәчәкләр уйнап көлешкән.

Фире зат — гүзәл зат.
Хури зат — хурлар нәселеннән.

1915

КАНУН ТЫҢЛАГАНДА

(Фараби хәзрәтләренә багышлыйм)

Әй, Фараби хәзрәтем, төркем, каным, нәслем, җаным,
Мәңге онытылмас әсәрдән безгә калдырдың канун.

Үлүең ишетеп, аннан елап җибәрдем, түзмәдем;
Түзмәдем, күз яшьләремне күзләремдә өзмәдем.

Чирттерә, аһ, һич тәкать юк, яшь килә үзалдына;
Әллә нинди шәүләләр урнаштыра күз алдына.

Әллә ниләр сиздерә ул, әллә ниләр уйлата;
Иске хәлләр, иске чакларны терелтә, тыңлата.

Тыңлыйсың чын тәм белән, уйлар оча, уйный хыял;
Әллә кайчангы бабайларның җырын тыңлый хыял.

Тыңлыйсың да: «Бар иде, аһ, безгә дә бер чак,— дисең,—
Шундый хөр чак, башкалар кол чак вә һәм курчак»,—
дисең.

Кайда киткән, кайда юк булган ул чаклар, аһ!
Әй, күңел, ул чак белән бу чакларың үлчәп кара!

Сине тыңласам, канун, төрле авазлар ишетәмен;
Әллә кайларда гаҗәеп моңлы вәгъдәләр ишетәмен.

Шул вакыт сәмгъемдә төрле иске чыңнар чыңлаша,
Әллә кайда әллә кайчангы кавемнәр ыңгыраша.

Шул вакыт нәкъ карт мөәзиннәр азаны яңгырый;
Нәкъ Фараби хәзрәт таушы гөрелди, шыңгырый.

Сәмгъемдә — колагымда.
Кавем — кабилә, ыру.

Шул вакыт Коръән укыйдир төсле бердәнбер кари;
Шул вакыт җырлый, гүя моңлы Давыт хәзрәтләре.

Әй, канункай, моңнарың гел изге моң һәм иске моң,
Иске солтаннар сараеннан ишетелгән төсле моң.

Син — бөтен ислам серен, ислам җырын җыйган китап;
Моңнарыңның астына яшереп җыеп куйган китап.

Синдә тик, синдә җыелган бар тавыш, барлык азап;
Һәм азан таушы, кари таушы, нәби таушы сыйган.

Син мөселман халкының башыннан кичергән хәлләрен
Моңланып әйтеп торучы җанлы һәйкәлсең, канун.

Кылларың назлы, назык мәгъсүм авызны аңкыта,
Канча тыңлап та туялмыйм, башкалар ник ялкыта?

Чөнки алар үз түгелләр, чөнки алар читнеке;
Чит малы, чит әйбере, чит илнеке, чит йортныкы.

Чит уеннардан күңел кайтты хәзер, тик синдә уй;
Синдә рәхәт, синдә рәхмәт, синдә сөенеч, синдә көй.

Син барында — син генә җанның түрендә, син генә;
Син югында — сине сагынып уйлыйм мин гел генә.

Аһ, синең таушың, канун, чын сихерле могҗиза,
Чын рәхәт, җаннар эри, каннар таша, бәгърең өзә.

Әй, Фараби хәзрәтем, төркем, каным, нәслем, җаным,
Яңгырасын мәңге кануныңнан олы исемең, шаның.

Мәгъсум — саф.

1915

ДӨНЬЯГА

Әй дөнья, шашма,
Юкны алдашма;
Синең хәлеңә
Мин бит бик ашна..
    Беләм: син ялган,
    Белеп алданам!

Алдама мине,
Язың күрсәтеп,
Аулама мине,
Кызың күрсәтеп...
    Язың киң түгел,
    Кызың тиң түгел!

Салкын гакылың
Үзеңә булсын,
Тимә күңлемә!..
Үземдә торсын...
    Күңелем — ялкын,
    Гомерем — алтын!

Үз маягымны
Үземчә кадап,
Үз сабагымны
Үземчә аңлап,
    Юллар ясармын,
    Шулай яшәрмен!

Күкләр очармын,
Йолдыз үбәрмен!
Диңгез кичәрмен!
Теләсә нишләрмен!!! —

Ашна — таныш.

Мин — ирек ханы,
Ханы-солтаны!

Мин үзем «әдәб»,
Үзем «нәзакәт»!
Дөнья үземә
Итсен итагать!
Иманым — үзем!
Коръәнем — сүзем!

Нәзакәт — гүзәллек.
Итагать итү — буйсыну.

1915

БЕЗНЕҢ МУЖИК

Бер мужик әйтте миңа: — Русча беләсеңме, туган?
— Как же белмәскә, беләм, абзый, беләм, бик шәп беләм.

— Мин дә белеп калыйм сине, алай булгач,— диде.—
Миңа карап кына бер русча сүз эндәш,— диде.

Мин аңа әйттем: — Я бит сәпсим по-русски не знаю,
Уж ни мишай, оту тибә муклашка дают!

Китте ул мескен мужигым: — Вәт сиңа рәхмәт,— диеп,
Тындым эчтән: алдана безнең мужик, ахмак, диеп.

1916

КӨТӘМ

(Башкорт ысулынча)

Йөргән чакта башкорт тугайларын,
Җаным әллә кайда җилкенә,
Ишеткәндә моңлы курайларын,
Йөрәгемә моңнар бөркелә...

Тауларына менсәм, кырда йөрсәм,
Балкый җәннәт нуры... гөлстан,
Мескен башкорт авылын килеп күрсәм,—
Аңкый хәсрәт... үлем... гүрстан!..

Гүрстандай гамьле авылларда
Кыбырдаша җанлы мәетләр!
Җанлы мәетләрнең гамен көйләп,
Җылап ага Сакмар, Җаекълар!

Янып-көеп, бәгырем өзгәләнеп,
Ләгънәт укыйм... кемгә?.. белмәймен!
«Килер микән ак көн безгә дә?» — дип,
Уралкайга карап елаймын.

Күрәм, үз олпатын бозмай саклап,
Урал ята әкрен, тын гына...
Ала шунда, җанны тынлык каплап,
Килә башлый тәмле уй гына.

Ишеткәндәй булам әллә кайдан
Ырыс бәхет, өмет җырларын!..
Өмет кайнап, ташып күкрәгемнән,
Көтәм тиздән ак көн килгәнен!..

Олпат — мәһабәт.

1916

ТЕЛИМЕН

Ходайга егълап, телимен теләк:
Беләккә — куәт, йөрәккә — җөръәт.

Утлы пар кебек сулыш телимен,
Зөлфекар кебек кылыч телимен.

Кабынсын дөнья, бер өрсәм «уф!» дип,
Табынсын миңа аждаһа, гыйфрит!

1916

ОЧТЫЛАР

Гөрләшеп, дәртле минутлар
Очтылар «моңнар» белән;
Мин төшеп киттем, төшеп киттем,
Төшеп киттем түбән.

Очтылар моңнар һавага,
Җырлашып кызлар белән;
Мин торып калдым, көеп, әрнеп,
Күңел сызлау белән!..

Җөръәт — кыюлык, батырлык.
Зөлфекар — мифик кылыч.

1916

ГАМЬЛЕ КӨН

Иә, бүген нинди күңелсез, нинди чеплә, хәлбуки,
Чормап алган җир йөзен бер эчпошыргыч гамьле көй.

Тал төбендә утырып, карыйм бүгенге дөньяга:
Күк йөзе соргылт болыт, ямьсез томан күкнең чите.

Җир суык, гөлләр, үләннәр, чәчкәләр — бар да боек,
Моңланып күзләр бүген күңелдәге гамьне укый.

Анда-санда чак кына, яңгырга төрелеп, бөрки кар,
Көзге салкын җил кебек, бер җил исеп, гамьне бутый.

Елгачык елап ага яннан, агачлар шаулыйлар,
Шуларны тыңлап колаклар, күңлемә гамьнәр укый.

Елашып җырлый алар михнәт, золым, вәхшәт көен,
Күздә шәфкать бөртеге, эчтә яна хәсрәт уты...

Тал башында карга кар-кар, ди, бүген көн ямьле, ди,
Ямьлене таптың, тиле! — дип, тал төбендә мин: хи-хи!..

1916

ЯЗГЫ БӘЙРӘМНӘР

Төп тыныч үтсә, кайчан да көндезендә җил чыгар,
Көн тыныч үтсә, төнендә суры Исрафил чыгар.

Җил-давыллар туздырып, күк күкрәтеп яңгыр ява,
Кырга чык яңгыр соңында — һәр тугайдан җил чыгар.

Яуса карлар, тунса бозлар, яз китәр бер, боз китәр,
Җир чыгып, җир өстенә үлән чыгар һәм гөл чыгар.

Гөл чыгар чәчкә атып, кырлар булырлар чоп-чобар,
Гөл җыярга нурлы йөзле назлы нечкә бил чыгар.

Назлы кызның кырга чыкканын күреп, шатлык белән,
Каршылап калмак өчен сайрап матур былбыл чыгар.

1916

КЕМ?

Кемне яздым? Кем аягы берлән башны таптады?
Нинди пәрдә, нинди сәтрә күзләремне каплады?

Кемне мактыйм? Кемгә Җәбраилдән сәлам? Кемгә сәнам?
Җил-давыл купканда кемнәр кыстыра җилгә салам?

Кем минем зиһенемне күкләргә очырды кош итеп?
Кем минем күк карганы сайратты бер былбыл итеп?

Кем эчерде, кем миңа каптырды илһам шурпасын?
Кем миңа, мәсҗед ясап, тоттырды инсан иркәсен?

Кем дәһанымны минем тешнәп канатты? Кем соң ул?
Кем дөханымны минем иснәп яратты? Кем соң ул?

Кем минем аркамны тырный? Кем башымдан бет карый?
Бозлы яшьләр түккәнемдә кем күземдән сөрткәли?

Кемгә кемне баглады салкын катыш ялкын белән?
Бәхтияр итде шагыйрьне кем вә кемне кем белән?

Кем җәһәннәм төпләреннән мендереп куйды җаным?
Кем җиһанны тетрәтә, шалтыратып зынҗырларын?

Кем мине шатландыра, борчак, сарымсак күрсәтеп?
Кем мине дәртләндерә, илһамлы корсак күрсәтеп?

Ул — минем әфләс хыялым, күркәм әхрас Иблисем,
Гомремә күңлемне тырнап торган әкбах Иблисем.

Сәтрә — язу юлы.
Сәнам — тәре.
Дәһан — авыз.
Дөхан — тәмәке төтене.
Бәхтияр — бәхетле.
Әфләс — бушка чыккан.
Әхрас — комсыз туймас.
Әкбах — иң кабахәт.

1916

АҢЛАДЫМ

(9176 нчы номерлы «Вакыт»тан)

Җил куып, күккә карап, үткән гомерне белмәдем,
Иркә чаклар үттеләр, ялгыз торуны белмәдем.

Күкрәгемдә сүнделәр ялкыннарым хәсрәт белән,
Ирдән аерылмак ачы хәсрәт икәндер — белмәдем.

Ал мине, дустым, дисәм дә, илтифат та итмәде,
Кечкенә бер кыз белән тордым да калдым — белмәдем.

Кыз-хатыннарның базары юк хәзер, чөнки сугыш,
Яңлышып бик назланып киткән икәнмен — белмәдем.

Ул үзенә кыз табар, әммә миңа кайда кияү?
Мин өмет иткән кеше качкан икәнен аңладым...

1916

БЕР ТӘМСИЛ

(«Уфа «Галия»сенең ун еллыгына)

Кечкенә тәмсилем бар, тезеп булса,
Тыңларсыз, бәлки, сез дә, кызык булса;
Бервакыт бер бал корты читкә китте,
Китми ни, китәрсең шул, ризык булса!..

Ил ярлы, җире такыр, күп җире саз,
Чәчәк юк, әлван-әлван булыны аз.
Юк җирдән чәчәк табып, бал җыярга
Корт әле өлгермәгән, белеме аз...

Китте корт, чит илләрдән бағлар тапты,
Күп чәчәк күкрәп торган тағлар тапты,
Ачыккан ач үзәккә бал тутырып,
Шул җирдә ничә еллар-айлар ятты.

Бер заман илгә кайта балга канып,
Үз илен баллатуны алга алып,
Дәртләре йөрәгендә кайнап ташый,
Әйтерсең җәһәннәмгә алган манып.

Кайта да кунып ала кортсыз җиргә,
Шык бирә пәри тормас шыксыз җиргә,
Авызына ач кортларның бал тамыза,
Ут бирә туңып каткан утсыз җиргә.

Янына үзе төсле дуслар ала,
Һәр яктан очып килгән көчләр бага.
Җир асты — мәгарәдә урын табып,
Җу итеп тора болар, эшләр бара.

Эш бара, дусы арта, күче арта,
Көннән-көн күңел үсә, көче арта.

Әлван-әлван — төрле-төрле төстәге.
Күч — іл, корт күче — иле.

Инде тик бер мәсьәлә җанга бата,
Ул да шул: юк бер бакча һәм умарта.

Юнь бирә — умарта һәм бакча була,
(Боларны хәзерләүче акча була),
Көч җыеп эш башлаучы бал корты үзе —
Умартада корт-анасы — патша була.

Бакча бар, умарта шәп, эшләр җайда;
Бакчада чәчәк баллы, яхшы файда,
Ел саен җиткән кортлар, аерылып,
Һәр якка таратыла билгеле айда.

Булгалый умартада шаулашкан ел,
Өстенә корт-ананың тау баскан ел,
«Бакчаңда чәчәгең аз, китәбез!» — дип,
Зык кубып, җан туздырып даулашкан ел.

Корт-ана җавап бирә түзү белән:
«Әй, илем, гөл үсмәс,— ди,— кызу белән,
Чәчәк аз, кызыл-шәкыйк гөлләр юк, дип,
Ни мәгънә умартаны бозу белән?».

Корт-ана баса илен, үгет итә,
Каршылар йортны ташлап чыгып китә,
Шул рәвеш бер болгана, бер тынлана,
Шул рәвеш әкрен-әкрен гомер үтә.

Ун елы якынлашып килгән чакта,
Умарта дәрәҗәгә менгән чакта,
Шөпшәләр, төклетура, кигәвеннәр,
Әйләнә-тәгъзыйм кылып йөргән чакта...

Шул чакта бакчага бер сыер кергән *,
Бакчада явыз бидгать уен күргән:
Бер күбәләк кызыл гөлдә утырганда,
Янына умарта корт килеп кунган...

Сыер абзаң ачуланып моннан чыгар,
Бу ни эш; моңа сыер ничек чыдар!..

---

* *Мәдрәсәдәге азатлык рухына каршы Уфа буржуазиясенең мәшһүр скандалларына ишарә (Г. Ибраһимов искәрмәсе).*

Шәкыйк — ишле, парлы-парлы.

Тәгъзыйм кылу — олылау, зурлау.

Явыз бидгать — асылы яман.

Имеш, корт кубәләкләр сөеп йөрсен...
Бу хәлгә таң кала һәм бакчачылар.

Шул вакытта өсләренә үгез керә,
Керә дә коточыргыч бер сүз бирә:
— Умартаның янында тыңлап тордым,
Әйттерен яталар! — ди,— кубыз беләә;

Бөтенләй җибәрелгән, кызганнар, ди,
Бииләр, җырлашалар, тузганнар, ди,
Бу сүздән бакчачылар тамырында
Җәһәннәм ташкыннары кузгалган, ди.

Җәһәннәм ташкыннарын бозлатырлык
Бер хәбәр дуңгыз сөйли — үгә терлек:
— Бакчаңыз харап булган, һәлак булган!
Билләһи, сезгә хурлык, йөзгә хурлык.

Элекке эрекмәннәр аста калган,
Үләннәр колач җәйгән, чәчкә ярган.
Бозылган чәчкә исе — башкаланган...
Үләрсең, болай барса, мәсхәрәңнән!..

Бу сүздән багчыларда тәкать бетә,
Авыздан утлы ачу чәчрәп китә.
«Кадалсын умартасы, бакчасы!» — дип,
Бөтенесе, куллар селтәп, ташлап китә...

Умартага куркыныч көннәр туа;
Корт-ана бал эзләргә билен буа,
Сикерә үрдән кырга, һәрбер җиргә,
Үләннән үлән калмый куна-куна...

Ни күрсә, аңа барып кадала ул;
Сыгып-суырып булса да бал ала ул;
Шул көйгә азапланып җыя торгач,
Берәр ел яшәр кадәр хәл ала ул.

Өмет зур, ниятем там — чыдармын, ди,
Ялгызым умартаны багармын, ди,
Сикереп, үрдән кырга йөри торгач,
Мәңгелек гөлле бостан табармын, ди.

Ниятем там — ниятем таман, ягъни бик ачык.
Бостан — бакча.

* * *

Умарта бәйрәм итә ун сәнәсен,
Чакырып һәр баласын, йорт агасын,
Уйлашыйк, бу бәладән, бу җәфадан
Ниткәндә кортыласын корт-анасын!

Чәчәкле аллы-гөлле бакча кирәк,
Җылы өй, җимрелмәстәй матча кирәк:
Табылыр бакчасы да, барчасы да,—
Гайрәтле корт-анасы тапса кирәк.

Көче күп умартаның ничә йөзләп,
Бал җыялар умартада гөжләп-гөжләп;
Сыер, үгез — кортлар чаккач — чыдый алмый,
Чаптыралар, койрык чәнчеп, безләп-безләп!..

Сәнә — ел.
Кортыласын — коткарып буласын.

1916

ҚЫШҚЫ ЮЛ

Их, рәхәт, шуа чана, юырта ат талгын гына,
Як-ягымда киң ялан йоклап ята тын-тын гына.

Алдымда ак кар җәелгән ялтырап, ап-ак булып,
Энҗе-мәрҗәннәр чәчелгән өстенә вак-вак булып.

Юл читендә кар кисәкләре торалар тезелешеп,
Барсы да нелеп калалар: «Хуш, исән бул!» — диешеп.

Ак кояш, нур җепләрен сузган да җиргә нур сибә,
Нурлы җепләрдән агып, моңлы күңелгә җыр килә.

Җырлый башлыйм... Шунда салкын җил исеп, җырны
кисә,
Әй, усал җил! Қырдагы бар ямьне, бар моңны кисә.

1916

ЯМЬ КҮРӘЛМӘМ

Куркыныч уйлар килеп баскач, ирексез баш бөгәм,
Эчтә хәсрәт кайнашып ташкач, өзлексез яшь түгәм;

Ямь күрәлмәм, гамьле хәлләр китмичә, яшь кипмичә,
Күз яшемне киптерерлек якты кояш чыкмыйча.

1916

* * *

И улым, син күз нурым, син сөнбелем;
Килче, килче бер үбимче, соңра уйнарсың,
гөлем!..

1916

МИН — ДАҺИ!

— Мин укучы, мин җыручы, мин даһи!
Уздырырмын мин «даһи»дан, биллаһи!..

— Чү! Ханис булырсың, ант итмә, исәр!
Чү... даһи җаннарны рәнҗетмә, исәр!

«Дәрьяны үртим!» — дигән чыпчык сыман,
Буш куык холкыңны аңкытма, исәр!..

— Мин даһи!.. Йөрмәм үземне кәм тотып,
Тергезәм үлгән йөрәкне ант итеп!..

Ник?.. Ханис булсам, түләрмен кәффарәт:
Бар гомергә ут тотып та кан йотып!..

Ханис — антын бозучы.
Исәр — юләр.
Кәм — ким.
Кәффарәт түләү — җәзасын түләү.

1916

ЯМЬЛЕ КӨН

(Җәй хатирәсе)

Ах, бүген дөнья киенгән кызга охшый: тәп-тәти!
Кыз булып баскан табигать дөньяга аппак тәпи...

Хаузы кәүсәр чишмәсе өстеннән искән җил кебек,
Их, бүгенге җил һавадан бер гаҗәп ләззәт татый...

Нинди ямьле!.. Их, бүген оҗмах көненнән ямьле көн!
Кайда оҗмах... Фирдәвес бер якта торсын хәтта ки!..

1916

ШАТЛЫК ҖЫРЫ

Чайпалышып, шатлык дулкыннары
Чәп-чеп бәрелә күңлем ярына;
Шул шатлыклар белән каршы торам
Бу дөньяның барлык зарына.

Хаузы кәүсәр — мифик күл, мифик чишмә.
Фирдәвес — дини әкиятләрдәге оҗмахлардан берсе.

1916

КИСАС

Бер кеше язса, шигырьдә булса ул ифрат тупас,
«Аң» белән уйнаучыларга бик тиешледер кисас.

Шул тупас нәрсәне баскан «Аң» чыга, бик зур гөнаһ,
Бәс шуңа Әхмәтгәрәй мәгъюб була, мәхкүм була.

Барчабыз да аңгыра, аңсыз, зәвыксыз бәндәбез,
Ник болай бу чаклы бахыр булдык икән һәммәбез?

«Аң»чыга күренә сукыр бер тиен бакыр алтын булып,
Нинди алтыннар ята «кәрзинкә»дә мәхкүм булып!

Озак яшәтмәс алла «Аң»ны, шундый гөнаһ эшләгәч,
Шунда да «Аң»чы гөнаһны бер дә белми эшләмәс!

Кисас — үч кайтару.
Мәгъюб була — гаепле була.
Мәхкүм — хөкем ителгән.
Зәвыксыз — ләззәтләнү тойгысыз.

1916

АЛТЫ ЕЛ

(«Тормыш» газетасыннан)

Алты ел яздым янып, мөбһәм каләмнәрне юнып,
Алты ел кызды мичем чүп-чар саламнарны ягып.

Алты ел мин тетрәдем, аһ, алты ел бизгәк булып,
Алты ел мин шалтырап йөрдем, коры чүлмәк булып.

Вәсвәсә һәм мөбһәмат берлән тилердем алты ел,
Карьяләрдән карияләргә мин йөгердем алты ел.

Алты ел, аһ! Һәр елым — зиндан, дозах, һәр төн — хокыб,
Һәр елымда һәр көнем үтте җыен чүп-чар чокып.

Сөймимен мин, нинди күркәм булса да үз әшгарем,
Чөнки сөймәскә хакым бар, һәммәсе — үз чүп-чарым.

Сөймәгәчтен башкалар, нишлим? Сөяр идем дә бит,
Һәм танавымны сәмаләргә чөяр идем дә бит!..

Әле дә мин өзмим өмид — алда сәма, балкый сәма!
Алдагы нурлар итәрләр акрын-акрын энҗе лә!..

Әле дә мин бер яшь сабый күк: арты тинлек юк гакыл,
Әле дә мин төшләр күрәм, дип: «Юкка капчык тот та
тор!»

Мин әле булса нәримен тинтерәп, илһам көтеп,
Бер урамнан бер урамга «алла» эзләп, аһ итеп.

Мөбһәм — билгесез, тотрыксыз.
Вәсвәсә һәм мөбһәмат — коткы һәм юк-бар нәрсәләр.
Карья — авыл.
Зиндан — төрмә.
Дозах — җәһәннәм.
Хокыб — сиксән ел.
Әшгарь — шигырьләр.
Сәма — күк.

1916

АНЫҢ ӨЧЕН

Өй эче тын, кич ятам, акрын гына саз сыздырып,
«Алиһә»мне нур томалый, дулкынында йөздереп.

Чү, тавыш бар!.. Нәкъ аның таушы кебек бәллүр тавыш,
Шул вакыт кемдер гүя: «Җилде,— диде,— тор, тор, кавыш!»

Үз-үзем онытып, ташып, сикереп чыгып киттем, шашып,
Мандолины калды бугай, мескен, өендә ыңгырашып.

Ул тавыш күктәнме иңгән? Һич берәү юк, аңламыйм,
Тик шуны аңлыйм: аныңчөн булды корбан мандолин.

Алиһә — хатын-кыз җенесендәге алла.
Бәллүр тавыш — кристаллдай саф тавыш.
Аныңчөн — аның өчен.

1916

КАРАҢГЫЛЫКТА

Якты эзләп күккә бактым — якты нурлар инмәде,
Җиргә бактым — җир караңгы, күз чәчәкләр күрмәде.

Шунда миннән көлде йолдыз, көлде ай күктән карап,
Ник газаплыйлар мине? Ансыз да җан күптән кәбап.

Ургылып, кайнап чыга күкрәк төбемнән утлы гамь,
Күкрәгемә чәнчәләр миллион зәһәрле ук белән.

Як-ягың дөм-дөм караңгы, нишләреңне белмисең,
Һич ирексез, күзләрең шешкәнче үксеп егълыйсың.

Күктәге йолдыз тагы ныграк җемелди, күз кыса,
Күктә булгач та үзең, син ник мине мыскыллыйсың?!

Син дә, ай, бик эреләнеп, керфек тә какмый көлмәле!
Кил, минем урыныма төш, шунда таныйрсың дөньяны...

Кәбап — сусыз көенчә утта пешерелгән ит.

1916

БӘХЕТЕМ

Зәңгәр күк — таҗым, чуар җир — тәхтем,
Үзем — азат хан, ак кояш — бәхтем...
  Йолдызлар һәм ай — серче дусларым,
  Сандугач, тургай — җырчы кошларым.
Чыксам сахрага, гөлләр, үләннәр
Тәгъзыйм итәләр, бирәп сәламнәр.
  Җан-чәчәкләрем, гөл-канатларым,
  Оча янымда күбәләкләрем...
Латыйф җил — саба, диеп: «Мәрхаба!» —
Сөеп, иркәләп, йөземнән үбә...
  Менсәм тауга... Эх! Очыйммыни соң!..
  Бөтен офыкны кочыйммыни соң!..
Гөлләр елмайган, кырлар нурланган,
Бөтен җир-күге нурга чорналган...
  Шашам, ашкынам... Шатланам чиксез,
  Азат мин, азат! Бәхтем офыксыз!..

Тәгъзыйм итү — олылау, хөрмәтләү.
Латыйф — матур.
Саба җиле — таң җиле.
Мәрхаба! — хуш киләсез!

1916

ӘЛЛӘ АЛЛА, ӘЛЛӘ ИБЛИС

Күктә алла, җирдә иблис, мин — малай!
Берсе: «Дин!» — дип, берсе: «Мин!» — дип тарткалай.
Белмимен,
Әллә алла, әллә иблис алдалай?!

1916

КЕМ ӨЧЕН

Айга үрләп, нурда уйнап,
Күкрәгемне нурладым.
«Ит гафу, әй, ай,— дидем,—
Мин нурларыңны урладым».

«Һич зарар юк, ал,— диде ай,—
Ал да чәч нур халкыңа;
Мин дә бит төн хакына
Алдым кояшның нурларын».

1916

ЯЗ ТАСВИРЫ

(«Котормыш»тан)

Нурлы яз! Балкый кояш... Аһ! Белмисез — мин шатланам,
Шатлыгымнан тигәнәктәй ыргынам, канатланам.
Яз көне сөенечле... Әмма мин кояшны сагынам!..
Ыргыем дисәм кояшка, былчыракка абынам.
Сайрый чыпчыклар, урамнарда сыерлар мөңгери,
«Му, му, му» дип сыер белән бозаулар йөри...
Мин дә баткакка батып, чумып бозауларны куам,
«И илаһи, нинди рушан бу бозаулар»,— дип куям...
Җәгъмәреш кызлар белән һәм мин урамнарда йөрим,
Эссе язда калтырыйм, санки бураннарда йөрим...
Шат кояшның шат нурында ялтырый сүнгән «Уфа»!
Монда сыйфатсыз сафа, монда хафа, аһ, вассифа!..

Рушан — сылу, матур.
Җәгъмәреш — карт, эшлексез.
Сыйфатсыз сафа — мәгънәсез рәхәтлек.
Вассифа — буш күренеш мәгънәсендә.

1916

МУНЧА РОЭЯСЕ — РОЭЯ БОТКАСЫ

(«Котормыш»тан)

Аһ... сугыш — роэя... күрәм роэя — сугышлар тиз бетәр...
Роэя — бер ан... төн үтәр... гөлләр үсәр... роэя китәр...
Гөл үсәр һәммә кабергә, һәр кабер — җанлы кабер...
Һәр кабер өстендә роэяле чәчәкләр... балкый нур...
Балкый нур... дөнья кабер... роэя кабер... хәсрәт матур...
Канлы роэяләр китәр тиз... роэясез таҗлар атыр...
Ул сугыш — роэя генә, роэя — бер ан... роэя бетә...
Аһ... Үтә роэя!.. Бетә роэя... Килә роэя!.. Китә?!

Роэя — төш.
Ан — вакыт, заман

1916

ГӨЛ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Тармак-тармак булып сабаклары,
Үсеп утыра бер гөл янымда.
Терс, яшел куе яфраклары
Каплап алган һәрбер ягын да.

Яфраккайлар бары да, башын иеп,
Тәсбих әйтеп тора тын гына.
Көмеш пәри сыйпап киткән кебек,
Өсләрендә — якты нур гына.

Кайбер яшь тармаклар өскә буйлап,
Үрләп менеп бара түшәмгә,
Кайбер яшь яфраклар, ямансулап,
Тәрәзәдән карый тышларга.

Шул яфраккайларның арасыннан
Атып чыкты бер көн өч чәчәк,
Бер-берсеннән берсе исле чәчәк,
Карап туюлардан тыш чәчәк.

Чәчәккәйләр гөлнең сабагында
Очып китәр төсле торалар.
Кызыл нурлар балкый үзәгендә.
Бигрәк нурлы, кызыл шул алар.

Яфрак асларыннан назланышып,
Иркәләнеп кенә карыйлар,
Гыйшык мәләкләре очып төшеп,
Бәбәкләрен үбеп ялыйлар.

Назлы чәчәккәйләр, мескенчәкләр,
Соклансам да, сезне кызганам;
Бик аз көннән шиңеп бетәчәксез,
Шуның өчен үләм, сызланам.

Мәләк — фәрештә.

Ничөн ул яфраклар, башын иеп,
Ничөн сезгә карап торалар?
Сезне сөеп, сезгә яныл-көеп,
Сезнең өчен дога кылалар.

Ник, чәчәкләр, сезнең гомер кыска,
Әллә үзегез теләп суламсыз?
Әллә кызык юкмы бу тормышта?
Әллә яшәү үзе иләмсез?

Күрәм, ишетәм сезнең сызланганны,
Сизәм: сездән иртән аерылам.
Ходай сезне миннән кызганганны
Белгән өчен өзелеп кайгырам.

Чәчәккәйләр, сезгә бер үтенеч,
Мөмкин булса рөхсәт бирегез;
Әйтми калсам, миңа зур үкенеч:
Күкрәгемә очып куныгыз.

Күкрәгемә очып кунсагыз сез,
Иснәп торыр идем туйганча,
Вакыт житеп, иртән сулсагыз сез,
Учлап йөрер идем торганча.

Тәмле исегезгә исергәндә,
Мәдхияләр жырлап йөрермен.
Ахыр гомер мәңге өстегездә
Мәрсияләр көйләп торырмын.

1916

ҚАЗ БӘБКӘЛӘРЕ

Өй эчендә, ишек почмагында,
Бер каз утыра алтын ояда,
Ак чыбылдык белән корып куйган,—
Охшатамын назлы кияүгә.

Йомшак итеп, казның оясына
Салам дигән түшәк түшәлгән,
Ничек кенә әйтсәң, «каз» инде ул,
«Кияү» дисең фәкать мисалдан.

Эргәсеннән үтеп китәр хәл юк,
Пых-пых итеп үреләә чукырга;
Уйлыйсыңмы, факыр, «чукырмын» дип,—
Юкка өметләнеп утырма.

Әй тиле каз, синең акылың аз,
Курыкмыймын синнән бөртек тә!
Пыхылдама бикәр муен сузып,
Борын очыңны да селкетмә.

Тик кенә ят, сузма борыныңны,
Канат асларыңа кыстырып;
Йокла да ят шунда, бәбкә көтеп,
Мине чукыймын дип төш күреп.

Түшәкләрең алтын, юктыр зарың,
Балаларың көмеш күкәйдә;
Күкәйләрне тишеп чыгуларын
Тыныч кына утырып көт әйдә.

Көмеш йортны ташлап, берәм-берәм
Бәбкәләрең чыккач, «чип-чип» дип,
Сезне көтәр яшел ямьле чирәм,
Без куарбыз сезне: «кит-кит» дип.

Ояларың белән исәнләшеп,
Безнең өйне ташлап китәрсең;
Яшь бәбкәләр белән рәхәтләнеп
Яшь чирәмдә сәйран итәрсең.

Ачык ялан, ямьле тугайларда
Бик күңелле үтәр гомерләр;
Әйләнәндә нәни балаларың
Каңгылдашып бергә йөрерләр.

Балаларың үсеп үзең кебек,
Кайтып килер өйгә көзге төн;
Шул вакытта сезне мактап җырлар,
Каз өмәсе ясар кыз-кыркын.

Сәйран иту — күңел ачып йөрү.

1916

ЧИТЛЕКТӘГЕ САНДУГАЧ ЯНЫНДА

Йөрәгемдә янган сагышларны
Сизденме әллә, моңлы сандугач?
Мин җырламый, былбыл, кем җырласын,
Йөрәк ялкыннарым кабынгач.

Язлар килә, әнә тамчы тама,
Искә төшә үткән гомерем;
Үткән язгы чаклар исемә төшсә,
Ташый, тула моңлы күңелем.

Карасана, былбыл, читлегеннән:
Урал тавы тора күгәреп;
Шул тауларга карап, мин җырлыймын,
Уйларымны ерак җибәреп.

Ник туктадың, былбыл, сайравыңнан,
Әллә мине тыңлап торамсың?
Ник ышкыйсың матур томшыгыңны,
Әллә мине үчләп коләмсең?

Мин җырлыймын сагнып, ә син, гамьсез,
Читлегендә ярма ярасың!
Яз җитә бит, нигә карамыйсың
Читлегеңнән котылу чарасын?

Язлар җитә, әнә тамчы тама,
Җылы чаклар килә якынлап,
Синең кебек матур моңлы кошлар
Килә башлар инде акрынлап.

Яз җитә дип мин дә бер куанам,
Бер җырлыймын өзелеп, сагынып,
Торырсыңмы, былбыл, син зарыгып,
Читлегендә һаман ябылып!

Язлар җитә, әнә тамчы тама,
Искә төшә үткән гомерем;
Искә төшеп үткән гомерем,
Ташый, кайный минем күңелем.

1916

ТЫН ТӨН

(Авылда)

Тын гына, тып-тымызык бер төн иде,
Чишмәкәй чылтыр, чылтыр, чылтыр иде...
Ерактан гөлдер-гөлдер арба килә,
Ул да тынлыкны куертыр өчен генә;
Аръякта бер эт өрә, ул шул тынлыкны
Колагыма куып кертер өчен генә...

Мин ятамын шул тынлыкны уйлый-уйлый,
Ике күзем йолдыз саен ыргып йөри;
Кайчагында акрын гына бер җил исеп,
Агачларга миннән яшерен нидер сөйли...

Йәсигъ узган, төн уртасы якынлашкан,
Тирә-якны караңгылык тәмам баскан;
Якты белән томаланган йөзләренең
Күзкәйләрен караңгы төн тәмам ачкан.

Почмакларда күп караңгы посып тора,
Төн, чымырдап, чем-чем... итеп тынсып тора,
Йолдызлар күз кысыша, кайсы уйный,
Кайсы бере җыламсырап, моңсу тора.

Йәсигъ — төнге намаз вакыты.

1916

КӨФУ ТҮГЕЛ

Көннәрем ямьсез... мохитем булмады җанга көфу,
Бәс шунынчөн дөньяга миннән мәкяфәт: кых-тфү!

1916

ХӘЛЕМЕЗДӘН БЕР КҮРЕНЕШ

Кызлар — иркә,
Ирләр — күркә,
Хатыннар — курчак!
Аңкый шәхсият,
Ялтырый тәрилкә,
Матбугат — уенчак!..

Күзләр — җыландай,
Телләр юмалай;
Малайлар үрмәләй,
Танаулар — «Һималай»!..

Көфу — тиңдәш.
Шунынчөн — шуның өчен.
Мәкяфәт — бүләк.
Шәхсият — гел үз интересыңны гына күзәтү.

1916

ЯШЬ ШАГЫЙРЬГӘ

Әлмисактан син шагыйрьсең, дип ходайның әмре бар,
Әмеренә иттең хилаф — мәлгунь мохитнең җәбере бар.

Күпме мәлгуньнәр борын төртсә дә, күңлең какшамас,
Чөнки күңелнең тирәннәргә узынган тамыры бар.

Әллә кемнәр күкрәгең белән шаярмакчы була,
Чү, аны болгатмасыннар, анда илһам нәһере бар.

Һич курыкма, мең шөкер, тәңреңне тапкансың, шагыйрь,
Чөнки тәңреләр ясап, ялганлый алмасын самирилар.

Һич тә офтанма, күңелсез булды дип гомерем башы,
Алда гомереңнең мөзәййән, аллы-гөлле ахыры бар.

Әллә ниләр сөйләсеннәр, тыңлама — урының сәма,
Дөнья булгач, нәрсә булмый: алланың да кафере бар.

Әлмисактан — дөнья яралганнан бирле.
Хилаф — кире, ярамаган эш.
Мәлгунь — куылган, сөрелгән, һәртөрле яхшылыктан мәхрүм ителгән.
Илһам нәһере — илһам елгасы.
Мөзәййән — матур, зиннәтле.
Сәма — күк.

1916

ЯШӘСЕН ҚЫЙММӘТЧЕЛЕК!

«Әй ару булды, ару булды, мәгыйшәт айкалып,
Яшәсен кыйммәтчелек!» — дип сикерә, ыргый бай халык.

Мин дә җир ертып: «Яшә!» — дип, сөенә-сөенә кычкырам,
Юкса бик кәнтәйләнеп киткән иде маэмай халык!..

Бер заманны ярлылар да чәй эчәйдә май кабып,
Инде бер шакмак шикәр юк, чәй алалар пай салып.

Бер заманны без буа торган идек иттән буа!
Инде булмый бер кадаклап итне дә уңай табып.

Бер заманны күктә йолдызда фикер йөрткән хауас
Инде тоз дип, чәй-шикәр дип, аһ итәләр чайкалып.

Бер заман әгъля читек кигән аякка инде бак!
Нинди мескенкәйләнеп киткән, чабата бәйләнеп!..

Бер заман саф суда иркенләп тыныч йөзгән балык
Инде хәлсез, әлсерәп уз төште чалкай әйләнеп;

Нәкъ шуның күк бер заманны дөньясын типкән халык
Инде алҗып тик йөридер, сызгырып, ай-хай салып!..

Кемне күрмә: «Йа ходай, сакла үзең!» — дип зар елый.—
Бар иде торган заманнар җиргә күктән [май] тамып!

Бар иде арзан заман, сәйран заман, хәйран заман...
Үттеләр шул, үттеләр шул... Булмый инде кайтарып!..

Булмаса булмас... Тәвәккәл... Яшәсен кыйммәтчелек!
Актарылсын, куптарылсын, дөнья бетсен айкалып!

Әһле зиндыйк шаккатып торсын, бозылсын интизам...
Әй, кояш! Син төнгә кал да, әйдә көндез ай калык!!!

Мәгыйшәт — тормыш.
Хауас — сайланмыш халык, өстен кешеләр.
Әһле зиндыйк — алласызлар, имансызлар төркеме.
Интизам — тәртип.

1916

* * *

Менә әле генә Каф тавыннан
Җен дөньясын иттем тамаша!..
Җен дөньясы матур, ямьле икән,
Комсыз дөнья түгел ләбаса.

Мин дә шулай нигә җен булмадым?..
Ник тумадым Каф-тау артында?
Нигә җирдә тудым, адәм булдым?..
Ник тормадым Каф-тау артында?!

Җен баласы булсам, Каф тавында
Туган булсам уттан-ялкыннан,
Адәм углы кебек, йөрмәс идем
Эчтән-тыштан туңып салкыннан.

Мәхшәр көне җитми үлмәс идем,
Чермәс идем туфрак астында,
Адәм углы кебек, йөрмәс идем
Кардәшемне бетерү кастында.

Ут маддәсе — иблис маддәсе, дип,
Кемнәр утның үзен яманлар?
Пәйгамбәрләр нәселе булган белән
Иблистән дә узган адәмнәр.

Каст — нният.

1916

МӘГЪРИФӘТ САТУЧЫГА

Ташла, зинһар, йөрмә инде! Җитте, йөрдең былчырап!
Бер куык эчрә салып куйган борчак күк шылтырап!..

Төрле җирдә «мәгърифәт» дип сөйләнеп йөргән булып,
Сизмисеңме? Ялганыңнан китте җир-күкләр тулып.

Син үзеңчә: «Ялганымны һич берәү белмәс»,— дисең,
«Нинди хәйләләр корып йөргәннәрем сизмәс»,— дисең!

«Мин!» — диеп, күкрәк сугып, бик күп чүбекләр чәйнәдең!
Әллә нинди керле җепләрдән төенчек бәйләдең!

Ап-ачык көндез көне йолдыз санадың «Мин» белән,
Кайда барсаң да сикердең: «Мин беләм! Мин, мин беләм!»

* * *

Тәкрар әйтәм: йөрмә шырлап юкка, тиз кадрең китәр,
Бер дә сизмәссең, гали зат, буш куык шалдырт итәр.

Ул вакытта тәүбә итсәң дә кабул кылмас ходай,
Мәслихәт шул: ят та йокла! Барысыннан шул уңай!

Тәкрар әйтәм — кабатлап-кабатлап әйтәм.
Гали зат — бөек зат, бөек кеше.

1916

КЫЗ

(Фәтүә)

«Кыз» дигәч тә күңелгә кызган тимер баскан кебек,
Яшь йөрәкне кайнатып, ут ташкыны ташкан кебек.

«Кыз...» дигәч тә селкенә күкрәк, колаклар шәмрәя...
Күзләр урыныннан куба, тоздай була, шашкан кебек.

«Кыз» диденме, кан кызарга башлый, бәгърең сызлана,
Яшь йөрәктә әллә нинди тәмле уйлар кузгала.

«Кыз» диденме — яңрый ямьле, мәхәббәтле тавыш,
Дөньясы корбан сиңа, әй, җанлы идеал — кыз бала.

* * *

Шул мөҗәссәм ямьле җаннарны татарлар «кыз» диләр,
Кыз күренсә, ихтыярсыз эчләреннән сызлыйлар.

Картлары кычкырсалар да: «Бакма, нәмм — харам, харам!»
Яшьләрне шәрран-яра кызмакка фәтүә эзлиләр.

Фәтүәсен таптым, егетләр, йөрмәгез истән язып,
Аңлагыз ки: кызларга кызмыйча йөрү — шиксез язык.

Чөнки «Кыз» — мотлак әмердер, мәсдары «кызмак» килә,
Бәс, димәк, эш пеште: кызларга кызыгу, шиксез, вәҗип!..

Мөҗәссәм — гәүдәләнгән, сынланган.
Нәмм — сүз йөртү, әләк.
Шәрран-яра — ачыктан-ачык.
Фәтүә — рөхсәт, юл кую.
Мотлак — мәҗбүри.
Мәсдар — тамыр.
Вәҗип — бик кирәк.

1916

ҚЫЗЫК БЕТТЕ

Тарау чәчләр тузып бетте,
Матур көннәр узып китте;
Матур көннәр, матур сүзләр
Йөрәккә ямь сызып китте.

Матур йөздә матур күзләр,
Матур уйлар тезеп үтте;
Бары китте, бары бетте,
Хәзер инде кызык китте.

1916

* * *

Бәләм, Мәхмүт, ялчы булу бик кыен эш.
Кыен эшләр җиңеләя, булсаң тырыш.
Төкер син андый узгын кыенлыкка,
Эшеңә яхшы өйрәнү — синең бурыч!

1916

ГАЕД УЗГАЧ

Нур балкытып, җырлап килгән изге гаед —
Өч көн кунак... дүртенче көн күздән гаеб!
Кайда гаед?.. Менә инде йөр сөмәеп!..

Өч көн гаед — өч минут юк.. Гомер — очкын!..
Өч көн — хәят, дүртенче көн дөнья үлгән...

Дүртенче көн — иске хәммам, иске комган...
Тизрәк, рәббым, бетсен иде гаед корбан!

Бәйрәмсез көн — караңгы төн, күңел төшкән!..
Җитәр безгә, ямьсез-гади көннәр бетсен!

Гади көн дә бәйрәм төсле балкып үтсен;
Фәрештәләр өстемезгә бәхет сипсен!..

Хәят — тормыш.
Хәммам — мунча.

1916

ГАЕД КОРБАН

Сөенегез, дускайларым! Бәйрәм бүген, корбан бүген;
Һәр мөселман кальбенә бәйрәм кошы кунган бүген.
Сайрый ул кош: «Алла әкбәр, алла әкбәр!» — дип куя,
«Сөй мөселман, бәйрәмеңне, алла яклар»,— дип куя.

— Сөй, сөен — җырлап җибәр, ыргыт бөтен зар-моңнарың;
Алла саклар, саклап уздырсаң бу бәйрәм көннәрен.
Алла мактар, мактасаң бәйрәмне, бик ямьле, дисәң,
Алла әкбәр, алла әкбәр, лиләхмәд... дисәң.

Кил, туганнар, бер туган күк берләшеп сәйран итик,
Кайгы-хәсрәтләр таралсын, гөрләшеп бәйрәм итик...
Кил, мөселман, бир кулыңны, бир, кысыйм шат җан белән,
Ач иманлы йөзкәең, котлап үбим, бәйрәм белән!..

Сәйран — күңел ачу.

1916

САҖИДӘГӘ

Син әле яшь, син яңа яфрак чыгарган бер бөрлегән,
Син яңа зәңгәр чәчәкләргә бөрелгән бер үлән.

Син газиз анаң канатыннан яңа чыккан бала,
Изге анаңнан әдәп-әркан ала чыккан бала.

Бел шуны: яшьлек үтәр, яшьнәп үсәрсең бер заман.
Кып-кызыл пешкән җимеш төсле пешәрсең бер заман.

Вакты җиткәч, бар чәчәкләр дә аталар бөреләнеп,
Син дә балкырсың шулай, аткан чәчәктәй нурланып.

Саҗидә ускәч, чәчәк булгач, ходаем сакласын,
Кунмасын туфрак чәчәккә, җил-давыллар какмасын.

Як-ягын нурландырып, күкрәп яшәсен Саҗидә,
Булмасыннар бервакытта Саҗидәдән рәнҗүдә.

Адәп-әркән — әдәп игезләре.

1916

ТЕШСЕЗ КЫЗ

Барып мин, бер кәп бакчага керсәм,
Борып мыскыл, арлы-бирле йөрсәм,
Күзем төшмәсме шунда бер туташка,
Бите ап-ак, сызылган кара кашка?

Белгем килде: бу кызмы, хатынмы?
Дидем мин: «Исәнме, саумы, акыллым!»
Борылып карады, көлеп күземә,
Тик җавап бирмәде әйткән сүземә.

Тагы әйттем: «Туташ, ник дәшмисегез?
Хода биргән авызны ник ачмыйсыгыз?»
Тагы әйләнеп карады туташым,
Үзе әндәшми — тәмам каңгырды башым.

Уйладым мин аны телсез икән, дип,
Гаҗиз булдым, тагы нишлим икән, дип.
Ишарә иткән идем утырырга,—
Тотынды бит туташым котырырга:

«Нигә шин мине мышкыл итәшең,
Алай булша, мипем яннан китәшең!..»
Ачуланып авызын ачса җаным —
Ике алгы теше юк икән аның!

Чәчелә төкерегә тешсез авызның,
Сорасым килмәде исемен явызның;
«Ачуланма, дидем, һәм көлмәдем мин,
Синең тешсезлегеңне белмәдем мин...»

Йомып йөрү белән шулай авызыңы,
Теш чыгар дип уйлый, ахры, явызыңа.
Кащ сызырткан, калын яккан пудрасын,
Тик оныткан алгы тешләр куйдырасын.

1916

«ӘСМА» КИТАБЫНДАГЫ ШИГЫРЬЛӘРГӘ ТӘХМИС

И кая ул көн, ки бездә шәп торулар бар иде,
Ындыр артында, яланда әйттерүләр бар иде.
Әйттерә торгач, кыйнаулар, теш төшүләр бар иде,
Өйгә кайткач, аркаларны ышкышулар бар иде...
Әмма дошманнарда гамьнәр, эч пошулар бар иде.

Бер заман чыгар идек без кырга дус-ишләр илә,
Дистәләп кызыллы башлар һәм дә дюшесләр илә.
Уйнар идек анда карта уннар-унбишләр илә,
Җырлый-җырлый кайтыр идек ду килеп кичләр илә,
Анда уеннар, көлүләр, сикерүләр бар иде.

Һай, гомерләр... үтте-китте... Кая китте ул заман!
Һай хәмерләр акты-бетте, кипте мичкәләр тәмам.
Кайда калды гыйше-гашрәт, солтанәт сөргән заман?
Эльәман, рәббым әман, шушылай торырбызмы һаман?..
Кая ул шәп һае-һулар! Гөфтегүләр бар иде!

Бер заман бонча рәхимсез түгел иде кызлары,
Кашлары сикереп тора, котырып тора иде күзләре,
Алланып, сандалланып, күперен тора иде йөзләре,
Боргаланып, назланып сыгылып йөрәйде үзләре,
Анда туташларда ымнар, күз кысулар бар иде.

Күп заманнар үтте, әмма күрмәдек кызлар йөзен,
Күрмәдек ул сахирәнә, нурлы йолдызлар йөзен,
Эремәдек, эретмәдек күкрәктә диңгезләр бозын,
Каргады тәңре: «Тыялмыйм, дип, бу комсызлар күзен».
Янымызда әүвәле кандай сылулар бар иде.

Шигърен ишеткәч Закирнең, диде өлкәннәр дә: «Һай!»
«Дөньялар оҗмах иде ул чакта»,— диде Миңлебай.
«Инде бит ахыр заман»,— дип егълады «аксак Җәләй»,
«Уф!»диеп сулап җибәрде һәр әби һәм һәр бабай:
«Яшь вакытта бездә дә анда йөрүләр бар иде».

Дюшес — грушаның бер төре.
Гыйше-гашрәт — ашап-эчеп гомер уздыру.
Эльәман — иминлек бир, коткар.
Гөфтегү — гәп сугу.
Кандай — нинди.

1916

ШАТЛЫК КӨТӘМ

Очынып-очынып, өзелеп-өзелеп,
Ашкынып шатлык көтәм...
Инде, әй, хәсрәт ләгыйньнәр,
Сезгә куркаклык көтәм!..

Инде бик күптән тамыр
җәйгән йөрәкнең аһлары,
«Аһ»ларымның кып-кызыл
Уттан яралган яфрагы,—

Һәммәсе корсын... Җитәр,
Күкрәккә утлар таммасын!
Тамган ут сүнсен, җитәр,
Инде җәһәннәм янмасын!..

1916

УЛ

Ул матурны мактамак булдым әле такмак белән,
Ямьле әйберләргә охшатмак, вәсыйф катмак белән.

Тәмле тел ул, сыгылып алган бал дип әйтәм тәүсыйфын,
Назлы бил ул... борылып үскән тал дип әйтәм кайсысын...

Йөзләре ал, таңга мәйял... битләре — бит солтаны...
Аузы зәмзәм, ирне кәүсәр, күкрәге — сөт вулканы.

Баш, муен һәм аркасын каплап тора чәч иркәләп;
Кай фәрештә эшләгән ул чәчне бәйләп, көлтәләп?

Ай кебек кашлар сикерсә, сер янып, сызылып китә...
Көлсә теш тезелеп китә... аһ, яшь йөрәк өзелеп китә!

Күзләре әсрар кара нур, аяклары ап-ак, матур,
Ни кирәк — гомрең буе бак та шуңа, шак кат та тор!

Вәсыйф катмак — сыйфатламак.
Тәүсыйф — сыйфатлау.
Мәйял — күңел куйган, мавыккан.
Кәүсәр — оҗмах елгасы.
Әсрар — серле.

1916

КАНДАЛА

(Баллада)

> Кайгы бетсен, көлдерә бир, көлке баш
> Әйдә көлдер дә халыкның күңлен ач.
> Син кызык сүзләр сөйлә,— көлсен халык,
> Шул кызыктан гайебене күрсен халык.

Нәкъ менә башымда арбалар йөри,
Шаулашып дулкынлы дәрьялар йөри;
Әлләниләр ызгыша, чыр-чу килә,
Нәкъ менә ызгышчы маржалар йөри.

Йончыла күкрәк җиңелчә моң белән,
Эссесе беткән җылы мунча сыман;
Тап колагымда кызык сүзләр йөри,
Аңламыйм үзем шуны, русча сыман...

Гәүдә тик чалкан, ятак буйлап ята,
Тәмле итеп йоклау уен уйлап ята;
Йоклыйсы килми әле, дип, күзләрем
Керфек астыннан гына уйнап ята.

Авырая тән: һәр минутта авырая,
Нык баса албастылы җепшек һава;
Шул һавадан гәүдәгә шаулап ява
Тындыра һәм йоклата торган дәва...

Йоклагандай булды тән изрәп, тынып,
Калды тик күзләр йомылмый, актырып.
Шул чагында: «Йоклады бу гәүдә,— дип,
Йә ходай, китәм кәсепкә — ауга,— дип,

Бер ярыктан чыкты да бер кандала,—
Юл ерак икән, каһәр!» — дип каргана.
Шунда уйлый: «Булса булсын юл ерак,
Нишлием соң, калса калсын ил елап;

Бер барып җитсәм бер айлык кан алам»,—
Дип, ачыккан кандалам салды кадәм!
И киләдер ашыгып-ашыгып, сөртенеп,
«Кан эчәм бит, кан эчәм!» — дип йотлыгып.

Ашыга торгач, хәл бетә, туктап тора,
Хәл җыеп, рәхәт аяк бөкләп тора.
Ул күрә: күзләр минем нык ялтырый,
«Ах, харап эш, күрсә! — дип, дер калтырый;

Күрсә, ул кулларны дәрхәл уйгатыр,
Аннары кул күздән утлар уйнатыр!..»
Шул секундта кандаланы күрде күз,
Бик тирән уй дәрьясына чумды күз...

Уйлана күз: «Ул да мәхлук, ул да җан,
Аллага ул да китергәндер иман;
Шул сәбәпле мин аны бик кызганам,
Йокласын, кулны уятмам, кузгамам...

Чөнки кул — кансыз, усал, ерткыч нәсел,
Әүвәл-әүвәлдән җиһан корткыч нәсел...»
Күз шулай шәфкатьле уйлар уйлады,
Кандалага һәм болай дип сөйләде:

«И зәгыйфь җан! Аз гына тор, тукта син!
Мин дә йоклыйм, тән дә чынлап йокласын.
Шуннан ары акрын-акрын кил дә син,
Үрмәләп чәчтән, башымнан мен дә син,

Шым гына атлап килеп, син кашка бас,
Каштан ыргып төш, минем керфеккә бас!
Бас та ныгытып керфегемне коч, йәме!
Күз төбемнән үз канымны эч, йәме?

Нагаһан гәүдә уянса шул заман,
Керфегем белән чөярмен — вәссәләм!..»
Ошбуларны аңлагандай, кандала
Урнысыннан сөенә-сөенә кузгала.

Кадәм салу — гайрәтләнеп атлау.
Дәрхәл — шунда ук.
Нагаһан — кинәт, көтмәстән.

Кузгала, гәүдә табантын әз сала,
«Йокла!» — дип, күзләргә шунда сүз сала.
Күзләрем йоклап китә, ләббәйкә дип,
Инде, дустым, эшне яхшы байка дип.

Күз йомылгач, йөгерә-йөгерә кандала
Килде җитте ярты үлгән гәүдәгә.
Гәүдә буйлап, башны юллап килде ул,
Баш янында аптырашта торды ул:

«Ай-яй-яй, бу баш дигән тау бик биек,—
Зарланып: — тәңрем, кичек меним?! — диеп.
Соңра мескен мең газаптан тырмашып,
Үрмәләргә башлады чәчтән басып.

Башның уртасына җиткәч бервакыт,
Төште еглып, мескенем, тәкмәч атып...
Хәл җыя да бераз үткәч: «Алла,— дип,
Инде, тәңрем, башка михнәт салма»,— дип,

Чәчкә ыргып, баш башына үрмәли,
Алла, дигәч, мисле дөлдел юргалый...
Чәч арасында Хозыр-Ильясмы бар?
Әллә бармы җен-пәри, албастылар?

Ник дисәң, баш өстенә ул мендә тиз,
Шулкадәр тиз — тик ачып йомганчы күз...
Башка менгәч, бакты күзне: күз йомык,
Күренәдер суы корган күл кебек.

Күл читендә яшь камышларның очы
Төсле күз керфекләренең күренеше.

Кандала чәчтән вә маңлайдан үтә,
«Каш» исемле яшь һилал-айга җитә.
Кашка баскач, торды ул мәгърурланып,
Мин хәзер кайда! — дигәндәй зурланып.

Шунда да куркып куя ул сискәнеп,
Төрмасын, дип, вәхши куллар искәреп.

Ләббәйкә — риза.
Мисле — гүя.
Дөлдел — мифик ат.
Һилал — ай.

Ул шулай кашка басып, тетрәп тора,
Ыргый, дип, күз керфеге сыкрап тора.

Тибрәнә керфек, аңарга ым бирә,
Ошбулай дип өн бирә әкрен генә:

«Тиз сикер, тиз, тиз сикер, тиз! Дивана!..
Торма, мәҗнүн, анда күренеп дөньяга!..»

Тиз генә керфеккә ул сикереп төшә,
Каш ябыннан эзләрен сыпырып төшә.

Ыргый, нәкъ керфек очына тап килә,
Ул аякларны, каһәр, шәп ләктерә.

Ашыгып-ашыгып кан эчәр якны карый,
Күз төбенә тиз генә борнын кадый.

«Әллә лә!» — дип, сискәнеп, уйганды күз,
Бирми сәр, уйганса да һич дәшми сүз.

Юк гаеп, ач бит бичара, нишләсен,
Ашыга торгач, әйтмәгән бисмилласын!

Әйтмәгәч бисмилланы, эш уңмый шул,
Әйләнергә башлый гәүдә уң вә сул...

Һәм тамакның төпләре гыр-гыр килә,
Болгана куллар, авыз мыр-мыр килә.

Сизде мескен гәүдәнең уйганганын,
Күрде кулның төрлечә болганганын.

Күз төбеннән тиз генә борнын ала,
Тын гына керфектә ул төрелеп кала.

Аллага сыгынып, җанын учка тотып,
Калтырыйдыр «нәмә әгъзамнар» укып...

Кандаланы белде кул керфектә дип,
«Ни кирәген мин бирим ул эткә!» — дип,

Бармагын күзгә табантын сирмәде,
Күз аңарга кандаланы бирмәде:

Мәҗнүн — тиле, дивана мәгънәсендә.
Сирмәү — кинәт кенә тотып алырга омтылыш ясау.

Селтәде керфек белән җилпеп кенә,
Калды куллар бармагын селкеп кенә.

Ул шулай керфек белән чәелеп китә,
«Баш сәламәт калды!» — дип сөенеп китә.

Кандаланы бирмәгәч, кул тырнагы
Ачуы белән күз төбен бер тырнады.

Кандала атылып һаман күккә менә,
«Кил!» — ди түшәм, әмма ул юкка менә.

Чөнки очмакка анарда юк сәләт,
Йөк авыр, күктә очарга юк канат.

Кандала очынып менеп китте шулай,
Бер секунд микъдар заман үтте бугай,

«Алла» дигән бер тавыш бар бик яман,
Дерт итеп киттем, котым да калмаган!

Нәрсә булды, дип торам, рәббым, хода,
Ни тавыш бар? Ник идәндә зилзилә?

Зур фаҗига булганын кальбем сизә,
Тиз генә күзләр идән өстен сөзә.

Күз күрә: зур фаҗига бар — вакыйган,
Зур каза урыны булып киткән идән:

Кандала егылып төшеп чалкан ята,
Эч ярылган, мисле вулкан, кан ата.

Ай бәхетсез, корсагын ярган да ул,
«Коткарын!» — дип чакыра ярдәмгә ул.

Кып-кызыл кан берлә болганган идән,
Тиңләшерлек булган ул Балкан белән.

Шул вакыт бу манзараны кул күреп,
Шатлыгыннан и куанды соң көлеп!

Зилзилә — җир тетрәү.
Калеб — күңел.
Вакыйган — чыннан да.
Манзара — күренеш.

«Бик ару булган, ходай суккан,— диде,—
Ошбу хәл сиңа кирәк күптән,— диде.—

Чәнчел инде, канга тончык, үл, кадал!..
Кыйммәтең юк бит синең бер нуль кадәр!..

Туймадың син кан эчеп үз гомереңә,
Очрадың түгелме тәңре каһренә?..

Күпме кан эчтең, беләсеңме аны?
Тотты бит үзеңне, күр, инсан каны.

Сау чагыңдагы бөтен иптәшләрең,
Дусларың, кардәш-ыруг, юлдашларың —

Инде барсы да килер дә йөгерешеп,
Үз каның эчеп китәрләр сөенешеп!»

Сөйләде гайрәтләнеп кул төрле сүз,
Егълады шәфкатьле булган моңлы күз.

Кандала ыңгырашмый, тып-тын ята,
Тик: «Үләм!» — дип, кулларын тырпылдата.

Инсан — кеше.

1916

ГАЗАЗИЛ

Инде аны мәңгегә иблис диләр,
Газазил дип эндәшергә кушмыйлар.
Билгеле, оҗмахта торды ул әлек,
Бар мәләкләргә имам булган булып.
Торды гыйльме аркасында ай булып,
Җәбраилләр, газраилләрдәй булып...
Урыны иде — фирдәвеснең түр башы,
Сөндес, истибрактан иде хөлләсе.
Фирдәвеснең энҗе, мәрҗән, алмасы
Берлә зиннәтләнмеш иде чалмасы.
Чын ефәктән иде тәсбих баулары,
Төймәсенең барсы кәүсәр гәүһәре...
Ак касәдән пакь шәрабларны кирәк,
Ак табактан шәп кәбапларны кирәк —
Ни кирәк булса, аңар шул бар иде;
Анда вилданнар аңа тәйяр иде;
Нишлисең, кальбендә ак эз булмагач,
«Кәкре бармак башта ук төз булмагач»,
Мәгълүмат тәүфыйк белән берләшмәгәч,
Вөҗданы гакылы белән серләшмәгәч,
Һич боларның җитмәде ул кадеренә,
Җитмәсә, арт бирде тәңре әмеренә.
Шул рәвеш нигъмәткә шөкран итмәгәч,
Тәңрегә, мәгърурланып, баш бөкмәгәч,
Диде алла: «Ник миңа буйсынмыйсың?
Бу кадәр дәүләтне ник сансынмыйсың?»
Иблис әйтте: «Дәүләтеңне сансынам,

Мәләкләргә имам — фәрештәләргә баш.
Җәбраил — илче фәрештә.
Газраил — җан алучы фәрештә.
Сөндес, истибрак — ефәк, асыл зат.
Фирдәвес — оҗмах, җәннәт.
Кәбап — кыздырылган ит.
Вилдан — яшь егет.
Тәйяр — хәзер тору.
Калеб — күңел.

Әмма шунсы: буйсынырга кимсенәм!
Чөнки мин зур, чөнки мин нур, мин галим,
Үз-үземә кечкенә бер алла мин!»
Шунда тәңре газбе илә: «И эт! — диде,—
Кит, сиңа ләгънәт!.. Күгемнән кит! — диде,—
Бар, хәзер шайтанга баш бул, пис! — диде.—
Ал бөтен нәрсәңне, кит, иблис!» — диде.
Ул шулай меңдәр-фәләннәр аркалап,
Алды оҗмахтан шәраблар тартмалап
Һәм дә алды скрипка (думбра),
И аңа шунда мәләкләр кундыра:
«Кит, тәкәббер, кит, ләгыйнь, имгәк! — диләр;
— Моннан ары юк сиңа ниг ъмәт! — диләр;
— Инде синнән без тәмам биздек,— диләр;
— Күңеленә «Иблис!» диеп сыздык»,— диләр.
Бәс чапан, таҗ, чалмасын салдырдылар,
Мескенемне шәп-шәрә калдырдылар!
Шунда иблис, тәңресенә тезләнеп,
Төсләрен бозып, диде ямьсезләнеп:
«Дөнья беткәнче, ходай, гомеремне бир!
Барыбер мәңге газап, мәңге җәбер!..
Дөнья беткәнче җиһанны айкарым,
Бар иман, вөҗданнарыны чайкарым!..
Инҗилең, Коръәннәреңне таптарым...
Аздырырмын дөньяны, бел, җәббарым!..»
«Бар! — диде тәңре,— камил рөхсәт,— диде,—
Кат миңа ширкәт, көферлек сат! — диде,—
Аздыручыларны, азганнарны да,
Базга төшкән, базны казыганнарны да —
Барчаңызны да йотар, ди, һавия!..»
«Ха-ха-ха-ха... үзем,— ди иблис,— һавия».

Җиргә иблисне сөрү булды кызык:
Хур вә гыйльманнар йөриләр пыр-тузып...
Килде шунда бар фәрештә күктәге,
Килде һәм барлык зобани уттагы.
Дәштеләр шунда җәһәннәм карчыгын.

Газыб — ачу.
Пис — шакшы, әшәке.
Ләгыйнь — ләгънәт суккан.
Җәббар — кодрәт иясе.
Кат миңа ширкәт, көферлек сат — миннән башка икенче тәңре ясап чыгарып, көферлек таратып йөр.
Һавия — тамуг; җәһәннәм.

Асты ул иблискә хәйлә капчыгын;
Муйнына чын утлы, ләгънәттән камыт
Салды карчык, куйды ут койрык тагып;
Күкрәгенә такты ул әнвәгъ елан,
Майлады авызын зәһәрле ягъ белән;
Кул-аягын чатлы-ботлы сузгалап,
Куйды һәрбер тырнагына җиз кадап;
Маңлаена басты карчык ут мөһер,
Кап-кара булды йөзе — мисле күмер!..
Һәм дә шунда кәкре мөгез кактылар,
Кот очар, күрсәң: очында чаткы бар!
Күзләре кайный җәһәннәмнән яман!..
Күрсәтмәсен күзгә, әман, раббым, әман!
Бар иде шунда зобани остасы,
Ул җәһәннәмдә гаҗип шәйләр ясый;
Бирделәр хәбәр: «Әй, оста, кил бире,
Безгә эшлә бик озын ут чылбыры;
Бик озын — җиргә җитәрлек булсын ул,
Бер колачтай җиргә җитми торсын ул!»
Эшләде чылбырны үтми бер минут,
Яңгырый күк, шылтырый чылбыр, чәчри ут.
Бер мәләк күкне тишеп алды уеп,
Түм-түгәрәк дүңгәләк төсле кыйлып;
Төрткәләп иблисне тишеккә таба,
Килделәр алып, и иблис ут яна...
Котыра, дулый, зык куба гыйфрит кебек!
Үкерә, авызыннан чәчеп кайнар күбек!
Куркалар бәләкәй мәләкләр шул вакыт,
Читтәрәк хурлар йөриләр шаккатып;
Шул чагында бик хәтәр һәм бик юан
Гөрзи тоткан бер зобани пәһлуан
Чак кына манган иде бер гөрзисен,
Бер песидәй тынды калды иблисен!..
Соңра аны барча әшьясы белән,
Аркасында скрипкасы белән
Әлеге чылбырның башына тактылар,
Тактылар да шул тишектән аттылар.
Күк йөзендә мең вә миллионлап мәләк
Күк йөзен күз зурлыгында тишкәләп

Әнвәгъ — төрле-төрле.
Ягъ — май.
Мөһер — печать.
Мисле — төсле, сымак.
Шәй — әйбер.
Әшья — әйберләр.

Алдылар да, шул тишектән күз салып,
Тордылар иблиснең төшкәнен багып.
Әй төшә иблис; төшә зыр-зыр килеп,
Кош вә корт куркып оча пыр-пыр килеп...
Койрыгы ялт-йолт итә, яшен кебек,
Куллары лап-лоп итә, лачын кебек...
Бу кызыктан күктә кеткелдәү китә,
Күз йөзендә саф тавышлар шау итә...
Мәлгунь иблис тик төшә торсын әле,
Куркышып кош-корт оча торсын әле.
Сүз рәтендә бер сүз әйтәм, туктагыз,
Читкә чыкты бу җүләр, дип сукмагез!
Кечкенә чакларда мин уйлый идем:
«Бу кояш, йолдыз ни нәрсә?»— ди идем.
Мин ишетсәм дә, алар әҗрам, диеп,
Һич ышанмыйдыр идем, ялган диеп;
Уйлап-уйлап, баш ватып та тапмагач,
Еглый идем кычкырып, баш чатнагач.
Инде белдем: чынлап ук әҗрам түгел,
Җир шикелле йөрмәле галәм түгел,
Әүвәл әйтимме кояшны?
— Әйт ничек?
Улмы? Ул — илбис төшергән зур тишек.
Шул тишектән җиргә ыргыткач аны,
Фирдәвестән ак, матур кандил шары
Китереп тишеккә куйганнар, имеш!
Муллалар, белми, шуны әҗрам димеш!..
Инде йолдызларны да әйтим чишеп:
Ул — ничә миллион мәләк тишкән тишек!
Тиштеләр, иблисне карап тормак өчен,
Бу шулай шиксез, менә тырнак очым!..
Инде анлар шул заманнардан бирле,
(Ни чара, чыккач ходайның тәкъдире)
Көн саен кич шул тишектән күз салып,
Тик карыйлар таңга чаклы сызланып!
Шул мәләкләрнең күзен «йолдыз» дибез,
Белмәенчә сез шуны «әҗрам» дисез!..
Янсын әйдә нурлы кандил көн саен,
Әйдә баксыннар мәләкләр төн саен.

Без килик максудка! Максуд билгеле:
Төште иблис ай түгел, күп ел буе...

Әҗрам — җисем.
Кандил — асылма лампа.
Максуд — максат.

Шул рәвешчә төште дә төште һаман,
Бер вакыт җиргә якынлашкан заман,—
Белмимен, никтер, кыен бик уйлавы;
Булдымы әллә мәләкләр уйнавы —
Селкенергә башлады ут чылбыры!
Әй ләгыйнь тырпылдый шунда, коргыры!..
Нишләрен белми, мәтәкли, җилпенә,
Кул-аяклар кылдый-пылдый селкенә!
Шәп атылгандай циркларда таган,
Атыла мәшрикъ һәм мәгърипкә табан!
Елтырый күк, елтырый ут чылбыры.
Җирне-күкне тултыра чылбыр нуры.
Бер заман чылбыр тәмам акрынлады,
Туктады, һәм бетте ут балкылдавы.
Тик фәкать ул туктаулып күп тормады.
Һәм ләгыйнь дә хәл җыеп өлгермәде,
Күктәге чылбыр башын тоткан мәләк,
Мин тагын эшлим, дигән күк, бер мәзәк,
Әй җибәрде чылбырын әйләндереп,
Ут чәчә чылбыр да очкынландырып!..
Нинди елгыр әйләнә чылбыр хәзер!
Бөтерелә чылбырда иблис зыр да зыр!..
Җирдә инсаннарга төште аптырау,
Әйтәләр: «Бу нинди хикмәт, ялтырау?
Күктә ул нинди өзексез ут?» — диләр,
«Хәлбуки һичбер болыт та юк!» — диләр.
Шул рәвеш торганда куркып, шиксенеп,
Көн аязда елдырымны читсенеп,
Күктә чылбыр әйләнүдән туктала.
Ут вә очкыннар бетә. Күк тын кала...
Күк тынычлангач, халыклар һәм тына.
Шунда да сизгеч йөрәкләр куркына;
Туктаулып иблис көферне селкетү,
Башланадыр тугры җиргә юл тоту.
Төште, төште... узды күп ел, күп заман...
Бервакыт җиргә җитеп калды әман!
Пыр туза, шаулый халык, дөнья куба!
(Әмма күктә бар фәрештә кул чаба.)
Курка инсаннар: «Кыямәт житте»,— дип,
«Ялтырауның хикмәте, аһ, чыкты!» — дип.

Мәшрикъ — көнчыгыш.
Мәгърип — көнбатыш.
Инсан — кеше.
Елдырым — яшен.
Әман — имиилек, тынычлык.

Аптырыйлар: «Төшме бу дип, өнме?» — дип;
Каптырыйлар: «Нәрсә бу? — дип,— җенме?» —
дип.

«Төшмәсен җиргә тере бу коргыры,
Нишләтик соң бу каһәрне инде?» — дип,
Үтерик дип, кайсы-берсе ук ата,
Эретик төшкәнче дип һәм уг ата...
Укка үлми, утка янмый — файда юк!
Башкача һич үлтерергә хәйлә юк!
Шунда күпләр тетрәде куркып, шашып,
Ауды кайсы һуш китеп, төсләр качып.
Һәр кеше: «Актык сәгать, ләхәүлә,— ди.
Ярлыка, ай алла, тәүбә, тәүбә!» — ди.

Бер заман чылбыр очы шартлап китеп,
Төште иблис җиргә егълып, лап итеп!
Тетрәде җилләр дә, таулар сыкрады,
Кайнар диңгез вә күкләр күкрәде...
Чыкты җил, купты буран... тузды туфан...
Әллә ниләр ыжгыра... кайный җиһан...
Сызгыра юха еланнар котырынып,
Ач аюлар акыра сахра тултырып,
Аз гына торгач та чылбыр салпырап,
Борыла-сарыла менде китте ялтырап.
Китте чылбыр күккә тиз-тиз суырылып:
Бетте ул күктә-тамугта куырылып.
Тау башыннан зур өермәләр куба,
Аждаһалар өерелеп күккә менә...
Күктә бик ямьсез болытлар агыла,
Әллә ниләр шартлый, ташлар ярыла...
Кап-кара урманда ерткычлар улый,
Һәм дә җир астында гыйфритләр дулый.
Җирне, күкне курыкныч дәһшәт ала...
(Әмма күктә бар фәрештә шатлана.)
Дөньяның бу чиктән узган дәһшәте,
Билгеле, иблискә байкот-нәфрәте!..
Аңлады иблис тә ошбу мәгънәне;
Аңлады да корды мәгъкуль хәйләне.
Аркасыннан скрипка алды да,
Сагызы берлән эсмычукны янды да
Әй сызарга башлады чын дәртләнеп,
Ыргый бармаклар хисапсыз шартлатып!..
Их, гаҗәп көй! Бер җылый да бер көлә,
Сайрый-сайрый моңланып күккә менә...

Мәгъкуль — акыл белән уйланган.

Белмимен, шайтанмы шундый шәп сыза,
Үтерә, өзә... Могҗиза, чын могҗиза!..
Килделәр иблис янына чынлап ук,
Фирдәвестә бар иде бер хур кызы,
Барча хурлардан матур ул бер үзе.
Бу гаҗәп көй шул чыгарган көй иде,
Күп вакыт хурлар шуны җырлый иде.
Уйнагач иблис кулында моңлы саз,
Һәр тарафка яңгырагач могҗиз аваз,
Шул минуттук тынды калды җир, җиһан,
Шып басылды ком давыллы җил-буран...
Алды тынлык дөньяны шул ләхзадә
Шылт та иткән бер тавыш юк сахрада!
Вәхши хайваннар улашмас булдылар,
Һәм пәри-җеннәр дулашмас булдылар.
Дәрьялар, күлләр, кыр, урман, тау-ташы,
Көйне тыңлап, моңга калды һәммәсе,
Һәммә әйбер «мин тугандай» калды тын...
Калды тын, көлде җиһан, ачты битен.
Шунда күктән сипте нулар ак кояш,
Шунда сайрап чыкты тургай, сандугач;
Шунда гөлләр баш ачып гөрләштеләр,
Һәм үләннәр баш иеп егълаштылар;
Күк йөзендә яңгырагач бу ямьле көй,
Хор белән хур кызлары җырлаштылар...
Җирдә иблис уйнаганны белделәр:
«Бездән откан көйне уйный җен,— диләр.—
Шундый көйләр аркасында ул каһәр
Бар адәмнәрне үзенә кол ясар!..»
Ашкынып, иблис һаман уйнап тора,
Таң калып, дөнья аны тыңлап тора,
Җыелышып бик күп кеше — миллионлап
ук...
Тордылар иблис янында баш бөгеп,
Көйне тыңлап, күзләреннән яшь түгеп...
Инде иблис һәммә эшне җайлады,
Оста тел белән халыкны майлады:
«Сезгә мин рәхмәт өчен төштем,— диде,—
Җиргә төшмәккә ходай кушты,— диде,—
Мин газазил, мин мәләкләр мулласы!
Сәҗдә итсеннәр миңа бар дөньясы!
Сезне мин якын кылыйм дип аллага,
Оҗмахымнан индем ошбу дөньяга...

Ләхза — секунд, күз ачып йомган аралыктагы вакыт.

Аллага якын булуымның шарты бар —
Әйтәемме, кайсыңызның дәрте бар?..»
«Әйт тә әйт!» — дип, гөж килә шунда халык,
Барсының дә дәртләре ялкынланып...
Иблис әйтә: «Тыңлагыз ихлас куеп!
Бак: минем ошбу сакал берлән мыек
Изге әйберләр болар — оҗмах гөлем;
Һәр кеше йолкып ашаса бер төген,
Бер дә шиксез, аллага якын булыр,
Эчкәне бал, кигәне алтын булыр...
Чөнки ошбу ак сакал һәм ак мыек
Үскән оҗмахта алар «һәувәлхак» диеп.
Сәлсәбилләрдә юылганнар болар!
Һәр мәләкнең кулына тигәннәр болар,
Һәм моны хурлар да тәбрик иттеләр.
Тәсбих әйтеп, сокланып гөл сиптеләр...
Һәм, тәбәрреклэп боларны, заты пакь
Алды бер кодрәт кулы берлән сыпап!
Шунда шатлыктан халык шау килделәр:
«Безгә бир, хәзрәт, төгенне бир!» — диләр.
Шатланып иблис, күзе ялт-йолт итә,
Һәм дә котсыз койрыгы шап-шоп итә!
Бер заман иблис сакал йолкып ятыр,
Һәр кеше үз кыйсмәтен кыркып ятыр;
Төк ашыйлар — и кызык! — шытыр-шатыр!
Калды иблиснең яңагы тап-такыр!..
Һәм сакалсыз, һәм мыексыз калды ул,
Тәңредән мәңге өметсез калды ул.
Төк ашап, сөенеп, халыклар киттеләр,
«Без хәзер рәхмәтле булдык бит!» — диләр.
Киң яланда калды иблис кул җәеп,
Мескен, алданган халыктан елмаеп...
Соңра иблис шатлыгыннан торды да
Бик каты бер күккә нәгъррә орды да:
«Йа хода, мәгъруp хода, сиздеңме? — ди, —
Һәр кешенең күкрәген боздыммы? — ди, —
Нинди оста алдадым түгелме? — ди, —
Эх, хәзер шатлык миңа, күңелле!» — ди.
Шул рәвешчә кычкырынгач, туктады;
Мендәрендә гырлый-гырлый йоклады...

Һәувәлхак — хак, чын.
Сәлсәбил — шәраб чишмәсе.
Заты пакь — алла.
Кыйсмәт — өлеш.

Керде һәр инсанга иблиснең төге,
Әмма изге булмады эшнең төбе;
Эчкә кергәч, төк ярылды урталай,
Килде чыкты уртадан шайтан малай...
Һәр адәмнең кальбенә урнашты ул,
Бар иман, вөжданны аска басты ул.
Тик нәфес берлә икәүсе дус болар,
«Нәфес шайтан» дип шуңа ат куштылар!..
Нәфес шайтан кергәч, инсан дөньясы
Азды-тузды, чыкты чиктән һәммәсе.
Инде җирдә изге бәндә калмаган,
Ямь вә тәмнән нам-нәшан да калмаган!..
Бер заман, инмәс борын иблис ләгыйнь,
Торды инсан ал да гөл дә, син дә мин...
Ул заманны җирдә пакь фитрәт иде,
Һәр адәмдә кардан ак күкрәк иде.
Ул заман оҗмах йөрәк — инде дозах!..
Әй матур чак! Әлфирак!.. Калдың озак!..

Уйкусыннан уйганып, иблис торып,
Өзмәенчә торды бик озак сызгырып,
Шайтани бер сызгырык булганга бу,
Шундук ишетелде бөтен шайтанга бу.
Барча шайтан, тупланып, мәхшәр кубып,
Килделәр диңгез кебек ляшкяр булып.
Җен вә шайтан берлә тулды әй дала,
Алдылар иблисне чорнап әйләнә.
«Нәрсә булды?.. Синме сызгырдың? — ди-
ләр.—
Белмибез дә без әле — син кем?— диләр.—
Төскә-биткә безгә байтак биңзисең,
Әллә юкса юл адашкан женмесең?»

Башлады сөйләргә иблис кыйссасын,
Баштан узган кыйссасыннан кыскасын:
«Ошбу җиргә мин яңа тоттым мәкан,
Калды күктә — фирдәвестә төп ватан!
Анда мин сөрдем гомер хәйран да шәп.
Тормышымны көн-төне бәйрәм ясап.

Нам-нәшан — исеме дә, әсәре дә.
Фитрәт — пәйгамбәр килмичә торган заман.
Әлфирак — аерылышу.
Ляшкяр — гаскәр.
Биңзәү — охшату.
Мәкан — урын.

Анда мин спай, матур һәм яшь идем,
Баш идем һәм тәңрегә сердәш идем.
Дәрьядай гыйльмем тирән булгангадыр,
Бар сүзем булды әмер, күрдем кадер...
Күбәләк күк хур-гаеннәр хорлашып
Йөрделәр абзаңны мактап, җырлашып!..
«Мулла Газазил» иде абзаң аты;
Ә хәзер — «Иблис» (галәйһеллләгънәте)!
Сизмисез сез эчтә ниләр янганын,
Дошманы булдым гомерлек алланың...
Җиргә ник ташлаганымны белмисез,
Маңлаемда бу мөһерне күрмисез!»
Шул сүзеннән бар шаятин кузгала,
Йотлыгып бар да мөһергә күз сала.
«Нәрсә бу?» — дип китте гөжләү, жу да жу!..
Бар мөһердә дүрт сатерле бер язу,
Уртадан бер хәлфәдәй шайтан торып,
Язманы башлый укырга кычкырып:

«Әмеребезне тискәре типкән өчен,
Чиктән үткән, эчкәре киткән өчен,
Җиргә аттык без моны мәхрүм итеп,
Барча шайтаннарга баш-мәлгунь итеп.»

Ахырына куйган ходай үз имзасын,
Имзасын, ягъни илаһи тамгасын!
Шул вакыт сүнгән һавалар алмаша,
Мәхшәр шайтан таша, сөенә, шаша...
Кычкыралар: «Яшәсен башлык! — диеп, —
Тилмереп көткәнне без таптык, — диеп, —
Башсыз идек таэзэлдән бирле без,
Ни бәхет! — башлыклы булдык инде без...
Таэзэлдән бирле без, башлык сорап,
Кәррә-кәррә зар елап, кыйлдык теләк.
Хаклы дип безнең теләкне, хуп табып,
Вәгъдә биргән иде тәңре күптән үк,
Ошбу көн тәңре үтәп шул вәгъдәсен,
Салды сөенечкә шаятин дөньясын!..»
Барча шайтан шундый сүзләр сөйләде.

Хур-гаеннәр — хур кызлары.
Галәйһеллләгънәте — ләгънәт төшкере.
Шаятин — шайтаннар.
Сатер — юл.
Таэзэлдән бирле — яратылганнан бирле.

Янгырады мәйданда сөенеч көйләре.
Уртага иблис чыга, нәүбәт алып,
Шунда барысы кул чаба, шаулап алып...
Сөйли иблис ут чәчеп, тәкерек коеп,
Мөгезенә һәм муенына йомрык төеп:
«Ант итәм мөгеземдәге ялкын белән!
Һәм дә муенымдагы камытым белән!
Ант итәм мин «ихласым», «дәртем» белән!
Сез сөекле махласым — халкым белән!
Кәефебезчә йөртәчәкбез дөньяны!
Җир йөзеннән селкәчәкбез алланы!..»
Ошбу сүзнең шатлыгыннан түзмичә,
Кул чаба шайтан иле зак өзмичә...
Кул чабудан соң лӛгыйнь сүздә дәвам:
«Мин әле күктән килеп төшкән заман,
Әйләнәм күрдем адәмнәр сарганын,
Мин аларны хәйлә белән алдадым.
Инсан углын алдалау ансат-җиңел,
Чөнки ул беркатлы һәм йомшак күңел...
Сүз белән эретеп аларны, йомшатып,
Үз-үземне изгеләрдән күрсәтеп,
Орлыгым сиптем аларның кальбенә,
Каршы килсеннәр өчен раббе әмренә,
Бастырып вөжданнарын орлык белән,
Киттеләр сөенеп олуг хурлык белән.
Инде безгә аздыру бигрәк уңай;
Эчләрендә инде шайтанлык ходай!
Эчке шайтан безгә зур ярдәмчедер,
Бар иман — вөжданга каршы камчыдыр.
Инде без тырышып котыртыйк, аздырыйк,
Бәндәне вөждан юлыннан яздырыйк!
Аздырырга тәңредән рөхсәт тә бар:
Кем, туганнар, мондый зур форсат табар?
Яшәсен шәүкәтле шайтан милләте!
Яшәсен инсанга шайтан хезмәте!»
Шул рәвеш нотыгын бетергәчтән лӛгыйнь,
Шау кубалар: «Яшәсен!.. Амин! Амин!..»
«Инде киттек илгә — Каф-тау артына»,—
Дип кенә торганда шайтан халкына,
Тик кенә торганда һәм бик шат кына
Күк йөзеннән күренә бер зат — ак кына!..

Махлас — таяныч, котылу урыны.
Зак — озак сүзенен кыскартылган язылышы.
Форсат — җайлы вакыт.
Нотык — речь.

Төште ул зат җиргә: ул бер кош икән!
Көлделәр: куркыткан әйбер буш икән!
Тордылар «ләмьялтәфит» шайтан иле:
Әмма ул зат кош түгел — Җибрил иде.
Берсе бер ак кошка җүнләп бакмады:
Килде дә Җибрил, шәрабле тартманы
Ачты да, тартма төбеннән актарып,
Ашыга-ашыга алды бер әйбер табып;
Сонра тиз-тиз ак канатка кыстырып,
Очты китте бер гаҗәеп кош булып...

Эшләр узгач, тартма тузгач, сизделәр,
Бер-беренә: «Тот та тот! Тиз, тиз!..»— диләр.
Бер бабай гыйфрит: «Тотыйм мин кошны, ди.
Бир изен, башлык! Алыйм мин үчне!» — ди.
Башлык иблис: «Бу, хәзер сондыр,— диде,—
Туйлар узган, инде эш дөмбер!— диде.
Кош алып очты, беләмсең, нә иде?..
Ул, туган, оҗмахтагы божра иде.
Бик кирәк булган өчен, иблис бабаң
Хәүзе кәүсәр бакчасыннан урлаган!..
Божра нәкъ күк төсле зәңгәр, саф үзе,
Саф пыяла төсле һәм шәфаф үзе;
Түгәрәк, шәфаф вә зәңгәр бәллүдә-
ләрне каплап берсе өсте берсенә,
Китереп куйсаң әгәр син каршыңа,
Һич фәрыксыз божра да охшар шуңа!..
Сизгән иблис божраның зур кыйммәтен,
Сизгән ул божра эчендә нигъмәтен!
Син беләмсең, нәрсә бар ул божрада?!.
Аһ, гаҗип кыйммәтле шәй — фәүкыльгадә.
Андамы, әйтимме?.. А! Анда гаять
Кадре зур бер нәрсә, ул — «Абелхәят»!
Нур үзе ул, су үзе, ялкын үзе,
Терекөмеш күк тере, сыек алтын үзе!..»
Ник ләгыйнь «Абелхәят»не урлаган?
Тәнредән ул үч алырга уйлаган.
Уйлаган ул: божраны ачсам әгәр,

Ләмьялтәфит — исләре китмичә, илтифатсыз, игътибарсыз
Изен — рөхсәт.
Хәүз — күл.
Шәфаф — үтә күренешле.
Фәрык — аерма.
Фәүкыльгадә — гадәттән тыш.
Абелхәят — тереклек бирүче су.

Дөньяга «Абелхәят» сачсәм әгәр,
Бу җиһан бетмәс иде һич мәңге,— дип,—
Һәм кыямәт куптара алмас тәңре! — дип.
Уйлаган ул: алланың җиңмәмме, дип,
Җирдә кәндем алланык кыйлмаммы!? — дип.
Шундый зур идеал белән ул урлаган...
Эле дә сөенеч, ул дигәнчә булмаган!..
Бу урында кечкенә бер нокта бар,
Тиз генә чәйнәп изелмәс ләкъма бар.
Ул исә шул: «Мәңге су»ны — божраны,
Ник ходай иблистән урлаткан аны?
Ник аны баштук яшертеп куймаган?
Ник мәләкләр урлаганны тоймаган?
Ошбуның тапсып иде дип, хикмәтен,
Җәлеп итәм Муса Ярулла дикъкатен!
Юк исә мөнкир вә зиндыйк — дәһриләр:
«Аллагыз гафләттә калган бит!»— дияр!..

Кыстырып «Абелхәят»ны куйнына,
Җибрил менде бу дөнья күгенә.
Котлары очкан мәләкләр шау-шулап,
Алдылар Җибрилне сөенеп, каршылап...
Шул сәгатьтә килде фәрман алладан,
Көтмәгән фәрман белән фәрманлаган:
«Әй, мәләкләр, күз йөзен уегыз!» — дигән,
«Шул урынга божраны куегыз!»— дигән.
Бәс мәләкләр уйдылар, уйлаштырып,
Божраны һәм куйдылар урнаштырып.
Божраны куйган вакыт нәкъ төн иде,
Ярты төн бардыр дию мөмкин иде;
Шул сәгать «Абелхәят»ның яктысы,
Ямьле, тылсым чаткысы, могҗиз төсе
Дәфгатән яктыртты һәм балкытты нур,
Нур белән тулды җиһан, ялт итте җир!..
Аптырау алды шаятин мәхшәрен,
Бар да юнәлткән сәмага башларын.
Шаулыйлар: «А.. нәрсә бу?.. нинди мәкаль...

Кәндем — үзем.
Ләкъма — кисәк, калҗа.
Мөнкир — танымаучы, инкяр итүче.
Зиндыйк — алласыз.
Дәһри — динсез.
Гафләт — ваемсызлык, гамьсезлек.
Дәфгатән — кинәттән, көтмәгәндә.
Сәма — күк.

Төнлә бу нинди кояш?! Бу нинди хәл?..»
Таң калуның шаукымын иблис баса:
«Ул бит ул, мин урлаган әйбер ләса!..
Бит бая көндез бер ак кош төште ич,
Шул теге әйберне урлап очты ич!..
Шул бит ул күккә уеп куйган анә!
Шул анә, нинди анә... нинди яна...
Шул кеенчә күктә торса бөҗрабыз,
Һәр ничек безгә аны урлау фарыз!..»
Шул сүзеннән барча шайтан тындылар,
Барсы да бер төрле уйга чумдылар.
Һәм лөгыйнь дә, күз тегеп бер ноктага,
Китте бик төпсез тәфәккергә таба!..
Уйга чумган көйчә торсыннар әле:
Карнәм, зиһенеңне күккә бор әле!
Күктә шул могҗиза, газиз «Абелхәят»
Күренә бәгъзан түгәрәк, бәгъзан урак!
Күренә бәгъзан ярты икмәк төсләнеп,
Кайвакыт кызлар кашындай нечкәреп!
Кайсы чакта һич күренми күзгә дә:
Шул рәвеш ул төрле хәлгә үзгәрә...
(Бөҗрасы мәңге күренми — юк кебек,
Чөнки ул зәңгәр иде бит, күк кебек!)
Шул күренгән «мәңге су»ны бөҗрадан,
Ялгышып «ай» дип йөрибез без — надан!..
Һич, кая мөмкинме соң ул ай булу,
Без гөман иткәнчә мәгълүм шәй булу!..
Ник, дисең, ул янса, төн әфсүнләнә?
Нигә ул нурланса, җан тылсымлана?..
Ник аның кайныйй төсендә шигъри моң?
Ник аның бар яктысында сихри ым?
Нигә соң аннан гашыйк гыйшык укый?
Күңеленә ник «мәңге сан сөймәк» укый?
Ни өчен аннан шагыйрь илһамлана?
Шигъренә ник мәңгелек рух-җан ала??.
Ник, дисәң, «Абелхәят» ул — ай түгел,
Без гөман иткәнчә мәгълүм шәй түгел!..
Бар да уйда... бар да тып-тын... бар да шым!..
Кычкырып уйгатты иблис барчасын:

Анә (ана) — савыт.
Тәфәккер — фикерләү, уйлау.
Карнәм — укучым.
Бәгъзан — кайчак.
Гөман иту — юрау.
Әфсүн — сихер.

«Йә, туганнар, без күп уйлап тормыек,
Һәр ничек тә божраны без урлыек;
Әйдәгез, кайтыйк та Каф-тау артына,
Тиз керешик без божра урлау дәртенә!..
Урламасак без аны, хәл куркыныч,
Аннары һич мәңге булмас җан тыныч!..
Аһ, әрәм ычкынды, дуслар, божрабыз...
Аһ, моның чөн бәгъренездән сызлаңыз!
Аһ, беләмсез, кулга ләктерсәк аны,
Бетерә алмас тәңре ошбу дөньяны!
«Мәңге су»га шундый көч биргән хода,
Шундый көч ки: кодрәтуллаһны җуя!..
Без шуның чөн һәрничек урлыйк аны,
Алладан саклап калыйк бу дөньяны!..
Аннары дөнья, беләмсез, безнеке!
Аннары рәхәт — ходайсыз йөзнеке!»

Барча шайтан гөжләде һәм кыжрады,
Урлыйбыз дип «мәңге су»лы божраны...
Шул рәвеш шатлык тавыш гөрләү белән,
Әллә ни шайтан җырын җырлау белән
Шул урыннан кузгалып та киттеләр,
Каф-тау артына табан юл тоттылар...
Бер юаш гыйфриткә атланган ләгыйнь!
Гыйфрите ай-һай юан, ай-яй сәмин!..
Атланып алдан бара ул, баш булып,
Җен куче арттан сузылган саф булып.
Син әгәр баксаң аңа читтән торып,
Бихисап урман агып киткән кебек!..
Әй, баралар җир дөберләп, җилкенеп,
Гел әдәпсез — язмаганча котырынып...
Артларында җил-давыл тузгып кала,
Зур өермә, бөтерелеп, сузылып бара...
Юлда уйнап барды иблис «каз муен»!
Бер кабих эш кыйлды... ансын язмыйммын!..

Зур хәбәр, сөенеч бирергә халкына,
Китте алдан илче Каф-тау артына...
Ул җитеп Каф-тау башына менде дә,
Ни өчендер, бик каты җилпенде дә,
Нәгърә орды сур кебек бер торбадан,

Кодрәтуллаһны җуя — алланың үз көчен дә җиңә.
Сәмин — көчле, куәтле.
Кабих — кабахәт.
Сур — көчле тавыш чыгара торган труба.

Җен-пәриләр чыкты сикереп морҗадан.
Барча шайтан курку ташлап кальбенә,
Нәрсә бар?.. дип килделәр Каф алдына...
Илче: «Мин килдем, диде, сөенеч илә:
Озакламый кәрван илә иблис килә!
Күп заманнан бирле көткән мән килә
Хан булырга безгә алладан килә!..»
Бу хәбәрдән урталык исереп китә,
Ыргый, сикерә, пыр туза, тилереп китә.
Бер-беренең җилкәсенә сикерәләр,
Әллә ниләр, язмаганча котыралар...
Сөенүдән авызын үбә бер-берсенең,
Авызы-борыны бетте чабырып илченең?..
Шул көс Каф-тау башын дер селкетеп,
Тордылар сөенечле кәрванны көтеп!
Озак та үтми, җил давыллар туздырып,
Иблис алдан скрипка сыздырып,
Такта-токта, җиз, тимерләр каккалап,
Берсе алга, берсе артка чапкалап,
Кайсы җырлап, кайсы сызгырткан килеш,
Кайсы ыргып, кайсы җир ерткан килеш,
Җитте шайтан кәрваны Каф авызына...
Тетрәде тау шунда шайтан тавышына...
Тау башында дөп тә дөп алкыш куба:
— Хуш киләсез... мәрхәба! урра... урра!!
Тау башына җыелышып һәр барсы да
Килделәр иблис-хәсис каршына.
Шунда гыйфритне акыртып чүккезеп,
Дүрт пәрине култыгыннан тоткызып,
Төште иблис җиргә, акрын баш иде:
«Мин менә сезләргә иблис — баш!»— диде.
Маңлаеннан мөһрене күрсәтте һәм
Әйтеп узды күктә торган чакны һәм...
«Котлы булсын, яшәсен солтан,— диеп,
Бу сәгатьтән без сиңа олтан»,— диеп,
Бар да иелеп җиргә сәҗдә иттеләр,
Кул-аягын үптеләр, йөз сөрттеләр...
Без тотарбыз, дип, синең һәр бойрыгың,
Тоттылар уттан ясалган койрыгын!..
Шул рәвеш беткәч олуглау иҗрасы,
Бар да сөенечтән чыгаргач күз яше,

Калеб — күңел.
Мән — зат, кеше.
Хәсис — шахшы.
Иҗра — йола.

Бар да кигәч буйсынуның нуктасын,
Сөйләде иблис тәшәккер хөтбәсен...
Хөтбәдән соң сөйләде бер җен нотык,
Бик кызу, бик дәртле, бик ялкынлы итеп.
Сөйләделәр бер-бер артлы йөзләре,
Җырлады иблисне мактап кызлары...
Бер шагыйрь күрсәтте шатлык ләүхәне,
Шигъре аның «Нәүхәсез» сәрләүхәле...
Шул рәвеш беткән иде җыр һәм нотык,
Чыкты да мәйданга бер мәҗнүн-өтек:
«Скрипка уйнасын иблис бабай!
Мин биермен, уйнаса!» — ди бит малай!
«Патша бит ул, телне тый, саклан, җүләр!» —
Дип, өтеккә бер-ике рәт мандылар...
«Күккә җилпербез тәненне көл итеп,
Моннары йөрсәң аны мыскыл итеп!..»
Шул сәгать чуклар, флаглар онгызып,
Һәр флагка: «Яшә, иблис!» дип язып,
Әллә нинди зур барабаннар кагып,
Быргы, торба һәм сыбызгылар кабып,
Кайсы җырлап, кайсы чырлап, сызгырып,
Урталыкны кайнатып һәм кыздырып,
Әллә ни шатлык маршлар уйнатып,
Кызларыннан «марсельез»лар җырлатып,
Гөрләтеп, чыңгылдатып, дөбердәтеп,
Киттеләр Каф-таулары буйлап-шцләтеп:
Киттеләр таудан төшеп Каф артына...
Чем-кара зур шайтани бер ат белә
Ялгызы алдан бара иблис пәри;
Мәгъруранә, фахиранә төсләре!
Бихисап зур бер шәһәргә керделәр,
Ду килеп мәркәз урамнан йөрделәр.

Шул шәһәрдә бар гаҗип зур бер сарай,
Һәр җирен йөрсәң — йөрерсең туксан ай!..
Шаһны шул мөдһиш сарайга керттеләр,
Бер тәхет күк калкуга утырттылар,
Зур шәһәргә керде зур шатлык төсе,

Тәшәккер хөтбәсе — рәхмәт белдерү сүзе.
Ләүхә — матур язулы плакат.
Сәрләүхә — исем.
Мәгърунанә — масаеп, горурланып.
Фахиранә — мактанган сыман, мактангандай.
Мәркәз — үзәк.
Мөдһиш — дәһшәтле, куточкыч.

Янгырады шатлык нәмаеш алкышы,
Һәр шәһәрдән, һәр авылдан — карьядан
Бар да килгән, бер дә килми калмаган;
Бар да килгән: ир, хатын, кыз, карт, яше,
Тик мөселман женнәреннән башкасы.
Шаһ янына керделәр нәүбәтләнеп,
Чыктылар бәйгат биреп, ләгънәтләнеп...
Бервакыт, беткәч тә бәйгать патшага,
Шул сарайның балконына баксана!..
Тик тора иблис хәсис шуннан карап,
Бер кулында бер шешә тоткан шәраб!
Ул гажип мәдһиш сарайның бер ягы
Ләгыйнь (чөн) балкон ясалган, сул ягы
Чит-кырыйсыз сахра күк мәйдан иде.
Шунда жыелышкан иде шайтан иле...
Әһле мәйдан бар да балконга багып,
Уррра!.. дип янгыраттылар зак кул чабып.
Шау-шуны баскач ләгыйнь, кынгырау кагып,
Аузына дәһшәт озын торба кабып,
Әй кереште кайнатырга боткасын —
Тәхеткә утыруның беренче хөтбәсен!..
Сөйләде зак, бирде дәрт, кыйлды вәгазь,
Барлыгын язсаң әгәр, житмәс кәгазь.
Сөйләде инсан котырту юлларын,
Нинди коткы, вәсвәсә һәм шом барын;
Сөйләде алда кылачак эшләрен,
Алмый калмыйм, ди, ходадан үчләрем.
Сөйләде хурлап мөселман женнәрен,
Тар-мар итик, ди, аларның илләрен...
Сонра көттереп халыкны, жирсәтеп,
Ул диде, кулда шәрабын күрсәтеп:
«Бу элек жәннәттәге ширбәт иде,
Һушны алмый һәм исертми — пакь иде.
Мин төкердем дә моны иблисләдем,
Пакь шәрабны саф исерткеч эшләдем!..
Мә, туганнар, сезгә ташлыйм, алыгыз!
Шул төбәктән бер тирән кул табыгыз!..
Ташлагыз илтеп шәрабны шунда сез,
Күл хәмергә әйләнер һич шөһбәсез!

Нәмаеш — демонстрация.
Бәйгать — патшалыгын тану, кул бирү.
Зак — озак.
Хөтбә — речь, нотык.

Безгә мәңге ул исерткеч күл булыр,
Аннары соң безгә ал да гөл булыр,
Һәм адәмнәргә таратырбыз аны,
Аздырырбыз, туздырырбыз дөньяны!..»
Дип, озын нотыгын тәмамлап бетте дә,
Һәм халыкка ширбәтен ыргытты да
Керде китте балконыннан эчкәре,
«Шу» килеп калды шаятин тышкары...
Иблис ыргыткан шәрабны тоттылар,
Күлгә ташларга алып та киттеләр.
Күлгә ширбәтне җибәргәч ыргытып,
Башлады кайнарга күл гор-гор итеп...
Берничә көннәр бытырдап кайнагач,
Язмышына аһ-ваһ фәрьяд әйләгәч,
Тынды күл рәнҗеп шаятин явызына,
Әверелеп калды аракы хауызына...

Күлне буйлап бихисап өйләр ясап,
Әллә нинди шайтани сыйлар ясап,
Һәм «хәмер күл»дән чиләкләп, мичкәләп,
Бер дә тынмас, туктамастан эчкәләп,
Ду галәмәт сиптереп кән һәм кичен,
Тантана берлән хәсис иблис өчен,
Атналар, айлар буе туй иттеләр,
Гел әдәпсез, язмаганча типтеләр...
Бәйрәм үткәч, бер олуг мәҗлес була,
Сәркатип бер җен, рәис иблис була.
Үзләре чөн төзделәр иң әүвәле
Мәңгелек тәфсилле «шайтан җәдвәле».
Иң ахырда кузгала бер мәсьәлә,
Бар хыял, уйлар шуңарга шатлана.
Мәсьәлә — «Абелхәят»ны өшкерү!
Башлана шул хакта чынлап тикшерү...
Аңлагач «Абелхәят» әһәмиятен,
Барсы да урларга салды ниятен.
«Урлыйбыз, ди, җан фида,— ди барсы да,—
Юкса шунсыз эш фәна, тормыш җәдә».

Фәрьяд — кайгы, хәсрәт.
Хауыз — ясалма күл.
Сәркатип— секретарь.
Рәис — председатель.
Җәдвәл — бирелә кагыйдә һәм күреләчәк эшләр тәртибе мәсьәләсендә.
Фәна — начар, яман.
Җәдә — авыр.

Кайнаша торсын шаятин мәҗлесе,
Түр башында утыра торсын иблисе.

Килде тугры монда бер сүз кузгату:
— Син беләмсең, нәрсә ул — «йолдыз ату»?
Белмәсәң, әйтим, белерсең белмәсәң:
Зур язык бит, мин белеп, белдермәсәм:
— Көн китеп кич булдыйсә, төн килдисә,
Күк мәләкләрнең күзиле тулдыйсә,
Шул вакытта божраны урларга дип,
Зур сәгадәт иңдерәм җеннәргә, дип,
Көн дә кич асманга җен, шайтан менә...
Менгәне берсе бетә... корбан була...
«Һавия»дән утлы вак ташлар алып,
Үзләре тишкән тишекләрдән багып,
Тик кенә торган мәләкләр төн катып,
Менсә шайтан, үлтерәләр таш атып...
Таш китә асманда атылып, ут сызып,
Нечкә нурдан ак сымак койрык сызып,
Таш, кереп шайтан ләгыйнь корсагына,
Әйди шайтанны җәһәннәм ягына...
Таш шулай шайтан эчендә өртелә...
Бездә шул «йолдыз ату» дип йөртелә.

Таркала мәҗлес хисапсыз дәрт белән,
Керешәбез эшләргә, дип, гайрәт белән...
Шул минуттан бил буып, җиң сызганып,
Тешләрен кайрап тәмам, кансызланып,
Дөнья халкын аздырып бетмәк булып,
Дингә, вөҗданга сугыш итмәк булып,
Дөньяга кормак булып һәр ауларын,
Китте бар да калдырып Каф-тауларын...
Би булып, әмир булып, остаз булып,
Китте һәм иблис тә баш булып.

. . . .

Саннары тик аллага мәгълүм дәһер-
ләр үтеп, җитте хәзер ошбу гасыр...
Җен вә шайтаннар, вә иблис әле дә бар,
Аздыралар, алдалыйлар әле да алар.
Мәлгунь иблис җиргә иңгәннән бире,

Язык — гөнаһ, гаеп.
Сәгадәт — бәхет.
Асман — күк.
Дәһер — заман.

Деньяны туздырдылар шуннан бире...
Үнде алар үзара бер гәп итеп,
Бихисап үткән гомерне яд итеп,
Падишаһ иблисләрен мактар өчен,
Хезмәтен тәкъдир итеп котлар өчен,
Зур итеп мәгърүр тәкәббер күркәгә
Юбилей-бәйрәм ясыйлар иртәгә!..
Аптырап калдым: бүген бер җил белән
Килде иблистән миңа бер телеграм:

«Каф тавында иртәгә зур юбилей,
Үз илеңнән син вәкил бул, кил!— дигән.
Бер җитез гыйфрит җибәрдем мин сиңа,
Атланып кил шул пәринең өстенә!
Үтенеп: «Иблис»

Телеграмны чак укып беттем генә,
Шул сәгать алдымда бер гыйфрит тора!..
«Мин — сиңа иблис җибәргән җен»,— диде.
«Һич курыкма, аркама кил, мен!» — диде.
«Йә, тәвәккәл... тапшырылдым иркенә!..» —
Дип, менеп алдым пәринең сыртына,
Буйсынып язмышка, мин булдым риза;
Хуш хәзер! Кайткач укырмын мәгърүза!
«Әйләнеп кайтырга язсын бер хода!»—
Дип, туганнардан китеп калдым дога!

Яд иту — искә төшерү.
Мәгърүза — доклад, рапорт.

1917

КӨТӘЛӘР

Бер кеше ашлык суга, ындыр табагын селкетә,
Ашлыгын суккан да инде җилгәрергә җил көтә.

Яшь егет бер яшь кәләш берлән торырга башласа,
Күпме ел узгач, ходайдан кыз яки бер ул көтә.

Гомере гел хурлыкта үткән, кәкрәеп каткан бабай:
«Йа ходай, үлтер мине, тындыр мине!» — дип чир көтә...

Пич башында катлы-катлы бөркәнеп яткан әби:
«Салкын алдым, калтырыйм, терелер идем», — дип тир
көтә...

Нәкъ шулар күк җир йөзендә инде күп ил «мир» көтә!
Газраилдән туйган инде, һәр кеше Җибрил көтә...

Төн кара, сүнгән фонарьлар, юл адашкан юлчылар...
Инде һәркем сүнми торган якты бер кандил көтә...

Кар өелгән тау булып, туңган бөтен шәфкать суы!
Инде дөнья ямьле, сөепечле, җылы апрель көтә!..

Җир йөзен су алса да, үрдәк авызга кайгы юк:
Кайберәүләр шатланып сил өстенә мең сил көтә!..

Һәр шәһәр, һәр карьядә «солдатка» калган йорт саен,
«Бер кавышсам, мең җаным корбан итәм!» — дип ир
көтә...

«Яшь, таза буйдак егетләр илгә сау кайтсын!» — диеп,
Сихри чаршауның эчендә назлы нәзкәй бил көтә!

Әйе, «герман» тилмереп, мәңге тынычлык — «мир» көтә...
Газраил, син тәңрегә кайт! Ил җылап Җибрил көтә!..

Карья — авыл.
Мир — тынычлык.

1917

ӨЗЕЛӘСЕҢ ДӘ СЫЗЫЛАСЫҢ

Ярсынадыр нәрсәдәндер, түзмәгәч, түзми йөрәк,
Тарсынадыр, нәрсәдер сызланып әзли йөрәк.

Эзләнү белән еракларга газиз күңелем оча,
Сызлану белән кулымнан дөньяви шөгылем оча.

Нык кына бәйләп тотыйм бу җилбәзәк күңелемне дип,
Юк кына эш берлә тып-тын уздырыйм гомремне дип,

Бар хыялдан, ярсынудан мәңге яшеренмәк булам,
Мәңгегә сабырым белән күңелемә баш булмак булам.

Шул вакыт бер «сын» килеп, ай кебек нур балкытып,
Бер карап, бер алмаеп, ул тайса күздән ялт итеп,

«Аh!» — дисең, шундук бөтен сабрың, карарың җимерелә,
Эчтә дулкыннар куба, дәһшәт, өермә өерелә.

Сайрый башлый шунда ян-яннан гыйшык былбыллары,
Яңгырый башлый монда асманнан мәхәббәт җырлары.

Шунда тагы өзеләсең дә сызыласың әүвәлгечә,
«Тынгысыз җан» тезмәсенә тезеләсең әүвәлгечә.

Шөгыль — эш.
Асман — күк.

1917

ЗӨФӘРГӘ

«Изге саум» дип сөенеч алган ак зөфафны шәгъбан ит.
«Изге нәүм»— йомшак түшәк, иркәңне коч та тайран ит.
Тайран ит, күктән узып кит, кабе каусин сәйран ит,
Гамьне йот, җирне оныт! Гомереңне сиптер — бәйрәм ит.
Наиханңне мәргаң ит — зәмзәмле аузын хәлвәң ит,
Лямига белән сәгадәт бостанында ләмган ит.
Ал мәхәббәт, бир мәхәббәт, җанга җан итсен нөфуз,
Гәүдәсе итсен сине ул, син аны һәм шәүләң ит.
Җил-давыллар күрмичә, гөрләп яшәү матлуб исә,
Кәгъбәсе итсен сине ул, син аны һәм кальгаң ит.
Лямигаң булсын Һаҗәр, сипсен җөфар, әйт, әй Зөфәр,
Син үзең бул Ибраһим, Борханны яктырт, Кәнган ит.
Пакь зефафеңне сәламләп, чын йөрәктән җыр язам,
Дус, онытма бу җырымны: муйныңа тез, сәйлән ит.
Туй көне күнелемне ирсал әйләрем дип, и күңел!
Җырла, уйна, мәҗлес әһлен һушларыннан ауган ит.
Тән баралмый, баш алалмый, дәрт белән көтсәң дә син...
Дәрткә шигърем дәрман ит тә, бармасам да — барган ит!

Саум (саумага) — гыйбадәт бүлмәсе, хөҗрә.
Нәүм — йокы.
Тайран иту — очу.
Наиха — янда йоклаучы хатын.
Мәрга — табындаш мәгънәсендә.
Лямига — нур чәчүче хатын.
Ләмган иту — яшен кебек ялтырау.
Нөфуз — үтеп керү.
Матлуб — теләнгән, соралган нәрсә.
Кальга — крепость.
Ирсал әйләу — юллау.

1917

МӨСӘХХИХ ҺӘМ НАБОРЩИКЛАРГА

И мөсәххих, көлмә кыйх-кыйх тиргәвемә,
Авырткан урыныңны тырнавыма;
Син дә тагы, наборщигым, авызың җырма,
Колагың ач, җаным ачып җырлавыма!

Бик беләмен: хәреф төзү кыен бер эш,
Кыен эшләр җиңеләя, булсаң тырыш;
Танавына ачы борыч сипсәләр дә,
Шул зур эшне зурлап үтәү сиңа бурыч...

Бер наборщик хәреф тезсә — дикъкать итсә,
Күзләрен «оригинал»да ипләп йөртсә,
Шиксез, аңа оҗмах авызы ачык булыр,
Хәрефләрне таза сайлап, чүпләп кертсә!

Бер наборщик шәп тезүне күзәтмәсә,
Бер мөсәххих күп яңлышны төзәтмәсә,
Ахирәттә ни эшләрләр, ходай әгәр
Уттан булган зынҗыр белән йозакласа?..

Йозаклар шул, ходайга ул кыен түгел,
Язучылар бәддогасы уен түгел;
Мәкаләсе яңлыш чыкса, ничек түзәр?
Язучы бит, аның күңеле чуен түгел.

Бездә инде ялгыш басу афәт булган,
Шул афәттән бер афәт нахак булган:
Эшгаремне һич тә дөрес басмыйлар, дип,
Бер шагыйрь хәсрәттән вафат булган!..

Әй наборщик, үзеңә дә түгел зәвык,
Яңлыш тезсәң, җәзасы бар дөньяда ук:

Мөсәххих — корректор.

Мөсәххих тезгененңне борган саен
Төзәтәсең азапланып авык-авык...

Шунда да мәгъзүрсең син, өске иләк,
Син, мөсәххих, аскы иләк, булма сирәк!
Иләп-иләп вак-төякне тазартмасаң,
Сиңа оят, сиңа төшә мәсьүлият!

Мөсәххихләр эчендә ялкавы күп,
Берәве тырыш булса, алтавы — чүп;
Урындыкны җылытып тик торалар
Күбрәге Шакирҗан Әттәкави кук!..

Мәгъзүр — берәр сәбәп белән бер эшне эшли алмаучы.
Мәсьүлият — җаваплылык.

11 З-472

1917

ТАШЛАНГАН ВӘРӘКАЛӘР

I

Туң тәрәзә аркылы, яткан урыннан ай карыйм,
«Ай, шигырь бир! Ай, шигырь бир!»— дип айны даулай карыйм.
Кит, поезд, дыңгырдама! Мин сөенә-сөенә ай карыйм,
Чын шагыйрьләр күк тирән уйларга чумгандай карыйм.
Кит, поезд, дыңгырдама! Мин тын да алмый ай карыйм,
Ай эченнән күнелемә дәрман булырлык җай карыйм.
Әнә күренә ай түрендә бер матур ай тәңресе!
Әй матур! Ыргыт шигырь! Җырлап үзенә кайтарыйм!..
Ай нуры — күз керфегең, ай яктысы — ак йөзләрең,
Әй матур кыз! Төш бире! Әй авызыңа сармай ягыйм!..

II

Әүвәле башлыйк Казаннан, анда «Аң» балкып чыга:
Аксадым, хәл бетте диеп, калт-колт килеп «Ялт-йолт» чыга

. . . .

Юк, кирәкми, язмыймын, эчтә көек, күңелем боек!
Ник боекмаска — тәмам ертык оек, шиблет кыек...
Хәлне белми димлисең, дускай, дисең: «Ал яшь кәләш!»
Яшь кәләш?! Ансат сиңа... Булсын әле шиблеткә баш!

III

Эш-фәлән тапкан булып, абзаңны кызлар дәшкәли;
Кышка керсә, абзыкаң кызлар белән кайнашкалый...
Бер шулай хат аркылы кызлар чакырган «Кил!» диеп,
Хат китергән нурлы кызны уйладым Җибрил диеп.
— Тукта, «Җибрилчек», торып тор! Хатка каршы хат языйм!
Эчтән уйлыйм: «Тукта, дим, кызлар кызарлык шәп языйм»

Вәрәка — язылган кәгазь кисәге.

«Әй егетләрнең хыялы — җанлы тылсымнар! дидем,
Сез дигәндә җан-тәнем корбанга торсыннар! дидем,
Чөнки мин сез дип яшим, сез дип көләм, сез дип үләм!
«Кил!» дигәч, килмимме соң, әлбәт киләм, әлбәт киләм!..»
Хатны «Җибрилчек»кә суздым, алды елмайган килеш,
Китте, ялт итте.., торып калдым, һушым тайган килеш.
Ис җыеп йөрдем бераз бүлмәмне буйлап, уйланып,
Сайрашып, кызлар белән йөргәннәремне уйга алып.
Ни сәгадәт! — дим, чакырганнар тагын кызлар бүген!
Тултырам бит мин тагын күкрәккә йолдызлар бүген!..

Сәгадәт — бәхет.

1917

ТӘМСИЛ КИСӘГЕ

(Үзгәреш мөнәсәбәтилә)

Җимерелеп китте кипәт чергән диварлар, матчалар,
Тумырылып китте югартын төрле ерткыч патшалар.
Сайгак астыннан чыгып, шаулап йөрергә башлады
Барча тычканнар, комаклар, ас вә әрлән, ләтчәләр.

Зык кубалар, сөенешәләр: чергән өй җимерелде, дип,
Безне өркеткән явыз, ерткыч халык себерелде, дип.
Күп гомер иттек кара туфрак эчендә тончыгып,
Сайгак астында җитәрлек аркалар сызырылды, дип.

Шаулаша әрлән иле: әрләр халыклар бетте, дип,
Даулаша ас милләте: даулар вакытлар җитте, дип.
Кауме тычкан уйнашып, йөгреп йөриләр чинашып,
Күп заманнар безне дә мордар песи рәнҗетте, дип.

Үз җырын җырлап, кавемнәр аерым-аерым җыелалар,
Үз көен көйләп ясыйлар төрле орган, «бюро»лар.
«Бик кызу чак, ятма йоклап, анда чап та монда чап;
Син аны бак, син моны»,— дип бер-беренә боералар.

Инде зур максатлары шул: йорт ясау бик якты итеп,
Якты йортта гөж килеп, уйнап яшәү бик яхшы итеп,
Беравыздан барысы да сайлап куярга уйлыйлар
Эчләреннән изге җанны йортка баш һәм сакчы итеп.

Кауме тычкан — тычканнар нәселе.

1917

ХӨРРИЯТ БҮЛӘГЕ

Исте җил... Сүнде бар ялган шәм,
Таралды һәм болыт, һәм томан.
Калыкты чын кояш, кипте яшь,
Капланды «кара көч» йөзтүбән!

Ябылды капусы сәкарьнең,
Ачылды җәннәте Ватанның,
Чәчелде хуш һава, хөр һава...
Бу иде көткәне татарның!..

И татар, калдың хөр һәм азат,
Хөрлеккә, көрлеккә алдың хак.
Артыңны — салкынны онытып,
Алга бак, кальбең як, ялкынлат!

Юлыңның артын яп — төрлесен,
Алдын ач — ак көннәр күренсен;
Өч йөз ел изелгән ак җаның
Терелсен, терелсен, терелсен!

Аяклан форсатта, хөр чакта,
Канатлан як-якта нур чакта!
Җитәрлек изелдең, яньчелдең,
Бәйләндең тозакка кол чакта!..

Өч йөз ел аһ ордың, Ватан дип,
Җан кыйдың, кан койдың, Ватан дип,
Шулай да ертылды намусың,
Сүгелдең: «Былчырак татар!» — дип.

Җитәрлек ерттылар йөзеңне,
Черттеләр золматта үзеңне.

Сәкарь — тәмуг, җәһәннәм.
Золмәт — караңгылык.

Син хәзер Ватанның хөр углы,
Моннан соң ачык тот күзеңне!

Көн туды караңгы Ватанга,
Юл бетте хакларны таптарга...
Ватаның Русия — уртак мал,
Кер, татар, кер, татар, катарга!..

Ябылды капусы сәкарьнең,
Ачылды җәннәте Ватанның,
Чәчелде хуш һава, хөр һава...
Бу иде көткәне татарның!..

Катарга — катына, бу очракта илнең башка халыклары с[illegible]
дигән мәгънәне белдереп килә.

1917

ЯШӘСЕН ЭШЧЕЛӘР

Эшче халык кузгалсын,
Beләкләрен сызгансын,
Теләкләрен кулга алсын,
Кирәкләрен эзләнсен!
  Эшче халык яшәсен,
  Тигез юллар ясасын!

Эшче халык яшәсен,
Сөрсен дөнья сафасын,
Берлек туын кулга алып,
Тигез юллар ясасын!
  Эшче халык яшәсен,
  Тигез юллар ясасын!

Эшчене күп изделәр,
Алар һаман түзделәр,
Фиргавеннәр, каруннар
Йөрәк маен сыздылар.
  Эшче халык яшәсен,
  Тигез юллар ясасын!

Аңла, эшче, үзеңне,
Ачып кара күзеңне:
Бөтен дөнья мөлкәте
Кем кулыннан төзелде?
  Эшче халык яшәсен,
  Тигез юллар ясасын!

Хакыңны ал һәр чакта,
Берләшеп кал форсатта,
Форсат бирмә корсакка —
Корсак тулмас һич чакта.

Ту — байрак.
Форсат — мөмкинлек.

Эшче халык яшәсен,
Тигез юллар ясасын!

Эшче тели гадәләт,
Тигезсезлек — яман ат!
Тулган карун карыны
Шиңә төшсен чамалап!
Эшче халык яшәсен,
Тигез юллар ясасын!

Тигезсезлек чәнчелсен,
Аяк аска яньчелсен;
Бөтен дөнья, бер булып,
Тигез нурга манчылсын!
Эшче халык яшәсен,
Тигез юллар ясасын!

Гадәләт — гаделлек.

1917

КОТЛАУ, ТЕЛӘК

(Яхшы имтихан биреп, «алгы сыйныф»ка күчкән туташка)

Кыл күперләрне үтеп, оҗмахка кергән төслесең,
Юлга төштең зур манигъларның үтеп иң көчлесен.

Ал кабуллап, ал да сал, шатлыкка сулган күңлеңә
Табригемнең эссесен һәм эссе ялкын төслесен.

Син кебек зат һич вакыт кальбен горурга ашламас,
Бу — минем төсле — газиз танышын исеннән ташламас.

Бер теләктәш тиңдәшеннән килсә бер котлау әгәр,
Син кебек зат дөньяга хурлау йөзеннән ташламас.

Бер сүз әйтсәң, син кебек зат сер итеп саклар аны,
Бер хатадан сүз гөнаһы зур икән — каплар аны.

Син кебек нур көлтәсе, шәфкать, шәфәгать чишмәсе,
Бер таныш ир күкрәгендә кер икән — пакьләр аны.

Чын күңелдән мин теләктәш, алга бас баскан саен,
Изге мотлакка табантын юллар ач ачкан саен.

Манигъләр — каршылыклар.
Мотлак — теләк.

1917

УЙЛАР УРТАСЫНДА

Һич тотар хәл юк күңелнең тезгенен,
Һич белер хәл юк фикернең төзлеген;
Бер минутта мең түгел, миллион теләк;
Һич белә алмыйм кай теләкнең үзлеген.

Алчы, тәңрем, бу күңелнең йөзлеген,
Салчы күздән бу томанлы күзлегем;
Аңкы-миңке каңгырып көннәр уза,
Инде аз-азлап бызылдар мизгелем.

1917

ӘЙ, ӘФЛӘТУН!

Әй, Әфләтун, Әфләтун,
Ач башыңның гафләтен!
Ташла, йоклап ятмагың,
Яз әкият, такмагың!

Гафләт — ваемсызлык, гамьсезлек.

1917

МӘХӘББӘТ ТОТКЫНЫ

Күбәләк дип кистерәлмим, сандугач тик таушы бар,
Сандугачкай һич дия алмыйм — күбәләктәй рәүше бар.

Сандугачның, күбәләкнең һәр икәүсен бергәләп,
Һәр икәүсен бергәләп кушкач, яралган бер мәләк;

Әйләнәмне әйләнеп чыкты сихерләп, көлгәләп,
Санки сызды әйләнәмдә сихри ямьнән дүнгәләк!

Дүнгәләк берлән мине әйләндереп, чорнап алып,
Дүнгәләккә күз нурын ялгап, мине сирмәп алып;

Сандугач күк таушы берлән бик матурлап бер көлеп,
Күбәләк күк рәүше берлән китте фырлап, җилпенеп...

Мин дә киттем, күз нурына тартылып, сәрхүш булып,
Шул сихерле дүнгәләктә коршалып, мәхбүс булып!

Кистерәлмим — кистереп әйтә алмыйм.
Санки — гүяки.
Сәрхүш — исерек.
Мәхбүс — тоткын.

1917

ҚҮБӘЛӘҚ ВӘ МИН

Багда очкан күбәләк тик ямьгә каушуны белә,
Ул бүтәнчә нә усал уй, нә дә шау-шуны белә!..

Күбәләк тик ямь сөя, тик гөл янында фырлый ул,
Ямьгә чумганнан ирексез гөлгә гыйшкын җырлый ул.

Күбәләкнең бар яме, барлык хәяты гөл белән,
Гөл белән һәм гөлгә гыйшкын сайраган былбыл белән.

Мин дә, дускай, күбәләк күк: җан күңелдән ямь сөям,
Бар вөҗүде ямь генә булган илаһи «җан» сөям!..

Вөҗүд — бөтен барлыгы.

1917

ТАБИГАТЬ ОҖМАХЫ

(Мәхәббәт)

Алтын сарай эчендә бер күл булса,
Күл читендә чәчәк аткан бер гөл булса,
Гөл өстендә сайрап торган былбыл булса,
Астында Гыйрфан белән Мәрьям торса,

Кочаклап берен-берсе үбеп торса,
Күл өсте шагыйранә көлеп торса,
«Котлы булсын бәхетләр!»— дигән кебек,
Аккошлар аңкылдашып, йөзеп йөрсә.

Карлыгачлар кыйлпып-кыйлпып, нурлар сирпеп,
Очсалар баш өстендә канат җилпеп,—
Ходаем, оҗмахларың торып торсын,—
Торсалар мәңге шулай гомер итеп.

1917

МАТУР СЫННАР

Матур сыннар, матур кызлар, матурсыннар,
Әйткән чакта исемегез дә матур чыңлар.
Сезне күреп, ямьгә чумып, киттем эреп,
Гакылсызлар: «Гакылсыз!»— дип бакырсыннар!

Карап карыйк: гакыллылар нишләр икән,
Бар гакылны көрәшергә чакырсыннар,
Карап карыйк: бер сылуны җиңәр микән,
Сихри күздән сихри уклар атылсыннар.

Кызыл ирен бер елмайса, ходай шаһит,
Бөтен фикер әсир төшәр, гакыл шүрләр;
— Ике тәңре: әүвәле — алла, икенче — кыз!—
Димәсәгез, биллаһи, кяферсеңнәр!

Күчегезгә иман итеп мин багындым,
Йөрәгемә мәхәббәт сал, матур сыннар!

1917

ӘКЪЛИМӘГӘ

Мин әле сезне, гафу ит,
Белмимен, сез кем, туташ?
Сез берәр кискен туташмы,
Әллә бер мескен туташ?

Сез дә шулай белмисегез
Мине — мин нинди җан?
Кем белә, мин әллә сезне
Белмәгәнгә моңлы җан!

Очрашыр, дип уйладым мин,
Кул белән әүвәл кулын;
Уйлаганнар күккә очты —
Төште әүвәл альбомың.

Альбомың алдымда, әмма
Ни языйм соң — белмәгәч?
Ичмасам, бер мәртәбә
Бульварны буйлап йөрмәгәч?

Ни языйм соң, бер генә
Рәхмәт никабың ачмагач?
Гөл йөзеңнән күңлемә
Илһам нурыңны чәчмәгәч?

Кил, туташ, әүвәл күңелең
Кылларын тибрәт элек,
Альбомыңа аннан нурлар
Коермын мин, шат булып.

Никаб — пәрдә.

1917

ГАЕД КӨНЕ

Шатлан, мөэмин, бүген шатлан — гаед көне,
Шатлыгыңнан исер, мөэмин, аек көе.
Аек җаннан җырлап җибәр гаед көе,—
  Син җырлый дип, фәрештәләр җырласыннар.

Син җырлый дип, изге рухлар җиргә керсен,
Әйләнәндә нурлар сирпеп уйнап йөрсен.
Сөен,мөэмин, гаед шәриф котлы булсын,
  Син сөенә дип, явыз җеннәр елашсыннар.

Сөен, сөен, бәйрәмеңне сөеп-сөеп,
Җырла, уйна, хур кызлары торсын биеп,
«Бәракалла, сиңа рәхмәт булсын»,— диеп,
  Җирләр, күкләр берләшсеннәр, серләшсеннәр.

1917

ДИМ БУЕ ҖЫРЛАРЫ

Дим буена төшкән идем,
Тал яфрак ярган икән.
Дәрткә кабынып, моңга табынып
Яшәргә калган икән.

Төшкән идем Дим буена,
Чәчәк аткан андызым!
Нишләр идем, торып калсам
Гомер буе ялгызым?..

Дим буена төшкән идем,
Бөрлегән пешкән икән.
Бөрлегәннәргә үрелеп,
Икәүләп өзсәк икән...

Дим буйларын ямьләндергән
Бөдрә башлы тал икән.
Егет башын әйләндергән
Кара кашлы яр икән.

Дим буенда таллар үскән
Былбылларга тәхеткә,
Ал иренеңне бер үпсәм,—
Ирешер идем бәхеткә.

1917

МӘХӘББӘТ ҖЫРЛАРЫ

Авылыгыз якын икән,
Урамы такыр микән?
Кызларыгыз матур микән,
Йөрәккә ятыр микән?

Чык энҗеләре тама
Күгәрчен күзләреннән;
Хуш исләр бөркелеп кала
Иркәмнең эзләреннән.

Агыйдел каты ага,
Астыннан вак таш ага.
Начар кызларга алданып,
Башың салма хафага.

1917

ИӘ ӘЙИЕҺӘЛ МӨСЕЛМАН

Ий әййеһәл мөселман,
Түп-түгәрәк тышыннан;
Әтәч кебек очынып
Юк-бар эшкә кысылган.

Күп йоклап, аз пошынган,
Йоклый торгач, шешенгән;
Көнгә чыкса — кысылган,
Кашынып, язган һушыннан.

Җилгә җилән киселгән,
Иске токтай бүселгән.
Эш чыкмавын эшеннән
Тик эш узгач төшенгән.

БАЙЛАРГА

(Руза бәйрәме мөнәсәбәте белән)

И калын корсаклы бай, корсаклы һәм «инсафлы» бай!
Ай буенча ач торып, ачлар хәлен сизденме — әй?..

Тук торып рәхәткә күнгән әчләрең кыйналдымы?
Ач-ялангачларга шәфкать хисләрең яугандымы?

Уйладыңмы: социаллар тартышуда хаклы дип?
Социаллар ярлы, тапталган халыклар яклы дип?

Уйладыңмы: чын золым бит, чын талау бит байлыгың!
Байлыгың күпме фәкыйрьнең җуймагандыр саулыгын!

Сезгә нәрсә: көн дә бәйрәм... сезгә көн дә тик тору;
Ярлылар көн-төн җигелгән, сезгә көн-төн типтерү!

Ник болай бу?.. Ярлылар да бай кебек инсандыр ич?
Ярлылар да бай кебек рәхәт теләүче җандыр ич?

Бертигез бай ярлы белән, юк аның артыклыгы,
Булса тик артыклыгы — онкытлыгы һәм мутлыгы!

Бетсен инде, буржуазлар дөньяга баш булмасын!
Бетсен инде, ярлылар мохтаҗ, ялангач йөрмәсен!

Бетсен инде киң җиһанда тар каберләр тарлыгы!
Бетсен инде бикләнеп яткан каруннар сандыгы!

Йөрмәсен инде фәкыйрьләр әлсерәп, хәлдән таеп!
Бертигез тотсын «руза» һәм бертигез итсен «гает»!..

УТРАУ

(Тәмсил)

Ул элек киң йир иде, андан киң йир юк иде,
Эчрәсендә вак-төяк күлләр вә силләр күп иде.

Ошбу күлләр йиргә сиздермәсдән, эчтән серләшеп,
Барсы бердән бергә кушылып, акрын-акрын берләшеп,

Алдылар киң йирне як-яктан басып, зур яу булып...
Калды киң йир уртада кеп-кечкенә утрау булып.

«Бу җиһан без — суныкы!»— дип, бер фикергә тагылып,
Ошбу күлләр җыелышып, олыгайдылар дәрья булып.

Дәрья: «Утрауны йотам!»— дип, сарыф итеп бар куәтен,
Торды утрау өстенә тулкын бәреп ул көн вә төн.

Кысты дингез тундырып утрауны кыш һәм көзләрен,
Язларын итде һөҗүм ул, кузгатып зур бозларын.

Тузды утрау өстенә җилләр, гарасатлар һаман,
Купты да торды кыямәтләр, фәләкәтләр тәмам...

Әмма утрау шунда да калды һаман утрау көе,
Куркыныч тулкынлы дәрья уртасында сау көе.

Ошбу утрау уртасында иске бер йорт бар иде,
Әйләнә таштан ясалган бик биек дивар иде.

Таш дивар утрауны җилдән, дәрьядан саклый иде,
Тик фәкать якты кояшның яктысын каплый иде.

Йорт башында бар иде айлы яшел, зәңгәр флак,
Җилфердәп ул, егълый ул, дип: «Иске йирләр әлфирак!»

Фәләкәт — бәла, бәхетсезлек, афәт.
Әлфирак — аерылышу.

Йорт вә утрауны йотам дип, дәрья тулкын типсә дә,
Һәм «флакны ыргытам» дип, җил-давыллар купса да,

Каф тавы күк таш диварлар... кайда ул утрау йоту!
Җен-пәриләр үтмәсә, мөмкинме соң Каф-тау үтү?..

Таш диварлар саклады һәм каплады көн яктысын,
Дәрьядан индертмәде ул хуш һава һәм пакь исен.

Шул сәбәпле, иске йорт искерде искергән саен,
Сайгак, өрлекләр, нигезләр черделәр чергән саен.

Якты нурлар төшмәгәч, гөлләр, үләннәр үсмәде,
Кайда сайлык, кайда комлык тулды утрау өстләре.

Үсмәде җүнләп агачлар, катды бер каткан килеш,
Ярмады яфрак та җүнләп, кайда ул бирсен йимеш!

Бу вакытлы кимчелекнең һич тә хәүефе юк иде...
Шул көенчә таш диварлар саклавы матлуб иде...

Таш дивар, утрауны саклап, дәрьядан йотдырмады,
Җил вә давылындан мөкатдәс айны ыргытдырмады.

Шул диварлар аркасында калды утрау сау-исән;
Ис китәр бу таш диварлар хезмәтен уйлар исән.

Гәр ут утрау ян-ягында таш диварлар булмаса,
Булса булсын да, мәгәр дингезгә каршы тормаса,

Ятсалар йә йиргә чалкан, ак кояш төшсен, диеп,
Дәрьядан утрауга хуш ис, саф һава иссен, диеп,

Ул чагында утравын какмасмы иде күптән колак?
Дәрья астында череп ятмасмы иде айлы флак?

Шөбһәсез, күбтән колак каккан булыр иде дөньядан,
Әл дә рәхмәт, таш диварлар саклаганлар дәрьядан...

Ошбу көн утрау яши, утрау булып, сап-сау булып,
Таш диварлар, вакты җиткәч, аудылар сырхау булып...

Таш диварлар урынына яшь-яшь диварлар калкды,
Балкыды нур, керде хуш ис яшь диварлар аркылы...

Инде дингез омтылалмый көчле дулкыннар белән,
Беткән анда иске дәрман, иске җан, иске иман...

Җил-давыл да җенләнәлми, зык кубып әүвәлгедәй,
Сизгән ул — бик нык кадалган йорт башында шанлы ай!..

Инде эш булмаслыгын кат-кат сынап белгән алар,
Шул сәбәп өстендән юашланган алар, тынган алар.

Инде җил астдан исеп, дингез дә аст якдан тишеп,
Булдылар утрауны йотмак, балчыгын астдан ишеп!..

Юк... мәгәр утрау төбе бик киң... мәхаль эш... юк, бикәр...
Бервакыт утрау үзе дингезне суырып юк итәр!..

Вакты берлән ул үзе өсткә чыгар, калкыр әле,
«Шәммас икъбал» бервакыт утрауга да балкыр әле.

Зур өмид бар... бакчы, утрау нинди ямьләнгән... кара!
Нинди ямьле, аллы-гөлле,[1] җанлы хәйран манзара...

Яшь агачлар нурлы яфраклар ярып лепрәп тора,
Яшь үлән, гөлләр белән утрау йөзе күкрәп тора.

Яшь диварлар аркылы утрауга төшкән ак кояш;
Гөл янында күбәләкләр, тал янында сандугач...

Күбәләкләр ямь коеп — гөлләр кочаклап уйныйлар...
Сандугачлар, җан биреп, утрауны мактап җырлыйлар...

Йорт та сипләнгән вә ипләнгән, яңарган һәр ягы,
Селкенә хуш җил белән зәңгәр, яшел, ак байрагы...

Кычкыра байрак гүя: — «Дөнья хәзер утрауныкы!
Солтанәт, шәүкәт хәзер шатлы, шәрифле айныкы!

Кит, золым, ялганчы дәрья! Кайт, утыр үз аслыңа!
Бир минем йирләрне, алгансың талап кул астыңа!»..

Шан — дәрәҗә, мәртәбә.
Мәхаль — урын.
Бикәр — файдасыз, буш вакыт үткәрүче.
Шәммас икъбал — бәхет кояшы.
Манзара — күренеш.
Солтанәт — патшалык.
Шәүкәт — көч, куәт.
Шәриф — кадерле.

Тәмсилнең чишелүе

Аз гына сүтмәкче булдым, ошбу тәмсил йомгагын,
Күрсәтим йомгак очын, үзегез сүтәрсез аръягын!..

Куркыныч диңгез —«алар», киң төпле утрау — халкымыз...
Кайда ул безнең элекке киң җиһан, йә әйтегез!..

Кем камалды, кем кысылды соңра шул утрау сыман?
Соңра кем чикде газап, әрнү, елау, сыкрау белән?

Кем булыр,— әлбәттә, без, кемләр елар — әлбәттә, без...
Күпме еллар кол булып күз яшьне түктек хәтта без!..

Шунда да калдык исән, сакланды тел һәм яшь һилал;
Безне кем соң саклады һәм булды кемләр таш дивар?..

Тотды кемләр кальбемезне сүндереп йоклатмыйча?
Тамырымызда канымызны туңдырып туктатмыйча?..

Чыкмадыкмы кап-кара төндән исән-сау юл йөреп?
Атмадымы нурлы таң күкрәккә рәхмәт иңдереп?

Өстемездән төн үтеп, бер офыгымыздан таң тугач,
Кемләр әйтер инде: «Чыкмас, дип, көтеп торган кояш».

Бу сөальнең җавабын күңелегезгә ташладым:
Инде күрсәтдем бугай бу тәмсилнең астларын.

Һилал — ай.
Кальбемез — күңелебез.

1917

ҖАНКАЕМ!

Аһ җаным!.. Ник күктә табынып, ямьгә кабынып тормадың?
Ник шигырьдән таҗ киеп, илһамга ялынып йөрмәдең?

Ник күгәрчен төсле гөрләп, тик ясап нурдан оя,
Тормадың ник нур эчендә, мәңге җырлап «мәдхия»?..

Ник мәләктәй йөрмәдең, аппак канат җилпеп очып?
Аңкытып җәннәт исен, сирпеп шигырь, сирпеп гыйшык?..

Җанкаем!.. Асманны ташлап, җиргә индең ни өчен?
Ямьне ташлап, гамьгә чумдың — тәнгә кердең ни өчен?

Уйладыңмы, җирдә дә мин нурга коенырмын, диеп?
Ямь коярмын, «яр» сөярмен һәм дә сөелермен, диеп?

Уйладыңмы, хөр яшәрмен, дип, бәхетсез җирдә дә?!
Ник ябылдың соң алайса «тән» исемле төрмәгә?!

Чык, җаным, тән зинданыннан, күккә оч, ямьләп янә,
Җиргә төшсен, ал шәфәкъкътәй алланып, шәүләң генә.

Мәләк — фәрештә.
Зиндан — төрмә.

1917

* * *

Бик имин мин, күкрәгемдә мәңге кайнар милли хис,
Бак телендә илне мактап, мәңге сайрар милли кош.
Бик имин мин, милли дуслардан зарланмас җаным,
Милли дусларга җанымны мәңге бәйләр милли эш.

1917

МӨРТӘТ СОЦИАЛИСТЛАРГА

Искерәк шиблет эченнән ныгырак чолгау урап,
«Социалист» дип йөрисең, кып-кызыл билбау урап.

Кып-кызыл сүзләр салып йөрттең кара күкрәктә син,
Пычрак төрдең дә ыргыттың кызыл чүпрәккә син.

Тышка чыктың — мәрхәмәт, шәфкатьле сүзләр сөйлисең;
Өйгә кердең — кай фикерне изәтәм дип уйлыйсың?

Тышка чыктың, алдыңа туфрак салып, икмәк турап,
Өйгә кердең — торды алдыңда төрле көмешләр шалтырап.

Нәгъря ордың: «Измәсен,— дип,— бай фәкыйрьләр
җилкәсен!»
Ә үзең ач җилкәсеннән күпме дәүләт чиртәсең!

Тыштагы барлык эшең: җил якка салпы кыстыру,
Өйдәге бар идеалың — бер тиенне меңгә үстерү.

Изәтәм — әзәрлим.
Нәгъря — ачы, каты тавыш, акыру-бакыру.

1917

СОЛДАТКА АЛЫНГАН БЕР ДУСТЫМА

Аңладык, белдек хәлеңне: килде таушың таң белән,
Килде таушың, тыңладык та, еладык бер тәм белән.

«Мин эләктем, китте баш. Хуш, хуш...» дигәнсең кайгырып,
Шатланып, кайгыңны котлыйбыз хәерле фал белән.

Селтә кулны дөньясыннан, кер әҗәл базарына,
Зур җаныңны хур итеп йөрмә кадерсез тән белән.

Кер сугышка һәм, тәнеңне канга ташлап, күккә оч,
Нинди мәгънә бар җиһанда җан кыйнап торган белән?

Күккә оч, күктә тыныч, монда сугыш, кулда кылыч,
Монда эшләр куркыныч, җир-су буялды кан белән.

Вәхши күз, шакшы күңел, алдакчы тел дөнья тулы,
Күпме-күпме тугрылык корбан була ялган белән.

Ак күңелне таплатып, кыйммәт намусны таптатып,
Торма җирдә, әй, бөек вөҗдан, җыен шайтан белән!

1917

БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ СПИСОК

И фәкыйрь дин кардәшем, юлсыз йөрүдән син оял,
Ант итеп әйтәм: сиңа яхшы, матур юл социал.

Социаллар партиясе тугрылык, хаклык теле;
Ярлыларга якты тормыш, бертигез шатлык теле.

И гөнаһсыз ярлы эшче, ир, хатын-кыз кардәшем,
Тәмле сүзләр белән катлаусыз җаның алданмасын!

Бай халыкта төп фикер: «Мәңге изелсен ярлылар!»
Шул фикерне: «Без мөселман, берләшик!» — дип
майлыйлар.

Тыңлама, алданма, кардәш, төшмә төпсез мичкәгә,
Социалларга тавыш бир — бер номерлы спискәгә!..

1917

МИН КИТӘР ЧАКТА

Мин китәр чакта гына сөйкемле күренә һәммә шәй,
Барчасы шат, барсы якты, барсы нурлы мисле ай.

Сез миңа бигрәк тә нур, бигрәк тә яктырган кебек,
Бер карашың — Исрафил илһам сурын өргән кебек.

Бер таныштa сезне мин куйдым күңелнең өстенә,
Бер таныштa сезне охшаттым кадерле дустыма!

Бер таныштa сезгә багланды күңелдән хөрмәтем,
Ошады кальбең, сүзең һәм нурга чумган килбәтең!

Бу риясыз бер генә кат сүзләремне ит гафу,
Китсә кәйфең, янда йөртмә ташла утка, ит мәхү.

Рия — икейөзлелек.
Ит мәху — юк ит.

1917

КИЛ, ЧИБӘР

Килче, мәгъсүм былбылым, оҗмахта үскән сөнбелем,
Килче, килче, бер үбимче, соңра уйнарсың, гөлем.

Күзләрең күзсенмәсен, мин сокланып туймыйм карап,
Ялтырый, уйный, шаян нур балкытып, гыйсмәт сәвап.

Ал гөлем син, тармагы гөлнең — кулың һәм бармагың,
Җәйге таңның ал нуры алган йөзеңнең ян-ягын.

Сөнбелем син: әйләнәндә ал күбәләкләр оча,
Күнлеңә күктән фәрештәләр инеп рәхмәт чәчә.

Нәп-нәни кызгылт телеңдә изге кошлар сайрыйлар,
Былбылым син, сайра, сайра, җилгә очсын кайгылар.

Кил, фәрештәм, килче, гыйсмәттән яралган сөнбелем,
Килче, килче, бер үбимче, соңра уйнарсың, гөлем.

Кил, сарыйм, иркәм, үзенне, кер кочакка, ямьләним.
Кит, карыйм күркәм күзеңне, кил, күзеңнән әйләним.

Мәгъсүм — керсез, саф.
Сөнбел — исле гөл (гиацинт).
Гыйсмәт — гөнаһсызлык.

1917

ХӘСРӘТ САГЫЗЫ

Шат вә шаркылдап көләлмим, көлкене куйган авыз;
Һәр авызда, белсәгез, гамьнән ясалган бер сагыз.

Ул сагыз «Ачлык! Сугыш!» атлы сүздән катыш,
Яндыра да, туңдыра да —ут белән боздан катыш...

Һәркайчан телдә: «Сугыш! Ачлык!» сүзе әйләндисә,
Һәм дә авызында сагыз урынында шул чәйнәлдисә —

Шаккатасың, дәһшәтеннән күз тона һәм сүз бетә,
Күкрәгеңне, бер ягын ут, бер ягын тоз әрнетә.

Ут синең иркеңне уйнаткан «тәбәссем»не ала,
Күзләреңнән нурлы шатлыкны җыеп, хәсрәт сала...

Боз синең шатлыкка тилмергән җаныңны туңдыра,
Дәртләреңне куркыныч хәсрәт төбенә чумдыра...

— Кич! —димен.— Ачлык! Сугыш!.. Син төш авыздан,
ут-сагыз!
Йә ала, мескен авызга тизрәк инде бал тамыз!..

. . . .

Йә алла! Мескен авызга тизрәк инде бал тамыз!..
Чөнки янган әүнебез һәм суга төшкән балтамыз!..

Тәбәссем — елмаю.

1917

КЫЗЫЛ ВӘГАЗЬ

* * *

Ярлы кеше! Сиңа дөнья хәрам төсле,
Инде син дә дөньяда тор адәм төсле!
Чыра булып чырай сытып йөрүчеләр,
Башкалар пумпайганда «кәбән» төсле!..

* * *

Бай кеше! Заман хәлен белгән яхшы,
Хәзер инде баеганнан да бөлгән яхшы!
Малыңның как яртысын — зәкят итеп,
«Милли шура» кассасына биргән яхшы!

* * *

Приказчик! Әгәр башың булса аек,
«Давай!» — диген, баеңа бак чекерәеп!
Баең бакса иңгерәеп, ташла да чык,
Магазины торсын, калсын сөмерәеп!

* * *

Син, мөхәррир, бай кәйфенә кол булгансың,
«Акча» дигән җәһәннәмгә убылгансың;
Кара көчне ак җилкәгә атландырып,
Хакыйкатьне бер яккарак сибергәнсең...

* * *

Мулла абзый! Ант итәмен чалмаң белән,
Ант итәмен күңлеңдәге аллаң белә;
Шәригатьне кырык якка тарткалыйсың
Күп вакытта «карман»дагы дәрман белән!

Пумпайганда — симергәндә; көрәйгәндә.

«Карман»дагы дәрман — кесәдәге акча барысын да эшли дигәнне аңлата.

* * *

Әй мөселман! Тәкъдиш итәм сабырыңны,
Син түзәсең, татар халкы кадереңне
Белмәсә дә: өзеп хәят тамырыңны,
Күз алдыңа китерсә дә кабереңне...

* * *

Мөфти хәзрәт! Бордык бугай койрыгыңны,
Тагын да бор!.. Шомартырсың җыерыгыңны;
«Кызыл»ларның арасында мөфти булгач,
«Кызыл-кызыл» бирдең бугай боерыгыңны!..

* * *

Әй мирза, керфек астың калыпайган,
Синең күздә күренәдер: «Татар хайван!»
Әйтимме? Бу кайдан килә? Ачуланма!
Күкрәгеңдә кяфер рухы тамыр җәйгән!..

* * *

«Социалист!» Бер сүз әйтим колагыңа:
Нигә кердең кадетларның флагына?
Кара, малай, адәм алдап йөрмә алай!
Сак бул аны, күсәк төшәр сыйрагыңа!..

* * *

Солдат кардәш! «Дин эшләрен беләм!» — димә,
Аңламыйча: «Җимерәм дә кырам!» — димә.
Дин эшләре тапшырылган үз урнына,
«Хатын-кызны мәҗлесләрдән куам!» — димә.

* * *

Артистларга сугышкалап торган яхшы,
Төрле-морлы су эчкәләп йөргән яхшы;
Домагыңнан ярты «әлеф» чыкмаса да,
Танавыңны баганага элгән яхшы!..

Хәят — тормыш.
Домагыңнан — авызыңнан.

* * *

Байбикә кем! Тәнең шәп вә саудыр бит?
Асрауларга җаның усал-асаудыр бит?
Бөтен фикрең — киенү дә ашаудыр бит?
Бөтен аңың — гайбәт чәйкәп яшәүдер бит?..

* * *

Әй туташлар! Сез йөрисез күңел кисеп,
Егет күңле сезгә төшеп тота гыйшык!
Мин фәкыйрь дә сезне мактап җырлап йөрим,
Шулай да кайберегез әллә... ничек?..

1917

ӘЙ БОЛЬШЕВИК!

Әй большевик, эшен кылдың һәр өяздә:
Яшен булдың, гөрзи булдың буржуазга,
Юлың имин, юлбашчың Ленин булса;
Кыр төлкене, ирек булсын үрдәк-казга!

1917

ӘЙ, ГАЙДАНИ!

Әй, юан корсак, нәзек аяк Гайдани,
Җилгә каршы борчак сибүдән файда ни?

1917

БУРЖУЙ!

Кып-кызыл каннар йөгергән күзләреңнең агына,
Күзләвең — корсак кына, сүзләрең — дөнья гына.

Социал димсең үзеңне, кып-кызыл, дип, маңгаем?
Ник кызыл ул? Чөнки имгәнсең фәкыйрьләр күз маең.

Ник кызыл каннан буялган күз төбеңнең керпеге?
— Юк синең күңлең төбендә тамчы шәфкать бөртеге.

Ник синең мәкъһүр калын ирнең кара-кучкыллана?
— Чөнки күңелеңдә фәкыйрьләргә ачу, мыскыл яна.

Шул көенчә син тагын булган буламсың социал?
Уң беләккә бәйләп алгансың кызылдан тастымал...

Мәкъһүр — каһәрле.

1917

ТУПРАК!

Тупрак безнең анабыз,
Без тупракка салабыз;
«Тупрак, тупрак, тупрак!»
Күкрәкдәге сәнабыз!..
Тупрак безнең атабыз,
Без тупракка ятабыз;
Тупрак кадрен аңламау —
Безнең өлкән хатабыз.
Тупрак өчен жанаек,
Тупракка шар салаек;
Үзебезнең анабызны
Үзебезгә алаек!..
Тупрак — башкорт бәхтедер,
Бәхтемезнең тәхтедер.
Тупрак калса, истикъбаль
Нурлы, рушан, яктыдыр:
Туар илгә батырлар,
Ак шоңкардай акынлар,
Арысландай айдарлар,
Әйләнеп үк кайтырлар...
Тупрак алсак — калабыз,
Бүтәнгә юк чарабыз.
Тупрак китсә — сау бул, дөнья!
Йотылмакдыр чамабыз...

Сәна — мактау.
Истикъбаль — киләчәк.

1917

СПИСОК № 9!

Ошбу көндә бер күпер алдындасыз — кылдан нәзек;
Куркыныч, бик куркыныч... Аһ! Китсәңез юлдан язып;
Ул күпер асты тәмугдыр, аръягында фирдәвес,
Кичсәгез ул күпердин, шадланып, рәхәтләнеп,
Тик фәкать башкорд өчен булган «пырак»ка атланып,
Башкалар биргән сарык, куйларга сез атлансагыз,—
Ант итәм: егълып төшәрсез, астқы катка капланып...
Нәрсә ул, сезне тәмугтан коткара торган пырак?
Ул пырагыңдыр тугызынчы нумерлы спискәң чырак?
Шул нумерга бир тавыш, алмакчы булсаң тупрак,
Юкса таушың читкә китсә — ямьле җирләр әлфирак!!.
Китсә җирләр, бел шуны: мәчед китәр, мәктәп китәр,
Ямьле башкорд илләрен чирмеш, урыс каплап китәр;
Йир сиңа, тик йир, дөньяң да йир, гыйкъбың да йир...
Йирдән айрылсаң, сине һәркем изеп, таптап китәр!..
И, туган башкорд, әгәр булмаска булсаң бәдбәхет,
Йирне сакла, йир кочакла, йир сиңа алтын тәхет...
Без тугыз кат әйтәбез: алдаучылар байтак булыр,
«Дин» диеб, «милләт» диеб майлаучылар да табылыр,
Тыңлама, алданма, башкорд, бир тавыш 9 чыга!
Шул вакыт йөз ак булыр һәм изге күңлең шад булыр.

Пырак — җәннәттә фантастик ат.
Әлфирак — аерылышу.
Гыйкаб — газаб.

1917

КАН ШӘҮЛӘЛӘРЕ

Күп зобанилар хисапсыз канлы арба тарталар...
Арбалар — утдан вә гөрзидән ясалган тәртәләр...

Йөз чытылган, тешләр ыржайган, кара көйгән ирен...
Күз төбендә кап-кара каннан оешкан арпалар...

Күр, әнә: ачлар ашыйлар, гүр казып, чергән мәет!
Сискәнә җан, чиркана тән һәм чымырдый аркалар...

Күр, әнә: инсан башыннан тау өелгән — баш тавы!
Як-ягында җабрылып очмакда козгын-каргалар...

Йирдә кан, каннан томан... күктә эленгән канлы кул!
Канлы кулда кан тамып торган коточкыч балта бар!..

Кан томанында йөзә мәнфур «үлем гыйфритләре»!
Бар да капкан аузына шомлы үләксә — мәйтәләр!..

Һәр офыктан ургылып, кайнап чыга утлы төтен!
Борла-сорла ажгырып, шуннан еланлар калкалар!..

Ул чыелдыйлар колакта бихисаб җен шымчысы!
Алгы көннән куркыныч, зур фаҗига аңгарталар...

Күрсәтә мең төрле төс, мең төрле эш бер лахзада,
Ләүхелмәхфузда тезелгән серле, тылсым карталар.

Инсан — кеше.
Мәнфур — нәфрәтле.
Мәйтәләр — мәетләр.
Лахза — күз ачып йомганчы.
Ләүхелмәхфуз — язмыш тактасы.

1917

СУГЫШ

Бу җәһәннәм, бу сугыш, бу канлы вәхшәт —ихтилал,
Җир, җиһан аст-өскә әйләнмичә бетмәс, ихтимал.

Күк йөзендә тын гына йөзмәктә йолдыз, ай, кояш,
Җир йөзендә зилзилә, дәһшәт, газап, кан, канлы яшь.

Әй, илаһи күбәләкләр, сөенәсез, кеткелдисез,
Җир тулы хәсрәт, газап, аһ, әллә сез һич белмисез?

Яшь сабыйкай, яшь сабый, син үсмә, кал, шул хәлчә кал!
Үсмә, дөнья бәхтенә кал, саф йөрәк, пакь җанча кал!

Җирдә шайтан — падишаһ, фәрман бирә: суй, кыр, кырыл!
Йә Мөхәммәт, кыл шәфәгать, мәркадеңнән тор, терел!

Ихтилал — бу урында «чуалыш» мәгънәсендә алынган.
Җиһан — дөнья.
Мәркад — кабер.

1917

ҮТКӘН КӨННӘР

Менә әле генә сахраларда
Яшь колындай чабып уйнадым;
Менә әле генә Сакмар буен
Яшь колындай чабып буйладым.

Менә әле генә чәчәкләрне,
Өзеп алып, айга кададым;
Менә әле генә, айга менеп,
Чәчәкләргә көлеп карадым.

Менә әле генә: кызыл гөлнең
Кызыл нурын сибәм йөземә;
Менә әле генә фирдәвестән
Урын алып төштем үземә!

Менә әле егълап, әле көлдем,
Әле көйдем, әле сызландым;
Менә әле җырлап, әле тындым,
Әле бар дөньясын кызгандым.

Менә әле генә, ләгънәт орып,
Таштым, шаштым, куптым «дулкындай»,
Әле гаффар булып, әле каһһар...
Холыкландым тәңрем холкындай.

Менә әле үзем һаман шушылай,
Һаман шушы минмен, һаман мин,
Күңел мең төрлегә талпынганда,
Көнем бертөрлегә янам мин!
(Ак уйларны таплап, җиргә каплап,
Вак хәсрәтләр өчен янам мин.)

Гаффар — ярлыкаучы.
Каһһар — каһәрләүче.

1917

* * *

Кулларымда кәкрә башлы,
Алтын кашлы мандолин.
Кайда җыр бар, кайда моң бар,—
Эзләсәгез, анда мин.

1917

* * *

Әйдә, бие, бабушка,
Бие, бездән калышма;
Спасибо, кергәнсең
Дөбердәгән тавышка!

1917

ЯШЬ ШАГЫЙРЬНЕҢ КАБЕР ТАШЫНДА УКЫДЫМ

Ваклыгы берлән җиһанның ваксынасым килмәде,
Ят үлемне каршы алдым, ятсынасым килмәде.

Дөньяда җанга тынычлык юклыгын белгәч тәмам,
Мин әле яшь дип, үлемнән тартынасым килмәде.

Тар кабернең куенына кердем, котылдым дөньядан,
Чөнки биздем дөньядан, артык торасым килмәде.

Яшьли үк кердем ләхеткә, киң түшәкне тарсынып,
Төп ятак булганга ләхетем, тарсынасым килмәде.

1917

МИНДӘ КӨЧ

(Мөтәшагыйрьләргә)

Миндә көч бар, мин сизәм бик,—
Миндә көчләр алласы.
Курка миннән түлке тычкан,
Үрмәкүчләр — һәммәсе.

Кырга чыксам — күрнешемдән
Карга, куянлар кача;
Күлдән үрдәк, балыклар,
Каз, саесканнаргача.

Янмаган бер шырпыны мин
Бер сызуда ут итәм,
Чынласам мин, бер сугуда
Бер чебенне юк итәм...

Кичә мин бер төш кисәген
Идәнгә алып җилләдем;
Зур итеп тиштем кырыен,
Бик матур су чүлмәген.

Шул каһарманлык өчен
Әнкәй мине бик мактады,—
Тал чыбык берлән, тотып,
Майлап пешерде арканы.

1917

ЗӨҺРӘГӘ

Әй, матур кыз Зөһрә-җан!
Мин сине күрәм кайчан?
Әй, Бибизөһрә, синҗа
Төште чын гыйшкым, ышан!

«Бик матур, бик ямьле»,— дип,
Мәрьям түтәй мактады.
Шул минуттан күңлемне
Мәхәббәтең каплады.

Күрмәсәм дә, күргән кебек,
Төште гыйшкың кальбемә.
«Зөһрә кызны насыйп ит»,— дип,
Дога кылдым тәңремә.

1917

ШӘМСЕКАМӘРГӘ

Әссәламәгайләйкүм, Шәмсекамәр,
Без исән-сау, башкача юк яна хәбәр;
Уңайлы вакытыңыз булыр микән,
Бүген кич сезнең якка барсак әгәр?
Бер төсле аккан көнгә ачу итеп
Сезгә барсак, азмы-күпме ачу канар,
Без баруга аулак булса, тыныч булса,—
Ул чакта өстегезгә рәхмәт явар!

1917

* * *

Кара бүрек бетә, диләр,—
Парлап алып калаек.
Байлар Себер кача, диләр,—
Типкәләштереп калаек.

1917

БАГЪБОСТАНДА

И илаһи килде дә керде борынга тәмле ис,
И газиз кич, ямьле кич һәм җанлы кич,
илһамлы кич.
Ямьле өстәл өстенә җәйгән матур ак эскәтер,
Эскәтер өстендә коймаклар нәфис ис искәтер.

«Эч, кунаклар!» — дип самавыр шатланып җырлап
тора,
Һәм дә Багъбостан йөзе илһамлы ай күк яктыра...

Алдымызда май белән баллар торалар: «Кап!» —
диеп,
Һәм Бабич та кычкыра: «Ныграк аша, Исхак!» —
диеп.

Ул матур кыз Сафия коймак ташый да чәй ясый,
Кып-кызыл алма кебек пешкән аның бит алмасы...

1917

ИСЕМНӘР БАКЧАСЫ

Башлангыч:
Каләмемә күңел җенен кагылдырган,
Тиле күңел... үз юлына абындырган,
Ике нәрсә: әүвәле алла, икенче кыз
Бәндәләрне кодрәтенә табындырган.

Мактаулар

Сара

Кашың кара, күзең кара, Сара туташ!
Күтәрелеп бичараңа кара, туташ!..
Синең өчен өзеләэчем көнен-кичен,
Ач үзәктә гыйшык уты яна, туташ!

Сәрвәр

Сәрвәр туташ! Алсу йөзең, күзең күркәм,
Тудыңмы әллә алсу нурлы җәйге иртән?
Күтәрелеп бер карарга кыя алмамын,
Сихерләнеп үләрмен дип куркам, иркәм.

Маһирә

И Маһирә, ходай биргән вәкарең бар;
Вәкарь белән матур итеп бакарың бар,
Ялкының бар, яндырыйм дип уйлаганда,
Туңдырсаң да үз кулыңда сәкарең бар!..

Нәфисә

Нәфисәгә сәлам нәфис җил аркылы,
Беләсез — уңган туташ һөнәр колы,
Шагыйрьләрнең күбесенә илһам килә
Сезнең кеби назлы, нәфис бил аркылы.

Вәкарь — үз-үзеңне тыя белү.
Бакар — карау.
Сәкарь — тәмуг.

Мәрьям

Ак күңелле, ачык йөзле Мәрьям туташ!
Исемеңне хөрмәт иткән аллаң, туташ!
Миң дә сине хөрмәт итәм, мәрхәмәт ит,
Синнән сорый мәҗрух йөрәк мәрһим, туташ,

Әсхабҗамал

Әсхабҗамал, нурың арта чәчкап белән,
Энҗе тезгән кечерәк кенә калфак белән;
Син охшыйсың күлдә йөзкән аккошларга,
Йөргәнең дә ак күлмәк, ак башмак белән.

Өммегөлсем

Сыйфатыңны тәүсыйф итәм, Өммегөлсем,
Үзәгенә былбыл кергән тере гөлсең,
Көчле йөрәк сине күрсен, ямьгә чумсын,
Түземсезләр үлгән хәлдә таңга керсен.

Өммикамал

Кәмаләтең биек синең, Өммикамал,
Җанны җанга тоташтырган син бер канал,
Тупас, надан сине күрсә, ул да әйтә:
«Нәгъләт икән, нинди чибәр монави мал!»

Бибиәсма

Таушың чишмә, телең тәмле, Бибиәсма,
Итәкләрең килешкән бу-буй тасма;
Гыйшык дигән дәрья булса, шул дәрьяда
Күңел савытын чайкар өчен син бер басма.

Өммелхәя

Кашың — җәя, керфегең — ук, Өммелхәя!..
Йөрәгемә угың керде! Мине ая!..
Аямадың, ташлап киттең әллә кая!
Ник ташладың?.. кая вәгъдә... кая хәя?..

Мәҗрух — яралы.
Мөрһим — дәва.
Тәүсыйф — тасвир.
Кәмаләт — һәр яктан да җитешкәнлек.
Хәя — оят.

Гамбәр

Мисек гамбәр исе аңкый, Гамбәр, синдә,
Күз алдыңны кочып торган ямь бар синдә,
Мәхәббәтле, эссе, көчле кан бар синдә,
Үз алдына очып торган җан бар синдә.

Сылубикә

Сылубикә, сылу туташ, кыз солтаны,
Бит уртанда кара миң бар — бит чулпаны;
Авызың зәм-зәм, ирнең кәүсәр, тешең гәүһәр,
Калку түшең — тигез җирдә сөт вулканы.

Хәят

Хәят туташ! Авызыңнан энҗе ява,
Синең белән бер сөйләшү дәрткә дәва;
Зәңгәр олы күзләреңне бер сирпесәң,
Бетте инде... бөтен адәм һуштан ава.

Мәймүнә

Мин, Мәймүнә дигәндә, мәймүн булам,
Туңган дәрья ташып китә, Сәйхун булам,
Гөжләп торган самоварның түбәсендә
Мин гүяки пар-бу кергән чәйгүн булам.

Зәйнәп

Зәйнәп туташ кара чәчен майлап тора,
Былбыл кебек, чәчкә тотып, сайрап тора,
«Ярты ай» күк, маңгаеның тирәсендә
Чәч бөртекләр дулкынланып, байнап тора.

Гөлгенә

Гөлгенәнең керфекләре гөл киенгән,
Ике күзе кичке тынык күл диелгән;
Ай, кояшның ак нурларын оялтырлык
Күзләренә чем карачкыл нур җыелган.

Мисек — мускус.
Мәймүн — маймыл.
Сәйхун — Сыр-Дәрья.

Мәгърифә

Мәгърифәкәй, синең төсең сокланырлык,
Нинди генә күңелгә дә тукланырлык;
Бик аз гына шадралык бар, булса булсын,
Зарары юк, кершән яксаң иплэнерлек.

Базаргөл

Әй Базаргөл, матурлыкта базарың бар,
Минем сиңа ике төрле назарым бар;
Ул симезлек, ул тигезлек биргән ходай,
Саклан, туташ, күп маташсаң, азарың бар.

Тугъзак

Тугъзак туташ! Син мөҗәссәм бизәк мәллә?
Мәхәббәтең көйдерәдер — дозах мәллә?
Сөюемне әйтим дисәм, тел бәйләнә,—
Ул күзләрең сихерле бер тозак мәллә?

Алтынкай

Алтынкайның яңа туган ай кашы бар,
Колагында бриллиант күк алкасы бар;
Кулларында — алтын йөзек бармак саен,
Чәчкә таккан чылтыр-чылтыр тәңкәсе бар.

Айзирәк

Айзирәк кыз — ай зирәк кыз, үткер теле,
Изгеләрдән изгерәктер, юктыр кере.
Күзләр тылсым, сүзләр әфсен, йөзе әфлисун,
Аның кеби оҗмахында юктыр хуры.

Җомгабикә

Җомгабикә, син җомга көн тугансыңдыр,
Кулларыңны мамык белән югансыңдыр;
Сәмавәттән бу дөньяга иңмәс борын
Хурлар белән нур тавында шугансыңдыр.

Назар — караш.
Мөҗәссәм — гәүдәләнгән.
Дозах — җәһәннәм, тәмуг.
Сәмавәт — күк дөньясы.

Миңлекәй

Ике якта ике миңе Миңлекәйнең,
Уртадагы карасы күк тулган айның;
Яман күздән тулган йөзне сулдырмаска,
Күктән иңгән сакчы алар бер ходайның.

Биксылу

Биксылу сылу була сыргасыз да,
Ефәк күлмәк, кырык итәк бөрмәсез дә;
Аның күзе туганнан ук сөрмәләнгән,
Керфекләре җем-җем итә сөрмәсез дә.

Аланкуа

Изге намың ишет, дисәм: Аланкуа,
Йөрәгемдә сиңа каршы сәлам туа,
Сөеп алып, сөеп барсаң — куаныч бар,
Бер дә шиксез «Чыңгыз» хандай бала туар.

Мәрҗәнбикә

«Мәрҗәнбикә», ирнең — мәрҗән, аузың — уймак,
Мөмкин түгел ул авызны үбеп туймак;
Уттан эссе, гөлдән исле кочагыңда
Ятсаң иде аузың үбеп, уйнап-уйнап.

Каләнфер

Әй, Каләнфер, көмеш димен тырнагыңны,
Каләнфернең сабагы дип бармагыңны,
Баскан җирең яшәреп һәм балкып калыр,—
Хозыр бабай өшкергәндер аягыңны.

Айдарсылу

Айдарсылу, маңгай чәчең айдарланган,
Күзләреңдә гыйшык буы кайнарланган,
Бу дөньяга син иңгәчтән, тәңресенә,
Миннән нурлы яраттың, дип ай зарланган.

Зөмөрд

Зөмөрд туташ зөмөрд тезгән муен буйлап,
Кызыл тамчы тамып тора ирен буйлап;

Сырга — алка.
Нам — исем, ат.

Күзләреннән шаян нурлар агып чыгып,
Ал йөзенә тараладар борын буйлап.

Алмагөл

Алмагөл, аһ, пешеп җиткән алмалы бит,
Иманлы бит, илһамлы бит, аллаһлы бит;
«Үп!» — диде дә үптермәде, күздән тайды,
Аһ, сихерче алмалы бит — алдады бит.

Рабига

Рабиганың матур тавышы моңлы, назлы,
Назы белән аулап ала ир-шаһбазны,
Сандугачлар аның назын мактап сайрый,
Аның өчен яраткандыр нурлы язны.

Гөлбәгыйдә

Бәгыйд түгел, гөлдән булса Гөлбәгыйдә,
Гөлгә бинзи кул вә бармак, тырнагы да;
Гөл багында гөл иясе кидергәндер —
Гөлдән теккән өстендәге күлмәге дә.

Саҗидә

Саҗидә бер кәрамәт саз шикелле,
Сазына миллион сәҗдә аз шикелле,
«Кәгъбә» итеп әйләнәсең әйләнәсең,
Барыбер ул алла кушкан хаҗ шикелле.

Хәдичә

Хәдичәнең исеме өстендә гөлләр үсә,
Кошлар сайрый, җилләр исә бер көлдисә:
Яңгырап чыккан ямьлек тавыш коча-коча,
Баш өстендә әрвах оча, ничә-ничә.

Мәгъфурә

Бар иде, аһ, Мәгъфүрәне күргән чаклар,
Мәхмүр күздән күңелгә рух өргән чаклар;

Ир-шаһбаз — ир-егет.
Бәгыйд — ерак.
Биңзәү — тиңләү, охшату.
Кәрамәт — яхшылык, кадер һәм хөрмәт.
Әрвах — рухлар.
Мәхмур — исергән, сихерләнгән.

Шул гүзәлне уйлый-уйлый истән таеп,
Ничә көннәр ашап-эчми йөргән чаклар.

Зифа

Зифа туташ, буең зифа — зелпенеке,
Арка чәчең чем-кара ял — елкыныкы;
Чү, чү... бакма! Күз укларың яман чәнчә,—
Бер якында торып торсын керпенеке.

Зөләйха

Әй Зөләйха, бер елмайсаң, исертәсең,
Бер минутта биш тундырып, биш эртәсең:
Бер як күзнең бер як кырын бер генә сал,—
Шул вакытта очыртасың, очыртасың.

Фирдәвес

Сорасаң Фирдәвесне, фирдәвеслек,
Тәүсифына сүз табалмый тиргә төштек.
Буе-сыны, кыйланышы әйтеп тора:
«Хурлар белән бергә тудык, бергә үстек».

Асия

Асиянең күңел бәхете көзгедән дә,
Син дә шулай булыйм дисәң, изге бәндә,
Туксан тугыз мәртәбә «алла» дигәч,
«Асия» дип кычкырып куй йөз дигәндә.

Һаҗәр

Һаҗәр туташ күктән җиргә һиҗрәт иткән,
Һиҗрәт итеп, матурлыкка хезмәт иткән;
Нурыннан безне мәхрүм калдырды, дип,
Артыннан фәрештәләр эзләп киткән.

Гөлнур

Гөлнур туташ, гөлең бар бит, нурың бар бит,
Күзеңдә «сүр», күкрәгеңдә «нурың» бар бит;
Сигез оҗмах каршысында синең белән
Җир мактанган: «Минем дә бер хурым бар!» — дип.

Тәүсиф — тасвирлау, сурәтләү.
Һиҗрәт — күчү.

1917

ҖЫРЛАР

Зиллим, зиллим, зилләтә, эссе булса тирләтә,
Суык булса туңдыра, давай безгә думбыра.
    Ак иделнең буйларын буйлаганым юк иде,
    Бу көннәрне күрермен дип уйлаганым юк иде.

Әйттер, типтер, сиптер, киптер, гомер үзебезнеке,
Җибәрсәләр җибәрсеннәр, Себер үзебезнеке.
    Ак иделнең буйларын буйлаганым юк иде,
    Бу көннәрне күрермен дип уйлаганым юк иде.

Скрипка имчүгең килештердем түгелме?
Әби белән бабайны үбештердем түгелме?
    Ак иделнең буйларын буйлаганым юк иде,
    Бу көннәрне күрермен дип уйлаганым юк иде...

1917

АФАРИН!

Афарин сезгә, ирек чулпаннары!
Афарин, чын изгелек солтаннары!
Бу карангы гүргә түнгән дөньяның
Көн вә көн атмакта чын таңнары.
Афарин, их... дөньяга шатлык кылә,
Юыла золмәт, елмаеп аклык кылә;
Җимерелә вәхшәт, хаксызлык, золым;
Акрын-акрын нур чәчеп хаклык кылә.
Шатланам мин, күкрәгем ташкан кебек,
Түзалмый, сикеренәм, шашкан кебек.

Афарин, әй, сезгә миллион афарин;
Нурлы истикъбаль якынлашкан кебек!

Истикъбаль — киләчәк.

1917

* * *

Уйлап, уйлап, уйга чумсаң,
Онтыла җан шатлыгы,
Җан арый... Ләгънәт сиңа,
Ләгънәт, адәмнең ваклыгы!..

. . . .

Ак уйларны таптап, җиргә каплап,
Вак хәсрәтләр өчен янам мин.

1917

* * *

Диңгезләрне чайкап дулкынлаткан —
Әй, кодрәтле диңгез патшасы!
Дулкынланып, мин дә дәрт-гайрәттән,
Диңгез кебек күкрәк каксамчы!

1917

* * *

Намус өчен, тәңрем, җаннар кисәм,
Китер вәгъдә, кодрәт-кулың бир!
Фәкыйрәләр тыныч кала, дисәң,
Бер җаныма миллион үлем бир!

1918

* * *

Барган идем стансага,
Стансаны ут алган.
Әллә ни булды дөньяга,—
Асты-өсте буталган.

1918

ГЫЙШЫК

Чын мәхәббәт, чын гыйшыктыр —
Чын илаһтан чын бүләк;
Чын гыйшыкка чын бишектер
Җем-җем иткән шом йөрәк.
Чын гыйшык — вөҗданга сеңгән
Нурани серле шәраб;
Дөньяның бар ямь-тәме шул,
Үзгә ямьнәр — буш шәраб.

Чын гашыйк — мәгъшука өчен
Мәҗнүн вә мәфтүндер җаны,
Шигъри ут кәфене белән
Күңелендә мәдфүндер җаны.
Бер тәбәссем — ак пырактыр,
Дәрт, өметләрдер сират;
Кавышу бәһшәттер, ләкин
Дәһшәт җәһәннәмдер фирак.

Нурани — нурлана торган.
Мәгъшука — сөелгән хатын-кыз.
Мәфтүндер — сихерләнгән.
Мәфүндер — күмелгән, яшерелгән.
Тәбәссем — елмаю.
Пырак — толпар.
Бәһшәт — оҗмах.
Фирак — аерылышу.

1918

НИ ЭШЛИ?

Котлы Әхмәт киң яланда мал карый,
Бетле Әбҗәй ат янында ял тарый,
Староста Абсаттар, сотник Вәли
Өйдән-өйгә йөгрә-йөгрә бал карый.

Бакчаның тар тыкрыгында кич белән
Ниндидер бер «мал» карый Әкмәл кари,
Нәкъ көтү кайткан вакытта ак кәҗә
Бәдри хәзрәт ырзыныннан тал карый.

Нигә син ялгыз гына монда, туташ?
Һа!.. Имеш, ул су янында сал карый!
Юлый куштан, ыштаның җилбердәтеп,
Ызгышырга көн дә бер җәнҗал карый.

Яшь бикәчкә — Гөлҗамалга аптыраш:
Ак, кызыл, күк, ал, сары бер шәл карый.

Чыкты көн, сүнде йолдызның нуры,
Тик чыгып сызган иде Баттал агай:
Инде кемгә тапшырам «Йолдыз»ны? дип,
Фәсле агай чардагыннан фал карый.

1918

ИКЕНЧЕ ГЫЙНВАР КӨНЕ

Бүгенге көн мин тудым,
Җыламыйча тын тудым,
Истигъдаттан, зәкандән —
Һәркайсыннан ким тудым.

Гомрем үтте биккәрәк,
Буш җил кудым да кудым,
Тудым, үстем, зур булдым,
Ник яралдым: ник тудым?

Истигъдат — эшкә яраклылык, сәләтлелек.
Зәкандән — зиһеннән, акылдан.

1918

БАЙРАМ

Байрамкаең, башкорд, котты булһын,
Шатдык менән тулһын йөрәгең;

Бер алланнан һора: изге көндә
Кабул кыл, тип, башкорд теләген!

Теләй күрең, юсык, кустыларым:
Башкорд халкы бәйдән сыксын! — тип;

Ирек алган иркен далаһында
Куанысман байрам итһен! — тип.

Куанысман — «куаныс менән» сүзтезмәсенең кыскартылган варианты.

1918

ҠУРАЙҠАЙГА

Сызгырт, курай, үткән кайгыларны,
Өздерт, курай, йөрәккәй кылларын;
Сиздерт, курай, кайнар тойгыларны,
Сөйдерт, сөйләп башкорд моңнарын...
    Сөйлә Сакмар, Җаек, Ашказарны,
    Сөйлә ямьле Урал буйларын;
    Сөйлә оҗмах кебек сахраларны,
    Җәйлеп яткан елкы, куйларны...
Сөйлә, җәйләүләрдә җәйне җәйләп,
Кырдан-кырга күчеп кунуны;
Сөйлә, кашмау киеп, челтәр бәйләп,
Кырда җырлап йөргән сылуны!..
    Сөйлә җилбердәгән таллыкларны,
    Шылтрап аккан чишмә буенда;
    Сөйлә күбәләкләр, бал кортларны,
    Уйнап үскән чәчкә куйнында...
Сөйлә тарихыңдан, яуларыңдан,
Сөйлә канлы башкорд боласын;
Сөйлә олатайлар хәлдәреннән:
Йөреш, торыш, заңын, йоласын!..

* * *

    Буын-буын гомер Башкордостан
    Сугарылды кара кан белән:
    Чыктык кара көчтән — канны эчкән,
    Сугарылсын инде ямь беләң...
Яугир ирләремез ничә заман
Ак тирмәдә кылыч кайрады;
Шалтыр-шылтыр чыңлап савыт-айман,
Өстемездә сөңге җайнады.
    Ничә заман, бахыр курайкаем,
    Газиз илнең җырын җырладың;
    Күпме кыен күреп, күпме ваем,
    Үксеп-үксеп өзелеп егъладың!..

Килде заман, инде шатлан, курай!
Ямьле таушың илгә яңрасын! —
Куанып китсен урман, сахра, тугай,
Бүз тургайлар куанып сайрасын!..
Уйна, курай, күктән ямь шауласын,
Нур җайнасын башлар өстендә!
Ямь яктысы җуйсын кан шәүләсен,
Гөлләр үссен ташлар өстендә!..
Күкерәтеп, гүләп, сайрап, өзлеп,
Килде, курай, уйнар мизгелең;
Якты уйлар салып, дәртең кузгап,
Күккә ашыр йөрәкләр сизгерен...

1918

ГАСКӘР МАРШЫ

(«Эскадрон» көенә)

Таярмыз без Ватан фәрманына
Чын ихласны биреп, баш орып;
Туган илемезнең корбанына
Җанны-тәнне сөйнеп тапшырып.

Илемез — түшәк, йиремез — караватдай,
Кары-бозы — эссе юргандай;
Түземлебез батыр Салаватдай,
Күкрәк гайрәт берлән тулгандай...

Утлы беләк безнең утын якса,
Кибәр төсле Өлкән Диңгез дә;
Ныклы беләк безнең угын атса,
Тияр төсле чулпан йолдызга!..

Без йөримез илне саклыймыз дип,
Саклармыз һәм Башкордостанны;
Туракларбыз, «Илне таптыймыз!» — дип,
Каршы килгән явыз дошманны!..

Илкәй өчен чыксын газиз җанлар,
Кунсын шәһид рухлар талына;
Халәл йиргә аксын халәл канлар,
Бабаларның каны янына...

Безләр гаскәр, әйдә, алга марш!
Тетрәп торсын йир, күк-асманы...
Без — арыслан, без бит һәм юлбарыс,
Яңа Башкордостан гаскәре...

Фәрман — боерык.
Шәһид — хак эше өчен сугышта үлүче.

1918

БАШКОРДОСТАН

> Башкордостан — гөлбостан,
> Сөнбелстан, нурбостан;
> Шунда туган, шунда үскән
> Башкорд атлы арыслан!

Арысланлар үз йирен —
Залимнәрдән таптатмас,
Таптаймын дип атласа,—
Башкорд каны атлатмас;
Ил өстенә чапкан яу
Башкорд җанын какшатмас,
Пычрак табан астында
Башкорд намусы ятмас!..
    Башкордостан — гөлбостан,
    Былбылыстан, нурбостан;
    Шунда туган, шунда үскән
    Башкорд угълы арыслан!
Башкордостан бакчасы —
Арысланнар торган йир;
Арысланнар бабасы —
Каһарманнар йөргән йир;
Каһарманнар гәүдәсен
Кочаклаган, күмгән йир;
Хәләл канлар шәүләсен
Күккә тәрсим кылган йир!
    Башкордостан — нурбостан,
    Рәйханстан, гөлбостан;
    Шунда туган, шунда үскән
    Башкорд дигән арыслан!
Башкорд халкы тарихта
Гайрәт берлән фаш булган;
Киң иреккә ашкынган —
Күңлендәге ташкыннан,
Һәрвакытта намусын
Үз башына баш кылган;

Тәрсим кылу — сурәтләндерү.

Туган илен саклауга
Үзе булган таш курган!
  Башкордостан — гөлбостан,
  Сөнбелстан, нурбостан;
  Шунда туган, шунда үскән
  Башкорд дигән арыслан!..
Көчле намус, ташкын җан
Торды, тагын калкынды;
Тагын башкорд халкында
Иске ялкын балкыды;
Мең җәһәннәм тудырыр
Бер башкордның ялкыны!
Миллион оҗмах яратыр
Бер Уралның алтыны!!.
    Башкордостан — нурбостан,
    Рәйханстан, гөлбостан,
    Шунда туган, шунда үскән
    Башкорд угълы арыслан!..
Уралкайның асты алтын,
Өсте шигырь, үзе нур;
Киләчәктә бу йиргә
Ходай үзе кызыгыр!..
Фирдәвесләр төзелер,
Әлуан нигъмәт тезелер...
Күкне ташлап, мәләкләр
Бу җирләрдә гизенер!..
    Башкордостан — ямьбостан,
    Илһамстан, шигърстан.
    Шунда туган, шунда үскән
    Башкорд намлы арыслан!
Куан, аңлап, әй Ватан,
Без аңладык хәлеңне;
Сине салып кулбашка,
Без йөкләдек гамеңне.
Гареш эгълә өстенә
Мендерербез даныңны!
Без фидаи синеңчөн,—
Яшәтербез намыңны!
    Башкордостан яшәсен!
    Сөнбелстан яшәсен!
    Шунда туып, шунда үскән
    Арысланнар яшәсен!..

Әлуан нигъмәт — төрле азык, байлык.
Нам — исем, ат.
Гареш эгълә өстенә — югары дәрәҗәгә.
Фидаи — корбан.

1918

САЛАУАТ БАТЫР

(Үз көе белән)

Салауат нисә яшендә?
Салауат нисә яшендә?
Егерме өс яшендә...
Яшел бүрке башында...

(Халык җырыннан.)

Салауат кандай пәһлуан,
Салауат кандай пәһлуан;
Даусан, яусан пәһлуан,
Еңелмәүсән пәһлуан.

Салауат тиңһез арыслан,
Салауат тиңһез арыслан;
Арысландай алышкан,
Угы алган алыстан.

Салауат — Урал балаһы,
Салауат — йөрәк кабәһе!
Йирдә әннүр гәүдәһе,
Күкдә зәңгәр шәүләһе!

Салауат даузы кайтарган,
Салауат яузы айкаган;
Кылысы таузы актарган!
Таушыннан күл сайкалган!..

Салауат — янлы шәҗәгать,
Салауат мәнге сәламәт!
Каны безгә амәнәт,
Китермәбез яман ат!..

Кандай — нинди.
Алыс — ерак.
Әннүр — нурлы.
Шәҗәгать — батырлык.

1918

КӨТМӘСДӘН

Уйламасдан, көтмәсдән,
Шәйләмәсдән-нитмәсдән:
Башкордостан буенда
Урманында, кырында,
Үзәгендә, сыртында,
Култыгында, чокрында;
Тау астында, өстендә,
Күкрәгендә, түшендә;
Тугайлыкда, шарлакда,
Каенлыкда, таллыкда;
Су буенда, елгада,
Камышлыкда, күлләрдә...
Бик кинәтдән, көтмәсдән
Бер дә сизмәс-нитмәсдән
Булды бик зур үзгәреш,
Ямьле шатлык-кузгалыш:
Кыйбла яктан җил исте,
Тулкынланды күл өсте;
Бар агачлар шаулашты,
Сәламләште, саулашты;
Сөенеп торды үләнләр,
Яшел бәрхет чирәмләр;
Гөл-чәчәкләр ачылды,
Хуш исләре сачелде;
Тау буйлары алланды,
Бер илаһи ямьләнде...
Тугайлыклар яшәрде,
Нур бизәнде, ясанды;
Урман эче гөрләде,
Яфраклары җырлады;
Сулар шарлап көлделәр,
Ташлар уйнап йөрделәр!
Урал тавы сөенде,
Өстенә нур коелды;
Фәрештәләр төштеләр,

Урал өстен кочтылар,
Кыр бәйрәмен күрделәр,
«Бу нинди туй? — диделәр.
Җавап килде сәмадан,
Катыр мотлак алладан:
«Бошкорд халкы терелде,
Терелү суры өрелде!..»
Фирештәләр, сөйнешеп,
Җырлап китделәр очып:
«Башкордостан яшәсен!
Башкорд күрсен сафасын!..»

Сәма — күк.
Сур — быргы, сигнал.
Сафа — рәхәтлек, кайгысызлык.

1918

ИКЕ АККОШ

(Тәмсил)

Күк кабагы ачылган бер нурлы төндә
Күренде ике аккош көньягында;
Төштеләр каңгылдашып очып барып,
Зәңгәр офык астындагы серле күлгә.
　　Күл әйтде: «Кошкайларым, хуш килдеңез,
　　Күп еллар аерылышып, буш кылдыңыз...
　　Сөенеңез инде, кошлар, очыныңыз;
　　Максудка менә тагы кушылдыңыз...»
Вә ләкин шайтан корган сихер белән,
Күл икегә бүленгән уртасыннан...
Ике аккош максудка кушылса да,
Күлемез кушылмас, дип, курка шуннан.
　　Ике аккош ике якда, күккә карап,
　　Бергәләп җырладылар кагып канат!
　　Сылу кыз — күл пәрие — судан чыгып,
　　Җырларын тыңлап торды, чәчен тарап.
Шынрагач аккошларның тавышлары,
Җил килеп күлгә нидер тавышлады...
Биткәен җыерчыклап, күл җылмайды,
Баш иде читендәге камышларга...
　　Камыш әйтде: «Сөенче бар җил бабайдан,
　　Җил бабай алып килгән бер ходайдан:
　　Гарешдә теләгеңез кабул булган,
　　Ачылыр сезгә тиндән якты мәйдан...»
Аккошлар шатлык белән кабындылар,
Су сирпешеп бер-беренә, кагындылар...
Күлдән чөйгән тамчылары өскә менгәч,
Ай нурында бер-беренә сарылдылар...
　　Ике тамчы бер булды, нур катышып,
　　Ике йөрәк бер булды, юлга төшеп;
　　Тамчылар энҗе булып кире тамды,
　　Ай нуры уйнап торды, күлгә төшеп...

Гареш — биек урын.

Нурлы ай: «Төн вакыты узды,— диде,—
Сандугач таң мәкамен суздың,— диде,—
Мин китәм, шәм булуга караңгыда,
Кояш атам карар инде сезне»,— диде.
Ай китде, таң нурланды, кояш чыкты...
Дөньяга һәм аңкытты, нур балкытты.
Камышлык арасыннан ике яклап
Аккошлар күлне буйлап йөзеп китте...
Ходаем мәдәд бирсен аякларга,
Бер максадка талпынган канатларга!
Арадагы шайтан тавын җимерсен, дип,
Илаһи фәрман чыксын мәләкләргә!..

Мәкам — җыр.
Мәдәд — ярдәм.
Мәләкләр — фәрештәләр.

1918

КҮЗЕҢНЕ АЧ!

Күзеңне ач, егет, бул каһарман,
Зәһәр сачеп ажгыр, каһәрлән!
Күр, илеңне ялмап һәр ягыннан
Дөрләп янып килә җәһәннәм!..

Җәһәннәмдән кайнап, ташып, күпереп,
Калкып тора уттан болытлар;
Сабый бала төсле ярсып, үкереп,
Йирдә егълай мескен «өмид»ләр!..

Ялкын сибеп, кызыл күмер сачеп,
Ут яңгыры ява, бөркелә...
Җәһәннәмдән чыккан убыр карчык:
Йирне йотам, диеп йилкенә!..

Болыт читләрендә җылан, чаян,
Ялкын чәйнәп тора, асылынып...
Шуны күрмәс өчен шәфкать-иман
Әллә кайда ята яшеренеп!..

Зобанилар, селтәп гөрзи-чукмар,
Болытларны бутый, куерта...
Ут эченнән чүпләп, вәхши кошлар
Безнең өскә «үлем» ыргыта!..

Сарыла йиргә ялкын һәр офыктан...
Ут суырыла, дөнья куырыла...
Өермәләр ясап кызыл уттан,
Әҗәл шайтаннары өерелә.
Саф һаваны ялкын ашап төшә,
Ут сулыйсың һава урнына...
Янә ялкын төшә, янә оча,
Янә кайный, янә ургыла...

* * *

Мәңге сүнмәс, ахры, бу җәһәннәм,
Һаман янар, һаман кыздырыр...
Газиз илең синең, әй каһарман,
Һаман ауыр көнләр уздырыр!..

Һич кайгырма, шатлан әүвәлгечә!
Бәхет йинәр әле, иншалла;
Җәһәннәмләр аша узмаенча,
Оҗмах табармыз дип ышанма!..

1918

ШӘФКАТЕМ

(Йөрәгем бүләге)

Алланың киң рәхмәтенә тиң минем киң шәфкатем!
Күрсәтә шул шәфкатем ләззәт итеп йир ләгънәтен!

Күкрәгемнең михрабында утыра шәфкать яндырып,
Нурлы шәфкәтьтән яралган бер мәләктәй саф катын!..

Эссе шәфкатьләр түгә ул бәгъремә, кән-тән җылап,
Балкыта күңлемне шәфкатьтән бизәкләп, энҗеләп...

Сүндерер ләза утын күңлемдә шәфкать яшьләре!
Бар зобанилар оялгандан торырлар кул бәйләб!

Кил, җылан, кил, эстәсәң дәһшәт, зәһәр ләгънәт
белән!
Ләгънәтеңне егълатырмын мин, сөеп шәфкать белән.

Мин чыдармын,— кил, туган, балтаң белән сук, ор, янеч;
Мин көләрмен — төрт озын сәңгеңне — күкрәкне чәнеч!

Ул озын сөңгең очын күкрәк үбәр, сөйнеп кабар;
Күз яшем, сәңгедәге канны ялап, йиргә тамар...

Күз яшемдән канлы сөңгендә кызыл нур ялтырар...
Кулларым киң шәфкатем каршында тетрәп калтырар...

Йиргә тамган күз яшемдән илгә балкыр күк чәчәк;
Ул чәчәкләр күккә очкан җаныма ямь сирпәчәк...

Таш бәгырь! Кил, миндән ал аткан ташыңны аш итеп!
Вөҗданыңны нурлар ул — бәгъреңдә йөрт алмас итеп!..

Дәрья төсле киң, тирән, төпсез, офыксыз шәфкатем...
Ул җуяр барлык залимнең золмәтен һәм вәхшәтен!..

Михраб — изге урын мәгънәсендә.
Ләза — рух рәхәтлеге.
Золмәт — караңгылык.

1918

ДОШМАННАР

Тыш яктан җылмаелап, дошманнар
Төшкәннәр без төшкән юл белән;
Язык лы, ләгънәтле кул белән
Без кочкан «бала»ны кочканнар...

Кочалар без кочкан баланы,
Үбәләр зәкъкумле авызлар...
Күптәнме әле ул явызлар
Типтеләр вөҗданны, иманны?..

Алданма, ак күңел башкордым!
Ялатма җыланны куеныңа!
Сарылып мәлгуньнәр муеныңа,
Башыңны мәҗырлар акыртын.

Куя тор киңлекне, аклыкны!
Кара бул, зәһәр бул дошманга;
Сер бирмә сыналган куштанга!
Башыңа «бөтү» кыл сагълыкны!..

Дөньяның тылсымлы тәхтендә
Ошбу көн «интикам», падишаһ!
Падишаһ: «Үченне ал!» — дисә,
Алып кал, алырлык вактында...

Юк, оят... үч алу — зур гөнаһ!
Гафу ит, бу — минем вәсвәсәм.
Азгыннар юлына басмасаң,
Тыныч бул! Ярдәмчең бер алла...

Зәкъкум — ачы, зәһәр.

1918

ЯЗГЫ ҖЫР

Утырдым мин тауның күкрәгенә;
Җырлар язам, җилкәй, исми тор!
Чишмәкәй! Тып! Әкрен!.. Чү! Шаулама!
Үткән гомерем, искә төшми тор!

Челтерәп аккан чишмә буйларында,
Аһ, мин йөрдем былтыр кем белән?
Шул чакларны, чишмә, алып актың...
Калдым сыкрап авыр моң белән!..

Җырлар язам тауның күкрәгендә;
Зинһар димен, җилкәй, исми тор!
Йомыл, гөлкәй, йомыл бер минутка —
Минем күзләремә төшми тор!

Аһ, чәчәкләр, былтыр сезне өзеп,
Кемнең күкрәгенә кададым,
Кемгә кадап, кемгә моңлы карап,
Күзләреннән җавап арадым?

Ни диде ул күзләр? Әй чәчәкләр,
Күрдегезме серле күзләрен?
Кем иде ул, тетрәп хозурында,
Ак кулларын сорап тезләндем?..

Җырлар язам тауның күкрәгендә;
Кодрәтле җил! Әкрен, исми тор!
Сандугачкай! Назлым, куй, сайрама!
Сайрап, яшь бәгырьне кисми тор!

Исеңдәме, былбыл, үткән язда
Син сайраган агач төбендә,
Кем иде ул шунда — кочагымда —
Ай балкыган язның төнендә?

Арадым — көттем.

Котлы булсын айлы төннәр, диеп,
Син бит безне котлап сайрадың;
Син бит шунда, сикереп ботак саен,
Кунар өчен урын сайладың.

Син идең бит апың күкрәк серен,
Сайрап-сайрап миңа белдергән;
Ул кайнаткан минем күкрәк җырын,
Сайрап-сайрап айга мендергән...

Кем иде ул шунда — ай битеннән
Минем җырларымны укыган?
Кем, тирбәнеп минем күкрәгемдә,
Уянып торды таңда йокыдан?

Җырлар язам тауның күкрәгендә;
Тау күкрәге серем белсен дип,
Гөлләр сирпеп язган җырларымны
Күкрәгендә саклап торсын дип.

Тыңлаңызчы, кошлар, җырларымны,
Тыңласагыз, сезгә җырлармын!
Сез сайрарсыз, соңра мин тыңлармын,
Тыңлап, үксеп-үксеп еглармын!..

1918

ЮК...

Атладым — эз юк,
Бакмадым — йөз юк,
Чатнадым — кыз юк.
Яшьлектән ләззәт
Тапмадым, тоз юк...

1918

ЮК...

(вариант)

Атладым эзсез,
Тапмадым йолдыз;
Бозланып күңлем,
Чатнадым кызсыз;
Үтте яшь гомрем
Ләззәтсез, тозсыз...

1918

ШАГЫЙРЬ БАШЫ

Күзне ачтырмый буран,—
Яфрак кадәрле кар ява.
Фу, каһәр, чәч тузгыган,—
Тырнак тидерсәң, бет ява...

Бет ява, бет — унлап-унлап
Укмашып, йөзләп була;
Укмашып, чәч төбендә
Гөж килеп, выжлап тора...

1918

ХӘСРӘТЛЕ ҖЫРЛАР

Алтын алка авыр тарта,
Алты мыскылдан арта.
Җырласак та, уйнасак та,
Һаман хәсрәтләр арта.

Онытам мин эшләремне,
Таратам һушларымны,
Адашкан коштай моңаям,
Югалтсам дусларымны.

Авылыгыз якын икән,
Урамы такыр микән?
Кызларыгыз матур икән,
Йөрәккә ятыр микән?

1918

УҢ АЯГЫМ БЕЛӘН СУЛ АЯГЫМ

Уң аягым тарта китәргә дип,
Сул аягым тарта калырга.
Башым катты шулай уйлый-уйлый,
Кайсы якны сайлап алырга?

1918

КИТЕР

Тәрилкәгә күмәчеңне өеп китер,
«Бабич агай, ашап бетер»,— диеп китер.

Китергәндә җырлап китер, биеп китер.
Шәйх агай ашасын дип, сөеп китер.

1918

* * *

Исә җилләр, өерелә болытлар,
Әллә давыл, әллә явынга?
Белми беркем, күпме чайкалырлар
Безнең башлар юлда, давылда?..

1918

БЕЗ

Без үзебез — башкорттар,
Күп ыруга бащ йорттар.
Беззә гәүһәр, беззә йәүһәр,
Беззә һәрбер ашлыктар.

Беззә тиңһез сахралар,
Сахралар — ожмах улар;
Унда гөлдәр тирбәнеп,
Ямьләнергә сакыралар.

Унда коштар һайраша,
Күлдә камыш шаулаша.
Камыш буе әрүшә,
Тамаша, эй, тамаша.

Беззә калын урмандар,
Беззә данлы Урал бар;
Урал асты алтындыр,
Өстә шәфәкъ балкыйдыр.

Һизен, башкорт, бәхтенде,
Төшен, башкорт, артынды,
Күрер өсен тәхтенде,
Истикъбалең алтынлы.

1919

БОЛЬШЕВИКТӘР БЕЛӘН КИЛЕШҮ ТУРАЛЫ БАШКОРТ ХАЛКЫНА КӨЙЛЕ ХИТАП

1

Башкорт намусына пычрак таштап
Юрый кайбер битһез, иманһыз;
Әйтә алар: «Дутов яклы булып,
Кара, пычрак юлны куганһыз!»

Менә хәзер дөнья алмашынды,
Һәр эш түнкәрелде аслына;
Без кушылдык якты, хөрлек якка,—
Дутов кайтты кара нәсленә!

2

Без кушылдык кызыл тарафына,
Кызыл беззең яклы булганга;
Азат Башкордостан җөмһүрлеген
Таныймын тип хуплап торганга.

Без кушылдык хәзер кызылдарга,—
Беззең өсен лаек шул булгас;
Нигә кушылмаска кызылдарга,
Күптән көтеп торган юл булгас.

Нигә без касмыйк ти шул Дутовтан,
Дутов юыртып киткәс уң яктан?
Нигә ярашмаска большевик белән,
Беззең һукмак киткәс һул яктан?!

Большевиктәр әйтә: «Бу дөньяда
Ярлы халык хөкеме йөрһен, тип;
Ярлы эшселәрнең хас дошманы —
Буржуйларның тамыры корһын!» — тип.

Җөмһүрлек — республикачылык.

Дутов-Колчак әйтә: «Эш башына
Алтын таҗлы батша менһен,— тип;
Батша менеп, һаман Николайдай
Ярлыларның канын имһен!»— тип.

Большевикар әйтә: «Коллык бетһен,
Ярлы халык рәхәт яшәһен;
Ирек көне туып бу дөньяга,
Тигез, якты көндәр яшәһен!»

Дутов-Колчак әйтә: «Закондарны
Бай-бәтсәләр язып торһын, тип;
Ярлы, эшче халык әүвәлгечә
Бай-бәтсәгә хезмәт кылһын!» — тип.

Большевиктәр әйтә: «Нәсел-нәсәп,
Түрәлекнең поты бер тин, тип;
«Калын йилкә» белән «ярылган кул»
Көнкүрештә булһын бер тиң,— тип.

Дутов-Колчак әйтә: «Йергә, күккә
Хуҗа булһын фәкать батша,— тип;
Мөселманнар һаман изелһен,— ти,
Батшаныкы гына дөрест!» — ти.

Большевиктәр әйтә: «Һәрбер илгә
Камил мохтарият бирелһен!
Һәрбер ярлы, мәзлум, изелгән ил
Мохтарият алһын, терелһен!»

Дутов-Колчак әйтә: «Вак милләтләр
«Мохтарият» ала күрмәһен!
Патша кул астында гомер сөреп,
Буржуаздар йырын йырлаһын!»

Уйлап кара, башкорт, акылың белән:
Кайһы тараф һиңә хәерле?
Әнә теге яман Дутовлармы?
Әллә большевикмы хәерле?

Бер дә шикһез һинең акылың әйтер:
Большевиктәр юлы хәер, тип;
Йәнең теләр шунда: «И ходаем!
Дутовлардан мәңге аер!» — тип.

Камил мохтарият — тулы автономия.
Мәзлум — изелгән, җәберләнгән.

3

Бер без генә түгел, бик күпләрне
Ышандырды Дутов бер сакта;
Себер якта залим Колчак сыккас,
Кушылды ла китте Колчакка!

Дутов төсен аскас, Халык явы *
Большевикка барып кушылды...
Дутов-Колчакларның юлын күреп
Чех-словаклар да пошынды.

Колчак сыккас, Дутов серен аскас,
Барлык социалист партия
Изге ихтилалның хөрмәтенә
Тагылдылар кызыл артына!

Шулай итеп, Дутов-Колчаклардан
Халык күңеле тәмам һуынды,
Был икәүгә каршы һугышу өсен
Кызылдарга барып һыенды.

Ике залим ситтән ярдәм һорап,
Союзниккә атты күзләрен;
Союзниктәр: «Һезгә гаскәр юк», — тип,
Аңлаттылар һуңгы һүздәрен.

Шул сәбәптән хәзер Дутов-Колчак,
Белмим, инде нихәл итәрләр?
Нихәл итсен инде, мәгълүм хәлләр:
Тиздән җәһәннәмгә китәрләр.

4

Башкорт халкын элек аңламастан:
«Гакес инкилабсы» тинеләр;
Батша утыртырга тели торган
Кара көсләр яклы, тинеләр,

Белһен улар беззең башкорттарның
«Гакес инкилабсы» түгелен;
Укыһындар башкорт тарихтарын,
Шунда күрер башкорт күңелен!

---

* *Халык явы* — народная армия (*Ш. Бабич искәрмәсе*). *Гакес инкыйлабсы* — шакшы бунтарь мәгънәсендә.

Шунда күрер, башкорт борыннан ук
Инкыйлабсы булып килгәнен;
Залим түрәләргә башын бирмәй,
Ирек өсен һугыш кылганын.

Белүп торың — беззәр борындан ук
Кара көскә яман каршы инек;
Беззең үткәндәге каһармандар —
Заманына күрә — большевик!

Беззең Абыз, Акай, Салауатлар,
Кара һакал, Айдар, Күсимдәр,—
Болар бар да кара төскә каршы
Һугышып үлгән алтын исемдәр!

Ирек өсен, азат илкәй өсен,
Борындан ук килдек кырылып,
Урыс менән нисә, нисә елдар
Һугыщып барып, көскә бирелдек.

Урыс кыскас беззе шытырдатып,
Маиләттән сыктык, изелдек,
Йер тарайды беззең, ил карайды,
Әдәм күрмәгәнде без күрдек.

Инде моңау форсат вакыт килгәс,
Башкорт халкы йоклап ятһынмы? —
Иле өсен һугышып шәһид булган
Олатайлар исемен һатһынмы?..

Юк, һатманы башкорт иске исмен,
Атылып килеп сыкты майданга!
«Мин — башкорт!» — тип шунда һөрәнләгәс,
Мәгъруур халык калды хайранга.

Бушка сыкты барлык явыз фикер,
Башкорт халкы үзен таныттй.
«Азат Башкортостан» туын алып,
Кара көскә каршы калыкты!

Ирек колы — башкорт, шулай булгас,
Дутов-Колчак яклы булырмы?

Маилэт — мөстәкыйльлек.
Шәһид булу — изге эш өчен корбан булу.

Аяк-кулын бәйләп, үзен-үзе
Ҡара көскә тотып бирерме?

Мәңге бирмәс башҡорт һәм бирдермәс,
Иле өсөн янган һагышы!
Үлһә үлер газиз иле өсөн,
Әмма тере калыр намысы!..

5

Үзаманым, энем, акһакалым,
Олатаем, апам, әнием!
Инанмагыз дошман һүзенә, тип,
Ҡайта-кайта йырлап көйләем!

Дутов залимнәрнең ялсылары
Һеззең арагызза йөрерләр,
Һеззе алдап ауга төшерергә
Төрле кыяфәткә керерләр!..

Алар кара шайтан булһалар да,
Йөрер тыштан яхшы күренеп,
Һеззе аягандай һүззәр һөйләп,
Фәрештәләрһымак кыланып.

Фетнә һалып йөргән шайтандарзы
Советларга тотып китер һин!
Кулга төшкән Дутов ялсыларын
Эһ дидерми эшен бетер һин!!.

1919

ЯРАШТЫК

I

Большевиклар белән без яраштык,
Кара-каршы көлеп караштык,
Талашмадык безләр коллык өчен,
Ирек сөйгән өчен талаштык.
18 февраль, сәгать 10 да
Игълан кылдык барлык гаскәргә:
— Без яраштык, дидек, кызыл белән
Кара көчне сыпырып ташларга!
Дутов белән бардык без бер сүздән,
Ләкин бармадык без бер эздән;
Без тырыштык, алып калаек дип,
Бер кыл гына булса дуңгыздан!!

II

Үзгәрмәде безнең ак уебыз,
Үзгәрде тик барган юлыбыз,
Безнең теләк — иске изге теләк,
«Башкортстан» безнең туыбыз.
Ярлы белән ярлы арасына
Хас дошманнар пычрак бау салды,
Шул сәбәптән башкорт баласына
Кызыл гаскәр килеп яу салды.
Шуннан безнең гаскәр ихтыярсыз
Большевикка каршы атлады.
Кызыл гаскәр безгә каршы килгәч,
«Кызыл мәлгунь» диеп аталды.
Әй кызыллар, хәзер өстегездән
«Кызыл ләгъиәт» тунын салдыгыз.

Ту — байрак.

Ярлы, мазлум башкорт халкыннан да
«Кызыл рәхмәт» исемен алдыгыз.
Бер булса да безнең төпке теләк,
Бугаз-бугаз килеп алыштык:
Ярлы халык канын урынсызга
Түгәр идек һаман сугышып.
Буржуй халкы һаман рәхәтләнеп
Торыр иде читтә көлешеп.
Әле дә Колчак чыгып ару итте,
Кемнең кем икәнен аңлатты.
Ике араны баскан кара канга
Әйтерсең лә ходай шәм якты.
Башкорт халкы безнең дус икән, дип
Сүрәнләнде шунда кызыл яу.
Сезнең белән сугышу буш икән, дип
Җавап бирде шунда безнең яу.
Шул сәгатьтән алып яраштылар,
Күреп бер-берсенең хатасын.
Кызыл гаскәр белән безнең гаскәр
Кара көчне җимереп таптасын!

ӨЙРӘНЧЕК ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘР

1907—1909

КОТЛЫЙМ

Мулла абзый, сине котлыйм чалмаң белән,
Тәбрик итәм эчең тулы ялган белән!

1907—1909

БАКЧАБЫЗДА

Җәй бакчабызда кошкай чырлады,
Гөлләрне үпте, җырлар җырлады.
Багъбостан эче ямьгә чормалды,—
Балкыды анда илһам нурлары.

1907—1909

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ

* * *

Урамыгыз — турыгыз,
Туры киткән юлыгыз.
Чабатасын кыек баскан,—
Шулмы матур кызыгыз?

* * *

Чынласам мин — бер чебенне
Бер сугуда юк итәм!
Чынласам мин — бер шырпыны
Бер сызуда ут итәм!

1907—1909

ТАТАР ТЕАТРЫ

Өй дә кечкенә,
Хатын өч кенә;
        Җир атлап йөрү
        Моңа кечкенә.
Чаршау коралар,
Шунда торалар,
        Намуска калып,
        Илдә туалар.
Балалар арта,
Фәкыйрьлек тарта,
        Тамак туйдыра
        Бу уйнап карта.
Кәсептән кайта,
«Юк,— ди,— һич файда,
        Ди ул: «Китерең —
        Ашарга кайда?»
Хатыннар тормый,
Юк диеп берми;
        Тамак кыра да,
        Җилкәсен тырный.
Гайрәте килә,
Ашыйсы килә,
        Тапмагач юкны,
        Иренен имә.
Берсе тора да,
Шулпа китерә,
        Ашап туя да,
        «У-у»,— дип кикерә.
Ашны өндерә,
Юлга кундыра,
        Трубка тартам дип,
        Утны сүндерә.
Хатыннар кырыша,
Балалар укерешә,

Егет тә буранны
Басарга тырыша.
Басалмый — шаша,
«Вәт инде яшә!» —
Диеп уйлый да,
Чыгып та кача.
Хатыннар көтә,
Күп көннәр үтә;
Кайтмасын белеп,
Таралып китә.
Бересе — бирге,
Көндәше — аргы,
Өченче берсе
Атасын каргый.
— Җитәр, каргамаң,—
Пешмәс бит ярман;
Көндәшкә булгач,
Авылга барман!

1907—1909

АВЫЛ МӘДРӘСӘСЕ ТАКМАКЛАРЫ

* * *

Зараба фәгалә фәзгендә
Без укыдык «Сарыф»ны;
Инде китәр вакыт җитә,—
Китерегез шарфны.

* * *

«Калә шәйхе фиш-шифа» — дип,
Без укыдык «Мантыйк»ны;
Эзләсәм дә табасым юк
Бу китаптан артыкны.

* * *

Үтә пешсә тәмле була
Алмагачның алмасы.
Сузсаң, Мәскәүләргә җитә
Имам хәзрәт чалмасы.

КИТАБЕННАС ФИ ХАККЫЛХАВАС

1916—1917

* * *

Пишлием соң, башлы көлтә чыкмады шул гел генә,
Нәрсә чәчкән халкымыз, тик мин шуны урдым гына.

1

Фәһүә, әбтәр нинди эш кем башлана «бисмилла»сыз,
Төп-томал мәсҗет салып куйган кебек һич мулласыз...

Фәһүә, әкътаги башласаң «бисмилла»сыз эш — ул кисек,
«Алла»ны алга алмаганлар һич чыгалмас юл кисеп.

Син әгәр эш башламастан «алла» исемен фашласаң,
Бар хәлеңчә алланны кертсәң — ашласаң;

Һәм дә күңлең кәсасеннән «илченә» түксәң дога,
Иртәләп нәфсең атын, баш өстенә бөксәң дога,—

Шул вакыт вөждан яныңнан изге кыңгырау шалтырар,
Изге өннән шук нәфсенең муены салыныр — җылпырар...

Шул вакытта җан ашар, җаннан начар шайтан качар!
«Алла [рахман] рәхмәте»ннән җаныңа ак таң ачар.

2

Мартны башлап арт тарафка кышны ташлап мәҗбүрән,
Авылыма кайттым шәһәрдән, эшне ташлап, яз белән.

Фәһүә — бәс ул, улдыр ки.
Әбтәр — макталмаган, начар.
Әкътаг — кискен рәвештә.

«Сау йөреп кайттыңмы, углым?» — дип, эти саулык сорый;
«Көчтәнәчлек бармы?» — дип, әнкәй көлеп яулык сорый.

«Абзыкай!..» — дип әйләнеп сикреп йөри бер сеңелкәй,
Сөйләнә, тәт-тәт килә... Әй, аппагым, сөйкемлекәй!..

Түргә мендем, алда ашъяулык вә тездә тастымал,
Бал да май, коймак та каймак — кайсын алсаң, шунсы ал!

Әллә бисмилламны әйтергә оныттым? Нә исә,
Бер заман коймак шәрифләрдән тәмам җилләр исә...

Чәй эчеп чыктым да эт берлән куыштым, уйнадым,
Әй күңелле соң минем сөйкемле мәэмай Муйнагым!..

Ак бәрәнләр берлә чаптым, абзар алдын бер итеп,
Дөньясыннан кулны селтәп, башны баштан хөр итеп...

Һәй кызык: күргәч мине, тайлар, колыннар өркәләр,
Чак кына «көш-көш!..» дигәч тә, куркалар каз күркәләр.

Өйгә кердем дә песи алдында уйнаттым кәтүк,
Уйнатып аргач шаянны, сөт кушып, бирдем катык...

Чү, каләм, чү... Кайда киттең?.. Юл адашкансың ласа!
Эх сине, мәэмәй итәрмен, читкә качкансың ласа!..

3

Өйдә эткәйнең китаплар берлә тулган шүрлеген
Актарып беттем бутап, калдырмадым әйтерлеген.

Актарып таптым китап эчрәсеннән бер китап,
Һәр авыл, һәр тирмәгә, һәркемгә мәгълүм ул китап.

Ул адәмнәр исеменә язган вәгазьләр көй белән:
«Әй, фәлән кардәш,— дигән ул,— бул фәлән дә, бул
төгән!

«Кыл намаз, йөз мең нәфел калдырма, Шәмсетдин»,—
дигән;
«Төн буе тәсбих санап чык, Баһаветдин»,— дигән;

«Очраган бер фетнәгә күз кысма, Миңнулла»,— дигән;
«Үз бичәңнән һич тышауны чишмә, Гыйндулла»,— дигә

Коймак шәрифләрдән — тәмле коймаклардан.
Эчрәсеннән — эченнән, арасыннан.
Нәфел — алла алдында изгелек.

«Булмагыл, Ханнан агай, Харрас бабай, ханнас!» — дигән;
«Эшләгәнең читләрен киртеп йөре, Мәннаф!» — дигән;

«Фатыйма, барсаң иреңнең катына, тик тор», — дигән;
«Күп савап бар, тарт аягын, чолгавын киптер»! — дигән:

«Куйныңа Мәрьям, — дигән, — ал да иренне иркәлә,
Муйныңа кул салса читләр, сал да җибәр җилкәгә!»...

«Гөлҗамал, туткәй, — дигән, — син булма аңкау, бул уяу,
Зөлҗәләлеңнән сора, төнлә торып, тәкъва кияү...»

Шул рәвеш байтак исемнәре атап, кылган үгет,
Бу мисаллардыр — китабыннан сыгып алган чүбек.

Бу китап кузгатты миндә көчле тәкълид шөһрәтен!
Салды сихри шәүкәтен нәкъ җанны тарткыч бер хатын...

4

Дөньяда һәр нәрсә тәкълидтән гыйбарәттер, дидем,
Хәтта тәкълид без «габед»ләргә гыйбадәттер, дидем,

Баглаган тәкълид канатны, фикерне, хисне дә,
Баглаган ап-ак мәләкне дә, хәбис иблисне дә.

Даимән инсанга — инсан, женгә жен тәкълид итә,
Кыз балалар, яшь тутыргач, җиңгәсен тәкълид итә...

Ел вә айлар, уйлаганда, арттагы айлардай була,
Яшь малайлар, уйнаганда, карт бабайлардай була.

Син күрерсең, тикшереп баксаң җиһанның җәнлеген,
Шунда инсан барча җәнлектән тәкълидчәнлеген:

Азды инсан төрлечә: хайванча да, шайтанча да,
Яздылар «Әл-фил дә Мәл-фил» дип, газиз Коръәнчә дә...

Ханнас булмагыл — бозык, азгын булма.
Зөлҗәләл — алла мәгънәсендә.
Тәкъвә — дин кушканны гына эшләүче.
Шәүкәт — көч, куәт, олылык.
Тәкълид — ияру.
Габедләр — коллар.
Хәбис — эшәке.

Без дә яздык, искеләр күк, «Зөһрә җаннар» төсле итеп,
Без дә кидек яңалар күк, иске аякка очлы итек!

Без, Шәрекъ, булдык Гаребдәй, шигъри күлмәк тектереп,
Охшадык Пушкин, Шекспирга, озын чәч җиткереп.

Без, Шәрекъ — күптән сарык, күптән бозау, күптән исәр,
Йөрде пәйгамбәргә охшап Миргаләветдин мишәр!

Безгә тәкълид уйламаска, төпченмәскә әмер итә:
Иске дөнья бар чагында нәрсәгә ул Америка?!.

Калбебездә шул таша һәм гаклыбызда шул паша,
Тугъмасын, сүнсен иҗат, син мең яшә, тәкълид, яшә!!.

Никадәр тәкълидкә каршы нәгъръә ор, акыр, бакыр,—
Зәррә тәэсир әйләмәс, тәкълид һаман шаулап ятыр.

Син, динеңнән гәп орып: «Мәзмум ул тәкълид»,— дисәң,
Ни диярсең, «Дин дә тәкълидтән ясалган бит»,— дисәм?..

Әйе, тәкълид — гоп-гомуми. тәб-тәбигый бер гадәт,
Әткәң-әнкәң таптаганны тапта, Бибигөлбанат!..

Искеләргә тәкълидән исмен «Китабеннас» куеп,
Яңаларны тәнкыйдән язмый чыдап булмас, диеп;

Шалтыраган, ялтыраган кемсәләрнең исмене
Охшатып тезмәккә уйладым, хәл кадәр, бу тисбене,—

Зур итеп куйдым кәгазьнең башына — «Баб-эл-әлеф»,
Башны тырнап аптырап беттем табалмый бер хәреф...

Теңкә корды, белмәдем кемнән тотып башларга да,
Бер карар бирдем каләмне ыргытып ташларга да...

Шул вакытта безнең өйгә бер урыс килгән иде;
«Ызнакум, кайдан?» — дигәч, ул: «Мин Орскидан»,— диде.

Шәрекъ — Көнчыгыш.
Гареб — Көнбатыш.
Кальбебездә — йөрәгебездә, күңелебездә.
Паша — баш, хуҗа.
Нәгъръә ору — оран салу.
Зәррә тәэсир әйләмәс — тамчы да тәэсир итмәс.
Мәзмум — шелтәләгән.
Тәнкыйдән — тәнкыйть белән, тәнкыйтьләп.
Кемсә — кеше, кем булса да берәү.

Бик кинәт эткәй миңа: «Ахмак икән Әхмәт,— диде,—
Һич китап килми «Шәрекъ»тан, ичмасам, юк хат»,— диде.

«Их, эти, рәхмәт... Каян әйттең, менә таптым,— дидем,—
Тукта, Әхмәт Исхакый, каптың, малай, каптың!» — дидем.

. . . .

Һәм шуны башлап язып киттем, тезеп киттем, тезеп,
Әй кызыксындым кызып, киттем кызып, киттем кызып...

Уйга урнашкан исемнәрнең барын түктем шулай,
Түгелә-чәчелә, акрын-акрын ахырына җиттем шулай.

Уй читендә читләтеп калган исемнәр калдылар,
Монда ауналган исемнәр үз насыйбын алдылар...

— Нәрсәгә мактау аны, әйт, ул өтек ни эшләгән?
— Нинди шәп булсам да мин, тәнкыйрь итепсең, пешмәгән!

— Ник фәләнне телгә алдың? Мин аңардан киммени?..
Хас белән гамнар арасын аера торган синмени?..—

Дип, сөальләр берлә, абзый, эчтәдекчә кычкырың!
Барыбер хәзер җавап юк, сөйләшербез кичкырын.

Булмасын, һәрхәлдә, рәнҗү, үпкә-сабка, рәнҗешү,
Гәр хатам чыкса — атарсыз: «Иҗтиһадта ялгышу...»

Мәҗрух булсаң, укларым тәңгәл үзәккә үтсә бик,
Тиз уңалырсың, кабатлап әйт: «Кабахәт Шөбшә!» — дип.

БЕР ИЗАХ

Тел төбендә бер сүзем бар, сүз төбендә бик лаек
Бер җөзаф сүз булса да гәр, бер изахсыз үтмәек:

Тәнкыйрь итепсең — мыскыл иткәнсең.
Хас — күренекле, атаклы шәхес, өстен катлау.
Гам — гавам сүзеннән кыскартылган, гади масса, «кара халык» дигәнне белдерә.
Эчтәдекчә — теләгәнчә.
Атарсыз — әйтерсез, игълан итәрсез.
Иҗтиһад — тырышу.
Мәҗрух булсаң — яраланcаң.
Тәңгәл — туп-туры дигән сүз *(Ш. Бабич искәрмәсе).*
Җөзаф сүз — ляф ору.

Бәгъзе затларга каләм артык җиңеллек әйләгән,
Бәгъзеләрне бер хосусый хәлгә бәйләп чәйнәгән.

Бәгъзе ашта пешмәгәнрәк эшләнгән кәтлитләрем,
Бәгъзе хаска гамь булыбрак төшмәгән тәнкыйтьләрем...

Шундый затларны яңартып, яңадан яздым тагын,
Иске калды искечә, ачтым «Яңартылган» бабын.

Искесеме, яңгысымы — кайсы шәр, кайсы хәер,
Кайсы мәнсух, кайсы нәсих... ансын инде син аер.

ИХТАРЧЫК

Түз, туган, йөз чытмасын күңелдә шайтан карчыгың,
Калмасын, дим, янчыгымда валчыгым-ихтарчыгым!

«Башканы язгач,— диләр,— соң ник үзеңне язмадың?!
Әл-җавап: «Мин үз-үземне хас дияргә базмадым:

Карга көйгә, сандугач мин, дип йөрү ул им түгел,
Үз-үзен саннан санаучы «Хиффәттулин» мин түгел!»

КИТАПНЫҢ ҮЗЕ

1

«Хәмзә» бабы *

Әхмәд Исхакый, син бик илтифатсызсың бугай:
Мин сораган өч рисалә әл дә юк — үтте өч ай!

Әхмәд әл-Урманчи, урманга ник бер бармыйсың?
Көн буе кырда ятып, буп-бушка чыпчык аулыйсың!

Хосусый хәл — аерым очрак, вакыйга мәгънәсендә.
Бәгъзе хас — кайсе бер кеше.
Мәнсух — юкка чыгарылган, кире кагылган.
Нәсих — юкка чыгаручы, кире кагучы.
Ихтарчык — искәрмә.
Им түгел — уңай күренеш түгел.
Рисалә — китап.
* *Хәмзә бабы* — **а, ә, и, у** хәрефләренә башланган исемнәргә багышланган эпиграммалар.

Әхмәд эт-Таҗетдини — «таҗ», «тин» колы нишли икән?
Әллә берни эшләми, актык тинен очлый микән?

Әхмәд әл-Һади, синең төп максатың сәүдә, диләр,
Басмас иде ул «Әлифба»сын, итмәсә файда, диләр.

Исхакый Гаяз да гайгылдашты шул Һади белән:
Әй, Гаяз, син яз, маташ «Мулла», «Шәкерт абый» белән!..

Әхмәдиев, син шәһид китсәң кирәк «Йолдыз» өчен,
Куркма Туктар бизмәненнән — үз кулында сөзгечең!

Әхтәмев, әй Биниәмин, әй, отсрочка корбаны!
Ошбу көндә монтазир сиңа шәкерт, хәлфә җаны...

Укмасый Миркәй-Газизгә ук та үтмәстер хәзер!..
Инде ул язган шигырьне кем дә укымастыр хәзер...

Әй, Әмирханов Фатих, «Фаткулла хәзрәт» һәм «Хәят»,
«Урталыкта»н чыкмасыннар, әйдә син тик ят та ят!..

Ибраһим Гыйрфанзадә Галимҗан — ул хәлфә хәзер,
Хәлбүки милләт аңардан күп өметләр монтазир.

Әл-Иманколый Садыйк әшгарь язарга башламыш!
Ай, кыямәт купмасын, дим: мулла чалма ташламыш!..

Әбдерахман Сәгъдиев ул бетте инде аптырап,
Ел да, ел да бер урыннан бер урынга бәлтерәп.

Ишмөхәммәд, син тәмам иблис белән тик ишкә-куш,
Тынма әйдә, үз табагына үзең тик әйдә кос!

Әйдә Әхсән Кормашый, выж!.. Матбугатта тормачы!
Ят авылда, бул зыялы бер сабанчы, тырмачы!..

Булса пис эшләргә үч, бирмәскә иблискә көч,
Мин теләрмен: бир ходай дип, һәр ике Идрискә көч!

Ибраһим Әхтәм — хаким, ди, бабына мөхкәм, ди ул,
Чын күңел берлән ләкин беркайда да макталмый ул.

1916 сәнә, март.

Шәһид киту — һәлак булу, дөнья кую.
Монтазир — көтүче, өмет итүче.
Пис — начар, шахшы.
Бабына мөхкәм — үр урынына яраклы.

2

Б. бабы

Батталов «Йолдыз» саен язды да торды капланып,
Яхшылап маташмый инде,— киткән, ахры, картаеп.

Бикбулат ул бер «улак»тан су агызып тик ята,
Кылдый-былдый боргаланмый, сатмый артык сафсата.

Син, Буранбай, ник буран төсле буранлый башладың?
Әллә, ахры, ямьсез эшләрне кҮралмый башладың?

Буби Габдуллалары — булды алар аллаһ «туб»ы,
Изге мәктәпне җимергәч Кушмый шайтаннар угы...

Баллы Багъбостан ханым, мәктәп тотып үскән ханым,
Тәңре гафу итсен бөтен тормыштагы янлышларын.

1916 сәнә, март.

3

Т. бабы

Туктаров Мәхмүт түгел ул, туктамас Мәхмүттер ул,
Туктамас, тынмас вә тындырмас өчен мәхлуктыр ул.

Тинчурин Үзбәк-Кәрим — тынчу урында ятучы,
Байтагук бар акчасы, беткәндә — штиблет сатучы.

Әй, Терегулов Үмәр, өч яклы, өчпочмаклы син,
Әмма шунсы: кулмәгең-ниең белән бер катлы син!

Төхфәтуллин — җырчы, бакыручы, «мөфәссир кибрия» (!)
Үпкәләсәң, үпкә ашарсың: һәммә эшләрең рия!..

Тәфкилев безнең тарихта чирканыч, мәлгунь нәсәб,
Шул тарихтан, әйтегез, кемнәр булыр мәмнүн вә шат?

1916 сәнә, март.

Мөфәссир — Корьәнне тәрҗемә итүче.
Кибрия — тәкәббер, үзен-үзе эре тотучы.
Мәлгунь нәсәб — ләгънәт нәсел.
Мәмнүн — риза, канәгать.

4

Ж. бабы

Баш мөдирлектән Җиһангир жилтерәр бер җанибә,
Тиз сызар, дим, үссә әгәр «Галияи Сания».

Син, Җамалетдин, Гаребтән кайт Шәрекъкә әйләнеп,
Китмә читкә, нык кына тор тәнкыйдендә бәйләнеп!

Әй, Хәсән бай Акчурин, әй, акча урыны, акча син!
Уйла: «Акча — изге яңгыр, милләтем — зур бакча»,— дип!

Юк, Хәсән Гали, тамыр җәймәк татарга хезмәтең,
Әйе, син кыргызга эшләш, чөнки кыргыз фитрәтең.

Әй, Хәсән Гата казый, барлык казый ата казы!
Сагына сине Уфа — карты-яше синнән разый.

Әл-Хәсән мулла Сабир булды «тәгассеб үрнәге»,
Аркылы кискә тыгып, ул эчне байтак тырнады!

Әл-Хәсән мулла Пономарьда гыйлемлек шәп, диләр,
Шулкадәр шәп — хат язарлык зиһне юк, дип мактыйлар!

Мөбәрәкшадыр Хәнәфи, түп-түгәрәк, оп-озын,
Акылы коңгырт, күңле — соргылт, чоп-чобар һәм кып-кызыл!

Хәнәфи әл-Бәкиригә ни дияргә белмәдем,
Чөнки анда мәгънәсезлек, мөстәбитлек күрмәдем.

Әл-Хәнәфи — әй Мозаффар, зөфрият бул, нык тырыш,
Барчасын син, муллаларны аска ташлап өскә оч!..

1916 сәнә, март.

Әй, Җамалетдин, кулың юмай каләмне Юнмаев,
Әй, изелгәннән, изелгәннән изелгән Унмаев!..

«Галияи Сания» — «Икенче Галия» (мәдрәсә).
Фитрәт — яратылыш заманы.
Тәгассеб — искелек, фанатизм.
Мөстәбитлек — деспотлык.
Зөфрият бул — өстен бул.

Син, Җамалетдин, җамал таптың Бәләбәйдә дә син,
Шөһрәт алдың, сыздырып Коръән юбәләйләрдә син!

Әл-Җәләлов чын Вакыйф булдың әсирлек хәленә,
Ул, ахрысы, тончыгып үләр фәгән вә зарына.

Хәзрәте Җарулла Муса башына төште гаса,
«Байрашев»ларга кушылган ул!» — диләр... Булмас!
Хаша!..

Җантурин, трарим-трим — анда трим, монда трим,
Кайда барма — анда юклык, кайсына мин җиткерим?..

1916 сәнә, май.

5

Х. бабы

Әл-Харис Фәйзи дигәч тә, төште искә «Әшъя»сы,
«Әшъя»лар чәнчелсен инде — «Әшъясыз» да баш яши!

Әл-Харис Корбангали милләткә корбанга ярый,
Зур бәхет бит: илдә күпме хәлфә корбан булгалый?!

Йоп-юан Харрас ишан Айдар, түгел алдар ишан,
Төлкедәй алдар ишанга эт кебек һаулар ишан!

Әй, Хәлим Сабит, бикәргә читтә йөрисең, энем,
Йөрмә анда, кайтчы монда, монда игәрсең иген.

Әй, Хәлим Искәндәрев, кузгалма һич, җил исмичә,
Һәм Троицкины да кузгатма,— торсын искечә!..

Әл-Хәлил — «Сакаллы абыстай» — ходайның әмре бу,
Нишлисең соң, безгә тәкъдирнең зәһәрле җәбре бу.

Җамал — күркәм.
Фәган вә зар — ялвару һәм зар.
Гаса — таяк *(Ш. Бабич искәрмәсе).*
Хаша — ялган, буш.

6

Д. бабы

Дәрдмәнд, дәрт шәп чагында «Дәрдмәнд» дип алдың ат,
«Исте җилләр... Күчте комнар...», бетте дәрман, сүнде дәрт...

Дулатов, дулатмагыз казакъны, бик дулап китеп,
Китмәгез бездән ерак, уймак чыгар, уйнап китеп.

Мулла Дәүләтшин! «Хөсәения» сиңа рәнҗеп тора,
Измә милләт дәүләтен син, булса вөҗдан чак кына!..

1916 сәнә, май.

7

З. бабы

Зәкәрия, белмимен, никтер миңа чит-ят кебек,
Ул «Кояш»ның уртасында кап-кара бер тап кебек!

Ой, Закир, «риба» сүзендә «ба»га бер нокта кушам
да үзеңә ыргытам, әйт: бу «рия» булмас микән?

1916 сәнә, май.

8

Р. бабы

Ой, Риза — эш үрнәге! Без бик риза түгел сиңа:
Вак-төяк, «әбер-чыбыр»га күп урын бирә «Шура»!

Ул Рәми эри тәмам, «исме Сәгыйть» эрмәс, диеп,
Эрмәсә-эрмәс, ләкин тик торма, тиң килмәс, диеп.

Ракыйби Ракыйб, рәкыйбең булды Рахманкол вафат,
Син дә, «аударгыч», терекөйгә вафат булсаң — харап!

1916 сәнә, май.

Дәрдмәнд — бәхетсез.
Риба — файда проценты.
Рия — ялагай, икейөзле.
Сәгыйть — бәхетле.
Рәкыйбең — конкурентың.
«Аударгыч» — Хәсән Гали тәгъбире — мөтәрҗим (булдыксыз) мәгънәсендә *(Ш. Бабич искәрмәсе).*

9

З. бабы

Зиннәтулла, килбәтең юк, ичмаса, бер якка да,
Зиннәтең юк, хезмәтең юк дингә дә, милләткә дә...

Син, Зөбәирн Хәбибрахман — педагоглар ире (!)
Акча бит, дус, нишлисең — кемгә йога язмак чире!

Яшь тарихчы карт Зәкине әрләделәр кәрлә дип;
Мин дә әрлим: кәрлә көйгә бик тәкәбберләнмә дип.

1916 сәнә, июль

10

С. бабы

Сүнчәләй, син Сүнчәләй! Сүнмәс исәң, чык мунчадан,
Яхшырак «Баб әл-самаэ» ач, бетсен инде мунчалаң!

Сәрвәретдин Мифтахетдин — һәм мөдәррис, һәм имам,
Ул тугандук «ислам, ислам, ислам, ислам...» дип туган.

Әй, Сәет Шәриф бабай, үл! Үлмәсәң — кит Мәккәгә!
Калса исмең — шул җитәр, җисменне монда саклама!

Саттаровлар булмагач, монда курс узды тыныч:
Булмады туйлар ясау һәм андый-мондый куркыныч.

Сәйфи! Кәйфең яхшымы? Нишләп торасың соң әле?..
Һәм мөгаллим, һәм учитель, һәм әдипме син әле?..

1916 сәнә, июль

11

Ш. бабы

Шәмгулов көндез дә шәмнәр яндырып күкрәк кага,
Бар явызлык эшләрен кибетендәге чүпрәк яба.

Шарлатан Шакир юрист, ай-һай, горурлы фиргавен!
Фиргавеннәр бик күбәйде, тәнрем, үзең бир гъәвен.

Гъәвен — ярдәм.

Әй, Шиһаб, милләткә хезмәт «Мәктәб»ең берлә вафат!
Инде ят, корсак карап тик, ач мөхәррирләр талап!..

Син мишәрләнмә, исәрләнмә, Шәриф, имля бозып,
Бом-бозык имляң белән син пылт итәсең пыр тузып.

Әй, Шонасый, кимиячы, әйт: бу җиһанда кем яши?
Кем намусны малга сата, бу җиһанда шул яши...

Юк Шәрәф Борһан, көтәм — юк, ай көтәм — юк, ел
көтәм...
Малга, балга батты, ахры, дим дә күңлем беркетәм...

Ничә ел төштең, «Шәһидуллин», календарь артына.
Төшмәдең тик шул календареңны рәтләү дәртенә.

1916 сәнә, июль.

12

С. бабы

Сәнгати әрсез адәм, сонгый шигырьләр башлыгы,
Бүрттереп куйган юан борчак кадәр бар ясмыгы!

Юк, сафа бетте, «Сафа» менгәч татарның тәхтенә,
Якты күрмәссең, татар, иблис төкергән бәхтеңә!..

Әй, Сәлихҗан Урманов, урмандагы эшләр ничек?
Изге вөҗдан рәнҗемиме, анда ерткычлар ничек?

Сәлихов, астында поскан «Ил»че һәм «Таң»чы Гаяз,
Инде эш, кем, ул кушылса, ахры бик тиз инкыйраз!

Әй, Сәхипҗамал, җитәр, рәхмәт, җитәр, гомрең зая,
Күпме йөрсәң дә, һаман шул бер титул — Волжская.

Садрый кадре сайрап артты, инде торткын кош кебек,
Ул кадерләр шаулап акты, калды тәмле төш кебек.

1916 сәнә, июль.

Имля — орфография, дөрес язу кагыйдәсе.
Кимиячы — химик.
Сонгый шигырь — ясалма шигырь.
Инкыйраз — үлеп бету.

13

З. бабы

Ул Зыя — эш һәйкәле, йөзләр яшәсен шан илә,
Дошманы янсын, гүзәл эзләр ясасын «Галия!»

Әй, Зыя Янгаличев, син яңлышып киттең бугай,
Ник боектың, әллә син милләткә булдың үгәй?

Йөрмәче, Зыя Насыйр, син төрлечә койрык борып,
Мәгънә чыкмый төрле бабларга кереп, йөгреп йөреп...

1916 сәнә, август

14

Т. бабы

Ташмөхәммәд, ташка үлчим юк хәзер ул, кайда, ә?
Таш мәчеткә юкагач мулла хәзер ул, ха-ха-ха!..

Таһири — таһир диләр, исме Һади — һади, диләр,
Мәгълүматны артка салган бер сабый абый, диләр.

Тучыбаш атты элек ташларга аш, ашларга таш,
Булды баш, күз өстендә каш, хаслар өстендә хауас!

Тангатар да юкны уйлап, таң көтен яткан татар,
Үз көче җитмәс кадәр зур нам көтеп яткан татар.

1916 сәнә, август.

15

З. бабы

Әй, Зариф, чык ялтырап, тик бар да китсен аптырап,
Дошманыңны калтырат, борчакларыңны шалтырат!

Син, Зариф Әмирхани, әмриканский чалмалы,
Алны бирдең, гөлне алдың — уфтанышка калмады.

Шан илә — дан белән.
Таһир — саф, таза.
Һади — житәкче.
Хаслар өстендә хауас — атаклыларның атаклысы.
Нам — исем.

Йә тагы, Зариф Мозаффар, ватмыймы бик милләтең?
Ватса ватсын милләтен, хезмәткә артсын һиммәтең...

1916 сәнә, август.

16

Г. бабы

Әй, Галиәсгар Камал! Әкбәр Камалны идеал ит!
Барлык артистларга каршы байкотыңны игълан ит!

Син, Галиәсгар Гафур, гофран тәлап кыл алладан,
Чү... тагын бидгать, хилаф эшләр чыгарма, уңмаган!

Әй, Гали Рәхим туган, рәхмәтле яңгыр урнына
Бозлы яңгыр яудырсаң, кундырырбыз борныңа!

Әй, Гали Рәфыйкъ, өмет бар синдә — яз, эшлә, тырыш!
Эшләсәң, күгең аяз, алдында яз — эшкә кереш!

Галихан — мескен казакъның бер генә ак йолдызы,
Һәр колакка яңгырый ялгыз Гәлиханның сүзе...

Әй, Гомәр Караш, синең гаклың да бар, инсаф та бар,
Тарт казакъны якты якка, шунда ул бәхтен табар.

Гөмдә — инсафлы шәкерт, «Тормыш»та эшли, сәркатип,
Каш төзәм дип, күз чыгарып, барча эшне таркатып.

Мәшһүрә Гыйффәт, елак, шөһрәт таба һәр як белән,
Аһ йөрәгем, дип елый, чиртсәң дә бер тырнак белән!

Йөрмә читтә җил куып син, кайт, Гыйлемдар, кайт әле,
Тәрҗемәңнән качма, дисәм, күзләрең мылтайтмәле.

Гыйрфан абзый — бер шәһәрдә гыйрфаны юк бер ахун,
Анда истибдад — хәзинә, анда гайбәт — ун вагон!

Син, Гариф, җуйдың шәрәфне, бик начар шәйләр язып,
Тапкалыйсың кайвакыт чүптән казып җанга азык!

Әсгар — кече, бәләкәй.
Гофран — гафу, ярлыкау.
Бидгать — изгеләр кылмаган эш.
Гыйрфан — белем.
Истибдад — мин-минлек, тискәрелек.
Шәрәф — кадер, хөрмәт, дан.
Шәйләр — нәрсәләр (әсәрләр мәгънәсендә).

Черәкәйле.шыр тиле Гыймад — тилечә телне кайраучы
беләү,
Берүзендә биш мөгез бар, шунсы җайсыз — күз берәү!

Әй, Галимҗан Идрис! Дошман сина иблис ләгыйнь,
Күп Галимҗан кангыручан, булмагач монда «зәмин».

Мулла Галимҗан барид шул җанга бик салкын бата,
Булмаса салкын ягы, булмасмиде «алтын ата»?

Әй, Галимҗан Акчурин! Шөһрәт күзенне кыздыра,
Әмма бер потлап сүзенә ярты мыскал тоз керә!

Синме, Габдулла Мәгази, «мин әгуз, мин тәррикә»?
Безгә хәсрәт инде исә, сез ясыйсыз ярминкә!

Кари Габдулла — чын артист, чын тәгассеб бер мишәр,
Куркамын: үз-үзенә Коръән чыгар вакты җитәр...

Синме, Габдулла Камал, «Сәйяр» дә тапталган кеше?
Моктәдир дип, оста дип, мәйданда макталган кеше?

Гыйсмәт Габдулла, исмең мәгъсуманә яңгырый...
Әмма өстендә болыт, салкын, явадыр яңгыры...

Гыйсмәтуллин — шалтыравык, ялтыравык дан пәрәс,
Йә илаһи, безне әйлә дан нәрсәләрдән хәляс.

Аптыраткан дөнья бит бу Габдрахман мулланы,
Дөнья шул бу: бар анын рәхмәт ягы, зәхмәт ягы.

Габдрахман Фәхри ул картларгарак тартым сымак *,
Кайда ялкын — анда салкын, кайда коймак — ул кунак.

Зәмин — җирлек.
Барид — салкын, буш, мәгънәсез.
Булмасмиде — булмасмы иде.
Мин әгуз, мин тәррикә» — явызлыклардан саклануыңны үтенәм.
Тәгассеб — фанатиклык.
Моктәдир — көчле.
Мәгъсуманә — гаепсез, керсез.
Хәляс — котылу, коткарылу.
Дан пәрәс — дан сөюче.
* Вэзен шигырь (шигырь ритмы) өчен койрыгы кыскартылды. — *Ш. Б.*

Бик кирәк Габделбәдыйгъ: ул җыр вә такмаклар җыя,
Җыр вә такмак — алтын ул, тик аннан ахмаклар көлә.

Габдрахман әр-Рәсүл, сиңа ишанлык зур мирас,
Булсаң ишан, әфьюн урнына гыйлем, әхлак өләш!

Габделхәмит Мөслими, кәфенең «Шура» белән ура,
Шул вакыт оҗмах түренә мендерер сине хода!

Әй, кызу Габдерәшит казый, кадерле, дәртле карт!
Күргәненне сөйләр иден, бик сагындык, өйгә кайт!..

Син, түрә Габделгәзиз, бар, ихтилалларны бетерт,
Торма һич вөҗдан-иман дип, бер мөселманны үтерт!

Котлаем Газиз Гобәйдуллинны идеалы белән,
Саф гыйлемгә хезмәт итү — идеалы шул дип беләм.

Габитов, син язма әшгарь, ат каләмне — утка сал,
Хәлфә бул да илне кайгырт, койрыгынны сыртка сал!

Мулла Габид Исмәгыйль ул өч йөрәкме, берме йә?
Ул йөрәктә нәрсәдер кайный — шигырьме, динме йә?

Тәүбә кылчы, әй Гыйбадулла әфәнде, имләче!
Дус-ишенне урта имляга табантын димләче!

Бай Гыйбадулла, ничектер, чынмыдыр, ялганмыдыр, —
Юмарт исемен алган, әмма күңлемә ялганмыйдыр...

Әйтсәң әйт Габдуллатыйф хаҗины бер ихсанчы дип,
Тик тәэссеф, бу хаҗи да «Ишми куштаннарчы» бит!

Булса Гыйльметдин Шәрәф мәҗлестә — бәхтең, сал колак!
Гыйльмең артыр, чөнки ул чын кызу бер дипломат.

Ми-һа-һа... яхшы бер айгыр Гайнелислам «Чишмәви»,
Айгыр исмен тактыра «Дингә мишәйт»тә эшләве.

Әфьюн — опиум.
Ихтилал — восстание.
Әшгарь — шигырь.
Ихсанчы — ярдәм итүче.
Тәэссеф — үкенеч.

Галимов Сафа дигәч тә, алды башны бер томан,
Бер томан шул: бер роман (!) язган да сүнгән бер имам!..

Голәмә журнал чыгарган: «Әл-галәм әл-Ислами»,
Инде алар кайда булды, һәй, гомерләр нишләми?!

Әй, Гыйният, сал җинаятьтән, ниһаять, зур бина,
Капкасына: «Капкаев капкапы» дип яз зур гына.

Хәлфә Габдулла Газиз, ул бергә — алтын, миңгә — җиз,
Шунда да алтын аталганнар Газиздән күп гаҗиз.

Әй, Галәветдин Ходаяров, хода ярың синең,
Барыбер дөнья өчен югың беләп барың синең.

Мулла Габдулла Сөләйман да адашканның бере,
Көйгә көйләп, хөтбә сөйләп телгә ашканның бере.

Гарип мескен, эреп төштең, бичарам, йөре качып!
Бар иде бит «аһ!» дигән чаклар, төректән урлашып.

1916 сәнә, ноябрь.

17

Г. бабы

Ул Гафури, язмаса, «Тормыш» юлында изеләчәк,
Акрын-акрын аксый торса, алгы сафка тезеләчәк

Кайвакыт ки җир йөзендә кып-кызыл кар яугалар,
Шул вакыт «Акмулла»ны рәтләр Гани пис сәүдәгәр!

1916 сәнә, август.

18

Ф. бабы

Фәтех итеп Фатих Кәрими файдалы эшләр гъәтеф итә,
Мәнфәгать чыккан чагында серле күзләр ялт итә!..

Хөтбә — нотык, сөйләгән сүз.
Пис — начар.
Фәтех итеп — ачып, башлап.
Гъәтеф итә — куша, йөз юнәлдерә, әйләндерә.

Син, Фатих Сэйфи-Казанлы, тет горурлар тетмәсен...
Күрсәтеп һәр ноктасын, дөнья үзенне этмәсен.

Фәрхи Фәхретдин түгел, картус бәрхеттин түгел,
Фәрхиләргә бездә: бар кит! Бер дә «жәл бит дин» түгел.

Әй, Фазыл Туйкин, ходайның фазлы берлә туй яса!..
Туйда җырлап төрле көйгә гомренә абруй яса!

Фәйзи «ти», «зи», «сад» вә «зад»... лар хәлфәсидеәүвәле,
Бу җиһан безнең татар күк — аумалы да тәүмәле...

Тыңла, Фаяз, булма мулла, үз бабыңнан капка ач,
Ни кызык бар, җан-күңлең берлә бергә акмагач?..

«Дин мәгыйшәт»нең зәвыксыз саесканы Фәезхан Давыт,
Әүвәле саткан махорка, инде муллалык зәвык?

Буби Фәйзулла — тырышлыктан яралган җан ди ул,
Бер каралганнан, агарганнан яралган җан ди ул.

Әйтегез, кем «Фираки»? Яшь микән ул, карт микән?
Татар микән? Татарлыгын сатар микән? Йә сарт микән?

Фатыймалар, Фатыйхалар, Фәүзияләр аузына
Сандугачлар сал, ходаем, керт нәфасәт хаузына!

Әүлия Фәхрелбанат тапты савап миллион кабат:
Ул — ханымнар дөньясында бер генә алтын канат!

Фәхринең фәхре түгел язмышы белән мөнтабыйкъ,
Хәлфә булган, чөнки мескен гайре рәсми бер табиб.

Фәхрелислам — ярты пазим, ярты мәзин, ярты имам.
Ярты нәшер, ярты насыйр, — бөхете киткән яртыдан!

1916 сәнә, ноябрь.

Фазыл — өстенлек, камиллек.

«Ти», «зи», «сад», «зад» — гарәп алфавитына нигезләнгән иске татар язуындагы хәреф исемнәре.

Сарт — үзбәк.

Нәфасәт — гүзәллек, нечкәлек.

Фәхер — горурлык, дан.

Мөнтабыйкъ түгел — ярашлы түгел.

Гайре рәсми бер табиб — рәсми (официаль) булмаган доктор.

Нәшер — издатель.

Насыйр — прозаик.

19

Къ. бабы

Каф тавы артыннан, Кыям, син, ал да кайт күп материал.
Рәсме хатны сүз истигъмал кылудан син оял!

Кортлыкайлар — Котлыкайлар, тик йөриләр кортланып,
Безгә бер әйбер биралмыйлар «Дума»дан үткәреп.

Мулла Касыйм Бикколов бик кул кеше һәр нәрсәгә,
Дөньялыкта кайгысы юк, батса, кырса, бәрсә дә...

Әй, Кыям, юлдаш итеп әйткән киңәшемнән уян!
Булма бер җирдә кыям, әй, юкка шатланган куян!..

Ах, Коләхмәт, ник уяндың, ник, уянгач, йокладың?..
Ник, уянгач, алга алган эшне әйдәп китмәдең?...

. . . .

Әл-Кадыйрның кадере төшмәк әлмисактан моктәдир,
Акылына, фәһеменә истибдадлы хиссият мөдир!

Курмашилар түр башында хөрмә ашыйлар, билләһи!
Зур башлылар аста изелеп хөр яшиләр, билләһи!

Әл-Касыйм Гыйрфан да аз-маз борчак атканның бере,
Талпынам дип, калкынам дип, сазга батканның бере.

20

К. бабы

Күрсәтә бәгъзән Кәбир төп-тигез дип кәп-кәкрене,
Хаклымы, хаксызмы — белмим, әллә дуслар хәтреме?..

Килдебәккә килде бит михнәт, мәшәкатьләр җиле,
Җил белән ут сүнде бит, кабынырмы ул утлар кире?

Күпне сайлап юкны каулайсын, Кәрамәт Айдаров,
Әй, печән чабам дип, комлыкта Чалгыкайраров!

Рәсме хатны сүз истигъмал кылудан — язмаларыңны кирәгеннән артык файдаланудан.

Булма бер җирдә кыям — бер җирдә генә торма.

Фәһем — аң.

Истибдадлы хиссият — беркемгә буйсынмаган. Деспотик тойгы.

Бәгъзән — бәгъзе вакыт.

Мулла кем Кашшаф Пати, бассаң да бик күптән тәпи,
Чыкмады рәт, бер карыш юл атлый алмадың тәки...

«Нигә язмыйсың, Карам, күп?» — дисәләр, шәп сылтавың:
«Бик язар идем, туганнар, бик тирән шул ялкавым!..»

Син, Камал, рәссам, хәритәләр, шамаилләр чыгар,
Йә, илаһым, безгә соң кайчан Рафаэльләр чыгар?

Кәримов Хәсни — учительләр эчендә дәртлерәк,
Шалтырап торса йөрәгең, ул коры дәрт ни кирәк?

Кәримов Камил дигәч тә, студентлар кылт итә,
Әй, егетләр, сезгә милләт ике күзен дүрт итә...

Әй, Кәримов бай, сиңа мал аркасында дан агар,
Бу җиһан мөэмингә дә һәм байга да зиндан мәгәр!..

Курмаев, Камил, Карамыш... бар да Мәскәү байлары,
Яхшылыкка, шахшылыкка каршы килмәстәйләре.

Мулла Кәшшаф Тәрҗемансыз мәгънәләр кәшшаф түгел,
Йә, ә-иммател Казан! Ник күңелегез шәффаф түгел?

1916 сәнә, ноябрь.

21

Г. бабы

Башкаларга нисбәтән азрак талай «Аңчы» Гәрәй,
Бер мәрәйгә тәгәрәй дә тәгәрәй,— ансы ярай...

Милләтеңнән читкә качтың, гимназистка Гөлҗамал,
Сезгә ләгънәт, әй, укыган һәм чукынган марҗалар!..

1916 сәнә, ноябрь.

22

Л. бабы

Лотфый! Лотфың булмаса, син йөрмәс идең себерелеп,
Йорт-җиреңнән умрылып, бар рәхәтеңнән томрылып.

Хәритә — географик карта.
Мәгънәләр кәшшаф түгел — мәгънәләр ачылмый.
Йә, ә-иммател Казан — әй, Казан имамнары.
Шәффаф — үтәли күрсәтә торган.
Мәрәй — һәдәф. Монда — максат, морад (*Ш. Бабич искәрмәсе*).
Лотыф — саф күңеллелек.

Лотфый Гадел төсле ни житте шәкертләр бездә — мыж,
«Ник алайса телгә алдың?» — дип сабырсыз кызмагыз!

Ул Ләбиб — кызгылт егет, лап-лоп басып, гайрәтләнеп
Әй йөри торгандыр инде, фәс киеп — дуракланып.

Мулла Локман Қанзәфәри аш вә икмәк-нанга куш,
Юкса аз-маз муллалыктан башка хикмәт анда — һич!..

1916 сәнә, ноябрь.

23

М. бабы

Мәржани, парлак яшә, сындырмыйча «Қармак» сабын,
Инша алла, маддият түгелдер бит бар максатын?

«Мөхтасар»ны Мәмлиев чаклы берәү дә чәйнәмәс,
Күп «хәшәб» алды мөдәррислек, аларны чәйнәгәч...

Мөхлисә — ихлас хатын, ихлас белән дәрсен бирә,
Бер сәгать дәрсендә ул көнлендәге барсын бирә.

Әй, Паташ Мәрьям, саташ, уйлап чыгып төнләр буе,
Һич насыйп булмый икән — шаулап йөре көннәр буе...

Тугъры мәсләкле «Алач»ың белән, Мәрьям, котлыйбыз!
Без «Азамат»тан казакъка юньле бер ямь көтмибез.

Әй, синең кергән галәм, Мәрдегалләм, карлы галәм:
Атнабай язганнырың селкеп-салып бәрде яман!

Әй, Мөнир, әткәң кая, әнкәң кая, җанкәң кая?
«Сөбханәкә» артынча «Вәлгасер» диден, «Әлхәм» кая?

Мостаев та кысталып, кысрыкланып йөргәч кенә,
Бер мөхәррир урнын алды бер гәзит сүнгәч кенә.

Мортазин артист, Мутин кырылышмыйча бергә яши,
Кем ышаныр: бер аю һәм бер бүре бергә ашый?..

Нач — ашамлык.
Парлак — рәхәт.
Маддият — материаль әйберләр.
Хәшәб — агач; аңсыз кеше мәгънәсендә.
Мөхәррир — редактор.

Минһаҗ абзаң «Галия» дип әле булса кәпрәя,
Кәпрәя торгач, ахрысы, теш төшә, бил кәкрәя...

Икътисадны читкә селтәп, «Икътисад»чы Мортазин,
Шиндереп карынын, менеп калды югартын бер сажин.

Яхшы ук мәгъруф хуҗа — Мәхмүт хуҗа, биһбуд хуҗа,
Һәр «хуҗалык»тан үзе мәгъруф диеп мәгъдүд хуҗа.

Матбагаң, әй, Максудов, шиксез таза, әйбәт, матур,
Әйт: кайчан шул матбагаң бертуктамый шаулап ятар?

Мостафа Сәйфелмөлек, сәйфең — белек, юк һич хафа,
Күпчелек бездә канатсыз; син канатлы, оч, дәһа!..

Әй, Манат, синдә кызу дәрт һәм иман бар — зур канат,
Монда безгә өйрәтерсең, анда тырышып ал сабак!..

Ник балаларга театр язмый Мирхәйдәр, диләр,
Бар икән русчаң язарлык — әйдә тик аудар! — диләр...

Әй, Мөхетдин, узам дип, алдыңа карга чыга,
Тик фәкать имляң төзәт, язганнарың алга чыга.

Мирвәли Калтай ахун шалтай да балтай селкенә,
Юкка мескең җилпенә, тырмашмый илнең күркенә...

Мәтлабе Мәкки Морадның табыла: янчык тула,
«Дин-мәгыйшәт»че имамнар табына... карчык көлә...

1916 сәнә, ноябрь.

24

Н. бабы

«Мин ачыйм «Нун» капкасын», — дип, Нәурузов, мәҗнүн кеби
Күренә: ул бәгъзән залим, бәгъзән катыйгъ мәзлум кеби.

Мәгъруф — танылган, атаклы.
Мәхмүт — макталган.
Мәгъдүд — саналган.
Биһбуд — бәхетлелек, хәл яхшылыгы.
Матбага — типография.
Сәйф — кылыч.
Дәһа — даһи.
Мәтлаб — теләк.
Бәгъзән залим, бәгъзән катыйгъ мәзлум кеби — бәгъзе (кайсы) чакта явыз, кайсы чакта бөтенләй изелгән, җәберләнгән кебек.

Тәкъдирең булсын шулай үлгәнче Наушнрвән Яуеш,
Иске эзләрдән йөреп, син яңа сүзләргә кавыш!

Ул Нәкыя җыр белән өлфәт казанмас: таушы аз,
Әй, кайчан соң сәхнәбездә шыңгырар моң, саф аваз?..

Нургъәли ахун утыз ел хәлфәлек иткән кеше,
Бер-ике әйбер язып һәм борчагын сипкән кеше.

Әй, Нуретдин, монда кайт та йөр бүректән, фәсне сал!
Игътикад, мәсләк яңарт!.. Юк, юк... яңартма, кайтма, кал!

Купшылык һәм майлану пәйгамбәре Нуркин Заһид;
Берни бакма, көн буенча йор дә тор, селкен, Заһид!

Син, Нәҗиб Хәлфин, хәлефләргә кайда калдырганың?
Кузгалак дип чәйнәгән чак бар иде балтырганың!

Әй, Нәҗиб, дәрвиш Нәҗиб, «хәлфүш» Нәҗиб, мәхзүн Нәҗиб,
Безгә биргел бик гаҗип һәм бик назик мәнзум, Нәҗиб!..

Ник Нәҗиб Гасрый язып беткәннәрен нык асраер?
Әллә ул, кәнденчә әйтәм: бер зәминме бәсләер?

Әй, Нәҗиб Түнтәр туган, син «Дин әдәп»тән түнтәрел!
Иплән-иплән «Дин-мәгыйшәт»кә табатын селтәр ул?..

Дусларыннан макталадыр шул Нәҗиб Корбангали,
Әүвәле күрсәтсен эшен, соңра мактарга ярый!

Үпкә тотма, әй, Нияз, әй, иткә-биткә бай Нияз,
Килче ипкә, урталыктан читкә китмә, әй, Нияз.

Бай Нәзирев мал тутырган баржага охшый тәмам:
Нинди буксирга тагылса, ул китә шунда табан!

1917 сәнә, февраль.

Өлфәт — сөеп карау, симпатия.
Игътикад, мәсләк — ышану, юнәлеш.
Хәлеф — нәсел.
Мәхзүн — кайгылы.
Назик — нечкә, нәфис.
Мәнзум — шигырь.
Асраер — асрый, саклый.
Кәндәнчә — үзенчә.
Зәмин — җирлек, нигез.
Бәсләер — көтеп тора.

25

В. бабы

Мин өмид иткән «вәлид»ләр—«Җим Вәлид»тән «ләм ялид»!..
Җан гаҗип, идеал бәгыйд булган дәрман гариб!

Әй, Вәлиш, мин-мин Вәлиш, ыграк чалыш кәсерең белән!
Башкаларның айгырыннан көлмәгел качырың белән!..

Нәкъ Вәли күк муллалар «дин угърысы» дип йөртелә,
Җаннары охшый аларның үрмәкүчләр йортына!..

Йөрде «Әлислах» Вафасы барны юктан торгызып,
Ниндидер дәрман белән кәрван күчеп, эт өргезеп!

Йөрмә иңрәп, әй, Вәсим, фикреңне үтреп чык «ясин!»
Торма уйлап, боз рузаңны, кил табынга — чәй ясыйм!..

1917 сәнә, август.

26

Һ. бабы

Ул «Һади», чүпрәк вә чүп-чардан корып, «Атлас» ясый,
Каш куям дип күз чыгаргач, өйгә кайткач баш кашый.

Билгеле, Сәгъди Һади — баткаклы сайда ташбака, —
Бик зур эшкә баш ватам дип, чикләвек дип таш вата...

1917 сәнә, сентябрь.

27

Й. бабы *

Ул Ярулла Вәли, күп булса, — өч-дүрт нөсхәлек,
Башкасын белмим, мәгәр бар бәйләнүгә осталык.

«Җим Вәлид»тән «ләм ялид» — Җамал Вәлидидән бер нәрсә дә чыкмады.

Бәгыйд — ерак.

Боз рузаңны — уразаңны боз.

Нөсхәлек — данә.

* Бу бабта Я (йа), Е (йе) хәрефләренә башланган исемнәр телгә алына.

Ярмәкинең муллалыкта тормакы мәгъкуль түгел,
Нишлисең, шуннан бүтән юл бездә һич мәкъбуль түгел.

«Ай» Йосыф Байкал, Идел, Алтай, Уралга ай иде.
Нурга айдан бай иде дә, уйга айдан сай иде...

Еникеевнең кыйммәтен тик хәлфәләр аз-маз белер,
Юкса ул бер сазда йөргән бер кыйкылдак каз ирер...

Айманов Ягъкуб, синең зиһенеңдә илһам көрсисе,
Көрсине ватсаң, пешәр аркаң, — зобани гөрзисе!

Әй, Йосыф бай, тел белән милләт дөбердәт, абзыкай!
Буш калайның өстенә яңгыр шыбырдат, абзыкай!..

1917 сәнә, сентябрь.

ХӘТИМӘ

1

Бу исәр, ялкау каләмне өстерәкләп кулларым,
Язгалый торгач китапны — аллаһ әкбәр ел ярым!..

Ел ярым уйнап кына эшләп, «кибән»не очладым,
Башлагачдин, ташламыйм дип, очлаганчы төшмәдем.

Очланып беткән кибәнне эшкә охшар эш итеп,
Башына какмак булам бу «Хәтимә»мне шеш итеп.

2

Бу кибәндә бер гаеп бар, сизсә, кем дә шелтәләр:
Эреле-ваклы, башлы-башсыз булды куйган көлтәләр.

«Көлтәләр» барсы ике йөздән беразрак арттылар,
Шәпләре вак көлтәләрнең, бәлки, гайбен яптылар.

Шунда да, бик ихтимал, яңгыр явар да су үтәр,
Бәлки, шунда эшерелеп ишелер, авар да бу бетәр?..

Нишләем соң, башлы көлтә чыкмады шул гел генә:
Нәрсә чәчкән халкыбыз — тик мин шуны урдым гына!

Мәгъкуль түгел — урынлы түгел.
Мәкъбуль түгел — кабул ителмәгән.
Ирер — иде.
Көрси — тәхет, урын.
Хәтимә — соңы, ахыры.

ЗӘИЛ

Тиргәмә, «хауас» дигәч, хасның да бардыр төрлесе,
Бу китапта аз ләкин «хауас» диеп әйтерлеге.

Кайсы бер хауас була — тыштан буялган хас була,
Юкса ул бер мәгънәсез, күзсез, колаксыз баш була.

Кайсысы: «Мин хас булам!»,— дип, таптый хаслар мәйданын,
Карга булган сандугач — откан әтәчләр сайравын!

Кайсысы: «Мин шәп кеше!» — дип, яр башынннан акыра,
Кайсысы кых-кых итеп, азбар башыннан какыра.

Кайсысы хайван көе гамнәр кашында шәп була,
Һай кадерле, һай гыйлем, һай-һай тәбәррек зат була!..

Кайсысы, хас дип үзен, тик корсагын киреп йөреп,
Ул кибәк баш җил-давыл өереп йөри койрык булып...

Шул кырык бер төрледән ошбу «кибән»не очладым,
Шул кырык берне кырык бер төрле телдән эшләдем.

Бәгъзеләр, бәлкем, табарлар бу китапның ялнышын,
«Бик тә тугъры йөрмәгән», — диярләр уемның чаңгысын.

Һәм диярләр: «Яклаган һәм мактаган җирләр дә бар,
Бигрәк артык ваклаган һәм таплаган ирләр дә бар...»

Әйтсә әйтсеннәр, тыялмыйм, һәр яраткан заты пакь,
Димәде бит һич берәү, мин язганымда, һәм «не так»...

Бу китап, белки, минем гомрем юлына «тап» булыр,
Алла белсен, бәлки, тап дигән шәй «ак» булыр.

Алла белсен, бу китаптан иске дуслар үчләшер?!
Һич белер хәл юк җиһанны, әллә бар да дуслашыр?!

Кем белә, бәлки, тарихка бик бөек хезмәт булыр,
Бу китап, бәлки, берәүләр күңленә бизгәк булыр.

Зәил — кушымта.
Хауас — күренекле, атаклы шәхесләр.
Хас — күренекле, атаклы шәхес.
Гам — гади халык, масса.
Тәбәррек — һәркем өчен хөрмәтле, газиз саналу.

Булмасын һичберсе, тик булсын ләгыб, булсын ләһү,
Итмәдем инде мәку, дип: «Ул гафу кылсын, гафу!»

ЯҢАРТЫЛГАННАР

Яңартылганнары булсын гыйлавә,
Кибән янында тора бер чүмәлә.

Дин исламны, Муса, балкыт Петербурдан торып,
Әмма кайбер шәйгә, остаз, бакма бик үрдән торып.

. . . .

Пәрваз — остаз, түлке аз-маз тәхрире ямьне җуя,
Зур җамалдыр, зур камалдыр, зур гамәлдер «Галия»...

Риза хәзрәт, сиңа әйтәм, син мөхтәрәм, дип әйтәм,
Бер җиреңне тешләр идем, ил ышанмас, дип әйтәм!

Садрый Максуд, күпне кәт, азны оныт, юкны куерт!
Вак адәмнәр берлә алдында һаман чүпне өерт!

Әй, осетин бәк Салих, сезгә лаек ат күрсәтим:
«Мим»гә өс, «җим»гә сәкен һәм «нун» — өтер («ну»),
«нун» — сәкен!

Һәр минут «мин» дип суга торган сәгать — Габделгазиз!
Барны онтыр, юкны тентер, мәгънә сонтыр, тел ләзиз!..

Тискәре яктан укып баксаң Гаяз — «зайагъ» була,
Ә «әфәләм төрле» шагыйрь күп катың — майыгъ була...

Бу Фатих «мыскыл» бабында һәм әмир, һәм хан хәзер,
Иркә мәхдүмнең багында күп чәчәк корган хәзер.

Ләгыб, ләһү — шаяру-көлү, күңел ачу.
Мәку итмәдем — юкка чыгармадым.
Гыйлавә — өстәмә, кушымта.
Тәхрир — әсәр язу, иҗат.
Җамал — матурлык, күркәмлек.
Камал — житешкәнлек.
Гамәл — эш, хезмәт.
Сонтыр — башкортча алама, начар, зәгыйфь мәгънәсендә йөри (*Ш. Бабич искәрмәсе*).
Ләзиз — тәмле.
Зайагъ — зая, әрәм.
«Әфәләм төрле» — юньсез-рәтсез.
Катың — катыгыз, бутагыз.
Майыгъ — ничек.
Мәхдүм — мулла малае.

Кырда талдан тал үсә, тайдан матур байтал үсә,
Әл-Кадирга кем җитә, җитсә җитәр Баттал, Муса.

. . . .

Гыйсмәтидә күп вакытта мәгънәдән күп лыклыка,
Хасләте — исламны хөрмәт, кыйсмәте — тик ак яка!..

Инкыйлабта мөнкәлиб булган, күчегән, ди Гомәр:
«Без — шөкер, әлхәмделилла, хак мөселман!» — ди Гомәр!

«Моня мин!» — дип, үз-үзенә тиң табалмый Биниәмин,
Валлаһи, сездәй адәмнәр кызганыч, билйәмин.

Әй, Рахман, рәхмәт явар, ахры, коры бостаныңа,
Күк чәчәкләр үстерерсең төсле яшь дусларыңа!

Макталырсың, мактануны куй, Манат, оч, оч канат!..
Мактанып тормыш сөрә инсан дигән вак хайванат.

Хөрриятта син, Шәһид, ай-яй күп кырдың, бугай,
Ярлыны ярдан алырга бик тырыштырдың, бугай.

Белсәнез, Борһан Шәрәф — тыштан юаш, эчтән чуаш,
Күрсәгез кызган чагында — санки ул эчкән куас!..

Кил, Баймбәт, тукта, тик, тик... чиртәем бер борнына!
Кит, кит андан, монда кил, кил... илтәем үз урнына!

Тәммәт тәмам.

1918 ел, июнь.

Хаслэт — үзенчәлек, сыйфат.
Инкыйлабта мәнкәлиб булган — революциядә алмашынган.
Моня мин — мене мин (мишәр сөйләше).
Билйәмин — ант итеп.
Санки — гүяки, әйтерсең лә.

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧНЫКЫ БУЛУЫ ИХТИМАЛ ӘСӘРЛӘР

1911

САБИЯГӘ

И сабия, күр, рәхәтлән, дөньяның яктылыгын.
Татлы гомерең, татлы чагың — яхшы бел татлылыгын.
Бел ганимәт бу вакытны, хөрилек чак бу чагың;
Сорасаң мөмкин хакыңны, уйнасаң бар курчагың.
Тәкрар итәм, йөр, рәхәтлән саф һава һәм бакчада,
Бу вакыт бер китсә килмәс, канлы яшең акса да.
Уйлама, һәрбер вакытта да сөйләрем дип [үз] сүзем,
Тондырырлар колагыңа: «Чү, кызым, оят, кызым!»
Юк, оят була сиңа инде сабакка йөрмәгә,
Йитде вакытың, булды судың: кермәгә «таш төрмә»гә!

1912

ИПТӘШЕМ ТАТАР ШӘКЕРТЕНӘ

Иптәшем, сиңа әйтәм — акча күп тап,
Шул юлда иҗтиһад ит, торма туктап.
  Ялганла, иманың сат, вөҗданың сат,
  Соңыннан йөзең булыр синең ап-ак.
Менә ул йөз ак булу шулай була:
Көз көне мәдрәсәгә шәкерд тула.
  Әнә шул күп шәкердинең арасында
  Кайсы бай, кайсылары фәкыйрь була.
Шул вакытта акча булса нинди рәхәт,
Бу мәдрәсә шунда була сиңа җәннәт.
  Хәзрәт вә хәлфәләргә өчәр сумлык
  Бирдисәң, кыласың син үзең микат.
Вәт шунда синең эшләр җайлана,
Бар нәрсәгә синең акча уңайлана.
  Шул вакыт фәкыйрь булсаң — эшләр яман,
  Бер алла үзе бирсен сиңа иман.
Һич берәү сиңа таба күзен салмый,
Гүя син иң әшәке бер эш кылган.
  Ул вакыт хәзрәт сиңа башка төрле,
  Хәлфәнең күптән инде эче керле.
Гүя син аталарың үтергәнсең,
Башыңа уйлар төшәр төрле-төрле.
  Белсәң дә, дәресләрне белалмыйсың,
  Аларның ачык йөзен күралмыйсың.
Үзеңнән алтын түгеп сөйләсәң дә,
Акчалы егетләрдәй булалмыйсың...

* * *

Әфәндем! Бу сүзләрем түгел ялган,
Ялганга урын да юк — күп сыналган.
  Акчасыз ул картларга якын барма,
  Аларның барында да акча — «иман».

Микат — билгеләнгән урын һәм вакыт.

1913

ЮК!

Юк кояш — ул да батадыр,
Юк Казан, юктыр Болак.
Юк Кабанның тәмле исе,
Юк ләфирем, юк табак.

Юктыр Әхмәтҗан бабай да,
Ул да зур юрсак кына.
Юк минем төсле шагыйрьләр,
Бардадыр борчак кына.

Юк миңа баккан хатыннар,
Бардадыр курчак кына.
Юк шигырьдә бер вәзен дә,
Бардадыр пычрак кына.

1915—1916

КАЙДА КИТӘМ?

Мин үзем язмак булам бу шигъремне яд итеп,
Үз төсем итеп карарлар, дим, югалсам [да] китеп,

Мин китәм, китми, китәрсең — чара юк,
Чын китәр юлыма сузылган ак әз — кара юк.

Мин китәм кайдан, чиксез юлың тармагын күрмәдем,
Шул чиксез юлдан китеп, кайда очравымны белмәдем.

Бер заманда, шул рәвешле, мин китәм дә юк булам...
Мин китәм дә мин китәм, дип язган шигъремә хәйран булам.

Юк әле, китмим икән, [бу минем] төшем икән,
Юлдан китеп юк булдым, — төш күреп ятуым икән...

Шул төшемдә бер кызык күрдем — язам әле,
И хода, түгел ул мәгълүм Казан әле.

. . . .
. . . .

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (1)

(Тукайга тәкълид)

И саендыр, саендыр, сазда үскән каендыр,
Кичә көндез «Йолдыз» күргән Һади абзыкаендыр,

Байлар кия кара бүрек, без киябез эшләпә,
Иҗтимагый карашларда «Закир» абзаң нишләтә?!

Эчәр идем бал булса, йөрәгемә ял булса,
Күк кәҗәмә указ алам «Гыйният» абзый сау булса.

Аргы яктан бирге якка чыгар идем өч атлап,
«Вәли мулла» мөфти булыр, тамга җыя өч яклап.

Актыр пәке башлары, күктер пәке башлары,
Пич башыннан төшәлмиләр, мөфти булыр чаклары.

Ап-ак каен кул саен, яфраклары чал каен,
Басып торган ботак сынгач «Г. С.» төште чалкаен.

Ак каенның бөресен күке күпләп йөресен,
Хаптыратты «Дин мәгыйшәт» колбасаның эресен.

И тал үсә, тал үсә, башын киссәң, тагы үсә.
«Кармак»чылар бик пычрана, янгыр яумый, югыйсә.

Чыктым сары ат сатуга, сармай эчтем катуга,
Песи-күсе ник тулганнар без барасы «Ак юлга».

И тал нәзек, тал нәзек, тал нәзеге дугага,
«Ил» дә «Холык» агарсын дип, дога кылыйк аллага.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (2)

(Тукайга тәкълид)

Безнең атлар күк ала, акрын басып күп ала,
«Доносчы абзый»... вафат булды, милләт хәле төзәлә.

Алмачылар алма ашыйлар, алманың ни туклыгы?
Мин дә мөфти булыр идем, дус-ишләрнең юклыгы!

Кашың кара бик нәзек, милләт алдау бик язык,
Язык казык башында, акча тора кашында.

Алмагачта алма күп, ир-җегеткә хәйлә күп,
«Гыйнаят» абзый озак тормас, аннан куштаннар да күп.

* * *

Алмагачның алмасы ачы була пешмәсә,
Садрый байны надан диләр, фәтва бирә ләбаса.

Безнең илләр ил түгел, борчак чәчәр җир түгел,
Динсезлектә «мирзалар» да шәкертләрдән ким түгел.

Җил булмаса да җилберди безнең бакча таллары,
Кул куйганга үкенәләр хәзер Уфа байлары.

Абау алла, ни болай ла, кыйблалардан җил-давыл,
Ялынмыйбыз надан байга, ходай үзе биргән ул.

* * *

Биек каен башында — саескан түгел — чәукә,
Не торопись, «Закир абзый»! Запылати мең тәңкә!

Өстәл өстем кенәгә, асларында күләгә,
Сафсим мәшһүр булыр өчен «Әмирхан» да дикләнә.

Фәтва биру — дини яктан дөресме-түгелме икәнен күрсәтеп бирү.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (1)

Сары атымны бәйләп куйдым, әзрәк сулу алсын дип,
«Рәшид казый» читтә йөри, башым гыйбрәт алсын дип.

Аклы-кукле күгәрчен укый «Әлхәм» сүрәсен,
«Баттал», «Габди» макташмыйлар, дустлык бетте, күрәсең.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява өй түбәсе калайга,
«Дин мәгыйшәт» мидал биргән календарьчы малайга.

Кабан күле өстендә байлар аты юргалый,
Шагыйрь булып йөргән кеше «чиновник» та булгалый.

Мәңгәрләрнең йорты зәңгәр, без дә шулай буятыйк,
«Урталык»та, «Хәят» чыкмый, «Кояш» укып юатыйк.

Ачы буран, салкын җил, чиметә ике битемне,
«Ил»нең саек чыкканлыгы ашый йөрәк итемне.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (2)

Ак Иделне кин диләр, аны диңгез димиләр,
«Туган тел» кала димиләр, «мишәр» телен димлиләр.

Ике туры ат уйныйдыр, муйны кыйгач буйлыдыр,
Әстреханда ике учитель донос ясап уйныйдыр.

Ай-һай, дустым, мыегың — сандугачның койрыгы,
Бер мөхәррир пилмән сата, бар да ходай бойрыгы.

Ак пирчәткә эчендә алтын балдак шәүләсе,
Бер Казанда, бер Мәскәүдә мескен «Шалт-шолт» гәүдәсе.

Сандугачлар су ташый, кайда икән су башы?
Гаяз хәлфә ялгыз башы, Хозыр булсын юлдашы.

Аккош күлләрдә була, борны суларда була,
Мәрхүм «Тукай җәмгыяте» черт-иблис кайда була.

Безнең ындырның артында кыр казлары тезелгән,
Казандагы бер «Ширкәт»тән инде өмет өзелгән.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (3)

Аккош кунган имәнгә, тал яфрагын игәнгә,
Мин җырламый кем җырласын, җырлыйм җаным көйгәнгә.

Апрель җитми агып китми Ак Иделнең бозлары,
Мода артындин туктар микән татар хатын-кызлары?

Ак калфагың җаңалган, җаңалса да каралган,
«Сәйяр»дәге шәп артистлар әллә кая таралган.

Акбүз атның аңлысы ындыр артын таптамый,
«Вәкыйф» белән «Чыкылдаучы» тәнкыйтьне һич аңламый.

Ак Иделнең тугаенда үсә икән ак каен,
«Алтын теш» белән «дуслар»ны без күтәбез көн саен.

Акбүз атлар сирәктер, матур йөргән кирәктер,
«Ишми» белән «мөпти» кебек кеше бездә сирәктер.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (4)

Сары атым сабмалы, туры атым нокталы,
Авыр хәлләр искә төште, бер җырлаем, туктале.

Ак бәз элдем читәнгә, чигеп челтәр итәргә,
«Богослав»лар козгын була, белмим, ни хәл итәргә?

Каенлыкның какысын, ашар идем татлысын,
«Дәрдмәнд»кә нәрсә булды, нигә шигырь язмый соң?!

Кимә итек, ки ката, ката канны тарата,
Харитонов татарларга хата Коръән тарата.

Алмашыймсың, балашыймсың, бал татлырак алмадан,
«Җомга көн кибет ябу»ны инде сорыйк алладан.

Алтын алка авыр тарта, алты мыскалдан арта,
Җырласак та, моңлансак та безнең хәсрәтләр арта.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (5)

Балан куак эчләрендә бадьян чәчәк атадыр,
«Коръән тәрҗемәсе» чыкмый, нәрсә көтеп ятадыр?

Иртән торып тышка чыксам, кояш та юк, ай да юк,
Җинаять казый мөфти булса, безгә тагы файда юк.

Сары сандугач баласы басып сайрар тал тапмый,
Бар «Кояш»та «Имгәк» мәхдүм, сугышмыйча ямь
тапмый.

Карурманның артында карчыга җон туздыра,
Татарда күп зыялылар бушка гомер уздыра.

Кара дуга, җиз алка байлар җигә дан өчен,
Шиһаб абзый ник эндәшми — «Мәктәп» чыкмаган өчен.

Өй артында алмагач, кистем алма булмагач,
Гаяз абзый, яз романнар, инде «Ил»ең туктагач.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (6)

Сары, сары сандугач, очып китә кагынгач,
«Мулла бабай», «Теләнче кыз»ны җырлап сорыйм
сагынгач.

Алмачылар алма сата, алманың ни табышы,
Уфаны мәркәз ясау тик Закир хәлфә сагышы.

Тал әйләнә, тал әйләнә, талга ефәк бәйләнә,
Безнең «кәмитет» эшләре бигрәк әкрен әйләнә.

Су агадыр барадыр, су көеге камадыр,
«Ш К» хикәя язмый хәзер: алтын унай тамадыр.

Безнең урам ак балчык, бата күрмә — атлап чык,
Кәрлә малай шәп мөәррих, ләкин әзрәк мактанчык.

Тау башына карале, каен яфраи ярамы?
«Безнең көнләр» кайчан чыга? Әллә чыкмый каламы?

Мөәррих — тарихчы.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (7)

Өстемдәге күлмәгемне саламын да киямен,
«Таң» алдында «Ил» туктагач, янамын да көямен.

Җиккән атым күк ала, әкрен басып күп ала,
Инде мөфтине сайлаулар Сафа үлүгә кала.

Мәдрәсә почмагында, ут яна учагында,
Әхмәтов «Милләт» чыгара кәйфе килгән чагында.

Җилбер-җилбер ука чук, нык җилберди — җил дә юк,
Муса абзый «Козгын» булгач, тавыш-тыны бер дә юк.

Тәрәзә ачып уклар аттым, пулат башы тимергә,
Карагруһ «Хур» гәзите туктар микән гомергә?

Тәрәзәдә алмалы гөл, үсә яңгыр яуганда,
«Аң» айда бер көчкә чыга, вакыт табылмаганга.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (8)

Алма пешәр, өзлеп төшәр хан, түрәнең тәхтенә,
Мөхәммәдьяр мөфти үлде Сафа мәхдүм бәхтенә.

Сандугачның баласы гөл чәчәген ярата,
Уфадагы Сабир мулла ни дип нәфәкъ тарата?

Төрле уйлар уйлый-уйлый уйлар сарды эчемә,
Сентябрь числосы җиткәч, «мөнбер» төште башыма.

Тауга менсәм, тау биек, түбән төшсәм — тамырлык,
И катыкчы, хәлең авыр, ходай бирсен сабырлык.

Саждәнең камчат бүреге күз өстендә күләгә,
Үтми сүзең, бичара халык, син аңарга сөйләмә.

Аргы яктан салган басмам бирге якка җитмәгән,
Эш сөюче депутатны ходай насыйп итмәгән.

Кабан күле тирән күл, аяк бәрми йөзәбез,
Безнең хәлләр бигрәк авыр, тик «Таң» көтеп түзәбез.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (9)

Сайрый-сайрый сандугач, очып китә кагынгач,
Җырламас җирдән җырларсың, күңелсез эшләр тугач.

Элеп куйган ак яулыгым җилбер-җилбер итәдер,
«Дингә мишәйт» соң заманда «миссионерлык» итәдер.

Кызарып кояш калкадыр, кара урман артында,
Сакла «Гыйффәт»не, ходаем явызлар тырнагыннан.

Кулымдагы яулыгымны элеп куйдым пәрдәгә,
Әстерхан халкы тап булды бер доносчы бәндәгә.

Бакчамдагы гөлләрнең арасыннан мин үтәм,
«Мөселман съезды» булуын ходайдан теләп көтәм.

Тәрәз ачып җимләр сачтем ак канатлы тавыкка,
«Тазат сәләс» һөҗүме фаш булды [ла] халыкка.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (10)

Скрипка башлары бәреләсарыла башлады,
Нигә безнең сукыр шагыйрь ырылдавын ташлады?

Ай яктысы бик якты дип, ташка басып су алам,
Ирем содатка китте дип, ятлар белән чуалам.

Сезнең авыл, безнең авыл, арасында — җил-давыл,
Хисап сораучы булмагач, вәкыф шулай була ул.

Үлгән куянәй еландай сузылып ята чуен юл,
Мәдрәсәгә солдат тулгач, ник гаепле булсын ул.

Уфа байлары дисезме? Алар шулай итәләр,
«Галия»гә дигән акчаны «Галя»ларга илтәләр.

1915

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (II)

Атның асылларын җигеп йөри бездә түрәләр,
«Вакыт», «Тормыш» гел сүгешеп кемнең малын
бүләләр?

Килгәч, дустым, минем янга, итмә мине бимаза,
Карт казыйны калкан итеп «Габди» мәкалә яза.

Мендем тауның башына, бастым зур-зур ташына,
Эшләсәләр — эш өелгән депутатлар башына.

Кемләр килеп монда корган асылкюшлар тозагын?
Епископ Андрей борды мөселманнар колагын.

Кара урманның артында борылып үскән бер каен,
«Ил»челәрнең «Сүз», «Тавыш»ы чыкмас икән,
ходаем...

Чылтыр-чылтыр су агадыр безнең артта — елгада,
Яшь Кушмыйлар күренгәли тагын безнең дөньяда.

1916

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ (12)

Өй түбәсе шома такта, кыек баса күгәрчен,
«Йолдыз» «Сүз»не җиңалмады, куәте юк, күрәсең.

Ап-ак диләр дә мактыйлар ак куянның баласын,
Муса абый «Кара көч»кә ни дип башың саласың?

Иртә торып тышка чыксам, бал тамадыр алмадан,
«Ислам-мәгариф» чыкмауны телик, дуслар, аллаһдан.

1915

ТАТАРЛАР АРАСЫНДА

Таушың бетәр кычкырып,
Тының бетәр бушка өреп;
Табалмассың аз суманы
Ел буе бушка йөреп.

1915

ФӘТВАСЕ ҺӘМ ФӘТВАЧЕСЕ

Бер кулыңа тот китаб син, музыка — башкасына,
Кил уку! Китаб яки музик уйна, мибах синә.

Мәхлукаң бик түбән алдымда, мин аны беләм;
Һич төкермим дә синең китаб, гәзит укуыңа.

Каршыңа барсаң музиклә, сөенеп егълый синә,
Белмәгән милләт өчен һәр эштә бер хөкем кирәк.
Музыка хакында безгә «ат» хөкем эшләү кирәк.

1915

МИН

Җырласам — җырлармын — исең китәр,
Хурласам — хурлармын, җанга үтәр;
Куркытсам өстенә бер кычкырып,—
Куркытырмын сине Газраилдән битәр.

1916

ТАҢ ВАКЫТЫ

(Сәгыйд Рәмиевкә тәкълид)

Таң вакыты, йоклый татар,
Йоклап бетә безнең татар;
Бар кешеләр, йокламыйча,
Донос ясап вөждан сатар.

Вакыт инде уйганырга,
Күзләр ачып уйланырга.
Ярым-йорты нәрсәләрне
Бөтенләтеп кулга алырга.

Җитә, туган, мөкатдәс таң,
Шул «Таң»ны син каршылап ал;
Ул «Таң» була инде «Чын Таң»,
Чынлык белән бирер зур аң.

ХИКӘЯЛӘР, МӘКАЛӘЛӘР, ФЕЛЬЕТОННАР

1912

ӘЙТЕП УЗЫЙМ

Сөекле дус-ишләрем!

Мәгез, тотыгыз әле үзишегез язган «Шигырьләр җыентыгын»!

Тиндәшләр! Иң элек сезгә үземнең авыл мәдрәсәсендә генә укуымны, ягъни шунда «Сукыр тәкә», «Чәүәкәй», «Бетле баш», «Кем сукты», «Хан — вәзир», «Чирмешле» кебек төрле уеннар белә гомер уздырганымны, атна саен шәкертләр белән мендәрләшеп, йон аралаш тузан дәрьясында йөзгәнемне, соңрак, 15 яшькә җиткәч, укудан туктал‍ып, казакъ арасына китеп, бер-ике елдан соң әйләнеп кайтып, атаклы мәдрәсәләребезнең берсенә керергә насыйп булганын шатлык белән белдереп, өйрәнмәгән каләмемне икенче якка борып тибрәтим.

Әй, тиңдәшләр! Мин бу җырларымны казакъта чагымда, мужик әйткәндәй: тик ятканчы бер «этлек» булсын, дип кенә язган идем. Боларны ташка бастыру ягы, ичмасам, хәтеремә кереп кенә дә чыкмаган иде. Бәй, илгә кайткан идем, ибтәшләрем миңа чат ябышты: «Әй-йә-йәй! Шигырьләрең бик шәп икән, бастыр гына, ибтәш»,— диделәр, йөдәтеп бетерделәр. Мин аларга: «Бу төссез сүзләрне ничек итеп бастырмак кирәк! Бастырсаң да бер дә файда булмас, бәлки үземне әллә ниләр белән тиргәрләр генә»,— дидем дә ни — бер дә колакларына кермәде шул. «Әй, ибтәш! Юкка гына шикләнәсең икән, җырларыңа ия бетәсе булмас әле, үзебез шикелле татарча сукалый торган малайлар беткән дисеңмени? Китапчыларда синекеннән дә алама шигырьләр, көйле хитаплар бар бит! Аларга караганда, синеке биш артык...» кебек сүзләр белән үз уйларын ипли генә бирделәр.

Шуннан соң алар белән күп җиңешеп вә тартышып, хәтерләрен калдырасым килмәде — тоттым да бастырдым (ни

булса булыр, дидем дә бастырдым). Ләкин бу шигырьләрем үземнең иш вә тыңдашләрем өчен мәйданга чыгарылды, белекле, аңлы шәкертләр вә хәлфә абзыйлар өчен түгел. Андый белекле вә шәпле абзыйлар моны карап чыксалар, күз алларына авыл мәктәбендә чабата-башмак киеп, ашханә алдында (яисә авыл мәктәбенең ашханәсендә) самавыр куеп йөри торган, төтенгә сеңешеп беткән шәкерт малаен, яисә чүбек-мүбекләр белән тулган башына тубалдай чәллә салып, сукыр кортканы җете азан белән өшкерергә барган суфый шәкертне китерсеннәр,— шуларны күз алларына китереп карасалар, матбугат болгаган, фәлән иткән, төгән иткән, диергә юл таба алмаслар.

Ләкин үз җырларымны үзем бик яратам, үземнеке үземә бик ягә. Бабайларыбыз: «Үз төтенең кәкре чыкса да, үзенә төз күренә»,— дигәннәр бит; диюләре шундый туры сүз, һәм шагыйрь Габдулла әфәнде дә: «Керпе үз баласын йомшагым, дип әйтә,— ди,— аю үз балаларын аппагым дип әйтә»,— дип «Халык әдәбияты»нда язган бит.

Бу җырларымны казакъта чагымда язганлыгымнан, кайсыбер шигырьләремнең арасында берәм-сәрәм казакъча сүзләр булса да, шул көйгә калдырдым. (Аннан зыян булырмы икән?)

Шигырьләремне рәте белән, ягъни иң элекке шигырьләремне иң башка, иң соңгысын соңга яздым.

Ш. Б.
1912 ел, ноябрь башы.

1913

ИШМИ СӨЕНӘ

«Ишми» сөенә. Доносларым белән җәдидләрнең койрыгын шиңдерәм, дип сөенә. Җәдидләр җәһәннәмгә төшеп бетәрләр дә, миңа оҗмахта типтерергә урын буш калыр, дип сөенә. Муса, Зыя, Риза, Фатихларга каршы дулаган «Дин мәгыйшәт» «айгырларын» күреп сөенә. Муллаларның бәлеш әйләнәсендә чәч, мыектан бәхәс итеп утыруларын, хәлфәләрнең: «Бәна бәрникә, әгәр чендикә»ләр белән шәкертләрнең миен черетеп, сыртын каезлап гомер уздыруларын, кызларның койма ярыкларыннан, очырма түбәләреннән генә узган-барганны карап торуларын күрә дә: «Ах! Эш минемчә бара әле!»— дип куя.

Доносым белән «Буби мәдрәсәсе»нең төбенә җиткән идем, аллага шөкер, бәддогам «Галия мәдрәсәсе»нә дә тиде: киләчәктә бөтен татарларны минем юлдан яздырып чыгаруга хезмәт итәчәк шәкертләрне минем бәддогам кызу канлылык һәм әллә нинди тәгассеб ачуы белән агулады да араларына мөгаллимнәргә һәм мәдрәсәгә каршы салкынлык хисе төшерде. Шуннан соң илледән артык шәкерт ызгышып чыгып киттеләр. Инде, и ходаем! Шушылардан үрнәк алып, бөтен ысул җәдид шәкертләре мөгаллимнәренә, мәдрәсәсенә, ата-анасына, иптәшләренә, кыскасы, бөтен милләтенә ала күз, кара күңел белән карасыннар иде дип дога кылам... дип сөйләнә-сөйләнә дә, шатлыгыннан үрле-кырлы сикерә, сөенече көннән-көн арта, көннән-көн әллә нинди яңа донослар ихтирагъ итә.

Егетләр! «Ишми» шулай мәңгегә сөенер микәнни? Аны бер дә көендерерлек нәрсәләр булмас микәнни? Юк, ул мәңгегә сөенә алмас, дөнья аңа мәңгегә көлеп тормас. Аның бу сөенүе вакытлы гына булыр. Менә аның тагы күз аллары караңгыланыр.

Тәгассеб — фанатизм.
Ысул җәдид — яңа алым (метод).
Ихтирагъ итә — уйлап чыгара.

1913

МӘКАЛЬЛӘР ФӘЛСӘФӘСЕ (1)

Безнең мәкальләр борынгы бабайларның бик күп тәҗрибә вә уй белән әйтелгән сүзләре булганга күрә, бер мәкальдән әллә нинди мәгънәләр, тәэвилләр, фәлсәфәләр чыгарырга мөмкин. Хәтта бер мәкальне шәрех итә башласаң, әллә никадәр язып ташларга да була. Менә мин «Акмулла» укучыларын мәкальләр дөньясы илә таныштыру өчен берничәләрен язып күрсәтәм:

1) **«Колның кайгысы бер — качмак».** Ягъни, чыпчыкның үзенә күрә бизмәне, дигән кебек, һәркемнең үзенә күрә кайгысы бар. Бу мәкальне төрле сыйныфка тәтәбыйк итеп карасак, менә болай дигән сүз була:

Казакъ мулласының кайгысы — бер казакъның чирләгәнен күрмәк. *Татар мулласының кайгысы* — мәхәллә мәктәбенең башына җитмәк. *Татар шәкертенең кайгысы* — әллә нинди мисле булмаган «шәп кеше» булып баш күтәрмәк. *Татар мөхәрриренең кайгысы* — бер-берен каләм илә чәнчеп җиңәргә тырышмак. *Һади хәлфәнең кайгысы* — вакыты илә төрле хыялый мәкалә вә ялган хәбәрләр язып булса да мөштәри күбәйтмәк һәм, мөфти хәзрәт үлсә яки истигъфа итсә, мөфти булып сайланмак. Вәли гайре ниһаять китә бирә.

2) **«Хатынга якын барма — карасы йога, балага якын барма — бәласе йога».** Бу мәкальдән истинбад вә истихраҗ кылып, менә нинди бер мәкаль чыгарырга мөмкин: «Татарның мәчетенә кермә — микробы, мәдрәсәсенә барма — какрыгы йога».

Тәэвил — аңлатма.
Шәрех итү — анализлау.
Тәтәбыйк итү — туры китерү, чагыштыру, тикшерү.
Мөштәри — сатып алучы, подписчик.
Истигъфа — отставка.
Истинбад — нәтиҗә ясау, йомгаклау.
Истихраҗ кылу — чыгару, табу.

3) **«Агай-энегә кадерем юк — битемне күрә, хатыныма кадерем юк — итемне күрә».** Бик дөрес мәкаль; мәсәлән, мин бер шәкерт, ятам мәдрәсәдә, мөгаллимгә кадерем юк — забастовкамны күрә, шәкертләргә кадерем юк — тәрилкәмне күрә. Мөгаллим: итагатьсез, башбаштак, ди. Шәкертләр: иттифаксыз, шпион, ди. Вәссәлам.

Иттифак — берләшмә, союз.

1913

МӘКАЛЬЛӘР ФӘЛСӘФӘСЕ (2)

«Акмулла» укучылары гел көлкә сүзләргә генә ияләшеп китмәсеннәр өчен әзрәк фәлсәфә дә сатарга кирәк бит! Әүвәлдә «Мәкальләр фәлсәфәсе» исеме белән бер баб ачкан идем, инде шул бабымны дәвам итәрмәгә телим.

1) **«Каз каңгылдар һәр җирдә, ир такылдар тар җирдә».** Менә бу мәкаль бабайларның фикерләре үз тирәләреннән артмаган һәм тәҗрибәләре азрак чагында әйтелгәнгә күрә, хәзерге заман хәленә чагыштырып карaганда, вакигъда муафыйк чыкмый. Муафыйк чыкмый диюемне исбат итәм. Мәсәлән, бездән башкалар (яһүд, әрмән кебекләр) һәр җирдә вә һәрвакытта туктаусыз такылдаган вә бакылдаганга күрә алга киткәннәр вә баеганнар, һаман да әрсезлекләре аркасында китеп утыралар. Ә безнекеләр, теге мәкальгә буйсынып: «Без ир кеше бит!» — дип, тавыш-тын юк, ята биргәннәр. Менә шул көйгә ятып та калганнар шул!

2) Теге мәкальгә каршы килә торган: **«Еламаган балага имчәк бирмиләр»** мәкале бар. Күп фикер, ачы тәҗрибә соңында «мөбәрәк бабайларыбыз»дан килеп чыккан бу мәкаль югарыдагы мәкальне нәсех итә. Инде бу мәкальне тормышыбызда корал итеп, теге мәкальнең мәгънәсен чыгарып ташларга калды. Димәк: җыларга тиешле урында җыларга да, имәргә тиешле имчәкләрне имәргә.

Тирбәткән бишектә җыламый гына ятсаң, инәң сиңа имчәк бирмәс шул!..

3) **«Кирәк ташның авырлыгы юк».** Ике генә сүз. «Китапларым кирәк булгач, кәрзинкәмне күтәреп, казакъ сахрасында мин дә тинтерәп йөрдем».

Шәкерт.

Баб — бүлек.
Вакигъ — чын, чынбарлык.
Муафыйк — туры килү, яраклы, урынлы.
Нәсех итү — алмаштыру, үзгәртү, юкка чыгару.

«Бәлеш ашар өчен, собраниядә имтихан тотып, шәһадәтнамә алырга булгач, никадәр авыр булса, да тубалдай чалмамны киеп йөр, имеш».

Татар мулласы.

«Фәлән бай дип күперткәч, никадәр авыр вә кыен булса да, мәктәпнең расходын күтәреп торамын».

Татар бае.

«Намусым зур булгач, никадәр авыр мәсьәлә булса да вә никадәр теңкә корыткан бер нәрсә булса да, Уфага барып яңадан газета чыгарырга тотындым».

Вәгыйә.

4) **«Ул тапмас хатын булмас, торырын әйт!**
Мал тапмас егет булмас, кулларын әйт!»

Бу мәкаль казакъчадан булганлыктан, үзебезнеңчә тел илә тәфсир вә тәэвил итәм. Менә болай дигән сүз: 25 мәртәбә бала тапмас татар хатыны булмас, ләкин шуларның бер-икесе тере калуын әйт! Бумажник тотмас егет булмас, ләкин акчасы булуын әйт! Газета чыгармас татар булмас, ләкин «Тәрҗеман»дай сүнми торуын әйт! Җыр җырламас шәкерт булмас, Фәттах шикелле концерт бирүендә хикмәт.

(Ошбуна кыяс кыла бир!)

Шәһадәтнамә — таныклык язуы, аттестат.
Тәфсир итү — җентекләп бирү.
Кыяс кылу — охшату, өлге алу.

1914

ӘГӘР ДӘ МИН БУЛСАМ...

(Хыялларым)

Әгәр дә мин тычкан булсам, «Дин вә мәгыйшәт» мөхәрриренең башын кимерер идем.

Әгәр дә мин мәчет пәрие булсам, кәбәкбаш муллаларны тәпәч илә кыйнап, мөнбәрләрдән җилтерәтеп куар идем.

Әгәр дә мин, алла үзе сакласын, көтүче булсам, хатынкызларыбызны «Сөембикә» болынлыгына куар идем дә андагы ир затларын этләремнән өстереп качырыр идем.

Әгәр дә мин, бәр фараз, тәрилкә булып, хәзрәтләр мине бай алдында тотып торсалар, чәлпәрәмә килеп кайрап төшәр идем.

Әгәр дә мин, ач таллан булып әверелсәм, ялкау шәкертләрнең җилкәсенә генә кадалыр идем.

Әгәр дә мин кандала булсам, татар мәдрәсәләреннән җирәнгән интеллигентларымызның борыннарына ябышыр идем.

Әгәр дә мин җен булсам, дин һәм милләтенә бер тиен ярдәм итмәс байларның эченә керер идем дә: «Кикри-күк... Эчеңә кереп утырдым түгелме, малыңнан зәкят чыгарасыңмы?» — дип, әтәч шикелле кычкырыр идем.

Әгәр дә мин убыр булсам, җиде төн уртасында студентканың бүлмәсенә керер идем дә, язышкан хатларын, көнлек дәфтәрләрен актарып, эч серләренә вакыйф булыр идем.

Әгәр дә мин, харикылгада буларак, «тәгассеб» булсам, Русия мөселманнары арасыннан дәһшәтле болыт булып күтәреләр идем дә, көнбаеш якка барып, көне-төне яварга керешер идем. Тәнбиһ: болыт булып күтәрелгән вакытымда иң куркыныч, иң коточкыч куе-калын «Казакъстан» өстендә булыр иде...

Бәр фараз — уйлап карыйк, мәсәлән.
Вакыйф булу — аңлау, белү.
Харикылгада — гадәттән тыш.
Тәгассеб — фанатизм.
Тәнбиһ — искәртү, кисәтү.

1916

УФА ТИГЕЗСЕЗЛЕКЛӘРЕ

Уфа шәһәренә беренче мәртәбә килгәч тә, шәһәрнең тау өстенә, чокырлы-чакырлы бер уңайсыз җирдә икәнен күреп, «тигезсез» җиргә салынган икән, дидем...

Бүген әллә нишләп «Нум» базарыннан бик иртә кайтып, бәдәнемдә әллә нинди «тигезсез»лек сизә башлагач, азрак күңел ачмакчы булып, базар ягына чыктым. Уфаның «тигезсез» күчәләреннән бер югары менеп, бер түбән төшеп, «рәхәтләнеп» йөри башладым. Базар янында танышмас нәрсәмнән, «Кисекбаш» тәгәрәгән шикелле, җилтерәп барган җиреннән, бер сәләмә зыя[лы]ны кылып, сораштым. Ул: «Иптәш, бу көн безнең театр була, «Тигезсезләр»не куямыз»,— диде. Бездән якында булган бер ләмави татар, яңлышрак ишеткән булса кирәк: «Нәрсә төятергә? Мин буш, безгә урамның «тигезсез» булуы ничауа!» — дип, берничә тартырлык калган махоркасын ташлап, каршымызга килмәсенме?!

«Мин: «Тавык төшенә тары җитә, нәрсә төяргә түгел, театр»,— дигәч, ташлаган тәмәкесен кире алып, үз юлына рәван булды. Әлеге иптәшем театрда старший помошник младшего контролера (...) итүен бик вәкарь берлә әйтте дә, ул да үз юлына сызды; тик калуш үкчәләре артына тия-тия чаттан борылганын күреп калдым. Уфа шәһәрендә татарча театрларның, ел буена бер кулның бармаклары санынннан артмаганлыктан, бик тансык булуы табигый.

Кич булгач, мин дә «Тигезсезләр» карарга киттем. Уенның башлануы, афишада күрсәтелгәнчә, сәгать 8 дә булыр дип, татар хатыннарының мәҗлескә җыелулары шикелле булсын дип, бер ярты сәгать алданрак барсам да, тәҗрибәм вакытның Петроградча булганлыгын белдерде. Шулай итеп, уен башлануына калган ике сәгатьне залдагы халыкны тамаша кылу илә үткәрдем. Зал тулган халык, хатынкызның исәбе-хисабы юк. Каюлары үземезнең милли кие-

---

Рәван булды — китте, юнәлде.
Вәкарь берлә — үзен олы тотып, горур рәвештә.

мебездә, каюлары барышня, госпожаларча, каюлары башына калфак кигән дә, калган киемләре матреналарча, гомумән әйткәндә, тәмам бер курчак иде. Мадмазельләрчә киенгән курчакларның русча гына сөйләшүләрен салкын канлылык берлә үткәрсәм дә, калфаклы халыкларның ике сүзгә бер русча кыстырып йөрүләрен ишеткәч, «тигезсезләр», дидем дә куйдым.

Вакытны тизлек берлә үткәзеп булмагач, бер программа алып, уйнаучыларны карый башладым. Уйнаучылар арасында *«Каргалы»* (?) вә кыска гына исемләр күргәч, «ә уйнаучылар бик атаклы, эре нәрсәләр икән, дидем»; бу уйнаучылар арасында программада күрсәтелгәнчә *«Себектегин»* дигән нәрсәне күргәч, азрак кызардым да.

Ниһаять, өченче звонок булды. Халык уен залына лапырдашып, пожардан качкан халык шикелле, хәзер генә тула башлады. Менә бервакыт яңгыратып кул чаба башладылар; моның әллә урын тапканлыкларына шатланганлыкларыннанмы, әллә: «Утырып алдык, башларга мөмкин»,— диюләреме дип, нигә икәнлеген белмәгәч, ирексез «тигезсезләр» шул була, дидем дә җибәрдем.

Роль ияләре дәресләрен, чыгып, тыңлата башладылар, рольләрен азрак ятлаганлары суфлер будкасына якынрак килеп тә тыңладылар. *Сәүдәгәр*...нең «Оптик» магазины турысындагы эшләр хакында трагически тавышлар берлә сөйләгәне, тиешсез озын паузалары, *Рокыя туташның* рояльдә бер көйне өзеп-өзеп уйнавыннан халыкның зал яңгыратып кул чабуы, соныннан рояльнең сихер коты берлә үзеннән-үзе уен башланганлыгы (сәхнә артында), *«Гимназист»*ның тавышы Мотыйгый тавышыннан да калын булуы, һәр пәрдәдән соң күрми күргән халыкның өзлексез кул чабуы, арт яктан беренче рәттәге «тәпиче»ләрнең сикерешүләре; пәрдә араларында һич булмаса оркестр да русча көйләр булса да (милли көйләр булыр дип уйламыйм да) уйнап тормавы, анда-санда булган мондый кичәләрне бигрәк тә «тигезсезлиләр» иде.

Яшәсен туган тел — яңа милли сәхнә!

1916

«МӘДРӘСӘИ ГАЛИЯ»НЕҢ УН ЕЛЛЫК БӘЙРӘМЕ

(Ярым ходдаг)

Бер заманлар (моннан ун еллар элек) хәзерге «Галия» урыны бер чүплек урыны иде. Менә шунда Зыя дигән ярым башкорт бер «татар», сәфәрендән кайта да «Галия» дигән бер бина торгызырга муафыйк була. Аңа бу эштә «Зариф» дигән, шул чүп-чар оясы мәхәлләсендә мулла булып тора торган, бер мөхтәрәм «карт» бик күп ярдәм итә. Ягъни ул Зыяга мәгънәви рух өреп торучы Исрафил галәйһиссәламнең беренчеләреннән була. Дәхи Зыяның ныклы терәкләреннән берсе мәрхүм Лотфулла Байчурин була. Матди җәһедләренә һәрвакыт тәйяр торучылар бигрәк мәрхүмән мөхтәрәмә Суфия бикә белән зәүҗе Сәлимгәрәй Җантурин була. Менә шулар, тырышып-тырмашып дигәндәй, трехэтажный бер бина коралар. Бу трехэтажный дом строить ителмәс борын Зыя вә иптәш хәлфәләре, шәкерт җыеп, чокыр-чакырлар арасындагы мәчет астында укытып тора башлыйлар. Үзләре рәтле-мәрәтле жалованье да алмыйча, 5—6 хәлфә барысы бергә ташландык бер йортта жить итәләр. Әлхасыйль: аларның күргән нуждаларын бер алла тәбәррәкнең үзе генә белә. Ну, ярый, бу торып торсын.

Киләм максудка.

Ягъни менә шул нуждалар белән башланган эш, менә шул нуждалар белән корылган мәктәб, ягъни «Мәдрәсәи Галия», нуждасын сөйри-сөйри, унынчы елына аяк басып тора. «Галия» шул 10 ел эчендә болганчык һәм гаять каты дулкынлы «Татар диңгезе»ндә ун төрле дулкынга очрап, ун төрле болганчыкка болганып, айкалып-чайкалып дигәндәй,

---

Ходдаг — ялган, хәйлә.
Муафыйк була — хуплый, хуп күрә, кирәк дип таба..
Мөхтәрәм — хөрмәтле.
Дәхи — шулай ук.
Матди җәһедләр — материаль тырышлыклар мәгънәсендә.
Тәйяр тору — әзер тору.
Зәүҗе — (хатынның) ире.
Әлхасыйль — кыскасы.

дәвам итеп килә. Ләкин айкалып чайкалса да, аның истикъбаленә, аның өмидле һәм якты истикъбаленә зарар иреш-ми. Ул, дулкыннарга очраса да, өмидсезләнми. Елдан-ел өмиден арттыра. Елдан-ел дулкыннарының зарбәсенә ныграк күкрәк киерә башлый. Шулай итә торгач, дулкыннар аны аз кага. Истикъбаль дәхи дә әрчелә төшә. Киләчәге шома ялтырый. Дулкынсыз күренә. Күзгә күренеп торган дулкыннар юк дәрәҗәсендә кала.

«Галия», 9 нчы елга китде дигәндә, Уфа байларының байкотына очраса да, аңа ул «шырт» та итмәде, бәлки куана гына. Бәлки, кинәеп китеп, иркенләп сулыш кына ала. Димәк, «Татар дингезе» өстендән йөзеп бара торган «Галия» корабы милләт кулына кала. Аның койрыгын хәзер милләт тотачак, аның, димәк, утыз миллион татар истикъбален тәэмин итәчәк. Бихисап капитанлар, яңа матрослар тәйяр торганда, корабның 2—3 капитаны пущай китә бирсен!..

Ну, алар китделәр. Алла аларга да ак юл бирсен! Барыбер аларның да ниятләре хәер... Әнә бит: күрмисеңмени, как «Галия»не ташладылар, и так «Госмания»гә барып та керделәр һәм эшли дә башладылар. Бәракалла, бик рәхмәт... Арба ватылса утын, үгез үлсә — ит, дигәндәй, милләткә файда гына ич ул... Ичмасам, ике җирдә ике «Галия» берсендән берсе уздырырга тырышыр. Менә шулай иттереп, каш төзәтәм дип, күзен чыгарган кабилендән, ике «Галия» берсен-берсе узам ди торгач, милләтне тәрәккый итдереп куярлар әллә кая... Рәкыйблек яхшы нәрсә ул тегеләй!.. Тик безнең Зыя берлән Закир генә, рәкыйб булганлыктан, бер-берсен куралмыйлар.

Пәрәмәч! Тагы читкә чыгып китдем, максудка килергә кирәк: менә шулай «Галия»не байлар ташлагач, и бер заман керешге, агай, милләт шауларга!.. Колагың гына түз-сен... Тегендә берсе Зыяны чөйли, монда берсе эттән яман сүгә, анда берсе байларның тетмәсен тетә: «Нигә, ди, Зыяның вә шәкертләрнең диненә кагыласыз, ахмаклар? — ди.— Адәм көлкеләре»,— ди. Бер ягындан «Дин вә мәгыйшәт» сөенә. Байларның бу эшен ул яңа тәүфыйкка кайту, яңа мөселман булу, дип тәлкыйн (толковать) итә. Байларга, киң кочакларын ачып, рәхмәтләр, тәбрикләр яудыралар, тәүбә

Истикъбаль — киләчәк.
Зарбә — сугу, кыйнау.
Бәракалла — бик яхшы, әйбәт.
Кабил — төр, төркем.
Тәрәккый итдереп — җыеп, оештырып мәгънәсендә.
Рәкыйблек — ярыш, конкурентлык.

яңарталар. Аларга иман укыйлар... Зыяның динсезлеге әшкәрә беленде, дип һәм, ничә ел кычкырып килгән сүзләремез дөресткә чыкды, дип шаркылдашып көләләр.

— Әй Пәрвәз! Сиңа гарьлек, гарьлек!..— дип нус күрсәтәләр.

Сөбханалла!.. Тагын читкә чыкканмын... Килим максудка. Быел «Галия»»не Уфа байлары ташласа да, милләтнең ничек каршы алганын гәзитәләрдә аңладык. Андан да мондан, рәхмәтле янгыр кебек, иганәләр явып торганын Зыяның игъланлары аша күреп тордык. Зыяның үзен дә тегеләй «аяклы эш үрнәге» диміі туры килмиі: бит, исәркәй, байларның чыкканын ишеткәч тә, садака янчыгын тоткан да Мәкәрҗәгә киткән. Киткән дә, исәркәй, янчыгын тутырып та кайткан. Менә җен!.. Йә, «Галия»нең шундый кешесе булгач, бетәрмени ул?!.

Читкәрәк чыкмас борын, тизрәк максудка борылам:

«Галия» быел хөр генә яшәп, яхшы гына чыкды шикелле. Шәкердләр дә элекке елларга караганда күбрәк җыелган, дип ишетдек. Һәм быел Галимҗан Ибраһимовның керүе «Галия»гә каршы текәлгән авыр-мәсхәрәче ачулы күзләрнең кире алынуына сәбәп булды. Һәм шәкертләрнең Галимҗандан чамасыз, чиксез мәмнүн булганлыкларын да ишетдек...

Ну, инде мәсьәлә менә шунда: «Галия», 9 ны тутырып, унга китде. Димәк, ун еллык бер бәйрәм ясарга кирәк була. «Галия» мәэзүнләре моңарга әһәмият бирергә тиешләр дип беләм. Әле Һади абзый да «Йолдыз»ның ун еллыгын исап алды ич... «Галия»нең «Йолдыз» кадәре генә хезмәте юкмыни? Уйлап караганда, «Галия» хезмәте тиңләштермәс дәрәҗәдә бөек. Аның чыгарган бер мәэзүне, мәсәлән, бер «Һади» урынына тора. Бер мәэзүне бер «җанлы йолдыз» аның һәм, вакыйган,— «бу кадәр караңгы булыр икән, яраббн!» — дип сокланыр дәрәҗәдә караңгы татар дөньясын яктырткан йолдызларның чулпаны «Галия» түгелме ишшү (еще)?!. Шулай булса, мәэзүнләре генә түгел, мәэзүнлекдән мәхрүмләре дә катышып, бер бәйрәм ясарга тиеш. Бәйрәм ясау хакында әнә «Сүз» гәзитәсендә Вәсимләр-фәләнләр яздылар. Шуларның фикере мәслихәт: 25 июньләрендә бәйрәм булсын. Менә шунда, алар әйткәнчә, «Галия»нең истикъбале хакында фикерләр бәян ителер,

---

Әшкәрә — фаш ителеп; ачылып.
Игаәә — халыктан җыелган акча.
Мәмнүн — разый, шат.
Мәэзүн — тулы хокуклы белгеч мәгънәсендә.
Бәян ителү — ачыклану.

21

борчак сибелер, танышылыр. Вакыт калса, зияратка менеп, «Зариф» хәзрәткә «ясинмы», «тәбәррекме» — берәр сүрә тәгәрәтелер. Аннары, хәл җитсә, бер ике-өч мичкә бал алдырып, Идел аръягына чыгып, «Галия» шәрәфенә кадәх күтәрелер. Аннары, алар әйткәнчә, «Галия» исемендән бер «мәҗәллә» чыгару хакында уйланылыр. Фәкать шунысы бар: ул гына калса-нитсә, ни рәвешле булыр соң ул?!. Анда шул гел «Галия» шәкертләре генә язар микән? Мөндәриҗәсе нидән гыйбарәт булыр микән? Ни бабтан язылыр? Мәдрәсә исемендән булгач, ысул тәкълим вә тәрбия бабыннан язылыр дисәң, исме дә мәгълүм булып бетмәгән бер нәрсә белән шәкерт ваксынырмы?.. Ичмасам, педагог Шонаси да чыгып китте. Ул булса, сәтрәләрдән урлаштырып булса да, материал бирер иде. Шәрекъ мәсьәләсе һәм хатын-кыз базары хакында язарлар дип әйтсәң дә, ул мәсьәлә хакында материал бирүче Закир юк.

Инде әгәр фәлсәфә язарлык дисәң, «Галия»не «фәлсәфә учагы» дип сүккән Батталлар тагын ныграк кабарынырлар. Ул бабтан яза күрмәсеннәр берүк! Һәрхәлдә, мөндәриҗәсе дә билгеләнер, исеме дә табылыр, алары кыен булмас. Ну бит, аның белән генә эш бетми. Аңа баш мөхәррир кирәк, мәсьәләнең кыен ноктасы шунда. Баш мөхәррир хакында, кызма баштан, тарткалаш-ызгыш китсә, бәйрәмдән ни ямь калыр?.. Бар да мөхәррир буласы килер. «Галия» шәкертләре бар да язучы бит. Мәсәлән, бер яктан: «Мин булам мөхәррир, чөнки мин язучы мәэзүн булу өстенә, мәктәпкә дә якын торам»,— дип Хәлим Искәндәрев чыкса, икенче яктан: «Кит андан, мин булам, мин барыгыздан да чибәр язам»,— дип иҗрәеп Шәһид Әхмәдиев килеп чыкса; өченче якдан: «Мин, Уфа кешесе булуым өстенә, матбагада да торам, бәс, мөхәррирлеккә мин мөстәкыйкъ»,— дип мәтәләймәтәләй Мәҗид чыкса, бәйрәм ихтиляф мәйданы булмасмы дим?..

Шуның өчен, әй мәэзүнләр! Сезгә әйтәм: хәзергә мәҗәллә чыгармый торсаңыз да ярар, тик Уфага җыелып, үзегезнең барлыгыгызны белдереп китә алсагыз да бик шөкер итәрсез әле!

Шәрәф — кадер, хөрмәт.
Кадәх — рюмка, бокал.
Мәҗәллә — журнал, җыентык.
Мөндәриҗә — эчтәлек.
Баб — тема мәгънәсендә.
Ысул тәгълим — укыту ысулы.
Сәтрә — китап юлы.
Шәрекъ — Көнчыгыш.
Мөхәррир — язучы, журналист.
Матбага — типография, китап баса торган урын.
Мөстәкыйкъ — яраклы, туры килү мәгънәсендә.
Ихтиляф — дау, ызгыш.

1916

ТӨРЛЕ ХӘБӘРЛӘР

Үткән ел гына Уфа татарлары, китапханә кирәклеген исләренә төшереп, Аксаков бабай исеменә ачылган библиотеканың почмагына шөгъбә ачканнар иде. Әнә шул шөгъбәгә «Дин вә мәгыйшәт»тән башлап бераз газета вә журналлар килә. Газета вә журналлар, вакытында җыелмаенча, бер хаос кеенчә яталар, кайвакытларда өр-яңа журналларның да келе күккә очкан бу шөгъбәдә, ичмаса, мөселман матбугатын тикшереп тора торган аерым бер цензор бар шикелле. Көлке журналларында Уфаның кычыткан җирләрен кашыган мәкаләле битләре бөтенләй юк булмый *.

* * *

Уфаның тәртәдән чыккан йәкәнчеләре үткән бер вакыт, «Тормыш» колакларын борганына карамыйча, каты борынның арт санынннан пешерелгән казылыкларны мөселманнарга атныкы, сыерныкы дип сатуларында дәвам итәләр.

* * *

Монда туксан тугыз партиягә бүленгән яшьләр(нең), әгәр дә бер реформатор чыгып, һәммәсен бер калыпка салса, сап-сау яшьләрнең болай милли хәрәкәтсез ятулары дөянең муены шикелле кәкре икәнлеген аңлатса, бәлки, бергәләшеп эш итеп яхшы ук файда китерүләре ихтимал иде дә бит, нишлисең...

Имеш-мимеш хәбәрләргә караганда, бу эш Агыйдел кирегә акканда булачак икән.

Әлли итә бу Уфа, бәлли итә бу Уфа!..

Шөгъбә — бүлекчә, филиал.

* Мәсәлән, 5—6 нумер «Кармак»ның 12—14 битләре юк. Башка журналларда да булынгалый, яисә кара карандаш белән сызылып, җора алмаслык итәләр *(Ш. Бабич искәрмәсе)*.

1916

«КӨЛКЕ КАПЧЫГЫ» ҖЫЕНТЫГЫНА СҮЗ БАШЫ

Көлке кешене рәхәтләндерә, күңелне ача, эч пошуны баса, җитди нәрсәләрне тыңларга бөек бер иштиһаэ бирә, ялыккан кешеләрне җиңеләйтеп җибәрә. Шуның илә бәрабәр көлке калыбына салып сугылган гаепләрне халык көлә-көлә кабул итә вә көлке илә сугылган мәгънәләр халыкның йөрәгенә мәңге онытылмаслык булып утырып кала... Шуңа күрә, «чын көлдергеч», димәк — бөек бер хатыйп, димәк, аның көлкеләре — гаҗәеп дәрәҗәдә тәмле вә мөәссир хотбәләр димәктер...

Иштиһаэ бирә — теләк уята.
Хатыйп — оратор.
Мөәссир хотбәләр — күңелгә тирән үтүче чыгышлар.

1916

МӨТӘШӘББИҺАТ

Коръәндәге — *альма, ан, са, госык*ларны мөтәшәббиһатдән дип йөртәләр бит инде... бәгъзеләр: мөтәшәббиһатнең мәгънәсен алла гына белә, дип кичәләр; бәгъзеләр: аның мәгънәсе менә болай була, дип, үзләренчә төрле якка тарткалыйлар...

Мөтәшәббиһ дигәндән әйтәм: уйлана торгач, газитә вә журналларымызның исемнәрендән мин дә мөтәшәббиһатләр кәшеф иттем бит әле, малай! Ул исә шулдыр:

Безнең матбугат мәукутамызның бәгъзеләренең ахыргы хәрефләре бәгъзеләренә тугъры килә, ягъни бер төсле хәрефкә беткән гәзитә вә журналлар бар. Мөтәшәббиһатне сез теләсәңез ничек аңлаңыз, әмма мин үземчә тәэвил итеп, ягъни мәсәлән, ахыргы максадлары, ахыргы нәтиҗәләре игътибары белән бер мәсләктәләр, яки, һич булмаса, бер җәһәттән охшамый калмыйлар, дип мәгънә чыгарам һәм аның мәгънәсен баганага аякны терәп торып дәгъва кылам. Хуш!.. Алай булса, дәгъвамны исбат итәм.

1) Алыйк, мәсәлән, «Сүз»не һәм «Йолдыз»ны. Икесендә дә ахыр хәреф «з». Вакыйган ахыргы максадлары да бер: «заман»ын, «зәмин»ен карамастан, бер-берсенә зобанн чукмары күтәрү.

Ахыргы нәтиҗәләре: «зыянлы зилзилә» ясау!

2) «Шура» һәм «Акмулла». Менә болар хакында ни диергә?.. Тукта, сабыр ит! Хәзер!.. Болай тыштан караганда бер-берсенә бөтенләй башкалар... «Шура» чыга, «Акмулла» бер дә чыкмый. Онытылганда бер эч поштырып куя. Алай булгач, кайсы җәһәттән охшар?.. Ул кадәр тәмам бер-бер-

---

Мөтәшәббиһат — охшашлык.

Кәшеф иту — ачу, уйлап табу.

Мәукута — вакыты билгеләнгән (*матбугат мәукута* — вакытлы матбугат).

Тәэвил иту — юрау, аңлату.

Мәсләк — дөньяга караш; караштан чыгып алган юл, принцип, нсул.

Зәмин — җирлек, нигез.

сенә охшарга да тиеш түгел алар. Чөнки «Акмулла»ның башында да, ахырында да «а». «Шура»ның ахырында гына «а». Ул да бит әле «әлиф» киемен кигәнгә генә «а». (Немец кепкасын кигән чын татар малайлары кебек.) Ләкин, һәрхәлдә, бер җәһәттән азмы-күпме охшаш булмыйча һич тугры килми ул. Минем «кәшеф»нең базары төшә башлар... Соң, нәрсә булыр?.. Ә, менә-менә, таптым:

«Акмулла» үз бабында әллә нинди «агач авыз» комга утырган «нәмә»ләрнең «әләмә-сәләмә»ләрендән гыйбарәт булган кебек, «Шура» да (күбрәк җире) шул ук «имласыз имамнарның» (указлы мужикларның) ачы-төче «искеләре» белән кайнап чыга. «Шура», минем кәшефне юкка чыгарасы килсә, тагы да яңара төшсен, «шигырь» сымак нәфис әйберләрне анда-монда ташландык чүп-чар кебек кенә чәчеп җибәрмәсен!..

3) «Дин мәгыйшәт», «Мәгълумат» — икесендә дә «т». Вакыйган, калыплары башка-башка булса да, калебләре бер: «тәкъвәлек» киемендә «татар»га «төкерү»! Бәгъзе тәэвилчеләр, ахыры барыбер «т» бит, дип әйтеп, «Вакыт»ны да китереп кыстырмакчы булалар. Ләкин «Вакыт» хакында бөтен җир-күк фәрештәләре сөкүт белән кичәләр. Алай да булса да мин, кәшфиятемә зарар килмәсен өчен, сөкүт белән генә кичә алмыйм. Ахыры «т» булгач, миңа себер ни, сеңер ни... Фәкать шул кадәресе бар: «Вакыт» булгач, аның «төкерүе» вакытлы гынадыр, дим. Вакыйган, бер заманны ул, төкерекләшкән булыпмы — нәрсәкәй, кара-мазар шунда булып маташтыы түгелме соң?!.

4) «Тормыш», «Кояш». Икесендә дә ахыргы хәреф — «ш» хәрефе. Икесенең дә башында «шәкерт-шөкерттән «шөрләп» качкан «шыр тиле» хәлфәләр тора. Икесе дә «шәхсият» «шрапнел»ен ата торган, көндез «шәм» яндырып «шөһрәт» таба терган «шартлавыклар». Максадлары: «шәрәф югалту».

5) «Кармак», «Казакъ». Боларның ахырлары гына түгел, җитмәсә, башлары да бер төрле хикмәтләре булса кирәк.

Вакыйган, «Казакъ»ны уйлап карасак, баштан ук һаман

«Әлиф» — гарәп алфавитындагы беренче хәреф.
Баб — тема, мәсьәлә мәгънәсендә.
Имла — орфография, дөрес язу кагыйдәсе.
Вакыйган — чыннан да.
Тәкъвә — дин кушканны гына эшләү, диндар булу.
Сөкүт — дәшми тору, сөйләшми тору.
Шәхсият — үз файдасына гына кайгыртучанлык.
Шәрәф — кадер, игътибар, хөрмәт, дан.

шул «Казакъ» иде. Әле дә һаман шул, ахырда да һаман шул булачак. Ягъни «Казакъ» баштан башлап ахырына кадәр ил эчендән бер тиенләп җыелган иганәләр янчыгы булып торачак, иганәләр бетте исә, буш янчыгын биленә бәйләп, томагын башына киеп алып, (...) Ырынбурдан казакъ арасына карай тартып китәчәк...

Ләкин «Кармак» хакында бу нәзария һич туры килми: «Кармак» мөкәммәлләшә бара, үзгәрә тора... «Казакъ» кебек, садака-мадакага да мохтаҗ түгел. Соң, ни җәһәттән охшатамыз? Әллә «Әл-Капун без исключения лякүн» дип, бәс боларга мөстәсна инде, җәмәгать! — дип, шул көйгә калдырамызмы?.. Әллә «Гыйлем әл-җәбер» вә «Әл-мәкабилә» буенча к—к=0 (нуль) чыгасы: болар хакында хөкем җарый түгел, дибезме?.. Әллә «Кармак»дан бер хәреф, «Казакъ»дан бер нокта алып ташласак, икесе бер сүздә, бер мәгънәдә калалар, бәс шул җәһәттән охшыйлар, дип котылабызмы? Ләкин бу тәэвил «үрдәкнең шурпасының шурпасының шурпасы» дигән кебек, бик болгавыр, зәгыйфь тәэвил булганлыкдан, «Әһле гыйлем» каршында мәкъбүл тәэвил саналмый. Соң нишләргә?.. Әллә боларның мәгънәсен чыгарырга баш җитмәгәнлеген игътираф итеп, кәшефнең төбе комга терәлмәс борын, тизрәк үземдән галимрәк кешегә — мәсәлән, Муса Бигиевкә мөрәҗәгать итим микән әллә?.. Ләкин анда җибәрсәм дә эш чыкмас сыман. Чөнки «Муса»ның үзе дә «мөтәшәббиһат» булып бара... милләт хәзерге көндә мөтәшшәббиһат хөкеменә кергән Муса хәлен тикшерү белән мәшгуль... Нишләргә инде, ә?.. Лутчы, ни булса булыр, мөфәссирләр кебек, җиңел генә котылыйм куйыйм?.. «Ничек котыласың?» — димә... И, андан котылу ни дә түгел. Ике генә сүз: Валлаһе әгъләм биссаваб! Бетте-китте...

Карагыз әле егетләр ! Ник «Ялт-Йолт», «Аң», «Сөембикә»нең бер-берсенә дә охшамаган?..Моңа сез җавап бирегез! Әйдә, тик торганчы, бер анкета булсын!..

Иганә — ярдәм, булышлык йөзеннән халыктан җыелган акча.
Нәзария — фикер, караш, уй мәгънәсендә.
Мөкәммәлләшү — камилләшү.
Лякүн — булмый.
Мөстәсна — аерып алынган, чыгарма.
Мәкъбүл — кабул ителгән, яраклы табылган.
Игътираф итү — гаебен тану, әйтү, үз өстенә алу.
Мөфәссир — бер нәрсәне аңлатып (ачыклап) бирүче.
Валлаһе әгъләм биссаваб! — алла гына дөреслекне белә, ул гына аңлышмый мәгънәсендә.

1916

УФА КЫЗЫКЛАРЫ

Кызык дигәч, син тагы кызык эзләмә! Уфада чуртым кызык булсынмы?.. Кызык дип тик аптыраганнан гына әйтәсең... Уфа сүнгән дек сүнгән инде... «Тормыш»: Уфа шәп, Уфа — мәркәз, Уфа фәләп... дип (...) котырсын, (...) күркәләнсен! Аңарга «ләм йәлтәфит»лә: көл дә куй. Котырган дек котырган инде ул мескен! Һәм шулай котыра-котыра да башкалар тарафыннан тотыла да куя... Чынлап уйлаганда бит, әфәндем, «Уфа дигән генә саен «вә хәйфа!» дияргә туры килә... Вафасыз бу Уфа, хафа бу Уфа, менә дигән генә кешеләрне ваклатып, җәфалап бетерә бу Уфа... Рәмиев килеп тора башлаган иде — эреде дә китте... Сүнде, бетте. Үзенчә әйтсәк, «як-ягын дәүләт алган да, хәзер нинди тәмле йоклый ул!» Уфа йоклатты аны!..

Йоклата бу Уфа, сүндерә бу Уфа; эре генә адәмнәрне дә вакландырып, ваклыкка күндерә бу Уфа: «Әлмансур» вә «Баб әл-сәмаә» кебек мөһим нәрсәләр мөтәрҗиме Сүнчәләй, Уфага килгәч бигрәк мунчалага әйләнеп китте ләбаса!.. «Котормыш» газетасына яңа гына кулына каләм тоткан малайлар да язарлык әйберләр бастырып, вакланган өстенә ваклана гына бирде. Аны да Уфа ваклатты!..

Ваклаңдыра бу Уфа, агач атка атландыра бу Уфа; кып-кызыл чырайлы гына егетләрне дә дегеткә буяп тапландыра бу Уфа... Мәсәлән, кызыл гына Фатих, «Мәлгунат»ка кереп, карайды да куйды түгелме соң?..

Әйе, карайтыр бу Уфа, туган-үскән җирләреңне исеңә төшереп саргайтыр бу Уфа!.. Дәрвакыйгъ, саргайта ла... Мәсәлән, Казаннан килгән нинди генә кеше булсын, «Әй Казан, Казан, Казан!..» дип, Казанны сагынып теңкәсе корып бетә...

Ләм йәлтәфит — илтифат итмәү, игътибар бирмәү.
Вә хәйфа! — аһ! аяныч! үкенеч!
Вафа — сүздә тору, эштә тугрылык күрсәтү.
Хафа — борчу, кайгы, эч пошу.
Дәрвакыйгъ — чынлап та, дөрестән дә.

Казаннан килгән бищ билле Гайнетдин булса — Печән базарын, Кәфер чатын сагына, дәмелла Әхмәтҗан булса — милли бүрекләрен сагына, урыс сымак яшьләренә нәдәр, ичмасам, анда милли бүрек кияләр, дип куя. Әхмәд әфәнде булса — театрларын, Кариевләрен һәм матбугатын сагына... Әлхасыйль нинди генә сыйныф булмасын: «Их, Казан...» — ди.

Апрель ахырында Уфага «Нур» труппасы килеп кигкән иде. Алар да: «Ии... и... и... безнең Ырынбурга җитәме ул? Берүзенә ике труппа асраган Ырынбур бит ул...» — дип саргаешып алдылар.

Мескенкәй «Нур»ны әйтәм: сүнгән Уфа сәхнәсенә аз булса да «нур» чаткысы салып киттеләр. Ләкин шуны күп кеше белмәде дә. Театрга түбәнрәк сыйныфтан беразкеше килгән иде. Мөхәррирләр-фәләннәр берсе дә килмәделәр. Уфа төшендә дә күрмәгән рәвештә шәп иттереп уйнадылар... Ә бит «Тормыш»та шул турыда язылмады... Кайда соң! Кәбир Бәкерне китереп куясымыни шул Уфага!.. Шулай иттереп, «Нур»ны матди хурладылар да куйдылар... Әй ачыкавыз Уфа!..

Соң бит труппа артистларының берсе — Казанский — Уфаның үз кешесе ләса! Шамтулов магазиныннан житешкән артистларның берсе ич!.. Аны, Уфага кайткач, тантанаи газимә (...) белән каршыларга кирәк иде... Юк, агай, юк!..

Уфа, имеш, мәркәз, имеш, зыялысы күп, имеш. Уку да, һөнәр дә, аң да тәрәккый иткән шәһәр, имеш. Тфү, билләһи! Бер труппа асрап, рәсми бер сәхнәгә малик булу торсын, әллә нидә бер уйнарлык бөтен бер «һәрвәскәр груһы» да юк бит ичмасам!..

Әй син, Уфа, үз кибетләреннән чыга торган артистларыңны куа торган шәһәрсең син!..

Уфа, имеш, «Галия»се бар, имеш, «Госмания»се вә башкалары бар, имеш!.. Әйтегезче: шул мәдрәсәләрнең зурырак сыйныфларында Уфаның үзеннән укучы бер генә адәм бармы? Юк бит!.. Шуның өчен мин, ике беләгемне сызганып, өстәлгә шапылдатып суга-суга әйтәмен ки, кирәк заһирән булсын, кирәк батыйнән булсын, ул мәдрәсәләр мәдрәсә булып күренәләр — анчак читләр, чит илләр ярдәме белән генә. Бигрәк тә хәзер «Галия»нең җисеме Уфада булса да, рухы..., мәсәлән, Мәскәүдә... Шул

Заһирән — тыштан караганда.
Батыйнән — эчтән караганда.
Анчак — бары тик.

мәдрәсәләр генә, шул мәктәпләр генә азрак яктырта инде Уфаны!.. Бер һөнәр мәктәбе, бер ханымнар җәмгыяте, бер кечкәй генә китапханәсе, бер-ике хамиятле ире һәм хатыны, бер мөслимә докторы, бер-ике һиммәтле бае, ике-өч гыйльми адәме бар. Әнә шулар гына бераз агарта инде Уфаны!.. Алар да булмаган булса иде, (...) бөтенләй караеп, караңгыланып бетәр иде... Әле шулай булып та, яртылаш караланган яки бөтенләй караеп барган груһ юк түгел. Шул груһ эченнән, мисал өчен, гимназист сымакларны алыйк. Гомумән алганда, мондый сыйныф үзләре бик эре генә, фырт кына!.. Өстә ялтыраган төймәле кием, башта җиңел картуз... «Без кем?» дигәндәй йөриләр!.. Вакыйган, шул «төймә» булмаса иде, алар белән, мәсәлән, шәкерт арасында койма булмас иде. Татарлыктан (алар «татарлык» дигәч тә аңлыйлар) күтәреп үк җибәргән шул калыплары булмаса, үзләре ише үк курсисткамы, гимназисткалармы белән йөргән чакларында, мәсәлән, үз телләрен кесәләренә тыгып куймаслар иде (...).

Уфа мактана: миндә, ди, бер «мәхкәмәи...» бар, ди. Әйе шул, мин әйтәм, бар шул, дим; иртәле-кичле имтихан комедиясе уйнала торган «хөсне шәхсия» бар шул!.. дип танау эченнән генә көлеп эшне бетерәм дә шунда ук зиһенемне икенче якка чөяргә тырышам... Юкса аның эченә керә башласаң, аны уйлый башласаң,— илаһым сакласын,— тәэссефеңнән саташу дәрәҗәсенә киләсең!.. Аннан башка да әле, «мәхкәмәи шәргыя» дип әйтү белән үк, күңелгә әллә ниләр килә башлый. Күз алдында Җинаятьнең катлы-катлы таш йортлары, «Түгәрәк» тылсымы белән мөдәррислек мөнбәренә менеп утырган «имтихан комиклары» (...) вә башка әллә ниләр заһир булып, эчеңне пошыра башлый (...). Шуның өчен аннан тиз-тиз генә зиһенне чөерәм... Астына әллә ниләр яшеренгән аның!.. Моннан соң аның исеме үк искә төшмәсен иде!.. Ярабби!.. Тфү, тфү, тфү, лә хәүлә вәла куәтә... Тфү, тфү, сөбхан алла! (...)

Уфа тагы фәвакылгадә иганәләр кылган байлары белән мактанмакчы була! Тукта, дустым!.. Бер-ике чиреклне берьюлы бушаткан адәм кебек кызмачаланма! Иганәлә-

---

Хәмият — башкаларның зарар китерүеннән саклау.
Мәхкәмәи — хөкем итә торган йорт.
Тәэссеф — кайгыга төшү, үкенү.
Заһир булу — барлыкка килү, туу.

ре фәвакылгадә булса, вакыт та фәвакылгадә — военное время!.. (Тере чагында биргән бер дирһәмең үлгәч биргән 100 дирһәменнән артык хәдис.) Ләкин, һәрхәлдә, әлекке чакларда бер-ике меңнәрне сыкранып биргән байларның 100 әр меңләп, 50 шәр меңләп, 20 шәр меңләп куя башлаулары бик күңелле эш. Байларның яхшы гына тамчылый башлаган хәйрат чишмәләре һәрвакыт тамчыласын, һәм Карунның да аръягына чыгып утырган байларга бу эшләре үрнәк булсын!..

Сүз ахырында да мин әйләнеп килеп һаман шуны әйтәм: монда бөтен эш диярлек рияга, тәрилкәгә, ходайсызлыкка манчылып бетә язып бара.

Вафасыз бу Уфа!.. Сафасыннан җәфасы күп бу Уфаның!..

Хәйрат — изге эшләр, яхшылыклар, садакалар.

Фәвакылгадә — гадәттән тыш.

Рия — бер эшне кешегә күрсәтү өчен, ялганнан гына эшләү, икейөзлелек.

Сафа — рәхәтлек, сафлык, хозурлык.

1916

ИМЗА КАРАГЫ

15 июльдә чыккан 113 нче номер «Ялт-йолт»ны ачып карасам, ни күзем белән күрим — «Шөпшә» дигән бер сүз ялтырый. Бу ни эш бу? Нинди бәндә ул минем имзаны урлаган?.. «Шөпшә» имзасы белән шаярган кем ул?.. Менә ахирәт! «Халык җырлары» дигән булып, 10—15 юллык бер оешма язган булган да (чөнки вәзен дисәң вәзен юк, тәм дисәң тәм... мөндәриҗәсе сасып беткән нәрсәләр) ахырына «Шөпшә» дип кул куйган. Түзеп булмады бит, малай! Хәмияты әллә нәрсәм кузгалып китте дә тизрәк игълан кыйлырга ашыктым. Чыннан да, уен түгел ич!.. Бу да бит үзенә күрә әдәби бер җинаять!.. «Гафет» бичараны да байтак җылаттыгыз инде, шул да җитәр...

Минем моңа кадәр әлхәмделилла шөкер, «Ялт-йолт» сәхифәләрендә талпынганым юк. Моннан түбән әлйәуми әмер аллаһдыр...

Әлеге «Шөпшә» имзасын таккан адәм укучыларны саташтырып гөнаһка гарык итәсе кылмәсә, мин аңардан, икенче имза артына посуың телэп, җазем белән таләп итәм... Югыйсә, моңда минем иптәшләрем, «Гафет»не «Сөембикә»нең әллә кем Фатыймаларына каршы пүләп күтәрергә, судка бирергә котырткан «Сүз»челәр ише генә түгел, турыдан-туры «фальшивый «Шөпшә» белән дуэльга чыгарга кычкырыналар...

Мин секундатларымны әзерләп куйдым; әгәр тәүбә итмәсә, 32 август, 13 сәгатьтә секундатларым «Кигәвен» белән «Москит»ны җибәрәчәкмен.

«Шөбшә».

Идарә.— Бер газета яки журнал сәхифәләрендә гражданлык дәрәҗәсен алган бер «имза»ның бу рәвешчә угырлануы чыннан да әдәби бер җинаятьтер. Шуның өчен дә «Ялт-йолт» идарәсе мәзкүр имзаның сәхибен игълан итсен иде.

Мөндәриҗә — эчтәлек.
Хәмият — башкаларның зарар китерүеннән саклану.
Әлйәуми — көнлек.
Җазем — кискен карар.
Сәхибен — иясен.

1916

УФАДАН

(Шәкертләре, прикащиклары, кызлары)

Безнең Уфа шулкадәр пычрак, шулкадәр кабахәт, шулкадәр буш куык, шулкадәр коры куык, шулкадәр мәгърур, шулкадәр әллә нәрсә ки, ни дип кенә әйтсәң дә, ни дип кенә сүксәң дә, ни дип кенә уйласаң да ярый. Мирзалары — гайре мирзаларына, яшьләре — картларына, карчыклары — кызларына, кызлары — шәкертләренә, шәкертләре — хәлфәләренә, хәлфәләре — хәзрәтләренә, хәзрәтләре берсе ахырына бу кадәр кырын караган бер шәһәр булыр икән, ярабби!.. Монда шулкадәр мәхшәр, шулкадәр башбаштаклык, шулкадәр груһ — груһка аерылучылык хөкем сөрә ки, борынгы татар халкының кабилә-кабилә булып яшәүләре искә төшә. Монда шәкертләр һичбер йиргә чыкмаенча, һичбер адәмгә катнашмаенча, үзләренең «мәдрәсә» дип аталган «мәгарәләрендә» яталар да яталар. Чыккан тәкъдирдә дә, һичбер кешегә күренмәскә ант иткән кебек, икенде-ахшам арасында гына чыгып, берәр караңгы урамнан урап керәләр. Монда 3—4 мәгарә бар, 3—4е өч-дүрт төрле, шәкертләре 3—4 йөзле, хәлфәләре 3—4 мәсләкле, хәзрәтләре 3—4 корсаклы. Шул 3—4 мәгарә хәяткә 3—4 төрле суфый, 3—4 төрле җебегән авыз, 3—4 төрле коры шартлавык ясап чыгара.

Монда прикащиклар тагын шулкадәр тозсызлар, шулкадәр «тозлы күзләр» ки, азрак кына хезмәттән бушамасын инде ул, хәзер тора да бер «вечер»га йөгерә. Аларның уйларында «вечер» гына. (Тик, ходай, үзең кичер генә!) Алар нәрсәләр уйламый дисең!..

Мондагы кызыкларга килсәк, иң әүвәл аларны берничәгә бүләргә туры килә:

1. «Прикащик! Прикащик!» дип авыз корытучылар.
2). «Мирза! Мирза!» дип үлеп баручылар.
3). «Шәкерт! Шәкерт!» диярргә мәҗбүр булучылар.

Тагын, мин сиңа әйтим, монда —

Кызлары бар төрлесе:
Читек-ката кигәне;
Бергә барып, бишне алдап,
Унны сөеп йөргәне...

1 нче кыйсем кызларның «күз буяларын» прикащикларның эче керле ак якалары алганга күрә, «Прикащик! Прикащик!» сүзе алар авызында зикер вә тәсбих булып киткән. Бу кыйсем кызлар тик азмы-күпме алла биргән төсләре белән аталары тектергән пальтолары аркасында гына «кәпрәеп» йөриләр. Юкса аларның башларында «прикащик» дигән сүздән башка бер нәрсә дә юк. Боларга инде *«җанлы курчак»* тәгъбире бик ошап бетмәс, «тере шигырьләр» дисәң, дәхи мөнәсәбәтсез булыр, иң мөнәсәбәте боларны тәҗәссем иткән Г. Сөнгатинең соңгый шигырьләре диергә ярый. Бу кыйсем үзләренең кем икәннәрен бик яхшы беләләр, шуңа күрә «чиләгенә — капкачы» прикащикларны сайлый беләләр дә.

2 нче кыйсем кызлар, ягъни «Мирза! Мирза!» диючеләр, яки, икенче тәгъбир белән «Интеллигент» диеп интегеп йөрүчеләр күбрәк үзләре шул сыйныфтан булалар. Бу индс, хикмәт хода, мөслимәләр күзе белән фаразый ук килми. Боларга «Татарка!» дип эндәшсәң, аллаһы тәгалә гамәл дәфтәреңә зур гөнаһ итеп язар төсле тоела.

Бу кыйсемнең артык ягы:

1. Болар телгә осталар; эчләрендәге юк нәрсәне бар итеп күрсәтә ала торган бер «сихерләре» бар боларның... Болар үзләре «гимназия»-фәлән кебек мәктәп бусагалары таптап үсәләр.

Безнең җилкуарларыбыз шундый кызларны күрәләр дә: «Аллага шөкер! Татар хатыннары уяна башлады»,— диләр... Боларга инде татарның шәкерте, мөгаллиме вә милли яшьләре җир кортлары кебек кенә күренә. Гомерләрен шуларны чәйнәп уздыралар; аларга көләр өчен иң зур материал шулар...

Бу икенче кыйсем кызларны хәзергә куеп торып, *3 нче кыйсемгә* килик.

Болар ни өчен шәкерткә илтифат итә?

Моның сәбәбе ике төрле: 1) яки ул бик ямьсез, бик шадра, бик тупас була; 2) яки бик гакыллы, бик милли, бик мөтәффәкирә була.

Кыйсем — төркем.
Тәҗәссем итү — гәүдәләндерү, күз алдына китерү.
Соңгый — ясалма, алдап ясалган.
Мөтәффәкирә — уйчан, фикерле.

Бик ямьсез кызлар иң әүвәл бер-бер жыелышка, әдәбият кичәсенә яки театрга бара, анда бик боргаланып, назланып, «печтәнләп» утыра, үзенчә теге ак якаларны, теге «интеллигентларны» җәлеп итмәкче була. Ләкин алар, моның барын-югын да белмичә, үз эшләре белән йөрүләрендә дәвам итәләр. Урталык «гү» килә... Тик шунда, бер почмакта, җанлы багана кебек, бер шәкерт белән икенче почмакта, суккан арыш көлтәсе кебек, теге кыз тора.

Нишләмәк кирәк, халык йөгереп, болар торып, чүгендер тәяүдән башка эш чыкмый, ихтыярсыз шәкерт белән кыз танышып, халык арасына катышып китәләр (...). Бичаран, әллә кайларга омтылыр иде дә бит, канат юк!.. Шәкерт илтифатына мөзаһир булса, бик бәхетле инде ул!.. Ямьсезлеге өстенә, сынсыз да булса, шәкерт тә бит, ахрысы, бөтенләй ачыкавыз түгел!..

Икенче — гакыллы кызлар; алар мәсьәләгә, Сафа мөфти әйтмешли, җитди карыйлар. Алар тышкы җилфердәкләргә генә җилфердәп китмиләр. Ләкин бер шатлыкка ун кайгы, йөз хәсрәт: мондый кызлар белән Уфада валлаһе әгъләм...

Җәй көннәрендә ару гына егетләр, ару гына мөхәррирләр өйләнергә дип киләләр дә, муафыйк кыз тапмаенча мәхрүм, мәхрүм китәләр. Алар, ахрысы, кызлар курсы булгач, теләгәнебезне сайлап-сайлап алырга мөмкин, диләрдер. Шулай булса да, өмидне өзмичә, бәлки, киләсе җәй курсларына шәпләр килер, дип, чыкмаган кояшка кызарып ятучы «әфәнделәр» әле дә бар.

Киләчәк мәкаләләремдә Уфаның мөхәррирләре, гимназистлары вә башкалары хакында язарга уйлап, алла боерса, хәзергә туктыйм.

Мөзаһир — ярдәм итүче, яклаучы.
Валлаһе әгъләм — алла гына белә.
Муафыйк — тиц килгән, кирәкле.

 3-472

1916

УФА СӘХНӘСЕНДӘН

«Уен ахырында татар театрына ун ел тулу мөнәсәбәте белән уенчыларга түбәндәге һәдияләр тәкъдим кылынды: Гомәр әфәнде Терегуловка бер көмеш партсигар (өстенә шул сүзләр язылган: «Татар театрын төзешүче Гомәр Терегуловка»), Зөһрә һәм Фатыйма Әхмәтоваларга көмеш чәй әсбабы (өсләренә: «Татар театрының беренче карлугачына» дип язылган). Шулай ук Рөкыя туташ Терегуловага «Һәвәскәр» сыйфаты белән, һәрвакыт яхшы уйнаганлыгы өчен», чәй әсбабы тәкъдим итте. Халык, уенчыларга бик күп чәчәкләр ташлап, аларны алкышлады».

(«Тормыш», 523 номердан.)

Халык уенчыларга күп чәчәкләр бирде, имеш. Тфү, билләһи. Уйнаучыларның әнкәләре-фәләннәре яки алышка-биреш сайлаша торган иптәшләре тарафыннан ыргытылган ике-өч чәчәкне әйтә. Шул күп, имеш. Җитмәсә, «бик»е дә бар.

Ярый, күп тә булсын. Шуны «халык ташлады»» диюен кара! Халык тилемени ул, синең чәчкән-ниең белән... Нинди йомышы бар аның?.. Хезмәтнең эресен-вагын, ямьлесен-ямьсезен һичберсе һичбер вакытта һичбер төрле дә тәкъдир белмәгән халык, әле килеп кенә... Терегуловларның ун еллык сәхнә бәйрәме иттереп уйнаган театрларын тәкъдир итеп, чәчкә, «бик күп чәчкә» ташласалар, икенең берсе: яки (...) шул төнне татар, алланың изене белән, бөтен татар «Фәтхула хәзрәт»тәге татар булып әверелгән булыр, яки Терегулов вә Терегуловалар, көтелмәгән рәвештә шәп уйнап, халыкның дикъкатен җәлеп иткән булыр. Ләкин, мәгатәәссеф, берсеннән-берсе мөхәлрәк, берсеннән-берсе хыялырак. «Фәтхулла хәзрәтләр» үлеп тереләсе, бу

Һәдия — бүләк.
Изен — рөхсәт.
Мәгаттәәссеф — үкенечкә каршы.
Мөхәл — мөмкин булмаган.

Терегуловлардан башка яңа Терегуловлар туасы бар. Меңә шунда халык чәчкә дә ташлар, алкышлар.

Югыйсә, берәр кода, берәр кодагый тарафыннан: «Мин сиңа чәчкә ташлыйм, син миңа ни бирерсең?»— дип ташланган чәчкәләрне халык өстенә ябу — ялганның да аръягы. Әткәләренең, әнкәләренең, агаларының, сеңелләренең һәм вак-төяк бала-чагаларының чәбәкәйләрен халык өстенә,гакыллы халык өстенә иснад итү баш-аягыннан шәхсияткә чумган «Тормыш»ка гына гаид мәзиәт. Юкса, шундагы алкышларның төрле-төрле сызгырулар белән зиннәтләнеп яңгыраганы һәм пьеса уйналган заманда минут саен: «Громче!» «Громче!»» тавышлары гөрелдәп торганы урамга да ишетелде, хәтта.

«Татар театрын төзешүче»гә, имеш, көмеш партсигар... Монысына ни әйтим? Ник, мәсәлән, Әхтәмовны калдырганнар! Хезмәтне тәкъдир итү нияте белән ясалган кичә булгач, ник аны да катнаштырмаганнар? Чөнки ул мөгаллим, чөнки ул ялганламый. Ул мирза түгел, поза юк. Лә экалле, груһташ түгел. Бинаэн галәйһи, Әхмәтов вә аның кебекләр беренче театр төзешүчеләрнең иң самими хезмәтчеләреннән булсалар да, алар онытылып тора. Чөнки партсигарга алар әһел түгел!..

Уен алдыннан баш мөхәррирнең сөйләгән нотыгы озын сүзнең кыскасы» дип нзүдән гыйбарәт булды. «Тәхрире мәрьәт» тәрҗемәсеннән» дә тәмлерәк чыкты. Халык шулкадәр мәмнүн калды ки, ихтыярсыз сызгырырга, яртысыннан күбесе чыгып китәргә мәҗбүр булдылар. Вакыйган, аның сүзләрен беренче рәттә утырганнар гына ишетә ала иде. Калган халык аның мөттасил булганын, җәелеп, таралып торган кулларын гына тамаша иттеләр.

Сәхнә шулай була ул, мөхәррир әфәнде, син аны мөнбәр дип кенә уйлагансыңдыр да. Сәхнә диләр аны. Каләм тотып тәнкыйть итү генә асат ул. Бер заманны (өченче ел иде бугай) Зыя әл-Камали әхлак турысында шул ук залда лекция сөйләгән иде. Шул лекцияне «Тормыш» газетасы, «Озын сүзнең кыскасы» дип тәкрар-тәкрар әйтеп ха-

---

Иснад итү — бер эшне башка кешегә сылтау, башка берәүгә аудару.

Гаид мәзиәт — артып кайта (*мәзиәт* — шәплек, өстенлек).

Тәкъдир итү — бәя бирү.

Лә экалле — ким дигәндә, һич югында.

Әһел түгел — монда яраклы түгел мәгънәсендә.

Мәмнүн калу — риза булып калу.

Мөттасил — даими рәвештә.

Тәкрар-тәкрар — кабатлап-кабатлап.

лыкны ялкытты», дип язып чыгарган иде. Инде шул сүзләрен «Тормыш» мөхәрриренең үзенә кайтарып бирәмез. Күршенең үрдәге дә каз булып күренмәсен иде ул.

Урыны чыккан саен Зыя вә аның тарафдарларыннан шәхси ачуны алырга тырышкан «Тормышчы»лар азрак инсафка килсеннәр иде!

* * *

Уфа шулай ул безнең. Сәхнә белән уйнарга бик ярата ул. Әллә нинди әһел булмаган кемсәләр кода-кодагыйлык ясап сәхнәгә менәләр дә, «Җәмгыяте хәйрия» файдасына дип, берәр нәрсә куялар. Уфаның байтактан мәгълүм һәвәскәрләре белән хисаплашмыйлар. Табигый, «Җәмгыять» файдасына булгач, халык күп килә. Теге на әһелләре театрны халыкка тере мәетләрнең хәрәкәтләреннән гыйбарәт бер нәрсә итеп күрсәтәләр.

Халык: «Шушы була икән театр дигәннәре, үз ихтыярым белән килмәм мин монда»,— дип, тәүбәләр укып кайтып китәләр. Ярый, шуннан соң килә бер труппа, килә бер җырчы... Килсәләр, нишләргә? Погода начар. Ну әһел муллаларның, дип тәнкыйть итә белмәенчә, исламнан качырулары кебек, теге на әһелләре халыкны тәмам качырып бетергәннәр. Мескен труппа, мескен җырчы, кесәдән җилләр искән хәлдә, «выж» икенче шәһәргә!

Менә быел «Нур» труппасы калдыгы килеп, Уфада калмак булганнар. Нишләп китәрләр инде? Халыкны тәрбия итә алырлармы, юкмы?

Әгәр көн күрә алсалар, бик ярый инде, гөбесенә күрә пешкәге, каегына күрә ишкәге, шәһәренә күрә труппасы!

Кышкы сезонны башлап, ике мәртәбә уйнадылар инде. Уфа әле сер бирми. Һәр икесендә халык байтак булган булды. Ләкин, һәрхәлдә, Уфа Ырынбур булмас, Казан булмас. Фал ачып караган кешегә мәгълүм. Җәгъфәр Садыйк хәзрәтләре боерыр кем: әгәр килде-киттегә риза булса, труппа язга кадәр чыдагай. Валлаһи, ярты кыштан сәфәр күренә.

Садака бирмәк кирәк.

Әһел булмаган кемсәләр — сәләтле булмаган кешеләр.
На әһелләре — яраксыз кешеләр.

1916

ЯЗУ

Син, бәлкем: «Бу бәндә, бер булса, язуның хасият вә фазыйләтләрен бәян итмәкче була торгандыр инде»,— дип уйларсың. Алай уйласаң, уйлагычың «шарт», чырагым. Аның хасият-масиятләрен без түгел, бездән борынгы сәләфләр дә җитәрлек тукыганнар иде. Колак төбендә бәрәңге буталаган кебек; мөттасил:

«Китабәт — олугъ сәнгатьтер»,— дигәнләр;

«Каләм үгрән, каләм изгегә тартыр,

Каләм белгән кешенең бәхте артыр»,— дигәнләр... «Әлхасыйль»,— дигәннәр... Ул гына җитмәсә, тагын «Милләт» китапханәсе дә нәшер иткән театрларның тышына шул фәлсәфәләрне язып куйган булган — лыгырдап!..

Инде шулай булгач, әфәндекәем, бик тыныч булгайсыз ки: язуның хасиятен дә язмыйм, файда мөһиммәсен дә язмыйм, хикмәт җәдидәсен дә язмыйм; әлхасыйль — язмыйм, язмыйм... Шулай ук язуның моңа кадәр беленми яткан тәҗвидләрен, симияләрен, кимияләрен, хәберләрен-җәберләрен, чуртларын кәшеф итеп, Зариф әл-Кишери әйтмешли: «Мин Эдиссоннан да өстен мөхтәригъ, кәшшаф»,— дип кычкырып җибәреп, шан вә шәрәф кәсеб итү ниятендә түгелмен.

Йә булмаса, китереп, Рәмиевнең «Уку» дигән назымыннан:

> Ирләргә дә фарыз йокы,
> Кызларга да фарыз йокы,—

дип бозганнары кебек мин дә:

Фазыйләт — артыклык, өстенлек.
Сәләф — борынгы кеше, нәсел-нәсәп.
Мөттасил — туктаусыз, өзлексез.
Китабәт — язу эше белән шөгыльләнү.
Әлхасыйль — озын сүзнең кыскасы, җыеп әйткәндә.
Мөһиммә — әһәмиятле, кирәкле эш.
Җәдидә — яңалык.
Мөхтәригъ — уйлап табучы.
Кәшшаф — яңа нәрсә уйлап чыгаручы.
Шан — дәрәҗә, мәртәбә.
Шәрәф — кадер, хөрмәт.

Ирләргә дә фарыз язу, чирләргә дә язу,
Кызларга да язу, бүзләргә дә язу...

дип тузга язмаганнарны язып, язуга кызыктыру ниятендә дә түгелмен.

— Соң алай булса, ни нияттә соң?

— Менә, менә, күптән сорыйлар аны, юкка лыгырдатканчы!.. Минме? Мин, әфәндем, мөмкин булса, бөтен нәшерне язудан туктатыр идем. Моңа кадәр язылган язуларның һәммәсен чүпләтер идем дә, бер җиргә туплатыр идем дә яндырыр идем.

— Икенче Чыңгыз заһир булды,— дип, Риза казыйларың җылашсыннар иде!..

— Бу фикерең залимлерәк,— дисәңез, икенче төслесен эшләргә мөмкин.

Икенче төслесе шул: мөмкин булса, әлбәттә, бөтен каләм тоткан бәндәләрне язган әйберләре белән бергә чакыртыр идем дә үз язуларын үзләреннән боздыртыр идем, «солдат бирмибез» дип карышкан бәгъзе казаклар кебек, «язуларны бирмибез» дип киреләнгәннәрен бик әйбәтләп кенә җилкә тамырларыннан кыздыртыр идем. Араларында зәвыклырак булганнарыннан шул язмалар эченнән юньлерәкләрен чүпләтеп, бер җепкә тездертер идем. Мөхәррирләр: «Ник каләм тоттык икән?»— дигән көнгә килерләр иде соң үзләре дә...

Вакыйган, язуның һәр юлында бер йолдыз тезелмәгәч, һәр мисрагыннан йөрәккә оҗмах рәхәте сызылмагач, нигә кирәк ул?.. Ул язуның күз тондырып укып утырганчы, ичмасам, пичкә ягармын да, рәхәтләнеп арка терәп кызынып утырырмын. (Ат кылыннан скрипка ясап уйнаганчы, шуны пичкә як та, аш перешеп аша! Яшь чакта без шулай итә торган идек.)

Чынлап, уенсыз әйтәм: бөтен каләмнәрне, бөтен кәгазьләрне, бөтен язмаларны югалтып бетергәндә, нишләр иде микән?... Коръән кәримнәр, Инҗил шәрифләр, Тәүрат, Забурлар да алланың әз нәүе белән рәфыйгъ ителсә, мөхәррирләр дә, һөнәрмәндләр дә күккә күтәрелсә, җыен чабаталы халыкларга ни булыр иде?..

— Кит, тәүбә диген, була күрмәсен! — дисезме? Юк, булсын иде, булсын иде! Гыйлем вә мәдәният бөтенләй кү-

---

Мисраг — шигырь юлы.
Кәрим — хөрмәтле, кадерле, бөек.
Әз нәү — яңадан.
Рафыйгъ ителү — югары күтәрелү.

тәрелсен иде дә жәһаләт вә наданлык падишаһысы заһир булып, үзенең караңгы итәкләрен җир йөзенә җәйсен иде. Ул чагында һәр милләт безнең татар дәрәҗәсенә төшеп калыр иде, дим.

Бездә ишаннар әзер. Тиз генә догалар-нилләр белән Коръән кәримнәрне әйттертеп, башка милләтләр белән чынлап ярышырга керешер идек. Ул чагында белер идек ярышырга! Гаязлар: «Татарга ике йөз ел инкыйраз»,— дип «их-әлләһи» кычкырсыннар иде анннары!.. Бер заман «Фәтхулла хәзрәт»нең үлеп терелгән вакытлары «ялт» житкәч, үзләре дә торырлар иде сон — (...) шаккатып!..

Гыйлавә:

Урманга утынга барган җирдән калага ычкынган башкортка охшаган бу мәкаләмне мин бөтенләй башка тарызда, озын иттереп язмакчы идем. Ләкин бу көн ки язуга каршы фикерем — каләмне башка якка кыйпылдырып алып кереп китте дә языйм дигәннәрнең барысын оныттырды. Чанасын төпкә суктырып тәртә бавын өздергән агай-эне кебек, хәйран вә сәргардан тор да кал!..

Җәһаләт — караңгылык, наданлык.
Заһир булып — барлыкка килеп, туып.
Гыйлавә — өстәмә.
Тарыз — рәвеш, сурәт, ысул.
Сәргар — аптыраган, баш әйләнгән.

1916

ИСТӘ ДӘ ЮК ИСКЕ ЧИКМӘН

(Әкият)

Борын борын заманда, борыны китек команда, бөркет кантон булганда, казлар лашманчы, торна поход йөргәндә; үрдәк — урятник, саескан — сотник, чәүкә — десятник, карга казак булганда, башкортлар иркен, маллар таркау, казакълар — качак, урыслар — куркак, инглиз, герман, француз, япон, Италия, Төркия — һич берсе ишетелмәгәндә, Троицк, Казан, Оренбур, Мәскәү.— кайда ул Уфа! — ул шәһәр урыннары һәммәсе дала, һәммәсе гөнаһсыз тыныч сахра булган, ди. Ә хәзер, тап сахараның уртасында, сугылып кирпеч, салынган шәһәрләр, сөрелгән далалар, туган балалар, үрчегән халык, киткән ялкаулык, качкан наданлык, башкортлыкка ядкарә салынган Уфа.

Уфа... Уфада хәзер балыктан уха. Ит юк, май юк, сөт юк, кымыз юк, аш юк, шулпа юк, тоз юк, ярма юк, он юк, икмәк юк. Чөнки борынгы «Айдагол», «Шаһияхмәд» юк. Кызлар, хатыннар күп, иркәкләр юк. Кызлардан да әүвәлге нечкә билләр юк, сайраучы былбыллар юк. Язучы күп, мөхәррир юк. Мөхәррир булса, әдип юк. Әдип булса, әдәп юк. Әхлак юк, әхлаклыларга аң юк, фикер юк, башларында ми юк. Һичкемдә изге максат, хосусый хаслэт юк. Максатка васлэт юк. Чөнки алырга материал, эшләргә вакыт юк.

Тагы Оренбур... Оренбурда «Вакыт» бар. Мәгәр «Вакыт»чыларда дикъкать юк, рикъкать юк, шәфкать юк. Башланган күп, эшләгән юк. Ашыйлар, эчәләр, берсеннән икенчесенә күчәләр, пешерәләр, төшерәләр, һаман да эшләгән эш күзгә күренми, вакытны, гомерне, форсатны, җимне тик бушка кичерәләр. Кояш чыга, көн була, озакламый төн була, мичкәләр «шыгыр-шыгыр», чирекләр «шыңгыр-шаңгыр», стаканнар «чылтыр-чылтыр», авызлар «голдыр-голдыр», күзләр ялтырый «ялтыр-йолтыр», телләр сөйли

Хаслэт — үзенчәлек, сыйфат.
Васлэт — кушылу, якынлашу.
Рикъкать — нечкәлек, күңел йомшаклыгы.

«лыбыр-лабыр». Соң шул, соң. Вакыт үтте, җыен таралды, малайлар күшекте, кармак сынды, балыклар тынды, капчык бөкерәйде, эшләр кәкерәйде, көн фәякүн . вәссәлам, эшләр тып-тын.

Ялкынлы яшьләр, үстереп чәчләр, чыктылар юлга, бардылар Мәскәүгә, алдылар маллар, кычкырып-бакырып, чәчтеләр даннар. Таралды даннары, җәелде шөһрәт, шаккатты хәзрәт. Диделәр: дурак, ул нигә кирәк? Гакыллы яшьләр, буталган башлар, булдылар «Сүз»чән, үгездәй үкерүчән, аюдай сүлпән, йолкынгандай шиңгән, банкроттай бөлгән, һәммә җир килгәч, төрле тип булгач, сибергә «тоз»ны, башладылар «Сүз»не. Тыңла, сөйлиләр. Ничек дулыйлар: «Яңаны башлыйк, искене ташлыйк. Пыр тузсын чәчләр, бетсен ул калфак, ташла яулыкны, йөрмәсен каплап. Ыргыт түбәтәйне, яндыр бишмәтне, умыр дөньясын, кыр Зыясын, бетсен Мусасы, сынсын гасасы, яшәсен фиргавен, таратсын данын, күтәрсен шанын. Чапсын Шакирләр, еласын Закирләр, саташсын Һади, тилерсен Садри, тотылсын «Кояш», югалсын «Вакыт», абынсын «Акмулла», язылсын «Кармак», буталсын «Тормыш», аздырсын хәннас, чуалтсын «Аң»ны, кызартсын «Таң»ны. Ялт итсен, гөлт итсен, кайнасын Казан. Аңласын надан, доносчы дошман. Корсаклы байлар, кайнар каныгыз, әрнер җаныгыз, янар йортыгыз, тузар бу дөнья».

Бер такым яшьләр, чүбекче башлар, чыктылар юлга, максат — Казанга. Килделәр Казанга, Казаннан учакка, учактан мичкә, мичтән юллыка, юллыктан торбага торбадан... Үрмәлә, үрмәлә, үрмәлә, үрмәлә, якты көн күрмә дә.

Тагы бер токым, һаман искергән токым, килделәр Троицкига. Борын иске Троицк әле дә иске. Капка иске, йорт иске, тун иске, бишмәт иске. Тик тужурка, пальто, штиблет, эшләпә. Гайникамал Миңлезифа ачтылар «Вазифа». Титуллар, исемнәр русча. Ә эшләр барсы да әүвәлгечә.

Ярар бер душка, җитәр хәзергә, эшләр җайланса, авыз майланса. Тагы язармын, җиһан гизәрмен, киләсе санга яман тезәрмен. Бер заман берәү бер сүз әйтте, ди, алла боерасыны әйтми китте ди. Эшләр пешмәде, алла кушмагач. Кайткачтын өйгә, ишекне кага: «Алла боерса, хатын, ишек ач». Минем дә шулай күңелем курка. Башка аң килсә, киләсе санга язармын янә, алла боерса.

Көн фәякүн — «Бул!» дию беләи була.
Гаса — таяк.
Хәннас — шайтан.
Токым — төркем.

1917

ИШАН ҮЛГӘЧ

2 февраль.

Нигә болай бу? — дисәм, һаммас ишан үлгәнгә, имеш: кар котырган, дөнья тутырган, буран куптан. Букча күтәргән ир һәм кыз шәкертләр белән урам тулган: — «Аллага шөкер», ишан үлмәкнең файдасын күрдек. Бер көн дәрестән азат!» — дип кайтып баралар.

Һәр муаһныи-мөселманның тәрәзәсе ягыннан үтәр хәл юк, шундук карт-корыларның әчкелтем-төчкелтем мәкамәләләр белән мыжгырдануларын ишетелә: әй, болар ишан рухына Коръән укып ята торганнардыр, мөгаен, дип уйлап китәсең.

Нигә бу мәхдүм хәзрәт иртә белән чабаланып йөри, дисәң, әтисе үлгәнгә икән: почтага барсаң да ул күренә, телеграфханәдә дә ул, хәзрәтләр янында да ул.

Нигә ишан капка төбендә кар эри башлаган икән, дисәң, мөридләрнең күз яшьләре белән чыланып эрегән, имеш, ул. Әйтәм җирле, күзләре пешекләнеп беткән, әйтәм, гәрселдәп йөриләр... Алай икән!

Кич белән чыксам, ни күрим: чалмалы халык төяп извозчиклар чаба, бар да «мәгъмүрия»гә таба агыла... Бу ни эш бу дисәм, ишанга хатимкә чыгып баралар икән ул да булса.

Ишан үлүдән бер көн элек мәшһүр мулла Такырҗан әл-Хәсәни Уфа вокзалында нишләп сөмәеп тора дисәм, Троицкига барырга поезд көтеп тора икән, ишанның чирләвен ишеткәч тә: «Тукта, барып кайтыйм, бер-бер хәл булмасын», — дип төшкән шул, күрәсең. Вакыйган, әүлия икән, шайтан: как ул килеп җитте, ишан китеп тә өлгерде... (мәрхүмнең кергән тоннеле якты, бара торган мәүкыйгъе яхшы булсын, амин! Дәвакамин!).

Мәкамәлә — көй.
Мәгъмүрия — төзек, матур биналар мәгънәсендә.
Хатимкә — Коръәнне баштан ахыргача укып чыгу.
Вакыйган — чынлап та.
Мәүкыйгъе — урыны.

Ник бу ишан мәктәбендә бер почмакта бер шәкерт ник уйга калган, дисәм, мәрсия язып маташа икән:

Үлде ишан, үлде зәйшан;
Фәкать исме калды исән.
Китте инде җүнле ишан,
Калды мәлгуньь Ишми куштан!

Мин барып кергәндә, шул мисрагын язган иде, шагыйрь мине күргәч, кызып: «Бар, чыгып кит әле, иртәгә хәзрәтемез каберендә укырга мәрсия язып ятам, күрмисеңме? Бар, чык әле, зинһар! Кара таракан булма!» — дип, мине куып чыгарды. «Әйдә, пычрансын инде, бичара!» — дидем, юкса кирәген бирергә иде исәп! Мәрсиясе ничек башланган егетнең! Нәкъ кабердә укырлык кына!.. Әйе, укырсың атаң башын!.. Укытырлар менә...

Әйдә, азаплангач азапласын, дидем инде, юкса бик ныгытып пешәргә иде исәбем!

3 февраль.

Ишанны күмү җомгадан чыгуга булачак.

Бүген дөнья купты, кар бураны бигрәк тузынды. Мөридләрнең, яраннарның (...), чалларның, киленчәкләрнең җылаулары, шаулаулары бигрәк куәтләнде, ишан йортында мәхшәр купты. Бөтен шәһәр ишан тугрысында гына сөйләнә, шул хакта гына гөрли башлады.

Мин: «Ля хаулә вә ля куәте»,— дип, иртәнчәк урыннан торгач да, бу көннең гади көн түгел икәнен тәрәзәгә чыжылдап бәрелгән карлы буранлан сиздем.

Чәй өчен урамга чыксам, дөнья бигрәк котырынган, күрдем: әллә кайларда бик каты колокол тавышлары, әллә кайда пожарныйлар чаба! Урам тулы халык! Ул җил, ул буран, бер дә харап! Әллә нәрсәләр дөмберди, шылтырый, гөрли... бер яктан урам тутырып «никрутлар» үкертеп килә, гүя бүген дөнья ишан үлгәнгә риза булмаганлыгын күрсәтә: бер яктан буран чыккан, бер яктан пожар чыккан, бер яктан җил улый...

Бер яктан «никрутлар» ишан үлгәнгә тәәссеф марш җырлап киләләр төсле, гармуннары да ишан үлгәнгә үкереп җылаган төсле...

Яран — якын кеше, дус, ярдәмче.
Ля хаулә вә ля куәте — көч һәм куәт юк мәгънәсендә.
Тәәссеф — кайгылы, үкенүле, ачынулы мәгънәсендә.

* * *

Ишанны күмәргә бару ай-һай тантаналы булып чыкты да соң...

Урамны буйдан-буйга тутырып барган мөселман халкын күреп читтән карап көлеп торучы урыс җәмәгате: бу ни эш булды!—дип торалар бугай, кем белсен!..

Вакыйган, урамның буеннан-буена барган җәяүле һәм чаналы халыкның тач сөннәтле бүректән генә булулары, тач мөселман җәмәгате генә булулары, урысларның читтән карап калулары күңелгә тәэсир итә, мөселманнарга ни дә булса бер галибәт табылган төсле, бер муафыйк эш эшләнелгән төсле тәэсир итә...

Бигрәк тә әнә шул чаналарга төялгән яшь-җилкенчәкләрнең рухлары күтәрелгән, шатлыклары, эчләреннән чыгып, бөтен йөзләренә җәелгән, иреннәре колакларына тикле җырылган. Көләләр, шаулыйлар, кайсы берсе җырлап та җибәрә.

Үз күңелләренә якын кеше үлсә, болай авыз җырып баралмаслар иде әле.

Әнә мөридләр төялгән чаналар!

Күбрәге, ачы буранга карамасдан, чалма-чапандан гына утырганнар... Муеннарын чүпрәкләр белән урап бетергәннәр, кайсысы меңле тәсбихен аскан... Аларның эчендә ниһаясез хәсрәт, күзләрендә өзлексез яшь! Муеннары аска ук иелгән, бөтен бәхет-сәгадәтләрен ишан үзе белән бергә алып киткән хас иттереп баралар.

Бара торган җирдән бер казакъ мөриде: «Йафармай, Жаркытгамай!»—дип, ай-һай салып җибәрде.

Бер башкорд мөриде:

Хәзрәтемезнең йөзләре яңа туган ай кебек,
Хәзрәтемезнең сәлләсе яңа яуган кар кебек;
Мин йөрмен хәзрәтемезнең эзен эзләп,
Мәсле кара себен кебек безләп!.. —

дип эчендән җырлап барган җирдән, кинәтдән: «Йә, шәйхем мәдид! Һауа хак!..»—дип кычкыруына сискәнеп киткәндәй булды...

Тагын берничә мөрид: «Йә, һауа»,— дип мөңгердәнделәр...

Галибәт — өстен.

Муафыйк — туры килгән, яраклы килешле.

Ниһаясез — чиксез.

«Йә, шәйхем мәдид! Һауа хак!..» — «Мәңгелек юлбашчыбыз! Алланың яратканы!..» мәгънәсендә.

* * *

Аллаи газыйм мәет артыннан зыяратка барып керде. Калку җирдә кабер тирәсенә җыелдылар. Яшьләр, чәчле хәлфәләр бер тирәгәрәк. Хәзрәтләр карга арка терәп сөмәеп утырдылар. Мулла Галим Җаушев кабер янындагы каек агачына менеп кунаклады.

Яшьләр, бер-берсенә бармак төртешеп: «Кара, кара, бай кайда менгән?.. Кара, анау мулланың күзе! Нәкъ ишан була торган адәм!»— диешеп көлешәләр. Һәм белгәне белмәгәннәренә, муллалар уртасында утырган Такырҗан ихсанины күрсәтеп: «Әнә, күрәсең килсә күр! Теге Уфаның шпион мулласы шул булыр инде»— диләр.

Ишанны күмә башлаганда, һәр мөрид, һәр надан, һәр мөхлис, тәбәррек зат шәрифнең туфрагын сибеп, шәрифәткә наил булыйк, дип уйладылар ахрысы: бер заман кар бураны өстенә туфрак яңгыры ява башлаган иде. «Җитәр, җитәр!.. Әй!.. Өст-башны тутырдыгыз... Сипмәгез!..»— дип, көчкә-көчкә генә туктаттылар.

Ишанны күмеп бетергәч, буран басылды, һәчнәрсә булмаган кебек, дөнья тынды, кояш ялт итте... Һәр мөрид йөргендән: «Һи тәбрик, халис әүлия икән, изге кеше үлсә йә буран, йә яңгыр булыр»,— диләр иде. Бик дөрест сүз. Әминабә!.. Хәзрәт үлгәнгә, без түгел, бөтен дөнья җылады бит!» кебек сүзләр йөри башлады.

Ишанны күмеп бетергәч, Коръән укылгач, мәхдүм хәзрәт үзе садака өләште. Чәчле хәлфәләр: «Их, миңа да төртсә, извозчиклык булыр иде!»— дип күзләрен тоз итеп карап тордылар. Мәхдүм аларның чәчләрендән курыкты...

Садакадан соң Такырҗан мулла һәм «Г. С.» хәлфә нотыклар сөйләделәр.

Соңра халык таралды. Мөридләр, кесәләрен кабер туфрагы белән тутырып, кайтып киттеләр. Кайткач, ишанның өендә калган кәфенлеген бүлештеләр. Кеше башына бер бармак урарлык кадәр чүпрәк тиде.

«Г. С.» хәлфә кайгыда. Ул ишанны күмеп кайткач, караватына егылып, кайгырырга тотынды. Мәсләгенә баль-

---

Аллаи газыйм — Алла рухы белән оештырылган зур, җитди эш.
Ихсани — изгелек кылучы.
Мөхлис — саф күңелле, ышанучан мәгънәсендә.
Тәбәррек зат — хөрмәтле, газиз саналучы.
Шәриф — кадерләүгә лаек
Шәрифәт — бәхет, кадер, хөрмәт.
Наил булу — ирешү.
Халис әүлия — чын әүлия.
Мәсләк — дөньяга караш, тоткан юл.

кыйль хилаф иттереп, Такырҗандан да карарак, буяулырак иттереп сөйләвенә бик үкенде. Ниләр сөйләгәне башыннан берәм-берәм йөреп үтте. Бәгъзе бер сүзләре хыялында кара болыт шәкелендә булып, кара болыт эчендәге аждаһа кыяфәтендә булып килеп тезелделәр. «Җәмәгать! Ишан үзе үлсә дә, мәсләгене үтермик, аның юлы мәңге яшәсен!» — кебек сүзләре колагында мөттасәл яңгырап, җаның үртәп тордылар. Шул сүзләре күз алдына ямьсез кара пәри сурәтендә булып килеп басды.

«Шушы каберстанда җыелган халык эчендә, мәрхүм ишан хәзрәткә кереп, кальбенә бер тәсәлла, бер сөенеч алып чыкмаган кеше юктыр; әйе, барыбыз да сөенеп чыга идек!» — дигән сүзенә каршы, каршысына әллә нинди котлар җанланып килеп бастылар. Әллә кемләр: «Юк сүз сөйлисең!» — дип кычкырган төсле булды.

Кемдер берәү: — «Мин, мәга әл-тәәссеф, ишан хозурыйдан коенып чыктым», — диде.

Кемдер берсе: «Мин, янына кергәч дә, «мөртәд», «бимазаһиб» кеби гыйбарәләр илә сыйлады», — диде.

Тагын берсе: «Исемемне ишеткәч дә: «Сык шәйги, сык шәйги! Сык! Сык!» — дип, хозурыннан куды», — диде. Әллә нинди бер мәет, җанланып килеп: «Зур тәслия дип биргән мәгъкуне мине үтерде», — диде.

Тагын әллә кемләр: «Урһабания ибтагуһа ма китабнаһа галәйһум» аятена мәсдак булган рәһбаниятьләр, имаплыклар дәвам иткәнен күргәндә һәм бихисаб мөридләрнең юк-бар хорафатлары белән агуланып, дини вә мали вә зәфәләрен онытып, «Һауа хак!», «Яшихум!» дип диваналанып утырганлыгын күргәндә, «милләтнең никадәр көче әрәм булганда нинди калеб һәм нинди вөҗдан сөенер?..» — дип кычкырган төсле булдылар. «Г. С.» хәлфәнең күңеле үтереп газаплана башлады. Ул: «Мин бит ул нотыкны ике мәктәп исемендән вәкил булып сөйләдем, минем үз фикерем бөтенләй башка иде», — дип күңелне тынычландырырга тырышса да, юк, һаман тынычланып бетмәде, вөҗдан

Баль-кыйль — уй — әйтелгән сүз.
Шәкел — форма, рәвеш.
Мөттасәл — өзлексез.
Тәсәлла — күңел юанычы.
Мәга әл тәәссеф — кайгы белән.
Бимазаһиб — ямьсез, котсыз мәгънәсендә.
Тәслия — юаныч.
Мәгъкун — бирелгән сүз.
Рәһбаният — монахлык.
Мали — мал (га караган), мал (га бәйләнешле).
Зәфә — авыр хәл.

ның әллә кай төшендән нидер булса бер нәрсә чәнчеп торды, әллә кай ноктасыннан: «Үз фикеренә, үз мәсләгенә хилаф нәрсәне ник сөйлисең? Ник мәсләгеңне таптыйсың?»—дип, бер нәрсә кычкырып торды.

Ниһаять, ул: «Әстагифирулла, әстагифирулла!» — дип, тәүбә яңартырга тотынды.

— «Г. С.» хәлфә бу нотыкы белән төште, үз мәсләгендән үзе калды, «Г.С.» сатылды, фәлән-фәсмәтән,— кебек сүзләр яшьләр арасында шау итте...

Мелла Такырҗан исә ишанның грамоталарын, фәзаилләрен, иманлыкның мөкаддәслеген, изгелеген һәм ахирәт газапларын сөйлисе җирдә, күбрәк ишанның шәһәргә иткән икътисади файдасын һәм гыйльми хезмәтләрен сөйләп, үзенең бик тиз генә койрык тоттырмый торган «хәйләкәр төлке» икәнен исбат итте.

Шуңа күрә ул, өенә кайткач: «Булдырдым бит»,— дип уйлады. Шатлыгыннан күкрәгенә сугып: «Булдыра бу чалмалы төлке!»—дип куйды. Эчендә кара пәриләр тырнап торсалар да, үз игътикадын, үз фикерен әйтә алмаса да, үз-үзеннән мәмнүн иде. Нотыгын сөйләп бетергәч ишеткән «Бәракалла!» «Рәхмәт!» тавышлары һаман колагында уйнап торды.

Ул шул тавышларга ияреп йокыга талды. Йокысында ул ишан хәзрәт белән саташып чыкты. Ишан аны нотык белән тәбрик итте: «Троцкиның ачыкавыз имамнарыннан уздырдың,— диде, — койрыкны бутый беләсең, мөфти дә булып куярсың»,— дигән бәшарәтенә уянып китде...

3 февраль.

Кич белән ишан йортында фәүкылгадә мөһим яшертен мәҗлес булды. Мәҗлесдә бер-ике хәлфә, бер-ике мөхлис вә яран, бер мөәзин һәм мулла Такырҗан белән мәхдүмнән башка кеше юк иде.

Мин бер почмакта кереп яшеренеп утырдым. «Ба, ходай, ни булыр»,—дип ишекне бикләделәр, ишек артларына каравылчылар торгыздылар. Моның соңында мулла Такырҗан мәҗлесне ачды. Мәҗлес хакыйкате мөһим иде. Мәҗлес «мәхдүмне ишанлыкка күтәрү» мәҗлесе иде. Мәҗ-

---

Фәзаил — өстенлек, яхшы сыйфатлар, яхшы эшләр.
Мөкаддәслек — изгелек, бөеклек.
Икътисади — экономик.
Игътикад — ышаныч.
Мәмнүн — разый, шат.
Бәшарәт — шатлыклы хәбәр.
Фәүкылгадә — гадәттән тыш.
Мөхлис — дус.

лес «мәхдүмне котырту, вәсвәсә салу, мәхдүмнең үзенең вөҗданы теләгән кадерләрен, мәсләкләрен йөрәгендән куптарып ыргытып ташлап, аның урынына буяуланган, майланган черек, иске нәрсәләр салу» мәҗлесе иде. Ягъни мәҗлес «бер кешене икенче кеше ясау, рухи операция ясау» мәҗлесе иде.

Мәхдүм баштарак: «Бу эш минем кулдан килми, мин теләмим моны, намуссынам мин, халкымдан, милләтемдән намуссынам мин, юк, кирәкми, килешдермим»,— дип караса да, булмады. Мәҗлеснең, билхасса, Такырҗан вәгазе тәэсир итте.

—«Юк... син ялышасың, мәхдүм... Этнең нафизын югалтма. Аның төзеп киткән тарикәтен җимермә! Бу тарикәт, бу силсилә бетәргә тиеш түгел; аның урынына синдән башка кешенең утыруы һич муафыйк түгел, син моның кадерен бел, кулыңдан ычкындырма! Бу синең бәхет, һәм дөньяң, һәм ахирәтең өчен бәхет; бу — Сөләйманның йөзеге! Йөзекне читләр кулына җибәрүгә эткәң асла риза булачак түгел! Истикамәтең, диянәтең урынында; этиең урынында утыр! Бу мөкаддәс урынны югалтмауны синдән ничә йөз мең яран вә мөридләр таләп итәләр, үтенәләр вә үтенәмез!..

Әгәр бу урынны югалтсаң, эткәннең фатихасы юк. Ул миңге рәнҗиячәк; бихисаб мөридләр дөнья ахирәт сәгатеннән мәхрүм калачаклар, ятим калачаклар, тәэссеф, раһибаният бик мөкаддәс эш... Аңа, буңа бакма!.. бөтен тарикият әһелләре синең ишан булуыңны, зар тилмереп көтәләр... Фәлән вә фәлән!..»— дип сөйләүләре аның рухын биләде. Каршы килә алмады. Мәҗлесдәге хәлфәләр дә бик кызу-кызу тәшвикъ вә тәзгыйбтә булдылар.

Ниһаять, мәхдүм, ризалыгын белдерде дә, тирән иттереп: «Уф!»— дип сулап куйды. Гүяки бөтен үзенең максадлары шул «уф» белән бергә күккә очып киттеләр...

Мәҗлес әһле, мәхдүмне бөккәч, шатландылар.

Вәсвәсә салу — коткы салу.
Билхасса — атап, төбәп, махсус рәвештә.
Нафиз — абруй, йогынты мәгънәсендә.
Тарикәт — мирас, башлаган эш, башлаган юл мәгънәсендә.
Силсилә — һич.
Асла — һич.
Истикамәт — турылык, намуслылык.
Диянәт — динлелек, диндарлык.
Тәэссеф — кайгыга калу.
Раһибаният — монахлык.
Тәшвикъ вә тәзгыйб — өндәү һәм үгетләү.

Такырҗан мулла бик самими сурәттә: «Алай булса, син әткән хәзрәтләренең урынына утырдыңмы?» — диде.

Мәхдүм:

— Утырдым, — диде.

— Алай булса, әткәң тарикыятен бөтен шәригате, бөтен әсрасы вә хафияте белән кабул итеп алдыңмы?

— Алдым.

— Алай булса, әтиең халикәсендә, әткәң кулы белән мөридләрне тәрбия итәрсенме?

— Итәрмен...

— Бир кулыңны алай булса...

Мәҗлес, әһле мәхдүмнең кулын кысып, вәгъдәсен алдылар. Мәхдүмне әткәсе урынына күтәреп утырттылар...

— Мә әткәннең чапанын, ки!

— Мә әткәннең чалмасын, чал!

— Мә әткәннең таягын, тот!

— Мә әткәннең тисбесен, тарт!

Мәхдүм барын да кылды...

Мәҗлестә, ишан хәзрәтенең хадимиятендә торган бер мөрид, торып: «Әлхәмделилла, эш булды; инде мин мәхдүм хәзрәткәйдән шуны үтенер идем: хәзрәт вакытында хадимиятендә торган кешеләр моннан соң да шул хадимиятләрендә булырга фатиха бирсәгез иде!» — диде.

Мәҗлес, кабул итеп, фатиха бирде.

Бу ан башмакчы һәм дару ташып йөрүче мөридләрнең йөзләре ачылды, авызлары тажрайды...

Ниһаять, «хәерле сәгатькә» дип, озын итеп дога кылдылар да, мәхдүмнең кулын үбеп, шатланышып, таралдылар.

Мин дә иплән кенә бер ярыктан чыгып сыздым.

Икенче көн шәһәрнең берничә имамы вә ахунды чакырылды. Мәхдүм аларга әткәсе урынына утырганны аңлатты, фатихаларын үтенеп, уч төпләренә ялтыратты. Имамлар: «Бик рәхмәт, бик мәслихәт, бездән дога!» — дип, кул озайтып, бик озак фатиха бирделәр.

Шуннан соң мәхдүмнең ишанлык тәхетенә җөлүсе игълан ителде. Шуңарчы «ни булыр икән» дип, бинәлхәвеф вә риҗа торган мөридләр, шатлыкларындан җылый-

---

Шәригать — закон, канун.
Әсра вә хафият — яшерен сер һәм борчулар.
Халикә — нэге урын мәгънәсендә.
Хадимият — хезмәт. Монда карамагында мәгънәсендә.
Ан — вакыт.
Җөлүс — (тәхеткә) утырту.
Бинәлхәвеф вә риҗа — борчылып һәм өметләнеп.

җылый өйгә кереп, «хәзрәткәем» дип, кулларын үбәргә, итәкләрен сөртенергә тотындылар. Яшь ишанны, ишанлыгы белән котлап, әйләнәсен акча белән күмделәр.

«Яшь ишан» оялуыннан бөтен дөньясы белән кып-кызыл булып, чөгендер төягән шикелле булып утырды.

Шулай итеп, карт ишан үлде, яшь ишан туды. Хәбәр — шәһәргә, шәһәрдән әтрафка җәелде. Читтәге мөридләргә ишетелде. Алар, ишетү белән, карт ишанга зияратка, яшь ишанга күренергә юлга чыктылар. Бөтен юллар ат арбалары, мөридләр, мосафирлар белән тулды. Алар шәһәргә килгәч тә туры хәзрәтләренең каберенә юнәлделәр. Анда барып, зар-зар елълап, йөзләрен кабергә сөрделәр. Һәм кабердән бер уч туфрак алып салдылар *. Соңра яңа ишанга кереп күрештеләр. Хәлкасына тезләнделәр, шатланышып җылаштылар, садакалар яудырдылар. Яңа ишанга әткәсенә иткән мөгамәләне иттеләр, аңа әткәсенә баккан кеби бактылар.

Яшь ишан тагын кызарды, тагын бүртенде:

— Әле мин өйрәнмәгән, миңа туры карамагыз әле,— диде. Яшь хатыннарны, киленчәкләрне бөтенләй янына ук китертмәде:

— Мин оялам әле,— диде.

Шулай итеп, мөридләр бер яктан кайгырып, бер яктан шатланып, кайтып киттеләр. Кайтып, мәрхүм ишан хакында төрле әкиятләр тараттылар: хәзрәтнең җанын Газраил галиһәссәлам, яшь егет булып килеп, рәхмәт белән кабул иткән, имеш; үлгәч, каты буран чыгып, ничә йортларны кайраткан, имеш; йөз йортта ут чыккан, имеш; суларның бозлары эрегән, имеш. Каберенә салгач, җир астыннан «Мәрхаба! Мәрхаба!» дигән тавышлар ишетелгән, имеш... Кабере өстендә ак нур сузылып күккә менгән, имеш... Шәйх Бисатам, Хуҗа Баһаветдин, Хәсән Басрый кебек әүлияләр, ак чәчәкләр, чалмалар белән ишанның мәсҗеденә килеп, хәтем багышлаганнар, имеш...

Шундый «имеш-мимеш»ләр белән бигрәк караңгы казакъ даласы гөр итте.

Әтраф — тирә-як.
Хәлкасына — янына түгәрәкләп.
Мәрхаба! — Хуш килдегез! Килүегезгә шат!
Хәтем — Коръән уку.
Мәлҗәэ — сыена торган урын.
Мәгъбүд — табыныла торган зат.

* Ихтимал, хәзрәтнең туфрагын бер дә калдырмый ташып бетерерләр. Ихтимал, әлгази билләһи, хәзрәт кабере Бохаралардагы әүлияләр каберендән дә битәр бер мәлҗәэ бер мәгъбүд булуб китәр дип хафаланучылар да бар *(Ш. Бабич искәрмәсе)*.

* * *

Карт ишан үлгәч, яшь ишан тугач, аңлы яшьләр үзара җыелышып, һәр ике ишан хакында да мөзәккәрә кылыштылар.

— Ишан мәрхүм (Алла рәхмәт итсен), тугрысын әйткәндә, чын галим дә түгел, тәрәккый пәрвәр дә түгел иде,— диделәр.

— Тәрәккый пәрвәр булса, фәлән, фәлән ...итмәс иде, диделәр...

— Чын галим, чын тәрәккый пәрвәр, чын яңалык тарафдары итеп күрсәтүләре бар да буяу гына,— диделәр.

Яңа ишан хакында төрле исемгә киттеләр. Бәгъзеләр: «Әткәсе намы белән түгел, бәлки үз юлы белән «тәәссефне», «раһибаният»не хак рәгаяәсе белән рәгаяә кылуы алып барганда ярый»,— диделәр. «Мөридләрен кулга алгач, заманча тәрбия итсә, саф ислам рухын урынлаштырырга тырышса,— тәбриккә генә лаек ул чакта»,— диделәр.

Шул рәвеш, төрле фикерләр бәян ителгәндә, арадан берсе торып:

— «Юк, иптәшләр, булмас, гадәт мәхкүмдер: ничәмә еллык тамыр җәйгән ишанлык әкәмәтләрен бетерү мөмкин түгел, ул мохиткә йотылачак, шул мохит аны суырачак... Мәхдүмнең замана ишаны булуы өчен ишанлыкның бөтен әсасы һәм мөридләре яңа булуы шарт»,— диде.

Шунда берсе: «Алай булса, без яшьләр сыйныфы үзебез аңа мөрид булып язылыйк»,— диде. Мәҗлес көлешеп таралды.

Карт ишан хакында мин үз тарафымдан бер сүз әйтә алмыйм. Ул ашады, яшәде, булды, бетте... үлде, котылды... вәссәлам.

Алла рәхмәт әйләгәй, урыны җәннәт әйләгәй, йөзләрен ак, сүзләрен хак, рухларыны шат әйләгәй.

Әлбәттә, аның хезмәтләрен һәркем тәкъдир иткән кеби, мин дә итәм. Билхаса, аның казакъ-кыргызны агарту юлындагы хезмәтен бик зур хәер һәм зур хезмәт дип яд итәм.

Мөзәккәрә кылышу — сүз алышу.
Тәрәккый пәрвәр — прогресс яклы кеше.
Нам — исем, ат.
Рәгаяә — бер дәүләтнең халыклары.
Мәхкүм — хөкем ителгән.
Әсас — нигез.
Билхаса — аерым алганда, атап әйткәндә.
Яд итү — искә алу.

Казакъ-кыргыз халкы ишанга фәүкылгадә мөнтәзыйрдыр. Аны белеп торсыннар.

Мин яна ишан хакында да артык сүи зан белән карый алмыйм. Башта мин ишанлыкны кабул итмәс, дип уйлаган идем.

Уйлагычым сынса да, һаман өметне өзмим:

— Ишанлыкны кабул итенүдән, инша алла, берәр сәясәте, берәр хәерле мәле, максады булыр,— дим.

Неужели «Сөләйман йөзеге» киюдән максады фәкать «асат кәсеп» кенә булыр? Ай-һай, белмим!..

«Қармак» журналында кемдер берәү «Китабеннас» дигән әсәрендә аның хакында шулай димеш иде:

Габдрахман Рәсүл, сиңа ишанлык зур мирас,
Булсаң ишан, мәгънүн урынына гыйлем-әхлак өләш!

Бу фикергә мин дә бөтен барлыгым белән иштирәк итәм.

Мөнтәзыйр — көтеп торучы, өмет итүче.
Сүи зан — начар уй, начар фикер.
Сәясәт — политика.
Мәгънүн — бозын фикер, ялган мәгънәсендә.
Иштирәк итәм — кушылам.

1917

УФА ХӘБӘРЛӘРЕНЕҢ МӨНДӘРИҖӘСЕ

Алла боерса, исән булсам — кызыл кар яуса, ата казың күкәй салса, терсәк тешкә тисә, карчык ачуланмаса, тиз арада языласак «Уфа хәбәрләре» нам мәкалә мөһиммәмнең мөндәриҗәсе ошбу түбәндәге рәвешчә булачак:

1) «Тормыш» газетасы. 2) Самад. 3) Госманов. 4) Самад. 5) «Тормыш» газетасы. 6) «Тормыш» наборщиклары. 7) Закир. 8) Сания. 9) Самад. 10) Гомдә. 11) «Тормыш» газетасы. 12) Әл-Кадири. 13) «Тормыш» газетасының кәгазе. 14) Гыйбадуллаһың ыгы-зыгысы. 15) «Тормыш» конторщигының күсәк астында каләмнәрне биетүе. 16) Бичара шагыйрь Җамалетдинның «Тормыш» идарәсендә мөсәххих өстәлендә тәмәке төтене белән чормаланып, шагыйранә сурәттә саргаеп, көне-төне моңаеп утыруы. 17) «Тормыш»ның «Госмания»гә, «Госмания» шәкертләренә хас бер әйбер булып калуы. 18) «Нур» калдыклары труппасының, «Новое» клубыннан чыгып, «Тормыш»ка, «Тормыш»тан чыгып клубка, клубтан чыгып «Тормыш»ка, «Тормыш»тан чыгып «Молочный»га, «Молочный»дан чыгып «Тормыш»ка, «Тормыш»тан чыгып көчкә-көчкә генә өйләренә кайтып китүләре. 19) Труппа калдыкларының, эчтә җилләр выжылдый, бүреләр улый башлагач, «бенефис»тан ботка пешерүләре, керосин салган ботка белән халыкның өстен-башын буяп җибәрүләре. 20) Уфа мөселман җәмәгать хадимләренең яңа ел туу шатлыгыннан өч көн сәрхүш булулары. 21) «Галия» юбилее көнендә «Тормыш» мөхәрриренең авылга качуы. 22) Юбилей мәҗлесендә Сабир һәм Җиһангир муллаларның буылып утырулары. 23) Юбилейның «Максад асылы»сы мөдиренә бирелгән бүләкләр астында күмелеп калуы. 24) «Милләт» китапханәсенең, «Милләт! Милләт!» ди торгач, саргаеп кибүе, «Чулпан»ның сусыз җирдә чуртан булып калуы,

---

Нам — исемле.
Мөһиммә — бурыч ителгән эш.

«Сәбах»ның сәбахы «сәбах аш-шаятин» булып чыгу сәбәпле, озын борыннарының ах-ух килеп йөрүләре; «Вәрисәи Хөсәения»нең, «коры корсак» чире ата-бабасыннан мирас калу сәбәпле, дарулар белән генә бетерү мөмкин булмавы. 25) Галимҗанның кызларны үкертеп җылатуы. 26) Мирзаларның һаман мирза булып тискәре агышларына риза булып яши бирүләре. 27) «Дин вә дөньяга имгәк» журналының сүгенсә хакы бар диярлек дәрәҗәдә татарларда озын, инсаф күрелмәве. 28) Аңсыз һәм мәгъзүр яшьләрнең «домашний маскарадлар»ны үрчетеп җибәрүләре... вә кечек-кечек Распутиннар заһир булуы!..

Мәгъзүр — булдыксыз.

1917

СӘФӘР АЛДЫННАН

> Каян тотып башларга?.. Язам дигәч, язам!.. Хуш бул, иптәшләр!.. И мескенкәй идарә!.. Әл-Кадири хәзрәтләре... Син милләтчеме, социалистмы? Милли-мәдәни мохтарият!

Пароходта бер көн килдем инде...
Яшәсен мохтарият вә кургагият!..

Кайдан тотып башларга? Язарга дисәң (хикмәт кемгә дә шулаймыдыр?), каян «тотып башларга» белми йөдәп бетәсең. Башыңа, бердән, биниһая чуалчык тәэссорат һәм чуалчык әфкяр килеп төшә дә, мәҗмугасыннан бик зур бер «кәбәк томаны» хасил була. Ул томан йә башыңны авырттыра, йә эчеңне пошыра, йә өметсезлек тудыра... Кала бер генә нәрсә: каләмне ыргытырга, кәгазьне җыртырга, шуннан соң йә торып йөрергә, йә акрынлап җырлый башларга!

Шулай бер мәртәбә каләм тотудан кәгазьгә бер нәрсә дә таммагач, башка тулган томанны таркатыр өчен ипләп кенә торып йөри башладым. Йөри башлагач та куллар чалбар кесәсенә керде. Бик табигый нәрсәдер ки, чалбар кесәсенә кул кердеме, дәррәү иреннәр як-яктан бөрелеп җыела да авыз очлаеп алга чыга. Керешәсең иплән кенә сызгырынырга, аннан ыңгырашырга, аннан җырларга... Шулай авазлар өрелеп тәдриҗи рәвештә җырлау хәленә килеп җиткәч тә, хәлгә монасыйб җырны табып җырлый башладым,

Язасылай сүзне ай язалмыйм,
Ни булдикән минем каләмгә?..

Биниһая — чиксез, очсыз-кырыйсыз.
Тәэссорат — тәэсирләр, уй-тойгылар.
Әфкяр — фикерләр.
Тәдриҗи рәвештә — әкрен генә.
Монасыйб — туры килә торган, шул дәрәҗәдәге мәгънәсендә.

Күз алдымда дәртләнеп аккан сулар, күкрәп торган урманнар мине мыскыл иттеләр:

Язасы да сүзне язалмыйм, дип,
Җырлау оят дәртле адәмгә.

— Юк, ни булса да булсын, язам дигәч, язам! Куркып-нитеп торырга, Коръән тәрҗемәсе түгел ул хәтле!

Язам, язам... Әһем, әһем...

Юл чыга торган кешенең эше билгеле: төренә, җыена, азык-төлек хәзерли... Бер җирдә тора-тора чүп-чары күбәеп киткән булса, безнең кебек адәмнәр кәрҗин (кәрзинкә) алырга чыга...

Чыктым кәрзинкә эзләргә. Талчук базарына бардым, югары базарга мендем. Алланың ачы каһәре белән тончыккан дөньясы бит, ачуым килмәгәе... Кәрзинкәгә кадәр юк... Ничек кирәк таптым шунда бер нәрсә... Чәй беткән, шикәр юк... Бер алынган да беткән... Карточка белән барсаң да бирмиләр. Хәер, дөя белән сәфәр чыгасы түгел, нигә анысы? Мин шулай җыендым, төрендем. Бу булды.

Калды иптәшләр белән исәнләшү.

Билгеле бит, бер җирдә күбрәк торсаң, лыгырдашып гомер үткәрү өчен, үз көймәңә утырырлык дус-ишләр ясап аласың... Күбрәк чәен эчкән, күбрәк тәмәкесен тартышкан иптәшең булса, үпкәләвеннән куркып, күрешә барырга туры килә. Телдә генә бит ул, никадәр «ахирәт» дус дип йөрсәң дә, күбесе «дөнья дусты» булып чыга аның. «Алыш-биреш» тә чак кына мөсәһалә кылганга да җимерелеп төшә торган «дус-иш» күп ул бик. Дус дигәнең астан кимереп ятучы дошман булып та чыккалый бәгъзе. Алла сакласын...

Шундый дуслар хакында ошбу бәет җари улмыштыр:

Дусларым дим, дусларым түгел, алар — шайтаннарым,
Барсы да шайтанга саткан җаннарын-вөҗданнарын;
Барсы да тыштан көлә, эчтән явызлык касд кыла,
Барсы да тыккан башын шайтан канаты астына!

Иптәшләрнең туры килгәне белән күрешеп, килмәгәненә язу калдырдым: «Хуш бул инде, иптәш! — дигән булдым.— Үзеңне күреп, күзеңне үбеп булмады инде,— дигән булдым,— тән аерылса да, җан аерылмасын, күңел аерылмасын, хуш бул! Фәлән-фәсмәтән...»

«Иш ише «белән», Ишмөхәммәт бичәсе белән»,— дигән-

Мөсәһалә кылу — йомшак, түбәнчелекле мөнәсәбәттә булу.
Җари — барлыкка килү, дәвам итү.
Касд кылу — максат итү.

дәй, һәркем үзенә иш тапкан кебек, үзенә ошаган урында, үзенә лаек зәминдә кайный. Китәр вакытта шул урыннарны зиярат кылып чыктым. Иң әүвәл барып кердем әллә нинди киң фикерләр, ерак өмидләр белән исергән «Исрек» идарәсенә. Йяләре өйдә булмаганга күрәдер, «Исрек идарәсе» аталган мескен бүлмә, ташландык бүлмә кеби, тәмам тузынган хәлдә ята...

Ишектән баш тыгып карап тордым да:

«И, мескенкәй идарә! Син шулай «йолкыш» булмасаң, син шулай «өтек» булмасаң идең, үзең кебек «хөрти», үзең кебек «җан тәүфыйк» ярлы-мескеннәрне яклаган булып та маташмас идең шул!» — дип уйланып чыгып, «Исрек» басыла торган «Мәшрикъ» матбагасына кердем.

— Ни хәлләр? — «Исрек» басыламы?

— Матбага бушамый... Аның кайгысы ди монда!..

Чыгып киттем... Бичара газета, әтиең-әниең өйдә булмагач, син ятимне кем карасын?..

Барып кердем — газета сәхифәләрендә «дин», «милләт» дигән «Мөкаддәс зәһәр» белән зәһәрләнеп котырган «Котормыш» идарәсенә. Анда очрадым — Мисыр әл-Каһирәдән мәгълумат төяп кайткан Каһир әл-Кадири хәзрәтләренә!

— Әссәламәгаләйкүм!

— Вәгаләйкүм әссәлам, исәнме-саумы?

— Ни хәлләр? Менә шул хәлләр...— Китте сүз, китте сүз. Сүздән сүз барып житте көлке журналларына.

Ул әйтә: «Безнең көлке журналлары җыен пычрак сүгештән гыйбарәт»,— ди. Бу сүзенә каршы: «И хаваҗаи би мәсәл... (...) «Пычрак сүгеш» тәгъбире дөрес түгел, бәлки «пычрак күренеш» булырга мөмкин, чөнки көлке журналы бер көзгедән гыйбарәт ул, аңа менә сездәй зат галиләрнең иҗтимагый, әдәби сәяси хәяттагы күренешләренең эч йөзен ингикас итә!» — дип әйтмәкче идем, әллә ни кыздырып җибәрер дип курыктым. Өстән кеше бәддога кылса, алла сакласын, йә сәфәрем уң чыкмас...

Тагын ул әйтә: «Синең язып торганнарыңны да күрдек, әдәпсез, пычрак рәвештә сүгенә идең! — ди. Ни өчен болай ди ул? Чөнки «Кармак»та зат галимнәренә дә таяк төшкән иде. Чынлап та, әгәр «Кармак»та аның хакында:

Зәмин — җир, урын.
Зиярәт кылу — күрергә, күрешергә бару.
Мөкаддәс — изге.
Сәяси хаят — политик тормыш.
Ингикас итә — чагылдыра, сурәтли.

Әл-Кадирның кадере төшмәк әлмисактан кад-кадер,
Гаклына, фәһменә истибдадлы хиссият мөдир,—

димәенчә, мәсәлән:

Зикер вә тәсбих урнына исмеңне яд иттем, Закир,
Бихисап эш күрсәтеп күңлемне шат иттең, Закир,—

диелсә иде, яки мәсәлән:

Остазым син, барча остазлар эчендә мөмтазым,
Син гыйлем котыбында мигъраҗларга ашкан шаһбазым!..—

— диелгән булса иде, яки һич югы:

Кырда талдан тал үсә, тайдан матур байтал үсә,
Әл-Кадирига кем җитәр?.. Җитсә җитәр Баттал, Муса! .—

мәфһүмендә берәр җыр әйтелгән булса иде, шык та юк инде миңа:

—«Кармак»та тик синең мәкаләләрең генә самимилеге илә мөмтаз,— дияр иде.

Шулай инде ул — чөйгә — чөй, сыйга — сый, азыкка — азык, казыкка — казык!

Тәнкыйть бирәүгә дә кәнфит түгел!

Билхасса, Закир әл-Кадири кебек гасаби мөхәррирләр ничек кенә эреләнсә дә — мәгъзүр.

Янә ул миннән сорый:

— Син милләтчемесең, социалистмысың? — ди.

Сөаль телендә (...) «көрмәләнгән» вакытта, маңгаена: «Син Галимҗан яклымы, әллә Гомәр әфәнде партиясендәме?» — дип аермачык язылган иде һәм күңлемдәге төп фикере дә маңгаена язылган мәзкүр сөальгә җавап алу иде.

Бу сөаль күңлемә: «Иман шарты»ндагы силсиләдән торырсың? Мәзһәбең нидер?.. Син сөннимe, шәйгыйме?

Әлмисак — ярату, яратылыш.
Кад-кадер — буй-сын, дәрәҗә.
Фаһем — аң.
Истибдад — мин-минлек, деспотлык.
Хиссият — хис-тойгы.
Яд иту — куллану (искә төшерү).
Мөмтаз — иң югары, яхшысы, сайланганы мәгънәсендә.
Мигъраҗ — баскыч.
Мәфһүм — мәгънә.
Билхасса — атап, төбәп әйтү.
Гасаби — ялап алучы, илбасар. Монда тиз кызучан мәгънәсендә.
Мәгъзүр — урынлы, гозерле.
Мәзкүр сөаль — югарыда әйтелгән сорау.
Силсилә — бер-берсенә бәйләнешле булып килгән әйберләрнең барлыгы.
Мәзһәб — тоткан юл.

«Тормыш» яхшымы, «Ирек»ме?.. дип сораулары кебек тәэсир итте. Мин аңа каршы:

— Мин милләтче дә, социалист та. Ләкин буржуй яки кадет түгелмен,— дидем.

— Мин дә буржуй түгел, ләкин, һәрхәлдә, социалист-революционер булудан еракмын. Чөнки С. Р. ләргә динең, милләтең нипачум аларга...— диде.

Теленнән: «С. Р. ләргә дин вә милләтең бер тин!» — дип чыккан сүзенең хакыйкатен — эчке үзәген маңгаеннан укыдым: «Чөнки С. Р. ләр — Галимҗан вә аның иттыйбагълары. Һичвакыт «дин, милләт!» дип сөйләшмиләр, дин, милләт исменнән язмыйлар, торалар да: «Байлар — ярлылар»,— диләр. Алар милләтне тар-мар итүчеләр... Менә, ичмасам, Гомәр Терегуловны әйт — һәрвакыт «дин» дип, «милләт» дип сөйли... Хак мөселман, гомергә кирәргә тиешле илх...

Укып бетерә алмадым, маңгаендагы язу гаиб булды.

Закир әл-Кадири җәнабларыннан сорыйсы иде:

— Байлар, ярлыларның иктисади маиләләрдә аерылышуларыннан дин, милләт эшләрендә дә аерылышулары газыйм булып килә микәнни?

«Икътисади эшләрдә берләшә алмыйбыз» дигән сүздән милли, дини эшләрдә берләшә алмауны ничек казып чыгара икән? — Үз тәгассебебездә нык торганыңны, мәсләк дошманыгызда чиктән узганынны, дин, милләт исемендә буяп күрсәтү, сакал кырып йөзне шома күрсәтергә тырышу кабиленнән бер нәрсә түгелме?

Татар социалистлары: «Дини, милли мәсьәләләр янына байлар мәнфәгатен кушып, барысын бергә буташтырып, шуның өстенә кызыл, яшел флаглар күтәреп:

— И, агай-эне мөэмин-мөселман! Кил, зинһар, берләшик! — диюләр күз буяу рәвешендә ярлыларга җәбер, ярлылар хакына илтифат итмәү, ярлылар теләген аяк астына салып таптау ул...

Кызыл, яшел флаг икесе генә булганда татар социалистлары аның астына җыела ала, әмма күздән яшерелгән

Иттыйбагъ — иярчен.
Илх — һәм башкалар.
Гаиб булды — юкка чыкты.
Маилә — теләк.
Газыйм булып килү — сәбәп булып килү.
Икътисади — экономик.
Тәгассеб — фанатизм.
Мәсләк — киләчәккә юл, хыял.
Кабиленнән — ягыннан.

өченче бер кара флаг, мәнфур флаг бар, кадетләр, буржуйлар кулыннан күтәрелгән күз яшь катып кара каннан ясалган «залим флагы» бар!.. Менә без шуңа күрә кушыла алмыйбыз!» — диләр түгелме?

Ярлыларны яклау белән кеше дин вә милләттән язмаса кирәк иде.

* * *

Пароходка утырып киттем...

Шәһәрдә калган газиз дуска күңелемнән җырладым:

Пароход китте,
пароход китте,
пароход күрми каласын...

(...) Серле секунд аңлаткан матур яшеллек капланган су читенә күз төште. Гүя ул җырның ахырына ялгады:

Яшьлек гомрең үтеп китте, рәхәт күрми каласың...

Күкрәк тутырып: «Уфф!» — дидем...

Каерылып артка: «Мин аерылдым, туганнар, хуш»...— дидем.

* * *

Сәфәр чыгасы булдисәм, һәрвакыт ашыгам да дөньямны онытам... Пароход кузгалып киткәч, фатирда яп-яңа кәвешем онытылып калганы искә төште. Ах, мур төшкере икән! Тиз генә бер иптәшкә җибәрергә хат язарга утырдым.

«Сөекле иптәшем!

Каһәр генә суксын, минем фатирда (беләсеңме, теге... урамның аръягында — яр ягында, сукыр карчык йортында) өр-яңа кәвешем калган!.. Зинһар, сина үтенеч... шуны барып ал да минем исемнән «шәкертләр комитетына» садака итеп бир!.. «Минем юл унуга дога кылып алсыннар»,— дип әйтеп әйтә, диген!»

Милли-мәдәни мохтарият!

Залда шәһәрдән алып чыккан газетаны карарга тотындым. Гадәт буенча, күз «Идарәдән җаваплар» кыйсеменә йөгерде:

— Гайнетдин Сәйфетдиновка: шигырегез, шигърияте тансыктан, басылмый;

— Мулла Биктимерҗан әфәндегә: сезгә дә шул җавап;

Мәнфур — җирәнгеч, нәфрәт ителгән.
Кыйсем — бүлек.

— Дәлдәлниса ханымга: андый вак гайбәтләргә газета сәхифәләрендә урын юк (...)

Тиз-тиз генә игъланнарны да сөзеп алгач, «Икенче корылтай җыелышын» укый башладым... Укыйм... укыйм... Менә килеп җиттем; гаҗәеп шатлыклы, гаҗәеп мөһим хәбәр:

— 22 июль, сәгать унда милли-мәдәни мохтарият игълан кылынды!..

— Бөтен Волга буе һәм Себер мөселманнарына...

— Сәхнәгә кызыл һәм яшел байраклар чыгарылды...

— Халык шаулатып, мәсәлсез рәвештә «Урра!» кычкырды, дөпелдәтеп кул чапты... шатлыктан нишләргә белмәде: үбеште, кочышты, елашты, көлеште...

— Мөфти хәзрәт Коръән укыды... дога кылды...

— Халык «Алла әкбәр! Аллар әкбәр!..» әйтте.

Зиһенеме бердән биниһая шатлыклар, искиткеч ямьле уйлар килеп тулды... Хәтергә мескен милләтнең, изелгән, тапталган сөекле кавемемнең үткәне һәм хәзергесе килеп кичте. Съездагы халыкның манзарасы: кочышулары, шатлыктан елашулары, гаһедләре, антлары, сәхнәдәге яшел һәм кызыл байрак күз алдына килеп басты... Ихтыярсыз рәвештә күздән яшьләр чыгып, милли-мәдәни мохтарият язылган сәхифәгә тамдылар.

Күз яшьләренә камил мохтарият биреп укуда дәвам иттем.

— Милли-мәдәни мохтариятне хөкүмәттән тәсдыйк кылуны таләп итәргә, тәсдыйк кылмаса, (...) «гамәлгә» куя башларга...

Ие, шулай итәргә, катгый шулай итәргә... Шытырдатып торып таләп итәргә!.. Тәсдыйк кылмаса — ис китмәскә! Ходага тапшырып эшкә куярга!..

Җитәр, байтак канымызны суырдылар, байтак дөньямызны, телемезне мыскыл иттеләр...

Хөррият гасырында да кол булырга — без кол түгел!.. Һаман суелырга — без хайван түгел!.. Сорыймыз, күзне акайткан, түшне киергән хәлдә сорыймыз:

— Яхшылык белән биреп котыл, малай! — димез... Бирмәсәңез, карап тормыйбыз, эшкә керешәмез... Бездә кешеләр дә бар, бар да бар — әлхәмделиллә! Барын да булдырырбыз!

Корылтай — съезд.
Мохтарият — азатлык, ирек.
Кавем — халык.
Манзара — күренеш.
Гаһед — вәгъдә, ант.
Тәсдыйк кылу — хуплау, раслау.

Үз тормышымызны үземез ясарбыз,
Үз хакымызны үземез ашарбыз...
Күкләр очарбыз,
                  йолдыз үбәрбез,
                         теләсәң нишләрбез!..
Кермәсен безнең арага таракан!..
Саумасын безнең йөрәккә кара кан!..
— Яшәсен милли-мәдәни мохтарият!
— Яшәсен мәгънәви азатлык!

Шундый шатлыклы уйларга чумып, мөкаддәс күз яшьләре берлән болганган газетаны җилфердәтеп, бүлмәдәге иптәшләр янына йөгердем.

— Татар милли-мәдәни мохтарият алган... Казанда алган... Съездда игълан кылганнар... Менә карагыз! — дип, газетаны алларына ташладым...

Алар укый, мин йөзләренә, күзләренә карыйм... Әйтерсең бер нәрсә булмаган — йөзләрендә «ләм-мим» юк!

Юкса боларның каннары йөрмиме?..

Берсе калын мыек астыннан салкын гына «һа-һа-һа» дип көлде дә сүз башлады:

— Үзе «милли-мәдәнни мохтарият» ди, үзе «урра!» кычкыра... «Урра» русча ич?..

Икенчесе:

— «Урра!» түгел, «Чүпрә!» дип кычкырганнар, ди... Хи-хи-хи!..

Өченчесе:

— Анысы-анысы, мохтарият — әйтергә асат... Татар, күбесе аңламый әле аны, аны эшкә кертергә кеше юк бит, кеше!.. Нибары ике-өч бөртек!..

Ул шул сүзләрне сөйләгәндә безнең тәрәзә яныннан арык һәм ватылган, мүкләнгән йөзле, сәләмә киемле бер «агай» үтеп китте. Теге иптәшем, шул тәсәддефтән файдаланып, сүзенең ахырына ялгады:

— Әнә, сакла инде мохтариятне шулар белән, бар!

Без көләргә мәҗбүр булдык. Шатлык, ышаныч ташкыны кайта төште... Сәхнәдә кызыл һәм яшел флаг: «Белмим шул, белмим...» — дип торган төсле күренде.

Иптәшләр яныннан пароход алдына чыктым. Ике татар утыра. Яннарыннан узганда баштанаяк сөзеп карадылар... Колакка килеп бәрелде:

— Мөселман кыяфәте юк!..

Пароход астына төштем. Татар егетләре җыелышып «карта» уйныйлар. Шулар янында ук, хәлфәләр булса кирәк, җиләндә өчәү «Дин вә мәгыйшәт» укый.

Тәсәддеф — туры килү.

— Ну, Рәмиевне пешергән! — дигән сүзләрне генә ишетеп калдым.

Бу да чүп өстенә чүмәлә.

Пароход стансага килеп туктады... Стансада татарлар, бар да — «эленке-салынкы!» — бар да «шылдырым».

Пароходтан чыгучы шома, ак киемле, шат кыяфәтле чит милләтләр арасында тетелеп беткән пычрак киемнән, кайшланган төксе бүрек астында нухтан калган түбәтәй кигән, кулы-битe төнлектән чыккан кешегә охшаган татар күрдем, ул бер-ике самовар, олтан, олтырак кисәкләре, тимер-томырлар, иске бияләйләр, пималар, тагын әллә нәрсәләрне билбавына бәйләп аркасына аскан — чыгып бара.

— Менә сиңа милли-мәдәни мохтарият! Менә сиңа шуларны саклаучылар!..

— Хәерле булсын инде, эш башындагы кешеләргә алла арымас көч, гайрәт бирсен инде!..

— Әйе, алла ярдәм бирсә...

— «Ширигать истиражчылар» дошманнарыннан сакларлык догалык кәшеф итсә.

— Әһли матбугат кырыкка аерылмый тәпәләшсә.

— Мөселманнар «анархистлар» белән «монархистлар» арасында кайгырса...

— Кызыл, яшел байрак арасына пычрак «кара флаглар» килеп кушылса...

— Милләтчеләремез социалистларымызны «динсезләр» дип араларыннан куса, шулай ук социалистлар да дини эшләр арасына бака ботын китереп кыстырса...

Бар да булыр, милли-мәдәни монахиятне җиңел эшкә кертермез һәм шул хокукны югалтмамыз, саклармыз...

Өметсезлеккә, ачуга манчылып менеп җиттем...

Тагын өметләр, тагын ышанычлар:

— Юк, булыр... Кешеләребез юк дисән дә бар, милли шуралар бар... һәркайда халык оешкан... Үз полкларымыз да тәшкил алдында. Халык һәркайда съездлар ясый. Мәмләкәт болганган... Никулай-Микулай юк... Тәмам хөррият. Аламыз, аламыз... Милли-мәдәни автономия аламыз!..

Зиндандан чыгу мәдди тулды, богаулар чишелеп, капу алдына тезелдек.

> Ач капуны залим каравылчы!..
> Юкса, тибеп ачарга аякларны суздык!..

Истиражчы — теләүче, сораучы.
Кәшеф итсә — ачып бирсә.
Әһли матбугат — халык матбугаты.
Тәшкил — оештыру, төзү.
Мәмләкәт — ил, хөкүмәт.
Капу — капка, ишек.

1917

САРАЙ СЕРЛӘРЕ

Иң элек тәкерек чәчеп алыйм:

Асыл максатка керешүдән элек, язарга тиешле бераз «әнгәмәләр» барга охшый. Менә шул асыл максатка керешүдән элгәре языла торган юлларны галим-голәмә, әдип-әдибә йә аны «Мөкаддимә» дип атый, йә «Мәдәхәл» дип атый... Әмма чат татарча язам дип маташканнары йә бер «лыгырдау» дип, йә «бер-ике сүз» дип, «фәсмәтән» дип атый, гәрчә үзләре, бичаралар, сөйләшкән вакытларында юньле итеп бер авыз җөмлә тезә алмасалар да...

Мин инде бөтенләй аны-моны уйлап тормыйча, «иң элек бер тәкерек чәчеп алыйм», дип керешеп киттем... Ие, мәсьәлә менә шул, җәмәгать:

Хөрриятән соң татар хөкүмәте төзелеп, аңа «Милли-мәдәни кургагыят» дип исем бирелгәне вә ул хөкүмәтнең вәзирләре Уфада торганлыклары һәр каюга мәгълүм; шулай ук татар хөкүмәтеннән үпкәләп аерылган кавем башкортның үз алдына ханлык корганы, вә аның хан вә вәзирләренең Оренбург шәһәрен пайтахете иттихад иткәнлекләре дә һичкемгә яшерен түгел... Менә шул ике хөкүмәт министрларының ашау-эчү, йөреш-торыш вә башка хәлләре белән, хөласә, Сарай серләре белән халкымызны таныштырасымыз килә... Бу таныштыруда халыкка күп-күп файдалар бар. Аларның күбесен хәзергә сер тотып, бер-икесен генә әйтеп узыйк:

1) Шундый олугъ, бөек, шәүкәтле, гәзиз, кибер, каһир, мөтәккәбир, солтанәт затларның ашау-эчүләрен, фәләннәрен белеп тору халыкка зур дөрес хосусан нинди ми-

---

Һәр каюга — һәр кемгә.
Иттихад итү — сайлап алу.
Хөласә — җыеп әйткәндә, кыскасы.
Шәүкәтле — көчле, куәтле.
Мөтәккәбир — үз-үзен һавалы тотучы, эре.
Кибер — зур, олы.
Каһир — җиңеп чыгучы, өстен.
Солтанәт — мәһабәт, олы, зур.

нистр ниндиен, нәрсәне ярата? Ниндиен тәгамне күбрәк ашый? Менә шуларны белү аркасында халык нинди министр нинди табигатьтән икәнен, аркылысыннан-буен «кәма һүә» төшенәчәк... Бу — бер. Икенчесе: министрларның әфгале халыкка зур үрнәк. Чөнки министрлар, олуг кешеләр булганга күрә, алар белмичә ашамас, белмичә киенмәс-нитмәс, дип, аларның тәбәгасе булган халык та шулай ук министрлар кебек ашарга, министрлар кебек киенергә гадәтләнеп китүләре бик мөмкин... Бу исә халкымызның берлеген, барлыгын, миллиятен саклауда бик зур бер «сафсатадыр»... Менә шул ике файданы белеп торсагыз җитәр! Калганнары сезгә түгел, миңа да сер... Менә шул сезгә мәгълүм ителгән вә үземә мәгълүм булмаган файдаларны күздә тотып, халкымызга үз вәзирләремезнең Сарай даирәсендәге хәлләреннән хәбәр бирергә уйладык. Хәзер, әлхәмделилла, хөррият... әлхәмдилилла, тик тотып сөймиләр генә. Элек ул истибдад заманында гына мөмкин түгел иде — Сарай серләрен белдерергә... Вә шул белдерә алмау сәбәпле, Сарайның үзенә дә, халкына да зарури күп иде... Халыкка мәгълүм ителмәү аркасында, Сарай эчендә эчү, фәхеш, исрафәт, әнвагъ, төрле фасикъ-касд кайнап тора иде... Хөрриятгән соң беленгән Распутин кыйссалары азлы «сафсата»дыр.

Менә шуңа күрә, безнең Сарай даирәләрендә милли фәхешләр, мохтарият буявына буялган милли Распутиннар заһир итә күрмәсен дип, хөрриятгән истифадә итеп, халкымызга Сарай серләрен ачып торачакбыз...

Хәзергә башлыйм министрларның ашам-эчем тәртипләреннән:

Уфада «Татар хөкүмәте» вәзирләренең көндәлек ашамлык-эчемлек тәртибе:

1) **Иртәнчәк.**— Күмәч тә су. Күмәч булмаса — әпәй. Әпәй булмаса, минсиңайтим, каткан булкины, Хуҗа Насретдин мәсәлендәгечә, көлгә манып, җебетеп ашарлар.

Баш министр (...) Садри әфәнде хәзрәтләре, мөстасна

Тәгам — ашамлык.
Кәма һүә — берьюлы, тулысынча.
Әфгале — хәрәкәте.
Тәбәгасе — дәүләт кул астындагы халык, дәүләт гражданнары.
Истибдад — кансызлык, деспотлык.
Исрафәт — малны урынсыз, кирәгеннән артык тоту.
Әнвагъ — төрле.
Фасикъ-касд — бозыклык-явызлык.
Заһир итү — билгеләнү, туу, барлыкка килү.
Истифадә итү — файдалану.
Мөстасна улмак үзрә — башкалардан аермалы буларак.

улмак үзрә, гөбедән төшкән зәңгәр әйрән һәм ике криндер илә кәефләнер.

2) **Өйлә алдында.**— Иртән калган каты-коты белән бик әйбәтләп йөземләп чәй эчәрләр. Шонаси әфәнде, мөстасна улмак үзрә, чәйне үзе ясаган бер төрле «Кимияви мохтарият» салып эчәр.

3) **Көндезге аш.**— Беренчесе. Тавык тәпие салып пешерелгән чумарлы борчак шурпасы; икенче. Тары ярмасы һәм кабаттан пешерелгән мич «тәкәсе» (төрмә); өченче. Чупрәле генә «Мәкъсума!» Фәкать мөстасна улмак үзрә, Закир әл-Кадири Бохарадан алып кайткан «әфьюн» истигъмаль итәр.

4) **Кичке аш.** Беренче. Казанда пешкән бер табак коры бәрәңге (хатын вәзир Әминә Мөхетдиновага бәрәңгене, азрак кәҗә мае салып, «өчаяк»та пешереп китерерләр). Икенче. Тозлы кәбестәле, тозлы сарымсаклы, суганлы аш. Һәм тозга манып торма ашарлар... Фәкать Һади Атласи (Рәхмәтулла)ның табигате чи шалканга маилрәк булыр...

Җомга көннәрдә, минсиңайтим, ниндидер кәефле «мазгыять»не солыдан ясалган буза дигән булып, мөфти хәзрәттән өшкертеп эчәләр... Һәм Һади абзыйның авылдан алдырган «пәрәмәчләр»ен бүлешеп тыгынырлар...

«Оренбургта башкорт ханлыгы» вәзирләренең җыймакэчмәк тәртибе:

1) **Иртәнчәк.**— Беренче. Каклаган, төтендә ыслаган казылык яки күптергән ит. (Берсе булмаганда икенчесе ярый.) Икенче. Берәр тустаган катык. Фәкать баш вәзир Манатов исә катык чүлмәгеннән сары суын гына чөмер-р-ә!..

2) **Өйләгә кадәр.**— Берәр турсык «чалаб» эчеп алырлар...

3) **Көндезге аш.**— Беренче. Көлләмә. Икенче. Талкан. Өченче. Кымыз. Фәкать мөгавин вәзир Зәки Вәлиди хәзрәтләре, мөстасна улмак үзрә, үзенә махсус ясалган «кислушка» эчәр дә, артыннан ук кәкре трубкадан тәмәке төтәтер...

4) **Кичке аш.**— Ит суы белән көлчә. Аннары эремчек. Аның артыннан сары май катыш корт суы эчеп ятырлар...

«Кимияви...» — химияле...
Истигъмаль — куллану, файдалану.
Маил — килешү, ярашу.
Мазгыять — эчемлек.
Мөгавин — ярдәмче, булышчы.

Бәйрәм көннәрдә балан суыннан ясалган ачыткы «эсәрләр». «Балан бәлеше» пешертерләр — кеше башына берәр тәкә башы өтәрләр. Кесәләренә әҗегәй тутырып, урамда ашап йөрерләр...

Ихтар — башкорт гадәтендә чәй эчү булмаганга, чәй эчмәсләр...

(Киләсе номерда, министрларның кием-салымнары, йөреш-торышлары вә башка хәлләре хакында мәгълумат бирелсә кирәк).

Әҗегәй — киптергән эремчеккә башкорт «әҗей» ди *(Ш. Бабич искәрмәсе).*

Ихтар — искәрмә.

1917

ТРОИЦКИДА

Безнең монда — Троицкида — халык хөррият килгән шадлыктан хәйран калды, ни кыланырга белмәде. Хөкүмәт идарәсе алмашыну хәбәре ишетелү белән монда хәлләр бөтенләй алмашынды. Халыкның фикере, рухы, калебе, истикъбальгә карашы — һәммәсе төбе-тамыры белән үзгәрде, тыныч, салкын һәм суынган халык кинәт терелде, кинәт җанланды; шадлыктан шашты, пыр туздьы...

(...) Бу мөнәсәбәт белән шәһәр өстенә төшә торган вазифаларны идарә итәргә бил баглап, урысы, мөселманы, яһүдләре бергә беркеп керештеләр. 120 кешедән гыйбарәт комитет төзергә карар бирделәр. Сайлаулар булды. Болар һәммәсе бик кызыклы, рухлы үтде. Иске хөкүмәтнең ярдәмчеләре — полицәләре, приставлары-фәләнләре — һәммәсе төшерелеп, алар урынына халыкның үзендән куелды. Тәки «Кочин» дигән цензорны да тәукыйф итделәр. Ул кайгысыннан саташкан, паралич суккан, ди. Менә, иптәш, нинди хәлләр заһир булды, баскычның асты-өскә әйләнде. Кичә әллә нинди озын, мактаулы тмтуллар белән закир ителеп йөргән падишаһ вә хатынына бу көн «Никулай һәм Николай хатыны» дип кенә куялар. Кичә хакыңны, намусыңны изгән золым түрәләрне бүген үзләрен дә мыскыл итеп, көлеп, төрмәләргә озаталар. Кичә Сафа Баязидовны «мөхтәрәм мөфти-л-Оренбургый хәзрәт зат галиләре» дип әйтергә мәҗбүр булып, нахактан гөнаһка батып йөргән һәрбер татар баласы «шпион», «пычрак» дип шәрран яра кычкыра... Кичә хөкүмәтнең пычратуы белән пычранган дини бер органны бүген мөселман баласы үз кулы белән бәреп тазарта. Кичә өч йөз юллык «Мөхтәсәр»е белән «Коръән»не еккан Капкаев — ул да бүген җәзасын күрә... Яшәсен хөррият!.. Яшәсен хакыйкать!.. (...)

Тәукыйф иту — кулга алу.

КӨЙЛӘР ТАРИХЫ

1915—1918

1. ТАШТУГАЙ

Борынгы казакъ яулары илләрне баскан чакларда башкортлар җирләрен ташлап казакълардан качканнар. Башка җиргә күчкәннәр. Шул вакытта Таштугай дигән су буена килеп урнашкан башкорт кызлары Таштугай көен чыгарганнар. Аның бер җыры:

Таштугайның сары талларыннан
Курайларны ясап тартаек,
Ялан, тугайларның кәккүге юк,—
Урал буйларына кайтаек.

2. БАТЫР СТАРШИНА КӨЕ

Бөрҗән ягында бер старшина үзенең писарен ачуланып, бер сугып җибәргән икән. Писер үлгән дә куйган. Шуның өчен старшина Себергә сөргенгә җибәрелгән. Киткән чакта шул җырларны җырлап киткән:

Төяләч кенә буен тал алган,
Яфраклары аның таралган.
Ямьле Төяләч буйлары...
Кәккүк кенә берләнән ай бүз тургай
Кайгы-хәсрәт өчен яралган.
Ямьле Төяләч буйлары...

3. КАСЫЙМ ТҮРӘ КӨЕ

Касыйм түрә Тамьян ягында яшәгән, замананың иң атаклы кешесе булган. Үзенә берничә йөз кешедән гыйбарәт гаскәр төзеп шуларга баш булган. Русларга бер вакытта да баш бирмәгән. Бөтен Казан ханнары руска бирелеп беткәндә дә ул ялгыз үзе калган. Ахырында үзенең замандашы булган рус майоры аны, җиңә алмагач, агу эчертеп үтерткән.

Касыйм түрә Чиләбе өязендә Владимир каласында вафат булган. Шул кала янында дәфен кылынган.

Аның тарихи җыры:

Касыйм түрә менгән соры юрга,
Сорашып та майор ала алмый.
Өч йөз генә кеше, бик күп кеше
Җылашып та кабер казалмый.

Касыйм түрә менгән соры юрга,
Бора-бора килә муенны;
Касыйм түрә үлгән дип ишеткәч,
Уйнаталар матур уенны.

«Башкынаем минем бик авырый,
Абкилегез яшел көймәмне;
Бер васыять әйтер сүзләрем бар,—
Абкилегез Акколый җизнәмне» *.

Касыйм түрә менгән соры юрга,
Манлаенда булыр урае.
Касыйм түрә җавап биргән чакта
Уң кулында булыр курае.

Касыйм түрә менгән соры юрга,
Тоякларын купкан, басалмый;
Берүзе генә түгел, биш йөз кеше,
Җылый-сыкрый, кабер казалмый.

4. БУРАНБАЙ

Бөрҗән янында Буранбай дигән авылда Буранбай дигән бер кантон булган. Аның Ибраһим дигән язучысы булган. Алар бер вакытларда ил күзендә күтәрелгәннәр, дәрәҗә җәһәтеннән бик үскәннәр. Аларның һәр әйткәннәре килеп, һәр атканнары тиеп торган. Алар югары мәхкәмәләрдә дә бик зур урын тотканнар...

Бервакыт алар, һичберәүдән әмерсез-нисез, тотканнар да халыкка мобилизация игълан иткәннәр. Авыл саен барып, халыкны солдатка язып йөргәннәр. Кайбер акча биргән кешеләрне солдатка алмаганнар. Шуның аркасында алар бик күп мал һәм акча җыйганнар. Бераздан соң халык боларның эшләренең төбен тикшереп-сизеп алалар да, боларның болай башбаштаклык итеп йөрүләрен югары урыннарга белдерәләр — әләклиләр (донос ясыйлар).

Шуннан соң, боларны тотарга әмер булгач, алар кача-

Мәхкәмә — хөкем йорты, идарә йорты.

* *Акколый* — Касыймның җизнәсе (кантон) *(Ш. Бабич искәрмәсе).*

лар. Самар губернасында Бозаулык өязендә Кәмәлек дигән су буендагы башкортларга барып тора башлаганнар. Кышларын шул җирдә үткәреп, яз көне үз илләренә кайтып, хатыннарын, балаларын күреп китә торган булганнар. Буранбай Кәмәлек буендагы башкортлардан да бер хатын алган. Иң соңыннан, 3—4 еллар шулай качып йөреп, тегендә барып, бонда килеп йөргәч, аларның икесен дә тотып, хөкүмәт әһелләренә тапшыралар. Шундан аларны хөкем илә Себергә озаталар. Шул вакытта Буранбай бер көй чыгарып үзенең зарларын, аһларын җырлап калдыра. Шул көйне Буранбай көе дип атап йөртәләр. (Ибраһим — Буранбайның үз углы булган.)

Аның тарихи җырлары:

Юл буйкайларыннан йөргәләгән
Кызыл гына аяклы күгәрчен,
Кайгырма син, башым, түгелмә, яшем,
Хак язган кайгыларын күрерсең.
Оренбуркайларда ак таш кибет,
Таш кибеткәйләрдә мал кыйммәт;
Эт ашасын тапкан малларынны,—
Маллар кыйбат түгел, баш кыйбат
Ак куянкайларның ай азыгы —
Ак усаккайларның кабыгы.
Болай булыр дибүк һич истә юк,—
Туры төште хакның язгы.

* * *

Менгән генә атың киреме иде,
Тибенке аткайлары тиреме иде?
Буранбай да берлән Ибраһимы
Себерләргә китәр ирме иде?
Табак кына табак ап-ак кәгазь —
Буранбайның язган хатлары,
Буранбайның язган хатын укып,
Зар җылыйлар авыл картлары.
Буранбайның өе сарайдыр,
Дүрт мөешкәйләре калайдыр.
Буранбайны күптән үлгән диләр,
Сыңар күзе белән карайдыр*.
Буранбайның язган күп хатлары
Табак кына табак ак кәгазь,
Буранбайны Себер китте дибүк
Балаларын аның какмагыз.

5. СИБАЙ КАНТОН КӨЕ

Сибай дигән Бөрҗән башкорты Тамьян Катай башкортларына кантон булып билгеләнгән. Шунда берничә

Мөеш — почмак.
* Буранбай сыңар күзле булган *(Ш. Бабич искәрмәсе).*

еллар кантон булып торган. Аңа ул җирләр күңелсез тоелган. Үз иленә кайтырга теләсә дә, югары мәхкәмәләр аны кайтармаганнар. Шуннан соң ул, үзенең илен сагынып җырлый-җырлый, бер көй чыгарып, Фатыйма исемле хатынына төбәп җырлаган. Шул көй, шул җыр «Сибай кантон» дип йөртелә.

Тарихи җыры:

Иртә генә торып мин карасам,
Кыркты белән Үрмәкәй күренә*
Тамьян Теләү җирең ай җир түгел,
Заруратттән яхшы күренә.
Яшел генә чана, ап-ак дуга
Җиткерсәнә, Фатыйма, туратка;
Үз илемә кайтып кантон булсам,
Җитәр идем, Фатыйма, морадка.
Менәм генә туры ат биленә,
Киттем Тамьян Теләү иленә,
Ак корбанлык чалып, нәзер әйтеп,
Кайтсам иде үз илемә.

6. ЧАПТАР ЮРГА КӨЕ (БИЮ КӨЕ)

Моннан йөз еллар элек, Оренбург шәһәре салынмастан борын, Мөхтәсиб Юлмөхәммәдов исемле окружной инспектор булган. Аның бер чаптар юргасы булган. Аркасына тәпәнгә тутырып кымыз утыртып җибәргәндә, шул кымызны бер дә түкми-чәчми юргалаган. Шул юргага багышланып бер көй чыккан. Шуны «Чаптар юрга» дип йөртәләр.

7. АЛЛАЯР БАТЫР КӨЕ

Фәлән җирдә фәлән су буенда Аллаяр дигән бер батыр булган. Үзе бик оста курайчы булган. Бервакытта ул ат өстендә, атының җиз йөгәнен буш куя биреп, курай уйнап тау буйлап килеп ята икән. Шул вакытта тау буенда бик күп кызлар тауга үскән муелны (шомыртны) җыеп йөриләр икән. Батырны күргәч кызларның күңелләре кытыклана башлаган. Аллаярның юлы муел агачы төбеннән үтә торган булган. Күп кызларның арасыннан берсе юл өстендәге муелга менгән дә, бер ботагына ябышып, Аллаярның юлы өстенә югарыдан асылынып торган. Батыр килеп җиткәч, кыз аңа: «Минем сиңа дәртем төште, әгәр мине муелдан тартып алсаң — сиңа барам»,— дигән. Аллаяр кызның ботыннан тартып төшергән дә атына атландырып иленә

---

* *Кыркты, Урмәкәй* — Катайдагы тау исемнәре.

алып киткән. Илендә кыз белән бераз торгач, аны азат итеп, үз иленә кайтарып җибәргән. Шул вакытта «Суык таш асты», «Суык муел» дигән көйне чыгарып җырлаган. Бу ике көй бер-беренә янәшә җырланып, уйналып йөриләр.

8. КОЛЫЙ КӨЕ

Идәш суының буенда Колый Акдәүләтов исемле берәү бер ат биреп үз исеменә көй чыгарткан.

9. БЕР ТИРӘК КӨЕ

Шул ук кешенең өе алдында бик зур, бик гаҗәп бер тирәк булган. Шул тирәк исеменә, тагын бер колын биреп, бер көй чыгарткан. Колый — пенсия ашап торган, гаять кәеф-сафага бирелгән бер башкорт булган.

10. ШӘҮРӘКӘЙ ЯКИ СӘЙФУЛЛА КӨЕ

«Насыйр көе» дип тә йөртәләр. Насыйр дигән кеше каторгага киткәндә җырлап киткән.

А н ы ң ж ы р ы:

Аккош кына очар күл тынар,
Насыйр гына китәр илләр тынар.
Насыйр китә диеп куанмагыз,—
Насыйрдан да усаллар туар.

11. ШАБӘРӘК КӨЕ (ШАҺИ МӨБӘРӘКОВ)

Орски өязендә Карагай Кыпчак волосында Биккол дигән авылда Шаһи Мөбәрәков дигән бер угъры булган.

Ул үзе асла угъры булмаган. Халык аны күрә алмаганлыктан гына «угъры» дип яман атын чыгарып, тоттырып Себергә җибәрткән. Шаһибәрәк җырчы һәм курайчы бер прапорщик булган. Халыктан качып китеп, бер кыя тау башындагы карагай агач башына менеп качкан. Халык, артыннан килеп, карагайның әйләнәсен сырып алган. Шунда Шаһибәрәк халыкка: «Сез барыбер мине тотасыз инде, миңа бераз ирек бирегез, мин аз гына җырлап алыйм»,— дигән. Халык аны тыңлаган, ул карагай башыннан торып җырлап җибәргән.

Т а р и х и ж ы р ы:

Ирәндеккәй тауның аръягында
Ак яурлы беркет сәүине,

Шаһи Мөбәрәкне тотып, угъры итеп,
Баер микән Биккол авылы?
Биккол гына авыл — бик бай авыл,
Урамнары бигрәк тар авыл.
Шаһи мескен кайтып килер инде,
Алды-арты аның каравыл...

12. ҮЗӘНБАЙ КӨЕ

Бу тарих языла башлаган вакыттан 40—50 еллар узган. Элек Беренче Үсергән волосында прапорщик Хөнәш Үзәнбаев дигән бер егет булган. Ул Муйнаб яки Кыргыз дигән авылның кешесе, зур мыеклы мәһабәт бер егет булган. Мыегын колагына җиткереп, колагына урап йөри торган булган.

Бервакытта ул конный (ат) заводында мөдир булып торган. Шул вакытта аны канечкеч түрәләр, старшиналар, куралмаганлыктан, эңа төрле яман атлар такканнар. Ахырда мировой посредник Соколов дигән урыска аны угърылыкта гаепләп күрсәткәннәр һәм аны Иркут губернасына Себергә җибәргәннәр. Шунда үлеп калган. Шул вакытта, Себергә киткәндә, шул көйне җырлап киткән.

Тарихи җырлары:

Керпе дә генә җир булыр,
Үзәгендә аның җил булыр
(Керпе җирләрендә җил булыр).
Угъры дигән исем таксалар да,
Үзәнбаев асыл ир булыр.
Муел гына агач ямьле икән,
Башларында чәчәк бар чакта;
Керпе дигән җирләр ямьле булган,
Кадрен белгән ирләр бар чакта.
Керпе буйларында ак татыр,
Ашаса, чыгар малның төсенә;
Хөнәшне дә җибәргән ай Соколов
Китсен сәфәр тәмуг төбенә.
Екмалы ла көймә тройка,
Аркылы ла елга буенда,
Вольный поселение китәр дип,
Килмәгәндер Хөнәш уена...

13. БАЛА КАРГА

Башкортларның курай даһилары Бала Карга атлы бер сикертмә бию көе уйныйлар. Ул көйнең тарихын шушылай сөйлиләр. Мондан күп заманнар элек бөтен кош-кортларга кадәрле хөкем йөрткән бер бик зур бер падиша булган. Көннәрдән бер көн падиша кошларның башлыгына шундаен бер әмер биргән: «Әй, кошлар башлыгы, син үз

янына бөтен сайрар кошларны җыйнап, сайратып кара да, арада иң матур сайраганын алып килеп, минем тәхетемнең түбәсенә куй»,— дигән.

Ул вакытта кошларга бер бик карт кара карга сайланып башлык булып билгеләнгән икән. Карт карга, дәрхәл бөтен кошларны җыйнап, сайратып караган һәм үзенең баласы яшь карганы да сайраткан. Бөтен кошлар арасында үзенең баласыннан матур сайраучыны тапмаган. Шуннан үзенең бала каргасын падишаның тәхете түбәсенә мендереп куйган. Падиша тәхеткә менеп утыргач, кош башлыгы килгән дә, сәлам биреп, җир үбеп: «Тәкъсир, эзләгән, теләгән кошыгызны алып килдем»,— дигән. Падиша да: «Хуп»,— дип җавап биргән һәм бала каргага сайрарга кушкан.

Бала карга: «Карк-карк»,— дип каркылдарга керешкән икән, падиша: «Шушы булдымы матур сайраучы кош, и исрек сарык!» — дигән. Кошлар башлыгы карга: «Тәкъсир, мин кошларның барын да тикшереп, сайратып, бик дикъкать белән тыңлап карадым, ләкин араларыннан каргадан да һәйбәт, матур сайраганын тапмадым»,— дигән. Падишаның уенчылары шул вакыйга мөнәсәбәте белән бер көй чыгарганнар, имеш.

14. ГӘЗИЗӘКӘЙ КӨЕ

Бу көйне Үргәнәй буендагы бер карт яшь вакытта чыгарган. Оренбург өязендә.

15. СЫРДӘРЬЯ КӨЕ

1856 нчы елларда Ак Мәсҗед, Хоканд халыклары белән яулашып яткан башкортлар җырлаган көй. «Сырдәрья» яки «Армия көе» дип атаганнар. Гаскәр белән күмәкләп җырлаганнар.

Җырлары:

Кояш кына чыгар әйләнеп, ак болытларга бәйләнеп,
Хак тәгалә кушса, без кайтырбыз, туган-үскән җиргә әйләнеп...

Башкынаем аурый, билем тала, билләремә кылыч бәйләсәм,
Ак куйлардан корбан чалыр идем, туган илгә кайтып әйләнсәм...

Камышлардан күпер салыр идек, Сырдәрьядан ярып үтәргә,
Хак тәгалә безгә кушкан икән исән кайтып дөнья көтәргә,

Дәрхаль — шул ук вакытта, шунда ук.
Тәкъсир — руханиларга олылап эндәшү.

16. ТУРЫ АТ КӨЕ

Борын заманда бер башкортның туры тулпары, ланда йөреп арыгач, ике тау арасына, аулак бер чокырга төшеп, канатларын җәеп хәл җыеп ята икән. Шул вакытта Гали дигән бер кеше килеп чыккан да тулпарга бик сокланып караган һәм, авылга кайтып, атның иясенә: «Атың фәлән чокырда ята»,— дип әйткән. Иясе аңа барып җиткәндә, тулпар үләргә ята икән. Шул вакытта атын кызганып «Туры ат көе» чыгарып җырлаган.

Аның җыры:

Ашамый да туры ат, күшәмәй дә туры ат,
Туры ат үлеп бара, Шәмси балам, бир пычак,
Шәмси балам, бир пычак...
Туры үлмәй ишләсен, Гали җиткән башына...

Тулпарны халык болай тәгъриф итә: ул карап торуга юаш кына, ябык кына була, имеш. Үзе канатлы була, имеш. Таудан-тауга сикереп очып йөри. Аның канаты кешегә күренми. Бик аулак урыннарда гына канатларын чыгарып, хәл җыйнап ята икән.

17. КАҺАРМАН КАНТОН

Борынгы башкорт кантоннары эчендә, Орски өязендә, хәзерге Үсергән волосында Каһарман Бурангол угълы дигән бер кантон булган. Ул, 17 яшьтә армиягә кереп, француз-рус сугышында катнашкан һәм Наполеонны Мәскәүдән куган башкорт гаскәре эчендә сугышкан. Каһарман үзе поручик булган. Аның атасы — Бурангол кантон армиясенең полковнигы булган. Каһарман үзе поручик булган. Аның батырлыгы өчен хөкүмәт тарафыннан 6 данә медаль бирелгән. Ул, сугыштан кайткач, илендә кантон булган. Аның заманында башкорт кантонлыгының аерым солдат тотулары бетерелеп, штатскига (Русиягә табигый гражданга) әйләндерелгән. Шунда Каһарман штатка керергә разый булмаган. Соңыннан, чарасыз, күнәргә мәҗбүр булган. Борынгы кантоннар һәркайсы үзләренә махсус курайчылар, җырчылар-үзләүчеләр тотканнар һәм шул куштан җырчылардан үзләренә атап көй чыгартканнар. Каһарман кантон бик ачарлы, гайрәтле кантон булган. Ул җырчылар тотмаган, курайчылар җыйнамаган, шулай да

Тәгъриф иту — сөйләү, аңлату.

курайчылар шул вакыйга мөнәсәбәте белән Каһарман кантонга багышлап бер җыр, бер көй чыгарганнар.

Аның җыры:

— Шәһидә, кая барасың?
— Су буена җиләккә.
Каһарман кантон котатский,
Ник булдың штатский?
— Ул җиләкне нишләтәсең?
— Җибәрәмен бүләккә.
Каһарман кантон котатский,
Ник булдың штатский?
Каһарман кантон, барам сиңа,
Булмасаң штатский...
Шәһидәнең бүләге —
Кызыл хәтфә түбәтәй.
Каһарман кантон котатский,
Булмасаң штатский...
Шәһидәсе йөрер иде,—
Фатыймасы пүнәтәй...

18. ӘЛМИ КАНТОН

Үсергәндә тугызынчы кантонлыкта Әлмөхәммәт кантон булган. Аның атасы Таһир, аның атасы мәшһүр Бурангол француз сугышына кереп, башкорт гаскәренә хөллә алган кеше. Әлмөхәммәт Казан университетының восточный факультетын тәмам итеп, алтын медаль алып чыккан кеше. Шуңа халык бик матур көй чыгарган.

Аның җыры:

Ялан гына җирдә ялгыз тирәк,
Яфраклары аның бик сирәк.
Егерме лә икедә кантон булган
Әлмөхәммәт кебек бик сирәк.

19. КАРА КАЛФАК КӨЕ

Чуркак авылында Гатаулла исемле бер хәзрәт булган. Ул хаҗга китәр алдыннан, бер курайчы чакыртып, бер көй уйнарга кушкан. Курайчы үзеннән чыгарып көй уйнаган. Шул көйгә «Кара калфак» дип исем кушканнар. Бу көйне «Су өсте көе» дип тә йөртәләр.

20. ДӘЛӘКӘ БАТЫР КӨЕ

Борын заманда Дәләкә дигән бер батыр булган. Ул зур бәлаләргә очрап Себергә киткән. Ул Себердә 25 ел

торганнан соң качып өенә кайткан. Авылы бер биек тауның өстендә булган. Ул нәкъ сәхәр вакытында тау өстенә менеп курай уйный башлаган. Авылның киленнәре, курай тавышын ишетеп, кымыз эчеп утырган картларга кереп белдергәннәр. Картлар чыгып тыңлагач: «Бу курай Дәләкә батыр кураена охшый»,— дип әйтешкәннәр. Барып карасалар, Дәләкә шыр ялангач көенә: «Киемле киттем, ялангач кайттым...» — дип җырлап утыра. Шуннан картлар аңа киемнәр алып чыгып, киендереп алып кергәннәр. Шул вакытта аның тау башында уйнаган көен «Дәләкә батыр көе» дип йөртәләр.

21. ЕЛАН ЙӘРКӘЙ

Урташ дигән җирдә казакълар белән сугышып яткан бер батыр исеменә чыккан.

ХАТЛАР, КОТЛАУЛАР

1911

Ш. БАБИЧНЫҢ КАЗАКЪ ДАЛАЛАРЫННАН ТУГАННАРЫНА ЯЗГАН ХАТЫ

(өзек)

...Казакъ теленә баргач та өйрәнеп алдым. Мин аларның укытучыларын да укытам. Казакъча шигырьләр язам, җырлыйм, тамашалар корам. Казакълар авызларын ачып, шаккатып, эчләрен тырный-тырный тыңлыйлар.

...Авылны, сезне бик сагынып кайтыр идем. Казакъларым «Китмә гуй, җибәрмибез сине гуй»,— дип җибәрмиләр, үзем дә аларга бик нязәштем. Ташлап китсәм — бик жәл калалар. Алай да, Уфага яки Оренбурга кайтуны күздә тотам. Сезне күрәсе, үз һавамны иснисе килә!..

1913

ЯШӘ, НӘКЫЙ!

Мин сине тәбрик итәм шигъриң беләң,
Әхмәт Нәкый.
Бик шат улдым, мәмнүн улдым мин сиңа,
рәхмәт, Нәкый!
Мин өметлемен сиңа, истикъбалең парлак
синең;
Һәм булачак (инша алла) мәртәбәң «чарлак»
синең!

Ихтирам илә кардәшеңез ***Ш. Бабичев.***

Мәмнүн — разый, шат.
Истикъбаль — киләчәк.
Парлак — ачык, акты.

1916

Ш. БАБИЧНЫҢ ВӘЛИ ХАНГИЛЬДИНГА ЯЗГАН ХАТЫ

(1916 ел, октябрь)

(өзек)

...Мин синең классларны — өченче, дүртенчеләрне, Галәү исә, елдагыча, беренче, икенчеләрне укытабыз. Аның беренче класс балалары каргалар кебек «а, ба, та, у, ду...» дип, көн буе такылдап утыралар. Минем эшләрем зуррак. «Әфтияк» белән «Коръән»нән башлап киттек без. М. Гафуриның «Милли шигырьләр»ен җырлатам малайлардан. «Уян, атам, атам, уян, уяныргa вакыт җитте»,— дип, бөтен өйне яңгыраталар алар.

Ләкин арада бик тәрбиясез малайлар да бар икән. Син шуларга ничек чыдап торгансың. Берничә көннән үк чыдар хәлем калмады. Нишләтергә инде аларны? Бүтән балаларны да аздыралар бит ул каһәрләр!..

1916

Ш. БАБИЧНЫҢ ВӘЛИ ХАНГИЛЬДИНГА ЯЗГАН ХАТЫ

(1916 ел, ноябрь)

(өзек)

...Монда каңгырып йөргән мөгаллимнәр таралып бетте, ләкин мөгаллим сораган игъланнарның, мөгаллим эзләп килгән җәдит муллаларның исәбе-хисабы юк. Мине дә көн саен кодалыйлар, котырталар: «Ташла шул чүплек чокырын, бер айга 60 сум түлибез»,— ди берсе, икенчесе: «80 сумга хәтле бирергә мөмкин»,— ди. Алматага айга йөз сум белән мөгаллим сорыйлар. Өйгә дә киләләр, хатлар да язалар. Уфада миннән башка читкә китәргә теләүче юк. «Анда барсаң да Шомбай, монда килсәң дә бер Шомбай»,— дип йөрим әле... Менә бүген тагын Ырынбурдан, «Кармак» мөхәррире Мәрҗанидән хат алдым. Ул аена 50 сум белән үзенең редакциясенә чакыра. Бусы минем күптән эзләгәнем инде...

...Сез монда усал малайларга ничек еллар буе түзеп тордыгыз? Түзәмемне озакка суза алмадым. Беренче атнада юаш мәче булдым, икенче атнада сырт җөннәрем кабарды, мыекларым сөрпәйде, өченче атнада инде мин гыйфриткә әйләндем. Бер-ике малайны элек класстан сөрдем, менә инде бүген мин аларны мәктәптән үк чыгарып җибәрдем. Килмәсәләр генә ярар иде дип торам...

Юк, болар белән эшләп булмас, боларны берәрсенә аударып, озакламый шул Ырынбурга китәрмен шикелле...

Хуш, Вәли. Инде Ырынбурдан хат көт!

1917

Ш. БАБИЧНЫҢ СӘЙФИ КУДАШКА ЯЗГАН ШИГЪРИ ХАТЫ

(14 сентябрь, 1917)

Бәйрәмеңне шартлатып котлыйм, туган,
Сине чакырырга бүген тозлыйм суган;
Килде бәйрәм, эч тә әйрән тышка чык,
Әй якын дустым, куан, эттән туган!

1917

Ш. БАБИЧНЫҢ СӘЙФИ КУДАШКА ЯЗГАН ХАТЫ

(24 февраль, 1917 ел)

Кылычбай!

Сиңа әлегә бу хатны почтадан гына язып җибәрәм. Мин дә, син әйткәндәй, дөбердәтәм бит, әй!

«Уфа хәлләре»нә каршы «Кармак» аркылы җавап көтәсеңме? Әгәр алай дисәң, туры килми бит. Чөнки ул хатында минем титул әйтелмәгән. Әгәр дә ачык рәвештә «Шөбшә»гә икәне мәгълүм булса, җавап язылыр иде. Инде теге хатыңны да шулай гына басып чыргарыр микән, ләгънәт!

Мин дә «Уфа хәлләренең мөндәриҗәсе» исеме белән кыска гына мәкалә җибәргән идем. Син җибәргән нәрсә шуның тәфсиле-аңлатмасы һәм мәгънәсе булса, бик шәп булыр иде. Әйе, Г. Ибраһимовтан аерылгансыз икән. Миңа бит Галимҗаннан хат бар иде. Сезнең хәлләрегезне үзегездән дә шәбрәк белеп торам бит мин. Син үзеңә эшкә керергә урын дисеңме? Урын сиңа сколько угодно! Тик русча гына бел! Иллә мәгәр казакъ даласы ялтырап ята, рәхим ит!

Уфадан миңа канатлы, мөгезле һәм гаҗәеп мәгълухат рәвешле бер мандолина килде.

Ябык хатың көтеп, «кылыч» йөзеңнең кайралуын теләп, дусың

«Шөбшә».

1917

Ш. БАБИЧНЫҢ СӘЙФИ КУДАШКА ЯЗГАН ХАТЫ

(13 март, 1917 ел)

Кудаш!

Бигайбә, иптәш. Ни хәлләр бар? Валлаһи алла хакына, бер тиенлек тә баш эшләми! Исердем, исерек мин. Мәңге исерек! Әлмисактан ук берне төшереп килгән исерек мин. Исерек булмаганда да исерерсең, небось! Үзең әйткәндәй, яз житә, терелер вакыт житә, исертер, небось!..

Яз житмәгәндә дә исерерсең. Уенмыни сиңа, Распутиннар кулыннан ычкынган мәмләкәтнең бер баласы, бер диванасы, хөррият сөйгән, азатлык теләгән мескен кошның читлектәге бер баласы бул да сиңа, исермә! Исерерсең, небось!.. Мин исерек хәзер, бигайбә, мәгъзур!..

Уфада булган вакыйгаларны бик нык борычлап, озын иттереп бәян кыл әле. Мөфтинең кирәгән бирдегезме? Шәп булган, яшәсен! Урра! Хөррият урра!..

Бик мөһим бер үтенеч: үзең «Галия»дән киткән вакытта минем назыйр бүлмәсендәге яшел сандыкны кираәтханәгә мендереп, бер почмакка яшереп куй әле, ярармы, иптәш? Без монда «Хөр милләт» дигән бер газета чыгарабыз. Беренче санында минем бер шигырем басылачак. Китер кулыңны, китер хөр калган кулыңны!

«Шөбшә».

Бигайбә — гаепләмә, гафу ит.
Әлмисак — яралу, яратылу.
Мәгъзур — гозерле, гозер иясе.
Кираәтханә — уку залы.

1917

Ш. БАБИЧНЫҢ СӘРВӘР ӘДҺӘМОВАГА ЯЗГАН ХАТЫ

(29 июль, 1917 ел)

Сәрвәр!

Сиңа хәзер, тәәссеф, үзең кебек матур, үзем кебек озын итеп, әниең сүзләре кебек татлы итеп, сеңлең кебек сөекле итеп хат яза алмыйм. Хәзергә бу кадәресен гафу ит!

Ләкин моңа кадәр озын итеп язалмый торуымны гафу итмәсәң, хакың бар. Көттем мин буш вакыт, ләкин барып чыкмады. Тәмле-тәмле итеп язарга дип, ике-өч мәртәбә утырдым. Барып чыкмады: иптәшләр килеп керделәр дә алып чыгып киттеләр. Ике хат башланган көе калдылар. Берсен, әбәү мәхәббәтсез, бигрәк әчеләндереп-төчеләндереп яза башлаган булган идем, бигрәк. Имеш, синең назлы, саф, тылсымлы күңелеңә, имеш, үземнең дәртле, нишанлы күңелемнең мәгъсумият бакчасында җитешкән чәчәгеннән иң кызылын, иң иялесен, иң нәфисен алып кадарга телим... имеш, әллә нәрсәләр. Менә хатымның берсен шулайрак башлаган идем... Инде эш килеп терәлгәч кенә сиздем.

Уфада вакытта юньле-башлы бер хат та язып булмый ахрысы, дип, йә, ни булса ул булыр, гаеп итмәссең әле, нәрсә, син бит тәхәллефсез кыз, син бит Азия кызы!.. Безнең бу якта гына ул кырык төрлегә төрләнеп, шомланып бетәләр.

Менә нәрсә, туган, миңа бик кинәт кенә китәргә туры килде. Бер дә сизмәстән китәм:

— Әти вафат!!

Юк, юк, юри генә әйтәм. Әти дә, аллага шөкер, исән, үзем дә сау, дөньям тыныч. Менә нәрсә: мине «Кармак»ка чакыралар иде. Мин: «Айга ике йөз бирсәгез, барырмын»,— дип язган идем. Шул язуга җавап килде: җавап белән бергә «Кармак»ның иптәш нашире З. Дәминов ди-

---

Тәәссеф — кайгыга төшү: бу очракта «кызганыч» мәгънәсендә.
Нишан — вәгъдә билгесе.
Мәгъсумият — гөнаһсызлык, сафлык.
Тәхәллеф — буйсынмаучан, кире.

гән егет тә килде: «Хәзергә ике йөзне «Кармак» күтәрә алмый, 150 не бирәмез,— ди.— Әйдә, риза булсаң,— ди.— Хәзер мин Нижный(га), Мәскәү(гә) барам,— ди. Әйдә бергә»,— ди. Мин күп уйламадым, риза булдым. Менә иртәгә, алла боерса, китәм. Сөекле Уфамнан китәм. Дәминов белән бергә үк китәремне уйламаган да идем, аның белән бергә китәргә кичә (28 июль) театрда гына карар бирдем.

Шулай көндез 22 кеше (11 е туташ) Дим буенда йөреп кайттык. Кич театрга бардык. Күңел хәдтән тыш шат. Шунда китәргә карар бирдем. Бер генә кешегә әйткән идем китәремне...

Менә бер заман шул хәбәр, яшен суккан кеби, театр эчен алган: тегесе дә килә, монысы да: «Китәсенмени? Китәсең дип ишеттем!.. Китмә! Уфаңны ничек ташлыйсың?.. Бик зур «успех»лар казанган идең, фәлән идең... Ник китәсең ташлап!..» Колаклар тонып бетте инде менә... Шунда үземә дә Уфа халкы кызганыч вә сөйкемле тоелды. Һәммәсе мине ихтирам итә кебек.

Шунда, почта уенында, Уфаның иң алдынгы, һәр җәһәттән иң өстен торган бер туташка (шәфкать сеңлесе булып хезмәт итә) көйле бер нәрсә яздым. Китүем мөнәсәбәте булганлыктан, син гаеп итмәссең, дип, күңелеңә таянып, шуны монда күчерәм. Мин аның черновасын алып калган идем.

Менә ул:

Мин китәр чакта гына сөйкемле күренә һәммә шәй,
Барчасы шат, барсы якты, барсы нурлы мисле ай!

Сез миңа бигрәк тә нур, бигрәк тә яктырган кебек,
Бер карашың Исрафил илһам суры өргән кебек.

Бер танышта сезне мин куйдым күңелнең өстенә,
Бер танышта сезне охшаттым кадерле дустыма!

Бер танышта сезгә багланды күңелдән хөрмәтем,
Охшады кальбең, сүзең һәм нурга чумган килбәтең!

Бу риясыз бер генә хат-сүзләремне ит гафу,
Китсә кәйфең, янда йөртмә, ташла утка, ит мәхү!

Уфада көннәрем гаять кызык, күңелле узды. Шуннан артык ни дим инде. Хәерле булсын, китәм инде, ахрысы.

Хәдтән тыш — чиктән тыш.
Шәй — әйбер, предмет.
Илһам суры — илһам быргысы.
Рия — икейөзлелек.
Мәхү — югалу, юкка чыгу.

Юкса Уфада яхшы гына урыннар бар иде. Мәсәлән, иң яхшысы, «Дәрелмөгаллимәт»кә татар теле мөгаллименә үтенгәннәр иде. «Вазифа» да бик яхшы иде. *Мәсләк*, максат хакына барысы да *фида*...

Мәсләгем хакы өчен «Уфа»мны корбан әйләрем! Әлмөхәммәдов та безнең илә бергә юл чыга. Оренбурга баргач та хат язармын. Ләкин син дә хат язу тугрысына минем кебек сарансың бугай, шулаймы?

Хәзергә хуш, Сәрвәр! Догада, Сәрвәр!

Хуш!

Кулыңны кысып, сәлам вә ихтирам белән,

Ш. Бабич.

Мәсләк — тоткан юл.
Фида — корбан.

1918

Ш. БАБИЧНЫҢ ТӨХФӘТ ЧЕНӘКӘЙГӘ ЯЗГАН ШИГЪРИ ХАТЫ

(январь, 1918 ел)

Т. Ченәкәйгә!

Бу хатымны тотып ал,
Бик аулакта укып сал.
Дус-ишләргә сөйләргә
Сүзләремне отып кал.

Хатны язам ерактан,
Алтын таулы Баймактан.
Кәгазьләрем — ак мәйдан,
Карасы — сөт-каймактан.

Мин исән-сау, сәламәт,
Сораганга сәлам әйт.
Сәясәттән сорасаң,
Эшләр харап, галәмәт.
Ару булыр иде — «З»не
Эш башыннан кусалар,
Башкортостан туфрагын
Мунчалалап юсалар!

Җибәрәм бер мәкалә,
Гаҗәп яңа, мә, кара.
Үзең укып карагач,
Җибәр Мәхмүткә таба.
Ул бастырсын «Кармак»ка,
Ташламасын аръякка;
Гонорарын үзең ал,
Ярар «кәгазь-бармак»ка.

Ченәкәем, белеп тор,
Мин хәзергә Баймакта.
Алла белсен, аннан соң
Юнәлербез кай якка.

Бу хатымны уйладым
Почтага да салмаска.
Чолгавыңа кыстыр, дип,
Тоттырдым бер солдатка.

Сүзләремнең серләрен
Яшереп куй келәткә.
Сак була күр, сердәшем,—
Аңа-моңа эләкмә.
Укып күргәч, төшенгәч,
Ерткала да утка як,
Дошман сизә күрмәсен —
Бәласеннән башаяк.
Аерылышканда бирешкән.
Зур вәгъдәне онытма;
Бабич ташлап китте, дип,
Кайнар күңлең суытма.
Белеп булмый дөньяны,
Син дә белмисең аны.
Бүгенгә бар — иртән юк,
Шуны онытма тагы!
Миннән элек син үлсәң,
Үлеп җиргә күмелсәң,
Кабердән хат язарсың,—
Әгәр мине дус күрсәң.
Мин үлсәм дә, кабергә
Каләм алып барырмын;

Кәфенемә хат язып,
Сезгә, дуслар, салырмын.
Фәрештәләр муйнына
Шул кәфенне чорнармын,
Ченәкәйгә алып кит, дип,
Аякларны болгармын.
Фәрештәләр аркылы
Хатлар салып торырсың,
Җирдә ниләр булганын
Миңа язып торырсың.

Тагын калган бер сүзем,
Авыр алма, аппагым,
Ул сүземне иң соннан
Язарга дип сакладым.
Шигырь саткан акчаңны
Зур банкага салдыңмы (!)

Теге сөйгән кызыңны
Кәләш итеп алдыңмы?
Бер кыз димлә миңа да,
Мин димләрмен сиңа да.
Рәхәтләнеп яшәрбез
Дүртебез бер ояда...
Ярый инде, бигайбә,
Юк сүзләрне бар кылдык.
Вакыт бик тар булганга,
Сүзне мохтасар кылдык.
Тап-татарча хат яздым.
Такыр башлы татарга.
Гарәпчә сүз кыстырып,
Нигә телне ватарга?

Бу юлларны язучы
Үзең белгән Бабичтыр.
Ябышмаган җирләрен
Үзең иплэп ябыштыр.

Мохтасар кылу — кыскарту.

1917

Ш. БАБИЧ — Т. ЧЕНӘКӘЙ ӘЙТЕШҮЛӘРЕ (1)

Ш. Бабич:

Самавырың сары икән,
Мөрьяләре тар икән.
Ченәкәй белән күрешеп,
Сөйләшер көн бар икән.

Т. Ченәкәй:

Мандолиның зур икән,
Грифләре туры икән,
Шигырьләрең матур икән,
Мәгънәләре мул икән.

Ш. Бабич:

Матур икән бүлмәгез,
Кайгы-хәсрәт күрмәгез.
Икегез дә күп яшәгез,—
Гомер бетми үлмәгез!

Т. Ченәкәй:

Мандолиның гөлле икән,
Җырларың мең төрле икән;
Тукай шигырьләре сыман,
Әйткән сүзең серле икән.

Ш. Бабич:

Чәйләрегез тәмле икән,
Сүзләрегез баллы икән,
Сезнең белән «балык тоту»
«Кармак»сыз да ямьле икән.

Т. Ченәкәй:

. . . .

Ш. Бабич:

Самавырың җиз икән,
Кайнаулары тиз икән.
Оренбурның былбылы —
Синең белән без икән...

1917

Ш. БАБИЧ — Т. ЧЕНӘКӘЙ ӘЙТЕШҮЛӘРЕ (2)

Ш. Бабич:

Ченәкәй, синнән сораем,
Сораем, аптыраем:
Инде сезнең Оренбурны
Кай җирдән каптыраем?

Т. Ченәкәй:

Балагыннан да каптыр,
Аягыннан да каптыр,
Колагыннан да каптыр,
Тамагыннан да каптыр!

Ш. Бабич:

Оренбурда кемнәр бар?
Нинди шайтан-җеннәр бар?
Ярып дару сала торган
Нинди яман чирләр бар?

Т. Ченәкәй:

Монда симез байлар бар,
Тәреләр һәм айлар бар.
Койрыкларын күтәреп,
Ыргып чапкан тайлар бар!
Бик күп юан корсаклар,
Оятсызлар, курчаклар;
Алдакчылар исәпсез,
Сибеп йөри борчаклар...

Ш. Бабич:

Борчакларын алырбыз,
Исемнәрем язырбыз;
Кайда кызык күмелгән,—
Һәммәсен дә казырбыз!
Үзләренең борчагын
Күзләренә аттырып,
Симезләрен байларның
Корсагыннан каптырып,
Асып куйыйк «Кармак»ка,
Күрсәтик без халыкка.

Уфа-Казан таң калсын
Без каптырган балыкка!

Т. Ченәкәй:

Монда бик күп муллалар,
(Егермеләп мулла бар),
Дүрт-биш җирдә мәчет бар.
Монда чыга чалмалы
«Дин мәгыйшәт» журналы,—
Шунда кабар «Кармак»ка
Балыкларның зурлары.

Ш. Бабич:

Иртәгә без, Ченәкәй,
Кармакларны алаек;
Алаек та икәүләп
«Дин-мишәйт»кә бараек;
Бараек та «Кармак»ны
Чәлләә башка салаек;
Эләгә калса симезе,—
Күрсәтергә алаек!..

1917

Т. ЧЕНӘКӘЙ — Ш. БАБИЧ ӘЙТЕШҮЛӘРЕ (3)

Т. Ченәкәй:

Насыйп булды Бабич белән танышырга,
Танышырга, күп фикерләр алышырга.
Инде миңа, Ченәкәйгә, яхшы булды,
Бергәләшеп көлке-мөлке язышырга.

Ш. Бабич:

Оренбурга мин үземне алып килдем,
Кесәләргә «Кармак» җебе салып килдем.
Яруллаңы, Җамал, Камал, Мәрҗанине,
Дәрдмәндне, Ченәкәйне сагнып килдем.

Каләмнәрнең үткенлеген арттырырбыз,
Дошманнарны «Кармак»ка без
каптырырбыз
Җаһиллекне, явызлыкны җинеп чыксак,
Байлардан да болай булып, шәп торырбыз!

Җаһиллек — наданлык.

1917

М. БӨДӘЙЛИ — Ш. БАБИЧ ӘЙТЕШҮЛӘРЕ

М. Бөдәйли:

Бабич, син күп көләсең гөлдер-гөлдер,
Синең күк шаяннар бик күп түгелдер,
«Матбугат клоуны»,— дип дан алдың,—
Тик торма, әйдә инде, барсын көлдер!..

Ш. Бабич:

«Җигәвен» дус, көчәнмә,
Угың юк бит чагарга;
«Быз»лавыңнан бозау гына
Куркып тотына чабарга.

КӨНДӘЛЕК ЯЗМАЛАР

1913

СЕБЕР САХРАСЫНДА КАЗАКЪТА УЗДЫРГАН КӨННӘРЕМ

*

Дәресләремне мәтълагъ кылып вә башка әллә нинди эшләр беләп мәшгуль үткәрмәкче булган 4 аем ялт итеп кенә калды. Мин «кап!» дип авыз ачтым да калдым. Теге исәпләр коп-коры «хыялый мөрәккәб» булды да калды...

*

Инде кайтырга күп калмады. Гәрчә муллалык мөддәтем покрау башына кадәр булса-да, мин теләгәнчә булса, сентябрьнең 20 сеннән калмый китәм, алла кушса. «Галия»дә 15 сентябрьдә имтихан, 22 сендә дәресләр башланачак. Шуңар күрә ашыгам. Үз теләгемчә булса, кайтырга 16 көн, таң атса 15 көн, ягъни ярты гына ай калды инде...

*

Унбиш көннән соң тагын көннәр туар. Әмма Дүсәнбай авылында мин булмам. Казакълар, муллабыз фәлән иде, төгән иде, дип сөйләшеп утырырлар, әмма 15 көннән соң мин булмам. Газеталар атна саен килеп торыр, ләкин төгәл укучы булмас, чөнки ул чакта мин булмам...

*

Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер. Бу сентябрь аенда мин дә һичкемнән ким булмасмын. Алла теләсә, бөтен хәер-садакалары белән 30 сум жалованьены мин дә кесәгә бөкләп салырмын...

Мәтълагъ — башлау.
Хыялый мөрәккәб — хыялый кушма.
Мөддәт — срок.

*

Көн салкын. Болытлы көзге җил. Бүген Нурмөхәммәт өенә кунак килеп төшкән мөнәсәбәт илә, көндез бер җирдә, кич өч җирдә мал суелды. Бер генә өйгә килгән кунакларның әллә ничә өйгә кисере тиде. Син теләгәндә бер җапрак ит таба алмыйсың, ә теләмәгәндә өсте-өстенә ит пешерелә. Гаҗәп бу тормыш!

*

Сентябрьнең өче. Көн җылы, ямьле. Җылы булганга, Хәмзә өенә кыдырып бардым. Хәмзә: «Безнең мулла, көннең күзе ачылса, кырмыскача тора килә, көннең күзен болыт алса күнҗүкәнең көпесен ябынып җатып ала»,— диде. Җамалның кызына исем куйдым. Аты — Кәләнфер. Хаҗи Чобар биягә барып килде. Газеталар һаман килмәгән булса кирәк.

*

ҖЫРЧЫНЫ КӨТКӘНДӘ

Трирра-рар-рири-рара-рири,
Тизрәк җырчы килсә ярар иде;
Җырчының җырлаганын тыңлап торсам,
Күңелдә кайгы-хәсрәт тарар иде,
Кайгыга аралашып кайнар яшем,
Мөлдерәп ике күздән агар иде.
Мөмкинме кызык җырга кызыкмаска,
Моңланып, моңлы көйгә боекмаска?
Таш колак, үлгән йөрәк, тунган башлар
Моңлыга моңаймас та, боекмас та:
Адәмне төрле хәлгә салган җырлар
Наданны кыздырмас та, суытмас та.

*

КҮҢЕЛСЕЗ ЧАКТА ҖЫРЛАНГАН

Юкка чыккан, юкка икмәкләрне черткән бәндә мин,
Бер зәгыйфь, көчсез, һөнәрсез буйга беткән бәндә мин.
Чәчкә төсле күкрәп үскән иң кадерле чакларым,
Бер дә юкка алданып, тик исраф иткән бәндә мин.

*

Гомерне бушка уздырмас өчен йорт эшләре белән шөгыльләнер идем, ана да иренәм. Юк, иренмим, эшлим дисәм дә эшли алмыйм. Эшкә кулым җитешми...

*

Авылда минем иптәшләрем җәй буе эшләп чыгалар. Чөнки аларның аталары эшче,— эшләтәләр, эшсез яткырмыйлар. Ә минем әти исә мулла, минс иркәләп кенә үстергән, бәләкәйдән эшләтеп өйрәтмәгән, шул сәбәптән, эшкә сәләхиятем юк. Инде этинең исенә төшкән төшүен. Бәгъзе вакыт мина, әнә үзең кебек Нәҗметдин вә Сәйфетдиннәр умырып эшлиләр, син дә тик ятма инде, фәлән, дип караса да, минем колакка керми, бәләкәйдән эшкә сондырмагач!

Сабан туенда чыксам, халык мине күрсәтеп, әнә мулла улы мәхдүмне чыгар, эшсез генә ашап яткан кеше көчледер ул, ди, һәм мине мәйдан уртасына сөйрәп чыгаралар. Шунда мине замандаш Нәҗмиләр күкрәккә күтәреп, селкеп кенә сала. Беләсезме, бу нилектән килә?

Әлбәттә, билгеле, Нәҗмиләр алар яшьтән эшләп, кыймылдап үскәннәр. Шуңар күрә алар көчле, алар нык. Мин, бичара, эшсез үсү сәбәпле, көчем бик аз. Тәнем дә зәгыйфь. Сыгылып, бөгелеп кенә торам. Ялгыз мин генә түгел, бик күп мәхдүмнәр көчле һәм эшлекле булудан мәхрүмнәр... Бер философ, нигә мине дөньяга чыгарырга сәбәпче булдың, дип атасына үпкә тоткан бугай. Шуңарга охшап, этигә мин дә әйтәм: «Нигә мине эшсез үстердең»?

Әйтче зинһар, мәкалә тозсыз, төзелеше майсыз булса да, рухы бөек түгелме?

БОЛГАНЧЫК ТӨШЛӘР

Әллә нинди кылдый-былдый «болганчык төшләр» күрдем. Бер вакытны Мәдинәдә, бер вакытны Галиядә, бер вакытны Хакимиядә, дәхи бер вакытны Сәрвәр мәзиннең өй эчендә булдым. Мәдинә шәһәре кыр астында. Якынлашкан саен күренә бара. Шәһәр янынная гына диңгез ага, гаять дәһшәтле. Балыклар чиртккән тавыш колак тондыра. Әллә нинди манзара. Аяк астыбыздагы җирләр тишек-тишек. Шул тишекләрдән аккан су күренә. Бер басмадан сыгылып-сыгылып чыкканда Сәйфетдин Гыйльметдиновка очрап күрештем (Сәйфетдин — иске шәригем). Сәйфетдин: «Мәдинә мәдрәсәсенә кыйраәт өйрәнергә килдем»,— диде.

Галиягә яңа кергән көзем иде, мәдрәсә акчасын түләмәгән идем. Шәкертләр ашарга төшкәндә мин сөрәеп кала бирәм. Бабайның звонок шалтыратуы кадимгедәй. Бервакыт Зәйни бөтен шәкертләрне бер бүлмәгә җыйнап укы-

---

Кыйраәт — уку.

тырга яште. Минем шәрикләрне бер-бер җиргә бастырып куйды. Мин бер җиргә аяк бөкләп утырдым да «Ашказар» көен сыздыра башладым. Бәй шунда ук Зәйни җырларга кереште. Шәкертләр көлә.

Мәдрәсәи Хәкимиягә барып керсәм, мәдрәсәнең эче ниһаясез бушлык фәза, аяк асты ташлы ком икән, димен. Йөз меңләп шәкерт бар. Һәммәсе дә гаскәр кеби гүләйт итеп йөриләр. Йөрүләре гаять шәп, гаять дәртле. Бу шәкертләр эчендә «Галия»дән чыккан шәкертләр дә бар. Кайберсе минем белән күрешә. Мәдрәсәне бер паровой машина ыжгырып әйләнеп тора. Шәкертләрнең армый-талмый йөрүенә шушы хезмәт итә икән, димәк. Тора-бара мәдрәсе дигәнем комлы сахра, таулык-ташлык арасы булып чыкты. Диңгез кеби шәкертләр сәер итеп таулар арасына китеп, күздән гаиб булдылар...

*

КҮҢЕЛЛЕ ЧАКЛАРДА ҖЫРЛАНГАН

Пакь туып, хак дип белеп, пакьлектә үскән бәндә мин;
Бәндәләргә «бәндә» булганнар эчендә алла мин;
Саф иман тапланмаса, тәкъдир аяктан чалмаса,
Нурлы йолдыздан да нурлы ялтырармын алда мин.

*

Ни булды икән минем каләмгә? Былтыр яз ике-өч дәфтәр язган каләмем бу ел яз ике-өч сәрләүхәдән артык яза алмады. Әллә үләң язу дәрте елдан-ел сүрелә бара инде.

*

Сентябрьгә каршы Мортаза мулладан төне буе мәкальләр әйттердем. Әйткән мәкальләрнең мәҗмугы 79 булып, шуларны монда күчереп язам.

«Беләкде берне җыгады, белдекде — меңне җыгады»...

Бездә булсын, казакъта булсын, Коръән сүзе кебек мәкальләр бар. Ләкин шул мәкальләр коры телдә генә йөри, мәгаттәэсеф, әле тәмам илә гамәлгә куелмый тора.

Фәза — ачык урын, ачыклык.
Сәрләүхә — мәкалә, мигырь исеме.
Мәгаттәэссеф — үкенечкә каршы.

*

«Алтау ала булса — авыздан китәде, туртәү төгәл булса — түбәдәге киләде». Күр нинди фәсәхәтле мәкаль! Бел иттифакка өнди «вәгътәсәму бәххәбел аллаһә илла йә» урынына әйтерлек бар.

*

«Теләнченең сөяр ашын кем бирде?» Әлбәттә, бирмәс. Бәс, димәк, бай булырга кирәк.

«Җегетдекде үлем бирмә, карилекде җотык бирмә». Ягъни, үлем хәвефе бар вакытта да, юк вакытта да Әнвәрбәкдәй бул, ди. Ярлылык сәбәпле картайма, байлык белән картай — «Мәхмүт бай» дай бул, ди.

«Алтбыс карсак ат булбайды». Ягъни, аз файда китерә торган кәсепкә тотынма, ди. Уйлап карасаң — иң файдасыз, иң кирәксез кәсеп безнең татарлар кулында. Мәсәлән, кырык тартмачылар, күнчеләр, сөяк вә чүпрәкчеләр бары да бездә.

*

«Үзең белмә, белгәннең телен алма...» Бу — борынгыларның каргышы булган. Димәк, гаять нәзакәтле вә шуның белән бәрабәр гаять ачы каргыш. Әмма казакъның хәзергә каргышлары нәзакәтсез ва бигаять тозсыздыр. Мәсәлән, хәзергә каргышлары ошбулардыр: «Ходайның мылтыгы тигер! Күк чәчәк килгер! Қорып калгыр! Қара сан килгер! Күк ала килсен! Мулла бул! Битең телгер. Битәгән чыккыр! Биш ай туарылып җат! Ходай атсын! Ике әрвах бер Қоръән орсын! Әлх...» Бездә дә бар: «Қаһәр суккан, ләгънәт төшкере» кебекләр...

*

Землянкага барып, анда торган чакларымны хәтерләп йөрдем. Алла сакласын, борчалар, чикерткәләр кеби, сикергәләп йөриләр иде. Тышка чыксам, итекләремә сырлан кебек ябышкан. Шаккатып, сыпырып ташладым. Җирдә яткан бер кәгазьне алып карасам, югарыдагы бер мәкаль язылган. Тәтәй тапкан бала кебек, куанып кайттым да язып куйдым.

Иттифак — бер сүздә булу, союз.

*

Хажи бу көннәрдә Орунбургтан «Кырык мисал»ны алдырып, соңрак Кызылъярдан «Ибраһим Кунанбай үләндәре»н алдырды. Мин әүвәл «Кырык мисал»ны яратып укыдыгыми кеби, Байторсынга Кунанбайдан артык мәхәббәт вә ихлас бәйләгән идем, ләкин соңга таба Кунанбайның үләңендә фәсәхәт вә ләззәт табып, Кунабайны татарның Тукае, гарәпнең Имрәл-кайсе дәрәҗәсенә мендердем. Әүвәл башта Кунанбаев үләңдәрен тәкъдир итә алмавым — китапның имлясы бозыклыктан вә үземнең төшенеп укый алмаганлыгымнан булган икән...

*

Борыным сәламәт, тыңкыш (пычрак түгел. Минем борынны казакълар «кайкы морын» диләр. Чөнки, уртасы чәнчелебрәк тора: бервакыт Хәмзә белән чабаклы барганда, Хәмзә миңа «Атың кем?» — диде. Мин аңа әйттем:

«Сорсаң, минем атым — «Шәех» мулла,
Уртасыддәл морнымның кайкы мулла,
Өстемдә бер чапан бар, ул да жока,
Җөрмәем очып китеп җарты җулда,—

дидем...

*

Ирекнән кеше ни кылмый дисең!..Язарга сүз таба алмый аптырап торганчы үземне-үзем тикшереп үтү кирәк. Әйдә, язулардан бер язу булыр. Тикшергәндә башымнан башлап аяк очыма чикле бурып чыгарга уйладым...

Китаптан күрепмедер, кешедән ишетепмедер, ни булса да, абый әйтә торган иде: «Башы артка чыккан кеше артык гакыллы, сабырлы була; башы алга чыкса, артык зирәк вә хәссас була һәм дә очлайган башлы кеше артык хыяллланучан вә уйга батучан була»,— ди торган иде. Мин үз башыма карап, шушы сүзнең чынлыгына ышанган идем. Чөнки минем баш никадәр очлы булган кеби, уемның да очы-кырые юк. Башыма бер курка төшеп уйланган вакытта, яхут нәрсәдән тәэсирләнеп, хыял дөньясына чумган вакытта дөньямны онытам. Күз алдым томалана, саңгырау кеше кеби, сүзне ишетмим...

Хәссас — сизгер.

Кутыр, таз, пеләш кеби нәрсәләрдән, ходайга шөкер, башым сәламәт. Әмма авырган вакытымда күбрәк авыруым башымда була. Бәләкәй чакта баш авыру мине ничә мәртәбә түшәккә еккан иде. Бу яз башым ике мәртәбә авырды. Ләкин заһири сәбәпләре бар иде: эссе сугу, йокы калу. Кайвакытта бер сәбәпсез-нисез авырта. Моны мин нервныйлык галәмәте дип беләм. Валлаһи әгъләм биссауап...

Минем маңгай бик киң дә, бик тар да түгел. Уртача. Бездә халык: «Маңгае тарның холкы тар була»,— ди. Моңа караганда, минем холкым уртача дияргә ярый. Әмма холкымның уртачамы-түгелме — тәгаен әйтә белмәдегем кеби, теге халык сүзен дә чын дия ышана алмыйм. Минем холкым бик бозылырга да, бик төзәлергә дә мөмкин. Бу мәсьәләне бер аллага тапшырдым. Маңгаем сәламәт...

Телем зур, җалпак, кәефе килгәндә сөйләргә иренми торган тел. Исәрләнеп, кеше көлдерергә дә кулыннан килә торган тел. Минем тел әүвәл гаять тупас вә нәзакәтсез иде. Соңга таба дөньяны күрә килә әзрәк шомарырга, төзәлергә бит алды. Хәйлә, мәкер, тәдбирне аз-азлап белә башлады...

Ике яктагы азау тешләрем, алла күрсәтмәсен, пычрак баз шикелле. Каты нәрсәләрне чәйни алмыйм. Яшьтән шикәр ашап үскәч, шулай булмый хәл юк шул...

Җилкәсе чокыр кеше ялкау була, диләр иде. Бу сүз ялганнардан булган бер ялган. Хәлбуки җилкәм тип-тигез булса да, мин ялкаулардан булган бер ялкау. Җилкәм киң түгел, тар, озын.

Әлхәмделилла, ике күзем дә бар, сәламәт. Әмма җилгә каршы күздән яшь килә һәм ерактан артык күрә алмый. Әлбәттә, моның сәбәпләре үземнең саксызлыгым һәм керфекнең бик аз вә бик сирәклеге булса кирәк, дип уйлыйм. Шул күземә бик нык ак төшү сәбәпле, әти мине докторга илтте. Бер атна ябып, көчкә төзәлде. Шул сәбәптәндер ки, сул күзем якыннан да бик ачык күрми. Ялтырап торган нурлы кара күз миңа мөяссәр булмаса да, сәламәт торганына куанам...

Минем чәчем сары. Бинаән, галәйһи, килешсез. Үстисә, пумала кебек тузып торудан башка эше юк. Үзе тагы ефәк шикелле йомшак...

Колагым сәламәт, бик яхшы ишетә. Ләкин бик зур һәм калкаеп тора. Кайбер казакъ «калкан колак мулла» ди.

Заһири — билгеле.
Тәдбир — алдан күрү.

Авызым бәләкәй авыз түгел, күз тимәсен!

«Әй, торна!» дип мыскыл итә иде мине малайлар. Вакыйган, мыскыл итәрлек тә бар. Буем кеби муеным да озын. Муенны бөгеп йөргәннән шулай озынайган булса кирәк. Хыялый адәмнәр кебек галстук кия башламасам, озын муенны серәйтеп йөрүе кыен булыр иде...

*

Эч поша!

Гомерем бигрәк тиккә, бушка үтә. Әле менә мәдрәсәдән кайтканнан бирле ничәмә айлар үтте. Яңадан мәдрәсәгә бару вакытлары җитте, шуннан бирле, мин сиңа әйтим, өч тиен көмешлек «йомыш» бетергәнем юк. Шөгыльләнеп уздырырлык эш тә юк шул... Хәер, эшлим дисәң, эш табыла ул. Мәсәлән, дәрес мөталәга кылу; бу бик яхшы һәм дә бик мөкаддәс бер эштер, Фәүт, турысын әйтим, киерендерә! Затән мәдрәсәнең үзендә дә «номер» ким сугылуыннан куркып кына укыган кеше идем бит мин! Дөрес, романнар вә шигырьләр укырга мин бик яратам һәм аңа иренмим дә, ләкин «манигъе коргыры» бар, авылда кыйраәтханә юк. Үзен алырга акча ягы такыр. Гомерне тиккә җибәргәнче, кыйраәтханә булса, каһәр, ару гына булыр иде дә, нә әйтәсең, юк... (Кыйраәтханә мөселман шәһәрләренең барсында да булмас борын авылларда була башласа, алла күрсәтмәсен, йә кызыл кар явар!)...

Мөяссәр — җайлы, уңай.
Бинаән — нигездә.
Галәйһи — аның зарарына.
Вакыйган — чыннан да.
Фәүт — кулдан ычкындыру, юк итү.
Затән — нигездә.
Манигъ — киртә.
Кыйрәтханә — уку залы.

ИСКӘРМӘЛӘР

ШИГЫРЬЛӘР, БАЛЛАДАЛАР, ПОЭМАЛАР

1910

СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы, Тарих, тел һәм әдәбият институтының кулъязмалар фондында Ш. Бабичның 1910—1911 елларда Казакъстанда балалар укытып йөргән чагында язган кулъязма «Шигырьләр җыентыгы» саклана. Унтугыз шигырь тупланган бу дәфтәрен яшь шагыйрь 1912 елда матбугатка да әзерләгән. Ләкин улниндидер билгесез сәбәпләр аркасында басылмый калган.

Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы» Ш. Бабичның үзе язган махсус кереш сүзе белән ачыла *.

Шагыйрьнең бу кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»на кергән әсәрләрнең күчермәләре СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы, Тарих, тел һәм әдәбият институтының Фәнни архивында саклаучы Зәбих Искужин фондында да бар (74 нче фонд). 1935—1936 елларда Ш. Бабич иҗаты буенча китап язып йөргән һәм үз эшен тәгәлли алмыйча вафат булган бу галим дә әлеге текстларны Уфадагы «Шигырьләр җыентыгы»ннан алган булырга тиеш. Аерма шунда гына, ниндидер билгесез чыганакларга таянып, З. Искужин бу әсәрләрнең язылу датасын 1911 ел белән билгеләгән, кайберләренең айларын да күрсәткән («И китап!» —1911 ел, май; «Бәхетсез мин» —1911 ел, май һ. б.).

Чыганакларның ачыкланмаган булуы сәбәпле, традиция буенча, 1958, 1985 елларда Уфада басылып чыккан җыентыкларда күрсәтелгәнчә (Ш. Бабич. Һайланма әсәрзәр. Өфө, 1958; Шәйхзада Бабич. Шигырзар, поэмалар. Өфө, 1985), бу юлы да кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»на кергән әсәрләрнең бер өлеше 1910 ел белән билгеләнде.

Шул рәвешле, «И китаб!» әсәреннән башлап «Күңел» әсәренә кадәрге шигъри текстлар 1912 елгы кулъязма җыентыктан алынды.

И китаб! *(17 бит)*.— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»на урнаштырылган беренче шигырь. Совет чорында бу әсәр беренче тапкыр «Пионер каләме» журналының 1936 ел 11 санында, соңрак «Хезмәт байрагы» газетасының (Башкортстан АССР Дүртөйле районы) 1956 ел 14 ноябрь санында басылган. Шагыйрьнең 1958, 1985 елларда Уфада, 1958 елда Казанда дөнья күргән сайланмаларына кертелгән.

Бәхетсез мин *(18 бит)*.— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы» (1912) буенча беренче тапкыр «Сәсән» (Уфа) журналының 1929 ел 1 санында дөнья күргән. 1958, 1985 елларда басылып чыккан башкортча сайланмаларга кертелгән.

---

* 311 нче биттәге текстны карагыз.

Кайда барсам, кайда торсам да...— Шигырь 1910 елда, яшь шагыйрьнең казакъ далаларында (Тургай өлкәсе) балалар укытып йөргән чагында язылган.

Охотник *(19 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Чәй эчеп иртүк, җиңел мылтык алып, шылдык икәү.— Яшь шагыйрьнең казакъ далаларында аучылык белән шөгыльләнгәнлеге билгеле.

И чаба ул, мин куамын, и чаба ул, мин куам...— Бу юллар Г. Тукайның мәгълүм «Су анасы» әсәренә ияреп язылган.

И дусларым *(22 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Дусларым, торган җирегез — туган авыл...— Бу шигырь дә казакъ далаларында «мүлдәкәлек» итеп йөргән чакта иҗат ителгән. Тургай өлкәсе, Дүсән авылында укыткан шагыйрь әлеге шигырь юлларын әнә шул авыл кешеләренә багышлаган булса кирәк.

Ике шәкерт *(22 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Яңгыр теләге *(23 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Син алдама *(25 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Безнең бакча *(26 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Безнең, иптәш, бакчабыз бар...— Шагыйрь туган Әсән авылында (хәзерге Башкортстан АССР Дүртөйле районы), чынлап та, Бабичларның зур бакчалары булган. Авыл картлары сөйләвенә караганда, бу әсәр әнә шул Бабичлар бакчасы хакында.

Әсма кыз — Бабичларга күрше генә яшәгән кешеләрнең кызы — Әсма Гыйззәтуллина.

Олактырылган песи *(27 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән. Шагыйрь бу әсәрен «Зиләйлүк» көенә җырларга яраткан.

Гашыйк дустыма *(28 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Куркак *(29 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

...таз Йосып калган Йосып...— Әсәр тулысынча Г. Тукайның «Таз» әсәренә ияреп язылганга күрә, төп герой да «таз» дип алынган.

Миңа юнь, ичмасам *(30 бит).*— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

...читкә чыгып китмәсәм.— Шагыйрь монда үзенең казакъ далаларында йөрүен күз уңында тота.

Зарлану *(31 бит)*.— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, беренче тапкыр «Сәсән» журналының 1919 ел 1 санында басылган. Башкортча сайланмаларга кертелгән.

Үтте гомремнең хәзер бер йөз дә туксан айлары.— Әсәрдә аталган айлар исәбен елларга күчерсәк, 15,8 ел килеп чыга. Димәк, шагыйрь бу әсәрен 1910 елның сентябрь — октябрь айларында иҗат иткән.

...йөргән җирләрем тик кап-кара Тургай җире.— Әсәрдә Казакъстанның Тургай өлкәсе хакында сүз бара.

1911

Кәҗә белән дуңгыз *(32 бит)*.— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, беренче тапкыр «Әдәби Башкортостан» журналының 1956 ел 10 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да (1958, 1958, 1985) кертелгән.

Ш. Бабич бу әсәрен Г. Тукайның «Кеше-хайваннар» («Ялт-йолт», 1910 ел, 5 сан) исемле фельетонына нисбәтән язган булса кирәк. Тукайда: «Д у ң г ы з —...гомерендә аңа тәрәккый күкләренә күтәрелеп карау мөяссәр булмас, һаман шул чүплегеннән борынын күтәрә алмас. К ә җ ә — мулладыр. Шул сарыклар алдында сакалын селкетеп, көтү башында йөреп рәислек итәр». Тәмсилен иҗат иткәндә Бабич шулай ук И. И. Крыловның Тукай тәрҗемәсендәге «Дуңгыз» мәсәлен дә файдаланган булса кирәк.

«Ялт-йолт».—1910—1918 елларда Казанда чыккан юмор-сатира журналы.

Нәсихәт *(33 бит)*.— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Шәйх — Шәехзадә Бабичның «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында таралган исеме.

«Галия» — Уфа шәһәрендәге яңа ысул мәдрәсә (1906—1917). Ш. Бабич бу уку йортында 1910—1916 елларда белем ала. (Җитәкчесе — мәгърифәтче-педагог, дин философы Зыя әл-Камали (Пәрвазетдин Камалетдинов, 1878—1942.)

Шайтаның арлы-бирле тарткаласа...— Бу мотив 1913 елда шагыйрь иҗатында «Вөҗдан һәм нәфес», «Нәфес — шайтан» кебек мөстәкыйль әсәрләр булып җитлегәчәк.

Курыкма! Эт өрсә дә, җырың җырла.— Бу юллар Г. Тукайның «Дошманнар» әсәре тәэсирендә иҗат ителгәннәр (Тукайда: «Эт кебек һаулап яманым, күз йомалар яхшыма...»).

Чеп-чи надан *(34 бит)*.— Кулъязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Шәйкулзадә — Ш. Бабичның үзгәртелгән исеме. Казакъ дуслары шагыйрьне шулай атап йөрткәннәр.

Тик тору артык *(34 бит)*.— Шагыйрьнең «Минем дә бар язганнарым» исемле кулъязма шигырьләр дәфтәреннән алып, «Сәсән» журналының 1929 ел 1 санында басылган. И. Насыйри һәм З. Искужин күчермәләреннән алынган бу әсәр шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән. Әмма аларда ул 1912 елгы әсәрләр белән бергә бирелгән. З. Искужин «Тик тору артык...» әсәренең язылу датасын «1911 елның июле» дип билгеләгән. Шуны истә тотып, бу сайланмада да ул 1911 елгы әсәрләр эчендә бирелә.

Текст 1958 елгы татарча сайланмадан алынды.

Күңел *(35 бит).*— Кульязма «Шигырьләр җыентыгы»ннан (1912) алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Күңел яна... яшь вакытлар әрәм үткәнгә.— Яшь шагыйрь казакъ далаларында йөргәндә үк (1910—1911) нинди дә булса уку йортына керергә хыяллана һәм, шуңа күрә, читтә йөргән вакытын «әрәм үткән вакыт» дип исәпли.

Габдулла әфәнде Тукаев *(36 бит).*— Әсәр беренче тапкыр 1930 елларда Ш. Бабичның шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарырга дәртләнеп йөргән мәрхүм язучы Имай Насыйри язмаларында телгә алына. Бу шигырьне ул безгә билгесез кульязма дәфтәреннән күчереп алган булса кирәк. Шул чорда И. Насыйри белән якын элемтәдә булган З. Искужин архивында да бу шигырьнең күчермәсе саклана. Әсәр шул ук Искужин инициативасы белән беренче тапкыр 1936 елда «Совет әдәбияты» журналының (Казан, хәзерге «Казан утлары») 5 санында басылып чыккан. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст З. Искужин күчермәләреннән алынды.

...Габдулланың хәзер Казанда мәскәне.— Г. Тукайның Казан шәһәрендә яшәвенә ишарә.

Моңланам *(37 бит).*— Шагыйрьнең «Минем дә бар язганнарым» исемле кульязма шигырьләр дәфтәреннән алып, «Сәсән» журналының 1929 ел 1 санында басылган. И. Насыйри тарафыннан табылган бу дәфтәр, кызганычка каршы, безнең көннәргә килеп җитмәгән. «Моңланам» шигыре З. Искужинга да мәгълүм булган. Ниндидер чыганаклардан файдаланып, галим аның язылу датасын да ачыклауга ирешкән — «1911 ел, июнь». Әсәр шулай ук башкортча сайланмаларга да урнаштырылган.

Текст И. Насыйри күчермәләреннән алынды.

1912

Сабантуй һәм милли бәйрәмнәр *(38 бит).*— И. Насыйри күчермәләреннән алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст И. Насыйри күчермәләреннән алынды.

Имтихан тотты шәкертләр, җитте апрель уртасы.— Апрель ае — «Галия» мәдрәсәсендә еллык имтиханнар чоры. Әсәрдә шуңа ишарә ителә.

Күп малай иртә торып, кычкырды: «Карга, карга...» — Шагыйрь туган Әсән авылында иң кызыклы йола бәйрәмнәренең берсе булган «Карга боткасы» бәйрәме хакында сүз бара. Бу йола Әсән төбәгендә хәзер дә яшәп килә.

...ботка беткәч... иртәгә күкәй җыябыз дип, йокларга яттылар.— «Карга боткасы» бәйрәме «Сабан туе» көннәреннән берничә көнгә алдарак уза.

...балалар өйләренә кайттылар, инде чыкты атлылар... —Сабан туе өчен бүләкләрне төшкә кадәр бала-чага җыя, төштән соң атка атланып зурлар чыга. Шагыйрь шул хакта яза.

... июнь җитәр... хозур җыен җитәр.— Әсән авылында җыеннар июнь аенда узган.

Бер көтү малай барып ачар басуның капкасын...— Җыен көннәрендә авыл читендәге басу капкасы тулысынча малайлар кулында була. Күчтәнәч бирмәгән кунаклар авылга үтә алмаганнар.

Г... авылыннан...— Күрше Гөбелекечек авылы хакында сүз бара.

Елмаер, муйнын борыр һәм яңгыратып сызгырыр, боргылатып

сызгычын.— Шагыйрь монда скрипкачы егет кыланышларын тасвирлый.

...гармуның ялтыратып тарткылар.— Монда сүз шагыйрьнең яшьлек дусты, шәриктәше, Әсән авылының иң оста гармунчысы Шакир Сабиров хакында бара булса кирәк.

...сыйланыр муллалар дүрт көнгәчә.— Әсән авылында җыен бәйрәме дүрт көнгә кадәр сузыла торган була. Динче-руханилар бу көннәрне аштан-ашка йөреп уздыралар. Шагыйрьгә бу хәл аеруча таныш. Чөнки бу көннәрдә аның атасы Мөхәммәдзакир хәзрәт тә ашка йөрергә тиеш була.

Кызгана *(41 бит).*— СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы, Тарих, тел һәм әдәбият институтының кульязмалар бүлегендә саклануччы «Кульязма шигырьләр дәфтәре»ннән алынды. Текстта язылган елы күрсәтелмәгән. Сүзлек составына, стиленә, идея-тематик эчтәлегенә карап, әсәрнең язылу елы 1912 ел белән билгеләнде. Бу шигырьнең «Аң» журналының 15 декабрь (1 сан) санында басылган «Шәрекъ йокысы» (Лекон-де Ноһ) исемле рәсем уңае белән язылган булуы да мөмкин. Әлеге рәсем мөнәсәбәте белән, «Аң» журналында Ф. Әмирханның «Шәрекъ йоклый» дигән нәсере дә басылган. Ш. Бабичның бу әсәре шулай ук Нәҗип Думавиның «Балалар тавышы» шигыренә дә аваздаш.

«Аң».— 1912—1918 елларда Казанда чыккан әдәби-иҗтимагый журнал. Аны чыгаруда Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Ә. Хәсәниләр башлап йөриләр.

Таң ата...— Тукайның «Аң» журналының беренче санында басылган «Аң» шигырендәге «Без бишенче елны бер көнне уяндык таң белән» дигән юлларга ишарә булса кирәк.

...туран угълы ята, башкалары кузгала.— Балкан сугышы алдыннан (1912—1913) Төркиядә пантюркизм идеяләре көчәеп китә. Аның йогынтысы Россиядәге төрки халыклар яшәгән төбәкләргә дә килеп җитә. Әлеге «туранчылык» (ягъни төркиләрнең бер дәүләткә оешуын алга сөрү) хәрәкәте шаукымы кайбер шагыйрьләр иҗатына да үтеп керә. Ул Бабич каләменнән дә читтә калмаган. Әмма аның бөтен «туранчылыгы» төрки халыкларны күпгасырлык йокыларыннан уянуга чакыруга кайтып кала.

Шулай алар нык кырышкан.— Төрки булмаган башка халыклар арасында барган сугышлар-алышлар аларга алга китәргә ярдәм иткән, дигән фикер үткәрелә.

Шаккаттыра *(42 бит).*— «Кульязма шигырьләр дәфтәре»ннән алып урнаштырылды. Язылу елы якынча куелды. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Сезнең мәртбә ятуыгызга...— Шагыйрь монда төрки халыкларның эшлексезлеген, ярдәмчесезлеген күреп ачына.

...төп атагыз туран.— Туран — төркиләргә иранлылар тарафыннан бирелгән исем.

Вөҗдан һәм нәфес *(43 бит).*— И. Насыйри күчермәләреннән алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст И. Насыйри күчермәләреннән алынды.

Имеш *(44 бит).*— «Кульязма шигырьләр дәфтәре»ннән алып урнаштырылды. Язылу елы якынча куелды. Танып бумау сәбәпле, соңгы ике юлы төшерелде. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

«Галия» җырлары *(44 бит)*.— Беренче җыр Ш. Бабичның яшьлек дусты, шәриктәше казакъ журналисты Әбдрахман Мостафин истәлекләре буенча бирелә («Агизел» (Уфа), 1966 ел, 8 сан). Икенче җыр башкорт халык шагыйре Сәйфи Кудаш истәлекләреннән алынды. «Менә 17—18 яшьләрдәге бер егет үзенә генә хас бер осталык белән, кешеләрне үзенә каратып, мандолина уйный һәм калын тавышын аккош кебек каңгылдатып җырлап та җибәрә...» — дип искә ала Сәйфи ага. (Кара: Сәйфи Кудаш. Хәтердә калган минутлар. Казан, 1959, 29 бит.)

«Галия».— Уфадагы яңа ысул мәдрәсә (1906—1917). Әлеге җырлар шушы мәдрәсә эчендә җырланганнар.

1913

Тукай үлгәч *(45 бит)*.— Әсәр беренче тапкыр И. Насыйри күчермәләреннән алып, башкортча сайланмаларга урнаштырылган.

Бу шигырь вакытында басыла алмый калган. Шул гына билгеле: ул Тукайның вафат булуы мөнәсәбәте белән иҗат ителгән һәм, бу зур кайгыны уртаклашу йөзеннән, «Вакыт» газетасы редакциясенә җибәрелгән. «Тукаев рухына» рубрикасы астында газетаның берничә санында басылган телеграммалар, хатлар, әдәби әсәрләр һ. б. исемлегендә «...шигырь, Уфадан, Бабичевтан» дигән мәгълүмат та бар («Вакыт», 1913, 31 апрель).

З. Искужин архивында сакланган күчермәдә бу әсәрнең язылу датасы «1913—IV» дип куелган.

Текст З. Искужин күчермәләреннән алынды.

«Вакыт».—1906—1918 елларда Оренбургта Фатих Кәрими редакторлыгында чыккан либераль-буржуаз газета.

Шагыйрь Габдулла.— Күренекле татар шагыйре Габдулла Тукай (1987—1913).

Җырчыны көткәндә *(46 бит)*.— Әсәр беренче тапкыр шагыйрьнең безгә билгесез «Истәлек дәфтәре» буенча 1929 елда «Яңалиф» (Казан) журналында дөнья күргән. (Кара: Гомәр Толымбай. Бабичның беренче адымнары (Яңа табылган истәлек дәфтәре буенча).— «Яңалиф», 1929 ел, 16 сан.) Башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст «Яңалиф» журналыннан алынды.

Кыйтга *(47 бит)*.— «Шура» журналының 1913 ел 21 санынннан алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

«Шура» —1908 елның 10 гыйнвареннан 1918 елның гыйнварена кадәр Оренбургта Риза Фәхретдинев редакторлыгында чыккан «әдәби, фәнни вә сәяси» журнал.

«Рәхмәт, апай...» *(47 бит)*.— Төхфәт Ченәкәй истәлекләре буенча китерелә («Әдәби Башкортостан», 1965 ел, 6 сан, 76 бит).

...җибәргәнсең дүрт бәрәңге.— Кагыйдә буларак, балаларын укытучы хәлфәләргә ата-аналар ай саен «эш хакы» җибәрергә тиеш булалар. Акчалары булмаган ярлы-ябагай исә бәрәңге, йомырка, катык кебек ашамлык әйберләре китергәннәр. Дүрт бала үстерүче ярлы хатын Хәтирә дә, Шәехзадә хәлфәгә дип, кызына тоттырып дүрт бәрәңге җибәргән.

Күңелсез чакта *(48 бит)*.— Шагыйрьнең «Истәлек дәфтәре» буенча китерелә. (Кара: «Яңалиф», 1929 ел, 16 сан.) Башкортча сайланмаларга кертелгән.

Күңелле чакта *(48 бит).*— Шагыйрьнең «Истәлек дәфтәре» буенча китерелә. Башкортча сайланмаларга кертелгән.

Һатиф вә татар *(49 бит).*— «Акмулла» журналының 1913 ел 31 санында «Бәбәйчүб» имзасы белән басылган. 1958 елгы башкортча сайланмада 1916 елгы әсәрләр рәтендә урнаштырылган. 1985 елгы башкортча җыентыкта беренче юлдагы «кызык та соң» урынына «аяныч», уннчы юлдагы «Ә Зыяң һәм Акчураң» урынына «Ә Зыяң һәм Закирың» дип бирелгән. Ш. Бабичның бу әсәре дә Г. Тукайның «Шагыйрь вә һатиф» әсәренә аваздаш яңгырый.

Текст «Акмулла»дан алынды.

«Акмулла».—1911 елның июленнән 1916 елның февраленә кадәр Троицк шәһәрендә Хәбибрахман Гаиеев редакторлыгында чыккан рәсемле сатирик журнал.

Һатиф.—Дини легенда буенча, кешеләр белән сөйләшә торган изге рух.

Сез утыз миллионга җиткән бер халык...— Монда «татар» төшенчәсе астында бөтен Россия төрки дөньясы күз уңында тотыла.

Зыя.— Зыя әл-Камали (Пәрвәзетдин Кәмалетдинов, 1878—1942).— Уфада яңа ысул «Галия» мәдрәсәсенә нигез салган мәгърифәтче-педагог, дин галиме.

Акчура.— Йосыф Акчурин (1876—1935), татар либераль-буржуа идеологы, публицист.

Муса.— Муса Бигиев (1873—1949), Петербург мулласы, дин философы, «Мөселман иттифакы» партиясен оештыручы либераль-буржуаз идеологларның берсе. Октябрьдән соң эмигрант.

Риза.— Ризаэтдин Фәхретдинев (1859—1936), әдип, журналист, галим, дин эшлеклесе; Оренбургта чыгып килгән либераль-буржуаз «Шура» (1908—1918) журналының редакторы.

Ишми.— Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев (1839—1919), элекке Вятка губернасы Малмыж өязе (хәзер Татарстан АССРның Балтач районы) Түнтәр авылы мулласы иң карагруһ динче, патша охранкасы агенты, татар тормышындагы бөтен прогрессив һәм демократик хәрәкәтне буып торуга зур сәбәпче булган кеше.

Мәдрәсәңне ябтыра, төрле доносларяздыра...— Ишми ишан доносы белән 1911 елда Иж-Буби мәдрәсәсе туздырыла, аның җитәкчеләре Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар төрмәгә ябылалар. Ишми ишан доносы белән башка бик күп мәдрәсәләр һәм алдынгы карашлы демократик язучылар (М. Гафури, Җ. Вәлиди һ. б.) эзәрлекләнәләр.

Кушмый шайтан.— Ишми ишанга шагыйрьләр тарафыннан бирелгән кушамат.

«Дөньяга мишәйт».— Монда дини-клерикаль «Дин вә мәгыйшәт» журналы (Оренбург) юри болай язылган. Журналның мондый кушаматы Бабич иҗатына Тукай шигъриятеннән килеп кергән, күрәсең. (Кара: Кеше — хайваннар.—«Ялт-йолт», 1910 ел, 5 сан (15 май); Динчеләр куаныштылар.— «Ялт-йолт», 1912 ел, 13 сан (20 сентябрь) һ. б.).

...журналның әгъзасы.— Ишми ишан «Дин вә мәгыйшәт» журналының редколлегия составына кергән булган. Шагыйрь шуңа ишарә итә.

...мескен татар һич эндәшми тик торса. «Иттифакъ!!» дип бер тавыш кылгач...— Төрки-татар дөньясын тулысынча үз кулларына алырга омтылган «Иттифакыль мөслимин»гә ишарә. «Иттифакыль мөслимин» («Мөселманнар союзы»)—1905 елда Россиядәге мөселман-либераль буржуазиясе һәм дин әһелләре төзегән контрреволюцион-милләтчел партия.

Кадим мулланың сүзе *(51 бит.)*—«Акмулла» журналының 1913 ел 23 санында «Бәбәйчүб» имзасы белән басылган. 1985 елгы башкортча сайланмага кертелгән.

Текст «Акмулла»дан алынды.

...җәдидләр.— Яңа ысул белән укытуны яклаучылар.

...яхшы, җуан башлы гошерләр.— Шәригать буенча, һәр мөселман барлык табышның уннан бер өлешен фәкыйрьләр, зәгыйфьләр файдасына — җәмәгать фондына бирергә тиеш. Әмма гамәлдә байлар тарафыннан бу беркайчан да җиренә җиткерелмәгән, үтәлмәгән, гошер садакасының бирелгән кадәресе белән гадәттә мулла-мунтагай туенган. Монда Бабич шуңа ишарәли.

Әбҗәд — борынгы гыйбрани (яһүд) әлифбасындагы хәрефләр тәртибен күрсәтү өчен ясалган мәгънәсез сүзләрнең беренчесе һәм бу сүзләрнең барысының исеме (бу сүзләр: әбҗәд, һәүвәз, хоттый, кәләмән, сәгъфәс, корищәт, сохоз, зазогъ).

Кисекбаш.— Борынгы (XIV йөз) шигъри ядкярләреннән «Кисекбаш китабы».

«Агыйделдә саллар ага...» *(52 бит).*— Р. Бикбаевның «Шәйхзада Бабич. Тормошо һәм иҗады» дигән китабыннан (Өфө, 1981 ел, 53 бит) алынды.

Вәли Хангильдин истәлекләреннән күренгәнчә, Ш. Бабич җәй айларында Агыйдел буйларында, салчылар янында булырга яраткан. Соңрак ул алар белән эшләп тә йөргән. (Кара: «Совет әдәбияты», 1959 ел, 5 сан.) Әлеге шигырь шул көннәр хатирәсе булырга тиеш.

Кыйтга *(52 бит).*— «Шура» журналының 1913 ел 20 санында басылган. Башкортча сайланмаларга «Тиң булырмы?» исеме астында урнаштырылган.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Халкым өчен *(53 бит).*— Казанда 1922 елда Галимҗан Ибраһимов редакциясендә чыккан «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. 1923 елда бу әсәр Фәтхи Бурнаш тарафыннан төзелгән «Көрәш җырлары» җыентыгына кертелгән. Шагыйрьнең өч сайланмасында да урын алган.

Сайланмалар вариантында соңгы строфада мәҗмугадагы «Ялкын чагым булсын миндә» урынына «Ялкын чагым булсын фида» дип бирелгән. Укучыга тәкъдим ителәчәк сайланмада да «фида» варианты калдырылды. Шагыйрь Х. Туфан «Галия» буенча шәриктәше Ш. Бабичның бу әсәре нәкъ шулай тәмамланырга тиеш дип саный иде. Туфанның шәхси архивында саклана торган «Шигырьләр мәҗмугасы»нда да «миндә» сүзе яшел кара белән «фида» дип төзәтелгән.

Текст, әлеге төзәтүне истә тотып, 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Бай һәм ярлы *(54 бит).*—1922 елда Казанда басылып чыккан «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның икенче китабында урын алган һәм 1925 елда Мәскәүдә дөнья күргән «Ш. Бабич шигырьләре» җыентыгына, соңрак шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ннан алынды.

Бер минут *(55 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Айга мендем *(56 бит)*.— 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән. Ш. Бабичның бу әсәре вакытында бик популяр булган булырга тиеш. Мәсәлән, 1917 елда «Кармак» журналының 9 санында Гариф Шәрифи дигән шагыйрь, Бабичның әлеге әсәренә ияреп, хәтта аңа җавап рәвешендә, түбәндәге юлларны бастыра:

Ятма, мен күккә, мен, мен гарешкә,
Оч киек каздай, син бит — фәрештә!
Мен дә син күккә — утыр көрсигә...
Кирәкми анда... дөньяң берсе дә...

Гареш — тора торган урын. Дини легенда буенча, җиһан унсигез мең галәмнән, ягъни планетадан тора.
Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Ярсынмаса күкрәк *(57 бит)*.— 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.
Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Кыйтга *(57 бит)*.—«Шура» журналының 1914 ел 10 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән. 1958 елгы башкортча сайланмага «Нәфес — шайтан» исеме белән урнаштырылган.
Текст «Шура» журналыннан алынды.
Нәфес — шайтан...— нәфес — шайтан көрәше хакындагы өйрәтмә дини мифологиядән килә. Ш. Бабич шигъриятендә ул соңрак «Вөҗдан һәм нәфес», «Газазил» әсәрләрендә төп идеяне билгеләячәк.

Мандолин *(58 бит)*.—«Тормыш» газетасының 1914 ел 17 октябрь (122) санында басылган, 1958 елгы татарча сайланмага кертелгән.
Текст «Тормыш» газетасыннан алынды.
«Тормыш».—1913—1918 елларда Закир Кадири тарафыннан Уфада чыгарылган либераль-буржуаз газета.
Син минем җан сердәшем...— Ш. Бабич үзе дә бик оста мандолиначы булган. Ул шулай ук «Галия» мәдрәсәсендә эшләп килгән кыллы оркестр җитәкчеләренең берсе.

Ярканат *(59 бит)*.—«Акмулла» журналының 1914 ел 40 санында «Чытырман» имзасы белән басылган, татарча сайланмага (1958) кертелгән. Башкортча сайланмада (1958) 1915 елгы әсәрләр рәтендә бирелгән, соңгы ике юл төшеп калган.
Калка гаклым башыма тик уткәч эш, баткач кояш.— Ихтимал, бу әсәрне язганда 1912 елны Уфа шәһәрендә булган вакыйгалар зур роль уйнагандыр. 1912 елның җәендә Уфага Г. Тукай килеп төшә. «Галия»дәге имтиханнардан соң, киләчәк Тукайны көтеп-көтеп тә каршы ала алмаган Шәехзадә авылына кайтып китмәкче була. Ләкин нәкъ менә ул шәһәрдән югалып торган арада Уфада Тукай булып китә...

«Ризабыз, кыйсмәтең безгә бүлемлә...» *(59 бит)*.— «Шура» журналының 1914 ел 13 санында басылган. Шагыйрьнең башкортча сайланмаларына кертелгән. 1958 елгы башкортча сайланмага «Мал һәм белем» исеме белән урнаштырылган.
Текст «Шура» журналыннан алынды.

Бәгъзе студентларыбыз *(60 бит)*.— «Акмулла» журналының

1914 ел 37 санында (7 май) «Бәбәйчүб» имзасы белән басылган. 1958 елгы башкортча сайланмага кертелгән.

Текст «Акмулла» журналыннан алынды. Әсәр татар милли культурасыннан кимсенеп йөрүче кайбер татар студентлары хакында.

Җиз төймәләр пальтода.— Студентларның махсус кием-формасына ишарә.

Бер муллага *(61 бит).*— «Шура» журналының 1914 ел 21 санында басылган. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Бу әсәр Әсән авылының беренче кадим мәхәллә мулласы Хаммат Шиһабетдиновка сатира рәвешендә язылган булса кирәк. Ул тирә-якта Бабичлар гаиләсе өстеннән донослар язуы белән билгеле (БАССРның Үзәк дәүләт архивы, 11-ф., 2-тасв., 73 с. б., 3—19 битләр). Шиһабетдиновлар (Ш. Бабичның анасы Бибисаҗидәбану нәселе кешеләре), рухани булуларына карамастан, эчкечелек белән шөгыльләнгәннәр. Хаммат мулланың Указы нәкъ энә шул эчеп йөргәне өчен алына да.

...*калага.*— Бөре (Бирск), Уфа шәһәрләре хакында сүз бара.

Самад өслүбе *(62 бит).*— «Самад» исеме астында язышучы «Тормыш» (Уфа) газетасы хәбәрчесенә (Самад Шәрәфетдинов —?) пародия рәвешендә язылган бу язма озак еллар Ш. Бабич мирасын туплау, өйрәнү белән шөгыльләнгән галим, профессор Хатип Госман архивыннан алынды.

Шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

Таркау уйлар *(65 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Ф. Бурнаш төзеп чыгарган «Көрәш җырлары» (1923) җыентыгына урнаштырылган, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Гавас — диңгез төбенә чумып җәүһәр эзләүче-табучы кеше *(Галимҗан Ибраһимов искәрмәсе).*

1915

Әйдә, милләт! *(66 бит).*— «Шура» журналының 1915 ел 1 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Мөтәшагыйрь зары *(66 бит).*— «Шура» журналының 1915 ел 3 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Скрипка *(67 бит).*— «Шура» журналының 1915 ел 3 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Әй минем сызгычлы нәрсәм...— Истәлекләргә караганда, Ш. Бабич скрипкада оста уйнаучыларның берсе булган.

Җен, пәри — халык мифологиясе геройлары.

Кыйтга *(68 бит).*— «Шура» журналының 1915 ел 3 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Кыйтга (Куй нәфесне иркенә...) *(68 бит).*— «Шура» журналының 1915 ел 4 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Куй нәфесне иркенә...— Бу юллар Ш. Бабичның 1912 елда иҗат ителгән «Вөҗдан һәм нәфес» шигыренә җавап булып яңгырый.

«Әйдә, күңлем, монда торма...» *(68 бит)*.—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән. Шуны да әйтергә кирәк, Г. Шәрифинең югарыда телгә алынган шигыре («Татар кызына» —«Кармак», 1917 ел, 3 сан) Бабичның әлеге әсәрен дә күз уңында тотып язылган булса кирәк.

«Кармак».—1915—1917 елларда Оренбургта Мәхмүт Галәү (Мәрҗани) тарафыннан чыгарылган көлке журнал. 1917 ел ахырында бу журналда Ш. Бабич секретарь булып эшли.

...монда сугыш, монда кылыч!—Әсәр беренче бөтендөнья сугышы башлангач иҗат ителгән. Шагыйрь канкоюлы сугышка нәфрәтен белдерә.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Көрәшеп үткәр кыска гомереңне *(69 бит)*.— «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның беренче (1922) китабында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән, «Ш. Бабич шигырьләре» (Мәскәү, 1925) җыентыгына урнаштырылган. 1958 елда Уфада чыккан сайланмада соңгы дүрт строфа төшереп калдырылган. Бу соңгы строфаларда күпмедер тематик аермалык сизелсә дә, әсәр тарихына кагылышлы мәгълүматлар булмау сәбәпле, алар шул килеш калдырылды.

Текст «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ннан алынды.

Гонаһ — җәза *(70 бит)*.—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Аптыраган минутларда *(71 бит)*.—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. 1923 елгы «Көрәш җырлары»на, соңрак шагыйрьнең 1958 елгы башкортча сайланмасына кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Какты дулкын...— Бу поэтик деталь Дәрдмәнд иҗатыннан килә һәм «язмыш дулкыны» дигән мәгънәне белдерә.

«Шәехзадә» бичарадан...— Шагыйрь үзе хакында яза.

Аптыраш (вариант) *(72 бит)*.— «Тормыш» газетасының 1915 ел 13 ноябрь (356) санында басылган. 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда бирелгән «Аптыраган минутларда» әсәренең бер варианты. Анда «Мәҗмуга»дагы «Артым салкын, алдым ялкын» дигән беренче юл һәм өченче строфаның:

Уй чуалды, катты баш,
Нишләргә дә аптыраш,—

дигән ике юл төшеп калган. Шуны да әйтергә кирәк, «Мәҗмуга» вариантындагы «Юл баткак вә лайла...» дип башланган икенче бүлек беренчесеннән ритмик төзелеше, аһәңе-яңгырашы белән кискен аерылып тора. Ихтимал, икенче бүлек мөстәкыйль әсәр буларак каралырга да каклыдыр.

Текст «Тормыш» газетасыннан алынды.

Шәмсетдин Суфый авызыннан *(73 бит)*.— Шигырь Хатип Госман архивындагы күчермәләр буенча, шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә. Бу әсәрдә XIX йөз татар шагыйре Шәмсетдин Зәки Суфыйның «Улгай — улмагай» шигырендәге поэтик алым кулланылган.

Әй адәм балалары *(74 бит).*— Шигырь, Хатип Госман архивындагы күчермәләр буенча, шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

Актык зарым *(76 бит).*— 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. «Керәшен җырлары» (1923) җыентыгына урнаштырылган, соңрак шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Мәлгунь иблисләр төкергән дөньяга...— Иблис — дини мифологиядә шайтаннар башлыгы, аллага каршы баш күтәргәне өчен мәңгегә ләгънәтләнгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Ауруым — саулыгым *(76 бит).*— «Шура» журналының 1915 ел 12 санында басылган. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Киңәшләр *(77 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 3—4 санында (15 февраль) «Чытырман, Уфа» имзасы белән басылган. Башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Карун — Муса пәйгамбәрнең кардәше, черегән бай; комсызлыгы, саранлыгы, шәригать законы буенча тиешле зәкятне (сәүдәгәрләргә еллык керемнең 40 тан бер өлеше күләмендәге еллык салым) түләмәгәне өчен йорты, каралты-курасы белән бергә җиргә убылып һәлак була имеш. Коръәннең 28 нче сүрәсендә 76—81 нче аятьләр Карунны гыйбрәт итеп куюга багышланган. «Ачкүз, комсыз, саран» мәгънәсендәге «карун» сүзе шуннан килә.

«Хатим-эттаилек»— изгелек, юмартлык мәгънәсендә. Борынгы гарәпләрдә үзенең юмартлыгы, шәфкатьлелеге белән танылган Хатим ибн-Габдулла ибн-Сәит Эттаи дигән бер батыр булган. Бу әйтем шул батырның исеме белән бәйләнгән.

...килештереп урлау яхшы.— Халыкны талап көн күрүче мулла-мунтагайлардан, байлардан көлү.

Җәй көне урамда *(78 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 16 санында (15 август) «Чытырман» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Фәс — төрекләрнең баш киеме.

Бер эчүченең зары *(79 бит).*— И. Насыйри күчермәләреннән алып, 1958 елгы башкортча сайланмага, З. Искужин күчермәләреннән алып, 1958 елгы татарча сайланмага урнаштырылган. Ике галим дә бер үк чыганак белән эш иткән булырга тиеш.

Текст З. Искужин күчермәләреннән алынды.

Шагыйрь үзе бу әсәренә «Аракы сату тыелгач» дигән аңлатма биргән. 1915 елда Уфада җомга көннәрендә аракы сату тыелгач язылган булса кирәк. Ул вакытта татар җәмәгатьчелеге, эчкечелекне бетерү максатын күз уңында тотып, җомга көнне аракы кибетләрен ябу мәсьәләсен күтәреп чыгалар. Шул ук 1915 елда Ш. Бабич тарафыннан язылган дип уйланылган «Авыл җырлары»ндагы («Кармак», 1915 ел, 10 сан) (15 май) түбәндәге юллар игътибарга лаеклы:

Алмашыймсың, балашыймсың, бал татлырак алмадан,
«Җомга көн кибет ябу»ны инде сорыйк алладан.

Хәзрәте Сүнчәләй рухына *(80 бит).*— И. Насыйри күчермәләреннән

алып, башкортча сайланмаларга кертелгән. Шул ук вариант З. Искужин күчермәләрендә дә бар.

Текст З. Искужин күчермәләреннән алынды.

Хәзрәте Сүнчәләй...— Әсәр Сәгыйть Сүнчәләй иҗатына пародия рәвешендә язылган.

Тимергә *(81 бит).*— И. Насыйри һәм З. Искужин күчермәләреннән алып, шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст З. Искужин күчермәләреннән алынды.

Бәнем фәрештәм *(82 бит).*— «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның (Казан, 1922) икенче китабында басылган. «Ш. Бабич шигырьләре» (Мәскәү, 1925) җыентыгында урын алган, соңрак шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ннан алынды.

Канун тыңлаганда (Фараби хәзрәтләренә багышлыйм) *(83 бит).*— «Шура» журналының 1915 ел 22 санында басылган. Шул ук журналның 24 санында шагыйрьнең түбәндәге аңлатмасы басылган:

«Тәсхихләр.

22 нче гәдәт «Шура»да «Канун тыңлаганда» сәрләүхәле шигыремберникадәр матбага хаталары бар. Шуйләнә:

15 нче юлда —«дисең» сүзе калган;

22 нче юлда — «күрелде» түгел, «куылды»;

31 нче юлда — «башыңдан» түгел, «баштан»;

42 юлда — «канлары» түгел, «канлар»;

43 нче юлда — «җаным» түгел, «каным».

Ш. Бабич».

Әсәр шулай ук башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Фараби.— Әбү Насыр Мөхәммәт ибн Тархан Әл-Фараби (870—950), атаклы Урта Азия философы һәм энциклопедист, бөтендөнья фәне үсешенә көчле йогынты ясаган галим. «Китабел-музик Әл-кәбир» дигән хезмәтендә музыка тарихы, эволюциясе, музыкаль эстетика, музыка теориясе һәм музыка коралларының тарихы кебек мәсьәләләр тикшерелгән.

Канун.— Урта Азия халыкларының борынгы уен коралы. Аның барлыкка килүен Фараби исеме белән бәйлиләр.

Чирттерә, аһ, һич тәкать юк...— Ш. Бабич «Галия» мәдрәсәсендә уку чорында Урта Азиядән килгән шәкертләрдән канунда уйнарга өйрәнгән.

...әллә кайчангы кавемнәр ыңраша...— Шагыйрь монда борынгы кабиләләргә, ыругларга ишарә итә.

...моңлы Давыт хәзрәтләре...— Дин тарихы буенча, изге «Зәбур» китабының авторы — Давыт пәйгамбәр.

Кари — мәчеттә яки дини мәҗлесләрдә Коръәнне яттан укучы кеше.

Әй, Фараби хәзрәтем, төркем, каным, нәслем, җаным...— Шагыйрь монда Фарабиның төрки нәселдәш, кандаш, ягъни туган булуына ишарә итә.

Дөньяга *(85 бит).*— «Шура» журналының 1915 ел 23 санында басылган. «Ш. Бабич шигырьләре» (Мәскәү, 1925) җыентыгына урнаштырылган. Ләкин анда соңгы строфа башкача бирелгән:

Иманым — үзем!..
Коръәндер — сүзем!!!

Бу әсәр шулай ук шагыйрьнең өч сайланмасында да урын алган.
Текст «Шура» журналыннан алынды.

Безнең мужик *(87 бит).*—1911 елда язылган (кулъязма «Шигырьләр җыентыгы», 1912 ел) «Чеп-чи надан» шигыренең варианты. И. Насыйри күчермәләреннән алып, башкортча сайланмаларга кертелгән.
Текст И. Насыйри күчермәләреннән алынды.

1916

Кәтәм (башкорт ысулынча) *(88 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды. Башкортча язылган бу шигырьнең нинди резонанс тудыруы кызыклы. 1916 елның җәендә «Тормыш» газетасы редакциясе, рамазан гаете уңае белән, М. Гафури, С. Рәмиев, Н. Думави, С. Сүнчәләй, Ш. Бабич һәм З. Бәширине үзенә чакыра. З. Кадири аларның бирәр шигырен 18 июль санында бастырып чыгарырга нияттә. Бабич үзенең әлеге «Кәтәм» дигән шигырен алып килә.

«Бабичның шигырен уку алдыннан әйткән шушы сүзләре,— дип яза Зариф Бәшири,— бүгенгедәй хәтеремдә калган:

— Алдан ук әйтеп куйыйм: шигыремнең ике сүзе ягы бар. Беренчедән, ул шактый кыю мәсләкле, икенчедән, шигырь башкорт телендә язылган...

...Бабичның бу «Кәтәм» дигән шигыре миңа да, башкаларга да ошады. Шулай да аны «Тормыш» газетасының редакторы Закир Кадири хупламады.

— Мин бу шигырьне,— диде ул,— Бабич үзе әйткән сәер якларын алып ташлаганда гына бастыра алам, ә бу кее — юк.

Мондый хөкемне ишеткәч, Бабич шигырьне күен кесәсенә тыкты да урыныннан торды һәм Закир Кадирига:

— Безнең халыкка ирекле көннәр килмичә, бу шигырь дөнья күрә алмас, ахры. Ә мин ул көнне көтәм!— диде дә редактор бүлмәсен ташлап чыгып китте» (Зариф Бәшири. Әйе, ул хаклы иде.— «Совет Башкортостаны», 1957, 12 декабрь).

Шушы вакытларда яза башлаган «Китабеннас»ының бер бабында Бабичның:

Әл-Кадириның кадере төшмәк әлмисактан мөктәдир,
Акылына, фәһеменә, истибадлы хиссиәт мөдир!— дип З. Кадирины әләктереп китүенә әлеге вакыйга да күпмедер сәбәпче булгандыр, күрәсең.

«Кәтәм» шигыренең язылу тарихы Әбрар Сәгыйдинең «Көтсәң дә...» шигыре белән бәйләнгән булуы ихтимал («Тормыш», 1916 ел, 7 февраль (411) саны). Бабич шигыре Ә. Сәгыйди әсәренә җавап булып яңгырый.

Телимен *(89 бит).*— «Шура» журналының 1916 ел 8 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән. 1958 елгы татарча сайланмада әсәр «Теләк» исеме белән бирелгән һәм 1914 елга нисбәт ителгән.
Текст «Шура» журналыннан алынды.

Очтылар *(89 бит).*— «Шура» журналының 1916 ел 6 санында басылган, «Шигырьләр мәҗмугасы»нда (1922), соңрак шагыйрьнең өч сайланмасында урын алган. 1922 елгы җыентыкта шигырьнең икенче строфасы түбәндәгечә тәмамлана:

Мин торып калдым, торып
Калдым күңел сызлау белән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Очтылар «Моңнар» белән.— Бу юлларның Г. Тукайның «Милли моңнар» әсәрен яисә «Халык моңнары» җыентыгын (1910) укып чыкканнан соң иҗат ителүе ихтимал.

Язгы бәйрәмнәр *(91 бит).*— И. Насыйри күчермәләреннән алынып, башкортча сайланмаларга кертелгән. З. Искужин архивында да бар.

Текст З. Искужин күчермәләреннән алынды.

Көн тыныч үтсә, төнендә суры Исрафил чыгар.— Дини мифология буенча, кыямәт көне җиткәч, Исрафил фәрештә сур (мөгез, быргы) өрәчәк (кычкыртачак) һәм барлык үлгән кешеләрне, алла алдында хисап бирү өчен, каберләреннән торгызачак имеш. Ш. Бабич үз әсәрендә шушы дини легенда образларын куллана.

Кем? (Аң журналыннан) *(92 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 2 нче санында (1 февраль) «Шөбшә» имзасы белән басылган. Башкортча сайланмаларга кертелгән. З. Искужин бу әсәрнең язылу датасын «1914 ел, январь» дип куйган.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Аңладым (9176 нчы номерлы «Вакыт»тан) *(93 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 5—6 саннарында (15 март) «Шөбшә» имзасы белән басылган. Башкортча сайланмаларга кертелгән. З. Искужин бу әсәрнең язылу датасын «1915» дип күрсәткән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Бер тәмсил (Уфа Галиясенең ун еллыгына) *(94 бит).*— «Шура» журналының 1917 ел 3 санында «Мәдрәсәи Галиянең юбилеенда укылган тәмсил» исеме астында басылган. Соңрак «Бер тәмсил (Уфа Галиясенең ун еллыгына)» исеме белән 1922 елгы җыентыкка һәм өч сайланмага кертелгән.

Әсәр, исеменнән үк күренгәнчә, «Галия» мәдрәсәсенең 1916 елда булып узган 10 еллык юбилеена багышланган һәм 1916 елның декабрендә «Галия»дә оештырылган зур кичәдә укылган. (Кара: С. Кудаш. Күккә үрләгән еллар.—«Агизел», 1965, 7 сан, 64 бит.)

Икенче бер урында С. Кудаш, «Бер тәмсил» әсәренең нигезенә салынган фикерләргә тукталып, түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Бу шәһәрдә (Троицкида.— *Г. Г.*) ул «Галия» җитәкчесе Зыя Кәмалига багышлап язган «Бер тәмсил» исемле гаять үткер мәсәлен иҗат итте, шәкертләрне диннән яздыруда гаепләп мәдрәсәне ташлап чыгып киткән укучыларны һәм мәдрәсәгә материаль ярдәмнәрен туктаткан Уфа байларын бөтен галәм алдында хурлык баганасына бәйләп көлде» (С. Кудаш. Яшьлек эзләре буйлап. Казан, 1964, 42 бит).

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Бервакыт бер бал корты читкә китте — Зыя Кәмалиның гарәп илләрендә укып кайтуына ишарә.

Эше бара, дусы арта, күче арта — «Галия» мәдрәсәсенең оешуы, үсүе хакында сүз бара.

...Умарта һәм бакча була — мәдрәсә бинасы төзелә, дип аңларга кирәк.

Шул чакта бинага бер сыер кергән — мәдрәсәдәге азатлык рухына каршы Уфа буржуазиясенең мәшһүр скандалларына ишарә (*Г. Ибраһимов искәрмәсе*).

Уйлашыйк, бу бәладән, бу Җәфадән ниткәндә коргыласың корт анасын!—«Галия» мәдрәсәсенең 10 еллык юбилее вакытында Бабич ярдәм итү мәсьәләсен күтәреп чыга һәм шунда ук юбилейга килгән кунаклардан, хәлфәләрдән, шәкертләрдән акча җыю эшен башлап җибәрә (Ш. Бабич. Мәдрәсәи «Галия»нең ун еллык бәйрәме.—«Кармак», 1 май, 8—9 саннар). Тәмсилдә шуңа ишарә ясала.

Кышкы юл *(98 бит)*.— «Тормыш» газетасының (Уфа) 1916 ел 22 март 335 санында басылган, өч сайланмага да кертелгән. Башкортча сайланмаларда «Кышкы юлда» исеме астында бирелгән. 1958 елгы башкортча сайланмага И. Насыйри туплаган кульъязма буенча кертелгән һәм беренче юл «Их, рәхәт шуа чанам, юрта ат алкын гына» дип бирелгән. З. Искужин бу әсәрне 1915 елга нисбәт итә.

Текст «Тормыш» газетасыннан алынды.

Ямь күрәлмәм *(99 бит)*.— «Шура» журналының 1916 ел 7 санында басылган. Соңрак шагыйрьнең өч сайланма җыентыгында да урын алган.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

«И улым, син күз нурым...» *(99 бит)*.— Әсәрнең тексты Вәли Хангильдин истәлеге буенча китерелә («Совет әдәбияты», 1959, 5 сан, 99 бит).

Мин — даһи! *(100 бит)*.—«Шура» журналының 1916 ел 8 санында басылган. Соңрак шагыйрьнең өч сайланма җыентыгына да кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Ямьле көн (Җәй хатирәсе) *(101 бит)*.— «Шура» журналының 1916 ел 9 санында басылган. Соңрак шагыйрьнең өч сайланма җыентыгында да урын алган.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Шатлык җыры *(101 бит)*.— «Шура» журналының 1916 ел 9 санында басылган. Соңрак шагыйрьнең өч сайланма җыентыгында да урын алган.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Кисас *(102 бит)*.— «Кармак» журналының 1916 ел 4 санында (15 март) «Шәбшә» имзасы белән басылган. Ике башкортча сайланмага да кертелгән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Бу әсәр М. Гафуриның «Аң» журналында (1915, №21—22) басылган «Кисас» исемле шигыренә пародия рәвешендә язылган. Түбәндә аның тулы текстын китерәбез.

1

Бер кеше үтерсә, эшләсә бик зур гөнаһ,
Ул кеше мәгъюб булып, үлем белән мәхкүм була.
Җан белән уйнаучыларга бик тиешле бу кисас,
Инде ул бетте гомергә, мәңгелеккә китте баш.

2

Һәммәбез дә бу үлемгә мәхкүм булган бәндәмез,
Тәңре каршында шулай катыйль микәнни һәммәбез?

Һәр минутта бу үлемгә күпме зат мәхкүм була,
Бу кешеләр кемне үтергән? Эшләгәннәр ни гөнаһ?
Ник яшәтсен соң ходай? Безне гөнаһ эшләгәч,
Мондый эшне һич сәбәпсез, тәңре белми эшләмәс.

Бер кеше...— Мәҗит Гафури хакында сүз бара.

«Аң».— 1912—1918 елларда Казанда Әхмәтгәрәй Хәсәни редакторлыгында (барлыгы 113 сан) чыккан рәсемле әдәби-сәяси журнал.

«Аң»чы... Әхмәтгәрәй.— «Аң» журналының редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни.

Нинди алтыннар ята «кәрзинка»да мәхрум булып...— «Аң» журналында басылмый яткан кайбер әсәрләргә ишарә.

«кәрзинка»— язучылар үз әсәрләрен махсус үрелгән юл «кәрзинка»ләренә салып йөрткәннәр. Бу сүз, шуңа күрә, иҗат ителгән әсәр саклана торган урын, архив мәгънәсендә дә кулланылып йөргән.

Алты ел («Тормыш» газетасыннан) *(103 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 4 санында (15 февраль) «Шөбһә» имзасы белән басылган. Ике башкортча сайланмага да кертелгән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Шигырь С. Сүнчәләйнең алты еллык иҗаты уңае белән «Тормыш» газетасында басылып чыккан әсәргә пародия рәвешендә иҗат ителгән.

Сөймәгәчтен башкалар...— Бу урында Ш. Бабич күбрәк С. Сүнчәләй шигырьләренә карата язылган үз пародияләрен, тәнкыйтьләрен күз уңында тота булса кирәк.

Алда мин өзмим өмид — алда сәма, балкый сәма!— С. Сүнчәләй әсәрләрендә күп очрый торган «күк-сәма» образына ишарә («Күзләреңдә»—1913, «Мин ирекле»—1915 һ. б.).

Әл дә мин бер яшь сабый күк... Әллә мин төшләр күрәм...— Шулай ук С. Сүнчәләй иҗатында еш очрый торган «төш» мотивына ишарә («Гөл бакчамда»—1913; «Дилбәрем»—1914; «Төн буе»—1914; «Кояш күрмим»—1916 һ. б.).

Алдагы нурлар итәрләр акрын-акрын энҗе лә!..— «Нур» — С. Сүнчәләй иҗатында еш очрый торган тагын бер романтик сурәт («Аерылышу җыры»—1913; «Якты булсын»—1914; «Эзләдем нур»—1915 һ. б.).

Шул рәвешле, Ш. Бабич шагыйрь С. Сүнчәләй иҗатында очраган поэтик сурәтләрне, романтик образларны пародик мәгънәдә кулланган.

Бер урамнан бер урамга «алла» эзләп...— С. Сүнчәләйнең «Тормыш» газетасында (1916 ел, 1 апрель саны) басылган «Шигырь» әсәрендәге: «Мәгъсүмә кызлар белән мин һәм урамнарда йөрим», дигән юлларга ишарә ителә булса кирәк.

Аның өчен *(104 бит).*— «Аң» журналының 1917 ел 8—9 саннарында басылган. Шуңа күрә дә әсәр 1958, 1985 елгы башкортча сайланмаларга 1917 елгы әсәрләр белән янәшә урнаштырылган.

1958 елгы татарча сайланмада шигырьнең язылу датасы бик хаклы рәвештә 1916 ел белән күрсәтелгән. Троицк шәһәрендә укытып йөргән шагыйрь белән якыннан таныш булган Мәхмүт Бәдәйли истәлекләренә караганда, Бабич бу әсәрен 1916 елны иҗат иткән булырга тиеш. (Кара: «Совет әдәбияты», 1965, 1 сан.)

1958 елгы башкортча сайланмада төгәлсезлек киткән. Андагы беренче строфада «алиһәмне» сүзе урынына «илһамымны» дип бирелгән.

Текст «Аң» журналыннан алынды.

Алиһәмне нур томалый...— Алиһә — хатын-кыз җенесендәге алла. Шагыйрь бу шигырен язганда конкрет кешене күз уңында тоткан. Ул — Бабичның Троицк чорында яратып йөргән кызы Сәрвәр. Сәрвәр Әдһә-

мова үзенең соңгы истәлекләрендә Бабичның мандолинасы хакында күп яза, ул, хәтта, шагыйрьнең иске, ватык мандолинасын ниндидер «канатлы» мандолинага алыштыруын да хәтерли. (Кара: «Совет әдәбияты», 1965 ел, 1 сан.)

Караңгылыкта *(105 бит)*.— «Сүз» газетасының (Мәскәү) 1916 ел 11 май (53) санында басылган.

«Шигырьләр мәҗмугасы»на (1922), соңгы өч сайланмага кертелгән. З. Искужин бу шигырьнең язылу датасын «1915 ел» дип билгеләгән.

Текст «Сүз» газетасыннан алынды.

1916 елда «Кармак» журналының 1916 ел 14—15 саннарында (1- август) «Кылыч» (Дим буе) дигән имза астында С. Кудаш әлеге шигырьгә пародия бастырган. «Караңгылыкта» («Сүз»дән) дигән исем белән бирелгән бу әсәр текстын тулысынча китерәбез.

Шөһрәт эзләп мин шигырь яздым. Һич илһам килмәде,
Кочагым җәеп ятсам да, һич тә бер нур иңмәде.
Бик телим булмак шагыйрь, урлаштырып шигырь язам,
Ну шулай да юк талант, күзләр сукыр, һич күрмәде.
Шунда миннән көлде сыер, көлде сарык, көлде ат,
Ник газаплыйсың мине?.. Мин бит шагыйрь, күңлем дә шат!
Юк җылылык, мин өшедем, күкрәгемдә юк җаным,
Алдашып булса да мин эләктерим изге ат.
Калтырыйм дер-дер килеп, юк бит эчемдә утлы гамь,
Һич күңел кузгалмый, үлгән, атсалар да туп белән.
Дүрт ягым якты да бит, күрми, әбынам, күзләрем,
Һич тәэсир итми татарга, көлеп әйткән сүзләрем.
Ну шундан соң аптырыйм да, үксеп-үксеп егълыймын.
И ходай! Миңа, димен... ник бирмисең талант, димен...
Мөнри абзарда сыер, ник мөнри, аһ, ник күз кыса,
Күп ашарыма минем дип, ник мине ул ваксыта?..
Син дә, ат, бик эреләнеп, кешнәп мине әрнетмәле!..
Кил, минем күк ач торып күр! Шунда таныpсың дөньяны.

Әмма, Сәйфи Кудашның үз истәлекләренә караганда, Ш. Бабич бу пародияне кабул итми. Моны бер генә сәбәп белән аңлатырга мөмкин. Ул үзе дә бу әсәрен Габделхак Байчурин дигән шагыйрьнең «Тормыш» газетасында (1916, 9 март, 429 сан) басылып чыккан шигыренә ярым-пародия рәвешендә иҗат иткән. Г. Байчурин әсәренең исеме дә «Караңгылыкта» дип атала. Аның текстын тулысынча китерәбез.

Мин чыгам киң дөньяма, һич күренми бер яктылык,
Киң фәза сүнгән бөтенләй, каралган киң зур болыт.
Һич күренми якты йолдыз, ай, кояшның берсе дә,
Кап-караңгы барча юллар, «сеть» корылган барсына.
Кайда барыйм, кайда йөрим? Күрмимен дим яктылык,
Кайда карыйм, анда «золмәт», анда «вәхшәт», шахшылык.
Кайда бассам, зур чокырлар туп-тулы яшь, кан белән,
Аһ, кыен тулган җиһан кансыз сугыш, бәрелеш белән.

Бәхетем *(106 бит)*.— «Сүз» газетасының (Мәскәү) 1916 ел 15 май 55 санында басылган. Соңрак шагыйрьнең өч сайланма җыентыгында да урын алган.

Текст «Сүз» газетасыннан алынды.

Әллә алла, әллә иблис *(107 бит)*.—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.
Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Кем өчен *(107 бит)*.— «Ярдәм мәҗмугасы»ның беренче китабында (Казан, 1921) басылган. Бу шигырь шулай ук 1931 елда Мәскәүдә чыккан «Сборник татарской литературы» дигән китапта С. Олейндр тарафыннан русчага тәрҗемә итеп бастырылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.
Текст «Ярдәм мәҗмугасы»ннан алынды.

Яз тасвиры («Котормыш»тан) *(108 бит)*.— «Кармак» журналының 1916 ел 8—9 саннарында (1 май) «Шөбшә» имзасы белән басылган. Ике башкортча сайланмага да кертелгән.
Текст «Кармак» журналыннан алынды.
Бу әсәр С. Сүнчәләйнең «Тормыш» газетасында (1916 ел, 1 апрель) басылган шигыренә пародия рәвешендә язылган.
«Тормыш»тагы текстны тулысынча китерәбез.

Шигырь

Нурлы яз! Сөенечле яз! Балкый кояш! Мин шатланам.
Аһ, сагынганмын кояшны! Мин кояшка талпынам.
Гөрлиләр моңлы күгәрченнәр, ташулар гөлдери.
Язга сөенеп мәгъсумә кызлар урамнарда йөри.
Мәгъсумә кызлар белән мин һәм урамнарда йөрим,
Ямьле хиссият белән мин, санкә шөгълә калтырыйм.
Шат кояшның нурларында вә күренекле Уфа,
Тетри кальбемдә гөфү, аһ, интифа, рушан сафа!
Йә, илаһи, нинди күркәм, дим, хәят — хезмәт итеп,
Хак итеп һәм нурлы икбальдә бәхет — рәхмәт итеп.

Мунча рәясе — рәя боткасы («Котормыш»тан) *(109 бит)*.— «Кармак» журналының 1916 ел 8—9 саннарында (1 май) «Шөбшә» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.
Бу әсәр С. Сүнчәләйнең «Тормыш» газетасында (1916 ел, 1 апрель) дөнья күргән «Шигырь» әсәренә пародия итеп язылган.
«Тормыш»тагы текстны тулысынча китерәбез.

Шигырь

Канлы сугышлар бетәр. Михнәтле рәя күк үтәр.
Таң туар, балкыр кояш нурлар сачеп. Гөлләр үсәр.
Ямь-яшел мәгъсум чирәмгә чорналыр һәммә кабер,
Нуха, ләгънәт булмасын. Кайгы — авыр. Хәсрәт матур.
Дөнья шатлыгы, үлем изге. Хәят — хактан бүләк.
Моңлы каберстанда һәм шат багда һәм әлвән чәчәк.
Онытылыр михнәтле рәя. Рәя — бер ан. Ул үтәр.
Таң туар. Балкыр кояш. Бәйрәм булыр, гөлләр үсәр.

Гөл чәчәкләре *(110 бит)*.— 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. 1923 елда Казанда чыккан «Көрәш җырлары» (Төзүчесе Фәтхи Бурнаш) китабына һәм шагыйрьнең өч сайланмасына кертелгән.
Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Каз бәбкәләре *(112 бит)*.—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. 1925 елда Мәскәүдә чыккан «Ш. Бабич шигырьләре» җыен-

тыгына һәм шагыйрьнең үз сайланмасына кертелгән. Татарча сайланмада (Казан, 1958) бу шигырь 1917 елгы әсәрләр белән бирелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Читлектәге сандугач янында *(114 бит).*— «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның беренче китабында (Казан, 1921) басылган. Шагыйрьнең үз сайланмасына да кертелгән.

Текст «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ннан алынды.

Тын төн (авылда) (115 бит).— «Шура» журналының 1916 ел 16 санында басылган. Соңрак шагыйрьнең үз сайланма җыентыгында да урын алган.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Бу шигырь шагыйрьнең туган авылы Әсәндә, Мөхәммәтзакир хәзрәт Бабичның данлыклы бакчасында язылган булса кирәк. Биек мәһабәт агачлар, якындагы чишмә, елга, ат юлы, елга аръягы — барысы да шушы авыл күренешләре.

Мин ятамын шул тынлыкны уйлый-уйлый — Бабичлар бакчасында үскән биек агачлар арасында зур бишек эшләнгән була. Авылдашларының истәлекләренә караганда, Шәехзадә Бабич авылга кайткан вакытта, төннәрен шунда үткәрә торган була. Әлеге шигырь шундый кичләрнең берсендә иҗат ителгән, күрәсең.

Ясигъ — төнге намаз вакыты.

Көфү түгел *(116 бит).*— «Шура» журналының 1916 ел 12 санында басылган. Соңрак шагыйрьнең үз сайланма җыентыгында да урын алган.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Хәлемездән бер күренеш *(116 бит).*— «Шура» журналының 1916 ел 12 санында басылган. Үз сайланмага да кертелгән. 1958 елгы башкортча сайланмада икенче строфа түбәндәгечә алынган:

Бабайзар һәрмәләй,
Малайзар үрмәләй,
Телдәр — бейәләй,
Танаузар — Һималай!

Шагыйрьнең үз сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Һималай — тау исеме.

Яшь шагыйрьгә *(117 бит).*— «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның беренче китабында (Казан, 1921) басылган. Шагыйрьнең үз сайланмасына да кертелгән.

Текст «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ннан алынды.

Сонги тәңреләр ясап, ялганлый алмасын самириләр — Самириләр — Палестинадагы яһүд кабиләләреннең берсе. Дини легенда буенча, Муса пәйгамбәр Сина ярымутравындагы Тур тавына алладан «Тәүрат» алырга киткән арада, самириләр алтыннан бозау сынлы «сонги тәкре» (ясалма алла) ясап, яһүдләрне шуңа табындырганнар имеш.

Яшәсен кыйммәтчелек *(118 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 12—13 саннарында (1 июль) «Шөбшә» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең үз сайланмасына да кертелгән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

«...Яшәсен кыйммәтчелек!— дип сикерә, ыргый бай халык.— Шагыйрь монда, беренче бөтендөнья сугышы нәтиҗәсендә килеп туган кыйммәтчелектән файдаланып, баеп ятучы Уфа байлары, руханилары хакында яза. Журналның шул ук санында Ш. Бабичның шундый хәбәре дә басылган:

«Уфа.— Кыйммәтчелек мөнәсәбәте белән Җинаять (Гыйнният кадый хакында сүз бара.— *Г. Г.*) абзый имтиханга килгән шәкертләрдән ала торган калогларны арттырырга карар бирде».

«Менә әле генә Каф тавыннан...» *(119 бит).*— 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Г. Ибраһимов тәкъдим иткән бу вариантта ике шигырь кушып бирелгән кебек. Беренче җиде строфа белән соңгы биш строфа арасында берниндн мәгънәви уртаклык та юк. Өстәвенә, соңгы өлеш шагыйрьнең «Газазил» әсәренең дәвамын тәшкил итә кебек:

Менә әле генә Каф тавыннан,
Җен дөньясын иттем тамаша!..

Бу әсәр 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алып 1923 елны Ф. Бурнаш тарафыннан төзеп чыгарылган «Кәрәш җырлары» җыентыгына, соңрак шгыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Каф тавы — Кавказ таулары.

Мәгърифәт сатучыга! *(120 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 14—15 саннарында (1 август) «Кара күз» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Кыз (Фәтүә) *(121 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 14—15 саннарында (1 август) «Шөбһә» имзасы белән басылган. Ике башкортча сайланмага да кертелгән. Башкортча җыентыкларда бишенче строфадагы «татарлар» сүзе урынына «кешеләр» дип бирелгән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Кызык бетте *(122 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

«Белә, Мәхмут...» *(122 бит).*— Ш. Бабич бу шигырен дә 1916 елның ахырларында иҗат иткән һәм аны дусты М. Бәдәйлигә багышлаган. Бәдәйли югарыда телгә алынган истәлегендә түбәндәгеләрне яза: «Типография хуҗасы Сосновскийның начар мөгамәләсе, синс кешегә дә санамый, кәпрәеп йөрүләре Г. Тукай Троицкига килгәч, аның белән күрешергә җибәрелмәгән чактагы җанымның әрнү-ачынулары, хуҗа алдында һәрберебезнең калтыранып торулары...— шундый хисапсыз түбәнлек, хурлыклар искә төшеп, мин дә тормышка яңадан кайтудан котым чыгып йөри идем. Ә Бабич миңа: «Һөнәрең бар!» — ди. Мин шуларны әйтеп зарлангач, ул миңа шигырь белән болай диде:...» (Кара: «Совет әдәбияты», 1965 ел, 1 сан.)

Текст М. Бәдәйли истәлегеннән алып кертелде.

Гаед узгач *(123 бит).*— «Тормыш» газетасының 1916 ел 27 июль санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Тормыш» газетасыннан алынды.

Гаед корбан *(124 бит).*— «Тормыш» газетасының 1916 ел 24 сентябрь санында басылган. Моңа кадәр аңа З. Искужин гына игътибар иткән.

Шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

Саҗидәгә *(125 бит).*—1916 елның ахырында Троицк шәһәрендә яшәүче Саҗидә Әдһәмованың альбом дәфтәренә язылган. Саҗидә Әдһәмова — тәрҗемәче һәм хикәяләр, күптөрле истәлекләр авторы буларак билгеле Сәрвәр Әдһәмованың сеңлесе. Соңыннан әдәбият укытучысы.

Троицк шәһәрендә укыткан вакытта Ш. Бабич Әдһәмовлар гаиләсе белән якыннан таныш була, берара аларда торып та китә. Соңрак та шагыйрь Сәрвәр, Саҗидә янына кич утырырга керә, аларга үзенең яңа әсәрләрен укый. «Саҗидәгә» шигыре шундый кичләрнең берсендә язылган. Әсәр «Совет әдәбияты» журналының 1957 ел 1 санында «Сәрвәр сеңлесе Саҗидәнең альбомына» дигән исем астында басылган. 1958, 1985 елгы башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст «Совет әдәбияты» журналыннан алынды.

Тешсез кыз *(126 бит).*— «Һәнәк» журналы (Уфа) редакциясендә машинистка булып эшләүче Фәрхия Хөсәенова тапшыруы буенча 1958 елда Уфада чыккан «Сайланма әсәрләр»дә басылган. Бабич Троицк шәһәрендә чакта, Фәрхия Хөсәенова егетләрчә киенеп, сәхнәгә чыгып, бу шигырьне татарча яттан сөйләп йөри торган булган.

Шигырь башкорт телендәге сайланмадан алынып, татарчага тәрҗемә итеп бирелде.

«Әсма» китабындагы шигырьләрне тәхмис *(127 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 19—20 саннарында (1 ноябрь) басылган. Өч сайланмага да кертелгән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Тәхмис — нинди дә булса шигырьнең икешәр юллы строфаларына өчәр юл өстәп, биш юллы строфа төзеп язу. 1903 елда Оренбургта Риза Фәхретдиневнең «Әсма» исемле романы басылып чыккан, анда Дәрдмәнднең «Үткән көннәр» исемле шигыре китерелгән. Шул шигырьнең һәр строфасына өчәр юл өстәп, ягъни тәхмисләп, Бабич аңа бөтенләй яңа мәгънә биргән.

Мәсәлән, Дәрдмәнд шигыре болай башлана:

Әй, кайда ул көн, ки бездә шәп торулар бар иде:
Әмма дошманнарда гамьнәр, эч пошулар бар иде.

Шушы ике юл арасына тагын өч юл өстәп, Бабич пародия иҗат иткән.

Әсәр 1958—1985 елгы башкортча сайланмаларда И. Насыйри кульъязмаларыннан алып басылган. Анда журнал тексты белән чагыштырганда кайсыбер текстологик аермалар бар. Мәсәлән, икенче бишьюллыкның беренче юлында «кырга» сүзе артыннан «да», дүртенче юлында «идек» сүзеннән соң «ду» өстәп язылган.

Ш. Бабичның бу әсәрен нигез итеп, башка шагыйрьләр дә «тәхмисләр» иҗат итә башлыйлар, мәсәлән, шул ук «Кармак» журналының 1917 ел 1—2 саннарында (1 январь) Г. Ченәкәйнең «Тәхмис» исемле шигыре басылып чыга.

«Кызыл башлар», «дюшеслар»...—шагыйрь яшәгән чорда киң билгеле шәраб исемнәре.

Закир — Закир Садыйк улы Рәмиев (Дәрдмәнд, 1859—1921) — күренекле татар шагыйре. «Әсма» китабында басылган «Үткән көннәр» шигыренең авторы.

Шатлык кәтәм *(128 бит).*— «Шура» журналының 1916 ел 19 са-

нында басылган. Соңрак шагыйрьнең өч сайланма җыентыгында да урын алган.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Ул *(129 бит).*— «Ташланган вәрәкаләр» циклы эчендә «Кармак» журналының 1917 ел 4 санында «Шөбшә» имзасы белән басылган. Кудаш бу әсәрне 1916 елга нисбәт итә һәм аның шул елның 20 декабрендә, шагыйрь «Галия» мәдрәсәсенең 10 еллык юбилеена килгән чорда язылган дип саный. (Кара: «Агизел», 1958, 8 сан, 65 бит.) Бу шигырь шагыйрьнең бер җыентыгына да кертелмәгән. Сәбәбе: әсәрдәге кайбер юллар Ш. Бабичның башка әсәрләрен хәтерләтәләр, аларга юллары-юллары белән тәңгәл киләләр. Мәсәлән:

«Ул»:

Йөзләре ал, таңга мәйял... битләре — бит солтаны,
Аузы зәмзәм, ирне кәүсәр, күкрәге — сөт вулканы.

«Исемнәр бакчасы»:

Сылубикә, сылу туташ, кыз солтаны,
Бит уртанда кара миң бар — бит чулпаны;
Аузың зәмзәм, ирнең кәүсәр, тешең гәүһәр,
Калку түшең — тигез җирдә сөт вулканы.

Әсәр җыентыкка, «Ташланган вәрәкаләр» циклыннан алынып, 1916 елгы шигырьләр белән бергә урнаштырылды.

Кандала (баллада) *(130 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 19—20 саннарында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Баллада шулай ук 1936 елда «Совет әдәбияты» журналының 5 санында да дөнья күргән. Бу текст журналга З. Искужин тарафыннан тәкъдим ителгән булырга тиеш. Архив материаллары буенча, аның бу әсәрне бастыру өчен хәзерләве мәгълүм.

Әсәрнең язылу тарихына кагылышлы шундый истәлек саклана. 1916 елның язында «Галия»не тәмамлаганнан соң, торыр урыны булмаган Бабич еш кына Мәүгузә Кәримоваларның Пушкин урамындагы фатирларына килеп кунып йөри. «Мәүгузә әбинең сүзенә караганда, аның фатирлы өе кандалага бай булган. Бабич, кандала талауга түзә алмыйча, төндә урле-кырлы сикерә икән. Менә шулвакыт ул шушы өйдә, кандаладан талана-талана, үзенең «Кандала» исемле балладасын язган. Мәүгузә карчык үзе үлгәнче шуның белән мактанып яшәде, мәрхүмәң!» — дип хәтерли Сәйфи Кудаш (С. Кудаш. Тәүге танышуым.— «Агизел», 1965, 1 сан).

Әлбәттә, «Кандала»ның туу җирлеге күпкә киңрәк һәм заманның кискен социаль каршылыкларын чагылдыра.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Дөлдөл — мифик ат.

Хозыр Ильяс — дини мифологиядә дөнья бектәнче үлмичә яши торган, яхшылыкка — яхшылык, яманлыкка яманлык белән җавап кайтаручы. Христианнарда — Илья пророк.

Җен, пәри, албастылар — халык мифологиясе геройлары.

«Исме Әгъзам» — дини китап исеме.

Балкан — бу әсәр язылган вакытта Балканда барган сугышлар күздә тотылса кирәк.

Газазил *(136 бит).*— «Аң» журналының 1916 ел 15 санында басылган. Бераздан шагыйрь бу әсәренә кабат әйләнеп кайта һәм аның тулырак вариантын эшли. 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»на шушы

соңгы варианты урнаштырылган. Шул ук җыентыкта, поэма текстыннан соң, түбәндәге аңлатма урнаштырылган.

«Искәрмә:

«Газазил»нең беренче бүлеге шуның белән тәмам. Икенче бүлек хәзер кулда юк. Бунын мөндәриҗәсе: Ахыр сүзләрендән дә аңлашылганча, Иблиснең юбилеен тасвирдан, шул хакда шагыйрьнең анда күргәннәрен докладтан гыйбарәт булачак.

Г. И.»

«Г. И.» — Галимҗан Ибраһимов.

Шунысы игътибарга лаеклы, «Аң» журналында әлеге поэма басылып чыккач, «Кармак» журналының 1917 ел 3 санында «Кылыч»ның (Сәйфи Кудашның псевдонимы) «Газраил» («Аң»нан) исемле пародик шигыре дөнья күрә. Менә ул:

Шагыйрь бит син үзең, шаның бөек,
Кардәш сиңа илче шайтан, җен;
Юк талантган шигырь язуыңнан
Бармы икән берәр туяр көн?

Аз булса да башта мие барлар
Тел тидерми шәриф затларга,
Ул сүзләрне әйтми надан татар,
Тиеш сиңа әдәп сакларга.

Һичбер инсаф юкмы әллә синдә, —
Мәңге шулай тупас торасың?
Уйлап кара, шагыйрь, вөҗданыңа
Тар кабердә ничек чыдарсың?

«Газазил» поэмасы шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән. Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Газазил — күк фәрештәсе, җиргә сөрелгәнче Иблис шулай аталган.

Иблис — дини мифологиядә шайтаннар башлыгы, аллага каршы баш күтәргәне өчен мәңгегә ләгънәтләнгән.

Җабраил — дини мифологиядә алла белән пәйгамбәрләр арасында йомышчы ролен үтәгән Җабраил (Җибрил) фәрештә изге кешеләрнең рухларына «күк капусын» (капкасын) ача; күк җиде кат булып, анда чыга торган капкалар сигез, имеш.

Газраил — дини мифологиядә җан алучы фәрештә.

Фирдәвес — дини мифологиядә оҗмах, җәннәт.

Вилдан — дини мифологиядә оҗмах хезмәтчесе.

Җәббар — дини мифологиядә кодрәт иясе.

Савия — дини мифологиядә җәһәннәм төбе.

Фитрәт — дини мифологиядә ике пәйгамбәр арасындагы чор.

Имам — мәчеттә намазны башлап алып баручы кеше, мулла.

Инҗил — Гайса пәйгамбәргә нисбәт ителгән дини китап.

Кыямәт — мөселманнарның ышануынча, үлгәннән соң яңадан терелү, хисап бирү көне.

Пәри — җеннәрнең матур, гүзәл төрләреннән бер вәкиле, халык мифологиясендә.

Дозах — дини мифологиядә тәмуг.

Хур-гайнәр — дини мифологиядә оҗмахтагы хезмәтче кызлар.

Мәхшәр — дини мифологиядә дөнья беткәннән соң (кыямәт көнендә) кубарылып чыккан барлык җан иясенең җыелу урыны, көне.

Тәәззәл — дини мифологиядә дөнья яратылу шулай дип йөртелә.

Каф тау — Кавказ таулары (легендаларда — мифик тау).

Төште ул зат җиргә: ул бер кош икән — дини легенда буенча, Җәбраил җиргә ак кош кыяфәтендә төшеп йөргән.

Хаузы кәүсәр бакчасы — дини мифология буенча, җәннәттәге тәтлы сулы чишмәсе булган бакча.

«Абелхәят» — дини мифология буенча, оҗмахтагы чишмәдән алынган «мәңгелек суы», «тереклек суы».

Җәлеп итәм Муса Ярулла дикъкатен — сүз Муса Ярулла улы Бигиев (1873—1949) хакында бара. Петербург мулласы, дин философы, либераль-буржуаз идеологларының берсе, Октябрь революциясеннән соң эмигрант. Бу рухани Тукай чорында ук, Коръәндә ялгышлар бар, төзәтергә кирәк, дип, матбугатта зур тавыш күтәрә. Тукай аңардан: «Безнең Муса һич тик тормас: ялгыш тапкан Коръәннән», — дип көлә («Яшен», 1909 ел, 2 март (7) саны).

Ш. Бабич та үз поэмасында, Иблистән урланган «Тереклек суы» аша, дини өйрәтмәгә пародия биреп, Муса Бигиевнең «хата эзләүчәнлегенә» ишарә итә.

Мөнкир вә диндыйкъ — дини мифология буенча, алланы танымаучылар.

Дәһри — дини мифологиядә алласызлар шулай аталып йөртелә.

Юлда уйнап барды Иблис «каз муенын» — Иблиснең думбра яисә мандолина уйнап баруына ишарә.

Сур — быргы кебек музыка уен коралы.

Нәгъра орды, сур кебек бер торбадан... — дини мифология буенча, кыямәт көне җиткәч, Исрафил фәрештә сур (мөгез, быргы) өрәчәк (кычкыртачак) һәм барлык үлгән кешеләрне, алла алдында хисап бирү өчен, каберләреннән торгызачак имеш. Бабич үз поэмасында шуңа пародия бирә.

«Марсельеза» — революцион җыр. Франциянең дәүләт гимны.

Әйләнеп кайтырга язсын бер хода... — Г. Ибраһимовның язуы буенча, Ш. Бабич поэманың икенче кисәген иҗат иткән. Әмма безгә аның кайбер өзекләре генә килеп җиткән. Аерым алганда, шагыйрьнең алдагы сайланмаларында «Үткән көннәр» исеме астында кертеп йөртелгән шигырьнең:

Менә әле генә Каф тавыннан
Җен дөньясын иттем тамаша,—

дип башланган икенче яртысы «Газазил» поэмасының дәвамы булырга тиеш.

1917

Көтәләр *(157 бит)*.— «Кармак» журналының 1917 ел 1—2 саннарында (1 январь) «Щөбшә» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

С. Кудаш әсәрнең тарихына бәйләнешле мондый бер истәлек китерә: «Бабич белән җырчы Газиз Әлмөхәммәтов концерт бирергә әзерләнә башладылар. Бу вакытта Троицкидан Уфага килгән Бабич Галимҗан Ибраһимовның Пушкин урамындагы квартирасында тора иде. Галимҗан Ибраһимов үзе Бөрегәме, Бәләбәйгәме командировкага киткәнгә күрә, бу вакытта квартира аулак һәм тыныч иде... Үзләренең концертлары буласы көндә ул шушы бүлмәдә миңа бер китап тоттырды да:

— Син миңа карама һәм сүз кушма, менә шушы китапны актарып утыр. Мин башлаган бер шигыремне бетереп алыйм, — диде.

Бабич үзенә карамаска кушса да, күз йомып утырырга мөмкин түгел иде. Ул бу минутларда урындыкка утырмады. Йөреп килә дә өстәлдәге кәгазьгә язып китә. Шулай йөри-йөри яза торгач, ул:

— Булды, давай тыңла! — дип кычкырып җибәрде. Шулай аяк өстендә язылган «Котләр» дип аталган бу шигырьне Бабич, газетага биргәнче, шул көн кичке концертта үзенә хас осталык белән сөйләп алкыш алды» (С. Кудаш. Хәтердә калган минутлар. Казан, 1957 ел, 78—79 битләр).

Газраил — дини өйрәтмә буенча җан алучы фәрештә.

Жабраил — илче фәрештә.

...Җир йөзендә инде күп ил мир котә... — Сүз монда беренче бөтендөнья сугышы алып килгән афәтнең соңгы чиккә җитүе, илләрнең бу фаҗигага түземлеге калмавы турында бара.

Кайберәуләр, шатланып, сил өстенә мең сил котә. — Бай сыйныфлар, сугыш чорындагы җитешсезлекләрдән файдаланып, һаман баюга табан баралар. Шуңа күрә сугыш озаграк, хәтәррәк булган саен, алар өчен табыш арта гына. Шагыйрь шуңа ишарә итә.

...Герман тилмереп, мәңге тынычлык — мир котә... — Шагыйрь бу очракта канкоюлы сугышны немец солдатлары өчен дә бер җәфа булуына ишарә итә.

Өзеләсең дә сызыласың *(158 бит).* — «Аң» журналының 1917 ел 1 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Аң» журналыннан алынды.

Зәфәргә *(159 бит).* — Хатип Госман архивындагы күчермәләрдән алынды. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

Мөсәххих һәм наборщикларга *(160 бит).* — «Кармак» журналының 1917 ел 3 санында (1 февраль) «Шөбшә» имзасы белән басылган. Өч сайланмага да кертелгән. 1958 елны башкортча сайланмада икенче строфада «тезү» урынына «җыю» алынган, алтынчы строфаның өченче санында «тә» төшеп калган. 1985 елгы башкортча сайланмада әсәрнең исеме «Мөсәххих һәм наборщиклар» дип алынган һәм алтынчы строфаның өченче юлында «Әшгар» сүзе «шигырьләр» итеп үзгәртелгән.

Әсәр иҗат ителгән чорда Ш. Бабич Троицкида Таҗетдин Рахманкулов дигән журналист белән бергә «Хөр милләт» исемле газета чыгарып йөриләр. Бу шигырь шул көннәрнең хатирәсе булып калган, күрәсең.

Шакирҗан Әттәкави — Сүз, белеме-мәгълүматы аз булса да, матбугатта күтәрелгән һәр мәсьәләгә тыгылырга яраткан Шакирҗан Хәмиди («Борадәран Кәримевләр» матбагасында корректор) турында бара.

Ташланган вәрәкалар *(162 бит).* — «Кармак» журналының 1917 ел 4 санында (15 февраль) «Шөбшә» имзасы белән басылган. Өч сайланмага да кертелгән.

Текст «Кармак» журналыннан алынды.

Бу шигырьләр циклын шагыйрь 1916 елның декабрендә һәм 1917 елның январь айларында Троицк шәһәреннән Уфага «Галия» мәдрәсәсенең унъеллык юбилеена килгән чорда иҗат итә, шуңа күрә дә кайбер тикшеренүчеләр бу шигырьләрне 1916 елга да кертеп карыйлар (мәсәлән, З. Искужин). Башкорт халык шагыйре Сәйфи Кудаш та бу әсәрләрне 1916 елның 20 нче декабрьләрендә, шагыйрьнең «Галия» тантанасына килгән вакытында язылган дип саный. (Кара: «Агизел», 1965,

8 сан, 65 бит.) Ихтимал, «Поездда» дигән шигырь 1917 ел башында, Бабич бәйрәмнән соң Троицкига кайткан вакытта, поездда язылгандыр. Тегәд мәгълүматлар булмау сәбәпле һәм циклның бөтенлеген саклау максатыннан, аның язылу датасы 1917 ел белән билгеләнде.

Вәрәкаләр — кәгазьләр дигән мәгънәне белдерә. 20 нче йөз башы татар әдәбиятында шигъри цикллар да еш кына шулай аталган.

«Аң» — 1912 елның 15 декабреннән 1918 елның башына кадәр Әхмәтгәрәй Хәсәни (1883—1938) редакторлыгында, Тукай, Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовларның актив катнашлыгында Казанда (барлыгы 113 сан) чыккан «Әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый, рәсемле журнал».

«Ялт-йолт»—1910—1918 елларда Казанда Ә. Урманчиев (?—1922) редакторлыгында һәм наширлегендә чыккан рәсемле сатирик журнал.

Җабраил — дини өйрәтмә буенча, илче фәрештә.

Кышка керсә...— Бу юллар шигырьнең 1916 елның декабрь, 1917 елның январь айларында язылган булуына ишарә итәләр.

Тәмсил кисәге *(164 бит)*.— 1917 елның апрелендә Ш. Бабич үз катнашлыгында чыккан «Хөр милләт» газетасында басылган һәм шул көннәрдә үк Троицк шәһәрендә чыккан «Хөррият бүләге» җыентыгында урын алган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Хөррият бүләге» җыентыгыннан алынды.

Хөррият бүләге *(165 бит)*.—1917 елда Троицкида чыккан «Хөррият бүләге» җыентыгында һәм «Хөр милләт» газетасында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Хөррият бүләге» җыентыгыннан алынды.

Яшәсен эшчеләр! *(167 бит)*.— Беренче тапкыр «Хөр милләт» газетасында басылган. Моннан тыш бу әсәр түбәндәге җыентыкларга кертелгән: 1917 ел, март хатирәсе. В. Хәлим, С. Кудашев, Ш. Бабич шигырьләреннән тәртип ителде. Нашире һәм мөхәррире — Вәлиулла Хәлили. Кустанай, 1917; Ш. Бабич. Шигырьләр мәҗмугасы. Казан, 1922; Көрәш җырлары (төзүче Ф. Бурнаш).— Казан, 1923; Ш. Бабич шигырьләре. Мәскәү, 1925; Ш. Бабич. Сайланма әсәрләр. Казан, 1958; Ш. Бабич. Сайланма әсәрәәр. Өфө, 1958; Ш. Бабич. Шигырзар. Поэмалар. Өфө, 1985.

Котлау, теләк *(169 бит)*.— И. Насыйри күчермәләреннән алынып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Шигырь астына Ш. Бабич тарафыннан «Яхшы имтихан биреп, алгы сыйныфка күчкән туташка» дип язып куелган. Әсәр шагыйрьнең Троицкидагы таныш кызы Сәрвәр Әдһәмованың алгы сыйныфка имтихан биреп чыгуыннан соң язылган. Сәрвәр Әдһәмова үзе түбәндәгечә искә ала: «1917 елның язында мин Троицкидагы рус кызлар гимназиясенә 5 нче класска керер өчен имтихан бирергә бардым. Бабич, мине озата барып, юл өстендәге шәһәр бакчасында утырып калган иде. Бер-ике сәгатьтән соң, инде имтихан бирү шатлыгыннан башым күккә тиярдәй булып кайтышлый бакчага керсәм, ни күзем белән күрим, ул һаман шул хәлендә утыра. Мине күрүгә, урыныннан сикереп торып:

— Тәбрикләргәме?— дип, ике кулын берьюлы сузып, кулымны кысты да куен кесәсеннән дүрткә бөкләп төргән кәгазь чыгарып бирде.

Ул кәгазьдә шәмәхә карандаш белән хәрефләре энҗе кебек тезелгән (язуы бик матур иде Бабичның) шундый бер шигырь язылган иде...» (Сәрвәр Әдһәмова. Тормыш сынавы. Казан, 1979, 95—96 битләр).

Текст С. Әдһәмова истәлегеннән алынды.

Уйлар уртасында *(170 бит)*.— И. Насыйри һәм З. Искужин күчермә-

ләреннән алынып, шагыйрьнең моңа кадәр басылып чыккан сайланмаларына кертелгән.

Текст З. Искужин күчермәләреннән алынды.

Әй, Әфләтун *(170 бит).*—1917 елның 29 июлендә Ш. Бабич белән Җ. Юмаев С. Кудашның туган авылы Келәшкә кайтып төшәләр. Шунда алар авылда «әкият капчыгы» дип йөртелә торган Әфләтунов Нурмөхәммәт исемле бер егетне очраталар. Соңыннан алар бергәләп кырларга да чыгып йөриләр (С. Кудаш. Безнең авылда.— «Агизел», 1975, 7 сан, 72—74 битләр).

Текст С. Кудаш истәлегеннән алынды.

Мәхәббәт тоткыны *(171 бит).*— «Аң» журналының 1917 ел 5 санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Бу әсәрнең язылу тарихы хакында Бабичның Троицкидагы танышы С. Әдһәмова: «Бер тапкыр почта уйнаганда миңа:

Күбәләк дип кистерәлмим, сандугач тик тавышы бар,

Сандугачкай һич дия алмыйм — күбәләктәй рәвеше бар,— дип башланган 12 юллык шигырь язып җибәрде»,— дип искә ала (Сәрвәр Әдһәмова. Тормыш сынавы. Казан, 1979, 84 бит).

Текст «Аң» журналыннан алынды.

Күбәләк вә мин *(172 бит).*— «Аң» журналының 1917 ел 6 санында басылган, 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда соңгы строфа «Мин дә, дустым, күбәләк бит...» дип башланып китә. Шагыйрьнең өч сайланмасына да «Аң» журналындагы вариант кертелгән.

Текст «Аң» журналыннан алынды.

Табигать оҗмахы (Мәхәббәт) *(173 бит).*— 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Матур сыннар *(174 бит).*— 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Әкълимәгә *(175 бит).*— Укытучы-пенсионер Әкълимә Мостафина тапшыруы буенча 1958 елда Уфада чыккан сайланмага урнаштырылган. Бу әсәрне шагыйрь, Ә. Мостафинага багышлап, аның альбомына Уфада 1917 елның 13 июлендә язган.

Гаед көне *(176 бит).*— «Ирек» газетасының 1917 ел 7 июль (№ 27) санында басылган.

Текст «Ирек» газетасыннан алынды.

Дим буе җырлары *(177 бит).*—1917 елның июнь көннәрендә дуслары белән Дим буена төшкән Бабич җырлап йөргән җырлар (С. Кудаш. Күккә үрләгән еллар.— «Агизел», 1965, 7 сан, 71 бит).

Текст С. Кудаш истәлегеннән алынды.

Мәхәббәт җырлары *(178 бит).*—1917 елның июль ахырында Келәшкә кайткан чакта Бабич тарафыннан җырланган җырлар (С. Кудаш. Безнең авылда.— «Агизел», 1965, 7 сан, 74 бит).

Йә әййеһәл мөселман *(179 бит).*— Бу шигырь, 1917 елның 25 июлендә язылып, шул ук көнне Бабич тарафыннан сәхнәдә сөйләнгән (С. Кудаш истәлеге буенча.— «Агизел», 1965, 81 бит).

Башкорт галиме Равил Бикбаев исә, И. Насыйри күчермәләренә карап, әсәрне 1915 елга нисбәт итә. Ул язмаларда шигырьнең исеме дә «Пайоһаннас» дип аталган (Р. Бикбаев. Шәйхзада Бабич. Тормошо һәм ижады. Өфө, 1981, 99—100 битләр).

Әмма И. Насыйри карамагындагы текст Х. Госман архивыннан алынган һәм 1915 елга нисбәт ителгән текстның бер өлеше генә. С. Кудаш истәлегендәге текст исә 1915 елгы шигырьнең бер варианты итеп карарга хаклы.

Текст С. Кудаш күчермәләреннән алынды.

Утрау (Тәмсил) *(181 бит)*.— Әсәр беренче мәртәбә шагыйрьнең 1918 елда Оренбургта «Тулкын» нәшриятында басылып чыккан «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») исемле китабында урын алган. З. Искужин архивында саклануча нөсхәдә әсәрнең язылу елы «1919 ел, июнь» дип билгеләнгән.

Текст шагыйрьнең сайланма җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

Җанкаем! *(185 бит)*.— «Аң» журналының 1918 ел 1 санында басылган. Өч сайланмага да «Ярдәм мәҗмугасы»ның икенче китабыннан (1922) алып, «Җан» («Йән») исеме белән кертелгән.

Текст «Аң» журналыннан алынды.

Байларга *(180 бит)*.— «Ирек» газетасының 1917 ел 7 июль (№ 27) санында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Ирек» газетасыннан алынды.

Мөртәт социалистларга *(187 бит)*.— И. Насыйри күчермәләреннән алынып, башкортча сайланмаларга кертелгән. З. Искужин язмаларында бу әсәр «Мөртәт социалист» дип билгеләнгән.

Текст З. Искужин күчермәләреннән алынды.

Мөртәт социалист — Ш. Бабич бу очракта ренегат социалистларны күз уңында тота.

Солдатка алынган бер дустыма *(188 бит)*.— Биш ел бергә «Галия» мәдрәсәсендә укыган дусты Хәернас Хәбиров сугышта үлеп калгач, иптәшләренә Бабич: «Мин «Солдатка алынган дустыма» исемле шигырь яздым. Аны тиз көндә берәр газетада бастырып та чыгарам әле. Аның һәлак булуы хәбәрен ишеткәч, мин ничә көн буе үземне кая куярга белмичә газапландым»,— дип сөйли һәм бу шигырь «Солдат теләге һәм Уфа мөселман гаскәрләре турасының хәбәрләре» дигән газетада 1917 елның 31 июлендә басыла (Р. Бикбаев. Шәйхзада Бабич. Тормошо һәм ижады. Өфө, 1981, 219 бит). Башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст «Солдат теләге» газетасыннан алынды.

Беренче номерлы список *(189 бит)*.— «Ирек» газетасының 1917 ел 7 июль (№ 27) санында «Эшче туганың» имзасы белән басылган. Башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст «Ирек» газетасыннан алынды.

Мин китер чакта *(190 бит)*.— Шигырь шагыйрьнең Сәрвәр Әдһәмовага язган хатыннан алынды. Анда шундый юллар бар: «...Шунда, почта уеньнда, Уфаның иң алдынгы, һәр җәһәттән иң өстен торган бер туташка — шәфкать туташы булып хезмәт итә — (ул туташның Җәмилә Нәфикова булганлыгын соңгы елларда гына язучы С. Кудаштан ишетеп белдем.— *С. Ә.)* көлке итеп бер нәрсә яздым. Китүем мөнәсәбәте

булганлыктан, син гаеп итмәссең дип, күңеленә таянып, шуны монда күчерәм. Мин аның черновасын алып калган идем. Менә ул...». (Кара: «Совет әдәбияты», 1957, 1 сан.)

Текст С. Әдһәмова истәлегеннән алынды.

Кил, чибәр *(191 бит)*.— «Кил, сабия» исеме астында «Аң» журналының 1917 ел 10 санында басылган. Соңрак бу әсәрнең редакцияләнгән вариантын Г. Ибраһимов 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»на урнаштыра.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Хәсрәт сагызы *(192 бит)*.— «Кармак» журналының 1917 ел 10, 11, 12 саннарында (сентябрь) «Шөбшә» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Кызыл вәгазь *(193 бит)*.— «Кармак» журналының 1917 ел 10, 11, 12 саннарында (сентябрь) «Шәрран-яра» имзасы белән басылган. «Мулла абзый!..» дип башланган эпиграммадан калганнары шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә. «Мулла абзый!..» эпиграммасы исә «Әй мулла абзый» исеме астында һәм бераз үзгәртүләр белән өч сайланмага да кертелгән. Бу шигырь моңа кадәр шагыйрьнең замандашы Габдулла Сабиров истәлекләре аша таныш иде һәм түбәндәгечә яңгырый иде.

Әй, мулла абзый, ант итәмен аллаң белән,
Ант итәмен башыңдагы чалмаң белән:
Өстән болай кеше төсле күренсәң дә,
Эчең-тышың тулы чеп-чи ялган белән!

Ш. Бабич 1916 елның җәй көннәрендә Казанда булып узган Россия мөселманнарының Икенче съездының йомгакларын тикшерү өчен Бәре шәһәрендә (хәзерге Башкортстан АССРдагы Бирск шәһәре) җыелган татар һәм башкорт буржуазиясенең җыелышына килеп эләгә һәм, протест йөзеннән, «Әй мулла абзый», «Әй большевик» кебек шигырьләрен укып чыгып китә. (Кара: Г. Сабиров. Бабич Бәредә.— «Агизел», 1961, 7 сан.)

«Милли шура»— Патша власте бәреп төшерелгәч, IV дәүләт Думасының мөселман депутатлары Петроградта Вакытлы хөкүмәт яклы Үзәк мөселман башкарма комитеты төзиләр. Мондый буржуаз Мөселман комитетлары урыннарда да төзелә. Соңыннан алар Милли шура исеме белән йөртеләләр. Октябрь революциясеннән соң, гражданнар сугышы башлангач, З. Вәлиди һәм аның иярченнәре Башкорт милли шурасын Мәркәз шура дип атый башлыйлар.

Зәкят — ислам шәригате буенча, еллык керемнең сәүдәгәрләргә кырыктан бер өлеше күләмендә салынган налог.

«Карман»дагы дәрман белән...— кесәдәге акча барысын да эшли дигәнне аңлата.

«Кызыллар»— кызыл акчалар мәгънәсендә.

Мөфти хәзрәт! Бордык бугай койрыгыңны.— Сафа Баязидовның 1917 елда эштән алынуына ишарә.

«Социалист»!.. Нигә кердең кадетларның флагына?— Монда мөртәт (ренегат) социалистлар күз уңында тотыла. Шуңа да бу сүзне шагыйрь тырнаклар эченә ала.

Әй большевик *(196 бит)*.— Шагыйрьнең өч сайланмасына да Г. Сабиров истәлеге буенча урнаштырылган. Күрәсең, Ш. Бабич «Кызыл

вәгазь» циклын артабан да дәвам иткән, әмма бастырырга гына өлгермичә калган. Кайбер галимнәрнең бу әсәрне «Кызыл вәгазь» циклына кертеп каравы дөрес булырга тиеш. (Кара: У. Гимадиев. Татарские сатирические журналы до Октябрьского периода. Методические указания по спецкурсу. «Татарские сатирические журналы (1906—1917) и вопросы теории сатиры»; «Агизел», 1961, 11 сан.)

Әй Гайдани *(196 бит)*.— Г. Сабиров истәлекләреннән алып бирелә («Агизел», 1961, 7 сан). Шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Гайдани — «Дин-мәгыйшәтче» ишан Мөхәммәт Гайдани.

Буржуй *(197 бит)*.— «Безнең юл» (Уфа) газетасының 1917 ел 22 октябрь (№ 9) санында басылган. Соңрак «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның икенче китабына (1922) һәм шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән, «Мәҗмуга»да бирелгән шигырьгә, газета текстыннан аермалы буларак, ике юл өстәлгән.

Текст «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ннан алынды.

Тупрак *(198 бит)*.— Шагыйрьнең 1918 елда Оренбургта басылып чыккан «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгыннан алынды. Шагыйрьнең 1985 елгы, башкортча сайланмасына кертелгән. Әсәрнең язылу датасы — «1917 ел, июнь».

Тупрак — башкорт бәхтедер.— Әсәр «туфрак автономиясе» («территориаль автономия») идеяләрен куәтләү йөзеннән иҗат ителгән.

Список № 9 *(199 бит)*.— «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгыннан алынды. Шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә. Әсәрнең язылу датасы — «1917 ел, октябрь».

Ошбу көндә...— Әсәргә Ш. Бабич үзе түбәндәге аңлатма-искәрмәне биргән: «Бу назым Учр. собраниегә сайлау вакытында Оренбург, Пермь губернасындагы башкордларга летучка суртында басылып таратылган иде. Уфа губернасы башкордлары 9 урынына № 11 куеп укырлар».

Кан шәүләләре *(200 бит)*.— Шагыйрьнең 1918 елда Оренбургта чыккан «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») исемле җыентыгында басылган, язылу датасы «1917 ел, февраль» дип билгеләнгән. З. Искужин язмаларында бу шигырьнең 1918 елның февралендә язылуы хакында әйтелә.

Текст «Яшь Башкордостан» җыентыгыннан алынды.

Сугыш *(201 бит)*.— «Шура» журналының 1917 ел 23—24 саннарында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шура» журналыннан алынды.

Мөхәммәт — мөселман диненә нигез салучы дип саналган Мөхәммәт пәйгамбәр (570 еллар тирәсе —632).

Үткән көннәр *(202 бит)*.—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да әсәр шул вариантында бирелгән. Әмма текст, мәгънәви яктан мөстәкыйль ике өлешкә бүленү сәбәпле, ике аерым шигырьгә таркалырга тиеш. Алты строфадан соң килгән икеюллык, чыннан да, лирик геройның хис-фикерләрен йомгаклап куя кебек. Ә инде әсәрнең соңгы өлеше билгеле «Газаазил» поэмасының дәвамын хәтерләтә. Шул сәбәпле, җыентыкта бу әсәр ике мөстәкыйль шигырь рәвешендә бирелде.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

«Кулларымда кәкре башлы...» *(203 бит).*— Тәхфәт Ченәкәй истәлеге буенча китерелә.

«...Бабич уң аяк бармаклары арасына,— дип искә ала Ченәкәй,— медиаторын кыстырып, сул кулы белән мандолинасының грифеннән тотып, аяк белән мандолина уйнап, җырлый...» («Әзәби Башкортостан», 1965, 6 сан, 70 бит).

«Әйдә, бие, бабушка» *(203 бит).*— Бу шигырь-такмаза Ш. Бабичның Оренбургта яшәгән чорында квартира хуҗасы бер рус әбиенә атап чыгарылган («Әзәби Башкортостан», 1965, 6 сан, 72 бит).

Текст Т. Ченәкәй истәлегеннән алынды.

Яшь шагыйрьнең кабер ташында укыдым *(204 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да «Яшь шагыйрьнең кабер ташында» исеме астында урнаштырылган. Башкортча сайланмаларда 1916 елгы шигырьләр рәтендә бирелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Миндә көч *(205 бит).*— «Кармак» журналының 1917 ел 1—2 саннарында «Йәкәнче» имзасы белән басылган. Мөтәшагыйрьләргә тәнкыйть йөзеннән язылган бу әсәрдә шагыйрь үзенең балачак такмакларын, өйрәнчек язмаларында куллана. Аерым алганда, шигырьдәге «Янмаган бер шырпыны мин»... дип башланган дүртьюллыкны без шагыйрьнең замандашлары истәлекләрендә үк очраткан идек. (469 биттәге искәрмәне карагыз.)

Текст шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

Зөһрәгә *(206 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең башкортча сайланмаларына кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Бу шигырь 1915—1916 елларда Уфа сәхнәләрендә уйналган күп спектакльләрдә катнашкан Зөһрә Әхтәмовага багышланган булса кирәк. Шагыйрьнең «Уфа сәхнәсендән» исемле мәкаләсендә дә ул артистка телгә алына («Кармак», 1916 ел, 19—20 бит).

Шәмсекамәргә *(207 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең башкортча сайланмаларына кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

«Кара бүрек бетә, диләр...» *(207 бит).*— Шакир ага Сабиров истәлекләре буенча китерелә. Бу юлларны Ш. Бабич 1917 елның урталарында туган авылы Әсәнгә кайткач җырлап йөргән.

Багъбостанда *(208 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. Шагыйрьнең башкортча сайланмаларына кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Багъбостан — Багъбостан Вильдан кызы Мөэминова (1884—1963)— Оренбургта хатын-кызлар мәктәбе оештырып, үзе дәреслекләр язу белән танылган мөгаллимә, журналист, мәгърифәтче; Ш. Бабичның якын танышы, дусты. Оренбургта эшләгәндә, шагыйрь Багъбостаннарга еш барып йөргән, аларда җыела торган алдынгы татар яшьләре белән аралашкан.

Исхак — шагыйрь һәм артист Исхак Зәйни.

Исемнәр бакчасы *(209 бит).*—1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. 1958 елгы татарча җыентыкта бу цикл кыскартылып алын-

са, башкортча сайланмаларда тулысынча бирелгән. Әмма, соңгыларында, 1922 елгы җыентыктан күрә, ахыргы өч строфа шул килеш калдырылган. Болар исә ниндидер ялгышлык белән «Китабеннас» әсәренең «Фатиха» бүлегеннән килеп кергәннәр.

1925 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Ш. Бабич шигырьләре» җыентыгында циклга кергән кайбер строфалар редакцияләнеп бирелгәннәр. Мәсәлән алганда, «Тугъзак» эпиграммасындагы беренче юл: «Тугъзак туташ! Син мөҗәссәм бизәк мәллә?», «Зифа» эпиграммасындагы беренче юл: «Зифа туташ, буең зифа зелпенеке» дип бирелгән. Сайланмаларда мондый төзәтүләр шулай ук искә алынган

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

«Уйлап, уйлап, уйга чумсаң...» *(218 бит)*.— З. Искужин күчермәләреннән алынып, шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

Диңгезләрне чайкап дулкынлаткан...» *(218 бит)*.— Башкортстан АССР Мәчетле районы Олы Ака авылындагы укытучы Хәнифә Вәисова (шагыйрьнең замандашы) тарафыннан Ш. Бабич кульязмаларыннан күчереп алынган. (Кара: «Агизел», 1985 ел, 1 сан, 7 бит.) Шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

«Намус өчен, тәңрем, җаннан кисәм...» *(219 бит)*.— Хәнифә Вәисова күчермәләреннән алынып, шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә. «Гаскәр догасы» әсәренең кыйныльчыгы (466б).

1918

«Барган идем стансага...» *(219 бит)*.— Бу җыр-шигырь С. Кудаш истәлекләре буенча китерелә. (Кара: С. Кудаш. Хәтердә калган минутлар. Казан, 1952, 112 бит.)

Гыйшык *(220 бит)*.— И. Насыйри күчермәләреннән алынып, ике башкортча сайланмага да кертелгән.

Текст И. Насыйри күчермәләреннән алынды.

Ни эшли? *(221 бит)*.— И. Насыйри күчермәләреннән алынып, ике башкортча сайланмага да кертелгән.

Текст И. Насыйри күчермәләреннән алынды.

Икенче гыйнвар көне *(222 бит)*.— Шагыйрьнең үз туган көне (иске стиль буенча —2 январь) уңае белән иҗат ителгән бу шигырь З. Искужин күчермәләреннән алынып, 1958 елгы татарча сайланмада, И. Насыйри күчермәләреннән алынып, башкортча сайланмаларда басылган.

Текст татарча сайланмадан алынды.

Байрам *(223 бит)*.— Шагыйрьнең «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») исемле китабыннан алынып, ике башкортча сайланмага да кертелгән. Текст монда 1918 елгы вариантында бирелде. Текст астындагы дата шигырьнең иҗат ителү вакытын 1918 елның июнь аена нисбәт итә.

Курайкайга *(224 бит)*.— «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгыннан алынып, шагыйрьнең барлык сайланмаларына да кертелгән. Әсәрнең язылу датасы «1918 сәнә, сентябрь» дип билгеләнгән.

Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Гаскәр маршы *(227 бит).*— Шагыйрьнең «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгыннан алынып, башкортча сайланмаларга кертелгән.
Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Башкордостан *(227 бит).*— Әсәр беренче тапкыр шагыйрьнең «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») исемле китабында урын алган. 1958, 1985 елларда дөнья күргән башкортча сайланмаларга кертелгән. Текст «Яшь Башкордостан» җыентыгыннан алып бирелде. Текст астындагы дата шагыйрьнең иҗат итәлү вакытын 1918 елның июнь аена нисбәт итә.

Әмма кайбер истәлекләр бу әсәрнең беренче варианты инде 1916—1917 елларда ук язылган булуы хакында сөйлиләр. Шагыйрьнең Троицкидагы тормышы турында язганда Сәрвәр Әдһәмова бу шигырьне дә телгә ала: «...Ул (Бабич.— *Г. Г.*) безгә еш килеп йөри, кайсы чакта үзенең капатлы мандолинасын да кыстырып килеп, уйнап, җырлап утыра. «Ком бураны» көен аеруча яратып уйный һәм үзенең «Башкордостан» дигән шигырен көйгә салып җырлый» (Сәрвәр Әдһәмова. Безнең Бабич.— «Совет әдәбияты», 1965, 1 сан). Әлеге юллар авторының тагын бер искәрмәсе бар. «Бу шигырь җыентыкта нигәдер 1918 елгы әсәрләр рәтендә күрсәтелгән,— дип яза ул.— Хәлбуки, мин аны Бабичтан Троицкида ук ишетеп беләидем. Басылу датасы 1918 елда булгандыр, бәлки».

Чынлап та, шигырь беренче тапкыр 1918 елда «Яшь Башкордостан» җыентыгында дөнья күрә. Ләкин моннан чыгып кына әле 1916 елгы шигыре белән 1918 елны язылган әсәрне тәңгәл куярга ярамый. Ихтимал, соңгысы бу шигырьнең икенче, тулырак варианты булгандыр. Шуңа күрә аны 1918 елга кертеп карау дөресрәк булыр.

Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Салауат батыр *(229 бит).*— 1918 елда «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгында басылган. Өч сайланмада да эпиграф, кыскартылып:

Салауат ничә яшендә,
Яшел күрке башында,—

дип бирелгән.

Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Салауат — Салават Юлаев (1752—1800)— башкорт халык герое, шагыйрь; 1773—1775 еллардагы крестьян сугышларында Ем. Пугачев армиясендә полковник, аннары бригадир.

Көтмәсдән *(230 бит).*— 1918 елда «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгында басылган. Башкортча сайланмаларга кертелгән. З. Искужин әсәрнең язылу датасын 1918 елның октябрь ае белән билгели.

Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Ике аккош (Тәмсил) *(232 бит).*—1918 елда «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгында басылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Күзеңне ач! *(234 бит).*— 1918 елда «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгында басылган. Башкортча сайланмаларга кертелгән. Язылу датасы «1918 сәнә, сентябрь» дип билгеләнгән.

Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Шәфкатем (Йөрәгем бүләге) *(236 бит).*—1918 елда «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгында басылган. Шагыйрьнең башкортча сайланмаларына кертелгән.

Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Михраб — мәчетләрнең мулла намаз укыр өчен җерым эшләнгән урыны, түре. Халыкта «изге урын» төшенчәсе дә шул сүз аша белдерелгән.

Дошманнар *(237 бит).*— Шагыйрьнең «Яшь Башкордостан» («Зәңгәр җырлар») җыентыгыннан алынып, башкортча сайланмаларга кертелгән.

Текст «Яшь Башкордостан» китабыннан алынды.

Язгы җыр *(238 бит).*— Беренче тапкыр «Ярдәм мәҗмугасы»ның беренче китабында (1921) басылган. 1931 елда «Сборник татарской литературы» җыентыгына урнаштырылган, русчага тәрҗемәсе С. Олейндр тарафыннан башкарылган. Шагыйрьнең өч сайланмасына да кертелгән.

Текст «Ярдәм мәҗмугасы»ннан алынды.

Шигырьнең язылу вакыты төрлечә күрсәтелеп килене иде. Мәсәлән, 1958 елгы башкортча сайланмада ул 1916 елга кертелгән. Әмма 1958 елгы татарча «Сайланма әсәрләр» җыентыгын төзүчеләр пенсионерка Хәдичә Тартищевада шигырьнең Бабич үзе язып, вакытында «1918, Май» дип үзе кул куйган кулъязмасы саклануын белдерәләр. Шуңа карап, бирелә әсәр 1918 елга кертелде.

Шигырьнең язылу тарихына кагылышлы тагын бер истәлек сакланган. Шагыйрь Төхфәт Ченәкәй, 1918 елның язгы-җәйге айларына бәйләп, түбәндәгеләрне хәбәр итә:

«Икенче көнне иртүк Бабич тагын килде.

— Ченәкәй, тыңла әле, бер шигырь яздым!

Бу шигырь аның «Язгы җыр»ы иде. Башта аның сүз башын «Чишмә буенда» дип куйган булса да, минем киңәшем буенча «Тау күкрәгендә» дип алмаштырырга булган иде. Соңыннан «Язгы җыр» дип исемләде.

— Мин синең шушындый ыгы-зыгы вакытында, бөтен дөнья кайнашканда, шундый матур лирик җыр язганыңа аптырап калдым. Башка вакытта язмадыңмы?

— Юк, юк, кичә кич белән генә яздым. Бу башкорт көйләренә җырларга бик килешә,— диде дә аны, «Шәүрәкәй» көенә булса кирәк, җырлый да башлады. Мин шушы ике көнгәчә Бабичның йөзендә күңелсезлек күргәнем юк, күңелендә төшенкелек сизгәнем юк иде. Шушы көнне ул гадәттәгедән киресенчә моңлы, төшенке күңелле булып күренде. Җырның өч куплетын җырлаганнан соң аның күзләрендә яшь бөртеге ялтырады...» (Т. Ч е н ә к ә й истәлеге.— «Әдәби Башкортостан», 1965, 6 сан, 71 бит).

Юк *(240 бит).*— Ш. Бабичның 1922 елда Казанда Г. Ибраһимов редакциясендә чыккан «Шигырьләр мәҗмугасы»нда басылган. 1958, 1985 елгы башкортча сайланмаларга 1915 елгы әсәрләр белән бирелгән. Шигырь берничә вариантта язылган булса кирәк. Шундый текстларның берсен шагыйрь үзе «Шура» журналына тәкъдим иткән. Әсәр «Атладым эзсез» дигән исем астында «Шура» журналының 1916 ел 6 санында дөнья күргән. Җыентыкта аның тулы тексты китерелә.

Бу әсәр нинди дә булса әсәргә пародия рәвешендә дә язылган булуы мөмкин. Мәсәлән, 1916 елның 15 мартында «Кармак» журналында (№ 5—6) «Чакмагыш» имзасы астында «Юк» исемле шигырь басылып чыга. Ул үзенең рухы һәм кайбер поэтик алымнары, сурәтләре белән Бабич шигырен хәтерләтә.

Дөньясында торып бонча бер тәм-ләззәт алганым юк,
«Кеше ләззәтләнә бит»,— дип, Мәсгутләргә исем китеп,
Ауызымнан сулар агзып, рәтле сүзем салган да юк...

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды.

Шагыйрь башы *(241 бит).*— З. Искужин күчермәләреннән алынып, шагыйрьнең җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

Хәсрәтле җырлар *(242 бит).*— С. Кудаш истәлекләреннән алынып, шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә. (Кара: С. Кудаш. Һайланма әсәрзәр, 2 том. Өфө, 1966. «Беззең ауылда» бүлеге.)

Уң аягым белән сул аягым *(242 бит).*— С. Кудаш истәлекләре буенча шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә. (Шунда ук. «Һуңгы осрашыузар» бүлеге.)

Китер *(242 бит).*— И. Насыйри күчермәләреннән алынып, ике башкортча сайланмага да кертелгән.
Текст И. Насыйри күчермәләре буенча китерелә.

«Исә җилләр, өерелә болытлар...» *(243 бит).*— С. Кудаш истәлекләре буенча, шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә. (Кара: С. Кудаш. Һайланма әсәрзәр, 2 том. Өфө, 1966. «Һуңгы осрашыузар» бүлеге.)

Без *(243 бит).*— И. Насыйри күчермәләре буенча башкортча сайланмаларга кертелгән.
Текст И. Насыйри күчермәләреннән алынды.

1919

Большевиктәр белән килешү туралы башкорт халкына көйле хитап *(251 бит).*— Листовка рәвешендә басылган бу өндәмә-шигырь 1919 елның февралендә (башкорт милли хәрәкәтендә катнашкан гаскәрләр кызыллар ягына чыккан чорда) аэропланнардан сугыштагы милли гаскәрләр өстенә сибелә. Кызыл Армия сафларына кушылучы янсә инде кушылган башкорт гаскәрләренә (5-нче армия сафында гына да унбиш меңләп башкорт сугышчысы исәпләнә) бу листовканың йогынтысы хәлиткеч була.

«Хитап», нык кыскартылып, «Без ник кызылларга кушылдык?» дигән исем астында Ш. Бабичның 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»нда (төзүчесе Г. Ибраһимов) һәм 1958 елгы татарча сайланмада дөнья күрә. 1958, 1985 елгы башкортча сайланмаларда да, бик нык кыскартылган хәлдә, «Башкорт халкына көйле хитап» исеме белән бирелә.

Бүгенге көндә әсәрнең тулы тексты Сәйфи Кудашның шәхси архивында һәм З. Искужин күчермәләре арасында саклана. «Хитап»ның тулы тексты Г. Ибраһимов кулында да булган. Үзе төзеп бастырган «Әдәби ярдәм мәҗмугасы» (1921) һәм «Шигырьләр мәҗмугасы» (1922) китапларында ул шундый искәрмә биргән: «Башкортстан хөкүмәте Колчакны ташлап, Советлар ягына чыккач, Бабичның халыкка язган озын хитабыннан».

Укучыларга беренче тапкыр тулы текстында тәкъдим ителгән бу «хитап»ка түбәндәге тарихи аңлатманы биреп китү зарури.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң Оренбург шәһәрендә берничә милли-политик хәрәкәт көчәеп китә.

1917 елның апрелендә үк Войсковой круг төзелә. Аның тирәсенә казакларның төрле политик төркемнәре оеша.

1917 елның сентябрендә Войсковой круг чираттагы җыенына җыела. Бу чорда башлыча офицерлардан торган бу оешма полковник Дутовның планнарын хуплый һәм аңа атаман булавкасын биреп, бөтен гаскәрнең баш атаманы итеп сайлый. Бу гаскәри хөкүмәттән большевиклар бөтенләй чыгарыла. Ә меньшевикларның һәм эсерларның җирле партияләре Дутовның төп таянычына әверелә. Атаман үз программасына төп нигез итеп түбәндәге лозунгны ала: «Без демократия белән дә, аристократия белән дә, теге партия белән дә, бу партия белән дә түгел, без казаклар — үзебез бердәм партия! Һәм без Ватанын сөйгәннәр белән! Станичниклар, 300 ел элек коткарып калган кебек, Ватанны коткарырга вакыт җитте!» (Дутовның 1917 елның 20 сентябрендә Войсковой кругта ясаган чыгышыннан.)

Октябрь революциясен Оренбург үзенчә каршы ала. Эсер-меньшевиклардан гына диярлек торган шәһәр Советы революциянең үсүенә теләктәшлек белдерми. Аларга таянып, октябрь ахырларында Дутов бандалары баш күтәрә һәм бу төбәкне Көньяк Уралның контрреволюция базасына әвереләдерә.

Икенчедән, Февраль революциясеннән соң ук Уфада, Оренбургта башкорт милли хәрәкәте активлашып китә. Бу хәрәкәтнең көчәеп китүенә төп сәбәп —1917 елның май аенда Мәскәүдә уздырылган Бөтен Россия мөселман съезды карарларында татар буржуазиясенең башкорт халкы интересларын да үз карамагына алырга тырышуы иде. Бу съездда башкорт милли хәрәкәте вәкилләре үзләренең аерым фракцияләрен оештырды, соңыннан 60 делегат съездны ташлап ук чыга һәм мөстәкыйль «Башкорт бюросы» төзи.

1917 елның җәй айларында башкорт милли хәрәкәте политик активлыгын тагын да көчәйтә. Аның эшчәнлегендә төрки-татар тарихы буенча зур белгеч, «Галия» һәм «Госмания» мәдрәсәләренең элекке укытучысы Зәки Вәлидинең (Вәлидов) роле хәлиткеч төс ала бара.

1917 елның 20—27 июль көннәрендә Оренбургта башкорт милли хәрәкәтенең Беренче өлкә съезды җыела. Шушы ук елның 25—29 августында Уфада Икенче өлкә съезды игълан ителә. Анда Үзәк шурага күпчелек тавыш белән унике кеше сайлана. Зәбих Искужин архивында бу исемлекнең күчермәсе саклаңган: Ш. Манатов, Н. Таһиров, З. Вәлидов, Х. Габиди, Кашаф Карипов, Әхмәди Гумеров, Галиәхмәт Хәсәнов, Муса Смаков, Ф. Дәүләтшин, Ш. Бабич, Сәләхетдин Атнагулов, Сәгыйть Мирасов.

1917 ел ахырында Оренбургта Шураның «Башкорт» исемле газетасы чыга башлый. Ш. Бабич яңа газета редакциясенә эшкә чакырыла.

11 ноябрьдә З. Вәлиди җитәкчелегендәге Башкорт Үзәк шурасы үзенең беренче фәрманын игълан итә. Анда Керенский хөкүмәте кискен тәнкыйть ителә һәм, социалистик революция җиңгәннән соң: «Россиядә үзара сугыш китте, мәмләкәттә тынычлык югалды»,— дип белдерелә.

15 ноябрьдә «Кече Башкортстан» республикасы игълан ителә. Үзәк шураның бу карары нигезендә Шәриф Манатов Петроградка Ленин исеменә телеграмма җибәрү хәстәрлеген күрә. Әмма Дутов карамагындагы шәһәр власте моңа каршы төшә.

Шәһәрдәге кайбер политик оешмалар да йөзләрен үзгәртергә ашыгалар. Асылда эсер һәм меньшевиклардан гына торган «Җәмгыятьне саклау комитеты» үзенең исемен «Ватанны һәм революцияне саклау комитеты» дип үзгәртә (рәисе — эсер Барановский). Аңа эсерлар, меньшевиклар, «милли демократия» оешмасы вәкилләре керә. Комитет шәһәрдә үзен бердәнбер хөкүмәт итеп игълан итә.

Шул ук 15 ноябрь көнне «Кәрван-Сарай»да эшче һәм солдат депутатларының зур җыелышы җыела. Әмма төнлә «Кәрван-Сарай» чолгап алына һәм Советлар, Хәрби-революцион комитет юлбашчылары, шул исәптән аның җитәкчесе С. М. Цвиллинг кулга алына. Йөзгә якын кеше төрмәгә ябыла. Бу вакыйгадан соң Оренбург большевиклар партиясе һәм Хәрби-революцион комитет, Советлар бөтенләй ялангач калалар.

7 декабрьдә Оренбург казак гаскәрләренең Войсковой округ җыелышында Башкорт хөкүмәте белән килешенгән союз раслана.

8 декабрьдә Оренбургта «Башкорт корылтае» җыела. Аңа 1917 ел ахырында Уфада барган Милләт мәҗлесендәге «туфракчылар» фракциясе кушуы буенча, аның җитәкчесе Галимҗан Ибраһимов та килә. Эш шунда ки, «туфракчылар» алга сөргән «Идел-Урал» штатының күпчелек идеяләре Башкорт хөкүмәте теләгенә туры килә. Шулай да «туфрак автономиясен» («территориаль автономия») яклап чыгыш ясаучы бу ике юнәлеш уртак фикергә килә алмыйлар, бик авыр бәхәсләрдән соң Г. Ибраһимов берникди килешүсез Уфага кайтып китәргә мәҗбүр була.

20 декабрьгә кадәр дәвам иткән бу корылтайда (ул «Башкортстанның учредительный съезды» дип тә йөртелә) Кулаев һәм Вәлидов җитәкчелегендә хөкүмәт төзелә. Шунда ук хөкүмәтнең гаскәрен җыю турында карар кабул ителә. Яңа башкорт эскадронының 24 кешедән торган ядросы оештырыла.

Корылтай барган көннәрдә, 1917 елның 18 декабрендә Ш. Бабич инициативасы белән «Тулкын» әдәби оешмасы төзелә. Шагыйрь үзе җитәкләгән «Башкорт» газетасында оешманың декларациясен дә бастырып чыгара. Анда шундый юллар бар. «...«Тулкын» оешмасы көчләнеп чыккан бер нәрсә булмыйча, яшьләрнең күңел дулкынынннан хасыйл булган табигый бер оешмадыр. «Тулкын»ның алга алган максатлары шуннан гыйбарәт: Башкортстанга яшь фикер, матур аң тарату, һәртөрле кара фикер вә хөррият микроблары, кара көчләр белән көрәшү, таралган яшьләрне оештыру, милли тел һәм милли әдәбиятның һәм аның хакимнәренә мәхәббәт иттерү, күмелгән хәзинәләрен актарып чыгару, Башкортстан халык әдәбиятын җыю, каләм әдәбиятының һәр төрен күбәйтергә тырышу, оешма исеменнән әдәби журнал һәм газеталар нәшер итү... бу көнгә кадәр кара көчләр тәсәллеге астында караңгы тормышта изелгән ханым вә туташларыбызны агарту, аларның якты, азат яшәүләренә тырышу. ...Яшьләрне дулкынландыру өчен озакламастан Уфа яки Оренбургта гаять тантаналы яшьләр съезды ясау лазим дип табылды... Яшәтегез «Тулкын»ны һәм дулкынландырыгыз башкорт дөньясын! Сөендерегез әдәбият, шигырь һәм моң фәрештәсен!

Утырышның башкарма әгъзалары: *Ш. Бабич, Х. Габитов, Гайнулла Гыйрфанов, Габдулла Дәүләт, Фәтхи Әхмәдуллин, Вәлирахман Габитов, Сәхи Рәхмәти*».

Бабич төзегән бу әдәби оешманың географик һәм политик офыгы шактый киң булган. Бер истәлегендә, мәсәлән, С. Кудаш болай дип искә ала: «1918 елның февраль башларында «Тулкын» оешмасының түбәнге ячейкаларын төзү өчен Бабич, Гайнулла Гыйрфанов белән, Бөре кантонына барышлый Уфада берничә көн торды» (С. Кудаш. Хәтердә калган минутлар. Казан, 1959, 74 бит). С. Атнагулов истәлегендә Бабич бөтенләй башка яклап ачыла: «Оренбургта Вәлидовның да, Кулаевның да булмавыннан файдаланып, минем инициатива буенча «Тулкын»ның гомуми җыелышы үткәрелде. Анда 200 ләп кеше катнашты. Җыелышның председателе Бабич миңа сүз биргәндә мине комиссар-большевик дип таныштырды һәм үзе үк кул чаба башлады» (КПССның Башкортстан өлкә комитеты партархивы, фонд № 1832, тасвирлама № 3, эш № 104, 8—9 битләр).

1918 елның 17 январенда Оренбургта калган большевиклар баш күтәрәләр. 18 январь көнне шәһәргә кызыл гвардия гаскәрләре керә. Дутовчылар кача. Башкорт хөкүмәте кулга алына һәм төрмәгә ябыла. Бу хакта Т. Ченәкәй дә: «Ш. Бабич шул хөкүмәтнең башлыклары белән бергә төрмәгә дә кереп чыкты, ләкин ул барыбер үзенең ни өчен утырганын аңламады»,— дип язды («Әзәби Башкортостан», 1960, 6 сан, 77 бит).

2 февраль көнне Оренбургта Мөселман хәрби-революцион комитеты төзелә. Аның җитәкчесе итеп Баһау Нуриманов билгеләнә.

4 февральдә Мөселман хәрби-революцион комитеты Оренбургта башкорт хезмәт ияләре вәкилләре белән берлектә зур киңәшмә уздыра. Анда Башкорт Үзәк шурасына каршы политика билгеләнә һәм Башкортстанның Вакытлы революцион советы сайлана. Җитәкчесе итеп большевик Б. Шәфиев билгеләнә. Яна совет җитәкчеләре арасында башкорт милли хәрәкәте активистларыннан Габдулла Дәүләтшин белән Фәтхи Әхмәдуллин да була.

Башкорт хәрәкәтенең беренче чорында зур активлык күрсәткән һәм Үзәк шурага сайланган Ш. Манатов та үз язмышын большевиклар сайлаган юл белән бәйли. Билгеле булганча, 1918 ел башында Учредительное собраниегә Казаннан депутат итеп сайланган Мулланур Вахитов, Уфадан килгән Галимҗан Ибраһимов, Оренбургтан барган Шәриф Манатов составында Милләтләр эше буенча халык комиссариаты янында Үзәк мөселман комиссариаты төзелә.

1918 елның апрелендә төрмәдән качып чыккан Башкорт хөкүмәте вәкилләре, үзләренә караган гаскәрләр белән бергә, Чиләбе ягына юл тота. Башкортлар яшәгән төбәкләрдә мобилизация үткәрелә, 5 мең кешедән, 7 полктан торган хәрби корпус оеша. 1918 елның җәендә Башкорт хөкүмәте кабат Оренбургка кайтып урнаша.

Бу чор хакында Г. Ибраһимов түбәндәгечә язды: «Сәләх Атнагулов, Муллаҗан Халиков һ. б. бик күп иптәшләрнең сөйләвенә караганда, башкорт автономистларының Колчак белән йөргән дәверендә Бабич ачыктан-ачык сул канатта була... Аның бу дәвердә һәрвакыт сөйләгән сүзе:

— Большевиклар белән сугыш — безнең үз туганнарыбыз белән сугыштыр, мин яктылыкны тик шул кызыллар ягында гына күрәмен!!— дип сөйләүдән гыйбарәт булган».

1918 ел ахырында Башкорт хөкүмәте Баймак якларына китә.

1919 елның январь, февраль айларында башкорт гаскәрләре арасында политик активлык көчәя, алар күпләп Колчак, Дутов гаскәрләре белән бер фронтта сугышудан баш тарталар һәм кызыл гаскәрләргә кушылуны таләп итәләр; аерым-аерым да, төркем-төркем дә Кызыл Армия ягына чыга башлыйлар.

Башкорт хөкүмәте гаскәрләренә төп мөнәсәбәтне билгеләүдә В. И. Ленинның 1919 елның 9 февралендә Уфа губкомына җибәргән телеграммасы хәлиткеч роль уйный. Монда башкорт солдатларына «Совет власте тарафыннан башкортларга милли азатлыкның тулысынча гарантияләнгән булуын аңлату», «Колчакка каршы башкорт полклары белән бердәм фронт төзү» турында әйтелгән иде (В. И. Ленин. Соч., т. 28, стр. 423).

Башкорт хәрәкәтенә В. И. Ленинның мөнәсәбәте Шәриф Манатовның истәлекләре аша да ачык күренә. «Без башкортларның хәрәкәтен безгә каршы юнәлтелгән контрреволюцион хәрәкәт дип танымыйбыз...— ди юлбашчы.— Без Көнчыгыш халыкларының милли хәрәкәтләрен бик тә табигый һәм кирәкле дип саныйбыз. Социаль революциягә Көнчыгыш халыклары бары тик милли революцияләр аша киләчәк». (Ленин и Башкирия. Документы, материалы, воспоминания. Уфа, 1970, стр. 232.)

1919 елның 18 февралендә башкорт гаскәрләре тулысынча кызыллар ягына чыга.

Бу көннәрдә Колчак, Дутов ялчылары тарафыннан кызыллар ягына чыккан башкорт гаскәрләре арасында төрле коткы листовкалар таратыла. Менә аларның берсе:

«Қазаклардан Башкорд халкына Ауыр кунляр тушди хурь булган башкурд балаларина.

Үзен башкорд хекуматинен башлеги диб атаган Валидов, шулаюк аларнен иярченляри сатылдилар кизилларга и аларнын яна халыкны таларга чегдилар. Башкорд халкинен зарарина юл ачдилар вакетлы узларенен файдасын кузатуб талалу юлы илан тиз басмакчы булдилар... Без сезни чакырабыз иль талаучиларны большевикларни ильбезден куганга кадер сугушар учун. Алла план хакикат безнен план». (Қара: Бикбаев Р. Шәйхзада Бабич. Тормошо һәм ижады. Өфө, 1981, 302 бит.)

Ш. Бабичның «Башкорт халкына көйле хитап» әсәре әнә шундый контрреволюцион характердагы листовкаларга каршы языла һәм аэропланнан сугыштагы башкорт гаскәрләре өстенә таратыла. Башкорт хөкүмәте белән Совет власте арасында барган сөйләшүләрнең тәмамлануын да көтмичә, башкорт гаскәрләре Қызыл Армия ягына чыгып бетә.

21—24 февральдә Темәс авылында Қызыл Армия ягына чыккан Башкорт хөкүмәте вәкилләренең һәм гаскәриләренең съезды җыела. Анда Кече Башкортстан автономияле республика дип игълан ителә һәм аның РСФСР составына керүе хакында белдерелә.

Ш. Бабич Башкорт республикасының Вакытлы хәрби-революцион комитетының 1919 ел 25 февраль приказы белән Башревком янындагы башкорт матбугатының сотрудниты итеп билгеләнә.

Ул, бер үк вакытта, Башревком органы булып чыга башлаган «Башкортстан хәрби инкилаб мөхбире» газетасында җаваплы секретарь вазифасын да башкара. Кече Башкортстан республикасы игълан ителгән көннәрдә Ш. Бабич җитәкләгән бу газетада шундый мәкалә басыла: «Без... монархия өчен, Дутов өчен сугышмадык. Монархиягә, патшага, князьләргә, помещикларга дошманлык безнең каныбызга сеңгән... Күбрәк рус тарихларында безнең каһарман бабаларыбызның яулары... «бунт» дип аталалар. Бабайларыбыз бунтовщиклар түгел, үзләренә күрә түрәләрне, помещикларны бетерергә тырышкан «большевиклар» иде. Аллага шөкер, безнең тарих пычрак түгел. Тарих — милләтнең көзгесе...» (Қара: Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты. Қазан, 1926, 170 бит.) Бу юллар Ш. Бабичның «Башкорт халкына көйле хитаб»ына аваздаш яңгырый иде.

1919 елның 20 мартында Совет власте белән башкорт гаскәрләре арасындагы килешү Халык Комиссарлары Советы һәм Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан рәсми төстә раслана. 23 мартта бу хакта матбугатта игълан ителә. Бу килешү нигезендә кызыллар ягына чыккан башкорт гаскәрләре тулысынча амнистиягә эләгә, ә З. Вәлидов һәм аның тарафдарлары Совет власте органнарында эшләргә тиеш була. Аерым алганда, З. Вәлидов Башревком составына кертелә, соңрак аның рәисе була. Башкорт хәрәкәтенең күпчелек активистлары төрле рәсми оешмаларда, советларда, матбугат органнарында, мәгариф оешмаларында эшли башлый.

Шушы тарихи ситуацияне ачыкламый торып Ш. Бабичның «хитабы»на дөрес бәя бирел булмас иде. Иң беренче шуны искәртергә кирәк: аңа бүгенге көн югарылыгыннан карау хата нәтиҗәләргә китерер иде. Шул чорда, З. Вәлиди хөкүмәтенә тулысынча ышанган башкорт гаскәрләренең Қызыл Армия ягына чыккан көннәрдә бу «хитап»ның нәкъ шушы рухта язылуы кирәк иде.

Безнең карашыбызча, Бабич бу өндәмәсендә З. Вәлидигә каршы политика үткәрсә, бу агитацион актның нәтиҗәсе бөтенләй кире булыр иде. Чөнки ике арадагы килешү Ленин белән Вәлиди арасындагы килешү дип игълан ителә һәм бу очракта З. Вәлидигә каршы сүз әйтү Ленин политикасына каршы бару булып аңлашылыр иде.

Икенчедән, кызыллар белән төзелгән килешүдә, З. Вәлидинең роле чыннан да зур. Әгәр Башкорт хөкүмәтенең бөтен идарә әгъзалары кызыллар ягына чыгып, З. Вәлиди берүзе кушылмый калса да, бу процессның дәвамы бик катлаулы төс алыр һәм озакка сузылыр иде. Чөнки меңләгән гаскәрне баштанаяк киендергән, туендырган, коралландырган, җирле халыкка җир, ирек вәгъдә иткән З. Вәлидинең абруе әле 1919 елның язында да гаять дәрәҗәдә югары булган.

Түбәндә «(Большевиктәр белән килешү туралы башкорт халкына) Көйле хитап» әсәренең тулы текстын тәкъдим итәбез.

1

Башкорт халкы! Һиңә бер һүз әйтәм,
Минем әйткән һүззе тыңлаһаң;
Зәки һеззе саткан тигән һүзгә
Ышанмасһың, алйот булмаһаң...

Уеңа да алма, башкорт булһаң,
Әхмәтзәки безне сатар, тип!
Коръән үбеп Зәки гаһед иткән,
Уйлай күрмә, антын таптар, тип!

Башкорттагы намыс, иман белән
Ярсып тибә Зәки йөрәге,
Колак асма дошман коткыһына,
Зәки — Башкортостан терәге.

Башын һалып Зәки эшкә кергән
Ятим Башкортостан бәхтенә;
Валлаһи, ул сатмас туган илен
Дөнья аксаһына, тәхтенә.

Ышан, ышангандай бер аллаңа;
Зәки һинең садык угылың!
Утта пешәр, Зәки суга төшәр,
Әмма сатмас намыс-күңелен!

Большевиктар белән ул килешһә,
Илне коткарам тип килеште;
Уйлай күрмә, нигә алай булгас,
Дутов яклы булып һугышты?

Дутов яклы булдык шуның өсен:
Дутов беззе яклап йөргәнгә,
Мин дә һеззең кебек һугыш кыйлам,
Корылтайды яктап, тигәнгә.

Дутов яклы булдык шуның өсен,
Дутов безгә корал биргәнгә;
«Кирәк казәр азык, кием, акса,
Тагын биреп торам»,— тигәнгә.

Дутов яклы булдык шуның өсен,
Дутов халык яклы булганга.
Барлык Корылтайсы социалисттәр
Дутов яклы булып йөргәнгә...

Дутов яклы булдык шуның өсен,
Большевиктәр таптап килгәнгә,
«Красный гвардия» сиктән сыгып,
Аскан, кискән, ваткан, ярганга...

Кайһыбыззы биктәп төрмәләргә,
Кайһыбыззы нахак атканга...
«Красный гвардия» вәхшәтендән
Башкортостан канга батканга!..

Башкорт намысына пысрак таштап,
Юрый кайбер битһез, иманһыз,
Әйтә алар: «Дутов яклы булып,
Кара, пысрак юлны куганһыз!»

Явыз йәндәр коткы һалганлыктан,
Дошман булды безгә большевик;
Шул сәбәптән Дутов яклы булдык,
Әмма аңа сыннан каршы инек.

Менә хәзер дөнья алмашынды,
Һәр эш түнкәрелде аслына;
Без кушылдык якты, хөрлек якка,—
Дутов кайтты кара нәсленә!

2

Без кушылдык кызыл тарафына,
Кызыл беззең яклы булганга;
Азат Башкортостан җөмһүрлеген
Таныймын, тип хуплап торганга.

Без кушылдык кызыл тарафына,
«Красный гвардия» беткәнгә;
Большевиктәр эшне рәткә һалып,
Асыл юлдарына сыкканга.

Без кушылдык хәзер кызылдарга,—
Беззең өсен лаек шул булгас,
Нигә кушылмаска кызылдарга,
Күптән көтеп торган юл булгас.

Нигә без качмыйк ти шул Дутовтан,
Дутов юыртып киткәс уң яктан?
Нигә ярашмаска большевик белән,
Беззең һукмак киткәс һул яктан?!

Большевиктәр әйтә: «Бу дөньяда
Ярлы халык хөкеме йөрһен, тип;
Ярлы эшселәрнең хас дошманы —
Буржуйларның тамыры корһын!» — тип.

Дутов-Колчак әйтә: «Эш башына
Алтын тажлы батша менһен,— тип;
Батша менеп, һаман Николайдай,
Ярлыларның каның имһен!»— тип.

Большевиктәр әйтә: «Коллык бетһен,
Ярлы халык рәхәт яшәһен;
Ирек көне туып бу дөньяга,
Тигез, якты көндәр яшәһен!»

Дутов-Колчак әйтә: «Закондарны
Бай-бәтсәләр язып торһын тип;
Ярлы, эшсе халык әүвәлгесә
Бай-бәтсәгә хезмәт кылһын!»— тип.

Большевиктәр әйтә: «Нәсел-нәсәп,
Түрәлектең поты бер тин,— тип;
«Калын йилкә» белән «ярылган кул»
Көнкүрештә булһын бер тиң»,— тип.

Дутов-Колчак әйтә: «Йергә, куккә
Хужа булһын фәкать батша,— тип;
Мөселманнар һаман изелһен,— тип,
Батшаныкы гына дөрест!»— тип.

Большевиктәр әйтә: «Һәрбер илгә
Камил мохтарият бирелһен!
Һәрбер ярлы, мәзлум, изелгән ил
Мохтарият алһын, терелһен!

Дутов-Колчак әйтә: «Вак милләттәр
Мохтарият» ала күрмәһен!
Батша кул астында гомер сөреп,
Буржуаздың йырын йырлаһын!»

Уйлап кара, башкорт, акылың белән:
Кайһы тараф һинә хәерле?
Әнә теге яман Дутовлармы?
Әллә большевикмы хәерле?

Бер дә шикһез һинең акылың әйтер:
«Большевиктәр юлы хәер»,— тип,
Йәнең теләр шунда: «И ходаем!
Дутовлардан мәңге аер!» — тип.

Ни әйтерһең икән инде миңә,—
Әхмәт Зәки һине һатканмы?
Әллә яман юлдан алып сыгып,
Яңа, якты юлны тапканмы?

Һин әйтерһең миңә, динең булһа,
Юк, һатмаган икән, тиярһең...
Башкортлыктың изге зур намысын,
Юк, актаган икән, тиярһең...

3

Бер без генә түгел, бик күпләрне
Ышандырды Дутов бер сакта;
Себер якта залим Колчак сыккас,
Кушылды ла китте Колчакка!

Дутов төсен аскас, Халык явы
Большевикка барып кушылды...
Дутов-Колчакларның юлын күреп,
Чех-словаклар да пошынды.

Канибыззы бикәр коя икән, тип,
Чех-словак аны ташланы;
Батша утыртырга телиһең, тип,
Илдәренә кайта башланы.

Колчак сыккас, Дутов серен аскас,
Барлык социалист партия
Изге ихтилалның хөрмәтенә
Тагылдылар кызыл артына.

Шулай итеп, Дутов-Колчаклардан
Халык күңеле тәмам һыуынды;
Был икәүгә каршы һугышу өсен
Кызылдарга барып һыенды.

Ике залим ситтән ярдәм һорап
Союзниккә атты күззәрен;
Союзниктәр: «Һезгә гаскәр юк»,— тип,
Аңлаттылар һуңгы һүззәрен.

Шул сәбәптән хәзер Дутов-Колчак,
Белмим, инде нихәл итәрләр?
Нихәл итсен инде, мәгълүм хәлләр:
Тиздән җәһәннәмгә китәрләр.

4

Башкорт халкын элек аңламастан:
«Гакес инкилабсы» тинеләр;
Батша утыртырга тели торган
Кара көсләр яклы, тинеләр.

Белһен улар беззең башкорттарның
«Гакес инкилабсы» түгелен;
Укыһындар башкорт тирахтарын,
Шунда күрер башкорт күңелен!

Шунда күрер, башкорт борындан ук
Инкилабсы булып килгәнен;
Залим түрәләргә башын бирмәй,
Ирек өсен һугыш кылганын.

Белеп торың — беззәр борындан ук
Кара көскә яман каршы инек;

Беззең үткәндәге каһармандар —
Заманына күрә — большевик!

Беззең Абыз, Акай, Салауатлар,
Кара Һакал, Айдар, Күсимдәр...
Болар бар да кара көскә каршы
Һугышып үлгән алтын исемдәр!

Ирке өсөн, азат илкән өсөн
Борындан ук килдек нырылып;
Урыс менән нисә, нисә йылдар
Һугышып барып, көскә биреддек.

Урыс кыскас беззе шытырдатып,
Маиләттән сыктык, изелдек.
Йер тарайды беззең, ил карайды,
Әдәм күрмәгәнде без күрдек.

Инде монау форсат вакыт килгәс,
Башкорт халкы йоклап ятһынмы? —
Иле өсөн һугышып шәһид булган
Олатайлар исмен һатһынмы?..

Юк, һатманы башкорт иске исмен,
Атылып килеп сыкты майданга!
«Мин — башкорт!» — тип шунда һөрәнләгәс,
Мәгърур халык калды хайранга.

Уйлай ине улар: башкорт халкын
Үлем исеректеге тоткан, тип;
Ямьле ерен аның урыс баскан,
Башкортлыгын татар йоткан, тип.

Бушка сыкты барлык явыз фикер,
Башкорт халкы үзен танытты;
«Азат Башкортостан» туын алып,
Кара көскә каршы калыкты.

Ирек колы башкорт, шулай булгас,
Дутов-Колчак яклы булырмы?
Аяк-кулын бәйләп, үзен-үзе
Кара көскә тотып бирерме?

Мәнге бирмәс башкорт һәм бирдермәс,
Иле өсен янган һагышы!
Үлһә үләр гәзиз иле өсен,
Әмма тере калыр намысы!..

5

Үзаманым, энем, акһакалым,
Олатаем, анам, әнием!
Инанмагыз дошман һүзенә, тип,
Кайта-кайта йырлап көйләем!

Дутов залимнәрнең ялсылары
Һеззең арагызза йөрерләр,
Һеззе алдап ауга төшерергә
Төрле кыяфәткә керерләр!..

Алар кара шайтан булһалар да,
Йөрер тыштан яхшы күренеп;
Һеззе алдагандай һүззәр һөйләп,
Фәрештәләр һымак кыланып.

Колак асма, башкорт, куркытуга!
Намаз-ниязыңны кыла тор;
Исәнлеген теләп ирләреңден,
Эштең ахрын көтеп тора тор!

Фетнә һалып йөргән шайтандарзы
Советларга тотып китер һин!
Кулга төшкән Дутов ялсыларын
Эй дидермичешен бетер һин!!!

***

Башкорт халкы! Һиңә һүзем ошы,
Баштанаяк ихлас тыңлаһаң.
Зәки һине һаткан, тигән һүзгә
Ышанмасһың, алйот булмаһаң!..

Йырсыгыз: Шәйхзада.
1919, 25 февраль, Темәс.

Зәки һеззе һаткан тигән сүз...— Югарыда телгә алынган дутовчылар листовкасына ишарә.

Мин дә һеззең кебек һугыш кыйлам, Корылтайзы яктап...— 1917 елның 11 ноябрендә дутовчылар белән вәлидичеләр арасында төзелгән килешү хакында сүз бара.

«Красный гвардия»... аскан, кискән, ваткан, яргангa...— 1918 елның январь вакыйгаларына ишарә. Дутовчыларны бәреп чыгарып, Оренбургка кергән кызылгвардеецлар башкорт милли хәрәкәте вәкилләрен кулга алалар, төрмәләргә ябалар; корбаннар да күп була.

Абыз, Акай, Салауат, Кара Һакал, Айдар, Кучим...— төрки-башкорт халык геройлары.

Урыс менән...— Патша Россиясенең милли изүе астында яшәгән дәверләргә ишарә.

Башкортлыгын татар йоткан...— Бу урында «милли-мәдәни автономия» идеясен алга сөргән татар буржуаз идеологлары эшчәнлегенә ишарә.

Яраштык *(249 бит)*.— Хатип Госман архивындагы күчермәләрдән алынып, шагыйрьнең җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә. Бу әсәр «Большевиклар белән килешү туралы башкорт халкына көйле хитап» әсәренең бер варианты булырга тиеш.

* * *

Шәехзадә Бабичның яңа «Сайланма»сына 1918 елда Оренбургта «Тулкын» нәшриятында басылып чыккан «Яшь Башкордостан» («Зәң-

гәр җырлар») исемле җыентыгында дөнья күргән берничә әсәр керми калган иде. Корректура өстендә эшләгән чакта төзүче бу әсәрләргә кабат әйләнеп кайтты һәм аларны, кыска тарихи белешмәләр бирел, «Искәрмәләр» бүлегендә бирүне кирәк дип тапты. Бу әсәрләрсез шул чорның тарихи, әдәби ситуациясе дә, Ш. Бабич иҗаты да, ниһаять, шагыйрьнең үз шәхесе дә чынбарлыкта булганча бөтен катлаулылыгында күз алдына килеп баса алмас иде.

Башкордостан мохтариятына каршы татарга.— Әсәр 1917 елның октябрь аенда иҗат ителгән һәм «милли-мәдәни мохтарият» идеясен тормышка ашырырга йөргән татар буржуазиясенә һәм руханиларына адресланган. Билгеле булганча, мөселманнарның Мәскәүдә һәм Казанда узган съездларында (1917) «мөселман берлеге» идеясе астында башкорт халкын да татар буржуазиясе кул астындагы «милли-мәдәни мохтариятка» кертү хакында сүз бара. Бабичның бу әсәре әнә шушы политикага протест йөзеннән Башкорт Үзәк (Мәркәз) шурасы заказы рәвешендә язылган булырга тиеш.

Әсәрнең тулы тексты:

Намус белән уйнап уңалмассың,
Бикәр китәр синең талашың;
Җиңәлмәссең мәңге, тыялмассың
Ирек сөйгән Урал баласын!..
Сездән түгел, башкорт урыстан да,
Җитәр инде, байтак кысылган...
Үзе өчен үзе тырышканда
Таяк тыкма, булсаң мөселман!.
Кирәк түгел сиңа, нифак сатып,
Иблисләнү, яну, тарлану;
Бер куркыткан булып, бер алдатып,
«Харап булдың!» — диеп зарлану...
Алдашуга башкорд курчак түгел,
Тешең йитмәс инде терсәккә...
Бездә намус, ялкын һәм ак күңел,—
Мыскыл итмә безне, жирсәтме!..
«Кушыл безгә, башкорд»,— дигән белән,
Айрылсынмы башкорд милкендән?
Яшел чапан, чалма кигән белән,
Төлкелегең мәгълүм сыртыңдан!!

Әлбәттә, бу әсәрендә Ш. Бабич, теге яки бу милләтне яманлап, бөтен бер халыкка каршы чыкмый. Ул бары тик башкорт халкының мөстәкыйль усеш юлын, тиң хокуклыгын танымаучы политик төркемнәргә отпор бирү максатын куйды.

Олуг шатлык (Башкордостан мохтарияты игълан кылыну һәм Кәрван-Сарай кулга алыну мөнәсәбәтилә). —Әсәр 1917 елның 16 ноябрендә, Оренбург шәһәрендә Хәрби-революцион комитет дутовчылар тарафыннан туздырылганның икенче көнендә иҗат ителгән. Нәкъ шул көнне, ягъни 15 ноябрьдә «Кече Башкортостан» республикасы игълан ителә, халыкка аның фәрманы җиткерелә. Башкорт хөкүмәте Кәрван-Сарайга күчә.

Әсәрнең тулы тексты:

Янрап, шаулап чыккан шатлык җырын
Фәрештәләр сөенеп тыңласын;

Шатландырдың, тәңрем, сибеп нурың,
Башкордостан халкы дөньясын,
Җибрил-мәләк, җилпеп ап-ак канат,
Очып йөрсен Башкордостанда;
Хәбәр бирсен, дип: «Булдың азат!
Чыктың ямьле, гөлле бостанга!..»
Азат булды газиз Кәрван-Сарай,
Азат булды барлык җирләрең...
Җырлап җибәр, сөйнеп, уйнап курай,
Чыксын тизрәк шатлык җырларың!..
Теләкләрең алга килеп тора;
Азатлыкка ошбу галәмәт.
Инеп тора, «дәүләт» куңып тора,
Киләчәгең якты, сәламәт.

«Бәхет кызы», матур йөзен ачып,
Сиңа табан көлеп борылды..
Шатлан, уйна, сикер ярсып-ярсып! —
Күпме шатлансаң да урынлы...
Үләм... ташам... тормыйм, ашам күккә,
Үкенмәймен инде үлсәм дә...
Үкенмәймен инде, туган йортка
Күкдән карап көлеп торсам да...

Истикъбаль (Корылтай вәкилләренә).— Әсәр 1917 елның 8 декабрендә иҗат ителгән һәм шул ук көнне Кәрван-Сарайда ачылган Башкорт корылтаенда (съездында) укылган.

Әсәрнең тулы тексты:

Әссәләмәгаләйкүм чын ихласдан!
Дулкыннар ташып чыгып башдан ашкан;
Күңелдә балкып янган матур хыял
Зиһендә ләүхә-ләүхә карарлашкан.
Мәрхәбә, ил-азамат хуш килебсең!
(Үзеңне бимазалап көч килебсең.)
Җаныңда ил бәхтенә шырпы капкан,
Ирeклек күкертенә ышкылыбсың...
Мәрхәбә... Корылтайга утлы сәлам,
Мәрхәбә... ил кадеме, төкле кадем,
Куеп кит ихлас белән ныклы кәбән!
Башына утыртып куй котлы әләм!..
Туганлар, килде дөнья хәйран булып,
Әверелде вәйран дөнья бәйрәм булып;
Җил исде... давыл кубды... салды куйды
Баскычның өстен аска әйләндереп...
Гомернең көзе үтде, язы килде,
Бәхетнең назы китде, сазы килде!
Ялт итеп җирдән чыкды, күкдән көткән,
Тарихның күп эчендән «азы» килде...
Салынды нурдан күпер упкын ярга;
Әйдәгез шул күпердән алга, алга!
Капусын сигез оҗмах ачып куйып,
Керергә бирде фәрман рәхим алла...
Әйдәгез, форсат туры килгән чакда,
Чит илләр карван, карван йөргән чакда...
Ярашмас арысланга куянлану.

Нигъмәтне әлвән-әлвән күргән чакда...
Тилмерә сезгә карап Башкордостан,
Әҗәлдән аны саклау сезгә төшкән...
Теләймен, өлкән мәҗлес үтсен күркәм,
Сөенсен Башкордостан, яшел бостан...
Мәрхәбә, Корылтайга утлы сәлам,
Мәрхәбә, ил кадеме, төкле кадем;
Куеп кит мәңгелеккә ныклы кәбән!
Башына кадап куеп котлы әләм...

Казан платформасы мөридләренә махсус (Башкордостан мохтарияты игълан кылынгач).— Әсәр 1917 елның ноябрендә Россиянең бөтен мөселман халыкларына баш булырга тырышучы кайбер татар буржуазиясе вәкилләренә каршы протест йөзеннән иҗат ителгән.

Аның тулы тексты:

Сез үгәйсеткәч — үгәйсендек, ләкин тарсынмадык...
Өрдеңез — һич сүнмәдек без, ордыңыз — һич сынмадык!
Сез үчекләп: «Кит!» — дигәндә, без үчекләп: «Кил!» — дидек.
Чөнки без бик киң күңел, мөэмин күңелле ил идек...
«Кит!» — диеп тә килмәгәч, мәгърур сынып сансынмагач,
«Кит!» — дигәчтен, без дә китдек, эштә вөҗдан ачылмагач...
Бергә барсак, эзгә салсак, безнекен алмакчидек...
Сезнеке күптән алынган, безнекен алмакчидек...
Сез тызылдап чыктыңыз, «ай-һай, хыял бит сезнеке!..»
Без дә чыктык, «сезнеке вак җанлы, тар, сөмсезнеке!»
Килде көннәр... «буш хыяллар» чыкты алга бар булып;
Әле дә булса күңелегез калды кабердәй тар булып.
Әле дә булса гомерегез вак, алдашып, майлап үтә,
Зур замандан һич оялмый, «мөхтәсиб» сайлап үтә!..
Нәфсеңез бик киң, фәкать тар фикреңез тар «җәзбәңез»!
Кәгъбәңез — «миңлек», фәкать «диплом»гадыр бер сәҗдәңез!!
Уйлап-уйлап уйга чумсаң, оптыла җан шадлыгы!
Җан ачы... ләгънәт сиңа, ләгънәт адәмнең ваклыгы!

Сау бул, бәйрәм.— 1918 елның январь-февраль айларында, ягъни Кәрван-Сарай һәм Оренбург кызылгвардеецлар тарафыннан алынгач һәм башкорт хәрәкәте вәкилләре Оренбург төрмәләренә ябылгач иҗат ителгән.

Әсәрнең тулы тексты:

Бәлки сез бәйрәм бүген, дип
Сөенәсездер, шау килеп,
Уйламыйсызмы, Ватанны
Чапты мәлгунь яу килеп?..
Кан туфаны илне баскан,
Дөнья шашкан чак хәзер,
Инде соң бәйрәм ясап, мөм-
Кинме булмак шад хәзер?!.
Бел, туганкай: бу авырлык
Көннәре узмас борын,
Бу «кызыл мәлгунь» явы
Көлдәй булып тузмас борын;
Безгә чын бәйрәм дә юк,
Сәйран да юк, чын туй да юк,
Тик хәзер илкәйне саклау-
дан бүтән уй да юк.

Ал корал, бар кит фронтка!..
Ит лэгыйньнэрне мэхү!
Теш кысып торсын эле
Барлык уен, келке, лэһу...

* * *

Хуш, олуг бэйрэм, исэн бул!..
Каршы килдек яуга без,
Шад кавыштырсын,
иkенче
Килгэнеңдэ аллабыз!..

Гаскэр догасы.— Эсэр 1918 елның язында иҗат ителгэн. Аның тулы тексты:

Йэһу аллам, синдэн сорап ярдэм,
Ярсып йерим үлем аузында;
Үлсэм, шэһид булсам — канлы гэүдэм
Балкып йезсен оҗмах хаузында...
Айа, гафур, айа, рэхман, рэхим!
Рэхмэтеңдэн читкэ каерма!
Куркытмассың мине, шайтан раҗим,
Нык имандан мэңге аерма!
«Тау иясе»— тэңрем, ташларыңдай
Белэгемэ каты ныклык сал!
«Ут иясе»— тэңрем, утларыңдай,
Йерэгемэ сүнмэс утлык сал!..
Диңгезлэрне чайкап тулкынлаткан,
Эй кодрэтле «диңгез патшасы»!—
Тулкынланып мин дэ дэрт-гайрэтдэн,
Диңгез кебек күкрэк каксамчы!..
Рэббым, сиңа сыгына Башкордостан,
Ишет мэзлум башкорд аһларын,
Кан болыты китсен иде естэн,
Салчы рэхмэтеңне, гаффарым!..
Намус ечен, тэңрем, җандан кичэм.
Китер вэгъдэ... кодрэт кулың бир!
— Башкордостан исэн кала,— дисэң,
Бер җаныма миллион үлем бир!!

Каһарман Эмир Карамышев.— Эсэр 1918 елның 22 августында (искечэ 8 август) иҗат ителгэн һэм башкорт гаскэрлэренең эскадрон башлыгы Эмир Карамышев каберендэ сейлэнгэн.
Аның тулы тексты:

Бүген безгэ ни булган?
Күңлебез ник кырылган?
Йезебездэ ник тагын
Үлгэн хэсрэт терелгэн?

Терелгэннең сэбэбе:
Бер аяулы ир үлгэн!..
Ул аяулы кем иде?—
— Эмир дигэн ир иде.

Башкорд күген яктырткан
Аз йолдызның бере иде,
Яу өстенә омтылса,
Куйга чапкан бүре иде...

Гаскәр жыйнап, баш булып,
Ястанганы таш булып,
Ут эчендә ут йотып,
Ничә көнләр ач йөреп
Дошман явын кырганда
Күкрәгендә чир иде...
Шул чирендән үлгәндә
Жиденче август көн иде.

Алдымызда нинди тән?
Кальбемездә нинди гамь?
Түбәмездә әйләнеп
Очып йөргән нинди жан?

— Алдымызда ир тәне,
Кальбемездә ил гаме;
Алды тәкъдир арадан
Тагын да бер иркәне!..

Жанын аның әйтәем:
Жан түгел ул — намусдыр!
«Әмир» дигән бер исем
«Намус» дигән тавышдыр!..
        Йа, илаһым, Әмирне
        Жәннәтеңә кавышдыр!

*

Әй Әмиржан, ил өчен
Сүнгән шәмнең бере син.
Кара гүрне агартып
Ингән жанның бере син.

Анаң сөтен анаңчөн
Имгән жанның бере син...
Бәхетле син — үлмәдең;
Ил күгендә тере син!..

Чәчкәләрдән сөелгән,
Чишмәләрдә коенган,
Дошманлардан жан саклап,
Тауга-ташка сыенган
Син бер батыр ир идең,
Илең өчен көенгән...
Яткан дәрдне калкыткан,
Намус йөзен яктырткан;
Кыя таулар башында
Янып торган кандилдәй;
Каһарманлык аңгыткан,
Гайрәт берлән дан тоткан;

Үрдән кырга сикереп,
Оча чапкан дөлделдәй,
Син бер асыл ир идең,
Ил бәхетенә ант иткән!..

*

Очтың, Әмир, асманга;
Тагын бәйрәм дошманга,
Тагын кайгы, тагын зар
Моңлы Башкордостанга...

Көенсәк тә, без монда,
Рәхәтдә оч син анда!
Бездән сәлам ирешдер
Габдулла һәм Гыймранга!..

Сәлам сезгә, өч корбан!
Әмир, Габдулла, Гыймран;
Җанны фида итдеңез
Башкордостан гыйшкыннан...

Өчәү бергә йөреңез,
Нур эченә чумыңыз!
Фәрештәләр гаскәре,
Йөзеп безгә килеңез!..

Атланып ак пыракка,
Очтыңыз сез еракка,
Калдыңыз тик йөрәкдә
Мәңгелеккә урнәккә...

*

Урныңыз нурдан ясалсын,
Уңлы булсын артыңыз;
Мәңге рәхәт яшәсен
Күп интеккән халкымыз!..

Корбан бәйрәме мөнәсәбәте белән.— Әсәр 1918 елның 16 сентябрендә иҗат ителгән.

Аның тулы тексты:

1

«Углыңны чал, ая Ибраһим!» — дип,
Ишетеп күкдән хакның авазын,
«Бисмилларахманрахим» дип,
Ышкый Исмәгыйльнең богазын...
— Куй, егълама, атай!.. Мин тыныч, шад...
Хак ризасын ал!..— ди Исмәгыйль;
Изге ата ышкый, кисми пычак...
Гүя ялап тора Җабраил...
Кинәт янрый тавыш: «Сөекле кол!
Изге Исмәгыйльне коткар!— ди.—

Углың урынына корбанлык кыл,
Җибәрелде күкдән кучкар»,— ди...
Ходай хакы өчен газиз углын
Корбан кылмак булды Ибраһим;
Олуг пәйгамбәрнең изге күңлен
Үрнәк кылды безгә ул рәхим.

2

Иле өчен башкорд, Ибраһимдай,
Корбан итә үзен, баласын...
Батыр балалары, Исмәгыйльдәй,
Иле өчен ташлый анасын...
Куанадыр, күреп аналары,
Яуга каршы китсә баласы...
Уйнаса да үлем шәүләләре,—
Куанып тора башкорд даласы...

Куан, башкорд, куанып хакка буйсын!
Ил бәхтенә бәгла билеңне!
Алгы көнге ямьле туең өчен
Куанып уздыр барлык кыенны...
Куанып көт, хакдан сугып сәгать,
Биргән корбан кабул булганын,
Зәңгәр нурлар сирпеп Җибрил мәләк,
Маңгаеңдан сыйпап торганын.

ӨЙРӘНЧЕК ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘРДӘН

1907—1909

Котлыйм *(266 бит)*.— Шагыйрьнең авылдашы, яшьлек дусты Шакир ага Сабиров истәлекләре буенча басыла. Истәлекләрдә шигырьнең башка варианты да телгә алына:

Әти, әти сине котлыйм чалмаң белән!

Тәбрик итәм эчең тулы ялган белән!

Соңгы очракта ул үз әтисенә — мулла Мөхәммәтзакир Бабичевка мөрәҗәгать итә.

1917 елда шагыйрь, бу шигырьне, ике юл өстәп, «Кармак» журналында «Кызыл вәгазь» циклы эчендә бастырып чыгара (1917 ел, 10—11).

Бакчабызда *(266 бит)*.— Ш. Бабичның бертуган сеңелләре Фәсәхәт Бабич һәм Рафига Бабич истәлекләре (11 апрель, 1977 ел) буенча бирелә: беренче тапкыр, Фәсәхәт Бабич истәлекләреннән алынып, «Кызыл таң» (Уфа) газетасының 1965 ел 15 январь санында, «Башкортостан пионеры» (Уфа) газетасының 1965 ел 15 январь санында (шагыйрьнең тууына 70 ел тулу уңае белән бирелгән материаллар арасында) һәм «Хезмәт өчен» газетасының (Башкортстан АССРы, Дүртөйле районы) 1967 ел 15 январь санында басылып чыга. Бу шигырь кергән мәкаләләрнең авторы — үз вакытында шагыйрьнең иҗаты, тормышы буенча материаллар туплап йөргән башкорт язучысы Вәзих Исхаков.

Авыл җырлары *(266 бит)*.— Ш. Бабичның Әсән авылының икенче мәхәллә мәдрәсәсендә укыган чорда чыгарган шаян җырлары. Беренче

жыр Мәрьям Мөхәммәдир кызы, икенчесе Шакир ага Сабиров, өченчесе Шәйхелзадә Вахитов истәлекләреннән алынды.

Татар театры *(267 бит)*.— СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы. Тарих, тел һәм әдәбият институтының фәнни архивында саклана торган кулъязма шигырьләр дәфтәреннән алынды. Бу әсәр беренче мәртәбә басыла.

Әсәрнең исеме юкка гына «театр» дип куелмаган. Шагыйрьнең туганнары, замандашлары әйтүенә караганда, бу шигырь ул вакытта авылда театр уйнау өчен сценарий булып та хезмәт иткән.

Берсе — бирге, көндәше — аргы...— Әсәр Әсән авылында яшәүче берәр кешегә багышланган булса кирәк. «Аргы як», «бирге як»— шул авыл өчен хас атамалар.

Авыл мәдрәсәсе такмаклары *(269 бит)*.— Шагыйрьнең авылдашы, яшьлек дусты Шакир ага Сабиров истәлекләре буенча бирелә. Шәкерт Шәехзадә жырлап йөргән бу такмак-жырларның кайберләре билгеле шәкерт жырларының вариантларын тәшкил итәләр. Аерым алганда, «Қалә шәйхе...» дип башланган жырның берничә варианты билгеле. Бу шәкерт жыры хакында Г. Тукай үзенең «Халык әдәбияты»нда (1910) ук язган иде: «Әлбәттә, безнең Кольцовларымыз, Пушкиннәремез булмаганга, мин: «Халык жырларына тәкълид итүчеләр билгемум булдымы?» — дигән сөальне тәкърар итәм дә: «Ник бумасын, булды»,— дип, үз сөалемә үзем җавап бирәм. Менә иң элек мәдрәсә шәкертләре тәкълид иттеләр:

Қаләш-шәйхе фишшифа дип
Укыганың Мантыйкмы?
Ма вәжәдәте, валлаһ, жаный,
Синнән гайре артыкны...»

«Мантыйк»— татар мәдрәсәләрендә махсус укыту предметы булып йөргән формаль логика китабы.

КИТАБЕННАС

(1916—1918)

Китабеннас фи хаккылхавас *(270 бит)*.— Тәрҗемәсе: Күренекле кешеләр хакында китап. Төп өлеше «Кармак» журналының 1916 ел 5—6, 10—11, 14—15, 16—17 саннарында «Шөбшә» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең үз сүзләренә караганда, китап 1917 елның көзендә тәмам булган («Язгалый торгач китапны — аллаһәкбәр ел ярым!»). Әсәрнең 1922 елгы «Шигырьләр мәжмугасы»нда басылган вариантында да кайбер баблар 1917 елга нисбәт ителгән.

Эпиграммалар циклы тәмам булгач та, күрәсең, Бабич аңа кат-кат әйләнеп кайта, ул хәтта, китапны бөтенәйтү йөзеннән, «Фатиха» (кереш, башлангыч), «Бер изах» (бер аңлатма), «Ихтарчык» (искәрмә), «Хатимә» (ахыры), «Зәил» (кушымта) бүлекләрен яза, 1918 елда (июль) аңа «Яңартылганнар» дигән бүлек тә өсти. «Китабеннас»ның тарихына бәйле шундый фикер дә бар: «Галимжан Ибраһимовның шул съездда (Мәскәүдәге Бөтенроссия мөселманнарының Беренче съездында.— *Г. Г.*) сөйләгән сүзләре, бу делегатларга таккан исемнәре соңыннан

Бабич каламе белән сатирик калыпка салындылар» (Сәйфи Кудаш. Ике талант.— «Агиэел», 1965 ел, 8 сан).

«Китабеннас» әсәре тулысынча бары тик 1922 елда Г. Ибраһимов редакциясендә чыккан «Шигырьләр мәҗмугасы»нда дөнья күргән. Ул шулай ук шагыйрьнең ике башкортча сайланмасына да кертелгән.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан алынды. Җыентыкта шагыйрь үзе тәкъдим иткән хронологик принцип сакланды, аңлатмаларда исә охшаш хәрефләр берләштереп бирелде.

Фатиха.

Мартны башлап... аулыма кайттым...—1916 елда «Галия» мәдрәсәсендәге чыгарылыш имтиханнары март аенда ук була. Апрель аенда Зыя Камали («Галия» мәдрәсәсенең мөдире) бушап калган мәдрәсәдә мөгаллимнәр курсы ачу турында хәбәр итә («Йолдыз», 1916 ел, 15 апрель (1635) саны). Шагыйрь монда «Китабеннас»ның март аенда, ягъни имтиханнардан соң авылга кайткач язылуына ишарә итә.

Аулыма...— Уфа губернасы Бөре өязе Әсән авылы (хәзерге Башкортстан АССР Дүртөйле районы).

...атай саулык сорый.— Шагыйрьнең атасы Мөхәммәтзакир Бабичев (1849—1922) хакында сүз бара.

...әнкәй күлеп яулык сорый.— Шагыйрьнең анасы Бибисаҗидәбану Бабичева (1867—1922) хакында сүз бара.

...сикереп йөри сеңлекәй.— Шагыйрьнең иң кече сеңлесе Фәсәхәт Бабичева (1913—1987) хакында сүз бара.

Бисмилла — «Бисмиллаһ иррәхман иррәхим; әгүзе биллаһи минәшшәйтан иррәҗим» (Мәрхәмәтле һәм рәхимле алла исеме белән; ташлар атып куылган шәйтаннан аллага сыгынам) дигән гыйбарәдән (догадан) алынган сүз. Һәр мөселман һәр эшне башлаганда шушы доганы укырга тиеш була.

...атайның китаплар белән тулган шүрлеген.— Мөхәммәдзакир хәзрәтнең Әсән төбәгендә бик билгеле зур китапханәсе булган. К. Насыйри, Акмулла, Р. Фәхретдинев, З. Камали, Тукай китапларыннан кала, бу китапханәдә икенче мәхәллә имамының (Мөхәммәтзакир Бабичев бер үк вакытта икенче мәхәлләнең имамы һәм җәдид «Мәдрәсәи Максудия» мәдрәсәсенең мөдәррисе дә булып тора) үзе язган кулъязма китаплары да хәтсез җыела. Шундый китапларның берсе әлеге җыентыкны төзүченең шәхси архивында саклана.

...таптым китап арасыннан бер китап.— Шагыйрь монда 1909 елда Каримовлар матбагасында басылып чыккан «Вәгазьнамә рисаләсе. Ирәнләргә һәм хатынларга исем белә бәян ителгәндер» (Казан) исемендәге үгет-нәсихәт китабын күз уңында тоткан.

Шәмсетдин, Баһаветдин, Миңнулла, Гыйндулла, Ханнан, Маннаф, Фатыйма, Мәрьям, Гөлҗамал — «Вәгазьнамә»дә телгә алынган кеше исемнәре. Аларга багышланган бәетләр бераз үзгәртүләр белән «Китабеннас»ның «Фатиха» бүлегенә дә күчерелгәннәр.

Нәфел намазы — мәҗбүри булмаган намаз.

...төн буе тәсбих санап...— Тәсбих — «Алла — иң бөек зат» дип кабатлап, тисбе (дисбе) төймәсен тарту. (Тисбе) (тәсбих) 33 яки 99 төймәдән тора.)

Зөлҗәлал — «алла» мәгънәсендә.

«Гыйбадәт»— дини китап исеме.

Азды инсан төрлечә: хайванча да, шайтанча да.— Бу мотив шагыйрьнең «Газазил» поэмасыннан килеп кергән. (Күктән сөрелеп җиргә төшкән Иблиснең кешеләрне яздыру күренешенә игътибар итегез.)

Иблис — дини мифологиядә алла кушуы буенча күктән сөрелгән фәрештә; ул кешеләрне аздырып йөри имеш.

Җен — халык мифологиясендә традицион герой.

«Әл-фил» — Коръәннең фил хакындагы 105 нче сүрәсе. «Мәл-фил»— «Әл-фил»дән юри үзгәртелеп ясалган исем.

«Зөһрә җаннар»— Галиәсгар Камал әсәре, «Таһир-Зөһрә» китабына ияреп язылган.

Без, Шәрекъ, булдык Гаребтәй, шигъри күлмәк тәктереп.— Шагыйрь монда Көнбатыш әдәбияты формалары белән мавыгып, «заманча» шигърият тудырырга теләүчеләрдән көлеп яза.

Пушкин Александр Сергеевич (1799—1837) — күренекле рус шагыйре.

Шекспир Вильям (1564—1616)— инглиз драматургы һәм шагыйре.

Иске дөнья бар чагында нәрсә ул Америка!— Шагыйрь бу очракта Американың халык телендә йөргән исеменә ишарә итә («Новый свет»).

Йөрде пәйгамбәргә охшап Миргаләветдин мишәр — үзен Мөхәммәттән соңгы пәйгамбәр дип йөргән Саратов сәүдәгәре.

Бибигөлбанат — татар хатын-кызларына бирелгән җыелма исем.

«Баб-эл-әлеф» — гарәп алфавитындагы беренче хәрефкә башланган бүлек. «Китабеннас»ның үзендә шагыйрь аны «Хәмзә бабы» дип биргән. *Хәмзә* — гарәп графикасында йомык, киселеп әйтелә торган тартыкны («э») белдерүче билге.

Әхмәт Исхакый — Орск шәһәрендә китап сәүдәсе белән шөгыльләнгән кеше. Бабичлар үз китапханәләренә китапларны шул кешедән кайтарткаННар.

«Шәрекъ» — Ә. Исхакый тоткан китап магазины «Шәрекъ көтепханәсе» дип аталган.

Шөбшә — Ш. Бабичның псевдонимы; «Китаб-эн-нас...» эпиграммалары «Кармак» журналында шушы имза белән басылган.

Ихтарчык.

Карга көйгә сандугач мин, дип йөрү...— Журналист һәм җырчы Камил Мотыйгый концертларына ишарә.

Хиффәтуллин — Шагыйрь җырчы К. Мотыйгыйга карата яратып куллана торган кушамат.

Китапның үзе.

Хәмзә бабы.

Әхмәт Исхакый (Әхмәт Исхак) — Орск шәһәрендә «Шәрекъ көтепханәсе» тоткан кеше. Аның хакында «Китабеннас»ның кереш өлешендә сүз бара.

Рисалә — китап.

Әхмәт әл-Урманчи — Әхмәт Урманчиев (?—1922)—1910—1918 елларда Казанда чыккан «Ялт-йолт» исемле рәсемле сатирик журналның нашире һәм редакторы.

Әхмәт Таҗетдин — Әхмәттаҗетдинн Мөхәммәтҗан улы Рахманкулов, (1942 елда үлгән) — журналист, унынчы елларда Истамбулда «Мәгариф әл-мөслимин» («Мөселманнар мәгарифе») дигән журналда эшләгән; 1915 елларда Оренбургтагы «Шура» журналында язышкан, соңрак Троицк шәһәрендә Ш. Бабичның үз катнашлыгында чыккан «Хөр милләт» (1917 ел, апрель) газетасының редакторы.

Әхмәт әл-һади — Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди (1868—1941)— Казанда чыккан «Йолдыз» газетасының нашире һәм редакторы, «Мөселман иттифакы» дигән партиянең актив әгъзасы.

«Әлифба»— һади Максуди шулай ук дәреслекләр язучы буларак та билгеле. Аның «Төрки нәхүе» (төрки синтаксисы), «Мизанел әфкяр»

(фикер үлчәве), «Мөгаллиме әүвәл» (әлифба) кебек китап-дәреслекләре билгеле. Эпиграммада соңгысы хакында сүз бара.

Исхакый Гаяз — Гаяз Гыйләҗетдин улы Исхаков (1871—1954)— билгеле татар язучысы; Мәскәүдә чыккан «Ил» газетасының редакторы, «Мөселман иттифакы» дигән партиянең актив әгъзасы, Октябрь революциясеннән соң эмигрант.

«Мулла» («Мулла бабай»), «Шәкерт абый» — Гаяз Исхакый әсәрләре.

Әхмәдиев — Шәһид Әхмәдиев (1888—1930) — язучы, җәмәгать эшлеклесе; баштарак «Йолдыз» газетасы сотруднигы, революция елларында «Аваз» газетасы (1917—1918, Уфа) редакторы, Коммунистлар партиясе әгъзасы, Октябрь революциясеннән соң ТАССРның беренче мәгариф комиссары.

Туктаров — Фуад Туктаров (1882—1934) — уң эсер, буржуаз милләтче, публицист, Октябрьдән соң эмигрант.

Соңгы ике эпиграммага Ш. Бабич үзе шундый аңлатма биргән: «Берзаман «Йолдыз» белән «Ил»дә Һади белән Шәһид бер яктан, Гаяз белән Туктаров икенче яктан торып сугыштылар». Бу очракта, күрәсең, шагыйрь Ф. Туктаровның «Ил»дәге мәкаләләренә каршы Ш. Әхмәдиевнең «Мәхмүд Фуадка тәнбия» дигән мәкалә бастыруын күз уңында тоткан. (Кара: «Йолдыз», 1916 ел, 19 февраль саны (1610.)

«Ил»—1913—1915 елларда Петербургта, 1917—1918 елларда Мәскәүдә чыккан буржуаз газета.

...үз кулыңда сөзгечең. — Шагыйрь монда Ш. Әхмәдиевнең, газета сотруднигы буларак, редакциягә килгән мәкаләләрне бәяләргә-хупларга яки кире кагарга хокукы булуын искәртә булса кирәк.

Әхтәмев Биниәмин — Биниәмин Гөбдессегуд улы Әхтәмев (Әхтәм мирза)— дворян, юрист, меньшевик, Уфадан Вакытлы хөкүмәт эмиссары; 1914 елда Петербургта Сәлимгәрәй Җантурин белән берлектә «Милләт» газетасы чыгарган. Шуны искәртергә кирәк, Ш. Бабичның: «Шәкерт һәм мөгаллимнәргә отсрочка сорап йөргән чагы» дигән искәрмәсенең тарихи нигезе бар. (Кара: «Кояш» (Казан), 1916 ел, 2 февраль (909) саны.)

Укмаси Миркәй-Газиз — Миргазиз Каюм улы Укмасый (Зәбиров, 1884—1946) — татар шагыйре.— «Китабеннас»ның 1916 елда «Кармак» журналында (5—6 саннар) басылган вариантта бу эпиграмманың икенче юлы түбәндәгечә: «Ук түгел, туп тисә дә, сизмәс вә курыкмастыр хәзер». Бу кеше шулай ук революциягә кадәр «Менә дигән шәп җырлар», «Менә сиңа шәп җырлар», «Җырлар тарихы» кебек китаплар чыгарган. Революциядән соң мәгариф эшчесе.

Әмирхан Фатих — күренекле татар язучысы Фатих Әмирхан (1886—1926).

«Фәтхулла хәзрәт», «Хәят», «Урталыкта» — Ф. Әмирханның мәгълүм әсәрләре.

«Урталыктан» чыкмасыннар... — «Урталыкта» романының, эшләнеп бетмичә, урта кул әсәр булып калуына, ә язучының, укучылар өметен акламыйча, актив иҗат эшеннән китүенә ишарә ителә.

Шуны да әйтергә кирәк, Ф. Әмирханга багышланган бу эпиграмманың бер варианты Бабичка нисбәт ителгән «Авыл җырлары»нда очраган иде инде («Кармак», 1915 ел, 6 сан):

Мәңгәрләрнең йорты зәңгәр, без дә шулай буятыйк,
«Урталыкта», «Хәят» чыкмый, «Кояш» укып юатыйк.

Мәңгәр — хәзерге Татарстан АССРның Арча районына кергән авыл.

«Кояш» — 1912—1918 елларда Казанда чыккан либераль-буржуаз газета. Аның эшчәнлегендә Ф. Әмирхан якыннан торып катнаша.

Ибраһим Гыйрфанзадә Галимҗан — Галимҗан Гыйрфан улы Ибра-

һимов (1887—1938) — күренекле татар язучысы, галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, Ш. Бабичның остазы һәм дусты. Эпиграммага шагыйрь үзе шундый аңлатма биргән: «Галия»дә һәм кызлар курсында укытып йөргән чагы иде.»

...кызлар курсында укытып йөргән чагы иде.—1916 елда Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсе каршында Зыя Камали тарафыннан оештырылган «Дарелмөгаллимәт»тә укыта.

Әл-Иманколый Садыйк — Садыйк Шаһиәхмәт улы Иманколов (?—1938) — Оренбургта чыккан «Дин вә мәгыйшәт» («Дин һәм тормыш») исемле дини-реакцион журналда шигырьләр, мәкаләләр бастырган Казан мулласы.

Габдрахман Сәгъдиев — Габдрахман Гайнан улы Сәгъди (1889—1956) — татар әдәбияты тарихчысы, профессор; баштарак Казанда, соңрак Ташкент һәм Сәмәрканд унверситетларында эшли.

Ишмөхәммәт — Ишмөхәммәт Динмөхәммәт улы (Ишми ишан, 1839—1919) — элекке Вятка губернасы Малмыж өязе (хәзерге Татарстан АССРның Балтач районы) Түнтәр авылы мулласы; карагруһ динче, патша охранкасы агенты, татар тормышындагы бөтен прогрессив һәм демократик хәрәкәтне буып торуга зур сәбәпче булган кеше; Г. Тукай аңа күп мәртәбәләр сатира язган («Доносчы колагына», «Ишан» һ. б.).

...үз табагыңа үзең тик әйдә кос!— Милләтне агартам дип йөргән Ишми ишан үз донослары белән милли культура хәрәкәтенә әйтеп бетермәслек зур зыян китерә, дип аңларга кирәк.

Әхсән Кормашый — «Шура» (Оренбург) һәм «Аң» (Казан) журналларында шигырьләр, кыска хикәяләр бастырган кеше.

Ике Идрискә — Эпиграммада Идрис Хәмиди белән Идрис Богданов күз уңында тотыла (Бабичның үз аңлатмасы). *Идрис Хәмиди* — матбугатта язышкан, 1915 елда «Рәсемле гыйльме хайуанат» («Хайваннар турында рәсемле зоология») дигән дәреслек бастырган; *Идрис Богданов* — рус теле укытучысы, кайсы бер рус язучыларының китапларын татар теленә тәрҗемә иткән; үзе дә «Помада мәсьәләсе» (пьеса) һәм «Югалган хатын» (хикәя) кебек әсәрләре белән билгеле.

Ибраһим Әхтәм — Ибраһим Габдессөгуд улы Әхтәмов — Уфа дворяны, юрист.

Б. бабына.

Батталов — Габделбарый Габдулла улы Сәетбатталов (Барый Баттал, 1873—1959) — буржуаз тарихчы, әдәбият белгече; «Йолдыз» газетасында һәм «Аң», «Шура» журналларында язышкан милләтче журналист. 1917 елда Казанда «Корылтай» исемле буржуаз газетаны оештыручыларның берсе; ул туктагач, 1918 елда «Алтай» дигән газета чыгара. Соңыннан — эмигрант.

Ш. Бабич үз эпиграммасында Г. Батталның «Йолдыз» газетасында басылган мәкалә-мактауларына ишарә итә.

Бикбулат — Сөнгатулла Нигъмәтулла улы Бикбулатов (1886—1954) — Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытучы, берничә дини дәреслек авторы. Октябрь революциясеннән соң Казан университетында гарәп теле укыткан.

Буранбай — «Кармак» журналында язышкан һәм 1916 елның башыннан матбугатта сирәк күренгән бер язучының псевдонимы.

Буби Габдуллалары — Эпиграммада Сарапул шәһәре тирәсендәге Иж-Буби дигән авылда (хәзерге ТАССРның Әгерҗе районында) урнашкан «Иж-Буби» мәдрәсәсенең җитәкчеләре, агалы-энеле Нигъмәтуллиннар хакында сүз бара. Габдулла Буби — Габдулла Габделгалләм улы Нигъмәтуллин (1871—1922) һәм Гобәйдулла Габделгалләм улы

Нигъмәтуллиннар үз мәдрәсәләрендә җәдитче укытучылар әзерләгәннәр. Әмма 1911 елда Бубилар Ишми ишан доносы белән мәдрәсәдән куылалар, төрмәгә ябылалар, ә мәдрәсә үзе яшәүдән туктый. 1912 елның маенда Сарапул шәһәрендә Казан губернасының суд палатасы Буби мәктәбен ябарга хөкем чыгара. (Бу хакта кара: *М.* Мәһдиев. Әдәбият һәм чынбарлык. Казан, 1987, 144 бит.) 1912 елда Г. Тукай да: «Былтыр Гүнтәр тарафыннан Дәҗҗал мәлгунь чыгып, теләгәннәрен оҗмахка, теләгәннәрен — тәмугка кертеп йөрде»,— дип язып чыккан иде. Г. Тукай мәкаләсе рухында Ш. Бабич та 1913 елда «Ишми сөенә» фельетонын яза һәм анда Ишми ишаннан: «Доносым белән «Буби мәдрәсәсе»нең төбенә җиткән идем, аллага шөкер...»— дип әйттертә. (Кара: «Акмулла», 1913 ел, 23 сан.)

Изге мәктәп... — «Иж Буби» мәдрәсәсе хакында сүз бара.

Кушмый шайтаннар угы.— Ишми ишан доносы дип аңларга кирәк. Доносчы ишан Ишмөхәммәт Динмөхәммәтевкә бирелгән бу кушамат Г. Тукайның «Кушмый ишәк җырлый» исемле шигыреннән үк килә.

Баллы Багъбостан ханым — Багъбостан Вилдан кызы Мөэминова (1884—1963)— XX йөз башында мәгърифәтче хатын-кызларның иң күренеклесе. 1908 елда Оренбургта кызлар мәктәбе оештырып, шул ук вакытта дәреслекләр язу, алдынгы фәннәр пропагандалау белән танылган Багъбостан ханым.— Ш. Бабичның якын танышы, дусты. 1917 еллар ахырында, ягъни Багъбостан мәктәбенең даны тирә-якта шаулаган бер мәлдә, Оренбургка Бабич килә һәм шунда бу «Мәктәп»нең якын дусты булып китә, анда төрле вакытларда укытып йөргән Р. Фәхретдинев, Ф. Кәрими, К. Бәкер, Н. Надиев, С. Бикбулат, И. Терегулов, И. Бикчәнтәй, Ш. Манатовлар белән аралаша.

Баллы Багъбостан... — «Баллы» кушаматының тарихы Багъбостан йортында узган кунак сыйларыннан килә. Мөэминовларның балга-майга бай кунак өстәле, күрәсең, шагыйрь каләменнән читтә кала алмаган. Бу хакта ул үзенең «Багъбостанда» исемле шигырендә дә әйтеп уза:

Алдыбызда май белән баллар торалар: кап! диеп,
Һәм Бабич та кычкыра: «Ныграк аша, Исхак!» диеп...

Исхак — шагыйрь һәм артист Исхак Зәйни.

Тәңре гафу итсен...— Багъбостан Мөэминова ачып җибәргән мәгърифәт учагының дошманнары — руханилар һәм байбәтчәләр, «Багъбостан мәктәбен» яптырып, аны тәңре алдында «гөнаһлы» дип игълан итәргә тырышалар. Өстәвенә бу кыю татар мөгаллимәсенең тормышын карага буяп, төрле бозыклыклар, рия-хәйләләр пәрдәсенә төреп бирмәкче булалар. (Кара: Сәйфи Кудаш. Халкыбызның каһарман бер кызы.— «Казан утлары», 1984, 10 сан, 164—169 битләр.) Бабич руханиларның шушы кампаниясенә ирония белдереп яза.

Т. бабына.

Туктаров Мәхмүт — Мәхмүт Фәссах улы Туктаров — юрист һәм журналист, эсерлар партиясе әгъзасы. 1906 елда Казанда чыккан «Таң» газетасының (соңыннан «Таң мәҗмугасы»ның) редакторы, «Ил» газетасында, аннары «Сүз» газетасында актив язышкан: революциядән соң эмигрант. Бабич эпиграммасы язылган чорда М. Туктаров: «Татар милләтенең үсеше ислам диненнән башка мөмкин түгел»,— дип, мәчетләр санын арттыруны, муллалар әзерләүне, дини-схоластик мәдрәсәләрне күбәйтүне кайгыртып йөри.

Эпиграмманың «Кармак»та (1916 ел, 5—6) басылган тәүге вариантында икенче юл түбәндәгечә: «Чөнки җәнҗал амбарында төрле запас күп тора».

Тинчурин Үзбәк-Кәрим — Кәрим Мөхәммәтгали улы Тинчурин

(Үзбәк — аның псевдонимы) (1881—1947) — күренекле татар драматургы, режиссер, артист.

Терегулов Үмәр — Гомәр Хәбибрахман улы Терегулов (Гомәр мирза) — юрист, Уфа губерна земствосы хезмәткәре; бер үк вакытта культура-сәнгать мәсьәләләрен кайгыртып, актив иҗтимагый эш башкарган һәм земствода патша хөкүмәте политикасына турылыклы булып йөрүе белән билгеле. Ш. Бабич аның шушы өч яклы эшчәнлеген «өчпочмаклы» дип атый. Г. Терегуловның мондый күпкырлы эшчәнлегенә шагыйрь үзенең «Уфа сәхнәсендән» исемле мәкаләсендә кабат әйләнеп кайтачак әле. (Кара: «Кармак», 1916 ел, 19—20 саннар.) Революция чорында Терегулов меньшевик, соңрак колчакчы булып таныла, эмиграциягә китә.

Земство — революциягә кадәрге Россиядә дворяннар һәм буржуазия кулындагы җирле идарә системасы.

Төхфәтуллин — Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин (1883—1940) — Уральскида чыккан «Фикер» (1905—1907) газетасының, «Уклар» (1906) һәм «Әлгасрел-җәдид» («Яңа гасыр», 1906—1907) журналларының нашире һәм редакторы; соңрак җырчы һәм артист.

...мөфәссир... — Коръән тәрҗемә итүче дигәнне белдерә. Вакытында К. Мотыйгый Коръәнгә татарча аңлатма биреп караган. Шагыйрь шуңа ишарә итә.

Тәфкилев — Котлугъмөхәммәт Тевкелев (1675—1766) — 1735—1736 елгы башкорт восстаниесен бастыруда аеруча нык ерткычлык күрсәткән полковник чинындагы морза. Соңрак ул, Урта Азия һәм казакъ ханнары белән рус патшалары арасында тәрҗеманлык кылып, генерал дәрәҗәсенә күтәрелә.

Морза — татар дворянлыгын белдерә торган титул.

Ташмөхәммәт — күренекле татар язучысы Фатих Әмирханның (1886—1926) яшерен имзасы (псевдонимы). Бу эпиграмма 1916 елда ике әдип арасында килеп чыккан аңлашылмаучанлыкка мөнәсәбәттәрәк язылган булса кирәк. Эш шунда ки, 1914 елда «Аң» журналының 15 санында «Ташмөхәммәд»нең «Танс кичәсе» исемле хикәясе басылып чыга. 1916 елда Ш. Бабич бу әсәрне үзенең «Көлке капчыгы» (Әдәбият кичәләре шәрәфенә, Уфа, «Тормыш» матбагасы) исемле җыентыгына урнаштыра, әлбәттә, «Ташмөхәммәд» псевдонимы астында. Шушы уңай белән Ф. Әмирхан «Кояш» газетасының 1917 ел 18 апрель (1107) санында «Ш. Бабич әфәндегә ачык хат» («Ташмөхәммәд») бастырган. Анда шундый юллар бар: «Сез «Көлке капчыгы» исеме белән тәртип иткән мәҗмугагызда минем «Танс кичәсе» исемле бер хикәямне үземнән яшереп кенә тәбегъ вә нәшер иткән икәнсез. Язучысыннан сорамый гына хикәяләрне тәбегъ иттереп чыгаруның җиңел кәсеп икәнлеген игътираф итү белән бергә, мин бу эшкә бик начар һөнәр дип карыйм...»

Таһири — Һади Таһири — 1915—1916 елларда «Шура» журналында шигырьләр һәм хикәяләр бастырган Екатеринбург (хәзерге Свердловск) укытучысы.

Тупчыбаш — Галимәрдән Тупчыбашев — алпавыт һәм адвокат; Азәрбайҗанда билгеле буржуаз милләтче, «мусаватчылар»ның берсе, Бакудан I Дәүләт думасына депутат, шул Думада мөселман фракциясе җитәкчесе; шулай ук «Каспий», «Хәят» газеталарының редакторы вазифасын башкаручы буларак та билгеле. Октябрь революциясеннән соң эмиграциядә. Тупчыбаш — аның матбугатта язышкан имзасы.

Таңгатар — Әхнәф Җиһангир улы Таңгатаров (1892—1953) — башкорт язучысы, вакытлы матбугатта басылган кыска хикәяләр һәм нәсерләр авторы; Совет чорында мәгариф эшчесе.

...татар. — 1909 елда «Шура» журналы тарафыннан «саф татар телендә язылган» әсәрләргә үткәрелгән «тел ярышында» (конкурста)

икенче буләкне алган кеше дә шул Әхнәф Тангатаров. Ш. Бабич күпмедер дәрәҗәдә әнә шул фактка ишарә итеп яза. Бу хакта ул эпиграммага бирелгән махсус искәрмәсендә дә әйтүне кирәк тапкан: «Тангатаровның башкорт икәнлеге мәгълүм булса да, назым үзгәртелмәде, чөнки, бердән, назым (шигырь ритмы.— *Г. Г.*), икенчедән, мөшәр иләйсинең (югарыда әйтелгән кешенең.— *Г. Г.*) язуларында «татарлар» лафзының (сүзенең.— *Г. Г.*) хисабыннан күп булуы шуны тели».

Җ. бабына.

Җиһангир — Җиһангир Абызгилдин — Уфа мулласы, «Шура» һәм «Дин вә мәгыйшәт» журналларында язышкан, берничә дини китап чыгарган.

Ш. Бабичның бу эпиграммасы 1915—1916 елларда «Галия» мәдрәсәсе тирәсендә барган зур ызгыш-гаугаларга мөнәсәбәттә язылган. 1915 елның август аенда Уфаның кайбер байлары һәм интеллигенция вәкилләре, аерым алганда Мәхмүд Алкин, Сәлимгәрәй Җантурин, Садретдин Нәзирев, Сабирҗан Шәмигулов, Хәсән Кәримев, Бәдретдин Нәзиревләр тарафыннан «Мәдрәсәи «Галия»нең әлеге бинасын ташлап чыгуларның сәбәпләрен вә мәдрәсәне икенче бер урында дәвам иттерергә карар биргәнлекләрен» белдергән мәкаләләр языла. (Кара: «Йолдыз», 1916 ел, 27 май (1651) саны.) Уфа байлары үзләренең бу хактагы фикерләрен бер төркем укымышлылар белән уртаклашырга, нәтиҗәдә бер фикергә килергә теләп, шул ук елның сентябрь аенда Закир Кадири, Әхмәд Зәки Вәлиди, Габдулла Шонаси, Гомәр Терегуловларны чакырып, зур мәҗлес оештыралар. Мәҗлес «Галия» мәдрәсәсендә кулланылган программаны яраксыз дип таба, аны динсезлектә, шәригать законнарыннан читкә тайпылуда гаепли. Ул мәдрәсәнең «үзенә башка бер бина салу яки, мауҗуд мәдрәсәләрдән берсенә кереп, ислах вә тәкълим итеп урнашу» мөмкинлеген көн тәртибенә куя. Мәҗлес шулай ук яңа ачылган мәдрәсәнең сметасын да карый, аңа һәр ел саен 16 мең сум акча биреләчәген дә раслый. Шунда ук яңа мәдрәсәнең урыны мәсьәләсе карала. «Галия»не Уфадагы икенче бер зур мәдрәсә — «Мәдрәсәи Госмания» белән кушу фикере җиңеп чыга. Нәкъ менә шушы вакытта хәлиткеч сүзне Уфа ахуны Җиһангир хәзрәт әйтергә тиеш була. Чөнки аның рөхсәтеннән башка андый зур эшнең уңышлы барып чыгуы мәҗлес вәкилләрен ышандырмый. Җиһангир Абызгилдин берсүзсез рөхсәт бирә. Әмма мәҗлесне бер хәл борчый. Яңа мәдрәсәгә мөгаллимнәр чакыру өчен, программаны яңабаштан үзгәртеп эшләү өчен вакыт бик аз калган була. Шул сәбәпле, «Галия»не башка урынга күчерү эшен 1916—1917 нче уку елына кадәр кичектереп торырга булалар. Шунда ук «мәдрәсәне вөҗүдкә чыгару эшләрен, устав вә программаларын, киләсе уку елына чаклы карап хәзерләп куяр өчен» махсус комиссия дә төзелә. Аңа «Госмания» укытучысы Зәки Вәлиди һәм «Галия»не ташлап чыгып киткән мөгаллим Габдулла Шонасилар кертелә. «Боларның эшләгән эшләрен яз житкәч ныклап карауны» Закир Кадири, Гомәр Терегулов, Сәлимгәрәй Җантуриннарга тапшыралар.

Ел барышында мәҗлес карары буенча актив эш алып барыла. З. Вәлиди белән Г. Шонаси, булачак яңа мәдрәсә өчен уку китаплары язып, аларны тиз арада «Госмания»дә сыный да башлыйлар. Алар бер үк вакытта яңа программа һәм яңа устав төзү белән шөгыльләнәләр. Анда аерым фәннәрне генә түгел, сыйныфлар (класслар) тәртибен дә үзгәртү карала. Мәдрәсә өчен яңа йорт эзләү башлана...

«Галия» мәдрәсәсе тарихында, шул рәвешле, Җиһангир Абызгилдин хәлиткеч роль уйный. Шуңа күрә дә Бабич аңа үз сатирасында аеруча каты бәрелә.

Жамалетдин — Җамалетдин Җәлалетдин улы Вәлидов (Җамал Вәлиди, 1887—1932) — татар әдәбиятчысы һәм телчесе.

Син, Җамалетдин, Гаребтән кайт Шәрекъка әйләнеп.— Җ. Вәлиди «Аң» журналының 1915 ел 3—7 саннарында басылган «Әдәби хәрәкәт» дигән мәкаләсендә Шәрекъ әдәбияты белән Гареп (Көнбатыш) әдәбияты арасындагы мөнәсәбәтне тасвир итү белән мавыгып киткән. Эпиграммада Бабич әнә шуңа ишарә итә.

Җамалетдин Юмаев — Җамалетдин Гыймалетдин улы Юмаев (1892—1940) — Уфада чыккан либераль-буржуаз «Тормыш» газетасының сотрудникы, унынчы елларда «Аң», «Шура», «Акмулла», «Сөембикә» журналларында актив язышучы шагыйрь. Аның Казанда «Җамалетдин Юмаев шигырьләре» (1913) һәм «Әдәби шигырьләр» (1915) исемле китаплары басылып чыккан. Ш. Бабичның якын танышларыннан берсе, революциядән соң авылларда укытучы.

«Китабеннас»ның «Кармак» журналында (1916 ел, 10—11 саннар) басылган вариантында эпиграмманың икенче юлы түбәндәгечә: «Әй, һаман яшерен яну белән гомергә Туңмаев».

...изелгәннән изелгән Уңмаев.— Монда шагыйрь «Тормыш» газетасы сотрудникларының хуҗалары кул астында буйсынып, изелеп яшәвенә ишарә итә. Бу хакта Бабич үзенең «Уфа хәлләре мөндәриҗәсе» исемле фельетонында да язып чыккан иде.

Җамалетдин Кормаши — Бәләбәй мулласы, берничә Дәүләт думасы әгъзасы.

Шөһрәт алдың сыздырып Коръән юбилейларда син.— Романовларның өч йөз еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә алар хөрмәтенә Петербургта Коръән укып йөргән кеше. Бабич шуңа ишарә белдерә.

Әл-Җәлалев — Вәкыйф әл-Җәлали (1886—1922) — татар шагыйре, дистәдән артык шигырь китабының авторы, революциядән соң Урта Азиягә китә, шунда фаҗигале рәвештә һәлак була.

...Булдың әсирлек хәлена.— Шагыйрь монда Вәкыйф Җәлалның Казанда Гайшә Апанаева дигән бер карт хатынга йортка керүен, «әсирлек хәленә төшү»гә («чын вакыйф булу»га) тиңләп яза.

...тончыгып үләр фоган вә зарына.— (*Фоган вә зарына* — ялваруына һәм зарына). В. Җәлалиең моң-зар тулы, ярым мөнаҗәт тибындагы шигырьләренә ишарә ителә.

Җантурин — Сәлимгәрәй Җантурин (1864—?) — Уфа губернасындагы иң эре алпавытларның берсе, буржуаз милләтче; заманында Мәскәү университетын тәмамлаган. Уфа губернасында мировой судья, земство башлыгы, I Дәүләт думасына депутат булып тора. 1914 елда Дәүләт думасы каршында «Милләт» исемле газета чыгара (редакторы — Биниәмин Әхтәмев).

Сәлимгәрәй Җантурин Уфадагы милләт мәҗлесләрен, мәктәп-мәдрәсәләрне материаль яктан тәэмин итеп торган. Аерым алганда, ул 1906 елда «Галия» мәдрәсәсен салдыру өчен 30 мең сум акча биргән. Әмма ул 1916 елда, бер төркем Уфа байлары һәм буржуаз интеллигенция вәкилләре белән бергә, бу мәдрәсәгә ярдәм итүдән баш тарта һәм, «Галия»не бөтенләй ябарга кирәк, дигән тәкъдим белән чыга. Эпиграммада Җантуринның шундый «юмартлыгы»ннан көленә.

...трим-трим — анда трим, монда трим.— Музыкаль тактны белдерүче бу юллар зур мәгънәгә ия. Билгеле булганча, Уфа байлары, руханилары иң беренче чиратта «Галия»дәге культура реформасына каршы чыгалар. 1915 елда «Галия»дә Г. Ибраһимов татар теле һәм әдәбияты укыта башлагач, аның инициативасы белән укыту программасына музыка дәресләре кертелгән була. Мәдрәсәдә Варшавадан эвакуацияләнеп кайткан музыка профессоры Вильгельм Клименц дәресләр бирә башлый. Ул шулай ук шәкертләрдән профессиональ дәрә-

җәле зур кыллы оркестр оештыра. Ш. Бабич бу оркестрның әйдәүче солистларыннан берсенә әверелә. Шагыйрь, шул рәвешле, үз эпиграммасында, әлеге музыка дәресләрен сәбәп итеп, мәдрәсәне ябтырырга йөргән Уфа баеннан көлә.

Җарулла Муса — Муса Ярулла улы Бигиев (1873—1949) — Петербург мулласы, дин философы; татар буржуаз милләтчеләрен рухландырып китаплар язган кеше, «Мөселман иттифакы» дигән буржуаз партиянең актив әгъзасы. Октябрь революциясеннән соң эмигрант.

Байрашевлар — Петербургның аеруча реакцион байлары. Үзен татарның иң алдынгы зыялылары рәтеннән исәпләп йөргән Муса Бигиев ахырдан шул Байрашевларга («Кармак»ның 1916 ел 10—11 санында басылган беренче вариантта Майлашевлар) барып сыена. Демократик әдәбият һәм матбугат вәкилләре тарафыннан әйтелгән тәнкыйть, Ш. Бабич фикеренчә, Муса Бигиев башына гаса (*таяк* — Ш. Бабичның үз искәрмәсе) булып төшә.

Х. бабына.

Әл-Харис Фәйзи — Харис Зариф улы Фәйзуллин (Харис Фәйзи-Чистапули, 1870—1933) — 1907—1908 елларда «Әхбәр» исемле газета чыгарып йөргән журналист; «Хөсәения» (Оренбург) мәдрәсәсендә тарих, әдәбият, физика, математика укытучысы; соңрак миллионер Хөсәеневләрдә (Оренбург) доверенный булып йөргән кеше. Ул шулай ук «Гыйльме әшъя» («Физика»), «Тәгълим җәгърәфия» («География»), «Мохтасар тарих» («Кыскача тарих») кебек дәреслекләр авторы буларак та билгеле. Октябрь революциясеннән соң «Кызыл Татарстан» (Казан) газетасында бухгалтер һәм кассир хезмәтен башкара. Харис Фәйзуллин — күренекле татар композиторы Җәүдәт Фәйзинең атасы.

1917 елда Оренбургка килгәч, Ш. Бабич Фәйзуллиннар гаиләсе белән тыгыз элэмтәдә яши, Җәүдәтнең музыка белән кызыксынып китүендә билгеле роль уйный. (Кара: «Казан утлары», 1968 ел, 1 сан, 123 бит.)

«Әшъя»сыз да баш яши... — Х. Фәйзуллинның югарыда телгә алынган «Физика» китабы хакында сүз бара.

Әл-Харис Корбангали — Троицкидагы Яушевлар мәктәбендә укытучы-хәлфә.

Харрас ишан — Харрас Айдаров (Айдар) — Оренбург Каргалысында имам хатиб мөдәррис (җәдит мәдрәсәсе тоткан), соңрак Ялтада мөгаллим булган, бер үк вакытта «Дин вә мәгыйшәт» журналының хәбәрчесе булып торган. 1904 елда аның «Мөназәрә» («Бәхәс») исемле китап язуы билгеле. Камил Мотыйгый белән полимикага нигезләнгән хатлар тупланган бу китаптан ялган фәннилек, ялган фәлсәфә, ялган эшлеклелек аңкып тора. Ш. Бабич үз эпиграммасында шуңа ишарә итә булса кирәк.

Алдар ишан — халыкны алдап йөрүче рухани дип аңларга кирәк.

Хәлим Сабит — Истамбулда укыган һәм шунда чыккан «Истамбул мәҗмугасы» дигән журналның редакторы булган Уфа кешесе.

Хәлим Искәндәрев (1888—1958) — шагыйрь, тәнкыйтьче, журналист; педагог; башта Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыган, аннары Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә күчкән, аны тәмам иткәч, Троицкига кайтып укытып йөргән, «Белек йорты» исемле хрестоматия төзегән, берничә дәреслек язган, «Йолдыз»да укыту мәсьәләләре буенча мәкаләләр бастырган кеше. 1918 елда Уфада «Ил тели» исемле газетаның редакторы була һәм «Кызыл яу» газетасын чыгарыша. Совет власте елларында балалар укыта, Арча (ТАССР) педагогия училищесында эшли.

Троицкины да кузгатма, торсын искечә!.. — Х. Искәндәрев, ни сәбәптәндер, Троицк яшьләре оештырган матбугат эшләренә, кичәләргә

бик салкын карый. Аның йөзендә Бабич 1916 елда чыгудан туктаган «Акмулла» язмышы белән килешүче битараф шәһәр интеллигенциясен тәнкыйтьләп, аларга ирония белән «мәдхия» укый.

Әл-Хәлил — Ягъкуб Ибраһим улы Хәлили (1877—1945) — 1913—1917 елларда Казанда «Сөембикә» исемле хатын-кызлар журналы чыгаручы (редакторы), «Мөгамәләт», «Гыйльме хак», «Иң яңа әлифба» дигән китапларның авторы.

«Сакаллы-абыстай...» — Монда Я. Хәлилинең хатын-кызлар журналында эшләвенә ишарә бар. «Сакаллы абыстай» кушаматы уңае белән «Кармак» журналының 1915 ел 16 санында басылып чыккан бер мәкалә игътибарга лаеклы. «Әстерхан шәһәрендә әдиб вә әдибәләр («Сөембикә» кәшәфиятендән) дип аталган бу язмада нәкъ менә шундый ук «кырылган сакаллы хатын-кызлар» хакында сүз бара. «Колак» имзасы астында язышучы ул кеше белән «Китабеннас» авторын бер үк кеше берләштерүе бик мөмкин.

Шул рәвешле, шагыйрь монда татар хатын-кызлары арасында үз журналларында редактор булырлык кеше юклыгына зарлана.

Хәсән Акчурин — Сембер (хәзерге Куйбышев шәһәре) губернасында зур сукно фабрикасы тоткан бай.

Хәсән Гата казый — Хәсәнгата Мөхәммәт улы Габәши (1863—1930) — тарихчы, рухани, 1908—1914 елларда Уфадагы Диния нәзарәтендә казый булып торган, бер үк вакытта шул нәзарәт каршында чыгып килгән «Мәгълүмат» (1908—1911) журналының редакторы да. Унынчы елларда тарих фәне һәм музыка мәсьәләләре буенча берничә китап чыгарган. Соңыннан Казанга күчеп киткән. Тарих фәненә һәвәслеге әлектән үк — Ш. Мәрҗани белән якын танышлыгыннан ук килә (Х. Габәши чыгышы белән Ш. Мәрҗанинең якташы һәм ерак туганы). Татарның беренче профессиональ композиторы Солтан Габәши (Ш. Бабичның дусты һәм «Галия» буенча шәриктәше) — Хәсәнгата Габәшинең улы.

Сагына сине Уфа... — Ш. Бабичның шундый искәрмәсе бар: «Уфадан, казыйлыгын ташлап, Казанга киткән иде.»

...карты-яше синнән разый. — Хәсәнгата Габәши, Уфадагы Диния нәзарәтендә казый булып торганда, җыр-музыка сәнгате үсешенә каршы булган дини руханилар белән каршылыкка керә. 1905 елгы революция белән рухланган татар яшьләре һәр җирдә музыкаль кичәләр оештыралар, концертлар бирәләр. Кадимчеләр исә, «шәригать законнары» нигезендә, бу кичәләрне тыймакчы булалар. Әмма Диния нәзарәте казые Х. Габәши алдынгы карашлы яшьләрне, зыялыларны яклап чыга. Ул болай ди: «Халыкны җырсыз, музыкасыз калдырсаң, ул үлә». «Вакыт» газетасы Х. Габәшине яклап чыккач, кадимчеләр, үч алу йөзеннән, «Вакыт» редакциясенә һөҗүм итәләр («Дин вә мәгыйшәт», 1915 ел, 20 сан). Үзенә каршы күтәрелгән гаугага түзә алмыйча Х. Габәши Казанга китәргә мәҗбүр була. Җыр-музыка сөюче, хөр күңелле Бабич үз эпиграммасында Х. Габәшидән кабат Уфага кайтуын үтенә.

Хәсән Гали — Хәсән Шәяхмәт улы Галиев (1870—1940) — тел белгече, педагог, фольклорчы; Оренбургта чыккан «Мөгаллим» (1913—1914) журналының редакторы һәм нашире; «Шура» һәм «Мөгаллим» журналларында татар теле мәсьәләләренә карата даими чыгыш ясап торган журналист, укытучы. Әлегрәк казакълар арасында укытучылык эше белән шөгыльләнгән. Революциядән соң Казанда укытучы булып эшләгән.

...син кыргызга эшләш... — казакъ-кыргыз мәктәбе-мәдәниятенә кагылышлы мәсьәләләр хакында сүз бара.

Әл-Хәсән мулла Сабир — Сабирҗан Хәсәнов (1866— ?) — Уфа гу-

бернасыннан I, II Дәүләт думаларына депутат итеп сайланган иске фикерле диндар мулла, «Хөсәения» мәдрәсәсенең имамы.

Г. Тукай үзенең бер мәкаләсендә аны «Такырҗан» дип атаган иде («Ялт-йолт», 1910 ел, 5 сан). «Ишан улде» дигән сатирик хикәясендә Ш. Бабич та аны «Такыржан әл-Хәсәни» дип исем бирде («Кармак», 1917 ел, 5—6 сан).

...тәгассеб үрнәге... — искелек үрнәге, кадим рухани үрнәге мәгънәсендә анларга кирәк. Троицкидагы Зәйнулла ишанның кадим мәдрәсәсеннән чыккан бу рухани әлеге «исемгә» гомере буе тугъры булып яши.

Әл-Хәсән мулла Пономарь — Хәсән Пономарев — «Шура» журналында язышкан Орск мулласы.

Мөбәрәкша Хәнәфи — Әл-Хәнәфи Мөбәрәкша — матбугат тирәсендә йөргән Стәрлетамак (хәзерге Башкортстан АССР) мулласы; укытучы, журналист, 1917 елда Уфада чыгып алган «Мохтарият» журналының секретаре. 1918 елда «Уфа хәбәрләре» исемле милләтчел-контрреволюцион газетада язышкан. Эпиграмма «Кармак» журналында (1916 ел, 10—11 сан) түбәндәгечә бирелгән:

Әл-Хәнәфи әл-Мөбәрәк, ишиләсен, төшкән базар.
Мәйданы сүнгән аның да, инде мескен ни язар?!

Акылы коңгырт, күңеле саргылт, чоп-чобар һәм кып-кызыл. — Монда шагыйрь Хәнәфи Мөбәрәкшинның мәсләксез, аумакай бер кеше булуына ишарә итә.

Хәнәфи әл-Бакир — Хәнәфи Бакири — Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытучы, Төркиядә укып кайткан кеше.

...ни дисрга белмәзсм. — Төркиядә укып кайтып, белемле булган булып, «белмәзсм», «күрмәзем» дип сөйләшеп йөргән Хәнәфи хәлфәгә ишарә ителә.

Әл-Хәнәфи Мозаффар — Хәнәфи Мөхәммәтҗан улы Мозаффаров — Казан тирәсендә яшәп, «Шура» журналында һәм «Вакыт» газетасында язышкан журналист.

Д. бабына.

Дәрдмәнд — Закир Садыйк улы Рәмиев (1859—1921) — күренекле татар шагыйре; Оренбург губернасы Орск тирәсендә алтын приискасы тоткан бертуган Рәмиевләрнең берсе. Дәрдмәнднең татар культурасы үсешендә югары урыны бар. Ул Оренбургта либераль-буржуаз «Вакыт» газетасы (1906—1918, редакторы Фатих Кәрими) һәм «Шура» журналы (1908—1918, редакторы Риза Фәхретдинев) чыгара.

Исте җилләр... күчте комнар...—Дәрдмәнднең атаклы «Кораб» шигырендәге юлларга перефраз.

...бетте дәрман, сүнде дәрт. — Бабич монда Дәрдмәнднең актив әдәби иҗат эшеннән тукталуына борчылып яза. Шундый ук борчылу Ш. Бабичның «Авыл җырлары» әсәрендә дә чагылып калган иде («Кармак», 1915 ел, 10 сан).

Дулатов — Мыржакып Дулатов (1885—1935) — казакъ шагыйре, бер чорда буржуаз милләтчелек идеяләре белән мавыккан.

...уймак чыгар, уйнап китеп. — Бабич монда, милләт язмышын артык кайгыртып ташлап, шовинизмга кереп китмә, дип искәртергә тели.

Мулла Дәүләтшин — Габдрахман Дәүләтшин — Оренбург мулласы, «Хөсәения» мәдрәсәсенең мөдире, I Дәүләт думасына депутат, соңыннан бик баеп китеп, миллионер булуга ирешә.

Измә миллат дәүләтен син... — «Хөсәения» мәдрәсәсендә урнашкан кадим тәртипләргә ишарә ителә. Бу юлларның башка мәгънәсе дә бар. Миллионер Әхмәт бай Хөсәеновтан калган вәкыф акчасын Дәүләтшин үз файдасына да файдаланган. Бабич шуны да истә тота булса кирәк.

Вәкыф акчасы — милләт файдасына васыять ителгән акча.

З. бабына.

Элек төрки телләр кулланган гарәп алфавитында «з» авазы үзенә аерым дүрт хәреф белән йөртелгәнлектән, «Китабеннас»та шул авазга башланган кеше исемнәре дүрт бабка булеп бирелгән. Монда алар бер бабка туплап биреләләр.

Зәкәрия — Зәкәрия Садретдинов — Казанда чыккан либераль-буржуаз «Кояш» газетасының (1912—1918) редакторы. Элгәрерәк Бәйрутта укып кайтып, «Галия» мәдрәсәсендә укытып йөргән.

...«Кояш»ның уртасында кап-кара бер тап кебек. — Ш. Бабич монда «Кояшта да таплар бар» дигән фикер белән З. Садретдиновның «Кояш»тагы эшчәнлеге арасында пародик тәңгәллек үткәрә. Чынлап та, үзенең мәкаләләре белән бу кеше «Кояш» газетасының абруен гына төшерә торган була.

Закир — Закир Насыйр улы Аюханов (1889—1961) — Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганнан соң, 1914 елда Египетта Каһирә университетын тәмамлап кайта. «Хөсәения»дә һәм «Галия»дә укыта. 1914—1916 елларда «Шура» журналында «Риба» турында (бурычка акча биреп, өстәмә процент алу) күп кенә мәкалә язган. Октябрь революциясеннән соң — Уфада В. И. Ленин исемендәге ятим балалар мәктәбендә башкорт теле укытучысы, Авыл хуҗалыгы институтында, пединститутта доцент, соңгы елларда СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы тарих, тел һәм әдәбият институтында гыйльми хезмәткәр булып эшләгән, Башкорт дәүләт университетында гарәп теле укыткан. «Башкорт әлифбасы»ның авторы.

...бу рия булмасмы икән... — Гарәп хәрефләренә нигезләнгән орфографиядә *риба (процент)* сүзендәге «б» астына икенче ноктаны куйсаң, ул хәреф «и»гә әйләнә һәм сүз *«рия»* (мәкер, икейөзлелек) дип укыла башлый. Шул рәвешле, бу эпиграммасында Бабич «рибачылык» нигезендә яткан икейөзлелекне фаш итә.

Зиннәтулла — Зиннәтулла Килбәтов (Килбәт) — унынчы еллар вакытлы матбугатында язышкан Стәрлетамак мөгаллиме.

Зәйнулла ишан — Зәйнулла Хәбибулла улы Рәсүлев (1830—1917) — Троицкида «Рәсүлия» исемле зур мәдрәсә тоткан рухани. Бу мәдрәсәдә заманында М. Гафури, З. Өммәти, З. Шәркый, Х. Искәндәрев, Г. Исхакый кебек әдипләр белем алган.

Мәгъҗүн — баллы камыр кисәгенә әфьюн кушып ясалган паста. Зәйнулла ишан кунакка килгән кешеләргә чәй алдыннан, дару дип, шул мәгъҗүнне бирер булган.

Бу эпиграмма Бабичның җыентыкларына кермәгән. Монда «Кармак» журналының 1916 ел 10—11 саныннан алып урнаштырылды.

Зәбири Хәбибрахман — Хәбибрахман Габделвәли улы Зәбири — Чистапули (1881—1933) — укытучы, берничә дәреслек авторы, «Гыйлем вә җәһел» исемле роман язган кеше. Ул шулай ук шигырьләр дә язган һәм берничә шигырь җыентыгы да чыгарган. Х. Зәбиров журналист буларак та билгеле. Ул 1906—1907 елларда Уральскида чыккан «Әл-гасрел-җәдид» («Яңа гасыр») журналында язышкан, соңрак Казандагы «Тәрбия» журналында секретарь булган. Октябрь революциясеннән соң Казанда нәшрият органнарында эшләгән.

...педагоглар ире. — Х. Зәбиревнең күп санлы дәреслекләр авторы булуына ишарә.

Зәки — Әхмәдзәки Вәлиди (1891—1938) — тарихчы, «Төрек-татар» дигән китап авторы, Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсендә төрек-татар тарихы укытучысы; 1917—1919 елларда Башкортстанда милли хәрәкәтнең җитәкчесе (бу хәрәкәткә берара Ш. Бабич та катнашып йөри

һәм 1919 елның февралендә кызыллар ягына чыга; бу хакта үзенең «Башкорт халкына көйле хитап» (икенче исеме — «Без ник кызылларга кушылдык?») исемле әсәрендә белдерә), 1920 елда Төркестанга, аннан эмиграциягә китә, Төркиядә яши.

Яшь тарихчы «карт» Зәкине... — Ш. Бабич үзе шундый аңлатма биргән: «Карт — шәех мәгънәсендә (юлбашчы, әйдәп баручы — *Г. Г.*), мәгънәви картлык морад, юкса Зәки әле 20—30 яшь арасында гына». Чынлап та, эпиграмма язылган чорда (1916 ел) Зәки Вәлиди талантлы, өметле яшь тарихчылардан саналып йөргән.

...эрләделәр кәрлә дип.— Татарча матбугатта З. Вәлидине «кәрлә» (иргайел) дип атап йөрткәннәр (мәсәлән, «Кояш» газетасында Ф. Әмирхан). Бабич монда әнә шул кушаматка ишарә итә. Әмма Бабич үзе дә З. Вәлидине «Кармак»та берничә тапкыр «кәрлә» дип атаган. Аерым алганда, Бабичка нисбәт ителгән «Авыл җырлары»нда («Кармак», 1915 ел, 14 сан) шундый эпиграмма бар:

Безнең урам ак балчык, бата күрмә, атлап чык,
Кәрлә малай шәп мөәррих, ләкин азрак мактанчык.

...бик тәкәбберләнмә...— («Авыл җырлары»нда: «азрак мактанчык») —бу юллар шулай ук «Галия» мәдрәсәсе тирәсендә барган скандал белән бәйләнгән булырга тиеш. «Мәдрәсәи Галия»не яптырып, аны «Госмания» белән кушарга йөргән Уфа интеллигентлары арасында З. Вәлиди дә була.

Зыя — Пәрвазетдин Җамалетдин улы Кәмалетдинов, әл-Кәмали (1878—1942)— Гарәбстанда укып кайтып, 1906 елда яңа ысул «Галия» мәдрәсәсенә нигез салган мәгърифәтче-педагог, дин философы; берничә дини китап авторы («Фәлсәфә» һ. б.). Ш. Бабич бу кеше белән бик якын мөнәсәбәттә була, хәтта, 1916 елда аның малаена дәресләр дә бирә.

...йөзләр яшәсен шан илә...— йөз яшь яшәсен дан белән, дип аңларга кирәк.

Дошманнар янсын, гүзәл эзләр ясасын «Галия».— Бу эпиграмма да «Галия»нең язмышын үз кулларына алырга омтылучы Уфа байларына, аларга ялагайланып ияргән кайбер буржуаз интеллигенция вәкилләренә юнәлгән. «Мәдрәсәдә динсезлек көчәю»не сәбәп итеп, Уфа байлары «Галия»не һәм Зыя Кәмалины бер тиен акчасыз калдыргач, мәдрәсә мөдире төрле юллар белән ике ел буе «Галия» өчен акча таба, шул рәвешле атаклы мәдрәсәнең ябылуына юл куймый. Бу эштә аңа Ш. Бабич та күлмедер ярдәм күрсәтә, аерым алганда, 1916 елда узган мәдрәсә юбилеенда (10 еллык) иганә җыю оештыра. Бу эпиграммасында шагыйрь «Галия» мәдрәсәсенең артабан да яши алачагына өмет белдерә.

Зыя Кәмалига багышлап язылган әлеге эпиграмманы Бабич соңрак «Бер тәмсил» исемендәге зур әсәр итеп киңәйтеп эшли.

Зыя Янгаличев — «Шура» журналында язышкан хәлфә, соңыннан укытуын ташлап, Саратов шәһәрендә мулла булган.

Зыя Насыйр — Зыя Насыйров (Зыя Ярмәки, 1887—1965)— татар шагыйре, 1909—1912 елларда «Галия» мәдрәсәсендә укыган, Ш. Бабичның якын танышы. Бу шагыйрь 1912—1913 еллар арасында дүрт шигырь җыентыгы чыгарган, соңрак берара актив әдәби иҗат эшеннән китеп торган, мулла булган. Октябрь революциясеннән соң Үзбәкстан ССРында төрле хезмәттә була, соңгы көннәренә кадәр иҗат эше белән шөгыльләнә.

Мәгънә чыкмый төрле бабларга кереп, йөгереп йөреп.— Эш шунда ки, Ш. Бабич «Китабеннас»та Насыйров фамилиясенә ике эпиграмма бирә. «З» һәм «И» бабларында телгә алынган Зыя Ярмәкигә шагыйрь көлеп шулай дәшә.

Зариф — Зариф Шәрәфетдин улы Бәширов (Зариф Бәшири, 1882—

1962) — татар шагыйре, педагог, публицист; казакъ далаларында балалар укытып йөрүе белән билгеле; Уфа әдәби мохитендә билгеле бер урын тоткан әдип, Ш. Бабичның якын танышы. Аерым алганда, бу ике шагыйрь Уфада 1916 елның җәендә очрашалар. (Кара: Зариф Бәшири. Замандашларым белән очрашулар. Казан, 1968.) Әлеге эпиграмма шул очрашу тәэсиратеннән чыгып язылган булса кирәк.

Зариф Әмирхан — Зариф Хәсән улы Әмирхан (1852—1921) — Казандагы милли, мәдәни, дини хәрәкәттә зур роль уйнаган мулла; күренекле татар язучысы Фатих Әмирханның атасы.

Зариф Мөзаффар — Зариф Мозаффаров — «Шура» журналында берничә шигырь бастырган автор. Гражданнар сугышы елларында Богырысланда чыккан «Кызыл маяк» дигән фронт газетасының редакторы.

Р. бабына.

Риза — Ризаэтдин Фәхретдин улы Фәхретдинев (Риза казый, 1859—1936) — әдип, журналист, галим, дин әшлеклесе; 1906 елда Уфада урнашкан Диния нәзарәтендәге казыйлык урынын ташлап, матбугат, фән һәм әдәбият белән шөгыльләнү өчен Оренбургка киткән, ун ел буе (1908—1918) Оренбургта чыгып килгән «Шура» журналының редакторы вазифасын башкарган, күп кенә әдәби, фәнни һәм дини китаплар бастырып чыгарган (кырыктан артык китап авторы). Октябрь революциясеннән соң Уфада Россия һәм Себер мөселманнарының дини идарәлеге башлыгы (мөфти).

Вак-төяк, әбер-чобарга күп урын бирә «Шура». — Риза Фәхретдиновның үзе кебек үк, Февраль һәм Октябрь революцияләре чорында «Шура» журналы да кризис чорына килеп керә һәм хәтсез генә төссез, чуар әйберләр бастырганнан соң, туктарга мәҗбүр була. Ш. Бабич үз эпиграммасында «Шура» журналының әлеге «чуар» чорына ишарә итә.

Рәми — Сәгыйть Лотфулла улы Рәмиев (Сәгыйть Рәмиев, 1880—1926) — күренекле татар шагыйре; 1910—1914 елларда Әстерханда чыккан «Идел» газетасының секретаре булып эшли. Патша жандармериясе таләбе буенча аннан китәргә мәҗбүр булгач, 1914—1917 еллар арасында Уфада «Авыл көнкүреше журналы» чыгара, Г. Ибраһимов оештырган «Ирек» газетасында актив язышса (1917), егерменче елларда «Яңа юл» журналын чыгаруда катнаша.

...тик торма, тиң килмәс диеп. — Элегрәк ярсу-бунтарь шигърияте белән халык күңелен яулаган С. Рәмиевнең әдәби иҗатта пассивлашып, тынып калуына ишарә.

Рәкыйби Рәкыйб — Рәкыйб Габдерәкыйпов (1887—1963) — татар журналисты һәм тәрҗемәчесе; баштарак Казанда чыккан «Бәянелхак» газетасының секретаре, соңрак Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасының һәм «Шура» журналының сотруднигы.

...рәкыйбең булды Рахманкол вафат. — «Кармак» журналының 1916 ел 8—9 санында (1 май) «Мәрхүм Солтан Рахманколов» дигән мәкалә басылып чыга. Имзасыз басылган бу мәкаләне Ш. Бабич та укыган булырга тиеш. Чөнки киләсе 10—11 санда ук «Кармак»та «Китабеннас»ның «Р» бабы һәм анда әлеге эпиграмма дөнья күрә. Шул рәвешле, югарыда китерелгән шигырь юлын, тәрҗемә эшендә көндәшең булган Солтан Рахманколов үлде, дип аңларга кирәк.

«Аударгыч» — Ш. Бабичның үз искәрмәсе: «Хәсән Гали тәгъбире — мөтәрҗим мәгънәсендә». *Мөтәрҗим* — булдыксыз тәрҗемәче.

С. бабына.

Гарәп алфавитында «с» авазы каты һәм йомшак авазлар белән билгеләнә. «Китабеннас»та да «С» бабы ике бабка бүлеп бирелгән. Бу җыентыкта алар берләштереп бирелә.

Сүнчәләй — Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләев (1889—1941)— татар шагыйре. Эпиграмма язылган чорда ул Уфадагы Аксаков китапханәсендә эшли, Ш. Бабич белән бик катлаулы мөнәсәбәттә тора. Октябрь революциясеннән соң халык мәгариф системасы хезмәткәре.

Сүнмәс исәң, чык мунчадан— Шагыйрь монда «Сүн-чәләй»— «сүнмәс» тәнгәллеген кулланган. «Сүнчәләй» —«мунчала» рифмасы да Бабич иҗатында еш очрый. Мәсәлән, «Кармак» журналының 1916 ел 10—11 санында басылган «Уфа кызыклары» фельетонында шундый юллар бар: «Әлмансур» һәм «Баб әл-сәмаә» («Күк капкасы».— *Г. Г.*) кебек мөһим нәрсәләр тәрҗемәчесе Сүнчәләй Уфага килгәч, бигрәк мунчалага әйләнеп китте ләбаса!» Шул ук «Кармак» журналының 1917 ел 5—6 санында «Гашыйк» имзасы белән басылган «Авыл җырлары»нда да «Сүнчәләй» — «мунчала» рифмасы яңартылган.

«Баб әл-сәмаә» — борынгы китап. Эпиграммада сүз С. Сүнчәләйнең «Баб» әсәре хакында сүз бара. Аның языла башлавы турында «Тормыш» газетасының 1916 ел 16 ноябрь (543) санында бер хәбәр дә басылган. Бабич эпиграммасын шул хәбәрне укыганнан соң язган булырга тиеш.

«Әлмансур»— С. Сүнчәләй тәрҗемә иткән бу әсәр буенча куелган спектакль хакында да белдерү басылган («Тормыш», 1916 ел, 30 март (440) саны). Ул да Бабич игътибарына эләккән булырга тиеш.

Сәрвәретдин Мифтахетдин — публицист, тәнкыйтьче; «Шура» журналында актив язышучы, ислам дине тарихына багышланган берничә китап та бастырган.

...һәм мөдәррис, һәм имам.— Оренбургта мәхәллә һәм мәдрәсә тоткан Мифтахетдин хәзрәтнең ислам динен актив пропагандалаудагы эшчәнлеге хакында сүз бара.

Сәет Шәриф бабай — татар байларына ялланып, алар өчен Мәккәгә барып, хаҗ кылып йөргән бер кеше.

Саттаровлар — Садыйк Саттаров — «Галия» укытучысы, бер үк вакытта «Галия» каршында ачылган мөгаллимәләр курсында да укытып йөри. Ш. Бабичның үз искәрмәсе: «Уфадагы Зыя Кәмали курсына ишарәдер: вакыйган, ышанычлы риваятьләргә күрә, былтыргы (1915 елгы.— *Г. Г.*) курслар борынгы җария базарларын искә төшереп торганнар икән».

Сәйфи — Фатих Сәйфи-Уфалы — татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Педагогия мәсьәләләре буенча мәкаләләр бастырган. Октябрь революциясеннән соң Уфада чыккан «Урал» газетасында язышкан.

Сөнгати — Габдрахман Сөнгати (1893—1917)— татар шагыйре.

...сөнги шигырьләр башлыгы.— Бу очракта Сөнгатинең ясалма («сөнги»), чынбарлыктан ерак әсәрләре күз уңында тотыла.

Сафа — Сафа Гатаулла улы Баязидов — Г. Тукайның чәнечкеле эпиграммаларына лаек булган Петербург мулласы (гаскәри мулла), соңрак атасы Гатаулла Баязидов чыгара башлаган «Нур» буржуаз газетасының нашире һәм редакторы, Февраль революциясе алдыннан Уфада мөфти.

Юк чара, бетте, Сафа менгәч татарның тәхетенә.— Бу юллар аша шагыйрь Уфага мөфти булып килгән Сафа Баязидовка үз мөнәсәбәтен белдерә.

1917 елга кадәр мөфти булып торган С. Баязидов Февраль революциясе чорында диннән читләшә, мөфтилеген ташлый һәм халык дошманнары сафына баса. Соныннан аның Февраль революциясе чорында ук патша охранкасы агенты булуы ачыкланды. Ш. Бабичның мөфтилеген ташлаган С. Баязидовка да әйтер сүзе булган. «Кармак» журналының 1917 ел 526 санында «Гашыйк» имзасы белән шундый эпиграмма дөнья күрә:

Ак Идел каты ага, астыннан вак таш ага,
Мулла Сафа, ыңгырашып, башың салма хафага.

Салихҗан Урманов — (1940 елда үлгән) — Себердән Уфага казый булып килгән мулла. Казанда чыккан «Ялт-йолт» журналы бу хакта: Себер урманыннан «Мөхкамәи шәргыя» йортына кертеп яптылар»,— дип язган иде. Ш. Бабич эпиграммасында да шул мотив яңгырый.

Салихов — Салихов Әхмәтбәк — Кавказ пантюркисты, I, II Дәүләт думалары депутаты; Петербургта «Ил» газетасында Гаяз Исхакый урынына куелган редактор.

«Ил»че һәм «Таң»чы Гаяз... — Эпиграммада сүз 1905 елгы революция чорында «Таң» («Таң йолдызы») исемле сул эсерлар газетасында, соңрак «Ил» (1913—1915, Петербург; 1917—1918, Мәскәү) дигән газетада актив катнашкан Гаяз Исхакый (Исхаков, 1878—1954) хакында бара.

Салихов астына поскан... — Салихов Әхмәтбәк, «Ил» газетасында Гаяз Исхакый урынын алса да, аның урынына һаман да Исхакый эшләгән. Бабич шуңа ишарә итә.

...ул кушылса, ахыры бик тиз инкыйраз. — Монда шагыйрь Г. Исхакыйның «Йөз елдан соң инкыйраз» (1902) дигән китабын күз уңында тотып яза. Аныңча, «Ил»гә кабат Гаяз Исхакый кушылса, «инкыйраз» бик тиз якынаер (бетү бик тиз килер).

Сәхибҗамал — Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская (1892—1974) — татар театр сәнгатенең күренекле эшлеклесе, беренче татар артисткасы, эпиграмма язылган чорда «Нур» труппасының җитәкчесе. Ул чорда труппа бик авыр көннәр кичерә. Бабич үз эпиграммаларында, фельетоннарында аның хакында берничә тапкыр язып чыкты. (Кара: «Кармак», 1916 ел, 18 сан; «Кармак», 1916 ел, 19—20 сан һ. б.)

Садри — Садретдин Низаметдин улы Максудов (1879—1957) — татар буржуаз идеологларының берсе, кадетлар партиясе әгъзасы, шулай ук «Мөселман иттифакы» партиясенең актив эшчесе, II, III Дәүләт думалары депутаты, Октябрь революциясеннән соң эмигрант, Төркиядә яши.

Ул кадерләр шаулап акты, калды тәмле төш кебек. — Демократик матбугат, Тукай, Әмирхан һ. б. алдынгы интеллигенция вәкилләре кадет С. Максудовның хезмәт халкына каршы эшләрен, Думада һаман уңлаша баруын берөзлексез тәнкыйть итәләр. Шуның нәтиҗәсе буларак, С. Максудов IV Дәүләт думасына (1912) сайланмый кала. Үзенең «1912 нче елның онтылганнан калган хисабы» дигән мәкаләсендә Тукай шуны күз уңында тотып әйтә, «профессиясеннән аерылды» ди («Ялт-йолт», 1913 ел, 49 сан, 10 гыйнвар). Ш. Бабич та үз эпиграммасында шул фикерне куәтли.

Ш. бабына.

Шәмигулов — Сабирҗан Шәмигулов — Уфада иң эре мануфактура магазины тоткан бай, миллионер. Эмиграциягә китеп үлгән.

...бар явызлык эшләрен... — С. Шәмигулов — 1915—1916 елларда «Галия» мәдрәсәсе тирәсендә гауга күтәрүчеләрнең берсе. Ул 1915 елда ук «Галия»гә материаль ярдәм күрсәтүдән баш тарта, соңрак, «Галия»не «Госмания»гә кушкан очракта, 10 мең сум акча бирәчәген белдерә. (Кара: «Кояш», 1917 ел, 18 апрель саны.) Бабич бу эшләрнең барысын да «явыз эш» дип карый.

Шакир юрист — Шакир Зариф улы Мөхәммәтьяров (1873—1967) — Уфада, Казанда, Ташкентта һ. б. шәһәрләрдә юрист булып йөргән татар зыялысы. «Вакыт», «Ил» газеталарында язышкан, берничә җыентык чыгарган, укучыларга хикәяләре белән билгеле булган. «Китабеннас» язылган чорда Ш. Мөхәммәтьяров Оренбург губернаторы канцеляриясендә юрист булып эшләгән. Шуның өчен дә аны Бабич «ай-һай, горурлы фиргавен!» дип атаган.

Шиһаб — Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәров (1882—1966) — Казанда чыккан «Мәктәп» журналының нашире һәм редакторы.

...«Мәктәбең» белән вафат.— 1913—1914 елларда чыгып килгән «Мәктәп» журналының («тәгълим вә тәрбия») туктап калуына ишарә.

Инде ят: корсак харап, ач мөхәррирләр талап— Журнал ябылгач Ш. Әхмәров китап сәүдәсе белән шөгыльләнә башлый. Шагыйрь шуңа ишарә итә. Һәм, сәүдә белән шөгыльләнеп, китап укучыларны талап ят, димәкче була.

Шәриф— Шәриф Камалетдин улы Байгильдиев (Шәриф Камал, 1884—1942)— күренекле татар язучысы.

Син мишәрләнмә... имля бозып...— Шәриф Камал тумышы белән хәзерге Мордва АССР, Рузаевка районы, Пешлә авылыннан. Көнбатыш диалектка (мишәр сөйләшенә) караган бу төбәк кешеләре телендә татар әдәби теленнән аермалы үзенчәлекләр күп. Алар Ш. Камал әсәрләрендә дә чагылмый калмаган, әлбәттә. Ш. Бабич әнә шул тел үзенчәлекләрен күз уңында тотып яза.

Шонаси— Габдулла Ибраһим улы Рәҗәпов.— Башта Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укытучы, аннары шул ук шәһәрдәге «Госмания» мәдрәсәсендә химия һәм физика укытучысы; татар телендә беренче башлап химия һәм физика дәреслекләре төзеп бастырган галим-мөгаллим. 1917—1918 еллар арасында булып узган «Милләт мәҗлесләренең» актив әгъзасы, Сабак мәгариф нәзарәте әгъзасы. 1918 елда милләтчелек лагерын ташлап, Мөселман комиссариатында хезмәт итә, Совет хөкүмәте органнарында эшли.

Шонаси кимиясе— Шонасиның химия фәне буенча язган дәреслекләренә ишарә.

Кем намусны малга сата, бу җиһанда шул яши— Бу юллар «Галия» мәдрәсәсе тирәсендәге ызгыш-гауга тарихына алып китә. 1915 елның август аенда бер төркем Уфа байлары, «Галия»не ябып, аны башка җиргә күчерү инициативасы белән чыккач, әлеге байларның калын кесәләре басымына түзә алмыйча, бу инициативаны «Галия» укытучысы Г. Шонаси белән «Госмания» мөгаллиме Ә. Вәлиди хуплап чыгалар. Шонаси, хуплап кына калмыйча, «Галия»не ташлап, «Госмания»гә үк күчеп китә. Бу ике мөгаллимгә шулай ук икенче «Галия» («Галияи Сания») өчен Устав һәм яңа укыту программасы тәзү эшен дә йөклиләр. Шул рәвешле, З. Кадыри, Г. Терегулов, Ә. Вәлиди белән берлектә, Г. Шонаси яңа мәдрәсә ачу кампаниясенең төп идеологы, методист-консультанты булып әверелә, бу чорда төзелгән һәртөрле комиссияләр әгъзасы итеп билгеләнә («Кояш, 1916 ел, 27 май (1651) саны.) Алдынгы укыту ысулы белән эшләп килгән «Галия»дән кабат дини мәдрәсә ясау өчен бар көчен кызганмый йөргән Шонаси мөгаллим Ш. Бабич «Китабеннас»ында иң зәһәр тәнкыйтькә очрый.

...бөгелә-сыгыла...— Бу мөгаллимнең, Уфа байлары каршында ялагайланып, алар кушканны үтәп, халык интересын санга сукмыйча йөрүен тәнкыйтьли.

Шәрәф Борһан— Борһан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1883—1942)— журналист, тәрҗемәче һәм әдәбият тәнкыйтьчесе; баштарак «Казан мөхбире (1905—1911), «Әхбар» (1907—1908), «Вакыт» (1906—1908) газеталары редакцияләрендә эшләп, соңрак «Аң» (1912—1918), «Шура» (1908—1918) журналларында язышкан. Октябрь революциясе чорында һәм аннан соң (1917—1923) «Оренбург хәбәрләре» газетасының редакторы вазифасын башкара, 1923 елдан Уфада медтехникум укытучысы. 30 елларда Ташкентта, Карагандада, Алма-Атада нәшрият органнарында эшли.

..ай көтәм, ел көтәм, балга-майга батты, ахыры.— Берничә ел буе «Вакыт» газетасында язышып килгән, 1911 елда «Йосыф китабы» да чыгарырга өлгергән Б. Шәрәф 1915—1916 елларда Оренбургтагы «Урал»

ресторанына хуҗа булып ала һәм бөтенләй дә язуын ташлый. Бабичның «юк... китәм...» дип уфтануы газета битләреннән Б. Шәрәф (Сәгъди) имзасының юкка чыгуына ишарә булырга тиеш.

Ш. Бабичның бу чәнечкеле эпиграммасы Борһан Шәрәфкә тәэсир итми калмаган булса кирәк. 1917—1918 елларда (бу чорда Бабич Оренбургта яши инде) ул кабат журналистлык эшенә әйләнеп кайта, «Оренбург хәбәрләре» дигән газетада редактор булып эшли башлый, бер үк вакытта «Багъбостан мәктәбе»ндә укытып йөри. Шул чорда Бабич аңа тагын бер эпиграмма багышлый. («Яңартылганнар» бүлеген кара.)

Шәһидулла — Шәрәфетдин Шәһидуллин — «Игъланат» (Казан) исемле газета, «Русия сәүдәсе» (Казан) исемле журнал һәм «Заман календаре», «Безнең Казан» дигән белешмәләр бастырган нашир һәм редактор.

Ш. Бабичның бу эпиграммасы шулай ук Тукай тәнкыйте белән аваздаш яңгырый («Ялт-йолт», 1913 ел, 4 сан, 10 январь). Бабич эпиграммасында шушы тәнкыйть яңартылган.

Г. бабына.

Гарәп графикасы нигезендәге алфавитта «г» авазы ике төрле әйтелә һәм языла. Бу басмада алар берләштереп биреләләр.

Галиәсгар Камал — күренекле татар драматургы, публицист (1879—1933).

Әкбар Камалны идеал ит... — текстта ялгышлык киткән булса кирәк; монда сүз төрек язучысы Әкрам Камал хакында бара ахры.

Барлык артистларга каршы байкотыңны игълан ит!—1916 елның җәендә Ш. Бабич драматург Г. Камал иҗаты белән йөзгә-йөз очраша. Ул Габдулла Кариев белән бергә «Беренче театр» комедиясен сәхнәгә кую бәхетенә ирешә. «Тормыш» газетасының 1916 ел 5—9 саннарында игълан да басылып чыга.

Ш. Бабичның ярымшаярулы бу эпиграммасы Г. Камал комедияләре белән «җепләнеп» йөргән шушы чорда язылган булса кирәк. Шагыйрь монда драматургның, артистларга «байкот игълан итеп», соңгы вакытта мөһим әсәрләр иҗат итмәвенә борчыла булса кирәк.

Галиәсгар Гафуров — Чыгътай (1867—1942) — Элекке Самара губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе) Бозаулык шәһәре мулласы; соңрак язучы-публицист; Совет чорында нәшрият органнарында эшли, озак еллар «Фән һәм дин» журналының редакторы.

...гофран таләп кыл алладан, чү... тагы бидгать, хилаф эшләр чыгарма... — Г. Гафуров «Исабәт» (турылау, Коръәнне дөресләү мәгънәсендә) исемле китап язып, Мөхәммәт пәйгамбәргә «тел тидергән» мулла. Ислам диндарлары мондый тәнкыйтькә каршы шау-шу күтәрәләр, Гафуровның муллалык указын тартып алуны таләп итәләр. Дини нәзарәт динчеләр таләбен канәгатьләндерә — Галиәсгар мулланың указы тартып алына. Әмма ул арада Гафуров, Дини нәзарәткә барып, кылган гөнаһларына тәүбә итә һәм указын кайтарып ала. Шундый кыен хәлләрдә калуына карамастан, бу мулла, танышлары белән үзара сөйләшкәндә, болай гына, указ саклау өчен генә тәүбә иттем, ди торган була. Ш. Бабич үз эпиграммасында, ироник көлү белән, мондый саксыз кыланышы өчен һәм, гомумән, «изгеләр»гә ят эшләре өчен Г. Гафуровның кабат җәза алачагын искәртә.

Бу хәл Тукай сатирасыннан да читтә калмаган. Шагыйрь үзенең «Мәҗрух указ» (1910) исемле сатирик шигырендә Г. Гафуров белән булган бу вакыйгадан бер көлгән иде инде. Бабич эпиграммасы шул тәнкыйтьнең дәвамы булып яңгырый.

Гали Рәхи — Гали Шакир улы Рәхимов (1892—1937) — язучы, татар әдәбияты тарихчысы һәм тәнкыйтьчесе.

Гали Рафикъ — Гали Лотфирахим улы Рафиков (1890—1944) — педагог, әдәби әсәрләр, фәнни-популяр хезмәтләр авторы; «Шура», «Аң», «Ак юл» журналларында язышкан. Октябрь революциясеннән соң балалар укыта, Коммунистлар партиясе сафына керә.

Галихан — Галихан Бүкәйханов — казакъ язучысы, «Семипалатинский листок» газетасының редакторы, Дәүләт думасы әгъзасы.

Гомәр Караш (1921 елда үлгән) — казакъ шагыйре, «Карлыгач» һәм «Бала толпар» җыентыкларының авторы. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган.

Гомдә — Гомдә Хәбиров — Уфада чыккан «Тормыш» газетасының секретаре, соңрак — редакторы. Октябрь революциясеннән соң Уфа мәктәпләрендә татар теле укытучысы.

Каш төзәм дип, күз чыгарып, барча эшне таркатып. — Бу юллар, күрәсең, 1917 елның февралендә (бу вакытта Бабич Троицк шәһәрендә балалар укыта) Уфада калган дусты Сәйфи Кудаштан «Кармак» журналы аша ачык хат алганнан соң язылган (1917 ел, 3 сан). «Уфа хәлләре» (журналымызның мөхәррирләреннән берәнә килгән хосусый мәктүбтән) исеме астында басылган әлеге күләмле хатта шундый юллар бар: «...Шул труппачылар («Нур» труппасы хакында сүз бара.— *Г. Г.*) вә «Котормыш»чылар («Тормыш»чылар.— *Г. Г.*) бер союз булып алдылар. Әгәр алардан башка кеше кичә ясаса, ул кичә тулай гына күңелле булса да, йөзгә төрләндерәләр дә, төймәне дөядәй, чүпне чүмәләдәй күрсәтеп язып чыгалар. Гомдә белән Самад сызганып кына торалар... Күптән түгел үзеңә мәгълүм яшь җырчы (җырчы Газиз Әлмөхәммәдев хакында сүз бара.— *Г. Г.*), һәвәскәрләр белән кушылып, концерт бирде. Иртәгесен «Котормыш», гадәтенә хилаф уларак («Тормыш» күп вакытта соңлап чыккан, монда шуна ишарә бар.— *Г. Г.*), таң беленмәстән чыгып, бөтен шәһәргә таралды (...). Ләкин хәзер халык үзе яхшы тәнкыйтьче. Халыкка Гомдә белән Самадның ялганнары кирәкми...»

Гыйффәт — Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева (1895—1977) — татар шагыйрәсе.

Аһ, йөрәгем, дип елый... —1915 елның 5 сентябрендә «Вакыт» газетасында Заһидә Бурнашеваның ачык хаты басылып чыга. Аянычлы язмышка, бикләүле тормышка дучар ителгән, ирек сөюче, киң дөньяга омтылучы бу татар кызының язмасы күз яшьләре белән юылган була. «Бөтен татар дөньясын каплап алган аңсызлык, наданлыклардан хасил булган тәгассеб вә кара көч белән тартышырга көрәштегем вакыттан игътибарән мин бик авыр дәверләр кичерә килдем...— диелгән анда.— Яшерен имза белән матбугатка чыккан шигырь кисәкләрем ата-аналарыма мәгълүм булгач, мин анам тарафыннан тәмам өйгә ябылдым... Ахырда... йортларын ташлап чыгарга мәҗбүр булдым. Читкә укырга барырга волостной старшина паспорт бирми, үземнең рәнҗетелгән йөрәгемне, мәзлуманә түгелгән яшьләремне матбугат аркылы милләткә аңлатып, үзенең хаксызга җәберләнгән вә уку юлында бу кадәр газаплар күргән бер кызын химаягә (якларга.— *Г. Г.*) милләтне чакырам («Вакыт», 1915 ел, 1863 сан). Әлбәттә, татарның алдынгы интеллигенция вәкилләре яшь шагыйрәгә ярдәм кулы сузалар. Ул башта Мәскәүгә барып чыга, аннары Уфага кайта. 1916 елда аның «Гыйффәт туташ шигырьләре» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Китапның күп өлешен хәсрәт-зар, сагыш лирикасы алып тора. Ш. Бабич үз эпиграммасында, әлбәттә, Гыйффәт туташның язмышын, бигрәк тә аның беренче шигырьләр җыентыгын күз уңында тотып яза.

Гыйлемдар — Гыйлемдар Баймбитов (1886—1932) — Мәскәүдә, Казанда, Уфада һәм башка шәһәрләрдә журналист һәм тәрҗемәче булып йөргән милләтче интеллигент, сул эсер.

Гыйрфан абзый — Екатеринбург (хәзерге Свердловск) шәһәре мулласы, ахун. Ул җәмәгатьчелеккә наданлыгы һәм диндарлыгы белән танылган.

...анда гайбәт ун вагын! — Ш. Бабич бу урында Г. Тукайның «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасына ияреп яза.

Гариф Шәрифи — Мөхәммәтгариф Шәрифи (Чистайлы) — шагыйрь, укытучы; «Шура», «Кармак», «Аң» журналлларында шигырьләр бастырган, берничә шигъри җыентык авторы.

...юдың шәрәфне бик начар шәйләр язып. — Г. Шәрифи, Г. Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» (1907) әсәренә ияреп, «Иске мәдрәсәдән чыккан бер шәкертнең зары» исемле шигырь язуы белән билгеле («Ялт-йолт», 1912 ел, 33 сан). Бу шагыйрьнең кешегә ияреп язу гадәте Ш. Бабич иҗатына мөнәсәбәттә дә күренә. Ул, мәсәлән, «Кармак» журналының 1917 ел 3 санында Бабичның «Әйдә, күңлем...» (1914) шигыренә пародия рәвешендәрәк язылган «Татар кызына» исемле әсәрен бастыра. Бабич башка шагыйрьләргә ияреп язылган шул «начар шәйләр»гә ишарә итә.

Гыймад — Гыймад Нугайбәков (Нугайбәк, 1881—1942) — тел галиме, профессор; ул гарәп телендәге алфавитка реформа ясау, хәрефләрнең киселешен яңарту турында проект төзеп бастыра. Әмма бу проект кабул ителми кала; башлангыч мәктәпләр өчен уку китаплары төзүче, «Русча-татарча сүзлек» (1938, 1941) төзүчеләрнең берсе.

Чергәкәйле — Гыймад Нугайбәкнең туган авылы (БАССР).

Галимҗан Идриси — Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытучы, соңыннан Төркия, Египет, Германия һәм башка илләрдә сәяхәт кылып йөргән буржуаз журналист.

Күп Галимҗан каңгыручан, булмагач монда «зәмин». — Галимҗан Идрисинең милләт өметен акламавына борчылып йөрүче Галимҗан Ибраһимовка, Галимҗан Барудига һ. б. ларга ишарә ителгән булса кирәк.

Галимҗан Баруди — Галимҗан Галиев (1859—1921) — Казан мулласы, дин галиме, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең хуҗасы, имамы; баштарак «Әд-дине вә әдәб» исемле журнал да чыгарып йөри (1905 елдан соң), берничә дини китап авторы. Октябрь революциясеннән соң Диния нәзарәтенең рәисе, мөфти.

Мулла Галимҗан барид шул, җанга бик салкын бага... — Монда шагыйрь мулла Галимҗан Барудиның исеме белдергән мәгънәне («барид» гарәпчә «салкын» дигәнне белдерә) поэтик алым итеп куллана. Ш. Бабичка кадәр бу алымны Г. Ибраһимов үз мәкаләләрендә кулланган иде. Мәсәлән, ул үзенең «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән мәкаләсендә түбәндәгечә язган иде: «...Заһир Бигиев, Зөһрә ханым вә Галимҗан хәзрәтләрнең тәрҗемәи хәльләрен күргәч, тагы аптырыйсың... «Хотбәи балига» исемендә салкын, туң вә балаларга ят нотык ни дип кертелде икән?..» (Кара: «Йолдыз», 1911 ел, 4 январь (628) саны).

Заһир Бигиев — (1870—1902) — татар язучысы.

Зөһрә ханым — Г. Ибраһимов анализ бирә торган хрестоматиядә Р. Фәхретдиновның «Мәшһүр хатыннар» китабыннан «Зөһрә ханым» дигән мәкалә-очерк бирелгән. *Зөһрә ханым* — Зөһрә Акчурина-Гаспринская.

«Хөтбәи балига» — Г. Барудиның шәкертләргә укыган лекциясе.

Галимҗан Акчурин — Галимҗан Кәлимулла улы Акчурин (1895—1933) — «Шура» журналында шигырьләр бастырган Казан мөгаллиме; соңрак Коммунистлар партиясе әгъзасы, Төркестанда басмачыларга каршы көрәш оештыручыларның берсе. Бохарада ревтрибунал башлыгы, 20 елларда ТАССРның финанс халык комиссары булып эшли.

Габдулла Мәгази — «Дин вә мәгыйшәт» журналында мәктәпләрдәге кимчелекләрне, искелекне яклап мәкаләләр язган бер хәлфә, буржуаз журналист, публицист, шагыйрь.

«Мин агуз, мин тәррикә» — аллам, явызлыклардан саклый күр, дигәнне белдерә. Бу гыйбарәнең Мәгази мәкаләләреннән алынган булуы мөмкин.

Габдулла Кари — Габдулла Хәйрулла улы Кариев (1886—1920) — татар профессиональ театрына нигез салучы артист һәм режиссер; Ш. Бабичның якын танышы.

Куркамын, үз-үзеңә Коръән чыгар вакыт житәр? — Эпиграммада сүз барган чорда, ягъни 1917 ел ахырында, Г. Кариев труппасы авыр чор кичерә — «Сәйяр» куйган спектакльләр саны кими, Кариев үзе артист буларак сәхнәгә сирәк менә, күбрәк режиссер буларак чыгыш ясый. Газета-журналларда басылып торган хәбәрләрне күзәтеп барган Бабич та мәшһүр артист язмышы өчен борчылып яза.

Кари — Коръәнне яттан белүче, сөйләүче дигәнне аңлата. Чынлап та, Габдулла Кариев кечкенә чагыннан «карилеге» белән билгеле булган. Бабич бу очракта шушы фактларга таянып эш итә.

Габдулла Камал — Габдулла Галиәкбәр улы Камал (Камал I, 1893—1933) — Г. Кариев житәкчелегендәге беренче татар профессиональ труппа («Сәйяр») артисты.

Гыйсмәти Габдулла — Габдулла Төхфәтулла улы Гыйсмәти (1883—1938) — «Йолдыз», «Кояш», «Тәрбия», «Мәктәп», «Ак юл», «Аң» газета-журналларында язышкан шагыйрь, публицист-язучы; Тукайның дусты; 1920 елдан Коммунистлар партиясе әгъзасы, Мәскәүдә Көнчыгышны өйрәнү институтында, Милләтләр эше буенча халык комиссарнатында эшли. 1924 елда Уфага кайта һәм җаваплы урынарда хезмәт итә. Госплан, Совнархоз председателе, Башкортстан мәгариф халык комиссары була. Башкортстанның экономикасы, культурасы мәсьәләләре буенча брошюралар, мәкаләләр яза.

Г. Гыйсмәти Ш. Бабич белән якыннан таныш булган. 1915 елда Г. Ибраһимов Уфага килгәч, «Галия» мәдрәсәсендә укыта башлагач, Гыйсмәти дә «Галия»гә еш килеп йөргән, андагы әдәби кичәләрдә катнашкан. Ш. Бабич белән дә шунда очрашкан.

...исемең мәгъсуманә яңгырый, әмма өстендә болыт... — «Китабеннас» авторы белән Г. Гыйсмәти арасындагы якын мөнәсәбәт шуннан да күренә: Бабич үз эпиграммасында күпләргә сер булып калган фактлар хакында яза. «Гыйсмәти» — гөнаһсызлык, сафлык, намуслылык дигәнне белдерә. Әмма патша хөкүмәте өчен ул шактый гөнаһлы, гаепле булып чыккан икән. 1915—1916 елларда Г. Гыйсмәтинең патша власте күзәтүе астына алынуын шагыйрь «өстендә болыт» дип искәртә, аңа саграк булырга куша.

Гыйсмәтуллин — (исеме билгеле түгел) — Уфадагы «Җәмгыяте хәйрия»нең («Ярдәмләшү җәмгыяте») рәисе, буржуаз милләтче, соңрак Колчакка ияреп киткән Хисмәтуллин.

Габдрахман Рахманкулов — Троицк шәһәрендә кымызчы мулла (Тукай анда кымыз белән дәваланган). 1916 елның көзеннән 1917 елның җәенә кадәр. Ш. Бабич шушы Габдрахман мулла мәдрәсәсендә балалар укыта. Бу хакта «Тормыш» газетасының 1916 ел 12 октябрь санында шундый хәбәр дә басыла: «Бу ел «Мәдрәсәи Галия»не тәмам иткән Шәехзадә әфәнде Бабич Троицкида Рахманкуловлар мәдрәсәсенә мөгаллим булып китде. Бу мәдрәсә Троицкиның могътәбәр вә карт хәзрәтләрендин Хажи ахун Назаретдинда булып, әлгәрәк бу мәдрәсә дә яхшы ук мокътадир гыйльмаи мәдрәсәләрдән иде».

Эпиграмма шагыйрьнең шул мәдрәсәгә барып урнашкан көннәрендә язылган.

Габдрахман Фәхри — Габдрахман Фәхретдинев (1886—1936) — журналист; Риза Фәхретдиневнең улы, «Шура» журналында һәм «Вакыт» газетасында актив язышкан, «Вакыт» газетасы редакциясендә эшләгән. Октябрь революциясеннән соң милләтчелек идеяләре белән мавыгып йөргән публицист, «Уфа хәбәрләре» исемле контрреволюцион газета редакторы, «Башкорт теле» исемле буржуаз милләтче газетада, 20 елларда «Башкортстан», «Яңавыл» газеталарында эшли. «Башкортлар яшәргә лаеклымы?» (1922), «Башкорт тарихы» (1926) дигән китаплар авторы.

...ул картларга тартым сымак: кайда каймак — ул кунак. — Бу юллар Г. Фәхретдиневнең шәһәрдән-шәһәргә кунак булып йөрүенә ишарә итәләр. Аерым алганда, 1916 ел башында ул Уфага да килеп чыга. «Вакыт» мөхәррирләреннән Габдрахман әфәнде Фәхретдинев шәһәремезгә килде»,— дип хәбәр итә, мәсәлән, «Тормыш» газетасы (10 январь (392) саны). Эпиграмманың шул хәбәрдән соң язылган булуы мөмкин.

Габделбәдигъ — Хуҗа Габделбәдигъ улы Бәдигый (1887—1947) — күренекле татар телчесе һәм фольклорчысы.

...ул җыр һәм такмаклар җыя. — Хуҗа Бәдигыйның шул елларда басылып чыккан халык авыз иҗаты җыентыкларына ишарә, «Халык әдәбияты. Мәкальләр», 1912; «Халык әдәбияты. Табышмаклар, такмаклар, такмазалар», 1913; «Халык әдәбияты. Бәетләр», 1913; «Халык әдәбияты. Җырлар», 1914 һ. б.).

Габдрахман Рәсул — Габдрахман Зәйнулла улы Рәсүлев — Троицк шәһәрендә мулла, соңрак атасы урынына ишан итеп сайлана. 1937—1950 елларда Уфада мөфти.

...сиңа ишанлык зур мирас. — «Кармак» журналының 1917 ел 5—6 санында Ш. Бабичның «Ишан үлгәч» исемле күләмле сатирик хикәясе басылып чыга. Анда вафат булган Һаммас ишан урынына Габдрахман мулла Рәсүлинең ишан итеп сайланып куелу вакыйгасы көчле сарказм белән тасвир ителгән.

Булсаң ишан, әфьюн урынына гыйлем, әхлак өләш. — Эпиграмма 1916 елның август аенда иҗат ителгән һәм «Кармак» журналының 1916 ел 16—17 санында чыккан. Димәк, шагыйрь әле Габдрахман мулланың ишан булачагын фараз кылып яза һәм аңа, ишан булган очракта, күпмедер өметләр дә багълый. Бу хәл аның соңгырак язмасында — «Ишан үлгәч» сатирик хикәясендә дә сизелеп кала.

Габделхәмит Мөслими — Габделхәмит Гатаулла улы Мөслими — «Шура» журналында укыту-тәрбия мәсьәләләре хакында мәкаләләр бастырган мөгаллим, Оренбургта яшәгән. Октябрь революциясеннән соң Стәрлетамак, Уфа шәһәрләрендә укытучы булып эшләгән.

Габдрәшит казый — Габдрәшит Гомәр улы Ибраһимов (1857—1922) — татар буржуа идеологы, публицисты, «Мөселман иттифакы» партиясенең актив әгъзасы; дини китаплар авторы; Петербургта «Өлфәт» (Бердәмлек, 1906—1907), «Ватан хадиме» (1908) һ. б. шундый, берсе туктауга икенчесе чыгып торган кыска гомерле берничә буржуаз газета һәм журнал нашире. Октябрь революциясеннән соң эмигрант.

Күргәнеңне сөйләр идең, бик сагындык, өйгә кайт. — Шагыйрь үз эпиграммасында Габдрәшит казыйның Япониягә ясаган сәяхәтенә ишарә итә булса кирәк. 1905—1906 елларда диничеләр тарафыннан: «Японияга мөселманлык кирә, япон патшасы (микадо) мөселманлыкка чыга икән» дигән хәбәр таратыла. Бу кампания шаукымына Ш. Бабич 1905 елда ук — туган авылы Әсән мәдрәсәсендә укыганда ук эләгә. Ул чакта аның атасы Мөхәммәтзакир хәзрәт тә «японнарның мөселманлыкларына» чын күңелдән ышанган бер кеше була. (Кара: Бикбаев Р. Шәйхзада Бабич. Тормышы һәм иҗады. Өфө, 1981 ел, 23 бит). Бу

хәрәкәт хакында Бабич остазы Тукай иҗаты аша да таныш. Халык шагыйренең Габдрәшит казыйдан көлеп язган язмалары уныичы елларда шәкертләр арасында бик популяр була. Тукай аның асручә «мөселман туганнары» янына Япониягә ясаган сәяхәтенкән көлә («Яшен», 1908, 4 сан, 5 ноябрь).

Габделгазиз — Газиз Дәүләтшин — Беренче бөтендөнья сугышы вакытында, патша хөкүмәте вәкиле буларак, Урта Азиядә, Төркестанда халык күтәрелешен бастырып йөргән генерал. Ш. Бабич искәрмәсе: «Дәүләтшин Петроградтан Төркестанга җибәрелгән иде».

Газиз Гобәйдуллин — (1887—1938) — татарлардан тарих буенча беренче профессор, язучы, әдәбиятчы.

Габитов — Хәбибулла Габитов (1886—1938) — башкорт шагыйре, Ш. Бабич белән бергә «Галия» мәдрәсәсендә укыган, соңрак Оренбургтагы төрле газета-журналларда шигырьләре белән катнашып барган мөгаллим. 1918 елда Зәки Вәлиди җитәкчелегендәге «Башкорт хөкүмәте» янында чыккан «Башкорт» газетасының редакторы (секретаре — Ш. Бабич), Ш. Бабич оештырган «Тулкын» җәмгыяте матбагасында басылган «Башкорт шоңкары» исемле җыентык авторы (1918). 1934 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы.

...син язма әшгарь, ат каләмне, утка сал... — Ш. Бабич Монда Х. Габитовның төрле газета-журналларда басылган «Кәрван Сарайга карап», «Сөйгәнемә» (1915), «Мәхбүс мөгаллим» (1916), «Нигә бу шәмнәр сүнә?» (1914) һәм башка шигырьләрен, художество ягыннан шактый түбән дәрәҗәдә торган әсәрләрен күз уңында тота булса кирәк.

Габид Исмәгыйль — Бу исемгә Ш. Бабич үзе түбәндәгечә аңлатма биргән: «Исмәгыйль Габиди имзасы белән шигырьләр язучы кеше әгәр Бишбалта мулласы Исмәгыйль Габиди булмаса, бу назым мәхсүх булыр». Әлбәттә, эпиграммада сүз пәкъ шул Казандагы Бишбалта мулласы хакында бара. Ташкентта 1905 елның июненнән декабренә кадәр «Тәрәккый» исемле демократик газета чыгарып йөргән Габиди, газетасы туктатылганнан соң, төрмәдә дә утырып чыга. Соңыннан Казанга кайтып мулла була, шигырьләр яза.

Ул йөрәктә нәрсәләр кайный — шигырьме, — динме, йә? — Вакытлы матбугатта шигырьләре белән күренеп калган И. Габиди 1916—1917 елларда, ягъни эпиграмма язылган чорда, Казанда тупланып алган дин әһелләренең күренеклесенә әверелә. Ул хәтта 1917 елда узган Дин галимнәре съездының оештыру комитетына да кертелә. Бабич Казан мулласының шундый ике яклы эшчәнлегенә ишарә итеп яза.

Гыйбадулла — Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров (1888—1936) — күренекле татар телчесе, профессор; Ш. Бабич белән бергә «Галия» мәдрәсәсендә белем алган.

...имлячы... — Шагыйрь монда Г. Алпаровның «Хәреф һәм имлябыз» китабын күз уңында тотып яза һәм артабан да шул китаптагы төшенчәләрне куллана.

«Урта имля» — гарәп орфографиясеннән аермалы рәвештә, шул гарәп орфографиясенә нигезләнгән татар язуында сузык авазларны күрсәтеп язу имлясы (орфографиясе).

Бай Гыйбадулла — Гыйбадулла Усманов — Уфа бае, миллионер, «Тормыш» газетасының нашире. Шәкертләр аны «Сабын короле» дип тә йөрткәннәр.

...юмарт исемен алган... — Г. Усманов, «Җәмгыяте хәйрия» дигән оешмага (Уфа) бик күп акча биреп, Коръән бастыручылар ниятен хуплавын белдерә. Әмма җыелган акчалар белән шау-шу куба. «Кармак» журналының 1916 ел 19—20 санында шундый игълан да басыла: «Авызы пешкән — өреп эчкән!» — димәкләр: Җәмгыяте хәйрия, нәшер Коръән өчен билгеләнгән йөз меңнән яртысын ычкындыргач, калганы

хакында нык тора. Хәтта ычкынган илле меңне эзләп, хәзинәдарын судка тартырга исәпләнәдер». Ш. Бабич үзенең «Уфа хәлләре мөндәриҗәсе» дигән фельетонында бу вакыйгага кабат әйләнеп кайта. Анда шундый юллар бар: «...13). «Тормыш» газетасының кәгазе; 14). Гыйбадулланың ыгы-зыгысы...» («Кармак», 1917 ел, 10—11—12 сан).

Габделлатыйф хаҗи — Габделлатыйф Хәкимов — «Галия» мәдрәсәсе бинасын салдыру өчен вакытында бик актив иганә җыюда катнашкан Уфа бае, хаҗи.

...бер ихсанчы... — бер ярдәмче, дигәнне белдерә. «Йолдыз» газетасының 1916 ел 24 август (1684) санында шундый хәбәр басылып чыга: «Габделлатыйф хаҗи Хәкимов тарафыннан Коръән бастырырга билгеләнгән китап «Өмид» матбагасына кермеш...» Эпиграмманың язылу чорына караганда, Ш. Бабич анда Г. Хәкимовның Җәмгыяте хәйрия өчен кылган шушы «ярдәменә» ишарә итә булса кирәк.

...бу хаҗи да Ишми куштаннардан бит! — Эпиграмманың беренче вариантында башкача («Кармак», 1916 ел, 16—17 сан):

Әйтсәң әйт Габделлатыйф хаҗины бер ихсанчы дип,
Ихсаны чишмә аның, о башкаларның — тамчы бит.

Күрүебезчә, беренче вариантта шагыйрь Г. Хәкимовны бары тик ярдәмчел бер кеше итеп кенә күрергә теләгән. Монда, бәлки, әлеге хаҗиның Бабич укыган мәдрәсәне салуда катнашуы да күпмедер роль уйнагандыр. Әмма шагыйрьнең бу кешегә мөнәсәбәте бик тиз үзгәргән. Инде 1917 елда ук ул аны карагруһ динче, доносчы Ишмөхәммәд ишан белән янәшә куеп, зәһәр сатира уты астына ала. Шагыйрьнең карашлары үзгәрүенә шул чорда вакытлы матбугатта күренеп киткән берничә язма да тәэсир итми калмагандыр. Мәсәлән, «Кармак» журналының 1916 ел, 19—20 санында шундый хәбәр басылып чыга: «Уфа. Латыйп Хәкимов нам (исемле. — *Г. Г.*)һиммәтле зат әүвәлдә доносчы муллаларга җим булган иде, хәзер исә аны озын казакилы «Гыйлем хальче»ләр сырып алды...»

«Гыйлем хальче» — шәригать законнарына аңлатма рәвешендә язылган дини-популяр китап укучысы мәгънәсендә. Бу китапның авторы — Шәһид Гауни (Рәҗәпов).

Гыйльметдин Шәрәф — Гыйльметдин Шәрәфетдин улы Шәрәф (1885—1943) — Казанда типография хуҗасы, китап сәүдәсе белән шөгыльләнгән, Г. Тукайның якын дусты.

Гайнелислам Чишмәви — Гайнелислам Шәңгәрәев — хәзерге Башкортсан АССР Чишмә районы Чишмә авылыннан чыккан бу кеше шул ук авылда мулла булып торган, Оренбургта чыккан «Дин вә мәгыйшәт» журналында «Чәчне һәм тырнакны кайсы көндә кисү саваплы?» дип мәкаләләр язган рухани.

«Дингә мишәйт» — «Дин вә мәгыйшәт» журналының татар демократик тәнкыйтендә киң таралган икенче исеме.

Галимов Сафа — Сафа Бәдретдин улы Галимов — унынчы елларда вакытлы матбугат органнарында чыгыш ясаган бер мулла.

...бер роман... — С. Галимовның 1914 елда «Йке үксез» дигән бер чәчмә әсәре басылып чыга. Бабич шуны күз уңында тота булса кирәк.

Голәмә — җыелма образ, галимнәр дигәнне белдерә. 1906 елда Уфа руханилары «Әл-галәм әл-ислами» («Ислам дөньясы») дигән журнал чыгара башлыйлар. Әмма аның төп принципларын, юнәлешен билгеләүдә бердәм фикергә килә алмыйча, ызгышып бетәләр. Ахырда, бер ел дигәндә, журнал ябыла, «Голәмә» тарала.

Бу эпиграмма шагыйрьнең 1922 елгы җыентыгына да; 1958 елгы башкортча сайланмасына да кертелмәгән. Монда «Кармак» журналының 1916 ел 16—17 саныннан алып урнаштырылды.

Гыйният — Гыйниятулла Капкаев — Уфадагы Мәхкамәи шәргыядә (Диния нәзарәтендә) казый булып торган рухани. Имеш, ул ришвәт акчасына үзенә йорт салдырып кергән.

...сал җинаятьтән, ниһаять, зур бина. — «Гыйният» — «җинаять» янәшәлеге «Кармак» журналында басылган мәкаләләр, хәбәрләрдән күренгәнчә, ул вакытта мәгънәдәш сүз булып йөргәннәр. Гыйният-Җинаять казый тормышыннан алып язылган мондый материалларның кайберләре Бабичның үз кулы белән язылган булуыда мөмкин. Гыйният казыйның Җинаятен раслаучы менә берничә хәбәр.

«Уфа.— Җинаять белән Җәфа арасында имтихан базарына килгән шәкертләрдән налог җыю хакында мәкаләлә ясалды... Шуның белән (...) күзәлге имтиханга керер алдыннан Җинаять белән күрешү гадәте дә дәвам итдереләчәк, имеш» («Кармак», 1915 ел, 10 сан (15 октябрь).

«Уфа.— Кыйммәтчелек мөнәсәбәте белән, Җинаять абзый имтиханга килгән шәкертләрдән ала торган налогны арттырырга карар бирде» («Кармак», 1916 ел, 12—13 сан).

Җәфа — революция алдыннан гына мөфти итеп сайланган Казан мулласы Сафа Баязидов хакында сүз бара.

«Капкаев капканы» — Гыйният казыйның шәкертләргә карата кулланган ришвәт җыю ысулларына (шәхси әңгәләмәләргә, кабул итүләргә һ. б.) ишарә ителә. Ш. Бабич «Кармак» журналының 1917 ел 5—6 санында бу поэтик алымга тагын бер тапкыр әйләнеп кайта («Ганийк» имзасы белән басылган «Авыл җырлары»).

Габдулла Газиз — Габдулла Кәлимулла улы Газизов (Сакмари) — кайчандыр Бәйрутта укып кайтып, Троицкида Яушевлар мәктәбендә укытып йөргән, әдәби әсәрләре белән вакытлы матбугатта күренгәләгән укытучы, буржуаз публицист; революциядән соң эмигрант, Хәрбиндә «Мен ел» газетасы чыгаруда катнашкан.

...Газиздән күп гаҗиз... — «Газиз» — «гаҗиз» янәшәлеге Ш. Бабич иҗатында артабан да очрый. Мәсәлән, 1917 елның көзендә, «Кармак» журналында секретарь булып эшләгән чорда, шагыйрь үзенә Троицк шәһәре буенча ук таныш булган Г. Газиз хакындагы бер хәбәрне эшкәртеп бастыра: «Ходай (...), үзенең сөекмсез колларыннан Г. Гаҗизнең телəгеи кабул итеп, максудына ирештерде: Гаҗиз, кырык өлешкә ярылып, кырык комитетка әгъза булды, кырык җиргә эшкә керешде. Халык авызында Г. Гаҗиз гына (...). Хәтта әбиләр дә, тәсбих тартканда, ялгышып китеб: «Гаҗиз... Гаҗиз!... Гаҗиз... дип җибәрәләр; тамакка сөяк кадалган хаҗи абзыйлар да, какалган вакытда: Г-г-г-газиз, г-г-г-газиз!..— дип какалалар. Бу вакыйга Троицк каласында «Шык Газиз» вакыйгасы дип мәшһүрдер» («Кармак», 1917 ел, 10—11—12 сан).

Галәветдин Ходаяров — Галә Гайнетдин улы Ходаяров (1892—1966) — педагог, журналист; Ш. Бабич белән бергә «Галия» мәдрәсәсендә укыган, соңыннан балалар укыткан. Октябрь революциясеннән соң (1919) ул Коммунистлар партиясе сафына керә, Уфада чыккан «Кызыл йолдыз», «Шәрекъ ярлылары» газеталарының редакторы; Татарстан мәгариф халык комиссары, соңрак Казан пединституты директоры.

Мулла Габдулла Сөләйман — Габдулла Хәлил улы Сөләйманов (Сөләйманзадә, Тамбови Г.) — башта Мәскәүдә, Нижний Новгородта (хәзерге Горький) мулла, соңрак Диния нәзарәтендә казый. Г. Сөләйман шулай ук шигырьләр дә язган, берничә җыентыкта шигырьләре, «Аң» журналында проза әсәрләре белән катнашкан урта кул әдәбиятчы буларак билгеле.

Хөтбә — җомга һәм гает көннәрендә патшаларга, ханнарга, дәүләт җитәкчеләренә сәламәтлек, иминлек теләп, намаз укып дога кылу, вәгазь сөйләү.

...көйгә көйләп, хөтбә сөйләп... — шагыйрь монда Г. Сөләйманның Коръән белән намазны татарча сөйләүне яклап йөрүенә ишарә итә булса кирәк.

Гарип — билгесез бер авторның псевдонимы. «Шура» журналында язышкан.

Бар иде бит «аһ» дигән чаклар, төректән урлашып. — «Шура» журналының 1908 ел 5 санында «Гарип» имзасы белән төрекчәгә тартым «Каберлектә» дигән шигырь басылган. Ш. Бабич үз эпиграммасында шул шигырь хакында сүз алып бара булса кирәк.

Эпиграмма «Кармак» журналының 1916 ел 16—17 саныннан алынды.

Гафури — Мәҗит Нургани улы Гафури (1880—1934) — күренекле татар һәм башкорт әдибе, публицисты; Башкортстанның халык шагыйре.

Гани — Хәбибрахман Галиулла улы Ганиев (1872—1939) — 1911—1916 елларда Троицкида чыккан «Акмулла» журналының нашире.

Шул вакыт «Акмулла»ны рәтләр Гани... — Демократик рухтагы журнал буларак чыга башлаган «Акмулла» 1914—1915 елларда, гражданлык позицияләреннән читкәрәк тайпылып, урталыкта торуны кулайрак күрә башлый. Башланып киткән беренче бөтендөнья сугышына карата да ул бер сүз әйтә алмый. Журнал җитәкчеләре, иң элек, табыш алу максатыннан чыгып эш итәләр. Әмма аларның мондый позициясе актив язышучы авторларны да, укучыларны да иҗтимагый көрәш мәсьәләләреннән, дөньякүләм хәлләреннән читкә алып китә. 1913—1914 елларда «Акмулла»да еш күренгән Бабич та бу журнал редакциясе белән арасын суыта, Оренбургта чыга башлаган (1915 елдан) «Кармак» журналына йөз тота. Ахыр чиктә, иҗат яшьләре белән «Акмулла» җитәкчеләре арасында конфликтлар ешая һәм 1916 елда журнал туктарга мәҗбүр була. Ш. Бабич эпиграммасы «Акмулла» журналының шушы аянычлы язмышы хакында сөйли.

Гәрәй — Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнов (1883—1934) — журналист, Казанда чыккан «Аң» (1912—1918) журналының редакторы һәм нашире. Октябрь революциясеннән соң Казанда матбугат органнарында хезмәт итә.

Башкаларга нисбәтән азрак талый. — Билгеле булганча, Ш. Бабич «Аң» журналы белән элемтәдә торган (Мәсәлән, аның «Газазил» балладасы шул журналда басылып чыккан). Шул танышлыкны искә алып, әлеге юлны ике төрле аңлап була: редакциягә җибәрелгән текстларны азрак үзгәртә, кыскарта, дип һәм, басылган әсәр өчен гонорарны кызганмый түли, дип.

Гөлҗамал — бу эпиграмманың кемгә багышланган булуы әлегә ачыкланмаган.

Ф. бабына.

Фатих Кәрими — Фатих Гыйлман улы Кәримов (1870—1937) — татар журналисты һәм әдибе, озак еллар буе Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасының редакторы, соңрак «Яңа Вакыт» (1918, Оренбург) газетасының нашире һәм редакторы.

...файдалы эшләр гатеф итә. — Ярымкөлеп әйтелгән бу сүзләрдән Ф. Кәриминең 1917—1918 елларда Оренбургта алып барган иҗтимагый эшчәнлеген күз алдына китерергә мөмкин. Ш. Бабич «Вакыт» редакторының җәмәгатьчелек алдында ясаган бер лекция-чыгышы хакында «Кармак» журналының 1917 ел 10—11—12 санында үзе дә язып чыккан (Бабич үзе бу вакытта «Кармак» редакциясендә эшли).

Фатих Сәйфи-Казанлы — Фатих Сәйфи Камалетдинов (1888—1942) —

татар совет язучысы, журналисты, әдәби тәнкыйтьчесе һәм җәмәгать эшлеклесе.

Эпиграмма Ш. Бабичның «Галия» буенча остазы, дусты, каләмдәше Ф. Сәйфи-Казанлы белән, нинди дер, хәзергә билгесез булып калган мөнәсәбәтләре хакында сөйли булса кирәк. Шуны гына әйтергә мөмкин: 1916 елда Ф. Сәйфи-Казанлы, Уфа прогрессив интеллигенциясенең кәефен җибәреп, «Хөсәения» мәдрәсәсе имамы, реакцион рухани Сабир Хәсәнов кул астындагы «Мәгълүмат» журналына эшкә керә. Шул вакыттан алып Ш. Бабичның төп язышу журналы булган «Кармак»та бер-бер артлы тәрттерүле «Уфа телеграммалары» басыла башлый. Бу язмаларның да Ш. Бабичныкы булуы ихтимал. Мәсәлән, «Кармак» журналының 1916 ел 5—6 санында шундый хәбәр басылган: «Уфа.— «Мәлгунат» мәҗмугасе бик тәрәккыйдә. «Мәлгунат»та «Казан яшьләре» представителе Фатих Сәйфинең эше дә башында таша: ул Сабир мулла мәкаләләренең сафсата сүзләре арасына запятой кыстырып күчереп язудан бушый алмый...»

«Мәлгунат» — «Мәгълүмат» журналының үзгәртелгән исеме.

Сабир мулла — Сабир Хәсәнов.

Фәрхи — Фәхри Әхмәтев (1891—1939) — журналист; баштарак Уфада чыккан «Безнең юл» газетасының (1917) секретаре, революция һәм гражданнар сугышы чорында Уфада мөселман эшләре комиссариаты тарафыннан чыгарылган «Көрәш» газетасы редакциясенең сотрудниги, соңрак 5 нче армиянең политбүлеге органы булган «Кызыл яу» газетасының редакторы; 1919 елдан Коммунистлар партиясе әгъзасы.

Фәрхи Фәхретдин түгел... — шагыйрь бу урында Ф. Әхмәтевне «Вакыт» газетасы сотрудниги, милләтчелек идеяләре белән мавыккан журналист Габдрахман Фәхретдинов белән чагыштыра булса кирәк.

Фазыл Туйкин — Туйкә (1887—1938) — татар-башкорт шагыйре, язучы, журналист, фольклорчы, педагог; татар һәм башкорт җырларын актив җыя башлаучыларның берсе.

Туйда җырлап төрле көйгә... — Ф. Туйкәнең, халык арасына чыгып, туйларда булып, халык җырларын язып йөрүенә ишарә.

Ходайның фазылы белән — ходайның рәхимлеге белән, дип аңларга кирәк.

Фәйзи — Фәйзрахман Черкасов — журналист; Троицк шәһәрендә «Хезмәт» исемле китапханә тотучы, «Акмулла» журналының редакторы, Ш. Бабичның якын танышы. (Кара: М. Бәдәйли. Ул тормышны сөя иде.— «Совет әдәбияты», 1965 ел, 1 сан.)

...ти, эи, сад, вә зад ...лар хәлфәсе иде әүвәле... — Ф. Черкасов — «Акмулла» көлке журналын «ябылу»га алып килгән кешеләрнең берсе. Иҗтимагый карашлары белән буржуаз-демократик лагерь вәкиле Черкасов белән Февраль революциясен тоеп яшәүче, үзе дә актив көрәшкә омтылучы (шагыйрь бу чорда революцион демонстрацияләрдә катнаша, «Хөр милләт» исемле газета чыгаруда катнашып йөри, революцион рухтагы шигырьләр тупланган җыентыклар чыгара һ. б.) Бабич арасында сизелерлек каршылык килеп туган булырга тиеш. Җитмәсә, Ф. Черкасов — язучы, журналист буларак та балкып торган талант түгел. Шуңа күрә дә Бабич аны, «т», «з» «с», «з» хәрефләре арасына сузыклар өстәп, «тозсыз» дип атый. Шул ук вакытта ул бу кешенең әлгәрерәк укытучылык белән шөгыльләнүенә дә ишарә ясый.

Бу инсан безнең татар кук... — Бу урында шагыйрь «Акмулла» редакторы Ф. Черкасовның татар кешесе өчен сәеррәк булган фамилиясенә ишарә итә.

«Хезмәт» — XX йөз башында Троицкида китап бастыру һәм сату

өчен оештырылган «Хезмәт ширкәте» каршындагы китапханә күздә тотыла. Бу китапханә халыкка бушлай хезмәт күрсәткән.

Фаяз — Шәехзадә Бабич искәрмәсе: «Фаязның «Рәһбәр фотография» дигән әсәре бар, шуңа карап әйтәм: әллә шул юлда йөрсә, яхшы бер фотографист булыр иде, дим. Югыйсә аның «Безнең китеш» мәҗмугасы вә «Идел»дәге вак-төяк мәкаләләре телгә алырлык вә Фаязны монда кыстырырлык чүпләр түгел». «Идел» газетасында язышып йөргән бу кешенең шәхесен ачыклап булмады.

Фәезхан Давыт — Оренбургта чыккан «Дин вә мәгыйшәт» исемле дини-клерикаль журнал (1906—1918) редакторы.

Буби Фәйзулла — Фәйзулла Мөхәммәт — Иж-Буби мәдрәсәсендә укытып йөргән Төркия гражданины. Бу кеше белән бәйләнешле шундый вакыйга билгеле. 1910 елда паспортының срогы тулганлыктан ул Ватанына кайтып китә. «Татарлар Төркия флоты өчен акча җыялар» дигән ялган хәбәр таралган бер чор бу. Буби мәдрәсәсе җитәкчесе Габдулла Буби, Төркия гражданины белән аралашып, мәдрәсәнең язмышын куркыныч астына куйганлыгын аңлый һәм Ф. Мөхәммәткә кабат килмәскә куша. Җитмәсә, Төркия гражданины Бубидан китүгә, аның инде күптәннән күзәтү астында торганлыгы беленә. Әмма Төркиядән: «Мөхәммәт Фәйзулла әфәнде Бубига китте» дигән хат килеп төшә. Әгерҗедә, Бубида «Истамбул профессорын» жандармнар өч көн буе көтеп яталар. «Истамбул профессоры» исә Казанда туктала һәм 1910 елның ноябрендә Бубига килеп төшә. Буби җитәкчеләре аңа дәресләр бирмәскә тырышсалар да, шәкертләр басымы астында аны мәдрәсәдә калдырырга мәҗбүр булалар. Буби мәдрәсәсе тарихы белән якыннан таныш булган шагыйрь шушы хәлләргә ишарә итә булса кирәк.

Фираки — шушы яшерен имза белән «Шура» журналында шигырьләр басылган. «Җибәрәм сезгә бераз кызматемде, искә алып батып жаткан милләтемде» («Шура», 1911 ел, 13 сан) дигән сүзләренә карап, Фираки казакъ шагыйре дип йөртелә иде. Әмма кайбер мәгълүматларга караганда, бу псевдоним белән яшь әдип Габдрахман Сәгъди язышкан.

Бу эпиграмма 1922 елгы «Шигырьләр мәҗмугасы»на кертелмәгән. 1958, 1985 елгы башкортча җыентыкларда да урын алмаган. Монда «Кармак» журналының 1916 ел 21 саныннан алып урнаштырылды.

Фатыймалар... — 1915 елда беренче тапкыр Оренбург сәхнәсенә чыгып, тиз арада халык арасында танылып өлгергән һәм 1916 елда Г. Кариев тарафыннан «Сәйяр» (Казан) труппасына чакырылган артистка Фатыйма Ильская хакында сүз бара булса кирәк.

Фатыйхалар, Фәүзияләр — шул елларда төрле театр труппаларында чыгыш ясап йөргән татар артисткалары хакында сүз бара.

Нәфасәт хаузы — нәфислек күле мәгънәсендә.

Фәхрелбанат — Фәхрелбанат Сөнгатулла кызы Сөләймания (1885—1959) — татар публицисткасы, тәрҗемәче, укытучы; Ш. Бабич эпиграммасы язылган чорда «Сөембикә» (Казан) журналында язышучы иң актив журналисткаларның берсе. Бу чорда ул шулай ук «Шура» журналында да еш күренә.

Фәхри — Абдулла Фәхри (1923 елда үлгән) — журналист. Истамбулда медицина мәктәбендә укып кайта, башта «Хөсәения»дә, соңрак Иж-Бубида укыта.

Фәхрелислам — Фәхрелислам Нигъмәтулла улы Агиев (1887—1938) — татар балалар язучысы, педагог, дәреслекләр авторы; Казанда чыккан «Ак юл» (1913—1916) исемле балалар журналының нашире һәм редакторы.

...бәхете киткән яртыдан. — Шагыйрь монда Ф. Агиевның бер үк

вакытта шигырьләр дә (назым), хикәяләр дә (нәсер) язып йөрүенә, шул ук вакытта журнал чыгаруына да (нашир), дин эшләре белән бәйле булуына да (мөәзин, имам) ишарә итә.

К. бабына.

Кыям — Кыям Зөлфекари — Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә каллиграфия укытучысы.

Каф тау артыннан, Кыям, син ал да кайт куп материал... — Элегрәк каллиграфия сәнгатен еш кына «Каф тау» артында, ягъни Кавказ якларында, бигрәк тә Дагстанда өйрәнеп кайтканнар. Эпиграммада Кыям Зөлфекариның әнә шунда йөрүе күздә тотыла булса кирәк.

Кортлыкайлар, Котлыкайлар... — Уфа губернасындагы алпавыт, Бәләбәй өязендә дворяннар предводителе, I, II, III, IV Дәүләт думалары депутаты, кадет Котлугъмөхәммәт Тәфкилев (Котлыбай, Котлыкай, 1850— ?) хакында сүз бара.

Безгә бер әйбер бирәлмиләр Думадан үткәреп. — Бу юллар, ирексездән, «Кармак» журналының 1917 ел 4 санында (1 февраль) басылган бер хәбәрне искә төшерәләр. Анда шундый юллар бар иде: «...Г. Думада Аксак Тимер хәзрәтләренең үләр алдыннан аракы эчепме, эчмичәме җан тәслим кылганы мөзакирә кылынган вакытда, фракциядә Зәки әфәнде тарафыннан бирелгән мәгълүмат буенча, Тәфкилев Думада Аксак Тимернең эчеп үлгәнлеген пәч итдерә иде!..» Эпиграмма белән хәбәрнең бер үк вакытта басылып чыгуын искә алганда, аларның икесенең дә Бабич кулы белән язылган булу ихтималы аңлашыла.

...фракциядә Зәки әфәнде... — Монда Зәки Вәлидинең IV Дәүләт думасы каршындагы мөселман фракциясендәге эшчәнлеге күз алдында тотыла булса кирәк.

Аксак Тимер — Тимерлан, Тимур (1336—1405) — Урта Азия дәүләт эшлеклесе, полководец, 1370 елдан — әмир, чыгышы белән Бырлас ыруыннан, Башкаласы Сәмәрканд булган дәүләт төзегән, Алтын Урданы тар-мар иткән, Иранга, Кавказ артына, Һиндстанга, Кече Азиягә һ. б. талау походлары ясаган.

Касыйм Бикколов — Касыйм Җамалетдин улы Бикколов — шагыйрь, прозаик, тәнкыйтьче, тарихчы; «Дин вә әдәб», «Шура» журналларында актив язышкан, дистәләп китап авторы. Берара Яңа Тинчәле авылында (хәзерге ТАССРның Буа районы) мулла да булып торган.

Кыям — Кыям Исхак улы Юлдашев (1890—1955) — татар шагыйре, «Моңлы тавышлар» (1908), «Гыйбрәтле тавышлар» (1912) исемле җыентыклар авторы; вакытында «Шура», «Аң» журналларында актив язышкан журналист.

Колахмәт — Гафур Юныс улы Коләхметов (1881—1918) — күренекле татар драматургы, татар пролетар әдәбиятын башлап җибәрүче, революционер; атаклы «Ике фикер», «Яшь гомер» пьесаларының авторы.

...«Ник уяндың», ник, уянгач, йокладың? — Чыннан да, «Аң» журналында Г. Коләхметовның «Ник уйгандым?» исемле шигыре басылган булган. Бабич шуңа ишарә итеп яза.

...алга алган эшне әйдәп китмәдең? — Шагыйрьне монда Г. Коләхметовның, баштарак драма әсәрләре язып та, соңрак бу өлкәдәге пассивлыгы борчый булса кирәк.

Әл-Кадир — Закир Кадири (1873—?) — буржуаз милләтчепублицист, Уфада чыккан буржуаз «Тормыш» газетасының редакторы, берничә дини-педагогик китап авторы, дини китаплар тәрҗемәчесе, берара «Галия», «Госмания» кебек Уфа мәдрәсәләрендә дә укытып йөргән. Октябрь революциясеннән соң эмигрант.

Акылына, фәһеменә истибдадлы хиссият мөдир! — Бу юлларда

«Галия» мәдрәсәсе белән бәйләнешле билгеле скандалга ишарә сизелә. Бераз вакыт «Галия»дә «сабак мөгаллим» дә булып торган Закир Кадири (Бу турыда кара: «Кояш», 1916 ел, 12 январь) 1915—1916 елларда алдынгы мәдрәсәгә байкот игълан иткән Уфа байларына кушыла һәм, «Галия»не ташлап, «Госмания»дә укыта башлый. «Динсез Галия»дән яңа уку йорты ясау өчен ул көчен кызганмый — яңа дәреслекләр яза, төрле комиссия эшләрендә катнашып йөри... Шуңа күрә дә, прогрессив рухтагы шәкертләр һәм мөгаллимнәр интересын санга сукмыйча, «Галия»не ташлап киткән бу кешенең деспотик ниятләрен «истибдадлы хиссият» — «деспотик хисләр» ди.

Зөкар (зикер) — туры мәгънәсе: искә алу, искә төшерү; алланы мактауга корылган махсус доганы хор белән яки эчтән генә уку.

Тәсәббих — тәсбих тарту, ягъни мактау; зикер әйткәндә, муенса кебек җепкә тезелгән «төймәләрне» алланы мактаган сүзләрне кабатлый-кабатлый тарту.

Остазым син... — Ш. Бабич монда З. Кадириның үзе укыган «Галия» мәдрәсәсендә кайчандыр мөгаллим булып торуын искә ала.

Шаһбаз — хан, шаһ улы мәгънәсендә.

Баттал — буржуаз тарихчы әдәбият белгече Габделбарый Баттал (1874—1949).

Муса — татар буржуа идеологларының берсе Муса Бигиев (1873—1949).

Кормашилар — Сабирҗан Кормаши белән Зариф Кормаши — Алма-Ата шәһәреннән «Шура» журналына язышып торучы бертуган журналистлар.

Әл-Касыйм Гыйрфан — Касыйм Гыйрфан улы Гыйрфанов (1891—1968) — Ш. Бабич белән бер чорда «Галия»дә укып йөргән шәкерт; мәдрәсәне тәмамлагач, мөгаллимлек итә, уку-укыту эшләре хакында, татар-башкорт тарихы, культурасы мәсьәләләре буенча вакытлы матбугатта мәкаләләр бастырган зыялы.

К. бабына.

Кәбир Бәкер — Кәбир Бакиров (1880—1941) — журналист, язучы, драматург, театр тәнкыйтьчесе; Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Ш. Бабичларның якын танышы, төрле елларда «Нур» (Петербург), «Йолдыз» (Казан), «Әлислах» (Казан), «Вакыт» (Оренбург) газеталарында, «Шура» (Оренбург) журналлары редакцияләрендә эшләгән яки язышкан; «Тукай Петербургта» исемле китап авторы, Октябрь революциясеннән соң Ташкентта чыккан «Олугъ Төркестан» газетасының редакторы.

Курсәтә (...) төп-төз диеп кәп-кәкрене... — Шагыйрь монда 1916 елларда төрле спектакльләргә, концерт программаларына карата рецензияләр язып йөргән К. Бәкернең хаклы булуына шикләнә кебек.

Хаклымы, хаксызмы — белмим, әллә дуслар хәтреме? — Күрәсең, Ш. Бабичка кемдер К. Бәкер язган рецензияләрнең сәхнәдә барган «кәкре» спектакльләрдән «төзрәк» булып чыгуы хакында сөйләгән. Шагыйрь чыганакларның икесенә дә шиген белдерә.

Килдебәк — Килдебәкев Һади (Килдебәки, 1881—1943) — баштарак мулла, соңыннан журналист, «Вакыт» газетасы хәбәрчесе, революция чорында «Чулпан» (Мәскәү) газетасы сотруднигы, Үзәк мөселман комиссариаты әгъзасы, күренекле җәмәгать эшлеклесе. Бу кеше шулай ук Октябрь революциясенә кадәр үк чыккан «Ислам һәм музыка» дигән китап авторы буларак та билгеле.

...килде бит михнәт, мәшәкатьләр җиле... — «Ислам һәм музыка» китабы авторының кадимче руханилар тарафыннан күргән каргышлары, михнәтләре хакында сүз бара булса кирәк.

Җил белән ут сүнде бит... — Шагыйрь монда Һади Килдебәкевнең кадимче руханилар басымы астында берара актив язу эшеннән тукталып торуына борчыла.

Кәрамәт Айдаров — үзе турында бик югары фикердә булып та, авыл мулласы булудан уза алмаган Оренбург янындагы Каргалы авылы мулласы.

Кәшшаф Пати — Кәшшаф Патии (Зимәнчәви) — татар шагыйре; тумышы белән элеккеге Хвалын өязе Зимәнчә авылыннан. Шигырьләре К. Мотыйгый, Г. Тукайларның Уральск басмаларында ук күренә башлый. Соңрак «Аң», «Шура» журналларында актив язышa, «Тугыз чәчәк» (1906), «К. Патии шигырьләре» (1910), «К. Зимәнчәви шигырьләре» (1913), «Әшгарь» (1915) исемле шигырь җыентыкларының авторы.

...бассаң да бик күптән тәпи... бер карыш юл атлый алмадың... — Ш. Бабич үз эпиграммасында шагыйрьнең 1905—1906 елларда ук әдәбият мәйданына чыгып, һаман да бер урында таптануына борчылып яза.

Кәрәм — Габдрахман Хәбибулла улы Кәрәм (Рәхмәтуллин (1878—1947) Стамбулда укып кайткан журналист һәм театр тәнкыйтьчесе. Октябрь революциясеннән соң да театр һәм әдәбият тәнкыйтьчесе буларак билгеле.

Камал — Сәлах Камалетдин улы Камал (1885—1954) — Стамбулда укып кайтып, Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыткан хәлфә. Мәдрәсәдә география укыту белән бергә, ул география карталары сызу, шамаилләр язу, журналлар өчен (мәсәлән, «Акмулла» өчен) корректуралар белән шөгыльләнгән. Октябрь революциясеннән соң Оренбургта, Хивада, Казанда укытучы.

Рафаэль Санти (1483—1520) — Италиянең даһи рәссамы һәм архитекторы.

Кәримов Хөсни — Хөсни Кәримов (Миңһаҗетдин улы (1887—1965) — язучы, журналист, педагог; Ш. Бабичның якташы (хәзерге Башкортстан АССР Дүртөйле районы Тумырҗа авылында туган), аның белән бергә «Галия»дә белем алган, соңыннан мөгаллимлек иткән, татар вакытлы матбугатында шигырьләре, хикәяләре, мәкаләләре белән катнашып торган. Октябрь революциясеннән соң «Башкортстан хәбәрләре» (Уфа), «Яңа юл» (Уфа), «Мәгариф» (Казан), «Безнең юл» (Казан) газета-журналларында актив язышa, Совет органнарында эшли.

...учительләр эчендә дәртлелек. — Мәдрәсә тәмамлап, мөгаллимлек итеп йөргән Х. Кәримнең татар-башкорт яшьләре арасында алып барган актив җәмәгать эшенә ишарә.

Кәримов Камил — Кәрим Камил (1892—1947) — публицист, тәрҗемәче; Фатих Кәриминең туганы (энесе), Мәскәү университетының юридик факультетын тәмамлагач, Казандагы арбитраж идарәлегендә эшли.

...сезгә милләт ике күзен дүрт итә. — Ш. Бабич бу очракта Мәскәү студентының «Вакыт» газетасында басылган, финанс-экономик мәсьәләләргә багышланган берничә җитди мәкаләсен күз уңында тота булса кирәк.

Кәримов бай — Хәсән Кәримов — Уфада һәм Казанда типография (борадәрән Кәримовлар матбагасы) тоткан һәм шул ук шәһәрләрдә мануфактура, галантерея, китап белән сәүдә иткән бай.

Бу җиһан мөэмингә дә һәм байга да зиндан мәгәр. — Х. Кәримов, беренче бөтендөнья сугышында пленга төшкән төрек солдатларына материаль ярдәм күрсәтүдә гаепләнеп, күпмедер вакыт төрмәдә утырып чыга. Шагыйрь үз эпиграммасында шуңа ишарә итә булса кирәк.

Курмаев Камил Карамыш — Камил Карамышев — Мәскәүдәге эре сәүдәгәр.

Кәшшаф Тәрҗемани — Кәшшаф Кыяметдин улы Тәрҗемани (1877 — 1940) — баштарак Уфада Диния нәзарәтендә казый, соңыннан Казанда мулла, имам. Унынчы елларда дини мәсьәләләргә багышланган мәкаләләре белән билгеле. Октябрь революциясеннән соң муллалыгын дәвам итә, хәтта, НЭП вакытында Казанда «Ислам» исемле дини журнал да чыгара.

...Тәрҗемансыз мәгънәләр кәшшаф түгел... — Чуар, ярым татар, ярым гарәп телендә язышкан Кәшшаф Тәрҗеманиның мәкаләләрен тәрҗемәсез уку мөмкин түгел, дип аңларга кирәк.

Йә, ә-иммател Казан! Ник күңелегез шәфаф түгел? — әй, Казан имамнары! Ник күңелегез ачык түгел? дип аңларга кирәк. Күрәсең, монда Ш. Бабич Уфаны калдырып Казанга киткән К. Тәрҗеманиның «дин-мәгыйшәтче» муллалар арасына барып керүен өнәп бетерми. Тәрҗемани исә, чыннан да, Казан муллалары арасында зур абруй яулап өлгерә. Ул, хәтта, 1917 елның язында Казанда узган дин галимнәре съездының оештыру комитетына да кертелә. (Кара: «Кояш», 1917 ел, 30 май саны.)

Л. бабына.

Лотфый — Мостафа-Лотфый Исмәгыйлев-Ширванский — журналист; 1905—1907 еллы революция чорында Төркиядә укып кайтып, Әстерханда төрле җәмәгать эшләрендә катнаша башлый, соңыннан «Мөселман иттифакы» партиясенә кушыла, хәтта аның җитәкче үзәгенә дә үрли. «Мөселман иттифакы»ның политик программасын раслау өчен җыелган Өченче съездда (Нижний Новгород, 1906 ел, 16—20 август) секретарьлыкка сайлана. Мостафа-Лотфый шулай ук «Борһане тәрәккый» (1906—1911), «Хәмият» (1907—1909), «Мизан» (1908—1909), «Хак» (1911) кебек мәсләксез, чуар телле, чуар карашлы газеталар нашире буларак та билгеле. Үзенең буржуаз газеталарында бу кеше революцион демократларга һөҗүмнәр ясый, татар әдәби телен төрекләштерергә чакыра.

...син йөрмәс идең сеперелеп, йорт-җиреңнән умырылып... — Шагыйрь монда Мостафа-Лотфиның Төркиягә ясаган «гыйбрәтле сәяхәтләре»нә ишарә итә. Бу тема инде Г. Тукай тарафыннан ук көн тәртибенә куелган иде. «Ялт-йолт» журналының 1912 ел 37 санында басылган шигырьдәге «Монда кайткач симергән, чучка булган Мостафа» дигән юллар Мостафа-Лотфыйның Төркиягә ясаган сәяхәтеннән соң язылган.

Лотфый Гадел — Лотфый Гаделев — Ш. Бабич белән бер чорда «Галия» мәдрәсәсендә укыган, соңрак журналист, тәнкыйтьче, тәрҗемәче; «Кояш» газетасында шигырьләре, хикәяләре, мәкаләләре белән еш чыгыш ясаган татар язучысы.

Ләбиб — Ләбиб Сәлимов — «Галия» мәдрәсәсе шәкерте, аны тәмамлагач, Истамбулда укып йөри һәм шунда врач булып кала. Читтә торып, «Шура» журналында һәм «Вакыт» газетасында мәкаләләр бастыра.

Фәс — төрек халкының баш киеме (бу очракта — төрекчелек символы).

Мулла Локман Канзәфәри — Локман Хәким — 1911 елда Уфада «Мәгълүмате җәдидә» дигән журнал чыгарып, уңышсызлыкка очраган (журнал таралмаган) һәм кабаттан рухани булып киткән Келәш авылы мулласы (хәзерге Чишмә районы, БАССР).

...аз-маз муллалыктан башка хикмәт анда — һич! — Бу юллар аша шагыйрь Локман Канзәфәринең булдыксыз журналист булуына ишарә ясый.

М. бабына.

Мәрҗани — Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани (М. Галәү, 1887—

1937) — күренекле татар язучысы, журналист; Оренбургта чыккан «Кармак» (1915—1917) көлке журналының нашире һәм редакторы, «Ник язылганнар?», «Мәктәп балаларына махсус шигырьләр», «Мөһаҗирләр», «Иван баҗай» кебек китаплар авторы. Бер үк вакытта сәүдә эше белән дә шөгыльләнгән: Оренбургта «Белек» исемендәге китап кибете тоткан. М. Мәрҗани — Бабичның якын танышы, дусты.

...парлак яшә, сындырмыйча «Кармак» сабын. — Шагыйрь монда М. Галәүдән «Кармак» журналын туктатмауны үтенә. Мондый шиккә, чыннан да, нигез була. Аның редакторы һәм нашире 1916—1917 елларда, Панкратов дигән бер бай белән берләшеп, зур кибет тота, сәүдә эше белән шөгыльләнә.

...маддият түгелдер бит бар максатың? — Бабич бу очракта да шул фикерне кабатлый, Мәрҗанигә «мал җыю чире» тимәсен, дип кайгырта. Бу борчу шагыйрь Оренбургка, «Кармак» журналына эшкә күчкәч тә дәвам итә әле. Оренбургта барган әдәби кичәләрнең берсендә залдан: «Бабич мине бер дә телгә алмый дип, Мәхмүт Мәрҗани үпкәләп утыра»,— дигән тавыш ишетелә. Бабич шунда ук җавап бирә:

Мәрҗани бай мал тутырган
Панкратов йортына,
Эш зураеп китте, диеп,
Хәзер үзе куркына.

(Кара: Р. Бикбаев. Шәйхзада Бабич. Тормошо һәм ижады. Өфө, 1981, 234 бит.)

Мамлиев — Нурмөхәммәт Мамлиев — Уфада Диния нәзарәтендә казый.

Күп хәшәб алды мөдәррислек... — «Чәйләү» (взятка) юлы белән бу казый аркылы мөдәррислек исеме ала торган булалар. Бабич шуңа ишарә итә.

«Мөхтасар» — шәригать кануннарының кыскача җыелмасы.

Мөхлисә Буби — башта Иж-Бубидагы атаклы мәдрәсә янындагы кызлар мәктәбендә укытучы; 1911 елда Ишмөхәммәт ишан доносы белән Буби мәктәбе туздырылгач һәм аның мөдәррисләре Габдулла Буби белән Гобәйдулла Бубилар төрмәгә ябылгач, Мөхлисә Буби Троицкидагы Дарелмөгаллиматтә (мөгаллимәләр мәктәбендә) укыта, соңрак Уфадагы Диния нәзарәтенә казыя итеп чакырыла.

Паташ Мәрьям — Мәрьям Паташева — бай кызы. Петербургта югары белем алган; 1912 елда Төрек-болгар сугышы вакытында Төркиягә үз ихтыяры белән шәфкать туташы (һәмширәсе) булып киткән дүрт мөселман кызының берсе.

Мәрьям — 1916 елда Ташкентта казакъ телендә чыккан «Алач» газетасының редакторы (милләте белән казакъ) Мәрьям Тугусова хакында сүз бара булса кирәк. Бабичның эпиграммасы шул газетаның чыга башлавы уңае белән язылган.

«Азамат» — милләтче казакъ шагыйре Мырҗакуп Дулатовның шигырьләр җыентыгы.

Бу эпиграмма шагыйрьнең бер генә җыентыгына да кермәгән. Монда «Кармак» журналының 1917 ел 1—2 саныннан алып урнаштырылды.

Мәрдегаләм — Мәрдегаләм Мөхәммәтев — укытучы, журналист, соңрак врач; Троицкидагы Зәйнулла Рәсүлев мәдрәсәсендә укыган, Казанда Учительская школа тәмамлаган мөгаллим, укыту-тәрбия мәсьәләләре буенча вакытлы матбугатта мәкаләләре белән катнашкан кеше. Октябрь революциясеннән соң Уфада балалар врачы, медицина фәннәре докторы, медицина институты профессоры.

...селкеп салып барган яман... — Рәхимҗан Атнабаев дигән Троицк

мөгаллиме һәм журналисты, күрәсен, еш кына М. Мөхәммәтевнең язган мәкаләләренә каршы тәнкыйть белән чыккан.

Атнабай — Рәхимҗан Атнабаев — Троицкидагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллиме һәм журналист-тәнкыйтьче.

Мөнир — Мөнир Рәшит улы Ибраһимов — Габдерәшит казыйның улы; Мөнир Рәшитов атасы белән бергә Япониядә мөселман миссионеры кыяфәтендә японлыларны мөселман диненә димләп йөргән.

«Сөбханәкә» артынчы «Вәлгасер» дидең, «Әлхәм» кая? — Бу юлларны, Коръән сүрәләренең тәртибен дә белмичә торып, ислам диненә димләп йөрисең, дип аңларга кирәк.

«Сөбханәкә», «Вәлгасер», «Әлхәм» — Коръән аятьләре.

Мостаев Шакир — журналист; Петербургта чыккан «Безнең ил» газетасының (1916—1917) редакторы.

Бер мөхәррир урынын алды, бер гәзит сүнгәч кенә. — 1916 елның сентябрендә Мәскәүдәге «Сүз» газетасы (1915—1916) ябтырылгач, аның урынына 1916 елның ноябрендә «Безнең ил» исемле газета чыга башлый. Газетаның башында асылда «Сүз» газетасы өчен нык тиргәлгән Гаяз Исхакый тора. Ләкин аңа патша хөкүмәте тарафыннан рөхсәт бирелмәгәнлектән, газетаның рәсми редакторы итеп әлегрәк «Таң»чылар тирәсендә уралып йөргән Шакир Мостаев куела. Эпиграммада шул вакыйгаларга ишарә бар.

Әйтергә кирәк, Г. Исхакый һәм аның газеталары язмышы Бабичны 1915—1916 еллардан ук борчып килгән. Шагыйрьнең «Кармак»та басылган «Авыл җырларына» гына күз салыйк: «Кармак», 1915 ел, 6 сан; «Кармак», 1915 ел, 7 сан; «Кармак», 1915 ел, 12 сан һ. б.

«Таң»чылар — 1905 елгы революция елларында Казанда чыккан «Таң йолдызы» исемле демократик юнәлештә татар эсерлары газетасы тирәсенә тупланган татар зыялылары хакында сүз бара.

Мортазин — Вәлиулла Байназар улы Мортазин-Иманский (1886—1938) — Татарстанда һәм Башкортстанда театр хәрәкәтен башлап җибәрүчеләрнең берсе, башкорт совет театрына нигез салучы режиссер һәм артист: Г. Кариев, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская белән бергә «Сәйяр» труппасы оештыручы, 1915 елда үзенең «Ширкәт» исемле труппасын төзи. Бу труппа артистларының бер төркеме соныннан В. Мортазин-Иманский җитәкчелегендә башкорт милли драма театрының режиссерлары һәм артистлары булып китәләр.

Мутин — Мохтар Исхак улы Мутин (1885—1937) — күренекле татар артисты. Октябрь революциясеннән соң Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли.

...кырыштырыйча бергә яши, кем ышаныр: бер аю һәм бер бүре бергә яши. — Эпиграмма 1916—1917 елларда, ягъни М. Мутин белән В. Мортазинның Уфада бер труппада уйнап йөргән вакытларында язылган. Бабич аларны бүре белән аюга тиңләп, бу артистларның сәхнәдә уйнау манераларын, характер сыйфатларын бирергә омтылган. Авыр сабырлылыкка, салмаклыкка, әмма шул ук вакытта мәһабәтлеккә ия Мортазин белән ярсу, каһарман рухлы Мутин чын-чынлап сәхнәдә бер берсен тулыландырып торганнар.

Минһаҗ абзый — Минһаҗетдин Юныс Кадермәтев (Минһаҗ Һинди, Кадермәти 1871—1925) — Һиндстанда укып кайтып, Хвалын өязендә (хәзерге Саратов өлкәсе) Һиндстан мәдрәсәләре тибында университет салдырам дип, дан чыгарып, халыктан акча җыйган һәм аны үз кирәгенә тотып бетергән аферист Минһаҗ Һинди-Кадермәти.

...«Галия» дип әле белса кәпрәя. — Бу кеше шулай ук Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен ябтырып, аның урынына икенче, яхшырак «Галия» ачтырам, дип, ил арасында акча җыеп йөри. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һ. б. әдипләр дә Минһаҗ Һиндине сатира уты астына алдылар.

Ш. Бабич эпиграммасы аеруча Г. Тукайның «Минһаҗ» әсәре белән аваздаш янгырый. Тукай шигырендә шундый юллар бар:

Таш ташыйлар, анда Минһаҗ «Галия» нигезен сала.
Туй ясыйлар: монда Минһаҗ гаилә нигезен сала.

Тукай монда «Галия» өчен җыелган акчаның туй мәҗлесенә тотылып бетүенә ишарә итә.

Мортазин Фатих — мулла, журналист; Самарада (хәзерге Куйбышев шәһәре) 1908 елда чыга башлаган «Икъдисад» (Экономика) дигән журналның нашире һәм редакторы.

Икътисадны читкә селтәп... — Шагыйрь монда авыл көнкүреше, сәүдә һәм экономика мәсьәләләрен яктыртучы «Икътисад» журналының 1913 елның апреленнән кинәт кенә чыгудан туктавына ишарә итә (бу журнал барлыгы 55 сан чыккан).

Мәхмуди Хуҗа — Мәхмүдхуҗа Бәһбүди — үзбәк язучысы, 1913 елда чыга башлаган «Айна» («Көзге») дигән журналның һәм «Яңа Сәмәрканд» исемле газетаның нашире һәм редакторы.

Максудов — Галим Максудов — Петербургта милли матбага тоткан татар бае.

Мостафа Сәйфелмөлек — Мәскәүдә укыган чагында «Шура» журналында мәкаләләр белән катнашкан студент. Соңрак Германиядә укып кайтып, теш врачы булып эшләгән.

Манат — Шәриф Әхмәтҗан улы Манатов (Әхмәтҗанов, 1892—1936) — тумышы белән хәзерге Башкортстан АССР Учалы районы Манат авылыннан. Башлангыч белемне авыл мәдрәсәләрендә һәм Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсендә алгач, татар мәдрәсәләрендәге уку торышы белән килешмичә, Швейцариягә китә һәм аннан югары белем алып кайта. Чит илдән кайткач, Шәриф Манатов актив җәмәгать эшлеклесе булып әверелә. «Йолдыз» газетасында кыю фикерләр белән чыгыш ясый. 1917 елда Үзәк шурага сайлана, Оренбургтан Учредительное собраниегә депутат булып бара, соңрак Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты төзүдә катнаша, М. Вахитов, Г. Ибраһимов белән бергә шунда эшли, башкорт-татар бүлеге председателенең урынбасары вазифасын башкара. 1920 елдан шул комиссариатның Башкортстандагы тулы хокуклы вәкиле. Артабан Әрмәнстан Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетында җаваплы хезмәткәр, Төркестан мәгариф халык комиссариатының коллегия әгъзасы, Башкортстан мәгариф халык комиссариаты янындагы Академүзәк җитәкчесе.

...анда тырышып ал сабак... — Ш. Бабич чит илдә укып йөргән Ш. Манатовка шулай дип дәшә.

«Рәсүлия» — Троицкида Габдрахман Рәсүлев ишан мәдрәсәсе.

Мирхәйдәр — Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзи (1891—1928) — күренекле татар драматургы.

Ник балаларга театр язмый... — «Галиябану», «Асылъяр», «Ак калфак» кебек драмалары белән танылган драматургка Ш. Бабич балалар өчен дә пьесалар язып карарга киңәш итә.

Мөхетдин — Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиев (1873—1941) — күренекле татар телчесе, педагог, профессор.

...имляң төзәт, язганнарың алга чыга. — М. Корбангалиевнең тел мәсьәләләре буенча басылган мәкаләләренә ишарә ителә булса кирәк.

Мирвәли Калтай — Тимергали Мирвәли улы Мирвәлиев — Башкортстанның хәзерге Кушнаренко районы Калтай авылыннан. Мирвәли Калтай имзасы белән татар вакытлы матбугатында, шул исәптән «Дин вә мәгыйшәт» журналына да, мәкаләләр, дидактик шигырьләр белән катнашкан мулла.

Мәкки Морад — Рәмзи Мөхәммәд Морад (Модал Мәкки) — динчебәдәлче, ялланып, байлар өчен хаҗ кылып йөргән бер адәм.

«Дин-мәгыйшәтче» имамнар табына... — сүз «Дин вә мәгыйшәт» журналы иярченнәренең, Мәкки Морадны яллап, хаҗга җибәрүләре хакында бара. Бу тема Г. Тукай иҗатында да тулы чагылыш тапкан иде. «Ялт-йолт»ның 1911 ел 26 санында (15 август) басылган «Өч баш» мәкаләсендә шагыйрь аны «Дин вә мәгыйшәт»челәр төркеменә кертеп тәнкыйтьли.

Хаҗ — (табыну) мөселманнарның «изге» урынга — Согуд Гарәбстанындагы Мәккә шәһәренә — Кәгъбәгә барып, гыйбадәт кылып кайтулары.

Н. бабына.

Нәүрузов — Вәгыйз Нәүрузов — буржуаз журналист; баштарак Троицкида чыккан «Сибирия» (1912—1913) газетасының, соңрак Уфадагы «Тормыш» газетасының редакторы; пантюркист, патша охранкасы агенты. Октябрь революциясеннән соң Колчак армиясе офицеры, «Ватан» (1919) исемле аклар газетасы редакторы.

«Нун» капкасын... — эпиграммаларның «Н» хәрефе бүлегеп...

...ул бәгъзан залим, бәгъзан катыйль мазлум кебек. — бу юлларда В. Нәүрузовның икейөзле, әчкерле кеше булуына ишарә ителә.

Науширван Яушш — Науширван Ширъяздан улы Яушев (?—1917) — публицист, телче, фольклорчы; миллионер Габделвәли Яушевның туганы, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе һәм 5 класслы кызлар мәктәбе хуҗаларының берсе.

Габделвәли Яушев (?—1906) — Троицк сәүдәгәре, миллионер, нашир. Аның хакында Г. Баттал 1912 елда «Габделвәли вә хатирәт иянәреннән» (Оренбург, «Вакыт» матбагасы, 1912) дигән китап та бастырган.

Иске эзләрдән йөреп... — Эпиграмма Троицкида язылган. Шуңа күрә, Ш. Бабич шул шәһәр кешесе Н. Яушев хакында җентекле мәгълүмат туплаган булырга тиеш. Монда ул Яушевның элгәрерәк Урта Азия шәһәрләренә ясаган сәяхәтенә ишарә итә булса кирәк. Бу кеше кайчандыр Урта Азиядә йөреп, андагы шәһәрләр архитектурасы хакында «Шура» журналында мәкаләләр бастырган.

...син яңа сүзләргә кавыш. — 1917 елның февралендә язылган бу эпиграмма Троицкидагы революция көннәренә алып китә. Үзе әйтмешли, революция рухы белән «исереп» йөргән шагыйрь Әхмәт Таҗетдин дигән Троицк журналисты белән берлектә «Хөр милләт» исемле газета чыгару турында хыяллана. Акча белән һәм бина белән ярдәм итүне үтенеп, алар әлеге Н. Яушевка мөрәҗәгать иткәннәр булса кирәк. Һәрхәлдә, 1917 елның апрелендә чыга башлаган «Хөр милләт» газетасы, Бабич Уфага, аннары Оренбургка киткәч тә, Яушев кулында кала. Әмма, Бабич киткәч, газета революцион мәсләген үзгәрткән булса кирәк. Шагыйрь аңа карата үткен-үткен генә тәнкыйть сүзләре әйтә. Бу хакта «Кармак» журналының 1917 ел 10-11-12 санында басылган хәбәр дә сөйли. Анда милләтчел идеяләр белән чуарланган бу газетага карата шагыйрьнең ачы иониясен сизми мөмкин түгел (бу чорда Ш. Бабич — «Кармак» журналында секретарь булып эшли): «Яушевларның өй түбәсенә кунаклаган «Хөрти милләт» чәүкәсе, милли-мәдәни мохтарият игълан кылынгач, газетасының башына: «Яшәсен татар хөкүмәте!» — дип куйды. Хәзерге көндә үзе урманда Төркиягә табан җир астыннан, һәм дә татар милләтенә, саклык өчен, урман кисеб, күсәк, чукмар, кәшәкә, тәпәч, корык, каугә вә башка кораллар ясау белән мәшгуль...»

Нәкыя — Нәкыя Абруй-Сәйфи (Фатих Сәйфи Казанлының хатыны, 1890—1960) — Унынчы елларда Уфада күпсанлы концертларда, кичәләрдә катнашып йөргән җырчы, мөгаллимә. Октябрь революциясеннән соң

Коммунистлар партиясе әгъзасы, татар-башкорт хатын-кызлар хәрәкәте җитәкчеләренең берсе, Татарстан өлкә комитетында хатын-кызлар бүлеге инструкторы. Совет чорында шулай ук педагог, журналист, җәмәгать эшлеклесе буларак билгеле. Соңгы елларда суд органнарында эшләгән.

...Җыр белән өлфәт казанмас: таушы аз... — эпиграмма язылган чорда, ягъни 1916—1917 елларда, Абруй Сәйфи Уфа халкының иң сөекле җырчыларыннан берсе була. Сәйфиләр гаиләсе белән якыннан аралашып яшәгән, Нәкыя белән уртак концертлар, спектакльләр биргән Бабич аны шаяртып «Йөз суы» дип йөрткән («Абруй» сүзенең татарчага тәрҗемәсе шулай). Абруй Сәйфигә багышланган эпиграмманы да шундый уртак концертлар хатирәсе буларак туган, дип уйларга кирәк.

Нургали — Нургали Сибгатулла улы Надиев (1883—1940) — Октябрь революциясенә кадәр Оренбург мәдрәсәләрендә, революциядән соң Казан педагогия институтында укытучы. Төрле газета-журналларда педагогик темаларга оригиналь һәм тәрҗемә мәкаләләр бастырган.

Инде байтак Нургали койрык-шәрифне боргалый... — Бу юлларда шагыйрь Оренбург тирәсендә яшәгән һәм мөгаллимлек иткән Нургали Ишаев (Нурлыгаян Ишаев) дигән шагыйрьне дә күз уңында тоткан булса кирәк.

Нургали ахун — Нургали Хәсәнов-Болгари — Татарстанның Буа шәһәрендә мәдрәсә тоткан ахун.

Нургали ахун — «Хөррият юлы, дин кайгысы» (Әсәрләр, 1910) кебек берничә китапчык чыгарган Нургали Курамшин (Кулаткави) хакында сүз бара булса кирәк.

Нуретдин — Нуретдин Гафур — Буби мәдрәсәсеннән китеп, Стамбулда «Ислам дөньясы» дигән газетада редактор булып эшләгән кеше.

...йөр бүректән, фәсне сал. — Төреклегеңне ташлап, татар бул, дип аңларга кирәк.

Нуркин Заһид (1889—1966) — журналист, театр тәнкыйтьчесе; революциягә кадәр «Аң» журналында, «Йолдыз», «Кояш» газеталарында язышкан. Октябрь революциясеннән соң мәгариф органнарында эшли. Ул шулай ук К. Маркснык «Капитал» әсәрен беренче тапкыр татар теленә тәрҗемә итүче буларак билгеле.

Купшылык һәм майлану пәйгамбәре... — 1916 ел ахырында, 1917 ел башында З. Нуркин аеруча «Кояш» газетасында актив катнаша. Һәр санда диярлек аның төрле спектакльләргә карата язылган мәкалә-рецензияләре басылып тора. Аларда куелган спектакльләр хакында махсус купшыландырып, матурайтып сөйләнелә. Бабич та Нуркинның әнә шул мәкаләләренә ишарә итә булса кирәк.

Нәҗиб — Нәҗиб Хәлфин — тәнкыйтьче, тәрҗемәче, галим, профессор; Октябрь революциясе елларында Казанда чыккан «Корылтай» (1917—1918) исемле буржуаз-милләтче газетада актив язышучы, I Мөселманнар съездын оештыручыларның берсе. Ш. Бабич үз эпиграммасында Н. Хәлфиннең шул чорда газета битләрендә басылып торган зур күләмле, әмма сай эчтәлекле кайбер чыгышларын күз уңында тота булса кирәк.

Нәҗиб — Нәҗиб Думави (1883—1938) — татар шагыйре, укытучы; атаклы Буби мәдрәсәсендә укыткан, ул ябылгач, беренче бөтендөнья сугышында катнаша, балалар укыта. Октябрь революциясеннән соң берара мулла булып та тора. 20 елларда рәсми рәвештә муллалыгыннан баш тарта.

...«хәлфуш» Нәҗиб... — Н. Думави, империалистик сугыштан яраланып кайткач, Чистайда балалар укыта, мәктәпләр тормышы хакында мәкаләләр яза (Мәс., «Кояш», 1916 ел, 10 июнь (979) саны). Бабич аның әнә шул хәлфәлегенә ишарә итә булса кирәк.

Безгә биргел бик гаҗиб һәм назик «манзум»... — Н. Думави үз ши-

гырьләрен еш кына «назым» дип атый («Яз», «Бер күренеш», «Бака һәм үгез» һ. б.). Бабич шуларга ишарә итә булса кирәк.

Нәҗиб Гасрый — Нәҗиб Мәүләмбирдиев (1887—1938) — язучы, журналист, тәнкыйтьче, педагог; Төркиядә укып кайтып, Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә әдәбият укыткан, артабан Астрахань шәһәрендә «Борһан тәрәккый», «Хәмият», «Мизан», «Сарай» кебек, 1906—1911 еллар арасында берсе туктауга икенчесе чыгып торган бик аз гомерле реакцион буржуаз газеталарда (нашире — Мостафа-Лотфый Исмәгыйлев-Ширванский) язышучы, аларның кайсыберләренең редакторы.

«асрайыр», «бәсләйер», «кәденчә әйтәм» — әлеге буржуаз газеталар теленә хас үзенчәлекләр. Төрекчелек идеяләрен алга сөргән бу газеталар чыннан да төрек теленнән кергән сүзләр белән чуарланып беткән була. Шуңа күрә алар озак яшәмиләр дә. Бабич бу үзенчәлекне бик төгәл тотып алган.

Нәҗиб Түнтәр — Мөхәммәтнәҗиб Гыйрфанов (Түнтәри) — Казан губернасы Малмыж өязендәге Түнтәр авылы мулласы (хәзерге Татарстан АССР Балтач районы), ысул җәдидче мөгаллим, журналист.

...син «Дин әдәп»тән түнтәрел! — Ш. Бабич эпиграммасында Мөхәммәтнәҗиб Гыйрфанов белән «Дин вә мәгыйшәт»че Ишми ишан арасында булган конфликтка ишарә бар кебек. Эш шунда ки, унынчы еллар башында Ишми ишан Түнтәр авылында ысул җәдид белән укытучы Нәҗиб мулланы судка бирә. Сарапул шәһәрендә узган суд җәдид мулланың указын алу белән тәмамлана. Шул вакыйганы күз уңында тотып, Ш. Бабич Түнтәр мулласын «Дин вә мәгыйшәт»челәргә баш бирмәскә өнди.

Нәҗиб Корбангали — Нәҗиб Корбангалиев — Троицк шәһәрендә Яушевлар мәктәбендә укытучы; юрист, Дәүләт думасы янындагы мөселман фракциясе әгъзасы, 1917—1918 елларда Уфадагы Мәгариф нәзарәтенең рәисе.

Нияз Максудов — Ниязколый Максудов — Америкада укып кайтып, Троицкидагы Яушевлар мәктәбендә укытучы булган. «Шура» да укыту эшләре буенча мәкаләләр бастырган.

Нәзирев — Садретдин Нәзирев — Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен матерналь яктан тәэмин итеп килгән бай. 1915 елда Җиһангир Абызгилдин җитәкчелегендәге Уфа байлары һәм кайбер интеллигенция вәкилләре «Галия»не ябтырып, аның урынына икенче мәдрәсә («Галияи Сания») ачу идеясен күтәреп чыккач, С. Нәзирев аларга кушылып китә.

Нинди буксирга тагылса, ул китә шунда табан. — Ш. Бабич монда Садретдин байның аумакайлыгын ассызыклап күрсәтте. Чынлап та, «Галия» тирәсендә барган шау-шуда ул кадимчеләр ягында чыгыш ясый. Шул ук вакытта ул «Галия»нең 1916 елның декабрендә узган унъеллык юбилеенда катнашуны да кирәк таба, иганәгә бераз акча да бирә. Бу хакта «Кояш» газетасы түбәндәгечә язып чыккан: «Ничек булса да, Садретдин әфәндене янадан «Мәдрәсәи Галия»гә мәхәббәт иттерүгә көч сарыф ителгәнлек күренә иде» («Кояш», 1917 ел, 12 январь (1066) саны). Әмма С. Нәзиревнең иске «Галия»гә булган мәхәббәте озакка бармый, ул кабат «Җәмгыяте хәйрия» (Уфа) әһелләре тәркемәнә барып кушыла, уку-укыту эшләренә бирәсе сумманы шунда биреп бара.

В. бабына.

Җим Вәлид — Җамалетдин Вәлидов (Вәлиди, 1887—1938) — галим, татар теле һәм әдәбияты белгече, педагог.

«Җим» Вәлид»тән «лам гайдә»! — Өметле күренсә дә, Җамал Вәлидидән берни дә чыкмады, дип аңларга кирәк. Үзе әйбәт галим булса да, идеалы еракка күрә, аңа ирешер чарасы юк, ди шагыйрь.

Вәлиш — Нурмөхәммәт Вәлишев — татар мәдрәсәләрендә укыту өчен математика дәреслекләре язган автор.

...ныграк чалыш «касрең» белән... — ныграк шегыльлән «касрең» («вакланма» — математика термины) белән, дип аңларга кирәк.

Вәли — Мөхәммәтвәли Хөсәенов — Оренбургның иң эре байларыннан мәдрәсә тоткан мулла, «Дин вә мәгыйшәт» журналының нашире, миллионер Гани бай Хөсәеновнең (1840—1902) улы, Мәхмүт бай Хөсәеневнең (1839—1912) энесе.

...«дин угърысы» дип йөртелә. — Вәли бай, мәктәп-мәдрәсә файдасына дип, атасы Гани Хөсәенев калдырган вәкыф малын үз файдасына тотып бетергән. Шул уңай белән Г. Тукай 1910 елда ук аны үзенең «Гаҗәп талантлар (Истигъдаде фәүкыльгадә)» дигән «Сүзлеге»нә керткән иде. Анда ул: «Вәли мулланың вәкыф малын ашарга (...) талантлары бардыр», — дип язган иде. («Ялт-йолт», 1910 ел, 1 сан). Ш. Бабич үз эпиграммасында Тукай башлаган тәнкыйтьне дәвам итә. Дини мәдрәсәләр өчен калдырылган акчаны үзләштергән Вәли мулланы ул «дин угърысы» дип атый, үзен үрмәкүчкә тиңләп, аның оясын мәдрәсә, шәкертләрне үрмәкүч авына килеп эләккән бөҗәкләр белән чагыштыра.

Вакыф малы — берәр кеше тарафыннан килерен җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек.

«Әлислах» Вафасы — Вафа Бәхтияров (1881—1960) — журналист, педагог; Казанда чыккан «Әлислах» («Реформа») газетасының редакторы.

«Әлислах» — 1907—1909 елларда Казанда чыккан демократик юнәлештәге газета. Бу газетаны чыгаруда Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал һ. б. әдипләр якыннан торып катнашалар.

...эт өргезеп! — «Әлислах» үзенең демократик рухтагы мәкаләләре, кыю фикерләре белән кадимче руханиларны, байбәтчәләрне, патша охранкасын һәрвакыт куркытып торган, ягъни «эт өрдергән».

Вәсим — Мөхәммәтвәсим Солтанов — элекке «Галия» шәкерте, соңыннан укытучы, китапханәче, «Канау буе» (1910), «Ләззәт яки тәм» (1913) кебек берничә шигырь китабы авторы.

...фикереңне үтереп, чык ясин! — Шагыйрьнең монда В. Солтановның сай фикерле, көпшәк поэзиясенә ишарә итә.

Ясин — Коръәннең 36 нчы сүрәсе. Аны үлем түшәгендәге кеше баш очында укыйлар.

һ. бабына.

һади — һади Мифтахетдин улы Атласов (Атласи, 1878—1938) — татар тарихчысы; «Казан ханлыгы тарихы», «Сибирия тарихы», «Сөембикә» кебек тарихи хезмәтләр авторы, II Дәүләт думасына депутат. Октябрь революциясеннән соң эмиграциядә.

«Атлас ясый» — китап оештыра, дип аңларга кирәк.

Сәгъди һади — укытучы, язучы («Бәхетсезләр» (Казан, 1911) исемле повесте билгеле), журналист; «Шура» журналында мәкаләләр белән еш чыгыш ясаган. Октябрь революциясеннән соң татар һәм башкорт башлангыч мәктәпләре өчен әлифба төзегән.

Й. бабына.

Йарулла әл-Вәли — Йарулла Вәли (1879—1934) — татар язучысы һәм драматургы; Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасының сотруднигы, 1917 елдан — редакторы («Яңа вакыт»).

Йәрмәки — Зыя Насыйров (Яәрмәки, 1887—1965) — татар шагыйре. (483 биттәге искәрмәне кара.)

...муллалыкта тормакы мәгъкуль түгел. — Революциягә кадәр үк берничә шигырь китабы чыгарып өлгергән бу сәләтле шагыйрь 1915—

1916 елларда атасы урынына мулла булып китә. Ярмәки мулла белән Бабич 1916 елның декабрендә «Галия» мәдрәсәсенең унъеллык юбилеенда очраша. Эпиграмма шул чорда ук язылган булырга мөмкин. Һәрхәлдә, шул очрашудан соң күп тә үтми, Зыя Насыйров-Ярмәки муллалыгын ташлый һәм кабат балалар укыта башлый, иҗат эше белән шөгыльләнә.

«Ай» (Йосыф)— Йосыф Акчурин (Акчура, 1971—1935) — буржуаз журналист; Казанда бостау фабрикасы тоткан. 1905 елда «Казан мөхбире» («Казан хәбәрчесе») дигән буржуаз газетаның редакторы. Йосыф Акчурин — шулай ук татар либераль буржуа идеологы, кадет, «Мөселман иттифакы» партиясен оештыручыларның берсе.

«Ай» — И. Акчуринның псевдонимы (А. Й. инициалларыннан ясалган).

...Байкал, Идел, Алтай, Уралга ай иде...— Шагыйрь монда Йосыф Акчураның кайчандыр «Мөселман иттифакы» партиясенең башында торуына ишарә итә булса кирәк. Эпиграммада шулай ук бу кешенең әлеге партиянең Дәүләт думасындагы фракциясе составына кертелгән булуына да ишарә бар.

Йеникеев — Гайса Хәмидулла улы Йеникеев (1867—1931) — мөгаллим, татар морзасы (аны *Гайса мирза* дип тә йөрткәннәр). Ул шулай ук III Дәүләт думасына депутат булып бара, соңыннан Вакытлы хөкүмәт составына кертелә. Гайса Йеникеев халык арасыннан күп кенә татар һәм башкорт җырлары җыючы буларак та билгеле.

...бер кыйкылдык каз ирер.— Вакытлы хөкүмәткә сайлаганда, бик күп вәгъдәләр биреп тә, гади халык өчен берни эшләмәгән Г. Йеникеевны шагыйрь шулай дип атый.

Айманов Йакуб — татар шагыйре; атаклы Кизләү авылы мәдрәсәсеннән (хәзерге Татарстан АССРның Октябрь районы) чыккан Сөләйманов (Кизләви) белән эпиграммадагы Якуб (Сөл) Аймановның бер үк кеше булуы ихтимал.

Көрси — «Аятель көрси» (тәхет турында аять) — Коръәндәге «Бәкара» (сыер) исемле икенче сүрәнең 256 нчы аяте. Анда, нигездә, алланың сыйфатлары санала: тере, белемле, аның тәхете җирдән дә, күктән дә киңрәк һ. б.

Зәбаный гөрзесе — тәмугта кешеләрне яндырып торучы газап фәрештәсенең җәзалау коралы.

Йосыф бай — Йосыф Дибердиев — Сембер бае, фабрикант.

...дөбердәт...— эпиграммада сүзнең Сембер бае хакында барганын шушы аваздашлыктан белеп була.

Буш калайның өстенә яңгыр шыбырдат...— «Милләт», «милләт» дип шапырынып та, халык өчен берни дә кыра алмаган Й. Дибердиев тәнкыйтьләнә.

Хәтимә.

Ел ярым уйнап кына эшләп...— Шагыйрь «Китабеннас» исемле бу эпиграммалар циклының төп өлешен ел ярым яза. Монда шуңа ишарә ителә (1916 ел башыннан 1917 ел ахырына кадәр).

Эреле-ваклы, башлы-башсыз булды куйган көлтәләр.— Баблар эчендә бирелгән эпиграммалар төрле характерда, төрле стильдә, төрле рухта килеп чыкты, төрле манерада язылды, димәкче була шагыйрь.

Көлтәләр барысы ике йөздән азрак арттылар.— Эпиграммаларның саны ике йөздән артып китте, ди шагыйрь.

Шәпләре вак көлтәләрнең бәлки гаебен яптылар.— Эпиграммаларда телгә алынган барлык шәхесләрнең дә кимчелекле ягын күреп бетермәвем мөмкин, дип аңларга кирәк.

Зәил.

Зәил — куштымта дигәнне белдерә.

Итмәдем инде мәху, дип: «Ул гафу кылсын, гафу!» — (мәху итмәдем — юкка чыгармадым) Ш. Бабич ахырга кадәр (1918—1919) «Китабеннас»та бирелгән бәяләрне хаклы дип санаган. Бу очракта да ул һичкайчан да үз бәяләреннән ваз кичмәячәген белдерә, тәнкыйть төшкән шәхесләрдән һич гафу үтенмәячәкмен, ди.

...бәлки, тарихка бик бөек хезмәт булыр. — Күрәзәче шагыйрь бу очракта да хаклы булып чыкты. Ул үзенең «Китабеннас»ында XX йөз башында һәм аннан да элгәрерәк яшәгән татар зыялыларына иҗтимагый-социаль, тарихи, әдәби яктан характеристика биреп чыкты. Бүгенге көн укучысы, чыннан да, XX йөз башы татар, башкорт, өлешчә казакъ әдәбияты, матбугаты, театр сәнгате, музыка, рәсем сәнгате, тарих һәм башка фәннәрнең торышын, иҗтимагый көрәш барышын Бабичның шушы эпиграммалар циклыннан өйрәнә.

Яңартылганнар *(286 бит).* — Бу циклга кергән эпиграммалар 1918 елның җәендә иҗат ителгәннәр. Анда, башлыча, алда инде бер тапкыр телгә алынган шәхесләр хакында сүз бара. «Яңартылганнар»ның язылу сәбәбен шагыйрь үзе түбәндәгечә аңлата («Бер изах» бүлеген кара):

Бәгъзе ашта пешмәгәнрәк эшләнгән кәтлитләрем,
Бәгъзе хаска гамь булыбрак төшмәгән тәнкыйтьләрем.

Шундый затларны яңартып, янадан яздым тагын,
Иске калды искечә, ачтым «Яңартылган» бабын.

Текст «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан (1922) алынды.

Муса — Петербург мулласы Муса Бигиев (1873—1949) — татар буржуа идеологларының берсе. Октябрь революциясеннән соң эмигрант. (441 биттәге аңлатманы кара.)

Пәрвәз остаз — Пәрвәзетдин Кәмалетдинов (Зыя Кәмали, 1878—1942) — Уфада яңа ысул «Галия» мәдрәсәсенең (1906—1917) мөдире, мәгърифәтче-педагог, китаплар авторы. Гражданнар сугышы чорында татар большевикларына ярдәм күрсәткән кеше.

...тәхрире ямьне җуя. — Зыя Кәмали «Фәлсәфә», «Дини тәдбир», «Фәлсәфи гыйбарәт» һ. б. шундый ислам философиясенә багышланган китаплар авторы буларак та билгеле. Ш. Бабич, күрәсең, остазның бу дини хезмәтләре белән килешмәгән. Тәхрире — язганы дигән сүз.

Риза хәзрәт — Ризаэтдин Фәхретдин улы Фәхретдинев (1859—1936) — әдип, журналист, галим, дин эшлеклесе, «Шура» журналының редакторы, соңыннан Уфада мөфти.

Садри Максуди — Садретдин Низаметдин улы Максудов (1879—1957) — татар буржуаз идеологларыннан берсе. I, II, Дәүләт думаларына депутат. Октябрь революциясеннән соң эмигрант.

Вак адәмнәр белән алдыңда һаман чүпне өерт!.. — 1917 елның 21 декабрендә булып үткән Милләт Мәҗлесендә (Уфа) Төрек-татар милли идарәсенең рәисе итеп Садри Максуди сайлана. (Бу хакта хәбәр: «Кояш», 1918 ел, 9 январь (1201) саны.) Аның тирәсенә Г. Баруди, Н. Корбангалиев, Ш. Алкин, Х. Акчурин, С. Җантурин, С. Мәмлиев, Г. Шонаси, Г. Исхакый кебек буржуаз интеллигенция вәкилләре — Бабич тарафыннан берничә тапкыр тәнкыйтьләнгән, фаш ителгән шәхесләр — тупланалар. Шагыйрь үз эпиграммасында шуларны күз уңында тота булса кирәк.

Осетин бак Салих — Әхмәтбәк Салихов — Кавказ пантюркисты, I, II Дәүләт думаларына депутат, «Ил» газетасының редакторы.

«Мимәгә өс, «җимәгә сәкен һәм «нон» — өтер («ну»), «нон» — сәкен. — Гарәп орфографиясе буенча, «м», «җ», «н», «н» хәрефләренә өс, сәкен, һәм өтер (хәрәкәләр) куеп язганда, «мәҗнүн» сүзе килеп чыга.

Гобәйдулла Газиз — Газиз Гобәйдуллин (1887—1938) — татарлардан тарих буенча беренче профессор, язучы, әдәбиятчы. (495 биттәге аңлатманы кара.)

Габдулла Газиз — Габдулла Газизов (Сакмари) — Троицкида укытучы, буржуаз публицист революциядән соң эмигрант.

Гаяз — Гаяз Гыйләҗетдин улы Исхаков (1871—1954) — билгеле татар язучысы, «Мөселман иттифакы» партиясенең актив әгъзасы, Мәскәүдә чыккан «Ил» газетасының редакторы. Октябрь революциясеннән соң эмигрант.

...Гаяз — зайагъ була... — Гаяз сүзен гарәп язуы буенча кирегә (уңнан сулга) укып карасаң — зайагъ була (ягъни, *зая* — әрәм).

«Әфәләм төрле» — юньсез-рәтсез, дип аңларга кирәк.

...«әфәләм төрле шагыйрь күп катың»... — юньсез-рәтсез язучыларны (шагыйрьләрне) бутагыз, катыгыз, дип аңларга кирәк. Бу очракта Бабич гомумән укымышлы, зыялы татар буржуаз интеллигенциясен күз уңында тота булса кирәк. Эпиграмма 1918 елның январь-февраль айларында, «Тупраклы мохтарият» буенча Милләт мәҗлесе барган чорда язылган. Бу вакытта Ш. Бабич «Тупраклы мохтарият»ка каршы чыгыш ясаган Гаяз Исхакыйга (кара: «Кояш», 1918 ел, 11 февраль (1215) саны) оппозициядә торган. Шагыйрьнең «Тупрак» исемле әсәре дә шул хакта сөйли. Үзе яклаган юлның дереслегенә ианып, шагыйрь Г. Исхакыйның эшчәнлеген әрәмгә үткән эш дип саный.

Фатих — күренекле татар язучысы, публицисты, журналисты Фатих Зариф улы Әмирхан (1886—1926) — бу хакта эпиграммадагы «... һәм әмир, һәм хан хәзер...» дигән сүзләр сөйли.

...мыскыл бабында... — Бабич бу урында «Китабеннас» бабларының ироник планда алып барылганлыгына ишарә итә.

Иркә мәхдум... — Монда Ф. Әмирханның рухани малае (мәхдүм) булуына ишарә ясалган.

Зариф Әмирхан — Казандагы дини хәрәкәт башында торган муллаларның берсе.

...багында күп чәчәк корган хәзер. — Язучының актив иҗат эшеннән туктавына ишарә ителә.

Әл-Кадир — сүз буржуаз милләтче журналист Закир Кадири (Уфа) хакында бара.

Эпиграмма «Кармак» журналының 1917 ел, 10—11—12 санында басылган «Сәфәр алдыннан» дигән сатирик язмадан алынган. Анда шулай ук эпиграмманы (ул, «Китабеннас»тагы башка эпиграммалардан аермалы буларак, «Кармак» журналында басылып килгән «Авыл җырларын»дагы куплетларны хәтерләтә) иҗат итүгә алып килгән сәбәпләр дә әйтелә.

Баттал — Габделбарый Баттал.

Муса — Муса Бигиев.

Гыйсмәти — Габдулла Төхвәтулла улы Гыйсмәти (1883—1938) — татар шагыйре, публицист-язучы, Октябрь революциясеннән соң партиянең һәм хөкүмәтнең җаваплы органнарында эшли.

Хәсләте — исламны хөрмәт... — табигате, холкы — исламны хөрмәт итү, дип аңларга кирәк. Шагыйрь монда Гыйсмәтинең аллага мөрәҗәгать итеп язылган пессимистик шигырьләрен күз уңында тота.

Гомәр — Гомәр Терегулов — Уфада земство эшлеклесе, буржуаз

журналист, публицист; татар буржуа идеологларының берсе. Октябрь революциясеннән соң колчакчы.

Инкыйлабта мөнкәлиб булган... — революциядә алмашынган, дип аңларга кирәк. Монда Г. Терегуловның революция чорында төрле матур лозунглар кычкырып йөреп тә, интервенция башлангач, Колчак ягына чыгып китүе хакында сүз бара.

«Без — шөкер, әлхәм дөлиллә, хак мөселман!» — ди Гомәр. — Бу юлларны «Кармак» журналының 1917 ел 10—11—12 санында (Бу санны баштанаяк Ш. Бабич үзе эшкәртә) да очратырга мөмкин. Менә Уфадан килгән бер хәбәрдән өзек (аны Бабичның үзе үк язуы мөмкин): «Әлимҗанчылар: Кызган баш кызган, без дигәнчә булмаса, айкыймыз-чайкыймыз!— диләр. Күкрәкләренә: «Халыкның 90% өлеше бездә, көч бездә! Революцияне без мәйданга китердек!»— мәзлумында, маңгайларына: «Җиргә социализация»!— дип язылган. Үмәрчеләр, бака боты белән сөйрәтеп, «Без хак мөселман!» дип язылган кара саплы яшел флаг күтәреп йөриләр. Кара сапны ак бияләй тотып тотканга күрә, ярлы халык та яңлышып барып керүчән...»

«Әлимҗанчылар» — «Туфраклы мохтарият» вәкилләре, сул эсерлар, «Ирек» (Уфа, 1917) газетасы тирәсенә тупланган Уфа прогрессив интеллигенциясе (Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Гафури, С. Сүнчәләй, И. Рәмиев һ. б.) күз уңында тотыла.

«Үмәрчеләр» — «Милли-мәдәни мохтарият» төзергә йөрүче буржуа-интеллигенция вәкилләре хакында сүз бара.

Биниәмин — Биниәмин Габдесәгуд улы Әхтәмев (Әхтәм мирза) — юрист, меньшевик, Вакытлы хөкүмәт эмиссары, 1917—1918 елларда Уфадагы Милләт мәҗлесе рәисе.

Биниәмин Әхтәмевкә багышланган эпиграммада да, аннан соң килүче Шәриф Манатовка багышланган юлларда да «Кояш» газетасының 1918 ел, 11 март (1223) санында басылган «Милләт мәҗлесе протесты» чагылыш тапкан булырга тиеш. Ул протест Казанга, «Идел-Урал штаты» рәисе Шәриф Манатовка җибәрелгән. Анда Манатов конференциядән тыш штат эшләрен хәл итүдә, штатның чикләрен үзе теләгәнчә билгеләүдә, карарлар кабул итүдә һ. б. гаепләнә. Ләмә астында имзалар: *«...1. Милләт мәҗлесе рәисе: Биниәмин Әхтәмев; 2. Төрек-татар һәм Себер штаты рәисе Садри Максудов.*

Уфа, 27 нче февраль, 1918 ел.»

Күрәсең, Ш. Бабич бу рәисләрнең (Б. Әхтәмев белән Ш. Манатов хакында сүз бара) берсе белән дә килешми, аларны эгоистлыкта, халык фикеренә игътибар бирмәүдә гаепли («Мин-я-мин... дип үз-үзенә тиң табалмый Биниәмин», «Мактауны куй, Манат, оч, оч, канат»).

Манат — Шәриф Әхмәтҗан улы Манатов (1892—1936) — Швейцариядә укып кайтып, актив революцион эш белән шөгыльләнгән журналист, педагог, җәмәгать эшлеклесе. Революция чорында «Идел-Урал штаты» рәисе, Милләтләр эше буенча Халык комиссариаты эшчесе, 1918 елдан Коммунистлар партиясе әгъзасы. Совет чорында күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе.

Рәхман — ?

Шәһид — Шәһид Гымадетдин улы Әхмәдиев (1888—1930) — язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның беренче мәгариф комиссары, 1917 елның мартыннан Коммунистлар партиясе әгъзасы. Эпиграмма язылган чорда большевистик «Аваз» (Казан, 1917—1918) газетасы редакторы.

Борһан Шәрәф — Борһан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1883—1942) — журналист, әдәбият тәнкыйтьчесе.

Баймбәт — Гыйлемдар Бәймбәтев — Уфада, Казанда, Мәскәүдә

һәм башка шәһәрләрдә тәрҗемәче һәм журналист булып йөргән бер татар зыялысы.

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧНЫКЫ БУЛУЫ ИХТИМАЛ ӘСӘРЛӘР

Сабиягә *(288 бит)*.— «Шура» журналының 1911 ел 15 санында «Шәйх-улла» имзасы белән басылган.

Иптәшем татар шәкертенә *(289 бит)*.— «Акмулла» журналының 1912 ел 18 санында (1 декабрь) «Кызыл каләм» имзасы белән басылган. Бу әсәрдә Ш. Бабич шигъриятенә хас поэтик алымнарны, сүзлек составын күрми мөмкин түгел. Аерым алганда, шагыйрьнең иҗатында бик популяр, фикерне көчәйтүгә корылган санау, кабатлау алымы монда да бар («Ялганла, иманың сат, вөҗданың сат...»). Бабич иҗатында еш күренәчәк «ап-ак йөз», «керле эч», «башыңа уйлар төшәр», «алтын түгеп» кебек сүзтезмәләр дә бу шигырьне Бабичка нисбәт итәргә мөмкинлек бирәләр. Өстәвенә Бабич иҗатының иң характерлы билгесе — ироник фикерләү дә монда бар инде.

Иптәшем, сиңа әйтәм — акча күп тап...— Шагыйрь монда үз биографиясен яза. Шәйх шәкерт тә («Галия» мәдрәсәсендә укыган Бабичны шәкертләр шулай дип йөрткәннәр) кыш көнендә мәдрәсәдә белем алу өчен җәен казакъ далаларында балалар укытып йөрергә тиеш була.

Ялганла, иманың сат, вөҗданың сат...— Шагыйрь язуынча, кайбер шәкертләр акча эшләүнең ансат юлын да табалар — төрле руханиларга куштанланып, аларның төрле кара эшләрендә катнашып, кышлык акча туплыйлар. Бабич монда әнә шундый шәкертләр хакында яза.

Хәзрәт вә хәлфәләргә өчәр сумлык бирдисең...— бу юллар татар мәдрәсәләрендә чәчәк аткан ришвәтчелек хакында.

Белсәң дә, дәресләрне белалмыйсың...— Ришвәт бирмәсәң, күпме генә яхшы укысаң да, алдынгы була алмассың, ди шагыйрь.

Юк *(290 бит)*.— «Акмулла» журналының 1913 ел 21 санында (1 гыйнварь) «Жен» имзасы белән басылган. «Мәшһүр шагыйрьләремезнең шигырьләренә тәкълид» циклында бирелгән бу шигырь Сәгыйть Рәмиевнең «Алданган» (1908) шигыренә ияреп язылган.

Әхмәтҗан — Казанда чыккан «Бәянел хак» буржуаз газетасының нашире һәм редакторы Әхмәтҗан Сәйдәшев (1840—1912) хакында сүз бара булса кирәк.

Кайда китәм? *(291 бит)*.— Ш. Бабичның ТАССРның Саба районы Тевеки авылында яшәгән Бибисара исемле апасы архивыннан алынды. (Карагыз: Гыйльманов Г. Шагыйрьнең билгесез әсәре.— «Җиңү байрагы» газетасы (Саба районы), 1987 ел, 11 август.) Танып булмау сәбәпле, соңгы ике юл төшерелде.

Авыл җырлары (Тукайга тәкълид —1) *(292 бит)*.— «Акмулла» журналының 1915 ел 48 санында (14 август) «Җырчы» имзасы белән басылган. Бу имза астында дөнья күргән «Авыл җырлары», Г. Тукайның шундый ук «җырлар»ына ияреп язылу белән бергә, сурәтләү объекты, поэтик алымнары, тел-стиле ягыннан Бабичның «Китабеннас»ына кергән кайбер эпиграммаларга авазаш. Өстәвенә «Җырчы» имзасын Бабич соңыннан да бер тапкыр кулланган. 1919 елның февраль аенда иҗат ителгән «Башкорт халкына көйле хитаб» әсәре дә шушы имза астында таралган.

«Йолдыз» күргән Һади абзыеңдыр...— Эпиграммада сүз «Йолдыз» газетасының редакторы Һади Максудов хакында бара.

Иҗтимагый карашларда Закир абзаң нишләтә.— Татар буржуа идеологларының берсе Закир Кадыйриның миллэтчел карашларына ишарә.

Күк кәҗәмә указ алам «Гыйният» абзаң сау булса.— Уфадагы Диния нәзарәтенең казые Гыйният Капкаев ришвәт бәрабәренә указ таратуы белән мәшһүр була. Бабич бу казыйның ришвәтчеллеге хакында «Китабеннас»ында бер язган иде инде.

Вәли мулла мөфти булыр, тамга җыя өч яклап.— Уфа бае, руханә Вәли Хәсәнов тә вафат булган Мөхәммәдьяр мәфти урынын алу өчен тавыш җыя башлый. Монда шуңа ишарә ителә.

Пич башыннан төшәлмиләр, мөфти булыр чаклары.— Чынлап та, кайбер эре руханилар (Гыйният казый, Вәли мулла, Сабир мулла һ. б.) бик карт булуларына да карамастан, мөфти сайлау кампаниясендә катнашалар. Бабич шуңа ишарә итеп яза.

Басып торган ботак сынгач, «Г. С.» төшите чалкаен...— Шушы имза астында вакытлы матбугатта шигырьләр бастырган автор хакында сүз бара (Габдулла Сөнгати булуы мөмкин). Бу имзага мөрәҗәгать итеп, шул чорда «Кармак» журналы редакциясе дә «Җавап» бастыра. Анда шундый юллар бар: «Г. С.» имзасы белән язучыга: никадәр яшеренергә тырышсаң да, булдыра алмыйсың...» («Кармак», 1915, 13 сан).

«Дингә мишәйт» — дөресе: «Дин вә мәгыйшәт».

«Кармак»чылар...— «Кармак» (Оренбург, 1915—1917) көлке журналында язышучылар дип аңларга кирәк.

Песи-күсе ник туладыр безә барасы «Ак юл»га? — Бу очракта шагыйрьне «Ак юл» (Казан) журналындагы төрле мәгънәсез имзалар борчый булса кирәк.

Авыл җырлары (Тукайга тәкълид —2) *(293 бит).*— «Акмулла» журналының 1915 ел 49 санында (5 октябрь) «Җырчы» имзасы белән басылган.

«Доносчы абзый... һәлак булды, милләт хәле төзәлә.— Бу юллар мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов вафатыннан соң язылган. Үзенең доносләры белән патша хөкүмәтенә «тугъры хезмәт иткән» бу кеше үлеменнән соң, инде артабан милләт үсешкә табан китәр, дип өметләнә шагыйрь.

...Мин дә мөфти булыр идем, дус-ишләрнең юклыгы...— Мөфти урынын алу өчен дус-ишлек, кода-кодагыйлык һәм кесә калынлыгы беренче урында тора, димәкче була шагыйрь.

«Гыйният» абзый озак тормас, аннан куштаннар да бар.— Мөфти булырга тиеш дип саналган Гыйният Капкаев хакында сүз бара. Әмма бу рухани барыбер дә кирәк кадәрле тавыш җыя алмый. Аның юлын тагын да куштанрак мулла — Сафа Баязидов бүлә.

Садри бай — Уфаның эре байларыннан берсе Садретдин Нәзирев хакында сүз бара.

«Мирзалар» — дворяннар дәрәҗәсендә йөрүче татар байлары.

Кул куйганга үкенәләр хәзер Уфа байлары.— Шагыйрь тагын мөфти сайлау вакыйгасына әйләнеп кайта. Ул, Петербург мулласы Сафа Баязидовны мөфти итү өчен кул куйган Уфа байлары хәзер килеп шуңа үкенәләр, димәкче була.

Ни торопись, Закир абзый! Запылати мең тәңкә! — Закир Кадыйриның мөфти сайлау кампаниясе өчен түләргә тиешле мең сум акчасы хакында сүз бара булса кирәк.

Сафсим мәшһүр булыр өчен «Әмирхан» да динләнә.— Дини руханиларның Казандагы юлбашчысына дәгъва итүче Зариф мулла Әмирханов хакында сүз бара булса кирәк.

Авыл җырлары —1 *(294 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 6 санында (15 март) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

«Рәшид казый» читтә йөри»...— либераль-буржуа журналисты һәм публицисты Габдрәшит Ибраһимов (1853—1944). Эпиграмма Г. Ибраһимовның Япониягә сәяхәте уңае белән язылган.

«Баттал» — Габделбарый Сәетбатталов (1873—1959) хакында сүз бара.

«Габди» — күренекле татар язучысы Галимҗан Ибраһимовның яшерен имзасы (псевдонимы).

«Дин мәгыйшәт» — дөресе: «Дин вә мәгыйшәт» — Оренбургта чыккан дини-клерикаль журнал.

...мидал биргән календарчы малайга.— Озак еллар буе Казанда «Заман календаре» чыгарып килгән Шәрәфетдин Шәһидуллин хакында сүз бара булса кирәк. Бу кеше үз календаре тышында күп кенә «Дин вә мәгыйшәт»челәрнең рәсемнәрен төшереп килгән.

Шагыйрь булып йөргән кеше чиновник та булгалый.— Бу юллар бер үк вакытта дәүләт оешмалырында да эшләп, шигырь дә язып йөргән татар шагыйрьләре хакында.

Мәңгәрләрнең йорты зәңгәр...— хәзерге ТАССРның Арча районына кергән Мәңгәр авылына атап чыгарылган халык җырыннан юллар.

«Урталык», «Хәят» — күренекле татар язучысы Фатих Әмирханның билгеле әсәрләре.

«Кояш» укып юатыйк...— Ф. Әмирхан Казанда чыгып килгән «Кояш» газетасында актив катнаша, үзенең үткен-үткен мәкаләләрен, фельетоннарын шунда бастыра. Бу хакта Ш. Бабичның «Китабеннас»ыннан да укырга була. (473 битттәге аңлатманы карагыз.)

«Ил»нең соек чыкканлыгы... — Гаяз Исхакый редакторлыгында Петербургта чыккан «Ил» газетасының (1913—1915) бетүгә табан йөз тотуына ишарә.

Авыл җырлары —2 *(295 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 7 санында (1 апрель) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

...мишәр теле димлиләр.— Шул елларда кайбер газета-журналларда күренгән мәкаләләргә ишарә.

Әстерханда ике учитель донос ясап уйныйлар.— Татар-рус мәктәбе мөгаллиме, цензор Исхак Искәндәрев хакында сүз бара. Аның доносчы булуы ачыклана.

Бер мөхәррир пилмән сата...— Эпиграммада сүз журналист Борһан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1883—1942) хакында бара булса кирәк. Озак еллар «Казан мөхбире», «Әхбар», «Вакыт» газеталары редакцияләрендә эшләп, «Шура», «Аң» журналларында актив язышкан бу кеше 1915 елда Оренбургта «Урал» исемле кунакханә ача. Бабич бу вакыйганы «Китабеннас»ында да билгеләп үткән иде (487 битттәге аңлатманы карагыз).

Бер Казанда, бер Мәскәүдә мескан «Шалт-шолт» гәүдәсе.— Монда «Ялт-йолт» журналы мөхәррирләре хакында сүз бара булса кирәк.

Гаяз хәлфә ялгыз башы...—1915 елда Гаяз Исхакый редакторлыгында чыгып килгән «Ил» газетасы туктый. Эпиграммада шул хакта сүз бара.

Мәрхүм Тукай җәмгыяте черт-иблис кайда була?..— Шагыйрь монда Г. Тукай вафатыннан соң төзелер дип көтелгән «Тукай җәмгыяте»нең һаман да тавыш бирә алмавына борчылып яза.

...бер «Ширкәт»тән...— В. Мортазин-Иманскийның 1915 елда оештырган «Ширкәт» исемле театр труппасы хакында сүз бара булса кирәк.

Авыл җырлары — 3 *(296 бит)*.— «Кармак» журналының 1915 ел 9 санында (1 май) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

«Сәйяр»дагы шәп артистлар әлә кая таралган.— Эпиграмма язылган чорда (1915 ел), чынлап та, «Сәйяр»дан берничә билгеле артист китә. Аерым алганда, үзенең труппасы белән. В. Мортазин-Иманский эшли башлый, Г. Волжская «Нур» труппасы оештыра.

«Вәкыйф» — татар шагыйре Вәкыйф Җәлал (1886—1922).

«Чыкылдаучы» — уничы еллар татар вакытлы матбугатында күренгәләгән билгесез шагыйрь имзасы.

«Ишми» — доносчы ишан Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев. (474 биттәге аңлатманы карагыз.)

«Мөпти» — Урта Азия һәм Себер мөселманнарының дин башлыгы мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов (1827—1915). Россия императоры фәрманы белән 1886 елда мөфти итеп расланган элекке прапорщик гомере буена патша хәзрәтләренә тугъры хезмәт итә, әмма мөселманнарның дин эшләрен, көнкүрешләрен рәткә салуда берни дә эшләми.

Авыл җырлары — 4 *(297 бит)*.— Кармак» журналының 1915 ел 89 санында (1 май) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

«Богослов»лар — козгын булса...— Рус диничеләренең «Богослов» журналына ишарә булуы мөмкин. «Дин-мәгыйшәтчеләр» тарафыннан Коръәнне тәрҗемә иткән өчен «Козгын» исеме алган руханиларга ишарә булуы да ихтимал.

Дәрдмәндкә нәрсә булды, нигә шигырь язмый соң?..— күренекле татар шагыйре Закир Рәмиевнең актив иҗат эшеннән тукталуына ишарә. Бабич бу хакта үзенең «Китабеннас»ында да әйткән иде. (481 биттәге аңлатманы карагыз.)

Харитонов татарларга хата Коръән тарата.— Харитонов нәшриятында басылган Коръәннәрдә хаталар булуга ишарә.

«Җомга кич кибет ябу»ны...— 1915 елда җомга көннәрендә кибетләрдә аракы сатылу тыела; монда шуңа ишарә.

Авыл җырлары —5 *(298 бит)*.— «Кармак» журналының 1915 ел 12 санында (15 июнь) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

«Коръән тәрҗемәсе» чыкмый...— Унынчы еллар башында яңа ысул укыту тарафдарлары — билгеле дин галимнәре — Муса Бигиев һәм Зыя Кәмали Коръәнне тәрҗемә итү эшенә керешәләр. Әмма аларның юлына реакцион «Дин вә мәгыйшәт»челәр каршы төшә. Алар 1912 елда үз журналларында Коръәнне тәрҗемә итүгә каршы кискен кампания башлыйлар. Казандагы «Өмид» матбагасында М. Бигиев тәрҗемәсендә Коръән басыла башлагач та, реакцион руханилар басымы астында бу эш ярты юлда тукталып кала. Эпиграммада шул вакыйгалар хакында сүз бара.

Җинаять абзый мөфти булса...— Бу юллар Мөхәммәдьяр мөфти үлгән һәм яңа мөфти сайлау көннәрендә язылган. Мөфти урынын дәгъва итүчеләр (тавыш җыючылар) арасында Уфадагы Диния нәзарәте казые Гыйният Капкаев та була.

«Кояш»та «Имгәк» мәхдум...— Эпиграммада сүз Казандагы «Кояш» газетасы белән якын мөнәсәбәттә торган, анда актив язышкан Фатих Әмирхан хакында бара булса кирәк. Язучы язышкан «Имгәк» псевдонимы да шуңа ишарә итә. Ф. Әмирхан бу имза белән үзенең аеруча усал, кискен фельетон-мәкаләләрен бастырган.

Шиһаб абзый ник эндәшми — «Мәктәп» чыкмаган өчен.— Монда

сүз 1913 елда чыга башлаган «Тәгълим-тәрбия» журналы һәм аның редакторы Шиһаб Әхмәров (1882—1966) хакында бара. Бабич «Китабеннас»та бу кеше хакында: «Әй Шиһаб, милләткә хезмәт «Мәктәб»ең белән вафат» дип язып чыккан иде. Шул рәвешле, 1914 елда чыгудан туктаган журнал язмышы белән Бабич һаман-һаман кызыксынып тора.

Гаяз абый, яз романнар, инде «Ил»ең туктагач...— Бу очракта шагыйрь «Ил»нең элекке редакторына иҗат эше белән шөгыльләнергә киңәш бирә. Ул бу киңәшне үзенең «Китабеннас»ында да әйткән иде.

Авыл җырлары — 6 *(299 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 14 санында (15 июль) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

«Мулла бабай», «Теләнче кыз»...— Гаяз Исхакый әсәрләре. Бу эпиграмманың икенче бер варианты «Китабеннас»та чагылыш тапкан. Анда Исхакыйның «Мулла бабай» һәм «Шәкерт» әсәрләре хакында сүз бара. (473 биттәге аңлатманы карагыз.)

Уфаны мәркәз ясау Закир хәлфә сагышы.— Баштарак «Галия»дә укытып йөргән, соңрак «Тормыш» газетасының редакторы Закир Кадыйриның милләтчел-шовинистик ниятләренә ишарә. Бу буржуа идеологының милли деспотик хисләре хакында Бабич «Китабеннас»та бер язып чыккан иде инде. (499 биттәге аңлатманы карагыз.)

Безнең «кәмитит» эшләре бигрәк әкрен әйләнә.— Эпиграммада сүз «Галия» мәдрәсәсе каршында оештырылган «Уфа шәкертләре комитеты» хакында бара. Бу «Комитет» вазифасына мәдрәсәләрнең җитәкчеләреннән уку-укыту эшләрен яхшыртуны таләп итү, яңа, дөньяви дәреслекләр кертүне сорау, уртак кичәләр, концертлар, очрашулар оештыру һ. б. эшләр кергән. Аның эшендә үз вакытында Ш. Бабич, Г. Нигъмәтиләр актив катнашканнар.

«ШК» хикәя язмый...— күренекле татар язучысы Шәриф Камал хакында сүз бара булса кирәк.

Кәрлә малай...— тарихчы, башкорт милли хәрәкәтенең юлбашчысы Зәки Вәлиди. (482 биттәге аңлатманы карагыз). «Кармак» журналының шул ук санында «Куркак» имзасы астында «Сәхәби бер мөәррих» исемле мәкалә басылган. Бу язманың да Ш. Бабичныкы булуы ихтимал. Чөнки монда да, «Авыл җырлары»нда да З. Вәлидинең «шәп мөәррих» булуы телгә алынган.

«Безнең көннәр» кайчан чыга?— Бу юллар Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы язылу тарихына алып китәләр. Эш шунда ки, романның ике табагы 1914 елда басылып чыккач, патша жандармериясе тарафыннан шунда ук конфискацияләнә. Әсәрнең ахырын укучылар күрми калалар. Шагыйрь монда шул хәлгә борчылып яза.

Авыл җырлары — 7 *(300 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 16 санында (15 август) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

«Таң» алдыннан «Ил» туктагач...— Шагыйрь тагын бер мәртәбә «Ил» газетасының аяныслы язмышына әйләнеп кайта.

Инде мөфтине сайлаулар Сафа үлугә кала.— Мөхәммәдьяр мөфтидән соң Уфага мөфти булып килгән Петербург мулласы Сафа Баязидов хакында сүз бара. Күрәсең, шагыйрь бу кандидатура белән риза түгел. Халык мәнфәгатен кайгыртучы мөфти сайлау мөмкинлеген ул бөтенләй дә шик астына ала.

Әхтәмев «Милләт» чыгара кәефе килгән чагында.— «Милләт» газетасының редакторы Биниәмин Әхтәмев хакында сүз бара. (473 биттәге аңлатманы карагыз.)

Муса абый «күзгын» булгач, тавыш-тыны бер дә юк...— Коръәнне

тәрҗемә итә башлаган Муса Бигиев реакцион динчеләрнең каршы кампаниясеннән соң тынып калды, димәкче була шагыйрь.

Карагруһ «Хур» газите туктар микән гомергә?..— Петербургта чыга торган «Нур» газетасының чыгудан туктавы унае белән язылган булса кирәк. Шагыйрь 1905 елдан чыга башлап, 1914 елда гына чыгудан туктаган бу газетаның яңадан чыга башлау мөмкинлеген күреп борчыла. «Нур» газетасының нашире Сафа Баязидовның Уфага мөфти булып килгән чагы бу.

«Аң» айда бер көчкә чыга...— Казанда чыгып килгән «Аң» газетасы һәм аның редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни хакында сүз бара.

Авыл җырлары — 8 *(301 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 17 санында (1 сентябрь) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

Мөхәммәдьяр мөфти үлде, Сафа мөфти бәхтенә.—1915 елда вафат булган Мөхәммәдьяр мөфти урынына Сафа Баязидовның мөфти булып килүе хакында сүз бара.

Уфадагы Сабир мулла ни дип нәфәкъ тарата? — Эпиграммада сүз Уфа кешесе Сабир мулла Хәсәнов хакында бара. Бу руханн, мөфти урынына сайлану өчен, юмартланып китеп, халыкка, мөритләренә күпләп акча, мал (нәфәкъ) таратса да, үз теләгенә ирешә алмаган.

Сентябрь числосы җиткәч, «мөнбер» төшә исемә.— Шагыйрь монда мәдрәсәдәге яна уку елына ишарә итә булса кирәк. (Бабич бу вакытта «Галия»дә укып йөри.)

Эш сөюче депутатны ходай насыйп итмәгән.— Шагыйрь монда Дума депутатларының эшсезлегеннән, булдыксызлыгыннан зарлана.

Тик «Таң» көтеп түзәбез...— якты киләчәк көтеп, дип аңларга кирәк.

Авыл җырлары —9 *(302 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 19—20 санында (15 октябрь) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

«Дингә мишәйт» — «Дин вә мәгыйшәт».

...соң заманда «миссионерлык» итәдер.— Монда шагыйрь «Дин вә мәгыйшәт» журналының ислам динен көчләп пропагандалавы, диндарлыгы хакында сөйли.

Сакла «Гыйффәт»не, ходаем, явызлар тырнагыннан.— Бу юллар «Китабеннас»тагы эпиграммага аваздаш янгырыйлар. (489 биттәге аңлатманы карагыз.) «Кармак» журналының шул ук санында Гыйффәт туташның йортын ташлап чыгуы хакында мәкалә бар (18 бит). Эпиграмма белән бу мәкалә арасында бәйләнеш булуы ихтимал.

Әстерхан халкы тап булды бер доносчы муллага.— ?

«Мөселман съезды» булуын... көтәм.— Эпиграмма Мөселманнарның I съездына әзерлек барган чорда язылган.

«Тазат сәләс» һөҗүме...— ?

Авыл җырлары —10 *(303 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 23 санында (1 декабрь) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

Сукыр шагыйрь — Троицкиның «Рәсүлия» исемле мәдрәсәсендә М. Гафури белән бергә укыган, соңыннан шигырьләр язгалаган сукыр шагыйрь Гобәй Кинҗин хакында сүз бара булса кирәк.

Вәкыф шулай була ул...— йөз мең сум вәкыф акчасын төрле вактәяккә туздырган «Җәмгыяте хәйрия» хакындагы бу юллар «Китабеннас»та да чагылыш тапкан иде.

Мәдрәсәгә солдат тулгач...— бу эпиграммада 1911 елда Ишми ишан доносы белән килгән кораллы отряд тарафыннан туздырылган Буби мәдрәсәсенең язмышы янара.

Уфа байлары...— дисез «Галия»не яптырып, яна «Галия» ачу хакында хыялланып йөргән бер төркем Уфа байлары хакында сүз бара (Сабирҗан Шәмигулов, Хәсән Кәримов, Бәдретдин һәм Садретдин Нәзиревләр, Мөхәммәд Алкин, Сәлимгәрәй Җантурин һ. б.).

«Галия»гә дигән акчаны «Галя»ларга иштәләр.— Яна ысул мәдрәсәләр өчен бирергә тиешле ул акчаларын Уфа байлары типтереп бетерәләр, димәкче була шагыйрь.

Авыл җырлары—II *(304 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 24 санында (15 декабрь) «Чәүкә» имзасы белән басылган.

«Вакыт», «Тормыш», гел сүгешеп, кемнең малын бүләләр?— Ике газета арасында була торган кайбер ызгыш-бәхәсләргә ишарә.

Депутатлар...— шагыйрь монда булдыксыз Дума депутатлары хакында сүз алып бара.

Епископ Андрей борды мөселманнар колагын.— Эпиграммадагы бу юллар 1910 елда Казан епископы Андрей белән Галиәсгар Камал арасында (бу вакытта ул «Йолдыз» газетасында эшли) булып алган бәхәскә ишарә итә булса кирәк.

XX йөз башында Казанда «Сотрудник братства святого Гурия» журналы чыга башлый. Журналда мөселманнар адресына шактый кимсетүле сүзләр әйтелә. Миссионерларның бу журналы татарлар тормышындагы һәр яңалыкны «иттихад ислам» (панисламизм) дигән шаукымга бәйләп аңлата, Г. Камал журналның әнә шул юнәлештәге эшчәнлеген тәнкыйть итеп чыга. Журнал әһелләренчә, дип яза ул, «мөселманнар тарафыннан кечкенә генә бер мәктәп ачылу — иттихад исламнан, төрекчә җөзьи генә бер китап нәшер ителсә — иттихад исламнан (...) Бонлар мөселманнардагы һәрбер тәрәккыятне (алга китешне), һәрбер уйганулы вә мәдәнияткә таба үрелүләрне иттихад исламга хитаб кылалар. Бонларча, мөселманнарның аз гына язу тануларын, аз гына фән вә мәдәнияттән хәбәрдар булулары — һәммәсе бик зур зарардыр» («Йолдыз», 1910 ел, 520 сан).

Г. Камалның бу мәкаләсе миссионерлар игътибарыннан читтә кала алмаган. Казан епископы Андрей бу уңайдан Г. Камалга җавап белән чыга һәм кыргыз, башкорт һ. б. халыкларга карата татарлар миссионерлык политикасы алып баралар, дигән гаеп ташлый. Без, ди Андрей, мөселман татарларга дус. Алар гадел, диндар, хезмәт сөючән һ. б. Ләкин ачыктан-ачык әйтәбез: татарлар чувашларны, мариларны, кыргыз, башкортларны татарлаштыралар («Сотрудник братства святого Гурия», Казань, 1910 г., с. 22—23). Епископ Андрей үзенең мәкаләсен «Йолдыз»да бастыруны таләп һәм «Йолдыз» моны тәрҗемә итеп тулысы белән баса. Әмма Г. Камал епископка тагын җавап белән чыга, татарлар арасында башка төрле халыкларга мөнәсәбәттә миссионерлыкның бөтенләй булмаганлыгын исбатлый. Кыргыз белән башкортка нәрсә тага алабыз без? — дип сорый. Без бит алар белән болай да тәрҗемәсез сөйләшәбез. «Миссионерлар мөселманнарның тәрәккыйләрен хөкүмәт өчен зур зарар итеп күрсәтергә тырышалар. Гүя алар фикеренчә, мөселманнар укыйлар һәм тәрәккый итәләр дә, бергәләшеп, хөкүмәткә, әллә нинди зарар китерәләр имеш. Мөселманнарның аңлы булуларыннан, мөселманнарның агаруыннан вә мәдәниятеннән хөкүмәткә файда гына хасыйл булачактыр» («Йолдыз», 1912, 798 сан).

«Ил»челәрнең «Сүз», «Тавыш»ы чыкмас икән гомергә.— Монда сүз 1915 елда туктап калган татар газеталары хакында бара.

Яшь «Кушмый»лар күренгәли...— «Галия» мәдрәсәсе тирәсендә барган скандал вакытында эре байларга куштанланып йөрүче кайбер татар зыялылары чын йөзләрен ачалар. Элгәрерәк алдынгы карашлы булган булып йөргән бер төркем татар мөгаллимнәре «Галия» тирә-

сендә барган вакыйгаларда кадим руханилар, Бабич әйткәнчә, Ишми ишаннар (шагыйрьләр аңа Кушмый дигән кушамат тагалар) ягында чыгыш ясыйлар. Шагыйрь монда әнә шул хәлгә борчылып яза.

Авыл җырлары —12 *(305 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 7 санында (1 апрель) «Чәукә» имзасы белән басылган.

«Йолдыз» «Сүз»не җиңалмады, куәте юк, курасең...— бу юллар «Кармак» журналының шул ук санында басылган (13 бит) «Мәгъҗүнче шәкерт вә ике батырлар» исемле хикәягә аваздаш булып яңгырый. Ул да «Йолдыз» белән «Сүз» газеталарының кычкырышы мөнәсәбәте илә язылган.

Муса абый, «Кара көч»кә ни дип башың сатасың? — Коръәнне тәрҗемә итеп тә, аны бастырып чыгара алмау белән килешергә мәҗбүр булган Муса Бигиев хакында сүз бара булса кирәк.

«Ислам-мәгариф» — дини журнал.

Татарлар арасында *(305 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 21—22 санында (15 ноябрь) «Сак» имзасы белән басылган.

Фәтүәсе һәм фәтүәчесе *(306 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 18 санында (15 сентябрь) «Сак» имзасы белән басылган.

Мин *(307 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 21—22 санында (15 ноябрь) «Сак» имзасы белән басылган.

Таң вакыты (Сәгыйд Рәмиевкә тәкълид) *(308 бит).*— «Кармак» журналының 1915 ел 16 санында (15 август) «Чәукә» имзасы белән басылган. Бу шигырь күренекле татар шагыйре Сәгыйть Рәмиевнең «Таң вакыты» әсәренә ияреп язылган.

* * *

Җыентыкка Ш. Бабичныкы булуы ихтимал барлык әсәрләрне дә урнаштыру мөмкин булмады. Аерым алганда, тел-стиле, образлар дөньясы, поэтик алымнары белән Ш. Бабич әсәрләренә тартым мондый әсәрләр «Кармак» журналында 1915—1917 елларда «Тәләкә», «Гашыйк», «Йәкәнче» һ. б. имзалар астында басылганнар.

Бу җыентыкка шулай ук «Сак», «Җен» имзасы белән бирелгән барлык әсәрләр дә кермәде.

ХИКӘЯЛӘР, МӘКАЛӘЛӘР, ФЕЛЬЕТОННАР

Әйтеп узыйм *(311 бит).*— Шагыйрьнең, 1912 елда төзеп, басмага әзерләгән кульязма «Шигырьләр җыентыгы»на кереш сүз рәвешендә язылган. (417 битгәге искәрмәне карагыз.)

...шагыйрь Габдулла әфәнде — Габдулла Тукай.

«Халык әдәбияты»— Г. Тукайның 1910 елда китап булып басылган лекциясе (Казан, «Сабак» көтепханәсе, И. Н. Харитонов матбагасы). Шагыйрь аны шул елның 8 апрелендә «Шәрекъ клубы»нда укыган.

Ишми сөенә *(313 бит).*— «Акмулла» журналының 1913 ел 23 санында (21 февраль) «Бәбәйчүб» имзасы белән басылган.

Ишми — карагруһчы ишан Ишми Динмөхәммәтев хакында сүз бара.

Муса, Зыя, Риза, Фатихлар...— Муса Бигиев, Зыя Кәмали, Риза Фәхретдинев, Фатих Кәримиләр.

«Дин мәгыйшәт» — «Дин вә мәгыйшәт» журналы.

Доносым «Буби мәдрәсәсе»нең төбенә җиткән иде.— Иж-Буби мәдрәсәсе тирәсендә барган мәгълүм скандалларга ишарә.

...бәддогам «Галия» мәдрәсәсенә дә тиде.—1912 елда «Галия» мәдрәсәсендә булып алган шәкертләр кузгалышына ишарә. Мәдрәсәдәге укыту дәресләренә һәм укыту тәртипләренә протест йөзеннән илледән артык шәкерт «Галия» мәдрәсәсен ташлап чыга.

Мәкальләр фәлсәфәсе (1) *(314 бит).*— «Акмулла» журналының 1913 ел 30 санында (октябрь) «Бәбәйчүб» имзасы белән басылган.

Мәкальләр фәлсәфәсе (2) *(316 бит).*— «Акмулла» журналының 1913 ел 31 санында (18 ноябрь) «Бәбәйчүб» имзасы белән басылган.

Вәгыйз — Мөхәммәт Вәгыйз Нәүрузи — буржуа журналисты, пантюркист, охранка агенты. Октябрьдән соң Колчак армиясе офицеры, аклар газетасы редакторы.

«Тәрҗеман»—1903—1918 елларда Бакчасарайда чыгып килгән газета (редакторы — И. Гаспринский (1851—1914).

Фәттах — Фәттах Латыйпов (1884—1968)— Октябрь революциясенә кадәр үк татар сәхнәләрендә җырчы булып танылган һәм көйләр иҗат иткән. Гражданнар сугышы чорында Кызыл Армия бүлекчәләрендә концертлар куеп йөри. 1920 еллардан соң Урта Азиядә яши.

Әгәр дә мин булсам (Хыялларым) *(318 бит).*— «Акмулла» журналының 1914 ел 36 санында (20 апрель) «Бәбәйчүб» имзасы белән басылган.

«Сөембикә»—1913—1918 елларда Казанда хатын-кызлар өчен чыккан журнал (нашире һәм редакторы Ягъкуб Хәлили).

...ир затларын этләремнән өстерәп качырыр идем.— Татар хатын-кызларының бердәнбер журналы булган «Сөембикә»не сырып алган ир-мөхәррирләргә ишарә.

Уфа тигезсезлекләре *(319 бит).*— «Кармак» журналының 1917 ел 5—6 санында (15 март) «Казалы казасы» имзасы белән басылган.

«Кисекбаш» тәгәрәгән шикелле...— Г. Тукайның мәгълүм «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» (1908) әсәренә ишарә.

«Тигезсезләр» — Фатих Әмирхан драмасы (1915).

«Каргалы», «Гимназист» — иясе билгесез сәхнә псевдонимнары.

«Себектегин»— С. Рәмиевнең сәхнә псевдонимы.

Мотыйгый — Мотыйгый Камил (Төхфәтуллин, 1883—1940), журналист, җырчы.

«Мәдрәсәи Галия»нең унъеллык бәйрәме *(321 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 8—9 санында (1 май) «Шөбшә» имзасы белән басылган.

«Мәдрәсәи Галия» — Уфада 1906 елда ачылган җәдит (яңа ысул белән укытучы) мәдрәсә. Гадәттә «Галия» дип кенә аталып йөртелгән.

Исрафил галиәссәлам — ислам дине өйрәтүенчә, ахырзаман җиткәнне белдереп, Исрафил исемле фәрештә сур өрә (быргы кычкырта), шуннан соң дөнья бетә, имеш.

Лотфулла Байчурин — «Галия» мәдрәсәсенең беренче хәлфәләреннән.

«Галия» шул 10 ел эчендә...— Мәдрәсәнең нигез салынуына 10 ел тулуга ишарә.

«Галия» 9 нчы елга килде дигәндә...—1915 елгы вакыйгалар хакында сүз бара.

Уфа байларының байкоты...— «Галия» мәдрәсәсе Уфа байлары акчасына төзелә һәм яши. Мәсәлән, Сәлимгәрәй Җантурин «Галия»гә нигез салган чорда 30 мең акча бирә. Мәдрәсәгә шулай ук Мәхмүд Алкин, Садретдин Нәзирев, Сабирҗан Шәмигулов, Хәсән Кәримов, Бәдретдин Нәзирев кебек эре байлар да даими ярдәм күрсәтеп киләләр. Әмма 1915 елда, Зыя Кәмалиның укыту алымнары, программасы белән килешмичә, «Галия»не таркатырга, аны кабаттан башка урында, башка бинада оештыруны таләп итәләр. Мәдрәсә идарәсе каршы килгәч, байлар байкот белдерәләр, ярдәм итүдән туктыйлар...

«Галия» корабы милләт кулына кала.— Мәдрәсәнең тормышы, язмышы гади халыктан җыйган иганәләргә бәйләнгән, димәкче була шагыйрь.

...утыз миллион татар...— Монда бөтен Россия төрки дөньясы («Татар диңгезе») күз уңында тотыла.

...корабның 2—3 капитаны пущай китә бирсен.— Уфа байлары басымы астында «Галия» мәдрәсәсен бер төркем мөгаллим дә ташлап чыга (Зәки Вәлиди, Габдулла Шонаси һ. б.).

«Госмания»гә барып та керделәр.— Бу мөгаллимнәр «Госмания» мәдрәсәсендә укыта башладылар, ди шагыйрь.

Зыя белән Закир...— «Галия» тирәсендә купкан бу ызгыш татар зыялыларын ике лагерьга бүлә. «Галияче»ләр Зыя Кәмали тирәсенә, «Госманияче»ләр Закир Кадири тирәсенә тупланалар.

...Зыяның вә шәкертләрнең диненә кагыласыз.— «Галия» мәдрәсәсенең идарәсен һәм укыту программасын дингә реформа ясауда гаепләүче кадим руханиларга ишарә.

«Дин вә мәгыйшәт» сөенә— дини-клерикаль «Дин вә мәгыйшәт» журналында Уфа байларының байкотын «тәүфыйкка кайту» дип хуплап язып чыгалар.

Пәрвәз— Зыя Кәмалиның икенче исеме Пәрвәзетдин.

Мәкәрҗә—XVI гасырның урталарында Идел буендагы Макарьев монастыре янында барлыкка килгән Мәкәрҗә ярминкәсе. 1849 елдан Нижний Новгородка күчерелгән. Ел саен 15 июльдән алып 25 августка кадәр бара.

...быел Галимҗан Ибраһимовның керүе—1915 елның көзеннән Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбияты укыта башлый.

Һади абзый— Һади Максуди.

«Йолдыз»—1906—1918 елларда Һади Максуди редакторлыгында һәм наширлегендә Казанда чыккан газета.

«Сүз»—1915—1916 елларда Мәскәүдә чыккан газета.

Вәсимләр-фәләнләр...— Вәсим Солтанов хакында сүз бара булса кирәк.

25 июньләрендә бәйрәм булсын.— Бабич билгеләгән көндә юбилей бәйрәме булмый кала. Ул 26—27 декабрьдә Уфа шәһәрендә уздырыла. Юбилей тантанасыннан җентекле репортаж «Кояш» газетасының 1917 ел 12 январь санында дөнья күрә («Мәдрәсәи Галия юбилейсе»). Тантанада Ш. Бабич мәкаләсендә телгә алган байкотчы байлардан Садретдин Нәзирев кенә катнаша. Юбилей көннәрендә мәдрәсә файдасына ике мең сум иганә акча җыела. Россиянең башка шәһәрләрендә дә «Галия»гә ярдәм күрсәтү эшен башкаручы комитетлар төзергә карар кылына. Бу махсус комитетларның рәисе итеп Гыйбадулла Госманов билгеләнә.

1917 елның апрель аенда «Галия» һәм «Госмания» мәдрәсәләрен берләштерү мәсьәләсен карау өчен Уфада зур мәҗлес җыела. 70 ләп кеше җыелган бу мәҗлестә күпчелек, ике мәдрәсәне кушарга кирәк,

дигән фикергә килә. Шул исәптән Г. Ибраһимов та «Галия»не «Госмания»гә кушуны яклый һәм мөгаллимнәр өчен көрәшнең киләчәктә әлеге мәдрәсәләрнең таркалуына китерәчәген дәлилли. Кушылачак мәдрәсәләргә Сабирҗан Шәмигулов 10 мең сум акча вәгъдә итә. Ике мәдрәсә язмышын өзеп кенә хәл кылу киләсе җыелышка калдырыла.

...педагог Шонаси — Габдулла Шонаси. Ш. Бабичның «Галия»дәге химия укытучысы. Уфа байларының 1915 елгы мәгълүм байкотыннан соң ул «Госмания» мәдрәсәсенә күчә. 1917 елның җәендә-көзендә Милли идарә активистларының берсе.

Милли идарә — 1917 елның 20 ноябреннән 1918 елның 11 февраленә кадәр Уфада Милләт мәҗлесе эшли. Мәҗлес Идел-Урал штатлары төзелүен игълан итә һәм Милли идарә сайлый.

Закир — «Тормыш» газетасы редакторы Закир Кадири (1873—?).

Баттал — тәнкыйтьче Габделбарый Баттал (1874—1959).

Хәлим Искәндәрев — тәнкыйтьче, педагог Хәлим Искәндәрев (1888—1937).

Шаһид Әхмәдиев — публицист, җәмәгать эшлеклесе Шәһид Әхмәдиев (1888—1930).

Мәҗид — шагыйрь Мәҗит Гафури (1880—1934).

Төрле хәбәрләр *(325 бит).* — «Кармак» журналының 1916 ел 8—9 санында (1 май) «Казалы казасы» имзасы белән басылган.

Аксаков бабай исеменә ачылган библиотеканың почмагына шөгъбә ачканнар... — Уфада 1915 елда Аксаков исемендәге китапханәдә ачылган татар әдәбияты һәм матбугаты бүлеге хакында сүз бара. Бүлек мөдире — шагыйрь С. Сүнчәләй.

аерым бер цензор бар шикелле... — С. Сүнчәләй хакында сүз бара. С. Кудаш шундый истәлек китерә: «Бервакыт «Галия»дә язгы имтиханнар барган көннәрдә «Кармак» журналының бер номерында Бабичның С. Сүнчәләй шигырьләренә язган ике пародиясе басылып килде. Бабич, журналда үзенең пародияләре басылып килгәнлеген белү белән:

— Әйдә, һавада йөреп кайтабыз. Шәһәр китапханәсенә кереп чыгарбыз,— диде (...)

— Әгәр дә «Кармак»ның бүген килгән номерын да шулай җәрәхәтләп бетерсә, мин аны журнал редакциясенә язып җибәрәм,— диде Бабич китапханәгә барган чакта.

Китапханәдә Сүнчәләй үзе юк иде. Уку залының өстәлендә яткан «Кармак» журналының пародияләр басылган битләре, нәкъ Бабич әйткәнчә, кара каләм белән, әдәпсез һәм тыйнаксыз балалар кебек итеп, сызгалап бетергәннәр иде. Каләмне бик каты басып ачу белән сызу аркасында бер бите хәтта ертылып чыккан иде. Бабич каләмен алды да журналның ертык битенең читенә: «Журналны болай мәсхәрәләп пычратып бетергән кеше үзе ахмак!» дип язып куйды.

Бу хакта Бабич шул көнне үк «Кармак» редакциясенә хат язды. Соңыннан аның бу хәбәре «Кармак»ның 8—9 номерында басылып чыкты. (Карагыз: С э й ф и К у д а ш. Хәтердә калган минутлар. Казан, 1959, 61—62 битләр.)

«Көлке капчыгы» җыентыгына сүз башы *(326 бит).* — Ш. Бабич тарафыннан төзелеп, 1916 елда Уфада «Тормыш» матбагасында басылган җыентыктан («Көлке капчыгы» (Әдәбият кичәләре шәрәфенә) алынды.

Мөташаббиһат *(327 бит).* — «Кармак» журналының 1916 ел 10—11 санында (1 июнь) «Шөбшә» имзасы белән басылган.

«Сүз» — газета (1915—1916, Мәскәү).

«Йолдыз» — газета (1906—1918, Казан).

«Шура» — журнал (1908—1918, Оренбург).

«Акмулла» — журнал (Троицк, 1911—1916).

«Акмулла» бер дә чыкмый.—1915—1916 елларда «Акмулла» журналы даими чыкмый. Бабич шуңа төрттереп яза.

...бер-берсенә эобани чукмары күтәрү...— ике газета арасында барган бәхәсләргә, ызгышларга ишарә.

«Дин мәгыйшәт»— дини-клерикаль «Дин вә мәгыйшәт» журналы.

«Мәгълумат» — «Мәгълумате шәргыя Оренбургия». «Диния нәзарәте» чыгарган дини журнал. Ул, Уфада гарәп шрифтле рәтле типография булмау сәбәпле, башта Оренбургта басыла. Чыккан еллары: 1908—1911; 1916. 1917 елның 10 октябреннән бу журнал урынына Милли идарә «Мохтәрият» исемле журнал чыгара башлый.

«Вакыт»—1906—1918 елларда Оренбургта Фатих Кәрими редакторлыгында чыккан газета.

«Тормыш»—1913 елның 18 октябреннән 1918 елның 29 апреленә кадәр Уфада Гыйбадулла Госманов акчасына яшәгән газета. Редакторлары — башта А. Нәүрузов, соңрак З. Кадири.

«Кояш»—1912 елның 10 декабреннән алып 1918 елның 14 январена кадәр Казанда чыккан либераль-буржуаз газета.

«Кармак»—1914—1917 елларда Оренбургта Мәхмүт Мәрҗани (Мәхмүт Галәү) редакторлыгында чыккан демократик юнәлештәге сатирик журнал.

«Казакъ» —1913 елның февраленнән 1918 ел башына кадәр Оренбургта чыккан казакъча газета.

«Гыйлем әл-җәбер», «Әл-мәкабилә» — алгебра, математика дәреслекләре.

Муса Бигиев — Муса Бигиев (1873—1949), татар буржуа идеологларының берсе.

...милләт... Муса хәлен тикшерү белән мәшгуль.— Коръән тикшерүдә, Коръән тәрҗемә итүдә карагруһчы динчеләр тарафыннан гаепләнеп йөргән чагы.

«Ялт-Йолт» —1910—1918 елларда Казанда чыккан демократик юнәлештәге рәсемле сатирик журнал.

«Аң» —1912 елның 15 декабреннән алып 1918 елның мартына кадәр Казанда чыккан әдәби, иҗтимагый-политик журнал.

«Сөембикә» — 522 биттәге искәрмәне карагыз.

Уфа кызыклары *(330 бит)*.— «Кармак» журналының 1916 ел 10—11 санында (1 июнь) «Шөбшә» имзасы белән басылган. 1985 елда «Агизел» (Уфа) журналының 1 санында дөнья күргән.

«Тормыш» — газета.

Рәмиев... эреде дә китте...— Бу алымны соңрак Ш. Бабич үзенең «Китабеннас»ында куллана: «Ул Рәми эри тәмам, «исме Сәгыйть» эрмәк, диеп...»

«Як-ягын дәүләт алган да, хәзер нинди тәмле йоклый ул!»— Бу шигырь С. Рәмиевнең «Ул йоклый» әсәреннән («Аң», 1916 ел, 29 февраль саны) үзгәртелеп алынган. Дөресе: «Дәүләт алган як-ягымны: Нинди ямьле йоклый ул». Бу юллар татар шигъриятенә канатлы сүз, хәтта бөтен бер мотив булып кереп кала. Мәсәлән, «Аң»да «Ул йоклый» шигыре чыккач, шагыйрь Габдрахман Сөнгати (1893—1917) шул ук журналның 1916 ел 7 санында «Ул уянсын (Сәгыйть Рәмиевкә)» дигән шигырен бастыра, шагыйрьне актив иҗатка өнди.

«Әлмансур», «Баб-әл-сәмаә» — С. Сүнчәләй әсәрләре.

«Котормыш» — «Тормыш» газетасы.

...кызыл гына Фатих — алдынгы гына карашлы Фатих Сәйфи-Казанлы, димәкче була шагыйрь.

«Мәлгунат»ка кереп карайды...—1908—1911, 1916—1917 елларда Уфада-Оренбургта чыккан «Мәгълүмат» журналы хакында сүз бара. 1916 елда Ф. Сәйфи-Казанлы шул журнал редакциясендә җаваплы секретарь булып эшли башлый.

...биш билле Гайнетдин —?

Печән базары — иске Казанда (хәзерге Киров һәм Париж Коммунасы урамнары чатында) шәһәр базары. Кадимчеләр, гайбәтчеләр оясы буларак мәшһүр.

дәмелла Әхмәтҗан — Әхмәтҗан Сәйдәшев (?).

Әхмәд әфәнде —?

Кариев — Габдулла Кариев.

«Нур» —1912 елда Уфада Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская тарафыннан оештырылган һәм 1913—1915 елларда Оренбургта, 1916—1918 елларда Уфада эшләгән театр труппасы.

Кәбир Бәкер — журналист, әдәбият һәм театр тәнкыйтьчесе, педагог Кәбир Бәкер (1880—1941).

Казанский... Шәмигулов магазиныннан җитешкән.— Баштарак Сабирҗан бай Шәмигулов кибетләрендә приказчик булып йөргән, соңрак артист булып киткән Гыйләҗ Казанский хакында сүз бара.

«Галия», «Госмания» — Уфадагы мәдрәсәләр.

Җинаять — Диния нәзарәтендә казый булып торган Гыйният Капкаев хакында сүз бара.

«Түгәрәк» — «Тәбарәк» сурәсенә ишарә (Имин булу). Коръәннең 67 нче сурәсе. Анда алланың чиксез көчкә ия булуы турында сөйләнә.

...Военное время!— Беренче бөтендөнья сугышына ишарә.

100 әр меңләп, 50 шәр меңләп, 20 шәр меңләп коя башлаулары...— «Икенче Галия» мәдрәсәсен салу өчен Уфа байлары тарафыннан вәгъдә ителгән акчалар хакында сүз бара булса кирәк.

Карун — дини-мифологик зат, саранлыгы белән дан казанган. Ул шәригать законы буенча тиешле зәкятне түләмәгәне өчен җиргә убылып һәлак булган, имеш.

Имза карагы *(334 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел санында «Шөбшә» имзасы белән басылган.

«Гафет»— билгесез язучының псевдонимы.

«Сөембикә»нең әллә кем Фатыймалары.— «Сөембикә» журналында язышкан шагыйрә Фатыйма Гайнуллина һәм Фатыйма Хабуловалар хакында сүз бара булса кирәк.

«Сүзче»ләр — «Сүз» газетасы тарафдарлары.

«Кигәвен» — Оренбург журналисты Мәхмүт Бөдәйлинең псевдонимы.

«Мөскит» —?

Уфадан *(335 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 6—5 санында (15 март) «Шөбшә» имзасы белән басылган.

3—4 мәгарә бар.— Шагыйрь, Уфада өч-дүрт мәдрәсә, уку йорты бар, димәкче була.

«җанлы курчак»— бу канатлы сүз Кәбир Бәкернең «Җанлы курчаклар» хикәясеннән кереп калган. Г. Ибраһимов «Йолдыз» газетасының 1912 ел 12 январь санында аңа югары бәя бирә.

Г. Сөнгати — шагыйрь Габдрахман Сөнгати (1893—1917).

Мирзә — татарларда дворянлык титулы.

Уфа сәхнәсендән *(338 бит).*— «Кармак» журналының 1916 ел 19—20 санында (1 ноябрь) «Шөбшә» имзасы белән басылган.

Гомәр Терегулов — земство эшчесе, татар буржуа идеологларының берсе, Октябрьдән соң колчакчы.

баш мөхәррир — «Тормыш» газетасы редакторы З. Кадыри.

Зөһрә һәм Фатыйма Әхмәтовалар — Уфадан һәвәскәр группа артистлары.

Рөкыя туташ Терегулова — Гомәр Терегуловның сеңлесе.

«Фәтхулла хәзрәт» — Фатих Әмирхан әсәре.

Әхтәмов — ?

«Җәмгыяте хәйрия» — татарлар күп яшәгән кайбер шәһәрләрдә байлар, сәүдәгәрләр, интеллигенция тарафыннан мәдрәсә-мәчетләрне карау, шәкертләрне укыту, халыкны кайгырту өчен төзелгән оешма. Андый оешма Уфада да булган.

Җәгъфәр Садыйк — ?

Язу *(341 бит).* — «Кармак» журналының 1916 ел 22—23 санында (1 декабрь) «Шөбшә» имзасы белән басылган.

тәҗвидләр, симияләр, кимияләр... — татар мәдрәсәләрендә укытылган фәннәр.

Зариф әл-Кимери — шагыйрь Зариф Бәшири (1888—1962).

Рәмиевнең «Уку» назыйны — С. Рәмиевнең «Уку» шигыре (1907) хакында сүз бара.

Чыңгыз — монгол ханы Чыңгыз (1155—1227).

Риза казый — әдип, тарихчы галим Ризаэтдин Фәхретдинев 1859—1936), Диния нәзарәтендә казый булып тора.

Коръән кәрим, Инҗил шәриф, Тәүрат, Забур — Мөхәммәт, Давыт, Юныс, Гайса пәйгамбәрләргә нисбәт ителгән дини китаплар.

Гаязлар: «Татарга ике йөз ел инкыйраз», — дип «их-әлләһи кычкырсыннар...» — Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902) әсәренә ишарә.

Истә дә юк иске чикмән *(344 бит).* — «Әкият» дип тәкъдим ителгән бу әсәр «Кармак» журналының 1916 ел 16—17 санында (1 сентябрь) «Башкорд» имзасы белән басылган. «Агизел» журналының 1985 ел 1 санында кабат дөнья күргән.

«Вакыт» — газета.

«Сүз»чән булдылар... — «Сүз» газетасына ишарә.

Зыя — дин философы, мәгърифәтче Зыя Камали (Җәмалетдинов Пәрвәзетдин).

Муса — дин философы Муса Бигиев (1873—1949).

Шакир — алтынчы-миллионер, нашир Шакир Рәмиев (1857—1912).

Закир — журналист, дин белгече Закир Кадыри.

Садри — татар буржуа идеологы Садри Максуди (1875—1945).

Һади — журналист, педагог Һади Максуди (1868—1941).

«Кояш», «Вакыт», «Акмулла», «Кармак», «Тормыш», «Аң», «Таң» — киң билгеле татар газета-журналлары.

Гайникамал Миңлезифа — ?

...ачтылар «Вазифа» — Уфа шәһәрендә ачылган мәдрәсә хакында сүз бара.

Ишан үлгәч *(346 бит).* — «Кармак» журналының 1916 ел 5—6 санында (апрель) «Шәрран-яра» имзасы белән басылган.

Һаммас ишан — Троицк ишаны Зәйнулла Рәсүлев (1830—1917) хакында сүз бара.

Такырҗан әл-Хәсәни — Уфа мулласы Сабирҗан Хәсәни. Бу кушамат Г. Тукай иҗатыннан килә.

Ишми куштан — Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев, Ишми ишан (1839—1919).

Мулла Галим Җаушев — Троицк миллионеры.

Такырҗан ихсан — Сабирҗан Хәсәни.

Уфаның шпион мулласы — Сабирҗан Хәсәни.
«Г. С.» хәлфә — ?
Мәхдүм — Габдрахман Рәсүли.
Сөләйман йөзеге — борынгы бай яһүд патшасы — Даут пәйгамбәрнең улы Сөләйман (Соломон, безнең эрага кадәр 965—928 елларда патшалык итә) суларны, җирләрне үзе теләгәнчә йөртә, үз файдасына җигә ала торган куәткә ия булган, шул сәбәпле бик нык баеган, имеш.
Газраил — дини мифологиядә җан алучы фәрештә.
Шәйх Бисатам, Хуҗа Баһаветдин, Хәсән Басрый — әүлияләр, дини легенда геройлары.
Кемдер бирәү — Монда сүз Ш. Бабичның «Кармак» журналында басылып килгән «Китабеннас» әсәре хакында бара. Әш шунда ки, шагыйрь «Китабеннас»ны «Шөбшә» имзасы белән, «Ишан үлгәч» әсәрен «Шәрран-яра» псевдонимы белән тәкъдим итә һәм бу әсәрләрнең бер үк авторныкы булуын юри сиздерми.

Уфа хәбәрләренең мөндәриҗәсе *(357 бит)* — «Кармак» журналының 1917 ел 4 санында (15 февраль) «Шәрран-яра» имзасы белән басылган.
Самад — журналист Самад Шәрәфетдинов (1888—1937).
Госманов — Гыйбадулла Госманов.
Закир — «Тормыш» газетасының редакторы Закир Кадири.
Гомдә — Гомдә Хәбиров, «Тормыш» газетасының секретаре.
Әл-Кадири — Закир Кадири.
Гыйбадулланың ыгы-зыгысы — Уфа кешесе Гыйбадулла Госманов хакында сүз бара булса кирәк.
«Тормыш» конторщигының кусәк астында каләмнәрен биетүе — «Шәрекъ» матбагасында, «Тормыш» газетасы редакциясендә эшләүчеләрнең хуҗалар сүзеннән чыкмыйча, хокуксыз яшәүләренә ишарә.
Җамалетдин — шагыйрь Җамаледин Юмаев (1892—1940); бу чорда «Тормыш» газетасында корректор булып эшли.
«Госмания» — Уфада XIX йөз ахырларында ачылып, XX йөз башында зур мәдрәсәләрнең берсенә әверелә. Мәдрәсәне оештыручы һәм аның имамы — Хәйрулла Госманов (1848—1907).
«Галия» юбилее көнендә «Тормыш» мөхәрриренең авылга качуы. — Бабич монда «Галия» мәдрәсәсенең 1916 елның 26—27 декабрендә Уфада узган 10 еллык юбилее алдыннан кинәт кенә авылга кайтып киткән Закир Кадиригә төрттереп яза.
Юбилей мәҗлесендә Сабир һәм Җиһангир муллаларның буылып утырулары. — Монда сүз Уфа муллалары Сабирҗан Хәсәни һәм Җиһангир Абызгилдин хакында бара.
«Максад асылы»сы мөдире — «Галия» мәдрәсәсе мөдире дип аңларга кирәк.
«Милләт» китапханәсенең... саргаеп кибүе — «Милләт» (Казан) матбагасы хакында сүз бара.
«Чулпан»ның сусыз җирдә чуртан булып калуы. — Татар вакытлы матбугатында «Галия» мәдрәсәсен Чулпан йолдызына тиңләп мәкаләләр басыла. Бабич, шушы чагыштыруны файдаланып, «Галия»нең Уфа байларының байкоты сәбәпле, ярдәмчесез, акчасыз калуына ишарә итә.
«Сабах» — Казан 1908 елның 15 маенда ачылган китапханә, нәшрият. Җитәкчеләре — Габделвәли һәм Габделгали Әхмәдуллиннар.
«Вәрисәи Хәсәния» — Уфадагы мәдрәсә.
Галимҗанның кызларны үкертеп җылатуы — Г. Ибраһимовның «Дарелмөгаллимәт»тә кызлар укытып йөрүенә ишарә.
«Дин вә дөньяга имгәк» — «Дин вә мәгыйшәт».

«домашний маскарадлар» урчетеп... — Уфада күбәеп киткән азгынлар, притоннар, азгын байбәтчәләр оештырган мәҗлесләргә ишарә.

...кечек-кечек Распутиннар зәһир булды! — аферист, әхлаксый һәм политик яктан тотнаксыз кайбер «җәмгыять эшлеклеләренә» ишарә.

Сәфәр алдыннан *(359 бит).* — «Кармак» журналының 1917 ел 10—11—12 санында (сентябрь) «Шәррам-яра» имзасы белән басылган.

Коръән тәрҗемәсе түгел ул хәтле! — Муса Бигиевнең, Корънне тәрҗемә итә башлагач, карагруһ динчеләр тарафыннан кискен каршылыкка очравына ишарә.

«Исрек» идарәсе... — 1917 елның 22 мартыннан 11 сентябренә кадәр Уфада Г. Ибраһимов редакторлыгында (барлыгы 35 сан) чыккан «Ирек» исемле сул эсерлар газетасы хакында сүз бара.

Иялере булмаганга күрә... — Бабич «Ирек» газетасы идарәсенә кергән көннәрдә (1917 елның июль ахыры) Г. Ибраһимов белән Ф. Сәйфи-Казанлы (редактор һәм җаваплы секретарь) Казанда булмыйлар: Г. Ибраһимов Бөтен Россия мөселманнарының Икенче съездында, Ф. Сәйфи-Казанлы Гомуми хәрби съездда.

«Мәшрикъ» — Уфада Кәримовларның «Шәрекъ» матбагасы. «Тормыш» газетасы шул матбагада басыла.

«Котормыш» идарәсе — «Тормыш» газетасы идарәсе дип аңларга кирәк.

Мисыр әл-Каһирәдән мәгълүмат төяп кайткан Каһир әл-Кадири — «Тормыш» газетасы редакторы Закир Кадыйри хакында сүз бара.

Көлке журналлары — иң беренче чиратта, Бабич язышкан «Кармак» журналы күз уңында тотыла.

...зат галимнәренә таяк төшкән иде. — Монда «Кармак» журналында Закир Кадиригә багышланган түбәндәге эпиграмма хакында сүз бара:

Әл-Кадирның кадере төшмәк әлмисактан мөктәдир,
Аклына, фәһменә истибдадлы хиссият мөдир...

Баттал — Габделбарый Баттал (1874—1959), тарихчы.

Муса — Муса Бигиев (1973—1949), Петербург мулласы.

Галимҗан яклымы, Гомәр әфәнде партиясендәме? — Сүз 1917 елның җәй-көз айларында Уфадагы политик төркемнәр көрәшенең иң үзәгендә кайнаган Галимҗан Ибраһимов һәм Гомәр Терегуловлар хакында бара. Гыйләҗ Гумирский 1917 елның июнь — июль айларында Уфа мөселманнар съездында шундый көрәшнең кискен төс алуы турында түбәндәге фактны китерә. Съездда Гомәр Терегулов авылларда ярлы крестьяннарның алпавыт, бояр җирләрен тартып алуларына каршы сөйли башлый. Г. Ибраһимов аңа каршы протест белән чыга. Тавышгаугa китә. «Моннан соң галимҗанчылар — Ибраһимов яклылар — «Шура»чыларга (съездга килүчеләргә.— *Г. Г.*) катнашмадылар. Алар Мәҗит Гафури фатирына китеп, киңәшмә үткәрделәр. Монда, киңәшмәдә, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Алпаров, Ш. Бабич һәм башкалар катнашты. Авылны үзебезгә тартырга тырышу, каланың фәкыйрьләре белән берләшү хакында сүз барды». (Карагыз: Ү з б ә к Г н м а д н е в. Талант һәм хезмәт. Өфә, 1982, 38—39 битләр.)

«Ирек» газетасы һәм Г. Ибраһимов җитәкчелегендәге сул эсерлар төркеме («туфракчылар») тирәсенә тупланган укымышлыларны бу чорда халык телендә «Галимҗан партиясе»: яисә «галимҗанчылар» дип йөрткәннәр, ә инде «Милли-мәдәни мохтарият» яклы Г. Терегулов иярченнәрен «Гомәр партиясе» яисә «гомәрчеләр» дип атаганнар.

«Иман шарты» — аллага ышануны белдерә торган догалар җыентыгы, Казанда 1874 елда басылган; сүзләр (догалар) гарәп һәм татар телләрендә алфавитка салып бирелгән.

милләтче, социалист, буржуй, кадет... — «милләтче», «социалист» яисә «милләтче-социалист» төшенчәләре Бабич тарафыннан «туфраклы автономия» яклыларга карата кулланыла; «буржуй», «кадет» төшенчәләре югары сыйныф вәкилләре мәнфәгатьләрен алга сөрүче шовинист байбәтчәләргә карата әйтелә.

С. Р. — эсерлар (социал-революционерлар) партиясе хакында сүз бара.

Кызыл флаг — Ш. Бабич язмаларында «кызыл флаг» «сул социалистлар»ның (Г. Ибраһимов термины), ягъни сул эсерлар белән большевикларның политик төркемнәрен символлаштыра.

Яшел флаг — мөселманнар берлеге идеясен гәүдәләндерүче символ.

Кара флаг — бу символ Бабич иҗатында кадетларга һәм башка карагруһ партияләргә, төркемнәргә карата кулланыла.

«Икенче корылтай җыелышы» — 1917 елның июль аенда Казанда узган Бөтен Россия мөселманнарының Икенче съезды хакында сүз бара.

22 июль, сәгать унда милли-мәдәни мохтарият игълан кылынды! — Казан шәһәрендә җыелган Икенче мөселман съездында игълан ителгән милли-мәдәни автономия» хакында сүз бара.

Мөфти хәзрәт — Сафа Баязидов.

«Гамәлгә куя башларга» — актив эш, кампания башларга, дип аңларга кирәк.

Үз тормышымызны үземез ясарбыз... — Шагыйрь бу шигъри парчада үзенең 1915 елда иҗат ителгән «Дөньяга» исемле әсәрендәге шигъри юлларны, поэтик алымнарны файдаланган.

Рәмиев — Закир Рәмиев (Дәрдмәнд).

Никулай-Микулай — Николай II (1866—1918), соңгы рус императоры (1894—1917).

Сарай серләре *(368 бит)*.— «Кармак» журналының 1917 ел 10—11—12 санында (сентябрь) «Шәрран-яра» имзасы белән басылган.

Хөрриятгән соң... — патша хөкүмәте бәреп төшерелгәннән соң, Февраль революциясеннән соң дип аңларга кирәк.

Татар хөкүмәте — 1917 ел ахырында Уфада булып узган Милләт мәҗлесендә сайланган «хөкүмәт» хакында сүз бара булса кирәк. Анда түбәндәге урыннар билгеләнә: 1. Төрек-татар милли идарәнең рәисе — Садри Максудов; 2. Диния нәзарәте рәисе — Галимҗан Баруди; 3. Мәгариф нәзарәте рәисе — Нәҗип Корбангалиев; 4. Маллия нәзарәте рәисе — Шәйхулла Алкин. Милләт мәҗлесенең баш рәисе — Бинигамин Әхтәмев.

«Милли-мәдәни кургагыять» — «Милли-мәдәни мохтарият».

...татар хөкүмәтеннән үпкәләп аерылган кавем башкортның үз алдына ханлык корганы, вә аның хан вә вәзирләренең Оренбур шәһәрен пайтәхте иттихад иткәнлекләре.— Мөселманнарның Беренче съездында аерылып чыккан башкорт делегатларының политик активлыгы 1917 ел барышында бәйсез Башкортостан хөкүмәте төзү өчен юнәлдерелә. Моның өчен иң уңай урын Оренбург булганлыктан, башкорт милли хәрәкәте вәкилләре ноябрь — декабрь айларында шәһәргә ныклап төпләнеп алалар һәм аны башкала дип игълан итәләр.

Распутин кыйссалары... — аферист, азгын Распутин тәртибенчә булган вакыйгалар, дип аңларга кирәк.

Баш министр Садри әфәнде — 1917 елның 20 ноябрендә Милләт мәҗлесендә сайланган Милли идарә рәисе Садри Максуди.

Шонаси — Габдулла Шонаси (1885—1938), педагог, татарча беренче химия дәреслекләре авторы, тәрҗемәче; 1917—1918 елларда Милләт мәҗлесендә һәм Милли идарәдә актив катнаша, сабак-мәгариф

нәзарәте әгъзасы була. 1918 елның җоеннән мөселман комиссариатында эшли; 1930 елларда ТКУ укытучысы.

«Кимияви мохтарият» — Бабич монда Г. Шонасиның химия фәне буенча белгечлеге белән политик тотнаксызлыгы арасында ироник янәшәлек куллана.

Закир әл-Кадири Бохарадан алып кайткан «әфьюн» истигъмал итәр. — Монда Милләт мәҗлесендә актив катнашкан Закир Кадириның яшьлегендә Бохара мәдрәсәләрендә белем алуына ишарә ясала.

...хатын вәзир Әминә Мөхетдинова — ?

Һади Атласи (Рәхмәтулла) — Һади Атласов (1879—1938), тарихчы, Бөгелмәдән II Дума депутаты, Октябрьдән соң эмигрант.

Җомга көннәрдә... эчәләр — Диния нәзарәте карары буенча, җомга көннәрдә аракы сату тыелгач, өйләрендә төрле исерткеч эчемлекләр ясаучыларга ишарә.

Һади абзый — Һади Максудов.

мөфти хәзрәт — Сафа Баязидов.

«Оренбургта башкорт ханлыгы» — Мәскәүдә узган Бөтен Россия мөселманнарының Беренче съездында съездны ташлап чыккан башкорт делегатлары «Башкорт бюросы» төзиләр. 1917 елның августында ул Мәркәз шура дип атала башлый, ә 15 ноябрьдә Оренбургта «Кече Башкортостан» автономиясе игълан ителә. Ш. Бабич шул хөкүмәт хакында яза.

баш вәзир Манатов — Башкорт Мәркәз шурасының рәисе Шәриф Манатов хакында сүз бара. 1918 ел башында Оренбург төбәгеннән Учредительное собраниегә сайланып киткәнче Ш. Манатов башкорт милли хәрәкәтенең башында тора һәм аның төп политик юнәлешләрен билгели. «Туфраклы Башкортостан автономиясе» дә аның идеясе. Мөселман халык комиссариатында М. Вахитов урынбасары булып эшләү чорында да ул шушы идеяне тормышка ашыру өчен көрәшә. Ә инде 1919 елның февраль аенда Башкорт хөкүмәтенең Совет власте белән союзы мәсьәләсе көн тәртибенә куелгач, ике якның килешүе хакындагы документларны, «Кече Башкортостан» совет автономияле республикасы проектын төзү дә Ш. Манатовка йөкләтелә. Шул рәвешле, башкорт гаскәрләренең кызыллар ягына чыгуында аның да роле зур.

мөгавин вәзир Зәки Вәлиди — башкорт милли хәрәкәтендә иң абруйлы кеше булса да Мәркәз шурада да, «Кече Башкортостан» хөкүмәтендә дә Зәки Вәлидов Ш. Манатовның урынбасары дәрәҗәсеннән узмый.

Троицкида *(327 бит).* — Уфага, шагыйрь Җамалетдин Юмаевка җибәрелгән шәхси хатның «Тормыш» газетасында (1917 ел, 22 март, 615 сан) мәкалә буларак басылып чыккан варианты. (Бу хат хакында Сәйфи Кудаш истәлекләрендә дә телгә алына.)

Текст, бераз кыскартылып, «Тормыш» газетасыннан алынды.

Сафа Баязидов — Февраль революциясеннән соң халык массалары басымы астында мөфтилеген ташларга мәҗбүр булган рухани. Соңыннан аның доносчы булуы ачыклана.

Капкаев — Уфа руханиe Гыйният Капкаев хакында сүз бара.

КӨЙЛӘР ТАРИХЫ *(373 бит).*

Ш. Бабичның 1922 елда Казанда басылып чыккан «Шигырьләр мәҗмугасы»ннан (төзүче Галимҗан Ибраһимов) алынды.

Казан ханлары руска бирелеп беткәндә дә... — XVI йөздә Казан ханлыгы ут һәм кылыч ярдәмендә Россиягә кушыла. Монда шул тарихи вакыйгаларга ишарә бар.

ХАТЛАР, КОТЛАУЛАР

Ш. Бабичның казакъ далаларыннан туганнарына язган хаты *(387 бит).*— Шагыйрьнең сеңлесе Фәсәхәт Бабич (1913—1987) истәлекләре буенча китерелә. Хатның күчермәсе җыентыкны төзүче архивында саклана.

Яшә, Нәкый! *(388 бит).*— Бу котлау шигыре Нәкый ага Исәнбәт истәлекләре буенча китерелә. 1913 елның март башында Ш. Бабич һәм казакъ шәкерте Әхәт Маҗитов белән бергә «Хөсәения» мәдрәсәсенә килә. Шунда алар Нәкый шәкертне очраталар һәм аның кульъязма шигырьләр җыентыгын алып китәләр. Апрель аенда кабат пәйда булган Бабич Нәкыйгә кульъязма дәфтәрне һәм әлеге мактау шигырен бирел китә. (Карагыз: «Казан утлары», 1967, 6 сан 12,7—128.)

Ш. Бабичның Вәли Хангильдинга язган хаты (1916 ел, октябрь) *(389 бит).*— Хат 1916 елның җәендә Уфада Бабич белән бер фатирда торган һәм бер мәдрәсәдә укыткан Вәли Хангильдин истәлекләре буенча китерелә. (Карагыз: «Совет әдәбияты», 1959, 5 сан, 99 бит.)

1916 елның сентябрь башында «Чүплек баш» мәдрәсәсеннән киткән Вәли Хангильдин урынында Ш. Бабич укыта башлый. Хатта шул мәдрәсә тормышы турында сөйләнә.

«Әфтияк», «Коръән» — дини китаплар.

М. Гафуриның «Милли шигырьләре» — М. Гафуриның 1907 елда Казанда Шәрәф матбагасында басылган шигъри җыентыгы.

Ш. Бабичның Вәли Хангильдинга язган хаты (1916 ел, ноябрь) *(390 бит).*— «Совет әдәбияты» журналының 1959 ел 5 саныннан алынды.

Җәдит муллалар — алдынгы ысул белән укытучы мулла-мөгаллимнәр.

Алмата — хәзерге Алма-Ата шәһәре.

«Кармак» мөхәррире Мәрҗани — Мәхмүт Галәү (1887—1940).

Озакламый шул Ырынбурга китәрмен шикелле...— «Кармак» журналыннан берничә тапкыр чакыру алып, инде Оренбургка дип юлга чыккан Бабич 1916 елның ноябрендә кинәт кенә Троицк шәһәренә балалар укытырга китеп бара.

Кылычбайга *(391 бит).*— Бу шигъри юллар С. Кудаш истәлекләре буенча китерелә.

«1917 елның сентябрендә мин аңа (Ш. Бабичка.— *Г. Г*) корбан бәйрәме уңае белән шаярып, түбәндәге котлауны язып җибәрдем:

Дускаем, сиңа телим алтын тәхет,
Тәхтенә куисын китмәс, бетмәс бәхет.
Тиндәшсез, карун кебек чергән бай бул,
Гомер ит үлгәнчә дөбердәтеп!..
Ходайдан телим сиңа мин дүрт кәләш,
Җитмәсә, бишенчегә тагын ярәш!
Әйләнәңне чолгап алсын бала-чаган,
Өеңдә тукталмасын ызгыш-талаш!..
Тавыштан-талашудан башың катсын,
Өнеръәеп ике күзең эчкә батсын...
Аптырап, эш кылудан гаҗиз калгач,
Күзләреңнән елга-елга яшьләр аксын!...

Моңа каршы Бабич 1917 елның 14 сентябрендә меңа дүртьюллык шаяру шигыре белән җавап кайтарды. Ләкин бу шигырь аның үзенеке түгел, бәлки шагыйрь Т. Чнәкәйнең Хөсәеновлар нәшриятының Уфа бүлекчәсе тарафыннан бастырылып сатылган бер визит карточкасы иде. (Карагыз: С. Кудаш. Хәтердә калган минутлар. Казан, 1959, 73—74 битләр.)

Ш. Бабичның Сәйфи Кудашка язган хаты (24 февраль, 1917 ел) *(392 бит).*— Хат Сәйфи Кудаш истәлекләре буенча китерелә.

1917 елның январь азакларында С. Кудаш Бабичның псевдонимы булган «Шөбшә»гә адресланган хат рәвешендә «Уфа хәлләре» исемле кечкенә фельетон яза һәм аны Оренбургка «Кармак» журналы редакциясенә җибәрә.

«Кармак» журналының 1917 ел 3 санында (1 февраль) С. Кудашның Ш. Бабичка атап җибәргән ачык хаты басыла. Ләкин, ни өчендер, редакция хезмәткәрләре Бабичның исемен сызып ташлап, «Журналыбызның мөхәррирләреннән берсенә килгән хосуси хаттан» дигән анлатма биреп, бастырырга кирәкле тапканнар. 24 февральдә Бабич С. Кудашка әлеге җавап хатын яза, әмма аны почта аша җибәрә. (Карагыз: С. Кудаш. Күккә үрләгән еллар.— «Агизел», 1965, 7 сан, 65 бит.)

«Уфа хәлләренең мөндәриҗәсе...» — Бу мәкалә «Кармак» журналының 1917 ел 4 санында (15 февраль) басылып чыга.

Г. Ибраһимовтан аерылгансыз икән.—Февраль революциясеннән соң Г. Ибраһимов «Галия»дән китә һәм «Ирек» газетасы чыгара башлый (1917 ел, 30 март).

Галимҗаннан хат бар иде.— Г. Ибраһимов безгә мәгълүм булмаган бу хатында Ш. Бабичны Уфага чакыра, «Ирек» газетасында эш тәкъдим итә.

Ш. Бабичның Сәйфи Кудашка язган хаты (13 март, 1917 ел) *(393 бит).*— С. Кудаш истәлекләре буенча китерелә. (Карагыз: «Агизел», 1965, 7 сан, 66 бит).

Распутин — Г. Е. Распутин (1872—1916) — Себер мужигы, хлыстлар дини сектасы члены, аферист. Патша сараена үтеп кереп, аның якын кешесенә, хатынының сөяркәсенә әверелә. Эчке эшләр министры дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән бу кеше үз властен үзенә файдалы махинацияләр, чиктән чыккан азгын эшләр өчен киң файдалана. Распутинны 1916 елда князь Ф. Ф. Юсупов, Дума депутаты В. М. Пуришкевич һәм бөек князь Дмитрий Павловичлар үтерә.

Мөфти — Сафа Баязидов.

«Хөр милләт» — Ш. Бабич Троицк шәһәрендә, Февраль революциясеннән соң ук, 1910 елларда Истамбулда чыккан «Тәгарифел мөслимин» дигән журналда эшләгән, 1915 елларда Оренбургтагы «Шура» журналында язышкан Әхмәт Таҗетдин Рахманкулов белән, аның редакторлыгында, «Хөр милләт» исемле газета чыгарып йөри.

Беренче санында минем бер шигырем басылачак — «Яшәсен эшчеләр!» әсәре хакында сүз бара.

Ш. Бабичның Сәрвәр Әдһәмовага язган хаты (29 июль, 1917 ел) *(394 бит).*— Хат Сәрвәр Әдһәмова истәлекләре буенча китерелә («Совет әдәбияты», 1957 ел, 1 сан, 99—101 битләр.)

Сәрвәр — язучы һәм тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмова (1901—1978). 1916—1918 елларда Бабич белән якыннан аралашкан кешеләрнең берсе.

Сеңелең...— Саҗидә Әдһәмова.

З. Даминов — «Кармак» журналының нашире.

Һәр җәһәттән иң өстен торган бер туташ...— Җәмилә Ибраһимо-

ва-Нафикова, медсестра булып эшли. Ул соңыннан композитор, драматург Хәбибулла Ибраһимовның хатыны.

«Дәрелмөгаллимәт» — «Галия» мәдрәсәсе каршында ачылган мөгаллимәләр әзерләү курслары.

«Вазифа» — Уфадагы мәдрәсә.

Ш. Бабичның Төхфәт Ченәкәйгә язган шигъри хаты (январь, 1918 ел) *(397 бит).*— Хат Төхфәт Ченәкәйнең югарыда телгә алынган истәлеге буенча китерелә.

Хатны язам... Баймактан.— Башкорт хөкүмәте бу чорда Баймак тирәсендә.

«Зәне» — Зәки Вәлиди хакында сүз бара.

Ару булыр иде... кусалар.—1918 елның җәеннән Ш. Бабичның З. Вәлиди белән мөнәсәбәте катлаулана.

бер мәкалә — бу мәкаләнең язмышы билгеле түгел.

Мәхмүт — Мәхмүт Галәү.

...бастырсын «Кармак»ка — «Кармак» журналының туктап калуы сәбәпле бу мәкалә дөнья күрми кала. Әмма мәкалә дә, шигъри хат та Мәхмүт Галәүгә тапшырылган булырга тиеш. Бу шигъри хатның күчермәсе бүгенге көнгә кадәр М. Галәүнең беренче хатыны Хәдичә Тартищева (Ташкент) архивында сакланган.

...сердәшем — Ш. Бабич оренбургта Т. Ченәкәй белән бер фатирда яши.

Ш. Бабич — Т. Ченәкәй әйтешүләре (1) *(400 бит).*— «Әзәби Башкортостан» журналының 1960 ел 6 санында басылган Төхфәт Ченәкәй истәлегеннән алынды.

«балык тоту» — бу урында, тормыштагы, кире якларны фашлап язу, дип аңларга кирәк.

«Кармак» — журнал.

Ш. Бабич — Т. Ченәкәй әйтешүләре (2) *(401 бит).*— «Әзәби Башкортостан» журналының 1960 ел 6 санында басылган истәлектән алынды.

Асып куйыйк «Кармак»ка — «Кармак» журналында каты тәнкыйтьлик, дип аңларга кирәк.

Чалмалы «Дин мәгыйшәт» — «Дин вә мәгыйшәт» (1906—1918, Оренбург) журналының карагруһ динчеләр органы булуына ишарә.

Т. Ченәкәй — Ш. Бабич әйтешүләре *(403 бит).*— «Әзәби Башкортостан» журналының 1960 ел 6 санында басылган истәлектән алынды.

«Кармак» җебе — шагыйрь үзе белән Оренбургка тәнкыйть өчен бик кирәкле сатира, юмор, көлке рух алып килүен белдерә.

Ярулла — татар язучысы һәм драматургы Вәли Ярулла (1879—1934).

Җамал — татар теле һәм әдәбияты галиме, педагог Җамал Вәлиди (Вәлидов, 1887—1938).

Камал — язучы Шәриф Камал (1884—1942).

Мәрҗани — журналист, язучы Мәхмүт Галәү (Мәрҗани, 1887—1940).

Дәрдмәнд — шагыйрь Закир Рәмиев (Дәрдмәнд, 1859—1921).

Ченәкәй — шагыйрь Төхфәт Ченәкәй (Сәмави, 1893—1959).

...сагнып килдем.— Ш. Бабич Оренбургта Вәли Ярулла, Шәриф Камал, Мәхмүт Галәү, Җамал Вәлиди, Төхфәт Ченәкәйләр белән якыннан аралашып яши. Ул шулай ук өлкән шагыйрь Дәрдмәнд янына барган, аның фатихасын алып калу бәхетенә ирешкән. (Т. Ченәкәйнең югарыда телгә алынган истәлеген карагыз.)

Ш. Бабич — Мәхмүт Бөдәйли әйтешүләре *(404 бит)*. — М. Бөдәйлинең «Совет әдәбияты» журналының 1965 ел 1 санында басылган истәлегеннән («Ул тормышны сөя иде») алынды.

«Матбугат клоуны» — Ш. Бабичның халык арасында киң таралган кушаматы. Моннан кала аны «Мәшһүр көлдерүче», «Көлкә капчыгы» дип тә йөрткәннәр.

«Кигәвен»— журналист Мәхмүт Бөдәйлинең псевдонимы.

КӨНДӘЛЕК ЯЗМАЛАР

Себер сахрасында казакъта йөргән көннәрем *(407 бит)*.— Хатип Госман архивындагы күчермәләрдән алынды. Бу көндәлек язмалар беренче мәртәбә Гомәр Толымбай тырышлыгы белән «Яналиф» журналының 1929 ел 16 санында дөнья күрәләр.

4 аем — Ш. Бабич казакълар арасында май, июнь, июль, август айларында укыта.

Теге исәпләр — күп акча эшләү исәпләре дип аңларга кирәк.

Дусәнбай — Казакъстанның Тургай өлкәсендәге авыл.

Минем әти исә мулла — имам, мөдәррис Мөхәммәтзакир Бабичев.

Мәдинә — сүз ислам дине үзәкләреннән берсе Мәдинә шәһәре хакында бара.

Галия, Хакимия — Уфадагы мәдрәсәләр.

Сәрвәр мәзин — Ш. Бабичның туган авылындагы (Әсән авылы, Дүртөйле районы, Башкортстан АССР) икенче мәхәллә мәзине. Имамы — Мөхәммәтзакир Бабичев.

Сәйфетдин Гыйльметдинов —?

Зәйни — Ш. Бабич белән бергә казакъ балаларын укытырга килгән Уфа шәкерте.

улаң язу — шигырь язу дип аңларга кирәк.

Мортаза мулла — Ш. Бабич фатирда торган казакъ кешесе.

Землянкага барып, анда торган чакларымны хәтерләп йөрдем — 1910 елда Ш. Бабич Дусәнбайда бер җәй укытып киткән була инде. Көндәлектә шул беренче сәфәр искә алына.

«Кырык мисал» — китап исеме.

«Ибраһим Кунанбай үләңдәре» — казакъ шагыйре, мәгърифәтче Абай (Кунанбаев Ибраһим, 1845—1904) җыентыгы.

«Имрә-әл-кайс» — Ислам динен кабул иткәнгә кадәрге чорда яшәгән гарәп шагыйре. Туган елы мәгълүм түгел, 540 елда үлгән.

Хәмзә —?

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧНЫҢ БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

Яшь Башкордостан: (Зәңгәр җырлар). I-кит.— Оренбург: Тулкын, 1918.

Шигырьләр мәҗмугасы. I-кит. Г. Ибраһимов ред. һәм кереш сүзе.— Казан: Татгосиздат, 1922.

Бабич Шәехзадә шигырьләре. I-кис.— М.: СССР халыклары үзәк нәшр., 1925.— Татар һәм башкорт телендә.

Сайланма әсәрләр: Шигырьләр. Х. Госман кереш сүзе.— Казан: Таткитнәшр., 1958.

Һайланма әсәрзәр. Ә. Харисов кереш сүзе.— Өфө: Башкитнәшр., 1958.— Башкорт телендә.

Избранная лирика / Пер. с башк.— Уфа: Башкнигосиздат, 1966.

Шигырзар, поэмалар. Р. Бикбаев кереш сүзе.— Өфө: Башкитнәшр., 1985. — Башкорт телендә.

ЭЧТӘЛЕК

Төзүчедән 5
Көяшлы шигърият. *Галимҗан Гыйльманов* 7

ШИГЫРЬЛӘР, БАЛЛАДАЛАР, ПОЭМАЛАР

1910

И китаб! 17
Бәхетсез мин 18
Охотник 19
И дусларым 22
Ике шәкерт 22
Янгыр теләге 23
Син алдама 25
Безнең бакча 26
Олактырылган песи 27
Гашыйк дустыма 28
Куркак 29
Миңа юнь, ичмасам 30
Зарлану 31

1911

Кәҗә белән дуңгыз 32
Нәсихәт 33
Чеп-чи надан 34
Тик тору артык 34
Күңел 35
Габдулла әфәнде Тукаев 36
Моңланам 37

1912

Сабантуй һәм милли бәйрәмнәр 38
Кызгана 41
Шаккаттыра 42
Вөҗдан һәм нәфес 43

Имеш . . . 44
«Галия» җырлары . . . 44

1913

Тукай үлгәч . . . 45
Җырчыны көткәндә . . . 46
Кыйтга (И ходаем, мал-милек...) . . . 47
«Рәхмәт, апай...» . . . 47
Күңелсез чакта . . . 48
Күңелле чакта . . . 48
Һатиф вә татар . . . 49
Кадим мулланың сүзе . . . 51
«Агыйделдән саллар ага...» . . . 52

1914

Халкым өчен . . . 53
Бай һәм ярлы . . . 54
Бер минут . . . 55
Айга мендем . . . 56
Ярсынмаса күкрәк . . . 57
Кыйтга (Нәфес — шайтан...) . . . 57
Мандолин . . . 58
Ярканат . . . 59
Бәгъзе студентларыбыз . . . 60
Бер муллага . . . 61
Самад өслүбе . . . 62
Таркау уйлар . . . 65

1915

Әйдә, милләт! . . . 66
Мөтәшагыйрь зары . . . 66
Скрипка . . . 67
Кыйтга (Фәлсәфәдән туйдык инде...) . . . 68
Кыйтга (Куй нәфесне иркенә...) . . . 68
«Әйдә, күңлем, монда торма...» . . . 68
Көрәшеп үткәр кыска гомереңне . . . 69
Гөнаһ — җәза! . . . 70
Аптыраган минутларда . . . 71
Аптыраш! *(вариант)* . . . 72
Шәмсетдин Суфый авызыннан . . . 73
Әй адәм балалары . . . 74
Актык зарым . . . 76
Ауруым — саулыгым . . . 76
Кинәшләр . . . 77
Җәй көне урамда . . . 78
Бер эчүченең зары . . . 79
Хәзрәте Сүнчәләй рухына . . . 80
Тимергә . . . 81
Бәнем фәрештәм . . . 82
Канун тыңлаганда . . . 83
Дөньяга . . . 85
Безнең мужик . . . 87

1916

Котәм 88
Телимен 89
Очтылар 89
Гамьле көн 90
Язгы бәйрәмнәр 91
Кем? 92
Аңладым 93
Бер тәмсил 94
Кышкы юл 98
Ямь күрәлмәм 99
«И улым...» 99
Мин — даhи! 100
Ямьле көн 101
Шатлык җыры 101
Кисас 102
Алты ел 103
Аның өчен 104
Карангылыкта 105
Бәхетем 106
Әллә алла, әллә иблис 107
Кем өчен? 107
Яз тасвиры 108
Мунча роэясе — роэя боткасы 109
Гөл чәчәкләре 110
Каз бәбкәләре 112
Читлектәге сандугач янында 114
Тын төн (Авылда) 115
Көфү түгел 116
Хәлемездән бер күренеш 116
Яшь шагыйрьгә 117
Яшәсен кыйммәтчелек! 118
«Менә әле генә Каф тавыннан...» 119
Мәгърифәт сатучыга 120
Кыз 121
Кызык бетте 122
«Беләм, Мәхмүт, ялчы булу бик кыен эш...» . . . 122
Гаед узгач 123
Гаед корбан 124
Сажидәгә 125
Тешсез кыз 126
«Әсма» китабындагы шигырьләргә тәхмис 127
Шатлык котәм 128
Ул 129
Кандала 130
Газазил 136

1917

Котәләр 157
Өзеләсең дә сызыласың 158
Зөфәргә 159
Мөсәххих һәм наборщикларга 160
Ташланган ворокаләр 162
Тәмсил кисәге 164

Хөррият бүләге 165
Яшәсен эшчеләр 167
Котлау, теләк 169
Уйлар уртасында 170
Әй, Әфләтун! 170
Мәхәббәт тоткыны 171
Күбәләк вә мин 172
Табигать оҗмахы 173
Матур сыннар 174
Әкълимәгә 175
Гаед көне 176
Дим буе җырлары 177
Мәхәббәт җырлары 178
Йә әййеһәл мөселман 179
Байларга 180
Утрау 181
Җанкаем! 185
«Кигәвен» дуска 186
«Бик имин мин...» 186
Мөртәт социалистларга 187
Солдатка алынган бер дустыма 188
Беренче номерлы список 189
Мин китәр чакта 190
Кил, чибәр 191
Хәсрәт сагызы 192
Кызыл вәгазь 193
Әй Гайдани! 196
Әй большевик! 196
Буржуй! 197
Тупрак! 198
Список № 9! 199
Кан шәүләләре 200
Сугыш 201
Үткән көннәр 202
«Кулларымда кәкре башлы...» 203
«Әйдә, бие, бабушка...» 203
Яшь шагыйрьнең кабер ташында укыдым 204
Миндә кеч 205
Зөһрәгә 206
Шәмсекамәргә 207
«Кара бүрек бетә, диләр...» 207
Багъбостанда 208
Исемнәр бакчасы 209
Җырлар 216
Афарин! 217
«Уйлап, уйлап, уйга чумсаң...» 218
«Диңгезләрне чайкап дулкынлаткан...» 218
«Намус өчен...» 219

1918

«Барган идем стансага...» 219
Гыйшык 220
Ни эшли? 221
Икенче гыйнвар көне 222

Байрам 223
Курайкайга 224
Гаскәр маршы 226
Башкордәстан 227
Салауат батыр 229
Көтмәсдән 230
Ике аккош 232
Күзенне ач! 234
Шәфкатем 236
Дошманнар 237
Язгы җыр 238
Юк... 240
Юк... *(вариант)* 240
Шагыйрь башы 241
Хәсрәтле җырлар 242
Уң аягым белән сул аягым 242
Китер 243
«Исә җилләр, өсрелә болытлар...» 243
Без 243

1919

Большевиктәр белән килешү туралы башкорт халкына көйле китап 244
Яраштык 249

ӨЙРӘНЧЕК ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘР

1907—1909

Котлыйм 253
Бакчабызда 253
Авыл җырлары 253
Татар театры 254
Авыл мәдрәсәсе такмаклары 256

КИТАБЕННАС ФИ ХАККЫЛХАВАС

1916—1918

Китабеннас фи хаккылхавас 257
Бер изах 263
Иктарчык 264
Китапның үзе 264
Хәтимә 284
Зәил 285
Янартылганнар 286

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧНЫКЫ БУЛУЫ ИХТИМАЛ ӘСӘРЛӘР

Сабиягә 288
Иптәшем татар шәкертенә 289
Юк! 290
Кайда китәм? 291

Авыл жырлары (Тукайга тәкълид) (1) 292
Авыл жырлары (Тукайга тәкълид) (2) 293
Авыл жырлары (1) 294
Авыл жырлары (2) 295
Авыл жырлары (3) 296
Авыл жырлары (4) 297
Авыл жырлары (5) 298
Авыл жырлары (6) 299
Авыл жырлары (7) 300
Авыл жырлары (8) 301
Авыл жырлары (9) 302
Авыл жырлары (10) 303
Авыл жырлары (11) 304
Авыл жырлары (12) 305
Татарлар арасында 305
Фәтвасе һәм фәтвачесе 306
Мин 307
Таң вакыты (С. Рәмиевкә тәкълид) 308

ХИКӘЯЛӘР, МӘКАЛӘЛӘР, ФЕЛЬЕТОННАР

1912—1914

Әйтеп узыйм 311
Ишми сөенә 313
Мәкальләр фәлсәфәсе (1) 314
Мәкальләр фәлсәфәсе (2) 316
Әгәр дә мин булсам... 318

1916

Уфа тигезсезлекләре 319
«Мәдрәсәи Галия»нең ун еллык бәйрәме 321
Төрле хәбәрләр 325
«Көлкс капчыгы» җыентыгына сүз башы 326
Мөтәшәббиһат 327
Уфа кызыклары 330
Имза карагы 334
Уфадан 335
Уфа сәхнәсендән 338
Язу 341
Истә дә юк иске чикмән 344

1917

Ишан үлгәч 346
Уфа хәбәрләренең мөндәриҗәсе 357
Сәфәр алдыннан 359
Сарай серләре 368
Троицкида 372

КӨЙЛӘР ТАРИХЫ

1915—1918

Таштугай 375
Батыр старшина көе 375
Касыйм түрә көе 375

Буранбай 376
Сибай кантон көе 377
Чаптар юрга көе (бию көе) 378
Аллаяр батыр көе 378
Колый көе 379
Бер тирәк көе 379
Шүрәкәй яки Сәйфулла көе 379
Шабәрәк көе (Шаһи Мөбәрәков) 379
Үзәнбай көе 380
Бала карга 380
Газизәкәй көе 381
Сырдәрья көе 381
Туры ат көе 382
Каһарман кантон 382
Әлмән кантон 383
Кара калфак көе 383
Дәләкә батыр көе 383
Елан Пәркой 384

ХАТЛАР, КОТЛАУЛАР

1911—1918

Ш. Бабичның казакъ далаларыннан туганнарына язган хаты (1911 ел) 387
Ш. Бабичның Н. Исәнбәткә язган котлавы (1913 ел) . . . 388
Ш. Бабичның В. Хангильдингә язган хаты (1916 ел, октябрь) . 389
Ш. Бабичның В. Хангильдинга язган хаты (1916 ел, ноябрь) . 390
Ш. Бабичның С. Кудашка язган шигъри хаты (1917 ел, 14 сентябрь) 391
Ш. Бабичның С. Кудашка язган хаты (1917 ел, 24 февраль) . 392
Ш. Бабичның С. Кудашка язган хаты (1917 ел, 13 март) . 393
Ш. Бабичның С. Әдһәмовага язган хаты (1917 ел, 29 июль) . 394
Ш. Бабичның Т. Ченәкәйгә язган шигъри хаты (1918 ел, январь) 397

Ш. Бабич — Т. Ченәкәй әйтешүләре (1) 400
Ш. Бабич — Т. Ченәкәй әйтешүләре (2) 401
Т. Ченәкәй — Ш. Бабич әйтешүләре (3) 403
М. Бәдәйли — Ш. Бабич әйтешүләре 404
Көндәлек язмалар 405
Искәрмәләр 415
Шәехзадә Бабичның басылып чыккан китаплары исемлеге . 544

Литературно-художественное издание

Бабич Шайхзаде Мухаметзакирович

ГОЛУБЫЕ ПЕСНИ

Стихи, поэмы, эпиграммы, статьи, письма

(на татарском языке)

Художнигы *В. Булатов*
Художество редакторы *Ф. Хэсьянова*
Техник редакторы *А. Газизжанова*
Корректорлары *Р. Хэмидуллина, Т. Шакирова*

ИБ № 5800

Җыярга тапшырылды 5.10.89. Басарга кул куелды 7.05.90. ПФ 09023. Форматы 84×108$^{1}/_{32}$. Типогр. кәгазе № 2. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма, Шартлы басма табагы 28,56+рәс. 0.11×форзац 0,21 Шартлы буяу-оттиск 29,09. Нәшер-хисап табагы 26,83+рәс. 0,05+форзац 0,33. Тиражы 8 700 экз. Заказ З-472. Бәясе супертышлык белән 2 сум 20 тиен.

Татарстан китап нәшрияты.
420084. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство.
420084. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты.
420084. Казан, Бауман ур., 19.

2з 20т.